
# КАЗАН УТЛАРЫ

6. 1992



# 1992 ЕЛГЫ ТУКАЙ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ



Ә. Авзалова



С. Липкин

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләре комитетының тәкъдимен карап, Татарстан Республикасының 1992 елгы Г. Тукай премияләрен бирү турында карар кабул иттеләр.

Премияләр:

**Авзалова** Әлфия Авзал кызына — Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе җырчысы, 1989—1991 еллардагы концерт программалары өчен;

**Әгъләмов** Мөдәррискә (Әгъләметдинов Мөдәррис Зөфәр улы) — шагыйрь, «Киләчәккә кайту», «Мин әйттем» исемле китаплары өчен;

**Липкин** Семен Израилевичка — шагыйрь, татар халык эпосы «Идегәй»не (1990 ел) һәм татар шигърияте классикларын тәрҗемә иткәне өчен;

**Шәрәфиев** Равил Шиһап улына — Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты. Хуҗа Насретдин (Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ында), Кучкарбаев (Ч. Айтматовның «Ахырзаман»ында), Робинзон (А. Островскийның «Бирнәсез кыз»ында), доктор Ломбарди (К. Гольдониның «Ике хуҗаның хезмәтчесе»ндә), Ислам (Т. Миңнуллинның «Илгизәр + Вера»сында) образларын иҗат иткәне өчен бирелде.



М. Әгъләмов



Р. Шәрәфиев

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**6**

**(836)**

**1992**

**КАЗАН**

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Г. АФЗАЛ. Күңел яктысы. *Шигырьләр* ........ 3
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Сират күпере. *Роман* ........ 9
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Ирек юлы. *Поэма* ........ 43
А. ХӘЛИМ. Өч аяклы ат. *Повесть* ........ 52
Н. МӘДИЯР. Карыйм тауга, упкыннарга. *Шигырьләр* ........ 102
М. ХӘБИБУЛЛА. Көн сурәтләре. *Шигырьләр* ........ 105

ПУБЛИЦИСТИКА

Г. ГАЛИУЛЛИН. Замана балалары ........ 106

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

М. ШАБАЕВ. Таборы — учак янында ........ 147

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. ПОВАРИСОВ. Яфраклар коелмасын иде ........ 166

МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Р. ӘМИРХАН. Гали рухлы шәхес ........ 157
С. ИСХАКОВА. Рухи хәзинәләребезне саклаучылар ........ 170
Ф. БАЯЗИТОВА. Керәшен татарларының йолалары һәм йола жырлары ........ 174
С. АЛИШЕВ. Тарихи багланышлар ........ 181
С. ШАКИР. Очрашулар ........ 186

Ижтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

**Тәлгат Галиуллин**

**Аяз Гыйләҗев**

**Салих Маннапов**

**Зиннур Мансуров**

**Ростәм Мингалимов**

**Фәрваз Миңнуллин**

**Минтаһир Минһаҗев**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

**Ринат Мөхәммәдиев**

**Рашат Низамиев**

***(баш мөхәррир урынбасары)***

**Индус Таһиров**

**Марс Шабаев**

***(җаваплы сәркатип)***

**Тәүфикъ Әйди**

**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа Р. МУХАМАДИЕВА «Мост над адом», начало повести А. ХАЛИМА «Трехногий конь»; стихи Г. АФЗАЛА, Н. МАДИЯРА, М. ХАБИБУЛЛЫ, поэма Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ «Путь свободы».
«Публицистика»: Т. ГАЛИУЛЛИН. «Дети своего времени».
«Дружба литератур — дружба народов»: статья М. ШАБАЕВА «У цыганского костра»; цыганские сказки.
«Литературная критика»: статья С. ПОВАРИСОВА о проблемах современной татарской литературы.
«К истории культуры»: статьи Р. АМИРХАНА о просветителе и политическом деятеле Г. Еникееве, С. ИСХАКОВОЙ «Защитники духовных ценностей», Ф. БАЯЗИТОВОЙ «Обряды крещеных татар и их песни», С. АЛИШЕВА «Исторические связи», С. ШАКИРА «Встречи».
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»: картина художника Санкт-Петербурга Р. Даминова «У моря»; известный поэт, общественный деятель, лауреат премии М. Джалиля Р. Харис.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.

Производствога бирелде 29.04.92 ел. Басарга кул куелды 05.06.92 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 39321. Заказ В-194. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Гамил Афзал

### Күңел яктысы

*Гаяз Исхакыйга*

Гаяз ага, син ярлыка безне —
Йөк атлары, сукыр көчекләрне,
Безне ярыш белән план издe,
«Сыйнфый көрәш» безне үчекләде.

Хәтәр хәбәр сөйләп иртә-кичен,
Шомлы шаулап торды карурман.
Без дөньяны аңламасын өчен
Тимер пәрдә корып куелган.

Бар икән ул,
                Борынгыдан булган,—
Йола булып торган, баш булып,—
Утта янмый, суда батмый торган,
Җирдә ятмый торган Яхшылык.

Кайда кыйбла,
                Кайда дөрес иман —
Белер-белмәс көе юл үттек.
Бар икән ул утта янмый торган,
Суда батмый торган Егетлек.

Татар йөрәгендә тәхет биләп,
Кара почмакларны балкытып,
Безнең алда, изге теләк теләп,
Син баргансың икән шәм тотып.

Безне
        ил буенча куып-чәчеп,
«Бишъеллыклар» дигән кәрваннар,
«Алга, якты киләчәккә» дәшеп,
Инкыйразга алып барганнар.

Җәберләнгән милләттәшне күреп,
Ярып бирдең җаның яртысын —

---

Гамил АФЗАЛ (1921) — *Татарстанның халык шагыйре, татар, башкорт, рус телләрендә басылган күпсанлы шигырь, проза китабы авторы. Әлмәттә яши.*

Төрмәләрдә, сөргеннәрдә йөреп,
Сүнми торган күңел яктысын.

Бар икән ул сынмый торган иман —
«Сыйнфый көрәш» диеп көчләүсез,
Яшел урман булып шаулый торган,
Диңгез суы кебек үлчәүсез.

Сагына сине Идел камышлары,
Борыла-борыла аккан Чулманың.
Күңел нурын илгә багышладың,
Беркемгә дә дошман булмадың.

Түбәтәй дә комган гына түгел,
Иман икән күңел аклыгы,
Мазлумнарга ирек, бәхет теләү,
Иҗат икән — гомер шатлыгы.

Озын юлда ерак илләр җиле
Маңгаеңнан сыйпап искәндер,
Сагына сине татар-болгар иле,
Баһадирлар иле исәндер.

Соңгы өең Истанбулда икән,
Шул ай карый сиңа,
шул кояш.
Кайда да син безнең җан илчесе,
Күкрәгеңдә милли моң булгач.

## Төркиләр моңы

1

Төрки халык йөргән күчеп-күчеп,
Ак тирмәләр куйган болында,
Дастаннарын язган кымыз эчеп,
Батырлык вә сөю турында.

Көтү йөргән, учаклары янган,
Моң тирбәлгән шәфәкъ нурында,
Ядкарь булып дастаннары калган
Батырлык вә сөю турында...

2

Син — далада туган кыпчак улы,
Сиңа иксез-чиксез далаң булсын,
Шат йолдызлар янсын күгең тулы,
Таштан ясап куйган аллаң булсын.

Кысык күзле дала улын сөеп,
Серле аллаң карап торсын илгә.
Тайлар йөрсен ефәк ялын чөеп,
Кылганнар чайкалсын язгы җилгә!

3

Бу урында һуннар учак яккан,
Кыннарында кәкре пычаклар.
Җәя киереп монгол уклар аткан,
Киез тирмә корган кыпчаклар.

Давыл булып килгән, киткән яулар,
Дала яткан кара кайгыда,
Шаһит булып торган шушы таулар,
Шаһит булып калган ай гына.

4

Яулар үткән, үкереп үлән үскән,
Оҗмах түре кебек яланнар.
Сөңге чөеп күңел ачты микән
Бәҗәнәкләр белән аланнар?

Мең ел үткәч (дөреслеге шикле),
Баскынчылар яла язарлар:
«Юына да белми торган, бетле,
Кыргый халык булган хазарлар...»

5

*Шовинист тарихчыга*

«Тарих тулы илбасар да дурак,
Кан коючы, кыргый тираннар,
Килмәгәннәр безгә киңәш сорап,
Гел таларга план корганнар.

Азиатлар таладылар илне,
Алар сатты, алар сатылды...»

Синең халкың гына әйбәт инде,
Синең халкың гына акыллы!

6

Ничаклы дәүләтләр югалган,
Гайрәтле халыклар онтылган.
Чишмәләр үзенчә юл алган,
Үләннәр үсәргә омтылган.

Чәчәкләр кояшка елмая,
Яфраклар серләшә үзара.
Таулар бар, сулар бар дөньяда,
Еракка-еракка юл бара...

7

Дөнья тарихын беләбез:
    Һәр патшасын, һәр батырын.
Төрки тарихын белмибез,
    Ни ерагын, ни якынын.

Кояш чыга нурга манып,
Ерактагы җылы була.
Тарихын белмәгән халык
Белгәннәрнең колы була...

## Патриотизм

Оча торган тәлинкәгә утырып
Йолдызлардан килгән кунаклар
Бер әйтерләр кебек авыз тутырып:
— И дураклар монда, дураклар...

Оча торган тәлинкәгә утырып,
Йөрсәләр дә монда ялтырап,
Патриотлар әйтер авыз тутырып:
— Безнең галактика яктырак!..

* * *

Эзоп теле белән сөйләшкәндә
Мәгънәлерәк иде сүзебез,
Әдәплерәк иде ходавәндә,
Акыллырак идек үзебез.

Ирек алгач кыю эш кырабыз,
Нәфрәт тулы тонган күзебез.
Долой-фәлән, диеп кычкырабыз,
Ач юлбарыс кебек үзебез...

* * *

— Әйдәгез, иптәшләр, театрга,
Алдынгы хисләрне уятырга!
Берәү дә селкенми, берәү дә кымшанмый,
Берәү дә беркемгә ышанмый.
— Әйдәгез, иптәшләр, алга барыйк,
Кыйммәтле призлар, даннар алыйк!
Берәү дә селкенми, берәү дә кымшанмый,
Беркем дә беркемгә ышанмый.

— Әйдәгез, иптәшләр, иңсәгә-иңсә,
Тормыш яхшы булыр, безнең саф җиңсә!
Берәү дә селкенми, берәү дә кымшанмый,
Берәү дә беркемгә ышанмый.

## Нәүмизлек сүрәсе

Йа, илаһе, безнең гомер юлы
Үртәлүләр, кимсенүләр тулы.
Без — сытык чырайлы имансызлар,
Алла колы түгел, түрә колы.

Йа, илаһе, безнең гомер юлы
Алданулар, үкенүләр тулы,
Кешелеген җуйган адәм улы...
Без — ирексез, мәнсез, тамак колы.

Йа, илаһе,без дә эш яраттык,
Ударниклар дигән дан тараттык,
Хәзер бездә дәртсез, салкын күңел,
Ышанмау һәм өнсез битарафлык.

Йа, илаһе, тагын ни күрәсе,
Бармы безгә нык лы ил сүрәсе?
Әллә һаман башлык булып йөрер
Ялганчы һәм карак ил түрәсе?

* * *

Әй, күк дала, күк дала,
Күк дала да тар иде.
Ник моңайдың, бүз бала,
Бөркет чагың бар иде.

Каршыбызда карурман,
Карый-карый барабыз.
Син туган да, мин туган,
Ару булсын арабыз.

«Күпер башы күк томан»,
Язым бар да көзем бар.
Телем барда тик тормам,
Илгә әйтер сүзем бар.

Илле батман илемдер,
Илем күреп барамын...
«Барын-югын белмидер,
Бал телидер тамагым»...

* * *

Урал тавы киртләч-киртләч,
киртләч саен өркәч,
Рәхәт булыр кышлар үткәч,
яшел җәйләр җиткәч.

Берәү әйтә: — Яхшы булыр
яңа закон керткәч,

Оҗмах булыр, бюрократлар
«лаек ялга киткәч».
Ничекләр алга барырбыз
ил таланып беткәч?
Ярык тагарак янында
утырып тор, иптәш...

* * *

Кемнәргәдер һәрчак «дошман» кирәк,
Дошманлашу кирәк үзара,
Кара мәкер тулы явыз йөрәк
«Дошманнар»ны уйлап чыгара.

* * *

Тарих кабатланмый, диләр,
Кабатланмасын да!
Бармасын иске гөнаһлар
Заман арбасында.

Үткән гомер кире кайтмый
Ачу, нәфрәт тулып.
Агым сулар кире кайта
Кара болыт булып.

* * *

Мин халыкны талап тормас идем,
Әгәр патша итеп куйсалар.
Кара эчле җәллад булмас идем,
Язар идем матур кыйссалар.
Кыйсса язу — закон язу түгел,
Мин кыйссаны язам болай да.
Ятсам-торсам, тын алуы җиңел,
Патша түгел — шөкер ходайга!

**Ринат Мөхәммәдиев**

# СИРАТ КҮПЕРЕ

РОМАН

* * *

Большевиклар партиясенең XII съезды ачылырга ике-өч көн чамасы вакыт калып бара. Илдә вакыйгалар киеренке. Төрле төбәклардән килгән делегатлар берсеннән-икенчесе күнелсезрәк һәм борчулырак хәбәрләр китерә. Җимереклек, тәртипсезлек, үзара низаглар урындагы иптәшләрнең җелегенә үткән. Шулар өстенә милли мәсьәләнең чишелмәгән булуы киеренкелекне бермә-бер арттыра төшә. Соңгы араларда гына «Грузиннар эше» дип телгә кергән вакыйга хакында да Кремль сарайларында төрле имеш-мимешләр таралып өлгергән. Бу уңайдан Ильич махсус хат язган икән, дип тә сөйләделәр. Ул, грузиннарның милли дәүләтчелек эшенә чамадан тыш тыкшынуларын килештермичә, Сталин, Орджоникидзе һәм Дзержинскийга каты ук бәрелгән дә иде булса кирәк. Үзен дөньяның кендеге итеп хис итәргә өйрәнеп килгән Генераль секретарь хаста кешенең канәгатьсезлегенә кулын гына селтәсә, калган икесе беркадәр сагаерга һәм телләрен тешләп торырга мәҗбүр.

Көн кичкә авышкан бер мәлдә Мирсәет Солтангалиев янына Бакудан әле генә килеп төшкән Нәриман Нәриманов килеп керә. Гадәттәгечә җылылык белән күрешеп хәл белешкәннән соң, азәрбайҗанлы аркадашы Мирсәеткә җитди йомыш булуы хакында хәбәр итә. Аңлашыла ки, кабинетта сөйләшә торган сүз түгел бу болай булгач. Октябрь инкыйлабынача ук фиркә әгъзалары булып торган ике большевик, шул рәвешле, эш бүлмәсеннән урамга чыгарга мәҗбүр булалар. ГПУ органнарының күзләре күпне күрүе, колаклары күпне ишетүе сүзсез дә аңлашыла, мәгълүм була һәр икесе өчен. Алла саклаганны гына саклармын, дигән гыйбарә халык тарафыннан нәкъ шул елларда әйтелмәдеме икән?!.

Киңәш-табыш итү теләге белән Нәримановның, башка берәү янына түгел, нәкъ менә Солтангалиев янына килеп керүе бу очракта беркадәр көтелмәгән хәл иде. Чөнки, әле 1922 елның көзендә генә милли дәүләтчелек һәм автономияләштерү мәсьәләләренә мөнәсәбәттә үзара җитди бәхәскә кереп, күпләргә мәгълүм булган аңлашылмаучанлык туган иде араларында. Нәриманов милли республикалар төзү идеясенә икенчел мәсьәлә дип карауучылар тарафында иде. Мирсәетнең фикере безгә ачык.

— Мин ялгышканмын. Син хаклы булгансың,— дип башлады сүзен Нәриман Нәриманов.— Хәтереңдәме, көнчыгыш коммунистларының 2 нче киңәшмәсендә каршы чыккан идем мин үзеңә. Урыннардагы вакыйгалар синең хаклы икәнлегеңне исбат итте бүген.

Ахыры. Башы 4,5 саннарда.

Үткәннәрне барлар заман түгел. Теге чакта Нәримановның үзен аңламавы кәефен шактый ук кырган булса да, Мирсәет ул хакта искә алмаска тырышты.

— Нәриман агай,— дип, үзенең хөрмәтен белдереп, олылап җавап кайтарды Солтангалиев.— Сезгә булган мөнәсәбәтемне беләсез. Мин һич үпкәләмим. Ул вакытта да сез — үзегезчә, мин — үземчә, һәр икебез дә хаклы идек. Бу безнең яңа тормыш корудагы эзләнүләребез нәтиҗәсе. Стратегиядә исә безнең арада каршылыкның булганы юк.

— Рәхмәт,— дип, Мирсәетнең аркасына кагылып куйды Нәриманов.— Җылы сүзең өчен рәхмәт. Шулай да сөйләшер сүзгә якынрак килик әле... «Грузиннар эше» хакындагы проблеманы шулай куертулары сине дә уйландырган булса кирәк?!.

Спасс капкасы каршыннан узып, Кызыл Мәйданга килеп чыккан иде алар. Нәриманов сынаулы карашын кардәшенә текәде. Ипле, мәһабәт кеше иде ул, күз карашы ук иманлы.

— Уйландырмыйммы соң!.. Мдивани белән мин даими элемтәдә. Башка иптәшләрнең дә ни уйлаганын, ничек сулыш алганлыкларын ачык күреп, тоеп торам.

Сүз берләшкәндәй, Кызыл мәйданның кыл уртасында туктап калган иде алар. Сүзләре житди.

— Милли кадрларга, җирле халык фикеренә түбәнсетеп, бармак аша гына карарга теләү галәмәте.— Нәримановның күзләре маңгайдагы җыерчыклар авырлыгыннанмы, кысыла төштеләр.— Үзәктәгеләр — акыллы, ә Бакуда яисә Тифлистә, Казанда яисә Бохарада шуларның әмерен үтәүчеләр булырга тиешле. Мөстәкыйльлек кабул ителми. Милләтләр һәм республика дип авыз суын корыту да, бил бөгеп, баш кагып торучылар өчен генә. Башыңны калкытасың икән — син контрреволюционер, халкыңны искә төшердеңме — милләтче. Империячел фикер яңа, патша заманындагыга караганда да кыргыйрак рәвеш ала бара бүген. Синең өчен, беләм, яңалык түгел болар, Мирсәет. Җаным әрнегәнгә, каным катканга сөйлим.

Баш кагып куйды Солтангалиев. Күбрәк «пролетариат» һәм «интернационализм» хакында рухланып сөйләргә күнеккән Нәриманов авызыннан мондый сүзләр ишеткәне юк иде бит әле аның.

— Килешәм... Килешәм, Нәриман агай...

— Әйе. «Грузиннар эше» турында иде бит әле сүз. Күңелем сизә, моның белән генә тәмамланмас кебек бу ыгы-зыгы...

— Мин дә шулай уйлыйм, Нәриман агай. Грузиннардан башлау Коба өчен чаршау гына булмагае, дигән шигем бар. Янәсе, иң элек үз улымның колагын бордым. Аннары башкаларга да кизәнергә тулы хокукым бар, дигән мәкер ятадыр төсле бу эшнең төбендә.

Як-ягына күз төшереп алды Нәриманов. Алар икәүдән-икәү генә иде. Арлы-бирле узып торучылар булса да, озын колаклар күренми әлегә.

— Кобаны мин яхшы беләм. Гомер буе хаким булырга теләде. Буйсынучы юк иде үзенә. Инде менә Кремльгә хуҗа булды. Аннан сөреп чыгару җиңел булмаячак аны. Киңәшеп эш итү һәм бер-беребезгә якынрак булу хәерле. Әйтергә теләгәнем шул! Юкса...— Ни әйтергә икән диеп уйланып торгач, башын чайкап алды Нәриманов.— Әйе, юкса һичкайсыбызга көн калмаячак. Таякның иң юаны синең, минем кебекләр башына төшүе ихтимал...

— Белмим шул,— дип, икеләнүдә торып калды Мирсәет. Нәримановның сүзләрендә хаклык бар, әлбәттә. Әмма, ни генә булмасын, Сталинга ышанычын югалтмаган иде бит әле ул. Дөресрәге, югалтудан курка, югалтырга теләми иде... Алар озак еллар дәвамында бергә аралашып эшләгән кешеләр. Фикер уртаклашып, ризык бүлешеп яшәгән еллар да эзсез узмаган. Аның көчле, үзен хәйран калдырган сыйфатларын белгән кебек, җитешсезлекләрен дә аңларга, гафу итәргә гадәтләнгән иде Мирсәет... Ышаныч — зур нәрсә. Ышанычны сакларга кирәк. Кыл өстен-

дә эленеп торса да сакларга ышанычны... Ул югалдымы — бетте... Әнә шундый хакыйкатьтән чыгып, тешен кысып түзсә түзде, Сталинга каршы эш йөртмәде Мирсәет. Өстәвенә, яхшымы-яманмы, ул бит Генераль секретарь да әле. Сталинга ул ышанычын югалтса, Нариманов югалтса, башкаларга, гади коммунистларга ни кала?!. Партияне нинди язмыш көтә?

— Нигә тынып калдың? Ник дәшмисең, Мирсәет? — дип сорарга, аны уйларыннан бүлдерергә мәҗбүр иде Нариманов.— Куркып калдыңмы әллә?... Әйе, таякның юаны безнең башка төшүе ихтимал.

— Юк,— дип, каршы төшәр көч тапты үзендә Солтангалиев.— Таяк бүлешер заман түгел. Төшсә төшәр. Тал чыбыгы ашап үскән малайлар ич, безгә күнегәсе түгел. Ил язмышы, халкым язмышы гына имин булсын. Калганнары үтәр. Һәммәсе вакыт эше...

Елмаеп куйды Нариманов.

— Мирсәет, партия съездында сөйләргә җыенган нотыгыңны калдырып тор әлегә. Рәсми сүзләргә кабинетта да өлгерербез... «Син» һәм «мин» дигәндә, иң әвәле үзебезнең төрки милләтләрне күздә тотуым иде. Сталинның төркиләргә мөнәсәбәтен беләсең. «Грузин эше» узды, инде чиратта кем?!. Татармы, башкортмы, әллә Төркестанмы?..

— Азәрбайҗанны искә алмадыгыз.

— Азәрбайҗанга ук буе җитмәс әлегә. Безгә үрелү файдасыз. Кавказ тарихын ул яхшы белә. Күршедә — Төркия.

— Димәк?..

— Әйе, татарлар пошыра аның эчен. Сездәге милли аң үсеше... Сездәге кадрлар... Сездәге хәрби берләшмәләр.

— Ул кадрлар, ул хәрби берләшмәләр революцияне яклап сугышты...

— Сугышты. Беләм,— дип, уйлы карашын Мирсәеткә текәде Нариманов.— Әмма бер хакыйкатьне искә төшерәм: солдатлар сугышканда гына кирәк. Ә дошман тар-мар ителдеме, алар күңелгә шом сала...

— Ярар, калдырып торыйк,— диде Мирсәет, сүз сөрешен ошатмыйча.— Борын төбендә — партия съезды. Көн тәртибендә — милләтләр язмышы. Нишлибез?..

Нәкъ шул мәлдә аларның янәшәсеннән узып барган бер төркем тукталып калды. Таныш авазлар яңгыратты Кызыл мәйданны.

— Бәй, Мирсәет, сез түгелме соң бу? Нариманов агай...

Колачларын коштай җәеп каршыга килүче Башкортстан вәкиле Әдһәмов иде. Шунда ук Төркестанның Совнарком рәисе Турар Рыскулов, дагстанлы Курыкмасов һәм тагы берничә милли төбәк вәкилләре. Үзәк Комитеттан кайтып барышлары икән. Очраклы рәвештә күрешеп, XII съездга килгән делегатлар һәм кунаклар урнашкан «Париж» кунакханәсенә кайтып барышлары.

Хәл белешү, төрле төбәктәге фиркa эше, революцион үзгәрешләр турында фикер алышу кузгалып китте.

Шул ыгы-зыгыдан файдаланып, Рыскулов белән Солтангалиев бер читкә тайпылып алдылар. Икәүдән-икәү генә калган мизгелнең кадере зур, Төркестан вәкиленең әйтер сүзе булган икән.

— Сталинда булдым,— диде Рыскулов читләп-урап тормый гына.— Сине сораштыра. Хатларың белән кызыксына. Дусларың, танышбелешләрең белән...

Мирсәеткә авыр иде боларны ишетү. Чигәсенә яшен ташы китереп сукты диярсең. Нигә аның белән булыша соң әле ул? Кызыксына икән, үзеннән сорасын. Һәр соравына, һичborгаланмыйча, яхшысын да, яманын да күзенә туры карап ярып салырга әзер бит ул. Инде ничәнче ай дәвам итә шул хәл. Үзе белән күрешкәндә елмая, ә артыннан иснәнеп йөри, тешләрен шыкырдата...

— Ни диден соң?

— Синең милли кадрлар даирәсендә зур ихтирам казануың хакында әйттем.

— Шуңа канәгать булдымы?

— Юк, әлбәттә. Синең халык дошманы Зәки Вәлиди белән элемтәдә булу-булмавың кызыксындыра аны...

— Зәки Вәлиди... Вәлиди дисең инде,— дип, бу кызыксынуның нигә булу ихтималын гоманларга тырышты Солтангалиев. Әмма ачык кына белешә алмады.— Зәки Вәлиди табылыр ул, Турар туган, югалмас...

Рыскулов гаҗәпсенеп сорап куйды:

— Син нәрсә, әллә чынлап та Вәлидине эзлисеңме?

— Ни булган? Вәлидинең миңа дошман булганы юк.

— Мирсәет,— дип аңарга текәлде Рыскулов. Күзләре зур булып ачылган, гаҗәпләнүенең чиге юк.— Ул бит халык дошманы. Басмачы...

— Зәки Вәлидинең үз халкына дошман булганы юк, Турар туган,— дип, икеләнер урын калдырмаслык итеп кистереп куйды Солтангалиев.— Хаталары булды. Дүрт аяклы ат та абына. Бүген Зәки әфәндедәнең арабызда булмавы ул — милли мәсьәләдә кылган хаталарыбыз нәтиҗәсе. Партия хатасы...

— Кеше ишетер, син нәрсә сөйлисең, Мирсәет?!.

Чигенә төшкән Рыскуловның каршысына ук барып басты Солтангалиев.

— Нәрсә, Төркестанда бары да иминме әллә? Халык барыннан да канәгатьме? Ә үзегез ничек, күңелегез кушканча эшли аласызмы соң? Һичкем йодрык күрсәтмиме, өйрәтмиме?

— Авыр. Бик авыр, Мирсәет,— диде Рыскулов. Тыштан тыныч күренсә дә, эчтән ул да дөрләп яна.— Төркестан ул Петроград яисә Мәскәү түгел. Шуны аңлатып булмый.

— Шулай шул.— Мирсәет исә алай булдыра алмый, ул — күкерт. Үзләренә таба карангалап торган Башкортстан вәкиленә аваз салды ул шунда.— Әдһәмов иптәш, сезне мөмкинме?.. Бер соравым бар иде.

— Тыңлыйм,— диде Әдһәмов килә-килешкә.

— Менә, әйт әле син?!. Рыскулов иптәш тә ишетсен, әйт әле. Башкортстанда сезгә совет һәм партия эшен җайга салу юлында кем аяк чала?.. Турысын әйт!

— Смидович белән Немвицкий иптәшләр,— диде Әдһәмов һич икеләнеп тормыйча.

Җавап көткәннән дә төгәлрәк һәм гыйбрәтлерәк булып чыкты. Рыскуловка борылды Мирсәет.

— Ишеттеңме?!. Курыкмасов иптәшне чакырсак та, Фирдәвестән сорасак та, җавап шундый ук булыр. Татарстанда да, Азәрбайҗанда да шул хәл. Ә революцияне кем өчен ясадык соң без?!. Халык өченме? Пролетариат өченме? Әллә үзәктән килгән вәкилләр өченме?..

Сүз шул урында бүленде. Бер читтәрәк әңгәмә коручылар аларга килеп кушылды. Өлкән кеше булурактыр, Нәриман Нәриманов тәкъдим кертте.

— Җәмәгать,— диде ул, ихлас елмаеп.— Әйдәгез, Солтангалиев иптәшне кунакханәгә чакырыйк үзебез белән. Минем кучтәнәчләрем дә бар иде. Азәрбайҗан чәе эчәрбез, иркенләп бер әңгәмә кылып утырырбыз. Кузгалдык, җәмәгать..

«Париж» кунакханәсенең 44 нче номерында мәңге онытылмаслык мәҗлес булды ул кичтә. Анда катнашучыларның исемлеген барласаң, моны XII партия съездының милләтләр палатасы утырышы дип әйтергә дә мөмкин булыр иде. Һәммә төрки халык вәкилләре янәшәсендә Буду Мдивани белән кергән өч грузин һәм чечен, авар, мари, калмыклардан берәр җаваплы хезмәткәр катнаша. Әлбәттә, сүз сәяси мәсьәләләр тирәсендә урала. Игътибар үзәгендә ике кайнар төбәк. «Грузиннар эше» һәм Төркестан.

Әле бүген генә Мирсәетнең Нәриманов белән фикерләшкәндә кылган гоманы рас килә димәк. Буду Мдивани да Сталинның бу эшне үзен Россия халыклары каршысында чын интернационалист итеп күрсәтү

максатыннан ясалма куpертелгән вакыйга дип саный. Милли мәсьәләне көн тәртибенә куйган XII съезд алдыннан кыңгырау шалтыратып алу.

Мона кадәр йөткерү өянәген баса алмый изаланып, әледән-әле чәй йотып тын гына утырган карт коммунист Махарадзе исә башкарак фикердә икән:

— Кобаны сез белмисез,— диде ул, сүзгә кушылып.— Үз сүзен сүз итү, максатына ирешү юлында туган атасын да сатарга әзер ул. Кендеге Кавказ федерациясе проектына ябышкан. Грузиянең мөстәкыйльлеккә дәгъвасы шүрләтте аны. Үзе утырган ботак киселә ич.

— Ялгышмасам, «Грузиннар эше» өчен иптәш Сталинга һәм бероч-тан Дзержинскийга Ильичның үзеннән шактый ук эләккән дип сөйли-ләр,— дип әйтеп куйды Рыскулов.

Нәримановның карашы Мирсәеткә текәлде. Үзара күз кысышып алдылар. Димәк, бу хәбәр башкаларга да мәгълүм булып чыга.

— Ишеткәнем юк,— диде Махарадзе.— Хак булса да, барыбер үзе-некен итәчәк. Әүвәл ул черек компромисска барачак, аннан алдаячак. Барыбызны да — Ленинны да, грузин коммунистларын да.

Рыскулов белән Махарадзе арасында бермәлгә бәхәс куерып алды. Төркестан вәкиле Сталинга үзенең ышануы һәм аның хакында ни эләкте шуны сөйләмәскә кирәклеген искәртте. Ә Махарадзе һәм бераздан аны куәтләгән Мдивани, үзләренең «Коба»ны гасыр башларыннан ук белүлә-ренә нигезләнеп, бергә — биш белән җавап кайтардылар.

Ленинның Сталинга бу уңайдан хаты булганмы-юкмы дип сүз кө-рәштерүчеләр алдында Мирсәетнең зур өстенлеге бар иде. Чөнки бу хатның нөсхәсен ул үзе укыды. Зур сер итеп кенә Троцкий күрсәткән иде. Гомумән, соңгы араларда Сталин белән аралары суына барган саен, Троцкийның Солтангалиевкә мөнәсәбәте тагы да якыная, эчкерсезләнә төшә. Милли мәсьәләне аңлауда Лев Давидович аны үзе өчен авторитет күрә, шуңа еш киңәшә торган иде. Мирсәет өчен — вәгъдә иман. Троц-кийга биргән сүзен боза алмый. Әлеге хатның кайбер җөмләләрен күз йөртеп чыккан арада ук хәтеренә уелып калган иде аның. Әмма сүзгә катышмады.

«Бу очракта Сталинның кабалануы, идарә итү белән мавыгуы һәм тагы «социал-милләтчелеккә» булган ачуы аның үз башына таяк булып төшмәгәе»,— дип язган Владимир Ильич.

Һәм тагы... «Әлеге чын мәгънәсендәге бөек рус милләтчелеге кам-паниясе өчен сәяси җавап, һичшиксез, Сталин һәм Дзержинский иптәш-ләр җилкәсенә төшә» — дигән бәя җәлеп иткән иде аның игътибарын.

Шулар өстенә Ленинның үз кулы белән Троцкийга тапшырган үтене-че дә таныш иде Мирсәеткә. Грузия коммунистларын Сталин һәм Дзер-жинскийның эзәрлекләүләреннән яклавын үтенә юлбашчы.

Бәхәс дәвам итә иде әле. Рыскуловка кушылып тагы берничә иптәш-нең Сталинга мәдхия укырга керешүе Буду Мдиванины тәмам чыгырдан чыгарды. Түзмәде, кавказлыларга гына хас кайнарлык белән кинәт кесә-сенә тыгылды һәм Ильичның үзеннән алган язу кисәген борыннарына төртте.

— Мәгез, укыгыз,— диде.— Ленинның үз кулы белән язган язуы.

Тынып калдылар. Ярты дәфтәр битенә язылган кулъязма кул-дан-кулга йөрде. Солтангалиев тә укыды. Чынлап та Ильичның үз кулы иде — таныды.

*«Ип. Мдивани, Махарадзе һ. б. кучермәләре: ип. Троцкий һәм Каменевка.*

*Хөрмәтле иптәшләр!*

*Бөтен күңелем белән Сезнең эшләрне күзәтәм. Орджоникидзеның дорфалыгы, Сталин һәм Дзержинскийның өзлексез бәйләнүләре минем дә ачуымны кабарта. Сезнең өчен бер язу һәм чыгыш хәзерлим.*

*Хөрмәт белән* **Ленин.**

**6 март, 23 ел».**

Гажәпсенеп калды күпләр. Үз күзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр. Чөнки ул көннәрдә матбугат битләрендә Сталинны Ленинның бердәнбер варисы, иң якын һәм ышанычлы көрәштәше буларак күрсәтү компаниясе аеруча зур колач алган иде.

— Менә сиңа мә, имәндә икән чикләвек,— дип куйды Татарстанның Халык Комиссарлары Советы рәисе Мохтаров.

Сүз иярә сүз чыгып, Грузия хакындагы сөйләшүләр Төркестан тарафларына барып тоташты. Төркестандагы аяныч вакыйгалар да һичкемне битараф калдырмый икән. Басмачылык хәрәкәтен бәяләүдә фикерләр төрле-төрле иде. Шулай да күпчелек моны — партиянең милли мәсьәләгә мөнәсәбәттә бигүк дөрес булмаган сәясәт алып баруы нәтиҗәсе диеп күрә. Турыдан-туры кистереп әйтүче булмаса да, тел төпләреннән аермачык сизелеп тора иде бу.

Мәҗлес корып утыручы XII съезд делегатлары арасында Солтангалиевнең хәле үзгә. Иң элек, аның җанын берөзлексез тырнап торган яңалык, ул да булса, XII съезда катнашу-катнашмавы шик астында бит әле. Бу хакта рәсми хәбәр булганы юк-югын. Әмма Сталинга шактый ук якын торучылардан Бройдо һәм Павлович иптәшләр әлеге серне Мирсәетнең үзенә җиткергәннәр иде инде. Димәк, милли мәсьәләгә багышланган корылтайны Сталин үзенең бу өлкәдәге төп оппонентыннан башка гына уздырырга җыена икән... Ә Мирсәет Солтангалиев бу хәлне күз алдына китерә алмый. Чыгышының тезислары әзер, фактлар саллы, аргументлар нигезле, Сталинның милли мәсьәләдәге уеннары чираттагы мәртәбә ачы тәнкыйтькә дучар ителәчәк иде.

Сталин ясаячак докладның да тезислары таныш иде инде аңарга. Турыдан-туры исемен атамаса да, Генераль секретарь съезд трибунасыннан Солтангалиевне тар-мар итәргә җыена. Катгый сер булып сакланса да, моны Үзәк Комитет аппаратында эшләгән һәркем белә. Ә мәҗлестә катнашучылар исә, Мирсәет Солтангалиевне бу корылтайда катнашу-катнашмавы бәхәследер, дип уйлый да алмый. Чөнки милли дәүләтчелек мәсьәләләрендә аның әзерлекле белгеч булуы мәгълүм ич. Үзе белән аерым-аерым киңәшкәннәре, чыгышларын тыңлаганнары, хезмәтләрен укыганнары бар. Бу юлы да аңардан, Үзәк вәкиле буларак, кайнар һәм төпле чыгыш көтәләр.

— Җәмәгать, Мирсәет дәшми әле безнең,— дип, Башкортстан Совнаркомы рәисе Халиков суз кыстырып алды берзаман.— Басмачылык мәсьәләсен аңардан да яхшы белүче булмас. Чөнки күптәнге әшнәсе Зәки Вәлиди дә шунда ич.

Гадәти төрттерү генә түгел, аяз көндә яшен суктыммыни, провокацияне хәтерләтә иде бу. Тагы шунысы гажәп, Халиковны әлеге җаваплы урынга куюны кайгыртып йөргән кеше Мирсәет үзе иде. Араларында һичбер аңлашылмаучылык булганы юк. Үзара хөрмәт һәм дустанә мөнәсәбәттә яшәгән аркадашы әйттеме бу сүзне?!. Дәшмим дигән сүзе бар иде. Чөнки белә, аларның бирedә сөйләшкән һәр сүзе иртәгесен ГПУда булачак һәм Сталинның өстәленә ятачак. Боларны кем эшләячәге дә мәгълүм аңарга. Әмма, колагы ишеткәннәрдән соң, дәшми калу мөмкин түгел иде ары.

— Әйе, иптәш Халиков,— дип, басынкы, әмма ышанычлы итеп сүз башлады Мирсәет. Куллары йодрыкланган, гүя шулар белән сугып һәр фикерен кадак урынына сеңдерә барачак.— Вәлиди— дошманым түгел. Башсовнарком рәисе өчен исә ул ата булырга лаек кеше. Үзенә дан-дәрәҗә эзләп түгел, булганнарын ташлап чыгып китте Зәки Вәлиди. Кемдер кулында курчак булырга теләмәде. Ул, ялгышса-ялгышмаса да, сез җитәкләгән республиканың башкалар белән тигез хокуклы булуын яклады. Һәм бүген дә шул иманындадыр дип беләм. Басмачылык — ул һәммәбез өчен күкрәктәге йөрәк җәрәхәте. Вәлиди белән, иптәш Халиков, хет сез авыз чайкамагыз. Үтенәм!

Халиков тып-тын булды, гүя урындыкка сеңде.

— Җәмәгать, монда һәммәбез большевиклар, Совет хезмәткәрләре,— дип, сүзгә кушылды, Мирсәетне куәтләп алды Турар Рыскулов.— Ерак барасы юк, үз башымнан кичкәнгә әйтәм. Безне бит әле дә, кимсетеп, икенче сортлыга чыгарып, «туземец» дип кенә искә алалар. Житәкче урынга мендем дип, үз халкыма дошман булырга тиешлеме мин? Сездән яшерен-батырын түгел, унтугызынчыда ел буе качып йөрергә мәҗбүр булдым. Ни өченме? Казакъ, кыргызларны кайгырткан өчен. Кемнән? Төркестандагы Совет хезмәткәрләреннән, Кызыл Армиядән! Һәм иң көлкесе шул, минем белән бергә урыс большевигы Кобозев та качып йөрде Төрекмәнстан чүлендә. Кыргыз егетләрен азат иткән, үтермәгән өчен ээзәрлекләделәр үзен. Шул,— диде Рыскулов тирән көрсенеп.— Гаепләргә җиңел ул. Безгә бер-беребезне аңлау кирәк хәзер. Юкса, Мәскәүдән чыгып киткәч тә, кайбер иптәшләр әле дә империя вәкиле итеп тоя үзен. Ә Төркестан — колония түгел. Туган җирем колония булсын өчен көрәшмәдем мин. Советлар өчен...

— Әйе, халык көрәшә икән, монда бер-бер хикмәт бар инде,— дип җөпләп куйды Нариманов та.— Басмачы дип әйтергә җиңел. Ә кем илен, кем җирен басқан соң әле алар?!.

Солтангалиев тынычлана төшкән иде инде. Шулай да эчкерсез бу сөйләшүдән читтә тора алмады.

— Әле шушы көннәрдә генә академик Бартольдның калын гыйльми китабы дөнья күрде,— диде ул, карашын бер ноктага төбәп.— Укырга киңәш итәм. Укырга һәм гыйбрәт алырга. Октябрь инкыйлабының алтынчы еллыгына чыгарылган шул хезмәттә царизмның Төркестанны яулап алуы прогрессив күренеш дип аңлатыла. Имеш, бу — кыргый феодализмны капитализм белән алыштыру, панисламизм урынына европача цивилизация китерү генә булган икән. Төркестанлыларны чебен урынына да күрмәгән генерал Куропаткин, шул рәвешчә, цивилизация китерүче изге җан булып чыккан. Бу логика белән китсәк, марокколыларны, вә Конго негрларын кырган француз империалистлары да цивилизация өчен көрәшкән икән. Кембридж университетының бер-бер профессоры да мисырлыларга каршы көрәштә үлгән ниндидер генерал Листекны кыргый варварлар кулыннан үлгән, шәһит киткән дип, байрак итеп күтәрә ала. Ә Һиндстанның вице-короле Азиягә тәрәккыят китергән пионер булып чыга.— Мирсәет янә кабынып киткән иде. Мавыгып, кулларын алга сузып сөйләүгә күчкән.— Тарихта казыну, үткәннәрне болгату-кайтару кирәк эш түгел. Шулай да тарихи дөреслек яшерелмәскә тиеш диеп беләм. Тарих империячел фикер коллыгыннан азат ителергә тиеш... Шунсыз социаль, иминлеккә нигезләнгән җәмгыять кору мөмкинме?! Мондагылар беребез дә яңа империя барлыкка китерү өчен көрәшмәдек. XII съездда нәкъ әнә шул хакта ачыктан-ачык, коммунистларча, барын уртага салып сөйләшергә, киңәшергә тиешбез. Юкса, соңгаруыбыз ихтимал, аркадашлар...

Мирсәетнең сүзләреннән соң бүлмәдә тынлык утырып торды. Һәркем уйлана калды. Аны хупладылар. Съезд трибунасыннан ачыктан-ачык сөйләшү ихтыяҗы күптән өлгергән булуы хакында кат-кат искә алынды.

* * *

Милли төбәкләрдән килгән коммунистларның әлеге очрашып сөйләшүләре хакындагы «әләк» иртәгесен сәгать унга Сталинның эш өстәленә китереп салынган була инде. Әлбәттә, куертылган, күпертелгән сурәттә. Һәм очраклы бу мәҗлескә, Солтангалиев оештырган буржуаз-милләтчеләр фракциясенең конспирацияле утырышы, дигән янгыравыклы яманат та тагылып өлгерә.

* * *

1923 ел. Апрельнең 25 нче көне. Киеренке бер түземсезлек белән көтеп алынган көн. XII съездның милли секциясендә хәлиткеч фикер алышулар көне. Генераль секретарь үзенең йомгаклау сүзендәниләр әйтер? Троцкий сүз алырмы, әллә бу юлы да дәшми калуны артык күрерме? Ленинның съездга язган хаты игълан ителерме? Мирсәет Солтангалиев нинди юл сайлар: гадәттәгечә, хакыйкатьне ярып салырмы ул, әллә баш очында куера барган болытлар аны да сагаерга мәҗбүр итәрме? Мдивани, Нәриманов һәм Рыскуловлар кайсы юлны сайлар?.. Сорауларның чиге-чамасы юк. Кем шул сорауларга төгәен җавап бирә алыр икән?!. Инде бер атнадан артыкка сузылган съезд күп нәрсәгә ачыклык кертте дияргә була. Сталин сүзе — канунга әверелә бара, күпләр тарафыннан бәхәстән югары буларак кабул ителә. «Милләтләр» һәм «халык», «хезмәт ияләре» дигән сүзләр күз буяу өчен генә. Генераль секретарь ни боерса, илдә шул булачак... Яшисең килсә, дәрәҗәле урыныңны саклап калыйм дисәң — дәшмәвәң мең алтын. Тагы да отышлырак юл — партиягә, аны «дөньякүләм бөек җиңүләргә җитәкләп баручы» Генераль секретарь иптәш Сталинга мәдхия уку. Күпләр, бик күп гайрәтле ирләр шул юлларның йә тегесен, йә монысын сайлап, үзләренә, уллары-кызларына вә оныкларына бәхетле матур киләчәк тәэмин итү турында хыялланганлыр. Һич ни әйтеп булмый, ниятләре изге. Әмма сорау кала: ул ниятләр тормышка ашармы?!. Революция принципларыннан ваз кичкән «ялагай»ны кол итеп, дәшмәүчеләр белән җирне ашлау осталары хуҗа булып куймасмы социализм чаршавы артына поскан бу бөек империягә?!. Әйтеп булмый әлегә, белеп булмый. Әдәми затны оятлы иткән, һәм соң чиктә харап итәчәк бер сыйфат бар, ул да булса — бүгенге көн белән яшәү. Ягъни, гамьсезлек, тарихка, үткәнгә гамьсез булу.

Тарих — ул тәгәрмәч кеби. Анда югары яисә түбән тараф булмый. Үзен югары санаган — түбән төшә, түбәндәге — күтәрелә. Феодализм, социализм, коммунизм — болар һәммәсе уйдырма. «Изм»нарга, гомумән, ышанмагыз. Кешене алдау адәми затны тарихта адаштыру өчен хакимнәр уйлап чыгарган, озак кына алар. Ә колбиләүчелек булган! Һәм бүген дә дәвам итә. Теге яисә бу рәвештә колбиләүчелекне хәтерләтмәгән җәмгыять табыгыз, күрсәтеп карагыз сез миңа. «Изм»нар колларны алдау, бер рәвештән икенче рәвешкә күчерүнең тышкы алдавычлары гына алар. Җитмеш ел «диктатура хуҗасы» булган эшче сыйныф татымадымы шуны?! Хезмәт ияләре җәмгыяте булган соңгы дәвер «изм»нары шуны исбат итмәдеме?!

Мирсәет Солтангалиев йокысыз төн үткәрде. Әмма кәефе зарланырлык түгел, хәлиткеч бәйгегә ашкынган яхшы аттай сизә иде үзен. Фатыйма белән кара-каршы утырып чәй эчтеләр. Кызлар тәмле төшләр күреп йоклый иде әле. Җиде тулып килгәндә ул урамга чыкты. Съезд башланганчы эш урынына кагылып узасы бар, күрешеп сөйләшергә теләүчеләрнең дә булуы бик ихтимал.

Зур таш күпернең уртасын узып барганда, үзенә каршы очраган беренче кеше үк исеме белән дәште аңар. Гаҗәпләнмәс жиреңнән гаҗәпләнерсең.

— Сез Мирсәет Солтангалиев түгелме? — дип сорады ул саф татар телендә.

Әйе, дип, баш какканга кадәр, иң элек күздән кичерде ул бу кешене. Яше кырыктан узган. Гадәти киемдә. Урынлы-урынсыз бәйләнеп, танышлык эзләп йөрүчегә охшамаган.

— Мин сезне танып бетермим кебек, агай. Кем дип белим үзегезне? Мирсәеткә якын ук килеп басты ул. Як-ягына карангалап алды. Ни кадәр зур күпердә икәүдән-икәү генә булсалар да, саклык максатыннандыр, пышылдауга күчте.

— Минем кемлегем әһәмиятле түгел,— диде ул, житди рәвеш алып.— Әмма сезгә киңәш итәр сүзем бар.

— Тыңлыйм...

Көттермәде теге. Кыска һәм төгәл жөмләләр белән аңлатырга кереште:

— Сезне кулга алырга жыеналар. Съездга бармаска киңәш итәм. Барсагыз, сүз сорамагыз. Һичкем белән очрашмагыз, сөйләшмәгез бүген. Балаларыгыз бар. Хатыныгыз яшь. Туганнарыгыз... Шуларны онытмагыз.

— Кем буласыз? Болар сезгә каян мәгълүм булды,— дип, очраклы танышының кулына үрелде Мирсәет. Әмма тегесе тоттырмады. Сүзем бетте дигәнне аңлатып, кырт борылып, китәргә каерды.

— Сүз иясе белән йөрми... Кардәш буларак, яхшы ният белән кисәтүем...

— Юк,— дип, йөгереп барып каршысына чыкты аның Мирсәет.— Зинһар, ашыкмагыз. Сез кайдан? Монда кем жибәрде үзегезне?...

Ир-ат тагы да житдиләнә төште. Күренеп тора, шаярмый иде ул.

— Кисәтү минем эш. Саклану чараларын күрү — сезнеке,— диде. Һәм инде жиде-сигез адым ераклашкач, ярым борыла төшеп, өстәргә кирәк тапты:— Хәлегез яхшыдан түгел, беләм. Төркия посолына мөрәҗәгать итсәгез генә инде. Мохтар-бәй шуны әйтергә кушты: ул көтә сезне... Бүген яисә иртәгә килеп чыксын, диде.

Таныш түгел кешегә артык каныга алмады Мирсәет. Ул китте, күздән югалды. Мирсәеткә дә юлын дәвам иттерүдән башка чара калмаган иде. Дөрес, адымнары күпкә акырынайды, инде аның хәзер башы салыча төште. Ни эшләргә белгән юк...

Шуның белән генә бетсә икән. Эш кабинетын ачып керүгә үк, игътибарын өстәлдә яткан конверт жәлеп итте. Аңардан башка бу бүлмәдән ачкыч һичкемдә юк. Ә ишек бикле иде.

«Монысы ни дигән сүз тагы... Монысы нинди хикмәт»,— дип, мыгырданды ул үзалдына. Әйтерсең, монда ялгызы гына түгел. Янәшәсендә аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торучы ят бер кеше бар диярсең.

*«Иптәш Солтангалиев!*

*Сездән шуны үтенәбез: партиягә таркаулык кертмәгез, үз саташуларыгыз белән милли республика вәкилләрен Ленин һәм Сталин сызган дөрес юлдан адаштырмагыз. Үзегезгә ышанучы булмас барыбер. Чөнки һәммә намуслы большевик өчен сезнең кем, ягъни Төркия, Әфганстан һәм Иран шпионы булуыгыз, Советлар иленең дошманы, басмачлар башлыгы Зәки Вәлидинең мәсләктәше икәнлегегез аермачык мәгълүм.*

*Коммунистларча сәлам белән, бер төркем милли республика вәкилләре».*

Чиста ак кәгазьгә язу машинасы белән урыс телендә суктырылган әлеге сүзләрнең кем һәм нинди максаттан аңарга житкерелгән булуы сер түгел иде, әлбәттә. Дәүләт йортының ябык ишекләрен теләсә кем ачып-ябып йөри торган еллар түгел. Ә ГПУның кулы житмәгән, күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән жир юк.

Кызык килеп чыга бит әле бу. Гомер булмаган хәл. Зур таш күперда очраган билгесез «кардәше» белән серле хат арасында турыдан-туры бәйләнеш бардыр кебек. Һәм боларның кичә яисә иртәгесен түгел, нәкъ менә бүген, 25 апрель иртәсендә бер-бер артлы кабатлануы да очраклы түгелдер. Димәк, кемгәдер, нәкъ менә бүген аңарга рухи тәэсир яисә басым ясау кирәк булган. Кемгә? Аның бүгенгә бәхәсләшер, фикер каршылыгына керер кешесе бер генә — Генераль секретарь Иосиф Сталин.

Димәк, Сталин?!..

* * *

Шулай да чыгыштан баш тартмады Солтангалиев:

«Милли мәсьәләнең иптәш Сталин тәкъдим иткәнчә куелышы белән мин тамырдан килешә алмыйм. Бу аны хәл итәргә омтылу түгел, киресенчә, тагы да ныграк буташтыру, җепнең очын һичкем яңадан кайтып сүтә алмаслык итеп чуалтудан гына гыйбарәт. Икенче, ягъни милли палата төзегән булып, зур эш кылган сыман шуңа басым ясауны күзгә төтен җибәрүдән гайре һични диеп әйтеп булмый.

Милләтләрне вә милли республикаларны сортларга, хокук күзлегеннән төрле-төрле дәрәҗәләргә аеру, бүлү кала икән, бу милли мәсьәләне хәл итү дип атала алмый, киресенчә, илнең сәламәт нигезенә бомба тыгып калдыру буларак кына бәяләнә ала. Социаль тигезлеккә нигезләнгән җәмгыять төзергә керешкәнбез икән, нигә әле аның нигезенә милли тигезсезлек индерелергә тиеш?! Социализмга империя күлмәге кидертү кемгә кирәк?! Шуңардан чыгып, автономияле республика һәм барлык милли өлкәләрнең дә хокукы яңадан каралырга һәм күтәрелергә тиеш дип саныйм. СССРның тулы хокуклы субъекты булу-булмау һәркемнең үз эше. Һичнинди рәнҗетү яисә мәҗбүр итүгә юл куелмасын.

Бу — бер. Икенчедән, монда доклад ясаган кайбер иптәшләр җирле милләтчелекне пыран-заран китерделәр. Әмма, кызганычка каршы, бу күренешнең нидән гыйбарәт булып, каян килүе хакында уйланып торуны кирәк санамадылар. Үз-үзебезгә сорау бирик әле: нәрсә соң ул җирле милләтчелек? Бөек державачылык шовинизмы белән килешергә теләмәү һәм шуңарга каршы чыгу, үз-үзеңне милләт буларак саклап калырга омтылу түгелме?! Әгәр шулай икән, бу — милләтчелек түгел, ә бөекдержавачылык шовинизмына каршы табигый реакция буларак кына бәяләнә ала. Милли мәсьәләдә үзен олы белгеч санаган кайсыбер иптәшләрнең шуны аңламавы кызганыч әлбәттә...»

Съезд тәмамлангач та икенче көнне иртәнге сәгать тугызда Мирсәеткә ашыгыч хәбәр китерделәр: «Иптәш Сталин көтә».

Бу чакыруның буласын чамалый иде ул. Һәм күңеле белән аңарга күптән әзер иде. Большевикларча кара-каршы утырып бер фикер алышырга да, ике арадагы һәммә аңлашылмаучанлыкларга нокта куярга вакыт җиткән иде инде. Чөнки алар арасында хәл ителмәслек каршылыклар юк, булса да милли дәүләтчелек мәсьәләсенә мөнәсәбәттә фикер каршылыклары гына. Сталин, съезддагы йомгаклау сүзендә, үзе дә Солтангалиев тәкъдим иткән тезисларның нигезле икәнлеген танырга мәҗбүр булды, кире кага алмады. Димәк, Генераль секретарь белән ике арадагы бу сөйләшүдә мәсьәләгә ачыклык кертү мөмкинлеге булачак...

Сталин керүчегә урын тәкъдим итте һәм сорау бирергә ашыкты.

— Дөресме шул, Солтангалиев иптәш, сине Төркиягә качарга ниятләгән диләр?

Көлемсерәми чарасы юк иде Мирсәетнең.

— Минем үз Ватаным бар. Һәм берәүдән дә качарга җыенмыйм, иптәш Сталин.

Ә күңеленнән уйлап куйды: «Тагы Төркия... Күпердәге очраклы кеше телендә дә, өстәлдәге язуда да, Генераль секретарьның телендә дә Төркия... Моңа нигез биргәне булмады ич әле аның?! Гаҗәп...»

Төп сорауга җавап алынды дигән сыман, иркен сулыш алды Генераль секретарь. Һәм төребкәсен көйрәтеп җибәрде.

— Мин дә шулай уйлыйм. Сезгә берәүнең дә янаганы юк... һәм моның өчен сәбәп тә күрмим.

Бу предметсыз сөйләшүне туктатырга ният итеп, сүз сөрешендә кискен борылыш ясады Солтангалиев.

— Иптәш Сталин,— дип, кулындагы кәгазьләрен өстәлгә куйды ул.— Илдә һәммә милли низагларга киртә булырлык чаралар күрү кирәк безгә. Һәм бу эшне иртәгесе көнгә калдыру ярамас...

— Кирәк...— дип, уйланган атлы булып утырды Генераль секретарь. Сәламәт кулы белән өстәлгә суккалап алды.— Кирәкнең чамасы юк. Әмма ничек?..

— Менә, монда әзер проект тәкъдим итәлә,— дип, кәгазьләрен Генераль секретарьга сузды Мирсәет.— Бу минем озак еллар дәвамына тупланган тәҗрибә һәм эзләнүләрем нәтиҗәсе.

— Әзер проект дисең инде, ә?.. Калдырып тор, танышырмын.

— Төзәтмәләр һәм тәкъдимнәргә юл ябык түгел, иптәш Сталин. Үзегез беләсез, мәсьәлә бик житди.

— Дөрес, мәсьәлә бик житди.— Үзе һаман бармаклары белән өстәлне шакылдата. Нидер уйлый, гаме башкада. Икеләнә, бер фикергә, нәтиҗәгә килә алмый иде кебек Сталин.— Төзәтмәләр дә кертербез... Тагы бер ун-унбиш көннәрдән очрашырбыз әле. Фикерләшербез...

— Димәк, ун көн,— дип, Сталинның күзләренә текәлде Мирсәет. Сүзне тәмамланганга санап, урыныннан торды.

— Әйе, ун көн... Ашыктыра да алабыз, әлбәттә.

— Мин түзәргә өйрәнгән, иптәш Сталин. Көтәрмен. Ашыкмыйк.

— Карарбыз.

Генераль секретарьның ни өчен чакырганлыгы һәм нәрсә хакында фикерләшергә ният иткәнлеген аңлый алмады Мирсәет. Һәм бу аның өчен озак еллар уйланып та җавап табылмаган сер булып калачак. Ни әйтергә җыенды икән Сталин аңарга шул көндә? Нигә икеләнә калды?.. Нигә фикернең җеп очын югалтты? Бер дә үзенә охшамаган иде ул. Әллә соңгы мәртәбә күзгә-күз очрашып калу гына булдымы теләге. Мирсәетнең гафу үтенүен, йә булмаса икеләнүен, сагаюын тоемлыйсы килдеме икән... Ни генә булмасын, аны ишек катынча озатып килгән Генераль секретарь кәефле түгел иде. Кул бирешүләре дә сәер генә килеп чыкты. Карашлары булсын, куллары булсын, магнитланган сыман, бер-берләреннән аерыла алмый торды.

* * *

Майның дүртенче көне. Соңгы араларда элгәре вазифалары өстенә Федераль җир комитеты рәисе итеп тә билгеләнгән Мирсәет Солтангалиев өчен катлаулы көн булды бу. Ул илнең төрле төбәкләреннән килгән дистәләгән вәкил һәм делегацияләрне кабул итте. Җир бүленеше өлкәсендә дә бәхәс һәм четерекле мәсьәләләрнең очы-кырые юк. Берәүне дә рәнҗетмичә, тарихта җөй калдырмыйча хәл итәргә, җайга салырга кирәк һәммәсен. Чуәләнгән төенне хәтерләткән төньяк Кавказ үзе генә ни тора. Бөре һәм Бәләбәй өязләренең язмышы да әле булса хәл ителмәгән. Килгән вәкилләр катгый рәвештә үзләрен Татарстанга кушуны таләп итәләр...

Көн кичкә авышып килгән мәлдә эш бүлмәсендә телефон чылтырады. Гадәтләнелгән таныш аваз иде югыйсә. Әмма бу юлы да көндәлек ыгы-зыгыга чумып онытылган Мирсәетне сискәндереп куйды. Бераз каушый төшеп, тәребкәгә үрелде ул. Кулына алды:

— Әйе, тыңлыйм...

— Элемтәдә — Шкирятов. Үзәк Контроль Комиссиясеннән.

— Сезне федераль җир комитеты рәисе Солтангалиев игътибар белән тыңлый, иптәш Шкирятов.

— Менә нәрсә,— дип, бер мәлгә сүзнең җаен таба алмыйчарак тордылар аргы тарафта.— Вакыт табып, хәзер үк ЦККга килеп чыгуыгыз сорала, иптәш Солтангалиев.

— Бераз көттерә төшсәм, гафу итәрсез,— диде Мирсәет, стенадагы сәгатькә күз төшереп.— Тагы бер сәгать, сәгать ярымнан сугылырмын.

— Хәзер үк! — дип боердылар аргы тарафтан.

Мирсәет аңарга әйтеп бетерергә ирек бирмәде, ярты юлда өзде сүзен:

— Иртәш Шкирятов, кем белән сөйләшүегезне онытып җибәрәсез түгелме?! Ишек катында торучыларны кабул итеп бетергәч тә килермен... hичшиксез, килермен...

Сүзне тәмамланганга санап төребкәне куйды да, ишек катына узып, Дагыстаннан килгән бер төркем тау халыклары вәкилләрен керергә чакырды.

Әмма Шкирятовларны да озак көттермәде. Бер сәгать чамасы уздымы-юкмы, ул Үзәк Контроль Комиссиясе рәисенең кабул итү бүлмәсендә иде инде. Үзен ни сәбәпле чакырганнарын белмәсә дә, канатланып, очынып килде ул монда. Бер-бер яңалык, яңа хәбәр ишетергә өметләнеп килде.

Чынлап та яңалык көткән булып чыкты аны монда. Уена да кереп карамаган яңалык. Ул килеп кергәч тә, кабул итү бүлмәсендә утырып торган дүрт-биш ир-ат каударланып, ничектер сөрлегеп куйдылар. Берьюлы үрә торып бастылар.

Әмма... сәлам бирү өчен түгел. Аңа таныш булмаган ике егет ишек катына үтте. Берсе эчтән ишекне бикләп куйды.

Мондагыларның үзенә бердәнбер таныш кеше Менжинскийга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр иде Мирсәет.

— Бу ни дигән сүз? Нинди тамаша бу?! Аңлатуыгызны үтенәм...

Җавап бирергә ашыкмады Менжинский, нибарысы елмаеп куйды.

Нәкъ шул мизгелдә арт тарафта торып калган ике адәм, көтмәгәндә Солтангалиевнең өстенә ташланды һәм кыргыйларча аның кулларын каерырга керештеләр.

Тик бу алай ук җиңел эш булып чыкмады. Вакытында сизенеп калдымы, балык сыман шуып кына чыкты Мирсәет тегеләрнең кулыннан һәм ялт кына аркасын стенага терәп кулын кобурага тыгып өлгерде.

— Селкенмәгез,— дип боерды ул, үзенә янә ташланырга әзер булган әзмәвердәй егетләргә—. Кисәтәм, башыгыз ике булмаса, коралга тотынырга уйламагыз.

Менжинский үзенең егетләренә тынычланырга киңәш итте. Мирсәетнең елгырлыгыннан хәйран калып, башын чайкап куйды.

— Гайрәтле кеше син, иптәш Солтангалиев.

— Гайрәт турында сөйләшергә килмәгәнсез, иптәш Менжинский. Аңлатуыгызны үтенәм: нинди нигездә яисә кем боерыгы белән кулга алырга җыендыгыз мине?..

— ЦККның партколлегиясе карары нигезендә,— дип, әлегәчә кулында тотып торган кәгазь битен Мирсәеткә сузды ул.— Таныша аласыз, рәхим итегез.

Бер кулы кобурада иде һаман. Сул кулы белән үрелеп, кәгазьне алды һәм күз йөгертеп чыкты Солтангалиев.

— Бу — копия. Аның дөреслеген кем исбат итә ала? Бу кәгазьнең дөреслегенә мин ышанмыйм,— дип, тавыш күтәрергә иткән иде ул.

Әмма, көтмәгәндә, ЦКК рәисе кабинетыннан нәкъ шул мәлдә Валериан Куйбышев килеп чыкты. Һәм Мирсәеткә таба атлады.

— Мин исбат итә алам. Менә монысы оригиналы,— дип, Мирсәетнең партиядән чыгарылуы һәм ГПУ тарафыннан кулга алынырга тиешлеге хакындагы карарны аның үзенә сузды.

— Иптәш Куйбышев,— дип, калтыранган аваз яңгырады.— Монын хакыйкать икәнлеген сез дә раслыйсызмы?..

— Раслыйм. Партия һәм Советларга каршы элемент буларак кулга алынасыз.

Күзләренә кан йөгерде, бугазына йодрык кадәр кайнар төер килеп тыгылды. Үз-үзен кая куярга белмәде Солтангалиев. Шул мәлдә үк, үз чигәсенә пистолет терәргә һәм барыннан да котылыргамы әллә, дигән уй да килгән иде. Тик шундук кире кайтты андый яман уйдан. Партия һәм Советларга каршы кыл да кыймылдатканы юк ич аның. Нахак гаеп күтәреп китәргә ярамый дөньядан.

Кинәт, бер нәтиҗәгә килеп, кобурадагы коралын өстәлгә китереп салды ул. Һәм кулларын артка куеп Үзәк Комитет секретаре Куйбышевның каршысына барып басты.

— Гаепле булуымны раслыйсыз икән, инде богауны да үз кулларыгыз белән салыгыз, иптәш Куйбышев.

Сүзем шуның белән тәмам, дигәнне аңлатып, кырт борылды һәм аркасын куйды ул Үзәк Комитет секретарена.

— Иптәш Менжинский,— дип боерды Куйбышев.— Салыгыз богау һәм алып китегез үзен.

— Сез! Бары тик сез генә,— дип, җилкә аша карчыганыкыдай күз карашы белән янә Үзәк Комитет секретарен чукып алды Мирсәет.— Шундый карарга кул куюдан җирәнмәгәнсез икән, монысына гына түзәрсез, шәт.

— Менжинский,— дип, Куйбышев тавышын күтәрде янә.

Тегесе, ни эшләргә икән дип, бертын икеләнеп торгач, ярдәмчеләренә таба ымлады.

— Алыгыз...

Ике җилкәсенә очып кунган ГПУ егетләренең берсе үзенең ничек идәнгә килеп төшкәнен, икенчесе ни рәвешле ишеккә табан мәтәлчек атып китүен сизми дә калдылар. Солтангалиевнең алай җиңел генә бирешергә түгел иде исәбе.

— Әйттем ич,— дип, этәреп җибәрде ул үзенә таба гайрәтләнеп килгән егетләрнең өченчесен.— Кулга богауны Үзәк Комитет секретаре иптәш Куйбышев кигерәчәк. Башка һичкем түгел.

— Менжинский,— дип, чираттагы мәртәбә тавышын күтәрде Куйбышев.— Алып чыгып китәсезме аны, юкмы?!

— Без төрмәдә түгел, иптәш Куйбышев,— дип, шундук ачыклык кертергә ашыкты Мирсәет.— Бу большевиклар партиясенең Үзәк Комитеты бинасы. Тавыш-гауга чыгару сезнең файдага түгел... Көтәм.

Ике кулын сузып Куйбышев каршысына килеп басты ул янә. Туры төбәлгән карашын тегеңәргә текәде.

Менжинский кушылды сүзгә. Ялынуга охшатып мөрәҗәгать итте:

— Без корал куллана алмыйбыз, иптәш Куйбышев. Солтангалиевнең үҗәтлеген беләсез. Бәлки, чынлап та, аның бу үтенечен канәгатьләндерергә кирәктер, ничек уйлыйсыз?..

— Үзең кигер,— дип фырылдады Куйбышев. Аннан Мирсәеткә мөрәҗәгать итте:— Ул кидерсен. Менжинский да җаваплы хезмәт кешесе.

— Юк! Минем партия билетыма ГПУ органнары түгел, сез хуҗа булырга җыенасыз. Иң элек кулны богаула, ул кадәр батыр икәнсез. Аннан, ихтыярың...

Менжинский янә егетләренә ым какты. Богауны Куйбышевка китереп тоттырдылар. Унҗиденче елдан большевиклар партиясе әгъзасы булган күренекле революционер һәм дәүләт эшлеклесе, шул рәвешле, богауланды. Мирсәет Солтангалиевнең кулларына РКП(б) Үзәк Комитеты секретаре Валериан Куйбышев кара тимердән эшләнгән богау кигерде.

Мирсәет башка берни хәтерләми. Күзләрен томан басты, ачы, юеш томан. Нибарысы, Менжинскийның булса кирәк «Төрмәгә»,— дигән боерыгы гына колак яфракларына ябышып калды.

* * *

Солтангалиевның кулга алынуы турында хәбәрне Сталинга Валериан Куйбышев үзе житкерде. Бар нечкәлекләренәчә бәйнә-бәйнә сөйләп чыкты Куйбышев. Сүз арасында, ГПУ егетләренен Солтангалиевкә беләзек-богау кигезә алмый иза чигүләрен дә искәртергә онытмады, үзенең исә моны бик җиңел башкарып чыгуын әйтте.

Күн креслода башын артка ташлап, төребкәсен тотәтә-тотәтә канәгать чайкалып утырган Сталинга әлеге хикәяләү олы ләззәт китерә.

— Булдыргансыз, иптәш Куйбышев,— дип куя шул урында Генераль секретарь.— Синең чын полководец булуың миңа күптән мәгълүм.— Ярым ирония төсмерен эченә алган мактау сүзеннән яңакларына кызыллык йөгерә Куйбышевның. Ул моны ихластан кабул итә, әлбәттә. Генераль секретарьның Самара янындагы вакыйгаларны хәтерләп сөйләвен тоемлап өлгерми.

Мактау сүзләре очындырып җибәрә үзен.

— Гайрәтле икән, татарин,— дип куя хикәяләүче.— Менжинский бер почмакка посты. Ә егетләре идәндә тәгәрәшә. Җаваплылыкны үз өстемә алмый чара калмады...

— Тарих онытмас... Партия онытмас,— дип мыгырдана, тегенең күңелен күрә Сталин. Ә уе башкада...

— Иптәш Сталин,— дип мөрәҗәгать итә шунда Куйбышев.— Батырлыгым бәяләвегезгә рәхмәт анысы. Тик минем җаным тыныч түгел.

Битараф карашын кабинетның ерак почмагыннан алмый гына сорарга мәҗбүр була Генсек:

— Җаныңа ни булды?! Сөйлә.

— Солтангалиевнең яклаучылары күп, иптәш Сталин. Телеграммалар ява башлады. Өзлексез шалтыраталар да...

— Хат һәм телеграммадан, гавәм сүзеннән өстен була белергә кирәк, пол-ко-во-дец!

— Алай гына булса икән. Үзебезнең политбюро әгъзалары арасында да моңардан бер-бер мөгез чыгару яисә файда күрү җаен кайгыртучылар булачак. Троцкий, мәсәлән... Зиновьев... Бухарин...

— Шөлләмә, полководец!

— Төрекләр бу эшне зурдан күтәрергә җыена дип ишеттем тагы. Иран һәм һиндстан матбугатында да аның исемен төрләндерәләр икән... Тамырлары әнә кай тарафларга киткән контрның.

— Төрләндерсәләр соң,— дип бүлдерде аны Сталин.— Димәк, без дөрес эшләгәнбез аны кулга алып. Французлар, инглизләр дә кызыксына әнә, минем үземә шалтыраталар. Халыкара Интернационал вәкилләре түгел ич, череп баручы буржуазия кызыксына. Димәк, без дөрес эшләгәнбез Солтангалиевне кулга алып. Шулай түгелмени, полководец?!.

Сталинның бу көнгәчә алай дип дәшкәне юк иде әле Куйбышевка. Ә бүген «полководец» та «полководец». Солтангалиевне кулга алудагы каһарманлыгы күтәрдеме аны шул югарылыкка, әллә Генераль секретарь, гадәтенчә, түбәнсетеп сөйләшәме аны шулай... Шик төште тәшүен, әмма шик урынсыз дигән нәтиҗәгә килде Куйбышев.

— Сез хаклы, иптәш Сталин.

— Әле бүген беләсезме кемнәр килде минем янга? — дип сорап куйды Генераль секретарь.

— Белмим, иптәш Сталин. Сез генә беләсез.

— Төркия посолы Мохтар-бәй килгән. Үзе генә дә түгел, беренче урынбасары Азиз-бәйне дә ияртән. Ха-ха... Нинди йомыш белән дип уйлыйсың?..

Канәгать елмаеп куйды Сталин. Тагы да киерелә төшеп ботын-ботка атландырып алды. Куйбышев белән әңгәмә кылудан тәм таба иде ул.

— Сез генә беләсез, иптәш Сталин.

Әнә ич нинди кызыклы һәм уңай әңгәмәдәш ул Валериан Куйбышев.

— Төрек җәмәгатьчелеге исеменнән Солтангалиевне азат итүебезне үтенәләр. Төркиядә ул билгеле кеше икән, әнә. Бу көнгәчә аның һәр хәрәкәтен җентекләп күзәтеп килгәннәр. Зыя Гөкальп һәм Йосыф Акчура атлы галимнәре минем исемгә махсус үтенеч юллаганнар. Безнең Солтангалиев язмышы белән Мостафа Кемаль паша үзе кызыксына икән хәтта. Менә ничек, иптәш Куйбышев. Әнә кемнең кулына беләзек кидергәнсең. Аңлашыламы?

— Аңлашылмыймы соң, аңлашыла, иптәш Сталин. Шулай да сез тирәнрәк аңлыйсыздыр, иптәш Сталин.

— Син хаклы, полководец. Беләсеңме кем ул Солтангалиев?! — дип уйга калып торды бермәл Генсек. Әмма, Куйбышев «Сез яхшырак беләсез, иптәш Сталин»,— дияргә өлгерми калды шулай да.— Солтангалиев — ул лакмус кәгазе. Ишеткәнең бардыр: шундый кәгазь бар диләр... Аны яклап хат җибәргән, тавыш күтәргән һәммә кеше — партия һәм халык дошманы. Без шул рәвешле аның үзен генә түгел, тышкы һәм эчке дошманнарыбызны да ачыклаячакбыз, фаш итәчәкбез әле. Шушы вакыйга сәбәпле без меңәрләгән, күп меңәрләгән дошманнарыбызны ачыклаячакбыз. Татарлар арасында аеруча күп Советның дошманнары...

Дәшми утырудан изаланган Куйбышев салпы якка салам кыстырырга кирәк тапты:

— Сез беләсез, сез ачыкларсыз, иптәш Сталин.

Әмма бу юлы сүзе җайсызрак килеп чыкты. Ә Генсек аңдыйны тиз тота, сизгер аңдыйга. Күтәрелеп текәлеп карап куйды ул әңгәмәдәшенә: «Үз аңындамы бу?!»

— Юк инде, сез ачыкларсыз, иптәш Куйбышев! ГПУ ачыклар.

— Юк, юк,— дип кыбырсынып алды Валериан. Түземлелек кирәк иде дә бит ләбаса. Әмма батыр булырга бик-бик теләсә дә, җаваплылыкны үз өстенә алырга күнекмәгән, нишлисең.— Миннән житәр, иптәш Сталин. Мин болай да аңарга богау кигезгән кеше.

— Куркасың!...— дип, күзләрен хәйләкәр кысып, сөзеп карады Генсек. Ялагайларны үз итсә дә, ул да аларны яратмый иде бит.

— Курыкмыйм, иптәш Сталин. Үзәк Комитет секретаре исеменең абруен саклау кирәк дип беләм.

— Менә нәрсә,— дип бүлдерде үзен Йосиф Сталин.— Урыннардагы партия һәм совет житәкчеләреннән күмәк хатлар күренә башлады соңгы арада. Һәммәсе аны яклый, аны азат итүебезне үтенәләр...— Куйбышевның алдына бер бәйләм хат китереп салды ул.— һәммәсе милли республикалардан. Моны туктатырга кирәк. Менә нәрсә!.. Әнә, анда Татреспублика житәкчелеге тулы составында нота җибәргән... Политбюро исеменә!

— Ни житмәгән үзләренә,— дип, сүз кыстырыр җай таба Куйбышев.

— Менә бит ничек дип язалар,— Сталин кабалана төшеп хатның өченче битен табып ачты.— Тыңап кара әле син аларны: «Солтангалиевның һәммә Көнчыгыш автономияләр һәм өлкәләрне оештыру һәм ныгыту юлында эшләгән эшләре онытылырлык кынамы соң...»

— Болар дөресме соң, иптәш Сталин?

— Татар-башкорт өчен, Төркестанлылар һәм Казах өчен, берөчтан башка вак милләтләр өчен җанын бирергә әзер иде ул. Бугазга-бугаз килеп чәйнәште... Россия коммунистлары өчен бу кирәк идеме соң? Хикмәт әнә нәрсәдә!..

Сталин сөйләп барган жирennән шып туктамасынмы шунда. Куйбышевка ни кала?..

— Кара син аларны!...— дип, башын чайкап куйды.— Гаҗәп халык бу татарлар, тәртә арасына кертермен димә үзләрен.

— Әнә, әнә,— дип күтәреп алды Генераль секретарь.— Мин сезгә нәкъ менә шундый бурыч йөкләргә җыенам да инде. Тәртә арасына тыгарга һәм... авызлыкларга кирәк үзләрен. Масаймасыннар. Юкса, грузин коммунистларыннан да болайрак азындылар соңгы арада. Янәсе, аларда Октябрьгә кадәрге чор стажы булган большевиклар бар...

— Тәртә арасына тыгарга һәм авызлыкларга...— дип, Сталин тарафыннан үзенә йөкләтелгән бурычны кабатлады Куйбышев. Борчуга төште. Моны ничек эшләргә соң?..

— Политбюродан түбәндәге карар үткәрергә кирәк: бер-ике атнадан соң барлык милли төбәкләрдән җаваплы хезмәткәрләрне җыярга. Һәм Солтангалиевне фаш итәргә. Бу эшне оештыру һәм башкарып чыгу сиңа йөкләтелә, иптәш Куйбышев.

— Фаш итү өчен дәлилләр, кирәк, иптәш Сталин. Ә алар, белүемчә аз һәм житәрлек түгел. Солтангалиев законны яхшы белә, аларны ул шундук кире кагачак. Мин моны эшкә Дзержинскийның катышмавыннан ук аңладым... Лениннын да хупламавы ихтимал.

— Кем кире кагачак? — дип тавышын күтәрде Сталин. Йөткеренә-йөткеренә мәкерле рәвештә елмаеп алды. — Ленин юк инде ул. Син аны юк дип сана. Ә Солтангалиев төрмәдә. Сак астында. Куллары богаулы... һәм ул богауны иптәш Куйбышев салган... Докладтан дәлил таләп итүче булмаячак. Ышандырырлык итеп сөйләү, гаепләү генә сорала сездән. Партиягә һәм Советларга каршы дип игълан ителгән халык дошманын һичкем якларга җөрьәт итмәс. Җаваплы работникларның, большевикларның психологиясен аңларга вакыт инде сезгә дә, иптәш Куйбышев.

— Аңлыйм, иптәш Сталин, аңлыйм. Ә соң мине татарлар кан дошманнары итеп күрмәсме? Татар бөтен Россия буйлап таралган.

— Күрмәсләр!.. Шул эшне башкарып чыксаң, киресенчә, син татарлар өчен иң күренеклә шәхескә әверелерсең. Казанда үзәк мәйдан Солтангалиев исемен түгел, Куйбышев исемен йөртер. Татарстандагы шәһәрләргә, авылларга, заводларга бирерләр синең исемеңне. Куйбышев исеме төшләренә керә торган булыр татарның. Кызыклымы?.. — дип, мәкерле, әмма юмарт көлеп куйды Генсек. — Син беләсең, мин бушка сөйли торган кеше түгел. Сүземдә тора беләм...

* * *

Майның унтугызынчы көнендә РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы гадәттән тыш утырышка җыела. Ябык ишекләр артында ил агалары И. В. Сталин, В. М. Молотов, Я. Э. Рудзутак, Г. Е Зиновьев, Л. Б. Каменев, Л. Д. Троцкий, Н. И. Бухарин, К. Б. Радек һәм В. В. Куйбышев катнаша. Алар Мирсәет Солтангалиев эшен алга таба ничек дәвам итәргә һәм ничек очлап чыгарга дигән сорауга җавап бирергә тиешле. Юкса, ыгы-зыгы шул дәрәҗәгә житеп килә ки, әйтерсең, илдә шушы «Эш»тән тыш житди мәсьәлә калмаган. Үзәк Комитетта да Солтангалиев, Совнарком бүлмәләрендә очрашып көрәшүчеләрнең дә телендә ул гына. Почта һәм телеграммалар турында да әйтеп тә торасы юк. «Солтангалиев кайда?» «Солтангалиевне азат итегез!..» Политбюро әгъзалары да икеләнүдә. Чөнки һәммәсе дә аның чын большевик булуын, сүздә генә түгел, күп мәртәбәләр эштә дә күргән затлар. Әмма... Күтәрелеп бәрелергә, үзен гаепләргә ашкынучылар булмаса да, күкрәк киереп якларга торучылар да күренми. Һәркемнең үз мәшәкате, үз сәясәте... Троцкий белән Рудзутак кына Солтангалиев эшен күпертүнең урынсыз икәнлеген әйтергә җөрьәт иттеләр. Алары да, узып барышлый дигәндәй, сүз уңаена гына.

Сталин исә үзенең Солтангалиевне башкаларга караганда күпкә яхшырак белүе һәм хәтта үз итүе, якын итүе турында искәртергә онытмый. Ләкин, нишлисең, янәсе, дуслык-дуслык белән. Ә инде партия һәм ил мәнфәгатьләре шәхси дуслыктан күп югары.

Куйбышев тәкъдиме белән, тагы ике атналардан милли төбәкләрнең җаваплы вәкилләре катнашында бер киңәшмә уздыру турында карар кабул ителә. ГПУга исә бу эшне тагы да җентекләбрәк өйрәнү кирәклеге искәртелә.

Көннәр уза тора. ГПУдан яңа мәгълүматлар күренми. Ә Солтангалиевне азат итүне кемнәр генә таләп итми!.. Татарстан хөкүмәте: Совнарком рәисе Мохтаров, Үзәк Башкарма комитеты рәисе Рәуф Сабиров һәм тагын дистәләгән имза куелган хат белән Сталинның үзенә инде икенче мәртәбә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр. Ул мөрәҗәгатьнең нөсхәләре башка Политбюро әгъзаларына да житкерелгән. (Әлеге мөрәҗә-

гатьтә татар әдипләре Фәтхи Бурнаш вә Шамил Усманов имзалары да бар).

«Мирсәет Солтангалиевне яхшы белгән кешеләр буларак, аны басмачылык хәрәкәте белән элемтәгә керүдә гаепләүне катгый рәвештә кире кагабыз... Бу кулга алыну аның милли республикалар ихтыяҗын кайгыртуы һәм XII съезддагы принципиаль чыгышы өчен кайбер иптәшләр тарафыннан үч алу буларак кына аңлашыла...»

Сталин үз нөсхәсендәге әнә шул юллар астына зәңгәр карандаш белән сызган. «Әнә ни чек, әнә кемгә кизәнәләр...» — дип уйлаган булса кирәк үзалдына. Һәм, билгеле, хатның ахырына кул куярга җөрьәт иткән унбиш татар шул сәгатьтән Генераль секретарьның хәтер дәфтәрендәге кара исемлеккә кертелгән. Боларга һәм боларны үз иткән кешеләргә, якыннарына, туганнарына, бала-чагаларына мәрхәмәт булмаячак, дигән сүз бит бу...

Генераль секретарьның җанында тынгылык юк. Әле кичә генә, ягъни 1923 ел маеның 22 көнендә аңарга ярдәмчесе А. Назаретян хикмәтле хат китерде. Солтангалиевнең Лубянка төрмәсеннән Сталинга һәм Троцкийга атап язган хаты. Төз һәм тыгыз юллар белән язылган 80 битлек хат. Исеме генә хат. Ә чынлыкта автобиографик роман. Төн буе, керфек какмый укып чыкты аны Сталин. Һәр җөмлә, һәр сүз артында үзе белгән, үзенә күптән таныш һәм якын булган татар большевигын күрде, Солтангалиевне.

Укып чыккач та, үзалдына әйткән беренче сүзләре шул иде: «Сынмаган... Төрмә дә сындырмаган үзен... Үзенә үпкәләсен!»

Ике нәрсә аеруча кәефен кырды Сталинның. Беренчесе, хатның үзенә генә түгел, ә Троцкийга да язылган булуы. Троцкийны аның белән яңашә, тигез куюы. Икенчесе, гафу үтенәсе, баш иясе урында, төрмәдә дә аек фикер йөртүе. Үзен ил һәм милләтләр язмышы өчен җаваплы кеше итеп тоюы. Акыл көче, фикер зирәклеге. Нәрсә-нәрсә, әмма боларны гафу итә, күтәрә алмаячак ул... Димәк, башлаган эшне ярты юлда калдырырга ярамас. Ашыгырга кирәк! Ашыктырырга.

Майның 24 нче көнендә янә җыела Политбюро. Көн тәртибендә әлеге дә баягы шул ук мәсьәлә: Солтангалиев эшен хәзерләүнең торышы һәм игълан ителгән киңәшмәгә әзерлекнең барышы.

ГПУга, аерым алганда Менжинскийга, тагы бер мәртәбә кисәтү ясала: «дәлилләр аз, дәлилләр җитәрлек түгел».

Киңәшмәгә вәкилләрне милли төбәкләрдән генә чакыру турындагы карар үзгәртелә. Килүчеләр дәррәү Солтангалиевне якларга керешсә, нишләрсең?! дигән шик килә бер акыллы башка. Урынсыз булмый андый шик. Шуны истә тотып, төрле өлкәләрдән, өстәмә рәвештә, рус милләтеннән булган унбиш җаваплы партия хезмәткәрләрен чакырырга карар кылына.

Ул киңәшмәдә Үзәк Комитет һәм Политбюро әгъзаларының бер фикердә булырга тиешлеге катгый төстә мәҗбүриләштерелә.

Докладчы билгеләнә.

• • •

Мирсәетнең хәбәрсез-кисәтүсез кунарга кайтмый калуы Фатыймага ничек тәэсир иткәнлеге аңлашылса кирәк. Төн уртасынача, менә кайтыр, менә кайтыр, дип көтеп йөрде ул аны иң элек. Аннан тәрәзәгә барып капланды. Мәскәү елгасы аша тоташтыручы Зур таш күпер бушап калган. Берән-сәрән үтүчеләр күренсә дә, аның җиңел һәм ашкынулы йөрешен хәтерләтүче булмады.

Гөлнарны йоклатырга яткан җирдән Рәсидә дә оеп киткән иде. Кызлар мес-мес килеп йоклый. Ярый әле алар белми, аларның күңеле тыныч, дип уйлап куйды Фатыйма. Юкса, уяу булса, Рәсидә ямансуларга керешкән булыр иде инде күптән. Әтисенә бер дә харап бәйләнгән бала шул. Әти диеп күзен йомган кебек, әтисен эзләп йокыдан уяна. Барын да аңлый кызый, Фатыймага инде ияләшсә дә, әле булса «әни» диеп ихластан әйтә алмый газаплана.

Керфек тә кага алмады ул төнне Фатыйма. Гомер булмаган хәл иде бит. Юлдан кайтып кермәсә, эштән бушамаса да, Мирсәетнең һичкайчан эзсез югалганы юк иде әле болай. Командировкага китәсе булса өйгә кагылмый үтми, соңга каласы булса хәбәр сала торган иде. Ә менә болай, ипле генә эшләп йөргәндә суга төшкән балта сыман югалуы һич мөмкин түгел иде аның. Өйдә хатыны һәм ике кызчыгы үзен ничек көткәнлекне белә ич ул. Исән булса, тәнендә җаны торса, юк-юк болай булмас иде. Нигә юрарга, нинди нәтиҗәгә килергә белми аптырады бахыр.

Кояш чыкты һәм таң атты. Ә Мирсәет юк та юк, хет бер кеше килеп җанны тынычландырырлык бер-бер сүз әйтсә икән... Ниһаять, кызлар уянды, алар сорарга кереште әтиләрен. Фатыйма алдады: әтиегезнең эше бик күп, диде, соң гына кайтты да, иртүк кире китеп барды. Сезне йокыдан уятырга кызганды, диде.

— Әттә безне сөйдеме соң? — дип сорап куйды нәни Гөлнар.

Ялганга бер керешкәч, туктыйм димә, ялганын дәвам итте ана. Хәер, бу очракта әлеге ялган, хакыйкатьтән игелеклерәк булгандыр бәлки.

— Иртән дә, кичен дә сөйде. Икегезне дә сөйде,— диде ана.

Шунда Рәсидә чираттагы мәртәбә хәйран калдырмасынмы үзен. Тугыз яшьлек бала авызыннан ишетәме ул моны.

— Син алдыйсың, әни,— диде ул. «Әни» сүзен авырлык белән әйтте, әле күнегергә өлгерә алмый газапланган чагы иде.— Әтием кайтмады бүген.

Фатыйма ни диярга белми югалып кала язды.

— Каян килеп шулай дисең, кызым, Рәсидә.

— Әтием сөйгәндә мин һәрчак уянам,— диде кыз, еларга җитешеп.— Бүген ул кайтмады. Син аны тәрәзә төбендә көтеп утырдың.

— Кем әйтте, каян белдең?

— Мин йокламадым. Одеял бөркәндем дә, әтием кайтканны көттем.

Фатыйма, аналарча җылылык белән, аркасыннан килеп сөйде, күзләренә бакты кызның. Чынлап та күзләре моңсу, моңсу гына түгел, кайгылы иде Рәсидәнең. Ә Гөлнар әле сабый гына. Ул һични аңламый, ишекле-түрле йөгереп йөрүен белә.

Кызларын ашатып-киендереп, ике кулына икесен җитәкләп урамга чыкты ана. Мирсәетнең эш урынына юнәлделәр. Эш сәгате җиткәч тә, үзен булмаса, ярдәмчеләре яисә секретарьларыннан бер-берсен очратып белешү иде уйларында.

Озак көтәргә туры килмәде. Федераль җир комитетында Мирсәетнең шәхси секретаре булып эшләгән өлкән яшьләрдәге Елизавета Ивановнаны очраттылар. Чәчләре чаларган бу ихлас хатын үзенә бирелгән сораудан хәйран калды. Солтангалиевне үз улыдай якын күрә, хөрмәт итә иде бит ул да.

— Һичкайда китәргә җыенмый иде, югыйсә,— диде көтелмәгән сорауга җавапсыз калган Елизавета Ивановна.— Кичке сәгать бишенче яртыларда иде булса кирәк, Үзәк Комитетка чакырдылар үзен. Тиз генә барып кайтам дип, җил-җил атлап чыгып китте. Үзен сорап килүчеләр булса, көтәргә кушты... Кайтам дисә, кайта торган иде, ни сәбәпледер кайтмады. Гаҗәп...

Күзләренә текәлеп торган ике сабый һәм яшь хатынның хәлен аңлап, шундук чара күрергә керește ул, телефонга үрелде. Һәм үзалдына сөйләнеп тә алды.

— Шкирятов шалтыраткан иде бугай. Хәзер, хәзер ачыклыйбыз аны... Алло, иптәш Шкирятовмы бу?.. Шкирятов иптәш кирәк иде... Әйе, әйе, федераль жир комитетыннан. Ашыгыч эш белән.

Дәшми, тыңлап торды Елизавета Ивановна. Тоташтыруларын көтте булса кирәк. Тын да алмый Фатыйма да көтте. Кызларның күзе дә чал чәчле ханымда. Алар да аның авызыннан тынычландырырлык, ипле сүз көтә.

Ниһаять, тотыштырдылар булса кирәк. Елизавета Ивановнаның ипле, кайгыртучан тавышы ишетелде.

— Иптәш Шкирятов, бу — федераль жир комитетыннан Солтангалиев иптәшнең секретаре иде әле. Әйтә алмыйсызмы, ул кайда хәзер?

— Әйтә алмыйм. Белмим,— дигән коры җавап ишетелде аргы тарафтан.

— Ул кичә, сәгать бишенчедә сезнең чакыру белән киткән иде. Шуннан соң күренмәде...

— Ә аны күрү шул кадәр үк әһәмиятлеме?

Тетрәнеп куйды ханым, телефон төребкәсен чак кына төшереп җибәрмәде. Әмма шундук кулга алды үзен, сиздермәде.

— Аны эзлиләр... Кабул итү бүлмәсендә көтәләр. Мин ни дип җавап бирергә тиеш, иптәш Шкирятов.

— Урынбасарлары кабул итсен.

— Ә ул, үзе кайда соң?

— Сүзем тәмам,— диде аргы яктагы дорфа тавыш.— Мин сезгә өстәп һични әйтә алмыйм. Солтангалиевнең кайдалыгын сезгә һичкем әйтә алмас, бу — дәүләт сере.

— Дәүләт сере?..— дигән сүз ычкынды гаҗәпләнүе чамадан узган ханымның авызыннан. Һәм төребкәне куйды, җавап көтүчеләргә йөз белән борылды.— Гаять житди дәүләт эше белән мәшгуль Мирсәет Хәйдәргалиевич. Ул, һичшиксез, кайтыр. Көттермәс, хәбәр дә итәр, кайтып та житәр...

Хушлаштылар һәм кайтыр юлга юнәлделәр. Әмма күңеле тынычланмады Фатыйманың, киеренке билгесезлек арта гына төште булса кирәк.

Өйгә кайтып, ишекне ачып керсәләр, чак кычкырып җибәрмәде Фатыйма. Авызын каплап калды алай да... Алар китеп торган арада фатирда кемнәрдер булган, нидер эзләгәннәр, актарганнар өйнең астын-өскә китергәннәр. Мирсәетнең эш өстәле бушап калган, тау-тау өелеп торган кульязмалардан һәм шүрлектәге китаплардан җилләр искән.

— Әни, бездә кем булган?.. Нигә өйдә шундый тәртипсезлек?— дип, куркынып артка чигенде Рәсидә.

— Әтиең кайткандыр. Кәгазьләрен, китапларын алырга кайткандыр... Ашыккандыр...— дигән өзек-өзек сүзләр чыкты ана авызыннан. Үзенең күзе күргәннәрдән чәч төпләре чемердәде. Өйгә керергә курка иде ул үзе дә, кызларын житәкләп кире чигенде.

— Әти түгел. Безнең әти похтә... Безнең әти өйнең астын-өскә китерми ул,— дип, куркынган күзләрен Фатыймага текәде Рәсидә.

Ана читкә борылды, күзләрен яшерде кызларыннан. Әлегәчә чырык-чырык уйнап, һәрнәрсәдән кызык табып йөргән нәни Гөлнар да, тынгысызлана башлап, шыңшып еларга кереште.

Өй ишеген тышкы яктан бикләп, Зур Татар тыкрыгына юнәлде алар. Кабалана-кабалана йөгерделәр, әйтерсең, күзгә күренмәгән ниндидер кара көч куа чыккан иде бу гаиләне.

Мирсәетнең язмышы турында, бер атна сузылган билгесезлектән соң гына, хәбәр житкерделәр Фатыймага. Анысы да озын колаклар аша гына! «Кулга алганнар икән... ГПУ төрмәсендә, Лубянкада аерым камерада бикләп яткыралар икән...»

* * *

Балачакта Мирсәетнең иң олы хыялы тизрәк үсеп җитү булгандыр. Үсеп җитү һәм ирекле, мөстәкыйль кеше булып үзең теләгәнчә яшәү. Ерак калаларга — Казанга, Мәскәүгә һәм Ригага барып чыгу турында хыяллана иде төннәр буе. Ни өчен Казан? Бу — аңлашыла. Казан — илнең кай төбәгендә генә яшәмәсен, татар баласы өчен рухи мәркәз, җан җылысы бөркеп үзенә тартып торган кала. Мәскәү — илнең иң зур һәм матур шәһәре. Шулай булмаса, патшалар Мәскәүдә генә тормаслар иде... Ә Рига, Рига ничек һәм ни рәвешле килеп керде икән аның хыялына? Патша армиясендә хезмәт иткән унтер-офицер морза абзасыннан ишеткәне булдымы икән? Әтисе үзен орыштымы, «Минә күрерсез, тотармын да Ригага качып китәрмен әле»,— дип куркыта торган иде. Күрәсең, Рига балачак романтикасының иң ерак хыялы булган, диңгез аръякларындагы иң ерак һәм матур кала тоелгандыр аңар.

Кызганыч, революция һәм гражданнар сугышы елларында илнең кай төбәкләренә, нинди шәһәрләренә генә барып чыкмады, ә менә Ригада булырга туры килмәде. Казан һәм Мәскәү аның өчен үз булган шәһәрләргә әверелде, ә Риганы күргәне дә юк. Латышлардан күпме таныш-белеш, көрәштәшләре бар иде, хәтта шуларның берсеннән Рига турында сораштырырга өлгермәгән. Хәер, яшәр, балачак хыялларын барлар арасы булдымы соң әле аның. Үсмер чактан ук революция дулкынына килеп кушылды һәм ташкын сыман кубарылып-актарылып аккан вакыйгаларның үзәгендә булды һәрчак. Үзәгендә булды... Тик менә хәзерге хәле генә башка сыймый. Үзәктә иде һәрчак. Инкыйлабка, бөтендөнья халыкларының азатлык хәрәкәтенә багышланган гомер шундый фаҗигале юлга килеп чыгар дип кем уйлаган. Актарылып аккан дәрья дулкыннары яр читенә чыгарып аткан бичара балык хәлендә торып калды түгелме соң ул хәзер?!

Әйе, Рига хакында хыяллана иде бит әле... Үз-үзенә сүз бирде. Гаепсез икәнлеге ачыкланып иреккә чыккач та, бер ара табып, Мирсәет, һичшиксез, хатынын һәм балаларын ияртеп, Рига каласына барачак. Рәсидә белән Гөлнар бер-берен узышып диңгез дулкыннарын сикерә-сикерә яр буеннан йөгерешерләр. Ә Фатыйма белән ул, балалар тавышы һәм дулкын шавыннан сихерләнеп, янәшә атлар...

Дагалы итекләре белән таш идәннән шак-шок басып килгән берәү ул утырган камера ишеге төбендә кинәт туктап калды. Хыял өзелде, Рига һәм Балтыйк ярындагы гүзәл манзара юкка чыкты. Обой артындагы кыштырдаган күсе кебек, тимер капкачны югары күтәреп нәни генә күзлек — тәрәзә аша аны күзәтәләр. Син аны күрмисең, ә ул синең ничек утырганыңны, ничек сулыш алганыңны күзәтә — революция һәм Совет хөкүмәтенә каршы берәр төрле яман ният кылмыйммы, янәсе. Шуны күтәрергә, шуңарга түзәргә кирәк... Нинди кыргый түбәнлек, газап!

— Әй, син! — дип, үз-үзен белешмичә кычкырып җибәрде Мирсәет һәм күз-тишеккә бармагын төбәде.— Мине генә түгел, үзеңне дә рәнҗетәсең.

Күзлекнең тимер капкачы ябылды. Әмма тимер дагалы күнитек китәргә ашыкмады. Бер адым ары киткәч кире борылды, ахрысы. Күңелендә бер-бер мәрхәмәт уянды булса кирәк, дигән уй килде Мирсәеткә.

Надзиратель бераздан, нинди дә булса карарга килеп, күрәсең, шалтор-шолтыр китереп тимер ишекнең йозакларын ачарга кереште.

— Син кемгә бармак төрткәнеңне беләсеңме? — диде кечерәк гәүдәле, әмма таза, төптән ныгып үскән урта яшьләрдәге ир-ат, ишекне эчке яктан кыса төшеп.

— Мине күзәтәсе юк, надзиратель иптәш,— диде һәм сагая калды Мирсәет. Ишектән керүче бер дә игелек күрсәтер затка охшамаган. Төссез, аксыл күзләрендә канга сусау.— Вакытыгызны юкка әрәм итмәгез дип кенә әйтүем.— Мин — большевик!

Теге явыз ният белән кергән. Синең сүзләреңә колак та салырга теләми.

— Надзиратель түгел, сиңа иптәш тә түгел! ОГПУ офицеры булыр бу абзаң! — диде ул кырт кистереп һәм, көтмәгәндә алга таба омтылып кул аркасы белән Мирсәетнең иреннәренә китереп сукты.— Ух, ты, татарин гололобый!..

Авыртудан бигрәк, урынсызга рәнҗетелүдән канлы иреннәрен кулы белән каплап бөгелә төште Мирсәет «Син монда кол, шуны онытма, Мирсәет, син — кол... син — кол... Җавап кайтара күрмә, син кол... Үзеннең кол икәнеңне онытма, онытсаң — шундук юкка чыгарачаклар...» — дип тынычландырырга тырышты ул үзен. Соңгы араларда үз тәҗрибәсе белән ирешкән фәлсәфәсе иде бу аның. Надзирательгә күтәрелеп карамады бүтән.

Ә теге исә чыгар юлына борылды. Шыгырдап торган тимер ишекне ябар алдыннан гына үзалдына мыгырданып алды:

— Кисеп-суеп бетермәгәннәр шул үзегезне...

Күзләрен чытырдатып йомды һәм, иялəнгән гадәтенчә, маңгае белән камераның салкын диварына орынды Мирсәет. Әле генә колагы ишеткәннәр җанын актарып алды, канын кайнатты аның.

Нәрсә бу? Аның халкына — татарларга карата шундый нәфрәт каян килә бу бәндәләргә? Тамыры кайда моның? Кемгә нинди зыян китергәне бар татар халкының?! Тарихның кай дәверләрен генә барлама, аның халкы — борынгы Болгар иле — берәүгә дә бәла-каза китермәгән. Рус кенәзлекләрен монгол явыннан саклап калган халык булган ул, рус патшасы кем белән мал бүлешсә, шунда уртак Ватан өчен гомер-гомергә җанын фида кылган халык. Революция һәм гражданнар сугышы елларында яңа тормыш өчен азмы кан түкте, имәндәй нык улларын корбан итте татар халкы. Тарихның иң хәлиткеч мизгелләрендә сынаткан халык түгел татар. 1919 елда М. В. Фрунзе гел: «Сез татарлар революциянең иң ышанычлы солдатлары булуыгызны канлы көрәш кырларында расладыгыз»,— дип тикмәгә генә әйтмәгәндер.

Уйлый калсаң, гаҗәп хәл бит. Гаҗәп сәер килеп чыга. Бераз тынычлана төшеп, маңгаен таш дивардан аерды Мирсәет. Аннары ишекле-түрле йөренергә кереште. Ваграк итеп атлаганда, нәкъ өч адым алга, өч адым артка. Шулай йөрү бәхетеннән дучар итсәләр ничек көн үткәрер иде?..

Өч адым алга, өч адым — артка. Үзе ни өчендер кешеләрне милләтләренә карап аермады ул. Рус та, яһүд тә, татар да, башкорт та бер иде аның өчен. Яңа тормыш өчен көрәшчеләр һәм шул көрәшнең дошманнарына гына аера иде ул кешеләрне. Хәтта үз милләттәшләренә кырысрак чаклары да булгандыр.

Гражданнар сугышы көннәреннән бер вакыйга исенә килеп төште. Колчак тылына «тел» алырга җибәрелгән ике кызылгвардияче, яшь кенә егетләр иде, шулай беркөн аның янына буш кул белән кайтып керделәр. «Тел»сез кайтулары бер хәл, хәтта винтовкаларын югалтып кайткан тегеләр. Мылтыкларын бер-беренә сөяп яр читендә калдырганнар да инешкә су эчәргә төшүләре булган, өсләренә дошман килеп чыккан. Мылтыклары турында онытып, инеш читендәге үзәнлек аша әрәмәлеккә кереп элдерткәннәр. Бу гайре табигый хәл иде мөселман сугышчылары өчен, шуңа аларны кайтып-кайтып мәзәккә алып та сөйләделәр. Хәйретдинов — татар егете, Иделбаев — башкорт. Саф алдына чыгарып тетмәсен теткән иде тегеләрнең.

Соңыннан Хәйретдинов дигәне аның янына килеп үз зарын сөйләде.

— Иптәш комиссар,— диде ул, гарьлегеннән күз яшьләрен йотып (Әйе, комиссар дип дәшә иде аңа күпләр).— Безнең гаеп Кызыл Армия каршында зур. Теләсә нинди җәза алырга да әзер. Ләкин мин аңламадым, нигә сез мине генә аерып сүктегез. Гаебебез Иделбаев белән бер үк дәрәҗәдә иде бит, иптәш комиссар.

Бу вакыйга Мирсәеткә хәзер көлке генә тоела инде. Әмма ул чакта башкачарак кабул ителгәндер, заманы бүтән иде.

— Дәшмә, Хәйретдинов. Син нәрсә монда балавыз сыгып торасың. Кызылгвардияче булсаң, кызылгвардияче бул. Приказны үтәми кайтуың гына җитмәгән, корал югалткансың! — диде аңа Мирсәет.

— Мин үзем генә түгел ич, иптәш комиссар, без икәү идек...

— Дәшмә! Җитәр! Син үзең өчен җавап бирергә өйрән.

Күрәсең, башкорт егетенә йомшаграк әйтелгәндер. Ни дисәң дә, үзеңнеке — үзеңнеке, катырак эләксә дә күтәрә. Без шулай күнеккән. Аның каравы, имеш-мимешкә урын калмый.

Милли чикләнгәнлектә гаепли күрмәсеннәр, «милләтче» дигән яла ягып куймасыннар, дип тырышты. Ихтимал, вакыт-вакыт чамадан арттырып, интернационалист икәнлегемне исбат итәм дип, киртәдән сикергән чаклары да булгандыр. Соң чиктә аны барыбер милләтчелектә гаепләделәр. «Милләтче» ярлыгы тагып, таш капчыкка ташладылар.

Искә алулар, уйлар тагы балачагына, Урал итәгенә, Башкортстан киңлекләренә алып кайтты аны. Авылдан-авылга күчеп мөгаллимлек иткән әтисе артыннан атка утырып, арбага ияреп йөргән еллары. Унике баланы ашатырга-киендерергә, ай-һай, җиңел булмагандыр. Шуңа да кырыс һәм коры булгандыр әтисе. Мирсәеткә дә еш эләгә торган иде үзеннән. Бәхәсләшкәнен, олылар сүзенә кысылып фикер йөрткәнен өнәмәде ул аның. Шулай да әтисен яратып һәм сагынып искә ала ул — берөзлексез эшләргә һәм максатка ирешергә өйрәтте аны. Ә менә уйлаганын турыдан ярып әйтә, дөреслек үз ягында булса, дәшми кала алмый торган гадәтен ташламады. Хаклыкны ачыклау, бәхәсләшү юлында сабырлык җитмәде шул. Кемнең кем булуы белән хисаплашмый, үз инанганына тугрылыклы булып яшәде. Бәлки, бу уңайдан да әтисе киңәшен тоту хәерлерәк булгандыр.

...Туган як һәм балачак хатирәләренә бер юлыксаң, үз ихтыярың белән читләшергә мөмкинме соң? Шул ачлы-туклы балачагының бер генә көнен ун ел гомере бәрабәренә алыштырып кире кайтарырга риза булыр иде ул хәзер. Әнкәсен сагынып искә төшерде ул. Камил булмаганы өчен, дөньяны каһәрләп яшәгән горур әткәсен хәтерләде. Бергә уйнап үскән күрше малайлары, авылдашлары кайда икән хәзер, тормыш җилләре үзләрен тузганак итеп кай тарафларга чәчте-туздырды икән?! Хәтта Тау башы авылында үткән санаулы көннәрен сагынып хәтерләде. Морза туганнарын...

Их, кулына каләм һәм ак кәгазь эләксен иде аның хәзер. Көнне-төнне белмичә язар иде ул башыннан кичкәннәрне. Гомере буе язучы булу, шагыйрь булу иде хыялы. Гомере буе ара табылмады, вакыт җитмәде. Хәзер исә ара да бар, вакыты да... Кәгазь-каләме генә юк. Язмышына давыл булып килеп кергән һәм шулай ук тиз, көтмәгәндә мәңгегә китеп югалган якын дусты, көрәштәше Муллануp Вахитовка багышлар иде ул иң тәүге әсәрен. Ялкынлы революционер һәм сокландыргыч талантка ия оештыручы буларак кына түгел, кеше һәм ир-егет буларак та мәңгегә хәтерендә уелып калган күренешләр аша сурәтләр иде аның образын...

Вакыт шактый ук соң булырга охшый. Таш капчыкта көн белән төн аермасы сизелми, онытыла икән ул. Төн дә түгел, көн дә түгел, һәрчак эңгер-меңгер монда.

Чү, таш идәннән берәүнең бире таба килгәне ишетелә түгелме соң?.. Кемдер килә... Баягы офицер булса кирәк, күнитегенә кагылган даганың берсе бушый төшкән — тавышы бүленеп чыга... Адымнар якыная... Ниһаять, аның ишегенә килеп җитте һәм тукталды. Кыштыр-кыштыр камера эченә күз салып алды иң элек. Шуннан соң гына ишекне ачып бире керде.

Әлеге дә баягы тонык күзле, җирән мыеклы офицер иде бу. Кәефе күтәренке, елмая төшеп сәлам бирде ул Мирсәеткә:

— Хәерле төн, иске дус...

Күңеленә җылы йөгерде Мирсәетнең, гөлт итеп балкып өмет кабын-

ды: «Ниһаять, гаепсез икәнлеге ачыкланган түгелме? Шулай буласын белгән иде бит ул, өметен өзмәгән иде. Сталинга ышанычын югалтмады... Өнеме бу, төшеме?!»

Офицер дәшми, елмая гына. Аның күзләренә текәлеп елмая.

— Йә, әйт, нинди яңалык алып килдең? Әйт тизрәк,— дип, ачынып, түземсезләнеп, офицерның каршысына килеп басты, кулларына килеп ягылды Мирсәет.

Теге исә, борынын җыерып, бер адым артка чигенде һәм, Мирсәет аны-моны абайлап өлгергәнче, үзен аяк чалып идәнгә төртеп екты.

— Җирәнгеч... Шакшы... Милләтче...— дип сүгенә-сүгенә идәндә яткан Мирсәетне типкәләргә, таптарга кереште.— Мә, ал кирәгеңне!

Күңеле булганчы типкәләгәч, берни булмагандай чыгарга юл тотты җирән мыеклы офицер.

Мирсәет авыз-борыныннан килгән канга буылып башын күтәрде. Офицерның бүгенге кыланышлары бер дә башына сыймый, гайре табигый иде аның өчен.

— Бу нәрсә, инструкциядә каралганмы, әфәнде!

Җиңүче кыяфәтендә аягүрә басып торучы, канәгать елмая иде.

— Юк, инструкциядә каралмаган. Бу минем сиңа шәхси бүләгем, иптәш Султан-Галиев.— Аның фамилиясен авырлык белән генә әйтте.— Көндез күргәчтән үк күңелемә хуш килгән идең. Синдәй акыл ияләрен үлеп яратам мин. Интеллигентларның тәне йомшак була икән ул. Шуңа һәммәсе йокыга талгач та хәлеңне белергә кердем. Канәгатьме?..

Офицерның ничек чыгып югалганын Мирсәет башын горур тотып карап калды.

* * *

Солтангалиев эше үткәреләчәк киңәшмәгә ике генә көн калды дигәндә Генераль секретарь үзе янына Менжинскийны чакыртып ала.

— Йә, сөйлә, дәлилләр җитәрлекме? Документлар әзерме? — дип, керүчегә урын тәкъдим итмәс борын, үгезне мөгезеннән элэктермәк була Сталин.

Керүче каушап кала. Сул ягына асылган кыр сумкасын ачып, аннан бер төргәк кәгазь тартып чыгара. Өстәлгә китереп салыргамы, әллә Генсекның кулына тоттырыргамы үзләрен — нишләргә белми аптырый, кабалана.

— «Икенче парламент» дигән яшерен исем астында үткәрелгән эш йомгакланды, иптәш Сталин. Игътибарга лаеклы документлар менә монда,— Әле булса кулында нишләтергә белми тотып торган төргәккә ымлый Менжинский.

Хуҗа тыныч түгел. Кәгазь кайгысы түгел аңарда, башлаган эшне ярты юлда туктатмый ерып чыгу әһәмиятле.

— «Парламентлар» үзегезгә калсын! — дип, фырылдап куя ул, карашын Менжинскийга текәп.— Миңа нәтиҗә кирәк. Солтангалиев гаепләме?

— Гаепле, иптәш Сталин. Нигә гаепле булмасын, гаепле.

— Гаебе нидән гыйбарәт?

Каушамас җиреңнән каушарсың, күзләре үтәдән бораулый.

— Сез беләсез, иптәш Сталин, Көнчыгышка мөнәсәбәтле милли сәясәттә аның фикерләре партия һәм Совет дәүләтенекеннән кискен аерылып тора.

— Фикер аерымлыгы җинаятьме?!

— Җинаять, иптәш Сталин. Чөнки ул Татарстан һәм Казагыстанда мөстәкыйль республикалар төзү идеясе белән йөри. Көнчыгыш халыклары Көнбатышның колониаль изелүеннән азат ителергә тиеш, дип сөйли...

— Тагы, тагы?.. Дәвам итегез, Менжинский иптәш.

— Солтангалиев тагы төрек, фарсы һәм әфганлыларның Мәскәүдәге илчеләре белән элемтәдә тора...

— Нииндидер мәгълүматлар тапшыруы мәгълүм түгелме?

— Ул хакта безгә мәгълүм түгел, иптәш Сталин. Әмма Көнчыгыш илләрендәге хәлләр белән даими кызыксынганлыгы исбат ителә.

— Кызыксыну җинаятьме, ачыклык кертегез, Менжинский?..

— Җинаять, иптәш Сталин. Чөнки ул үзенең килеп чыгышына якын булган милләтләр язмышы, ислам динендәге халыклар язмышы белән кызыксына күбрәк.

— Тагы бармы?

— Зәки Вәлиди белән элемтәгә омтылуы исбат ителә тагы.

— Омтылыш та җинаятьме?

— Кая омтыла бит, иптәш Сталин. Ә бу очракта ул Совет дәүләтенең төп дошманнарыннан берсе булган Зәки Вәлидигә чыккан.

— Максаты мәгълүмме?

— Мәгълүм. Вәлидине солыхка чакыру. Мөселман һәм төркиләрнең бер-берен үтерүенә чик кую.

— Аңлашылды,— дип, тамак кырып алды Сталин. Һәм ашыкмый гына тәребкәсен алып, аңарга тәмәкене дыңгычларга керешә.— Ишкәнсез икән ишәк чумарын!

— Ничек бар — шулай, иптәш Сталин.

— Ничек бар шулайны ачыклау өчен кирәкме ул ГПУ?! Сездә бит хәзер дәүләт һәм партия органнарындагы кадәр кеше эшли, ачуым килмәгәе. Нәрсә белән мәшгуль алар анда?! — Янә тамак кырды һәм тәребкәсенә ут салып, имәргә керешә хуҗа кеше.— Шул эшләр өчен утыртып буламы Солтангалиевне, юкмы — шуны әйт син миңа?!

Ниһаять, ихлас сүз өзелеп төшә Менжинский авызыннан:

— Утыртып булмый, иптәш Сталин. Солтангалиевне бүген үк азат итәргә кирәк.

Сталин, үз колагы ишеткәннәргә ышанырга-ышанмаска белмичә, магнитланган сыман урыныннан калыкты. Һәм өстәл артыннан чыгып, Менжинскийның каршысына ук килде. Текәлеп карап торды ул аңар. Озак карап торды. Сталинның карашына түзү мөмкин түгел. Ике күзен нишләтергә, кая яшерергә белми изаланды ГПУ вәкиле.

Ниһаять, телгә килде хуҗа. Сеңдереп, ипле генә аңлатырга керешә.

— Иптәш Менжинский, тагы ике көннән Солтангалиев эше буенча махсус киңәшмә узачак. Шуны онытмагыз! Ул партиядән чыгарылды. Партия һәм хөкүмәткә хыянәт итте. Бөтен Совет иле хезмәт ияләренә хыянәт итте. Бу азмы?!

— Аз түгел, иптәш Сталин. Аз түгел, бу олы җинаять.

— Димәк, сез ул кәгазьләрегезне Куйбышевка кертеп тапшырырсыз. Ул докладчы. Аның фикерен чуалтмагыз. Гаепләме, түгелме, гаепле булса, ул гаеп нидән гыйбарәт икәнлекне Куйбышев үзе ачыклар... Тагы шул, Менжинский иптәш, ялгышмасам, сез ГПУда Көнчыгыш бүлеге ачкан идегез. Шул бүлектә яңа бүлекчә оештырылсын. Солтангалиев эшен баетуны йөклә үзләренә. Берочтан Солтангалиевнең әшнәләрен дә онытырга ярамас.

* * *

9 июнь. Сәгать, төшке аштан соңгы исәп белән, ике. Мәскәү. Кремль. Үзәк Комитетның зур киңәшмәләр залы.

Президиумда — Политбюро әгъзалары. Залда милли республикалардан һәм өлкәләрдән махсус исемлек белән чакыртылган җитәкчеләр. Көн тәртибендә — Солтангалиев эше турындагы мәсьәлә. Ә Мирсәет Солтангалиев үзе Лубянка төрмәсе подвалындагы аеруча куркыныч җинаять-

чеҗләр өчен билгеләнгән таш камерада. Ике кат тимер ишекле, тәбәнәк түшәмле, тәрәзәсез ул камераның исәп саны — алтынчы.

4 майда китереп ябылган Мирсәет Солтангалиев монда 19 июньгәчә, ягъни тулы 45 көн гомерен үткәрә. Сындырырга теләсәләр дә — сынмый. Вакытын да бушка уздырмый, «Мин кем?» дип исемләнгән автобиографик әсәр яза. Күләмле һәм драматик әсәр. Монда шәхси драма гына түгел, тулаем татар халкының драмасын эченә алган сәхифәләр дә байтак.

Язу бер хәл. Аны югалтмау да әһәмиятле бит әле. Монда да Мирсәет бердәнбер дөрес юлны сайлап алган. Ул аны Сталинга һәм Троцкийга хат итеп юллый. Ә Сталинга юлланган хатлар югалмый, ертылмый һәм яндырылмый ул елларда.

Киңәшмә залына кайтыйк. Гадәттәге ыгы-зыгы юк бүген залда. Шомлы тынлык. Исәнләшү-сәламләшүләр дә бүген бөтенләй башка, ым кагу, кул һәм күз хәрәкәтләрендә генә. Киңәшмә барган дүрт көн дәвамына гына түгел, алга таба һәрчак шулай булачак. Курку, шикләнү вә сагаю кабинетлардан гаиләләргә, гаиләләрдән һәр аерым җанга күчәчәк.

Тирән итеп сулыш алучы да юк. Рәислек итүче Каменев торып баса. Янәшәсендә утырган Сталинга карап куя ул. Тегесе ым кага, янәсе, «башла».

— Политбюро кушуы буенча киңәшмәне ачык дип белдерәм. Бу киңәшмә беркадәр гадәти түгел, әлбәттә... Көн тәртибендә ике мәсьәлә: беренчесе — Үзәк Контроль комиссиясенең Солтангалиев эше турында докладь, икенчесе — XII съезд карарларын тормышка ашыру мәсьәләләре.

Киңәшмәдә катнашучылар хакында шуны хәбәр итә алам: Үзәк Комитет тарафыннан 60 иптәш чакырылган иде, әлегә шуларның 51 е килде. Җиде кеше килә алмый, аларның берничәсе башка иптәшләр белән алмаштырылды. Алты кеше — юлда. Хива вәкилен исәпкә алмаганда, милли республика һәм өлкәләрнең һәммәсеннән килделәр. Димәк, бу эшне башлый алабыз дип саныйм. Фикер һәм тәкъдимнәр булса, рәхим итегез.

Урыннан тавыш. Төп мәсьәлә ни өчен икенче көн тәртибенә калдырылды. Беренче мәсьәлә ул кадәр үк җитди түгел иң. Аларның урыннарын алмаштыруны үтенәм.

Каменев. Бу тәкъдим логик яктан табигый күренсә дә, уйлавымча, урынсыз. Без Политбюрода ул хакта киңәштек инде. Көн тәртибендәге беренче мәсьәлә ул кадәр үк гади түгел. Уйлап карагыз: иң күренекле иптәшләребезнең берсе, Милләтләр эше халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы партия сафларыннан чыгарылган. Һәм нәкъ менә милли мәсьәләгә мөнәсәбәте нигезендә чыгарылган. Бу гадәти күренешме?! Иң беренче нәүбәттә шушы тарихка игътибар итми китә алмыйбыз без.

Урыннан тавыш. Мин үз тәкъдимемне кире алам.

Сәетгалиев урыныннан чәчрәп сикереп тора. Гадәттәгедән күпкә кызган күренә. Иптәш Троцкий фикерләренә каршы чыгу мөмкин түгел, әлбәттә. Мин аның алдында баш иям. Әмма, ул кадәр үк күренекле иптәшкә санап, аның эшен беренче көн тәртибенә куеп, без ул адәмне артык күтәреп җибәрмибезме соң?! Аннан килеп монда Солтангалиевнең бик күп иярченнәре утыра. Без аларга иң элек икенче көн тәртибе буенча чын йөзләрен ачу өчен мөмкинлек тудырырга тиеш. Ә инде киңәшмәне Солтангалиевне үз урынына куюдан башласак, алар соңыннан дәшмәячәк, койрыкларын кысачаклар. Көн тәртибендәге мәсьәләләрне алыштырырга кирәк саныйм. Чөнки икенче мәсьәлә буенча докладчы иптәш Сталин үзе булуны да истән чыгарырга ярамый бит әле...

Каменев. Димәк, тегеләй уйлаучылар да бар, болай уйлаучылар да бар. — Күз чите белән Сталинга карап ала: «Нишлим?» диюе. Генераль секретарь баш кага — «дәвам ит» дигән сүзе. — Шулай итеп, беренче булып Солтангалиев мәсьәләсе көн тәртибендә кала. Үзәк Контроль Комиссиясе исеменнән сүз иптәш Куйбышевка бирелә.

Куйбышев. Иптәшләр... Мин вакыйгаларны хронологик тәртиптә китерүдән башлыйм докладымны. Шул вакыйгалар Солтангалиевне партиягә һәм Совет дәүләтенә каршы җинаятьтә гаепләргә нигез бирде.

Солтангалиевне шик астына алырга мәҗбүр иткән беренче вакыйга «Рөстәм» имзасы белән Персиягә җибәрелгән хатның ГПУга килеп керүе булды. Ул хат күренекле фарсы сәясәтчесе, коммунист Таҗи-Бахшыга адресланган. Россиядәге мөселман коммунистларының, төрек һәм фарсы коммунистлары белән берләшеп, Коминтерннан аерым бер оешмасын төзү тәкъдиме үткәрелә бу хатта. «Рөстәм» имзасын Солтангалиев үзенеке дип танырга мәҗбүр булды. Шундый ук хат төрек коммунисты Җәләлгә дә язылган.

Икенче фактны ГПУга бер башкорт иптәш җиткерде. Аның әйтүенчә, Солтангалиев җирле партия хезмәткәрләре һәм партиясезләрдән яшерен оешма төзү тәкъдиме белән хат җибәргән Башкортстанга. Хат үзе юкка чыгарылган. Әмма әлеге иптәш ул хатны күргән. Хат акгвардиячеләр телендә язылган һәм ният ителгән оешманың советлар дошманы Вәлидов рухында булуы, бәхәссез.

Бер кечкенә искәртү таләп ителә. Бу хакта иптәш Сталинга хәбәр ителгәч, ул Солтангалиевне кисәтергә кирәк таба. Әмма Солтангалиев иптәш Сталинның аталарча кайгыртып әйтелгән сүзләреннән тиешле нәтиҗә ясамый. Гафу үтенәсе, төзәләсе урынга, ул киресенчә, Казанга, Башкортстанга һәм Кырымга яңа яшерен хатлар җибәрә. Саграк эш итәргә киңәш бирә. Мисал өчен аның Башкортстанга җибәрелгән хаты очраклы рәвештә ГПУга килеп ирешә. Бу болай була:

Солтангалиев партиясез иптәш, Үзәк Мөселман диния нәзарәте әгъзасы булган, ниндидер, Кәшшафетдин Тәрҗеманов атлы кешегә сургыч белән ябыштырылган адрессыз хат тапшыра. Һәм алга таба, партиясез Космасов сөйләвенчә, түбәндәге хәлләр була: шимбә көн 31 март кичендә ул Сандуны мунчасына бара. Һәм шунда Уфа буенча элгәреге танышы дин әһеле Тәрҗеманов белән күрешә. Космасовтан теге сорый: «Уфага кайтучы ышанычлы кешең юкмы?» — ди. «Икенче апрельдә үзем юлга чыгам»,— ди Космасов. Дин әһеле аңарга үзенең үтенечен белдерә. Космасов ризалаша һәм Мәскәүдә тукталган хуҗасы Хәсәнов Закир адресын бирә. Беренче апрель кичендә өйгә кайтса, Космасовның өстәлендә ике хат ята. Берсе — Тәрҗемановның Уфага хатынына язган хаты. Икенчесе — адрессыз, сургычлы. Янәшәдә нәни генә кәгазь кисәге: «Бу хатны Халык мәгарифе комиссары иптәш Әдһәмовның кулына тапшырырга. Ә кәгазьне ертып ташла».

Кәгазьне Космасов иптәш ертып ташлаган, билгеле. 1923 елның 2 апрелендә Космасов Мәскәүдән Уфага юлга чыга. 5 апрельдә кайтып җитә. Юлда ул бизгәк белән авырып китә, шул сәбәпле кайтып җиткәч тә урынга егыла. Якшәмбе көнне 8 апрельдә аңарга танышы Закир Богданов иптәш килә. Космасов аңардан хатларны тапшыруын үтенә. Богданов хатларны ала. Әмма Кәшшаф Тәрҗемановтан икәнлекләрен белгәч, шикләнә кала. Һәм әйтелгән адресларына түгел, ГПУ органнарына тапшыра. Һәм Солтангалиевне фаш итүче төп документ нәкъ әнә шул адрессыз конверттан килеп чыга да инде. Хат яшерен тамгалар белән, ягъни шифрлы итеп язылган.

Менә ул хат. (Куйбышев гарәп алфавитында язылган дәфтәр битен болгый. Кыяфәте җитди һәм канәгать). Инде хәзер ГПУ тәрҗемәсендәге шул яшерен хатны сүзгә сүз укырга рөхсәт итегез (Укый):

*«Үзең генә укы, аннан яндыр. Сталин миңа түбәндәгеләрне хәбәр итте: янәсе, аңарга минем тарафтан Башкортстанның җаваплы хезмәткәрләренә язылган бер яшерен хатны биргәннәр. Ул хатта, Мәскәүдә Зәки Вәлиди рухындагы яшерен оешма яши, диелә икән. Сталин мине кулга алырга теләүчеләргә каршы чыкты. Артымнан өзлексез күзәтәләр. Ашыгыч рәвештә хәбәр ит, сиңа һәм иптәш Халиковка юлланган хатларым юк ителгәннәрме. Ул хат яисә аларның күчермәсе*

*ни рәвешле чит кулга эләгү ихтималын ачыкла. Хат үзе эләккәнме, әллә күчермәсеме — моны белү минем өчен әһәмиятле. Хат үзе юкка чыгарылган тәкъдирдә кичекмәстән телеграф ысулы белән Татарстан вәкиллегенә хәбәр ит. Юмахуҗинга. «Каршы түгелмен» дип. Сталинга мин, Халиковка бер хат язган идем, әмма анда әллә ни юк, дидем. Кем анда ул эш белән шөгыльләнә икән, ачыкла. Сак бул, сизгер һәм нык бул. Сезнең арттан да күзәтәләр булса кирәк. Сталин миңа ул хатның күчермәсен күрсәтергә вәгъдә итте. Һәм хушлашканда киләчәктә саграк эш итәргә киңәш итте. Болар хакында фәкать Морзабулатов белән Бикбауовка гына сөйли аласың.*

*Халиков эше түгелме икән болар?*

**Мирсәет.**

*P.S. Советлар съездыннан соң миндә Сәлимҗанов, Теләубирдин, Туалбаев һәм Солтанов, Мортазиннар булды. Алдагы өчесен Төхбәтуллин тәкъдим иткән иде. Бу кешеләргә ышанып буламы? Төркестанда, Бохарада басмачылык хәрәкәте көчәя бара. Язга таба тагы да оешканрак төстә һөҗүмгә күчәләр икән дигән хәбәрләр йөри. Шул сәбәпле милли мәсьәләдә Үзәк шактый ук чигенергә мәҗбүр. Зәки Вәлиди белән элемтә урнаштыр. Әмма үтә саклык кирәк — җанлы элемтә яисә шифр белән генә. Минем өчен борчылмагыз — ахыргача нык булырмын».*

Шушы хат һәм әлеге фактлар нигезендә Үзәк Контроль Комиссиясе 4 май көнне Солтангалиев эшен тикшерде, аның үз аңлатуларын тыңлады (Бусы — чираттагы ялган. Солтангалиевне чакырмыйлар, тыңламыйлар, барын да үзе югында хәл итеп, кулга гына алалар.— Автор) һәм түбәндәге резолюция кабул итте: «Солтангалиевне, партиягә һәм советларга каршы элемент буларак, партиядән чыгарырга. Партия һәм совет органнарындагы җаваплы эшләреннән төшерергә. Солтангалиев эшен, ачыклап бетерү өчен, ГПУ органнарына тапшырырга».

Политбюроның 10 майдагы утырышында әлеге резолюция махсус карар белән ныгытылды.

Солтангалиев хәзер сак астында. Ул башта үзенең кыек эшләреннән баш тартып килде. Әмма ГПУ органнары каршында ул үзенең байтак кына эшләрен инде танырга мәҗбүр булды. Шифрлы хатка килгәндә, ул аны кире кага алмады. Әмма энесе кулы белән язылды дип бара. Хатның өстәмә өлеше булган «П. С.»тан катгый төстә баш тарта. Вәлидов белән элемтәгә чыгу омтылышын, аны Советларга кайтару максатыннан иде, дип ышандырырга тырыша. Әмма бу безне һәм ГПУ органнарын беркатлыга санаудан бүтән түгел, әлбәттә...

Партиягә һәм Советларга каршы Солтангалиев туплаган оешманың булуы яисә шундый омтылышның булуы документлар тарафыннан расланa. Аның Башкортстан вәкилләреннән тыш элемтәләре дә мәгълүм. Мисал өчен, Кырым республикасының Юстиция халык комиссары Фирдәвес белән язышулары шул хакта сөйли. Төркестан һәм Татар республикасы белән дә бәйләнештә икәнлеге сер түгел. Партия әгъзалары белән беррәттән, аның партиясезләр белән дә элемтәдә булуы коточкыч күренеш. Ә инде мөселман дин әһелләренә хәерхаһ булуы, алар белән очрашуы һәм хәл белешүләре башка сыймаслык нәрсә.

Игътибар итегез әле, Солтангалиевнең ГПУга язган күрсәтмәләреннең берсендә мондый сүзләр бар: «Партия «житәкчеләре һәм кайбер Совет хезмәткәрләренең Көнчыгыш халыклары, республикалар һәм илләренә мөнәсәбәтле сәясәтен кабул итә алмаганга, мондый сәясәтне ялгыш дип санаганга, мин үземә фикердәшләр эзләдем»,— дип яза. Басым ясап әйтәм: моны кичәге коммунист, җаваплы партия һәм совет хезмәткәре яза...

...Халыкара капитал агентлары куенына сыенып Советларга каршы сугышучы контрреволюцион хәрәкәтнең атаманнарыннан берсе Зәки Вәлиди белән элемтә урнаштыруны максат иткән кешене нинди язмыш көтә ала? Бары тик революцион трибунал гына. Һәм аның белән сөйләшү теле дә бер генә — ГПУ теле генә була ала,— дип, кулын, кылыч белән кеше башын чапкандай, баш очында болгап алды Куйбышев...

Ярты сәгатькә сузылган докладтан соң Үзәк Контроль Комиссиясе тәкъдим иткән җиде пункттан торган резолюция проектын да Куйбышев үзе укый. Һәм резолюцияне укып бетергәч, иркен сулыш алып, канәгать төстә үзеннән өстәп куя: «Җинаятьчел рәвештә партияне саткан бу адәм безнең сафлардан читкә тибәрелде. Өстерәлеп йөрсен шунда. Аның исеме тирәсендә легендалар иҗат итмәсеннәр...»

Каменев. (Кем сүз сорый, сораулар юкмы, дип кызыксынып тормый. Алдында яткан, берничә көн элегүк хәстәрләп куелган чыгыш ясаучылар исемлегеннән беренче фамилияне укый. Күзлекләрен сөртә-сөртә, авырлык белән генә укый). Иптәш Рыскулов сүз сорый.

Рыскулов. Үзвакытында мин дә Милләтләр эше халык комиссариатында Коллегия әгъзасы булып торган идем. Әмма Солтангалиев белән сирәк күрештек, бергә эшләмәдек диярлек. (Бизмәнгә башың салынса, тел ни әйтмәс, дигәннәре шул була торгандыр. Мирсәетнең озак еллар аралашып эшләгән фикердәше, сердәше сөйли бу сүзләрне.— Автор).

...Мин татар хезмәткәрләренең Көнчыгыштагы фидакарь эшчәнлеген таныйм һәм кире какмыйм. Чөнки анда үзәк сәясәтен үткәрүчеләр, нигездә, татарлар. Шулай да әйтергә кирәк саныйм, Көнчыгышта, бигрәк тә Төркестанда алар, рус иптәшләр белән бергә-бергә таякны артыграк бөгеп ташладылар кебек. Бохара яисә Харәзмдә татарлар турында фикер сорасагыз, әйтерләр, халыкның фикере тискәре. Шуңа күрә теге яисә бу урынга татар кешесен мактый-мактый тәкъдим итә башласалар, күпчелек каршы төшә. Чөнки алар Көнчыгышны яхшы белми, алар Россия шартларында тәрбияләнгән...

Каменев. Иптәшләр, көн тәртибендәге мәсьәлә турында гына чыгыш ясавыгызны үтенәм.

Сәетгалиев (Үзе сикереп чыга, сүз биргәнне көтеп тормый). Мин сөйләргә җыенам көн тәртибе буенча. Кхм... Ишетүемчә, борын-борын заманнарда кемдер, тарихка керү өчен, бик кыйммәтле бер бинаны яндырган диләр. Солтангалиев та шундый ахмаклык эшләде, минемчә. Үз исемен мәңгеләштергән булып, ул иң кыйммәтле бинага — Совет хакимиятенә ут төртмәкче булды. Әмма бу аның гына буе җитә торган эш түгел. Шуңа күрә бүген Солтангалиевнең үзе турында түгел, ә солтангалиевчелек хакында сөйләшергә кирәк.

Иптәш Куйбышев үзенең докладында бу хәрәкәтне — солтангалиевчелекне тудырган көчләрнең берсе буларак, бөекдержавачыл шовинизм күренешен атады. Моңарга ачыклык кертеп узу кирәк. Кемгә, кайдан һәм ничек яный соң ул шовинизм?! Кемне куркыта, кемнең башына суга ул? Аз санлы милләтләрне кыерсыту, яшәп яткан җирләреннән куу яисә кысрыклау булса, әйтер идек, әнә ул — шовинизм дип. Ә андый күренешләр совет илендә була алмый. Инде кайбер житәкчеләрне эштән алу, урыннан төшерүгә андый бәя бирү урынсыз дип саныйм.

Үз сүзләреннән үзе илһамланып киткән Сәетгалиев очынып-очынып сүзен дәвам итте:

— Үземнең Татреспубликада эшләү тәҗрибәмнән бер мисал китерәм. 1920 һәм 1921 елларда да хуҗалыктан икмәк җыю планын 103 процентка үтәдек без. Моны, әлеге дә бәягы кайбер иптәшләр, татар авылын талау, Мәскәү куйган чын интернационалист вәкилләрнең яман эше дип аңлатырга тырыштылар. Ә югыйсә илнең икмәкле булып, татар авылларының ач калуында бөекдержавачыл шовинизмның һич катнашы юк иде. Бу бары тик пролетар интернационализм күренешенең матур бер чагылышы гына булды. Шуны да төрлечә буташтырырга омтылды солтангалиевчеләр. Татар крестьяны ачтан үлгәндә урыс мужигының ризыклы булуына бөекдержавачылык гаепле түгел иде бит. Ни өчен шулай килеп чыктымы. Чөнки татарның бар белгәне — умач, ә урыс авылы балык тотты, кәбестә ашады, яшелчә, гөмбә. Син умач кына ашыйсың дип, татарга арышны күбрәк калдырып булмый бит инде. Алай итсәк,

без вак буржуаз милләтчелек түбәнлегенә төшкән булыр идек... Шул эш өчен мине, Мәскәү куштанына санап, 24 сәгать эчендә Татреспубликадан сөрделәр. Әнә нинди явызлыкларга сәләтле ул солтангалиевчелек!.. Боларга бөекдержавачыл шовинизм гаепле түгел инде, табигый милләтчелек хикмәте бу. Гомумтөрек федерациясе кору уе белән саташкан пантюркистлар эше! Чит илгә качышкан эмигрантлар белән бәйләнгән панисламистлар эше бу! Әлбәттә, партия мондый агымнарга бүген үк чик куярга тиешле. Менә шул!

Чыгышын тәмамлауга ук ялт итеп, күрше бакчасына кергән кәҗә сыман, президиум өстәленә, Сталинга таба карап куйды. Генераль секретарьга ошаган иде аның чыгышы. Ул беренче булып зәгыйфь кулының уч төбенә өч бармагы белән чәп-чәп сугып куйды. Аны иң элек президиумдагылар, аннан бөтен зал күтәреп алды. Югарыдан ничек төшеп, үз урынына ничек барып утырганын да тоймады Сәетгалиев. Ул бәхетле иде, чиксез бәхетле... Ниһаять, Мирсәет Солтангалиевне сыртына салды бит әнә!

И б р а һ и м о в (Пенза төбәгеннән чыккан партия эшлеклесе. Әлеге очракта ул, вәкил буларак, Кыргызстаннан чакырылган). Башка милләтләр һәм аз санлы милләтләр дигәндә без ул исемлеккә татарларны кертергә тиешле түгел. Беренчедән, татарлар аз санлы түгел. Икенчедән, аларның күп меңләгән пролетариаты бар. Өченчедән, мәдәниятлары чагыштыргысыз югары һәм матди яктан да бай яшиләр. Шуңа күрә, Төркестанда рөхсәт ителгән дип, Татарстанда динне тыймау — ул җинаять. Һәм бу җинаятьнең башында Солтангалиев тора. Ул татар-башкорт дин башлыкларының Үзәктәге вәкиледәй саный иде үзен. Солтангалиевнең чын йөзен фаш итү өчен мин сезгә нибарысы бер документ, аның тарафыннан хупланган документны укып китәм. Тыңлагыз әле:

1. Ислам кануннарын һәммә яшьтәгеләр өчен дә укытуны рөхсәт итәргә. Теләүчеләргә һичнинди чикләүләр булдырмаска;

2. Дин мәктәпләре, мәдрәсә биналарын халыкка кайтарырга;

3. Эчке Россия һәм Себер диния нәзарәтенең, мөфтинең, казыйларның, муллаларның халык белән мөнәсәбәтен чикләмәскә, ә чикләүче декретларны урынсыз дип табарга;

4. Дин әһелләре һәм мәчетләрне салымнан азат итәргә;

5. Мөселманнарның мәдәни үсешендәге әһәмиятен истә тотып, Ислам диненә чикләүләр куймаска;

6. Муллаларга никахлашу, аерылу, мирас бүлү кебек эшләрдә хокук бирү;

7. Дин әһелләрен тулы хокуклы гражданнар һәм юридик хокуклы итеп тану;

8. Партия һәм Совет органнары тарафыннан дингә мөнәсәбәттә теләсә нинди кысрыклауны тыю;

9. Диния нәзарәтенә матбугат ирекe бирү;

10. Диния нәзарәтен юридик көчкә ия дип танырга.

Менә шул. Йә әйтегез, кай чорда вә нинди җәмгыятьтә яшибез без, җәмәгать?! Аңладыгызмы инде Солтангалиевнең кемлеген?

Ш ә м и г у л о в (Башкортстан исеменнән сөйли). Җәмәгать, мин, гомумән, бербөтен Рәсәй эчендә аерым-аерым вак республикалар төзүгә элек-электән каршы идем. Нишлисең, Үзәк Комитет Солтангалиев кебекләрнең сүзенә колак салды.

Тагы шуны искәртергә кирәк табам. Мин үзвакытында иптәш Сталинны Вәлидов хакында кисәткән идем. Әмма иптәш Сталин аның хакында аталарча кайгыртуында дәвам итте. Вәлидов аңлый торган кеше түгел иде, аңламады.

Нәтиҗәсен беләсез, нәтиҗәсе күз алдында — Зәки Вәлиди басмачылар сафына басып, Советларга каршы фронт ачты. Һәм мин бүген дә искәртергә кирәк саныйм, Солтангалиевнең дә Вәлидов юлыннан китүен теләмәсәк, без аның белән башыннан сыйпап сөйләшмәскә тиешбез. Үзен

иң югары җәзага тартырга кирәк дигән тәкъдим кертәм. Һәм иярченнәренә дә шул ук җәза. Шуны эшләмәсәк, үкенергә туры килмәгәе...

Аның Совет дошманы булуын тагы шундый факт раслый. Ул миңа без икәүдән-икәү генә утырганда үз шигырьләрен укып тинтерәтте. «Монысы Һиндстан шигыре рухында»,— ди. Икенчесен фарсы шагыйрьләренә ияреп язган. Өченчесен гарәп фәлсәфәсенә нигезләнеп. Тагы төрек шагыйрьләренә багышлап язылганнары да бар иде... Күрәсезме, уе гел читтә, теге тарафта... Менә ул кем!

Ж а н б а е в. Иң элек үзем белән таныштырырга рөхсәт итегез. Мин сез бик куркыныч итеп тасвирлаган Татарстан вәкиле, Җир эшләре комиссары. Солтангалиевне яхшы беләм һәм аның белән бергә эшләгән көннәремне сагынып искә алам, горурланам.

Миңа калса, безгә үз-үзебезне аклау өчен, бер-бер артлы трибунага чыгып Солтангалиевне сүгү, гомумән, Татарстан республикасын һәм татар халкын буярга омтылудан тыелырга вакыт. Без, Ибраһимов иптәш әйткәнчә, партиялелегебезне милли чыгышка бәйләп кенә ачыкларга керешсәк, бик тирәнгә кереп китәрбез; австриялеләр үрнәгенә барып чыкмагаек.

Арабыздан бер иптәшебез, һәм басым ясап әйтәм, иң яхшы иптәшебез, хаталанган икән, без аңарга ул хатасын күрсәтик. Нигә аны дөньядагы һәммә җинаятьләрдә гаепләргә? Һәм тәкъдим ителгән резолюциядәге трибунал рухында да мин ихтыяҗ күрмим.

Инде бер иптәшнең «табигый милләтчелек» хакындагы фикеренә мөнәсәбәтле ике сүз. Әлегә бернинди теориядә һәм хәтта биологиядә мондый төшенчә юк иде кебек. Һәм аны уйлап чыгаруда да ихтыяҗ күрмим.

Х а л и к о в (Башкортстан Совнаркомы рәисе). Солтангалиев иптәшне Вәлидов белән бәйләнеше, Диния нәзарәтенә булган дустанә мөнәсәбәте һәм Төркия кебек илләрдән дус-иш эзләгәне өчен генә дә гафу итеп булмый дип саныйм. Монда һичнинди икеләнү була алмый, иптәшләр. Ул — җинаятьче...

Ф и р д ә в е с (Кырым республикасыннан, Юстиция халык комиссары). Иптәшләр, мин мондый югары трибунадан беренче мәртәбә чыгыш ясыйм... Солтангалиевне Вәлидов белән бәйләнеш эзләүдә гаеплисез. Мин монда гаепкә бөгәр нәрсә күрмим. Чөнки алар Вәлидов белән мәктәп елларыннан ук танышлар. Совет хөкүмәте өчен кирәк булганда Солтангалиев аның белән бер генә мәртәбә элемтәгә кереп беренче генә мәртәбә килешүе түгел. Бу омтылышы өчен аны хупларга гына кирәктер әле... Солтангалиев иптәшнең хатларыннан гаеп кенә эзләмик. Ул бөтен җаны белән хезмәт иясләрен бәхетле итәргә омтылып яши, эзләнә, уйлана торган иптәшебез безнең. Таеп егылган кешене типкәләмик, без аңа кул бирик, тартып торгызыйк. Ул үзе безне болай авыр хәлдә калдырмаган булыр иде...

(Беренче утырыш төнге сәгать 11 тулып килгәндә генә тәмамлана).

Киеренке фикер алышулар, бәхәсләр әле тагын өч көн дәвам итә. Дистәләгән һәм күп дистәләгән җитәкчеләр чыгыш ясый. Кабат-кабат та сүз алучылар була.

Әдәби камиллеккә зәгыйфьлек китерү бәрабәренә булса да, тагы берничә чыгыштан аерым фикерләрне документаль төгәллек белән теркәп узмау мөмкин түгел.

Ф р у н з е. Мин Солтангалиев эшен, һәм, монда искәртелгәнчә, солтангалиевчелекне, Башкортстан һәм Татреспубликаның эчке тормышына мөнәсәбәтле мәсьәлә дип кенә карый алмыйм. Мондый күренешләр Грузиядә дә булды. Һәм аның кайбер төсмерләре бүген мин эшли торган Украинада да бар. Һәм бу күренешне тудырган сәбәп, танырга телибезме без аны, юкмы, ул — бөекдержавачылык шовинизмы. Милләтләрнең тигезсезлеге һичкайчан эзсез узмый һәм уза алмас.

Шуңа күрә, Солтангалиев һәм аның иптәшләренең хаталары никадәр генә житди булмасын, бер-бер нәрсәне ачык итеп һәм күзгә туры карап танырга мәжбүр: алар безнең үз кешеләребез! Ялгышлары булса да, коммунистлар. Һәм ул ялгышлар яңа тормыш төзү юлында, эзләнүләр юлында жибәрелгән безнең уртак ялгышыбыз.

Солтангалиев иптәшнең шәхси эшен болай күпертү белән мин килешмим.

Орджоникидзе. Мин Төркестанда эшләгән кеше. Һәм Рыскулов иптәшнең нинди группага кергәнлеген беләм. Шуңа сорау бирәм: нигә соң Рыскулов Солтангалиевтән ике хат алган була торып, әлегәчә аларның икесен дә кесәсендә яшереп тота? Юкка түгелдер бу...

Солтангалиевнең милләтчелеген бөекдержавачылык белән бәйләп кенә карау мәсьәләне гадиләштерү ул. Без бер нәрсәне, мөселман массаларына тәэсир итүдә бик мәкерле һәм көчле көндәшебез — кемалчылык Төркиясе барлыгын онытырга тиеш түгел. Безнең илдә кемалчы төрекләрнең агентлары үтеп кермәгән бер генә мөселман почмагы да юк, моны сез беләсезме икән?!. Кемалчылар безнең төп дошманыбыз, алар һәр жирдә безгә каршы актив коткы алып баралар. Бер мисал китерәм: Азәрбайжанда Совет хөкүмәте урнаштырылуның беренче еллыгын бәйрәм иткәндә мөселман укытучылар семинариясе шәкертләренең күкрәкләрендә тоташтан Мостафа Кемал сурәте төшерелгән значоклар була. Берсе дә, ялгышып кына булса да, Нәриманов иптәш сурәтен такмаган иң. Солтангалиев әнә шундый төрекчеләр, панисламистлар, пантюркистлар идеологиясен алга сөрүче интеллигент ул.

Мохтаров (Татарстан Совнаркомы рәисе). Солтангалиев, чынлап та, татарлар арасында иң популяр шәхес. Чөнки ул революционер һәм большевик буларак эштә яулады бу дәрәжәне. Юкка гына үзәктә дә аны һәрчак иң жаваплы урыннарга күчереп йөретмиләрдер. Республика оешканда — Милләтләр эше халык комиссариатында, жир мәсьәләсе үзәккә куелгач, ул — Федераль жир комитеты рәисе. Эш урынына кагылсаң, гүя бөтен ил аның ишеге төбендә диярсең. Ул да кеше иң. Ничек түзә икән, дип гажәпләнә идем мин. Ул урында һәркемнең күңелен күрү кыен, шуңа үпкәләүчеләр дә булуы ихтимал. Әмма без бүген жир мәсьәләсен тикшермибез, бутамыйк мәсьәләләрне.

Урыннан кемдер тавыш бирә:

— Безнең хакта борчылмагыз.

Мохтаров. Мин сезнең хакта борчылмыйм. Без төрле төбәкләрдә яшибез.

Сталин. Әмма юлыгыз бер.

Мохтаров. Әйе, юлыбыз бер, һәммәбез дә теге дөньяга таба юл тотабыз, иптәш Сталин... һәм сүземне йомгаклап әйтәсем килә, Татарстанда басмачылык хәрәкәте кайгысы түгел. Солтангалиев тә үзенә кирәккәнгә түгел, ил кайгысын үзәккә алып мөрәжәгать иткән булса кирәк Зәки Вәлидигә. Үтенеп сорыйм, инде басмачылык хакында сөйләшкәндә генә булса да тынычта калдырып торыгыз без татарларны?!

Троцкий (Политбюро әгъзаларыннан аның М. Солтангалиевкә аеруча дустанә мөнәсәбәттә торуы һәркемгә мәгълүм. Шуңа күрә зур игътибар белән көтелә бу чыгыш. «Троцкий ни сөйләр? Якларга жөрьәт итәрме икән?» — ди-ди көтәләр бу чыгышны. Әмма бу вакытта Троцкийга Солтангалиев кирәк түгел иде шул инде!) Солтангалиев элек-электән партиядә үзенә бер идея хәрәкәтен тәшкил итә иде. Милли мәсьәләгә мөнәсәбәттәге бу үзгәлеге үсеш кичергән саен катгыйлана һәм көчәя барды. Һәм менә, ниһаять, ул аны турыдан-туры жәмгыятебезгә хыянәткә китерде. Бу эш өчен 1919—20 елларда без аны, гражданнар сугышы кануннары буенча, аткан булыр идек, мөгаен.

Татарларның элгәредән килгән милли изелүе, авыр хәле һәммәбезгә мәгълүм. Шуңа күрә дә Солтангалиевнең бөекдержавачыл шовинизмга иң беренчеләрдән булып каршы күтәрелүендә гажәпләнер эш юк. Бөек-

державачылыкка каршы тору яхшы нәрсә, әмма ул, һичшиксез, икенче чиккә — милләтчелеккә китереп җиткерә кешене. Солтангалиев әнә шул упкын читендә тора бүген. Әмма, Фирдәвес иптәш дөрес әйтә, Солтангалиев үзенә фикердәш санап хат алышкан һәр кешене гаепләү дөрес булмас иде. Үз милләтең турында кайгырту җинаять түгел. Шулай бит, иптәш Сталин (Президиум өстәленә таба борылып, ирония белән кеткелдәп көлеп ала).

Юкса, безгә икенче тарафтан шәмигулловчылык, сәетгалиевчелек чире китереп бәрүе ихтимал. Милли мәсьәләләргә мөнәсәбәттә аларча фикер йөртсәк, милли төбәкләрдәге халык массалары безнең арттан иярмәс. Дошман ягына күчәр алар. Иптәш Шәмигуллов, иптәш Сәетгалиев, шуны исегезгә төшерәм, кайвакытта артык яхшы дуслар дошманнан күбрәк яманлык эшләп ташлый. Мануильскийның чыгышы да украин акценты белән сөйләнелгән «шәмигуловщина»дан ерак китмәде. Үз колакларыма ышана алмый тыңладым, чак кына үз башымдагы бөдрәләрне йолкып ташламаганмын. Хәйләкәр мәгърифәтче Сәетгалиев иптәшкә дә кагыла бу. Милли хисләргә арка куеп юлыгызны ары дәвам итсәгез, сезне дә упкын көтә, Сәетгалиев иптәш. Милли мәсьәләдә һәммәбезгә гаять итагатьле, сак булу кирәк...

Ниһаять, әлегәчә һәр чыгышны олы дикъкать белән тыңлап, нидер язып-сызгалап утырган Сталин кымшанып алды. Торырга җыена, сүз ала. Шуны чамалап алган рәислек итүче Каменев торып баскан җиреннән кире урынына иңде. Шулкадәр югалды ки, «иптәш Сталинга сүз бирелә» дип әйтергә дә кыюлык тапмады үзендә.

С т а л и н (залда утыручыларны берәм-берәм барлап чыкты гүя). Мин монда чыгыш ясаган кайбер иптәшләрнең аерым фикерләренә игътибар итү теләге белән тордым.

Әйе, Солтангалиев иптәшнең беренче конспиратив хаты хакында иң элек ишетүче мин идем. Ул хат ни өчендер әлегәчә телен тешләп утыручы, әмма башкалардан элек һәм инде күптән торып сөйләргә тиешле булган Әдһәмов иптәшкә иде булса кирәк. Әйе, иптәшләрнең миңа булган шелтәсе урынлы. Мин Солтангалиев иптәшне чамадан тыш яклап килдем. Әйе, мин чынлап аны соңгы чиккәчә якладым һәм алга таба да бу минем вазыйфам дип беләм. Әмма билгеле бер чиккә кадәр генә якладым мин аны. Инде Солтангалиев тарафыннан билгеле бер чик узылгач, мин аңардан йөз чөердем. Беренче конспиратив хаты ук Солтангалиевнең партия белән араны өзгәнлеген күрсәтте. Аның сүз сөреше акгвардиячеләрнекеннән кайтыш түгел. Үзәк Комитет әгъзалары хакында хат аша фикер җиткерүне башкача бәяләү мөмкинме?! Һәм мин аны дусларча кисәттем. Политбюрода очраштык. Ул анда Татреспублика үтенечләрен Наркомзем җитәкчесе буларак кабул иттерергә газапланды. Татарга җир җитми инде ул...

Мин кисәттем. Ә ул мине алдады. Нәкъ бер атнадан соң Әдһәмов иптәшкә басмачылар җитәкчесе Вәлидов белән элемтә урнаштыруын үтенеп икенче кат яшерен хат җибәргән. Шул хакта мәгълүм булгач та Солтангалиев минем өчен партиядән читтә, советлардан читтә торган шәхескә әверелде.

Ә бит мин аны якын иттем үзвакытында, аңарга ышандым. Кайбер «сул» иптәшләр аны якын итүемне әле 19 ел башларында ук охшатмыйча, кисәткәннәр иде үземне. Мин Солтангалиевне партия өчен сакладым. Марксист булыр дип сакладым. Аның кебек интеллигент фикерле һәм грамоталы кешеләр Көнчыгыш республикаларда санаулы гына, гомумән, бармак белән генә санарлык — ничек итеп аның кадерен белмәскә, сакламаска мөмкин иде... Әмма һәр нәрсәнең, түземлекнең дә чиге була. Ул чик җитте. Коммунистлар арасыннан басмачылар лагерена үзе атлап чыкты ул чикне. Менә ни өчен төрек илчесе аның өчен безнең Үзәк Комитетка караганда әһәмиятлерәк булып киткән икән...

Әйе, үз вакытында Вәлидовны да шулай ук саклаган идем мин. Һәм шул сәбәпле Шәмигуллов иптәштән шелтә дә ишетергә туры килде. Төзәлер дип якладым аны да. Ахыр чиктә Шәмигуллов хаклы булып чыкты. Вәлидов төзәлмәде, хыянәт итте. Шулай да партия, аның басмачылар тарафына качуын бер елга кичектереп, отты дип уйлыйм мин. Ул чакта, ягъни 1918 елда, Вәлидовны юкка чыгарган булсак, бүген безнең арада Мортазин, Әдһәмов, Халиков кебек күп кенә башкорт иптәшләр булмас иде, бәлки.

Урыннан Халиков тавышы. Халиков калган булыр иде.

Сталин. Бәлки чынлап та Халиков китмәгән булыр иде.

Мин Рыскулов иптәшне тыңладым. Ул эчкерсез була алмады үзенең чыгышында, аның чыгышы авыр тәэсир ясады миңа. Мин аңардан эчкерсезлек көткән идем. Югыйсә, бит аның өендә дә Солтангалиев язган ике хат саклануы турында безгә яхшы мәгълүм. Күрсәтмәде, димәк, ул да Солтангалиев белән идея бәйләнешендә булган.

Җанбаев иптәш тә дипломатик һәм эчкерсез чыгыш ясады. Ә бит Җанбаевның башка татар иптәшләр белән бергәләп, Үзәк Комитетка һәм шул исәптән миңа да Солтангалиевне кичекмәстән азат итүне таләп итеп мөрәҗәгать иткәнлеге факт. Татар иптәшләрне мин бер дигән практиклар дип беләм, әмма идея ягыннан тотнаклылык җитми аларга.

Фирдәвес иптәшнең чыгышы баштан-ахырынача дипломатиядән гыйбарәт. Бер сорау туды миндә: кем кем белән җитәкчелек иткән? Солтангалиев Фирдәвес өстеннәнме? Әлле Фирдәвес Солтангалиев өстеннәнме? Мин бу сорауны әлегә ачык калдырам.

Минемчә, Ходжанов иптәш яхшы сөйләде. Икрамов иптәшнеке дә ярыйсы иде. Әмма бу иптәшләрнең бүгенге Төркестан белән патша Төркестаны арасында һичнинди аерма юк, исеме үзгәрсә дә, җисеме элеккечә калды, дигән фикерләре белән килешә алмыйм. Сез сөйләгән сүзләр дөрес булса, димәк, без түгел, басмачылар хаклы булып чыга. Төркестан әле дә колония хәлендә икән, димәк, Солтангалиевне дә без юкка гаеплибез, ул хаклы икән бит?! Әлбәттә, Ходжанов белән Икрамов иптәшләр уйлап җиткермичәрәк әйттеләр ул фикерне.

Инде, ниһаять, Солтангалиев язмышы турында. Берәүләр монда үзен хәзер үк атарга кирәк диеп әйттеләр. Икенчеләр хөкемгә тартырга кирәк диде. Мин үзем, Куйбышев иптәш кебек үк, аны азат итү ягында. Партиядә, урын, әлбәттә, аңарга булмаячак...

Урыннан тавыш. Ә ул нишләр соң?

Сталин. Совет эшенә яисә башка бер-бер җиргә ярап куюы бар.

Урыннан тавыш. Ул партияне саткан кеше.

Сталин. Борчылмагыз. Аның кеше буларак эше беткән. Политик берәмлек буларак ул юк. Тагы ни җитми?

Урыннан тавыш. Ул безгә чит элемент хәзер.

Сталин. Килешәм. Ул ят, чит кеше хәзер безгә. Әмма хезмәт итсен.

Урыннан тавыш. Азат итмәскә кирәк!

Сталин. Мин үз фикеремне әйттем. Үзегез карагыз...

Сталин үз урынына утыра. Игътибар итегез: ул Солтангалиевне яклый. Аны азат итәргә кирәк, дигән фикерне авыз тутырып әйтүче ул гына булды. Дуслары да җөрьәт итмәде ич, Троцкий да хәтта. Ә залда ыгы-зыгы. Канәгатьсезлек тавышлары: «Генераль секретарь артык кешелекле безнең...», «Ул Солтангалиевне иске дусты буларак кызгана...» — дигән сүзләр. Ә икенче тарафтан «Атарга кирәк үзен, атарга» — дигән тавышлар. «Үзен генә түгел, һәммә иярченнәрен, яклаучыларын атарга кирәк...» Бер-берләренә бармак төртә-төртә бәхәсләшәләр...

Сталин канәгать. Нинди матур тамаша оештырдылар бит әнә. Һичкем моның Куйбышев һәм аның тарафыннан һәр детале алдан ук уй-

ланылган, рольләр алдан ук бүленгән тамаша икәнләгән уена да китереп карамый... Татарстан вәкилләренең, әнә ич, башлары түбәнгә иелгән, сулыш алмый утыралар. Әдһәмов, Җанбаев һәм Фирдәвесләр кайда? Постылармы — постылар! Милләт дип, республика дип, сүз кузгатачак кеше булмаячак моннан ары... һәм тагы да әһәмиятлерәге, Солтангалиев ягына борылып та карарга теләүче булмас. Ә инде, кем дә булса кыюлык күрсәтә икән, андыйлар белән башка урында һәм башка телдә булыр аңлашу...

Залдагы ыгы-зыгыны олы канәгатьлек хисе белән күзәтеп утырган Сталин белән Куйбышевның, очраклы рәвештә генә, карашлары очрашып куйды шул мәлне. Күз дә кысышмадылар, баш та какмадылар бер-берсенә, үзара көлемсерәүләрен дә сизү мөмкин булмагандыр. Әмма аңлаштылар: «Милли мәсьәлә хәл ителде. Милли дәүләтчелек турында сүз булмаячак бүтән. Дистә һәм күп дистә еллар дәвамына чәчәк ату, гармония һәм интернациональ дуслык хакында гына булыр сөйләшүләр...»

Берничә көннән соң, политик эшчәнлеген дәвам итмәү турындагы имзасын алып, Мирсәет Солтангалиевне ireккә чыгаралар. Бакчаларда алма агачлары ап-ак чәчәккә төренеп утырган 19 июнь иртәсе була бу.



Флера Гыйззәтуллина

# Ирек юлы

ПОЭМА

I

Җиргә сызылып калган һәр юлымнан
Имин кайттым, дисәм, хак булмас:
Без җир белән бергә яраландык,
Язмыш вулканнары атылгач.
Яраларны бәйләп тормыйча да,
Дөрес, һәрчак алга йөгердек.
Ләкин, никтер, ал таңнарга түгел,
Кояш баешына күмелдек.
Үзәк өзгеч кискен ят җилләрдән
Яшьлек гүзәллеген йолкытып,
Тапшырылдык «якты киләчәк»кә
Кулга көрәк, кәйлә, лом тотып.
Сугыш елы платформасыннан
И-и-и бушаттык җиргә чуер таш!..
Чуерланды җаннар — чыдамлыгын
Чуерташлар белән юдырткач.
— Менә нинди татар кызлары!..— дип,
И-и-и күмделәр безне мактауга.
Язып үттек лом очлары белән
Шул мактаулы сүзне ак тауга.
Таудай өметләрне ак юл итеп
Офыкларга суздык аннары...
Илгә ачыграк күренсен, дип,
Безнең көчнең җанда калганы.
Агаруга дәшкән бар өметләр
Кичерелгәч керсез күңелдән —
Безнең хакка үскән ак тауларның
Кара коеласын кем белгән?!.
Һәм кем белгән шушы ил эчендә
Безнең үз илебез булмавын,
Һәм ломнарның чуер ташта түгел,
Безнең күкрәкләрдә доңлавын?
Нигә безне язмыш яшәтмәде

---

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА — *шагыйрә, Татарстан Җөмһүриятенең атказанган мәдәният эшлеклесе, «Чишмә юлы», «Сәлам хаты», «Акчарлагым — асыл кошым» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Тамырыбыз иңгән җирлектә?—
Күкрәкләрне кара канга мандык,
Башкайларны «Себер сөрдек» тә.
Үлем-китем әллә аз булдымы
«Сөрген»дәге татар халкында?—
Тар гүрләре кара янып калды
Тәре урманнары артында.
Әҗәлләргә тотып бирсәк тә без
Нурлы йөзне, моңлы йөрәкне—
Белмәгәнбез, үлгәч, баш өстенә
Ярым ай куярга кирәкне.
Җан чыкканда — ясин чыкмаганбыз,
Читенсенеп җирле халыктан...—
Диктатура шулай киләчәккә
Безнең әҗәл аша калыккан.
Колбиләүче камчы селтәмәгәч
Юртып килеп җитез атларда,—
Уйламаганбыз да үзебезне
«Диктат колы!» — диеп атарга.
Айга бер кат эштән баш калкытып,
Йөргән чаклар булды иректә—
Киселмичә калган манаралар
Үрелгәннәр иде биеккә...
Киселгәннәр безнең манаралар,
Беркем йолып кала алмаган.
«Шәп мөселман» булып саналганбыз
Ераклаша барып Алладан.
Аңга килеп, тиеш хакыбызны
Сорап тел тибрәтсәк бераздан—
Ачлык яки шып-шыр ялангачлык
Буып алды тынсыз бугаздан.
Күрәләтә буды безне чорлар,
Чәчәк чагын сайлап гомернең...
Хәл калмагач, ризык эзләп беркөн
Чиркәвенә кердем Себернең.
Курка-курка гына барып кердем
Халык агымына тагылып.
Ләкин уйламадым, чыгармын дип,
Чиксез гөнаһларга манылып.
Шәм яктысы белән яктыртылгач
Яшәү өметемнең чаткысы,—
Бардыр, дидем, изге бу тарафта
Күреп алыр хәерхак кеше.
Әй, монда да үксеп үкерәләр
Булмаганны санап, булганны...
Бу дөньяның бөтен гөнаһлысы
Бер чиркәүгә кереп тулганмы?
Монда керү — миңа да бит гөнаһ!—
Тора-тора вөҗдан төшенә...—
Яннан үткән-сүткән һәрбер кяфер
Тәре төртеп китә түшемә.
Татлы пирог, күмәч, коймак исе
Ярып килеп керә борынга:
Йөрим чиркәү буйлап, уйлый-уйлый
Бер туйганчы ашау турында.
Каршымы мин шундый хөрмәт хакын,
Ризык хакын эшләп түләргә?..—
Аңлаттылар:

— Ризык татыганчы
Син тиешсең тәре үбәргә —
Аллабызга безнең табынырга,
Тезләнергә мәрмәр идәнгә...—
Шулчак тамагыма таш утырды,
Каннар чымырдады чигәмдә.
Тораташтай үлеп, катып калды
Ризыкка дип сузган кулларым —
Шушы килеш тә бит мин аларның
Моңлы догаларын тыңладым.
Гөнаһымның зурын искәрткәнгә
Рәхмәт әйттем аллаларына:
«Шөкер!.. шөкер!» — диеп сөенгәндә
Ризыкларын алмаганыма.
Шуңадыр да әйләнмәде башым,
Әйләнергә тиеш булып та...
Һәм бернинди алыш-бирешем юк,
Өметемне өзгән бу йортта.
Хәерчелек һәм мескенлек — гөнаһ! —
Ярый миңа шуны аңлагач...
Чиркәү юлы, кара тәре юлы
Бәхет күперемә ялгамас!

2

Күрәчәкнең күперләре озын,
Озынлыгы алда гомернең дә...
Киттем ары, догаларым укып,—
Тәреләрен юлдан себердем дә.
Йөгерә кергән, жиңел кергән жирнең
Авыр табылса да чыгар жае,
Табан астымдагы Себер кары:
— Яшә! Яшә! — диеп шыгырдады.
Шыгыр-шыгыр атлап, чиркәү яклап
Кергәч кенә урман эчләренә —
Шул чиркәүдә минем кул сумкамның
Онытылганы төште исләремә.
Җем-җем килеп торган кар өстенә
Утырып бер еладым,— түзалмадым.—
Кире борылырга уйласам да,
Тәре белән тулды күз алларым.
«Мескенлегем миннән үч аламы?..» —
Акылымның жуйдым аныклыгын:
Тикшерсәләр, алып күрсәтергә
Юк паспортым... туу таныклыгым.
Ә тикшерү монда адым саен:
Бары урман — яшеренер төшем!
Тумышымнан килгән байлыгым бар:
Саф күңелем , тере шигъри хисем.
Башка килгән бәхетсезлек белән
Әнә шул хис жанда богалаша.
Чит-ят кешеләрдән кача-поса
Тимер юлга кайтам урман аша.
Урман — әкият дөньясыдай серле,
Чумган кышның ап-ак тылсымына.
Ялгызлыктан, чарасызлыктанмы,
Каеннарга таба кул сузыла.

Каен әйтә кебек:
— И сеңелкәй,
Язмышкаең авыр, тамаша! — дип.—
Син бит табигатьнең үз баласы,
Күз карасы идең ләбаса! — дип.—
Асылыңа кабат кайта алсаң,
Үз хәстәрең үзең күрер идең:
Бала болан булып кар астыннан
Мүк җиләге чемчеп йөрер идең.
Сары умырзая җыяр идең,
Җаның сагышларга сабышканда.
Күңел аланында яз каршылап,
Унике ай бергә кавышканда.
Исән-имин кайтсам туган җиргә,
Тапсам бирәр борын төртер урын,
Моңсу күңелләргә өмет салып
Мин дә көйләр идем каен җырын.
Ә хәзергә мин тимер юл салам,
Күперләрнең салам яңаларын,—
Шулар аша бәлки илләренә
Кайтарырлар адәм балаларын.
Ә хәзергә бер гөнаһсыз башны
Мең газапта язмыш эзәрлекли:
Баш кадерсез, җан тамырсыз булгач,
Сүзләр үтми ятка, сүзләр үтми.
Бүгендәме кая киткәнемне,
Сәгатемне санап торганнармы?—
Әнә, юлдан ике атлы килә,
Нинди тозак икән — корганнары?
Икесе дә хәрби, килештереп
Атланганнар тулпар атларына...
Узар сукмаклары еракмы дип,
Мин каранып куйдым як-ягыма.
Теткәләнгән киез итегемә,
Иске тун җиңемә куйдым карап...
Килеп җитеп берсе алданрак:
«Качкан идең — тотылдыңмы, карак?!»
Атлы вәхшиләрдән бастырылып
Бара-бара манма тиргә төштем.
...Алар — җирле! Гаделлектән өстен!..
Сүзем бер тиенгә тормый торган
Мин — килмешәк!.. Бер җәяүле мескен!
Ничә тапкыр егылсам да арып,
Аттан алар бер дә төшмәделәр.
Минем мескенлектән кызык табып,
Атларына кушылып кешнәделәр.
Төрмә ишегеннән төртеп керткәч
Тентеделәр шәрә... чишендереп,
Кем икәнлекләрен төшендереп,
Чишендерүләрнең көчен белеп...
— Син кем белән чиркәү бастың? — дигәч,
Әллә аяк өсли аңым җуйдым...
Эзәрлекче язган протоколга:
«Үзем генә!» — диеп кулым куйдым.
Эшем, адресымны бутамадым,
Алдашсам да, кулым каушамады:
Түләтсәләр — гомеремә җитәр
«Урланылган» алтын акчалары.

...Тик, аларның сабырлыгы житми:
Бүген кирәк «түләү», хәзер кирәк.
— Кая күмгән булсаң,— шуннан казы! —
Менә сиңа, диләр, әзер көрәк!..
Урман көртен актарталар миннән,
Актарыла җаным: каерыла...
Илсез кызны, мине — үксез кызны
Җәлләгәндер монсу каен гына.
Төрмә кирпечләре җәлләгәндер:
«Тоткын булдың, бала, тиктомалга!..» —
Чыдар көч тапмаган үкенечтән
Елап чәчемне мин йолкыганда,
Шыксыз камерада мин үземә
Асылынып элмәк тапмаганда
Җәлләгәндер сакчы, коридордан
Адымнарын санап атлаганда.
Әйе, сакчы тәрәземне чиртте:
— Китер савытыңны, сөт саламын!..
Төрмә сакчысына мәҗбүриме
Сөт эчкәнен күрү чит баланың?
Миңа сөтне ул шешәдән салды,—
Алып килгән ахры үз өеннән...
Кыяфәте йончу!
Әллә ул да
Алҗыганмы тормыш изүеннән?
Минем сыман бәхет эзләп китеп,
Адашканмы читтә үз баласы?
Авыр хезмәтеннән җаны бизеп,
Сулкылдыймы ике күз алмасы?
...Бер үк ритм, бер үк адым белән
Көне-төне шулай атлап кара!
Тормышның бар гаделсезлекләрен,
Кадерсезлекләрен саклап кара!
...Сөтен салгач сакчы савытыма,
Чеметеп кенә кара ипи турый:
— Нинди милләт?.. Кайсы якта синең
Туган илең, балам? — диеп сорый.
Буш камера миннән түзем сорый,
Йокымсырый авырайган гәүдәм.
Кемнәр монда мин йокласын өчен
Таш идәнгә бер кат кирпеч җәйгән?
Кискән агач кебек аудым шунда,
«Ятагыма» туным түшәдем дә:
Үз-үземне кызгандыру яки
Кызгану юк иде исәбемдә.
Йоклап уянуга, бу хәлемдә
Җавап тапмас идем нишләремә...
Кояш кебек ир баласын тотып
Апам килеп керде төшләремә.
Сугыш башлануга ул авылдан
Киткән иде урман кисүенә...
Өстендә бит бары җәйге күлмәк! —
Ничек түзде икән өшүенә?
Бу ир бала каян килгән икән
Аңа, кияүләргә чыкмас борын?
— Ал! — ди апам,— миннән бүләк сиңа! —
Җырлап үстер аңа бәхет җырын...
— Шушы безнең бәхет күперебез!..

Син дә безнең белән яшә, апам?! —
Апам алып килгән бу тормышны,
Мин яратам икән, ах, яратам!
Үз төшемне үзем төштә юрыйм:
«Ир балалар алып килә — Ирек!»
Төшләребез безнең юш килсенгә
Хәер итеп кемгәниләр бирик?!
Тик бирмәбез аны ятимлеккә,
Аерсалар... кая кусалар да,
Нинди нахак тәкъдир таксалар да,
Кеше жаны сыймый кысаларга.
...Баскан килеш идән уртасына
Юравымны тыңлап тора апам.
Төш аралаш ләкин сакчының мин,
Авыр аяк тавышын ишетеп ятам.
Һәм кычкырам:
— Бар, кит. Бар, кит, апам!
Төшләремә кереп озакладың.
Шул арада кемдер шалдыр-шолдыр
Ачып керде ишек йозакларын.
«Үзем кебек тоткын мәллә?» — дисәм,
Ишек тыштан бикләнмәде кабат:
Хәрби кием, текә, шәп кыяфәт
Югартыннан тора миңа карап.
Матур төштән, каушау, аптыраудан
Түгел идем берни сөйләр хәлдә...
«Кунагым»ны түргә чакырмадым,
Янәшәмә үзе чүгәләгән:
— Тузан арасында ник ауныйсың? —
Шундый буламыни ил кызлары? —
Ул шулай дип, тезгә кагылып үтте,
Чагылып үтте погон йолдызлары.
— Зинһар, миңа кагылмагыз! — дигәч,
Тезләремә бүтән карамады.
Шундый игътибарлы, «илаһи зат»
Әшәкелек өчен яраламы?
Вәхшилектән күпме изелсәм дә,
Ышанасым килә өметемә:
Әйбәтлектә ул охшаган сыман
Минем хыялдагы егетемә.
Сөйләп китсәм матур төшләремне,
Тыңлап торыр кебек таңга калып.
«Илаһи зат» янә телгә килде:
«Дөрес» уйларымны аңлап алып:
— Якын күреп әйткән сүзләремне,
Тыныч кына тыңлап утыр, туган!..—
Шушы фикер белән килешә алсак,
Коткарырмын судтан, утыртудан.
Юл төзүдә озак чыдамассың...
Син торырсың бездә бала карап...
Үзе бала таба бер бер артлы,
Өйдә тормый хатын — ала канат!...
— Ярар, ярар!.. Рәхмәт... — Әйбәт итеп
Мин юармын керне, идәнне дә...
Нәрсә диим, мин бит аңым белән
Балалыктан чыгып килəм генә.
Уйламыйм да кинәт кочып алып,
Тотыныр дип дер-дер калтырарга.

Бар көчемне җыеп кычкырганда
Өметләндем ишек шалтырауга.
Утка куйган таба кебек кызды,
Мин утырган кирпеч токымнары.
Юк, бу юлы кулларымны каерып
Ул көчләргә мине тотынмады.
Иртәгесе төндә шул ук төшләр,
Шул ук кичерешләр кабатланды.
Бирешмәгән өчен соңыннан ул
Яңакларым чалт-чалт яңаклады...
Соңгы җавап тан соң җикерделәр:
— Әрәм тамак, бар, юлыңны кара!! —
Вәхшиләргә бу да җан азыгы,
Бик урынлы, тантаналы чара.
Кара йөрәк өчен бу да җиңү:
Эчкә милли мәкер туплаганда...
Нишлим — китми? Китәм «дүрт кыйбла»ма,
Авыр сулап кат-кат уфтанам да.
Китәм якындагы стансага,
Бәхетлегә күпер, юл салырга.
Иртәнге уй, кичкесеннән аек:
«Нигә үз-үзеңә кул салырга?»
...Кабат эш турында уйлый-уйлый
Үрләр менеп, менә үрләр төшәм.
Төштә туган ирек дөньям исән:
Саф күңелемнән шигъри сүзгә күчәм.
Урмандагы агач саен туктап
Килсәм дә мин башым ия-ия,
Моңсу каен җырым күккә чөя:
— Син намуслы татар кызы! — дия.
Урман узгач керер күперләргә,
Шушы каенга мин чит булмаммы?
Салкыннардан түгел, каенкаем
Минем сагышлардан сыкыланды.
Сыкранды, авырлыгын белеп
Җан көчемә тарткан тормыш йөгем...
...Гадел хезмәт халкы арасында
Мин дә халкым кебек тырыш идем.
Калсалар да бәхет түрәләре
Шәхесемә юкка чыгу юрап,
Кайттым бит мин Татарстаныма
Шушы авыр язмышымны зурлап.
Гомер эшләп алган эш хакымнан
Калмаса да тиен акчаларым,
Тумышымнан иманыма иңгән
Камиллегем белән какшамадым.
Очрап хәлем сорашучыларга:
— Хәлем авыр! — диеп сөйләмәдем.
Берәүнең дә шат җырына кушылып
Кара кайгы көе көйләмәдем.
Әмма җанга сеңгән кайгыларны
Табып алсам язу әмәлләрен —
Өзгәләнә кинәт шигъри юлым,
Ломга әверелә каләмнәрем.
Хыялымда үскән ак тауларым
Биек кыяларга әверелә...
Ак бәхетләр эзләп чыккан юлым
Хәерлегә булсын! Хәерлегә!!!

3

Еллар упкыны — еланга,
Кыялар — чыдамнарга.
«Елан!» — ди, халык үзенең
Бәхетен буганнарга.
«Елан!» — дип әйтү аздыр ул,
Илеңнән куган затка.—
Авылны корытты алар,
Без читтә йөргән чакта.
Халыкка кылган хыянәт
Онтылсын да ди, әйдә,—
Ни булыр — күккә иңмәгәч
Тәңребез көткән тәүбә?
Вакыт ич жирдә еланны
Еланнан аерырга!
Юк «елан елгасы» һаман
Ашыкмый саегырга! —
Үзләре жирдән шуышса,
Күзләре багар күктән...—
Безне кол итеп күрергә
Күнеккән алар күптән! —
Кулыңа гомерлек ломың,
Көрәгең, кәйләң биргән...
Таулы, ак ташлы язмышны
Кыяга әйләндергән.
Нужасын ташка язганда
Арыган, талган жаннын.
Мин дә бит кулда лом түгел,
Каләм, дип, алданганмын...
Язуым, язмышым белән
Чыгам дип чын юлларга...
Чумганмын халкымны йоткан
Еланлы чоңгылларга.
Шуңадыр күрмичә чорның
Аен да, кояшын да
Чайкалып утыра кыям
Еланнар оясында.
Сорарсыз: «Бу чайкалышка
Нинди моң яшерелгән?..» —
Иленә илдәш керттенме
Еланнар нәселеннән?..
Эшсез, чарасыз калдымы
Ломнан бушаган кулың?»..

...Миемә капкан еланнар —
Иңемдә толым-толым!..
Мыж килә, агыла өскә
Аклары, каралары...—
Ничәсе инде, ничәсе
Куеным балалады.
Кайнады елан уклары
Канымда, жилегемдә
Хәлемне белми ирем дә,
Улым да, киленем дә ...
Күренми, килми берсе дә
Йөзләгән танышларның ...—
Бер генә тыңлатыр идем

Ысылдау тавышларын!
Бер генә каратыр идем
Биектән түбәннәргә:
«Илемнең, туган җиремнең
Хәле шәп!» — дигәннәргә.
Язмышны читләп узалмас
Заманның менгән үре.
...Чагылып елаучыларның
Мин түгел бердәнбере!
Кешенең елан җанлысы
Беркемне җәлләмәгән:
Тормыш төбендә буылып
Гасырлар бәргәләнгән.

Ак, кара, соры еланнар.
Хәтергә сеңеп кала...
Җитәргә барып ак көнгә
Ерак булса да ара...
«Ак елан» калды тик минем
Изгелек ирегемдә.
Кайгымнан өркеп ул Ирек
Китмәсен кире генә!



**Айдар Хәлим**

# ӨЧ АЯКЛЫ АТ

**ПОВЕСТЬ**

*Рәшит абый Хисамов истәлегенә*

Ычкындык, болай булгач!

«Мбамбо-бимбо. Сама-рана-сама».
Нәкъ кирәк мизгелендә генә телдә ярала һәм бары тик үзе генә төшенгән бу сәер ымлыклар өермәсе: «Кузгал. Сәгатең сукты»,— дигәнне аңлата иде.

Нәзек чаукалыктан каерып кораштырылган, сылап агартылган, бер үк вакытта әйбер-сәйбер, кирәк-ярак саклана торган кәҗәнкә ихтыяҗын үтәгән өйалдының боздай салкын җир идәненә аяк очлары белән генә басып, малай тәрәзә аша урамга капланды — әйе, Зөлхиҗә әбисе күздән югалган иде. Тормышның мең табы, мең тимгеле белән чуарланган һәм чит-читләрен пәрәвез оясы челтәрләп беткән бу кул яссуы гына пычрак пыяла өлгесе аның өчен хәзер дөньяда иң таза, иң садә, ягъни чиксезлекнең үзенә әйдәүче иң якты юл башы иде...

Ниһаять!

«Мбамбо-бимбо. Сама-рана-сама». «Ашыгырга кирәк».

Малай яшен тизлеге белән кәҗәнкә почмагына атылды, аннары, шикләнмәсеннәр, дип, оек-чабаталарын тартып чыгарды. Аяклар күз ачып йомганчы кып итеп калды. Менә ул өсте киҗеле ашъяулык белән капланган агач чиләккә уң кулын тыкты һәм кинәт, утка пешкәндәй, кире тартып та алды: «Урлашам түгелме?!» Соңгы өч көн эчендә инде ничәнче тапкыр көйдереп куя иде аның күкрәгән шушы куркыныч тойгы. Әмма алга куелган максат вөҗданның мондый газапларыннан югары, күпкә югары иде шул. Малай күзләрен чытырдатып йомды һәм чиләккә сул кулын чумдырды, гүяки аның өчен уң кул кадерлерәк, гүяки сул кул уңы өчен дә, аның үзе өчен дә җавап бирми — чиләк төбеннән түм-түгәрәк кара ипине кармалап алды да, тышка атылды. Болдыр аша гына сикереп, ике-өч омтылыш белән абзар лапасына иярgә атлангандай атланды һәм кышкылыкка печән кертә торган өн аша сәндерә караңгылыгына чумды.

Мондагы караңгыда Кәбир, песи сыман, ныграк күрә иде: монда, ни дисәң дә, үзенә генә билгеле булган сихри даирә, монда, әгәр тагын да

Айдар ХӘЛИМ (1942) — *шагыйрь, прозаик, җәмәгать эшлеклесе, татар, башкорт һәм рус телләрендә чыккан дистәдән артык китап авторы. Хәзерге көндә Чаллыда яши.*

ачыграк итеп әйткәндә, өч көн буе җыештырган хәзинәсе саклана. Малай, ат сыман, бер генә тынга колакларын шомрайтты: барысы да тәртиптә, бугай.

Ул икеләтә игътибар белән тынлыкка йотылды. Бер... Ике... Өч... Ниһаять, астан, абзарның аргы почмагындагы араннан, Бамбукның шактый тигез тын алышын, вакыт-вакыт борын тишекләре белән фырылдап, коерык кыллары белән һаваны кыеп, чебен-кигәвен кууын һәм иң мөһиме — авызлык тимерен агач аратаъларга тидергәләп, үлән уртлавын ап-ачык абайлагач, күңеленә җылы йөгерде.

Кыек почмагыннан санаганда өченче бәпкә тапкырыннан, былтыргыдан калдык печән астыннан, капчык сөйрәп чыгарды. Җәһәт кенә элмәген ычкындырды. Капчыктан төен өстенә төен булып ялганган иске дилбегә, чуклап үрелгән кыска каеш чыбыркы, камчы килеп чыкты. Алар гынамы? Зөлхиҗә әбисенең карбазына төшеп, нәкъ утыз ике данә бәрәңге чәлдергән иде ул. Шунда ук тоз, бер кап шырпы, чүпрәккә төрелгән пәке һәм үзе генә белгән тагын бер төргәк бар иде.

Тагын да аныклык өчен әйтсәк, бәрәңгеләр кырык сигез иде. Подаука кадәр зур чиләк. Өймәләмә. Авырга китәр, дип уйлады Кәбир. Дүрт көнгә сигезәр бәрәңгедән куйды: атына дүрт, үзенә дүрт. Калган уналты бәрәңгене алырга базмады. Чынлап та авырга китәчәк шул. Их, көче җитсә, чамасы булса, бәрәңгене Кәбир әллә күпме төягән булыр иде дә бит! Инәсен ничек кенәләр куандырган булыр иде! Югыйсә, Зөлхиҗә әбиләрендә бу байлык җитәрлек. Монда, Димтамакта, ачлык аларның Бүләгендәге кебек барысын да кырып себермәгән. Ипекәйләре бар, бәрәңгесен инде сөйләп тә торасы юк. Әмма җәяүлегә янчык та авыр, дигәндәй, малай моннан да артыгын күтәрә алмам, кадерле азыкны ярты юлда ташлап калдырырга туры килмәгәе, дип борчылды.

Кәбир ипине капчыкка тыкты. Кечкентәй генә ике бәрәңгене капчык почмакларына шудырып, бауны тарттырып бәйләде дә капчык авызын кысып чалды, йокне аркасына киде һәм бауларның ике канатын күкрәк турысына китереп төйнәде. Иңнәрен киереп, баскан урынында сикергәләп карады, йөреп карады. Болай уңайлы гына кебек. Әлегә арканы бимазалап, төртеп торган нәмәстәкәе юк кебек.

Камчыга охшаган кыска чыбыркының сап бавы бөҗрасын уң кулына кидерде һәм, сул кулы белән дилбегәне элэктереп, аска, түбәннән югарыга ургылган яктылык ташкыны аша сөндерә авызына — җиргә сикерде.

Көтелмәгән дөпелдәүдән оркегән Бамбукның күзләре аларып китте һәм ул бер якка янтаеп куйды. Аннан, малайны күздән кичереп, «Ә-ә, син мени әле, дус кеше?» — дигәндәй тынычланды һәм борынын янә яшел үләнгә төртте.

— Мин бу, Бамбук, мин...

Кәбир гомер буе күрмәгәндәй бер сагыну белән атның муенына килеп сарылды. Башы белән ялбыр ялларына сыенып, кечкенә куллары белән аның муеныннан, күкрәкләреннән сыйпады. Бу иркәләүдә ялвару күбрәк иде шикелле. Гүя бер җан, бер тән булып атка сеңешкән Кәбирнең куллары, онытылып, аска шуды һәм менә алар, ниһаять, күкрәк битләвендәге каты ярылар белән капланып, кутырланып килгән ярага кагылгач, бөтен тәненә салкын тир бәреп чыкты. Хыял доньясыннан кырыс чынбарлыкка кайтып, малай шундук айныды. Карашы Бамбукның сөян кабыгы белән кысып бәйләнгән алгы уң аягына төште. Абзардагы башка бихисап хуш исләр барысы да юкка чыкты — танауга авыр дару исе килеп бәрелде. «Нигә һаман мыштырдыйсың?!»

Кәбир аран баганасына бәйләнгән тезгенне чишә башлады. Юк, юк, ул һич кенә дә Бамбукның аксак икәнлеген исенә төшерергә теләмәгән иде. Киресенчә, малай үзенә бу хәлне онытырга боерык биргән иде. Кулларын әйтер идең! Әйе, ничәме-ничә якты көнне карайткан, ничәмә-ничә караңгы төнне кайгысы белән яктырткан, ничәмә-ничә авылны,

кешене, барысыннан да бигрәк инәсен, Кәбирнең үзен, туган-тумачаларын хафаларга салган, дусның дошман, дошманның дус белән буталу хәленә җиткергән шушы яралы ат аягына игътибар итәрмен дип һич кенә дә уйламаган иде. Ул гынамы, үзенә бирелгән акыл һәм хис белән бер хәерсез сәгатьтә шырт итеп өзелгән бердәнбер буынның аяк кадәр аяк, ат кадәр атны, кешеләр кадәр кешеләрне буынсызландыра, тарката, аера алмавында үзен ышандырырга тырыша, шуның рас чыгачагына инанып, күңелен күтәрә иде. Инәсе түккән күз яшьләре хакына булса да төзәлергә тиеш иде бит инде ул бичара буын, билләһи газыйм!..

Кәбирнең уйларын сизенгәндәй, байтал утлыктан үлән чемчүеннән туктады һәм аңа таба борылды. Аранның бик тә саран яктысында атның күзләре күксел-зәңгәр ут булып яна. Алар гүя: «Йомшарма, Кәбир,» — диләр. Хәлиткеч омтылыш белән малай Бамбукны авызлыкլады, тезгенне муенына чалып, ирләрчә бәйләде. Дилбегә очының тимер каптырмасын йөгән бокрасына зеңк итеп каптырды һәм Бамбукны тышка, яктылыкка әйдәде:

— Кузгалдык, малкай...

Әмма малкай кузгалырга ашыкмады. Ул, бөтен авырлыгын арт аякларына салып, башын югары чөйде, дилбегә кылдай тартылды — кояшта каз канаты кебек кипкән, җилләгән, үз авырлыгын үзе дә сизмәгән малай Бамбукның күкрәгенә килеп чәпәлде. Аны абзардан үз ихтыяры белән алып чыгып булмаячагы көн кебек ачык иде. Дилбегәне бушата төшеп, Кәбир атның янбашына чыбыркысы белән берне тамызып та алды. Сау-сәламәт чагында чыбык һәм чыбыркы ише касәфәтне күзенә дә чалындырмаган, ул гына дисезме, бия булуына карамастан, авыл сабантуйларында үзе тудырган балалары — чабышкы айгыр-алаша белән ярышларда да еш кына җиңеп чыккан Бамбук хәзер инде кайдадыр читтә, туган ягыннан еракта бәлагә очрап, ниндидер чебенле алачыкта михнәтле көннәр һәм төннәр кичергән карт бия Бамбук, әле шушы мизгелдә үзенең якташы-авылдашы булган чәкүшкәдәй генә малай актыгының үзен шулай чыбыркы кайнары белән кимсетүенә гарьләнеп булса кирәк, баскан урыныннан җан ачуы белән өч аяклап алга ыргыды һәм, үзе артыннан малайны да өстерәп, яшел бәпкә үләне баскан ишек алдыннан ачык җил капка аша җан-фәрманга урамга бәреп чыкты.

Төшкелектән соң яңадан ялан хезмәтенә таралган авыл урамында адәм әсәрен дә күрмәссең. Авылның аргы очындагы ерак чишмәгә суга киткән Зөлхиҗә әбисе кайтып килмиме, дип, Кәбир артына борылып карады. Юк, күзгә чалынмый иде көянтәле кеше. Бик һәйбәт. Тик менә июнь томрасында оеган этләр генә, тояк тавышыннан уянып, бимазалый башлады малайны: капка асларыннан тавышсыз-тынсыз гына чыгалар да, бөтен авылга дау куптарып, күңелләре булганчы озата баралар.

Ниһаять, этләрнең дә тамагы тыгылды. Менә авылның очына да чыгып киләләр. Алда, сул кулда, тимерчелек һәм тавык фермасы биналары. Әгәр боларны да үтсәк, инде чынлап та кайтыр юлга чыгабыз, дип уйлап алды Кәбир. Көтмәгәндә генә нәкъ әнә шул ике арадан эт көтүе ябырылды. Кәбирнең тонган колагы ачылып китте. Эт кенә түгел иде болар. Муса бабасы әйтмешли, җәһәннәм сандугачлары. Тавышларның колакка ачыктан-ачык аерымлануына караганда, бу өер тоташ бер гаиләдән тора иде, күрәсең — анда маэмайларның бабалары да, ата-инәләре дә, балалары да, хәтта оныклары да бар иде...

Кәбир артына борылды. Өернең алдыннан тешләрен ыржайтып, өрә-өрә, башмак кадәр бурзай аның эзенә үк басып килә, ләбаса! Балтырдан ук амалап ала дигәндә генә Кәбир аңа чыбыркысы белән селтәнде:

— Пш-шол!

Ләкин соң иде инде. Барысы да яшен тизлегендә булды: эт аның үкчә очасыннан тешләп алды. Сеңергә кайнар без тыккандай итте. Һәммәсе дә буталды. Юл читенә сары ука булып сибелеп, үлән чирткән каз бәпкәләре, юлның нәкъ бугазына чыгып җим эзләгән һәм җан-фәрман чабып барган Бамбуктан өркеп, читкә пырхылдаган тавыклар, ферма читәненә басып, көпә-көндез, бер дә мохтаҗсыз тамак ярган әтәчләр... Әрнүне оныттырып, аякта бушаганлык сизелде. Бурзай киндерәне өзгән, чабата, менә төшеп калам, менә төшеп калам, дип өлтери калган иде. Ләкин бу коллыктан котылудан куанган малай һич сер бирмәде. «Бара алганчы барыр. Чабата да булдымы байлык!»

Юлның Усылы елгасына борылган тәңгәлендә Кәбир соңгы тапкыр авылга борылып карады. Әбисе күзгә чалынмады. Болай да артык борчылучан, болай да артык чәүчәләк, юкка-барга көяләнүчән әбисенең әлегә булса да белми торуы яхшырак. «Авылдан чыкканчы гына түз, малкаем. Аннан дүрт ягыбыз — кыйбла». Яралы аягын җиргә тидерер-тидермәс кенә чатанлап, дөресрәге, өч аягында ыргыган Бамбук һич тә туктарга уйламый. Елганы шәйләгәч, Бамбук тагын да кызулаткандай тоелды. Сусаган булса кирәк, дип уйлап алды Кәбир. Юк, ялгышкан ул. Җил тегерменедәй күкрәк сулышы белән гүелдәп, барлык көченә килгән ат, шул ук куәт, шул ук омтылыш белән малайны да өстерәп, кичүгә ыргыды һәм су чирканчыгыннан ләззәтле пошкырып, ниндидер кеше аңламас ыңгырашу авазлары, сагыну катыш аһ-зар аһәңнәре иҗат итеп, аргы ярга барып та чыкты. Су тәңкәләре өермәсендә калган Кәбир, кичүдән кем ярдәме белән шулай җиңел үтә алдык икән, дип үзе дә аптырады.

Малай тагын артына борылып карады. Аны хәзер Зөлхиҗә әбисе түгел, Соры Бүре үзе куа чыккан төсле тоела. «Бүре барыбер корбанының башына җитә, улым,— дигән иде Муса бабасы, ул аксак байтал белән юлга чыгарга рөхсәт сорагач.

— Бугазлаган малының канын эчә алмаган икән, димәк, Соры Бүре малны барыбер эзәрлекләячәк. Тозәлсен малкай! Үзең дә ит кундыр бераз. Бу хакта әбиеңә чыгара күрмә, йокысын югалтыр!..»

Малай моңа һич кенә дә ышанмый. Кайдан һәм ничек кенәләр эзләп тапсын инде аны Соры Бүре? Картлар алар куркыту өчен арттырып сөйләргә яраталар инде...

Нинди рәхәтлек, нинди җиңеллек!

Алда — таулар, чиксез офык, артта — дала һәм әрем исе! Димтамак читлегендә берничә көн ятып, җиләс һавага чыккан һәм моңа кадәр ул юньле-рәтле игътибар да итмәгән әрем исенең бу кадәр җанга кадерле һәм ләззәтле икәнлеген гомерендә беренче тапкыр тойгандай булды. Әнә, аскы яклап, бөдрә таллар, карт өянкеләр һәм шомырт түйралыклары арасыннан бөгәлләр ясап, Усылы елгасы үз дулкыннарын вак чуерташлар өстеннән кайдадыр Ырынбур далаларына тәгәрәтә-тәгәрәтә күздән югала бара. Озакламый, уң ягына пөке белән уелгандай тигез таулар тезмәсен култыклап, Кәбирне туган авылы Бүләк аша агып, бу якларга килеп җиткән Сабыр елгасы каршылаячак. Кошлар моңы, чикерткәләр чекердәве кайнап торган бу хәтфә үзәнлектән илле чакрымлап юл үтеп, Сабыр Усылыга килеп кушылдым дигәндә генә, сабырлыгын югалтып, кинәт кенә уңга борыла һәм Артыш таулары артындагы Димгә барып коя. Гүя, бу ике елга озакламый далага әйләнеп тигезләнәчәк соңгы тауны бүлешә алмый үпкәләшкәннәр дә, шулай бер-берсенә арка белән борылган килеш, мәңге ут күрше булып тыныч кына яшәп яталар... Иңнәренә шул ук ефәк таллыклар, колмаклыклар чормаган Сабыр килеп чыккан тәңгәлдә юл икегә аерыла. Дөресрәге, Бамбук белән Кәбир титаклаган зур таш юл район үзәге Кыргызга китә, ә тар гына, меңләгән ат һәм кеше табаны белән тапталып, көзгене хәтерләткән юл, кара тасма булып олысыннан аерыла да, туп-туры көнбатышка, Кәбирләр авылына юнәлә...

Байталның бу юлдан кайтканы юк. Килгәне генә бар. Таныр, чамалар микән? Әгәр танып, туган якка үзе борылса, малай бер хәвефсез кайтып җитәчәкләрен юрап куйган иде. Көне буе барлык тереклекне эссе табада аяусыз кыздырган кояш баш түбәсеннән күпкә түбәнәйгән һәм офыкка чумарга әзерләнгән сыман. Әмма аның мунча ташында кызуы байтак иде әле. «Күз бәйләнгәнче Кәрешкә барып җитәргә һәм анда кунып та чыгарга». Илле чакрымлык юлны ул дүрт көндә үтәргә дип бүлгәләп куйган иде. Бамбукның ялда туплаган мае исәбенә /чирле булса да, атның совхозда үткәргән көннәрен ял дип уйлый иде Кәбир/ беренче көнне, ягъни төштән соң, унике, икенче көнне унсигез, өченче көнне унике, дүртенче көнне сигез чакрым үтеп, авылларына кайтып керергә тиешләр. Кәрешкә — нәкъ унике чакрым. Мондый тизлек белән барсалар, бәлки Тушкырга да җитәрләр әле!

Кәбир җиң очы белән тирен сөртеп алды. Беренче тир. Карашы байталның янбашына төште. Анда аксыл-сары тоз тимгелләре сытылып чыга башлаган түгелме? Йөрәгә жу итеп куйды. «Яндырып үтермим тагын». Әмма Бамбукның тизлеген киметми алга баруыннан күңел күтәренке иде...

... Монда килгән чакта, Кәрешне чыгып, яңадан Сабыр үзәнлегенә төшкәч, туктап, арбаларына яшел печән чабып салганнар иде алар. Коелып бармасын, дип, инәсе үлән учмаларын эчкә тыккалаштырды, чит-читләрен чыпта белән бәйләштерде дә, өстенә бишмәт салып: «Сузылып ят, улым, арыгансыңдыр»,— диде. Даңгордык арбада гел утырып килеп, буыннары утыракланган мәлләрдә җиргә сикереп төшеп, арттан йөгергәләгән Кәбир, аруын арымаса да, инәсенең тәкъдименә каршы килмәде — башын барган уңайга куеп, печәнгә сузылып ятты һәм келтертәп кенә йөгерткән җайга бер-бер артлы ачылган манзараларны күзәтеп бара башлады. Күзен йомса, кирегә, артка барган кебекләр. Ачса, иң әүвәле Бамбукның сул як ботындагы төзәлеп килә торган яра күзгә ташлана. Гүя, ниндидер албасты шул төштәге сум итне: «Кая әле, тәмле микән?» — дип чеметеп алган. Авыл халкының сөйләве буенча, имеш, Бамбукның сугышта алган ярасы эзе бу. Бәлки, дөрестер дә. Совхозга юлга чыгар алдыннан ат билгәргә дип баргач, ат караучы Сәми бабай үзе үк әйтмәдемини? «Мәтри, малай, Бамбукны яхшылап караң! Ул безнең бердәнбер пашпортлы атыбыз!» Шулай, атларга да пашпорт бирәләр микәнни? Ә кешеләргә бирмиләр. Әнә, Гадел абыйсын былтыр Сталинабад ягына бәхет эзләргә чыгып киткәндә пашпорт бирмичә күпме интектерделәр! Кыргыз юлына тузан төшермәде. Тәүдә бригадир Бөкебаш Галләм урак өсте бетсен, көзге чәчү бетсен, урман эше бетсен, дип интектерде, аннары персидәтель Зәйнетдин абзый спрафкы бирми йөдәтте, аннан яздан ук әле чәчелмәгән-чабылмаган игенне таларга килгән упалнамуч җәфалады абыйсын, аннан учаскавай милициясе, аннан пашпорт өстәле... Әйтеп бетерерлекме? Бамбукка килгәндә, аның пашпортын карар әле Кәбир авылга кире кайткач. Тик кемдә саклана икән ул? Сәми бабасындамы, Бөкебаш Галләмдәме, әллә кәнсәләрдәме? Тирә-юньне күзәтеп, үз алдына уйланып барган уңайга йокыга киткәнен сизми дә калган ул. Бер мәлне, һаман да шул арба келтердәвеннән уянып, күзләрен ачса — йә, хода! — Кояш! Аның бу кадәр зур кояшны күргәне юк иде. Колач җитмәслек алтын табак булып күкне һәм җирне тоташтырган ул. Гүя җир йөзендә бу кояштан башка бер нәрсә дә юк: урманнар һәм таулар аның эчендә, хәтта Бамбук та шул кояш эченнән юрта. Дугадагы боҗра да кояш эчендә зеңгелди. Күзнең явын алган бу алтын табак эри һәм аннан тетелгән ялкын яулыклары җиргә, инәсенең чәчләренә коела... Ә якынлыгын әйт, якынлыгын! Рәис абыйсының ХТЗ тракторы сыман үкереп, өскә менеп килә бу кояш. Малай алтын табакны тотып карамакчы булып кулларын сузды. Юк, тоттырмый иде бу могҗиза! Кызык, әнисе күрә микән бу

тамашаны? Күрсә, нигә эндәшми? Малай арбаның ал рәшәткәсенә аякларын терәп утырган инәсеннән сорап куйды:
— Бу якта кояш нигә алай зур, инәй?
Инәсе, күрәсең, бөтенләй игътибар итмәгән булган. Шуңа күрә ул бу гадәттән тыш хәлне бер дә исе китмичә аңлаткандай тоелды:
— Бу инде безнең кояш түгел, улым. Дала кояшы бу, Ырымбур кояшы... Монда сызгырсаң, әчесе Домбау, Шарлыкларга кадәр ишетеләчәк. Сизәсеңме, монда һавада да икенче тәм — җитлегеп килгән арыш тәме?
Кәбир арбага басты, танавын киерә биреп, иснәде, ләкин һавадан һич кенә дә «җитлегеп килгән арыш исен» тота алмады.
Кояш чынлап та аптыраткан иде малайны. Бәй, Ырынбур даласының үз кояшы бар микәнни? Арышлы, икмәкле кояш? Ә безнең кояшның бәрәңгесе дә юкмы? Аларга бит мәктәптә бөтен җир йөзен бер генә кояш җылыта дип өйрәтәләр. Менә күрше авыл Кәртәлегә бишенче класска баргач, бу хакта сорар әле ул укытучылардан. Хәер, ул бишенчене быел ук тәмамлаган булырга тиеш иде. Өстенә киеме булмагач, дүртенчедә ике ел утырды. Кышын бер пинжәктә мәктәбенә йөгереп барды, йөгереп кайтты. Малайның бу мизгелдә Зөлхиҗә әбиләренә кунакка барулары хәтергә төшкәч, ни кадәре куанганын күрсәгез иде! Унике яше өстендә булып, аның бит әле туган авылыннан читкә чыканы юк. Ә монда — илле чакрымга! Җитмәсә — кунакка! Бәрәңге көткәнгә — бәлеш! Җитмәсә, үз атың белән. Җитмәсә, атаклы, пашпортлы Бамбук белән. Авылда аны еш кына «Туры бия» дип кенә җибәрәләр. «Бурлы бия» дип тә атыйлар. Охшамый бу исемнәр Кәбиргә. Бамбукка җитә буламы? Үзе матур, үзе серле. Ә нәрсә ул Бамбук? Кем тапкан, кем кушкан? «Колхозда тырышып эшләгәнеңне искә алып кына бирәбез сиңа ат,— дигән инәсенә персидәтель Зәйнетдин абзый.— Ат белән кунакка йөрер заманмы? Печән өсте, урак җитеп килә. Ә биз сиңа атның да ниндиен тапшырабыз — первай режимда, савнаркум паюгы ашаганын. Башкалары белән барып җитә алмаячаксың син, ярты юлда күтәртәчәкләр...»
Сәми бабасы да, Зәйнетдин абзыйсы да дөрес әйткән. Җилдереп кенә ята Бамбук. Дилбегә очы күрсәтүгә дә адымын ешайта малкаең. Чакырып хат язуы өчен Зөлхиҗә әбисенә рәхмәт. Инәсенең бер туган апасы ул. Башкортстан белән Ырынбур чигендә урнашкан совхозда яшиләр. Бай яшиләр. Әнә бит ничегрәк кенә язган хатны әбисе! Кичен, эштән кайткач, болдырга төшкән ай яктысында укыды аны инәсе. Безнеңчә язылган булса, Кәбир аны шатырдатып үзе дә укып чыккан булыр иде. Юк, гарәп хәрефләре белән чуарланган иде кәгазь. Аптырады Кәбир. Хәреф дигәнең таяк тек таяк, чалгы тек чалгы инде, әмма укыла! Ярты гына бит кәгазьдә күпме кадерле, серле сүз, мөһим хәбәр! «Дөньянықы дөньялыкта калмасын иде кем, бик тә сирәк күрешәмез»,— дип язган иде әбисе.— Без барып чыга алмыйбыз, сез дә килә алмыйсыз. Мәгълүм улуынча, җизнәң һаман да шул трахтырында эшли, ялан-җирләр безнең ифрат та зур, унбишәр чакырымга сузыла. Атналап ятып эшлиләр. Мөмкин улса, сеңелем, язгы кыр эшләре бетеп, көн җәйгә сарыккач, Кәбир улымны да утыртып /Әйе, Кәбир улымны да дип, атап әйткән!/, безләргә килеп чыксаңыз, күрешер һәм эч серләрен бушатыр идекемез. Белүемезчә, туган якта тормышның бер дә рәте-чираты юк икән. Бәрәңге һәм игеннәр былтыр да уңмаган икән. Халык ачлыктан җәфалана дигән хәбәрләр йөри. Безнеке ходайга шөкер, кара булса да, ашар икмәкемез, саварга сыерымыз бар, бәрәңгене, кишер-чөгендерне әйтеп тә торасы юк. Килгән хәлдә бер-ике капчык бәрәңге, берәр пот он, бераз атланмай алып китәр идеңез...»
Менә кешеләр ничек кенә чирттерә! Бер-ике капчык бәрәңге, берәр пот он, атланмай...
Күпме яңа җир-сулар, авыллар, кешеләр күрде Кәбир бу сәяхәттә!

Капка төпләре йә шомырт, йә өянкеле, салам түбәле, өйләренең тәрәзә төпләре кына гөлләре белән ялкынланып утырган, үзләре исә Сабыр елгасы буйлап сузылган татар, йорт аралары да яланнары кебек иркен, өйләре еш кына ихатасыз, кыексыз, урыны-урыны белән бөтенләй бакчасыз башкорт, кыйшайган читәнле, вак тәрәзәле чуваш, бакчаларында Кәбирнең туган авылында күзгә-башка да күренмәгән кыяр-кәбестә үстергән, йә сирень, йә сәрби куаклары арасыннан зәңгәрләнеп күренгән кахул авыллары аша үттеләр. Дуңгыз дигән малны Кәбир үз гомерендә беренче тапкыр кахул авылы Колосовкада күрде. Балалары белән баткакта мыркылдаган дуңгызларны ком белән ышкып чистартылган жиз самавырларга охшатты ул...

... Бамбук артыннан тотам да калмый йөгергән малайның күз кабагын нәрсәдер чеметтереп алды. Ат тоягы астыннан очкан ком-таш кәтрәсе булды, ахрысы. Ул тагын тирен сөртте. Кайдан килә бу кадәр тир?! Кырыкмыш тайлар муенына тагыла торган кыңгыраулар тавышы ишетелгәндәй булды. Малай сагайды. Юк ла, тоелган гынадыр. Бары алсу шәфәкъ кенә тау кырлачларына һәм агач башларына эленеп ялкынлана, түбәндә, аның белән янәшәдә, бар дөнья куе шәмәхә төскә кереп дулкынлана, кичке каралык рәвешенә иңеп, куерганнан-куера бара, ә кояш исә һаман күзен кызартып, офык читенә үрмәли... Алда өч аягы белән лап-лоп килеп чапкан өч аяклы ат, аркасында, үз җаен алып, бушый һәм шулай ук лапылдый башлаган капчык, ә арттa — баюга барган кояш. Авызын киң ачып, Кәбир кайнар һаваны уртлады. Ул сусаган иде. Татырланып кипкән аңкавында чак-чак телен әйләндерде. Күкрәктә нәрсәдер әчетте. Ул ачыкканлыгын тойды. Менә хәзер туктап, капчыктагы кара икмәкне умырып алсаң икән дә бит! Авызы селәгәй белән тулды. Юк, Бамбук әле туктарга уйламый да. Дилбегә кинәт уңга тартылды. Малай уңга янтайды, сөрлегеп егылудан чак кына котылып, Бамбукка укталды — ат таш юлны ташлап, уңга — алар кайтачак бәләкәй юлның нәкъ үзенә каерган иде...

Шатлыгын эченә сыйдыра алмый, кычкырып җибәргәнен сизми дә калды:

— Мбамбо-бимбо! Сама-рана-сама!

Үзе генә аңлаган телдә әйтелгән бу сүзләр хәзер инде бөтенләй икенче, ягъни: «Ычкындык болай булгач, Бамбук!» — дигәнне аңлата иде...

## Без алай түгел идек

Рәхәт җиләс җил исеп куйды.

Әллә туган оясына якынайганга, әллә бер аягы оекчан булганга, аның табаннарына бу юл аеруча йомшак, аеруча сөйкемле һәм үз тоелды. Иң курыкканы кинәттән хәлсезләнеп, егылып калу иде. Бу — үлем белән бер. Әгәр мондый куркыныч яный башласа, ул капчыкны ташлап калдырачак. Курыкканга куш дигәндәй, ат гыжлап тын алгандай тоелды малайга. Бот асларыннан һәм янбашларыннан, чөгермәкләнеп, бөҗра-бөҗра күбек чыгып оча. Вакыт-вакыт пошкырынып, тын юлларын лайлалы күбектән тазартып ала. Өч аяклы гарип атның мондый рәвеш, мондый тизлек белән бара алуы аның өчен илаһи бер могҗиза, галәмәт бер сер иде. Мондый гамәлдә һич тә кайта алмас, дип ат өчен курыккан Кәбир көтмәгәндә үзе өчен курка башлады. Туу белән буразнага төшкән, ат белән бергә үскән, кем әйтмешли, ат белән бер кашыктан ашаган һәм бер бишектә йоклаган авыл малайлары арасында «Өч аяклы ат чаба аламы?» дигән бәхәс купса, Кәбир, белмим, ничегрәк җавап биргән булыр иде икән? Юкка бирмәгәндер бит табигать атка дүртенче аякны? Ул аксак атларның авыл урамыннан сикер-

гәләп барганнарын күргәне бар иде барлыкка, ә менә бу рәвешле чапканын... юк, юк! Ә ул чаба. Ничек кенә чаба әле! Өч гамәлдән тора иде ул гүя: тәүдә Бамбук, төен кебек төйнәлеп, бар авырлыгын арт аякларына сала; аннан, күтәрелә төшеп ыргый, авырлыкны алгы сул аягына төшергән арада ниндидер бер газаплы ыңгырашу, эһелдәүләр белән иңрәп, яралы аягын җиргә тидереп ала һәм бу гамәлләр яңадан кабатлана... Кеше акылыннан мәхрүм булган ат, тере җан аксыл рәшәләр аша кешеләргә хас акыл һәм сизенү, аналык тойгысы белән туган ягына ашкына иде.

Ачыклыкка чыктылар. Юл, баш кысып яткан арыш басуына килеп керде. Күп тә үтми, юлда җигүле ат күренде. Фурман үрәчәсенә ике яклап утырып алган кешеләр чатанлап ыргыган ат артыннан чапкан малайга сәерсенеп карап тордылар да, тоттырмаган атны тотарга ярдәм итәбез дип булса кирәк, Кәбирләр юлына аркылы ташландылар. Ат күкрәк көче белән ажгырып, читкә тартылды һәм Кәбирне тагын үзенә суырып алып, арыш басуы аша яңадан юлга төште. Шул мәлдә бәкәленнән читкә очкан ниндидер аксыл нәрсә күзгә чалынды. Арыш сабакларына кыршылып, яра бәйләме кайрысы-ние белән чыгып очкан иде.

«Дилбегәгә асылынып, тыерга, туктатырга мәллә? Юк, бара алганчы барсын.» Урыны-урыны белән зәңгәр чәчкә, кара солы баскан арыштан барган уңайга Кәбир башак сыдырып алды да, шунда ук авызына кабып, чәйни башлады. Көчсез иде, төерсез иде шул башак. Шулай да барыбер ярыйсы, барыбер азык ишарәте: аннан урман-су, сазламык җир тәме килә, ашказанын кытыклап, баллы сөт сытыла... Читтә тәрәзәләренә шәфәкъ ялкыны капкан Софиевка хуторы күренде. «Биш чакырым үтелде,— дип уйлап алды малай.— Керешкә кадәр тагын җиде чакырым калды». Аяклар авырайды. Гер тактылар мәллә югыйсә? Хәлдән таеп егылганчы йөгерәчәк ул. Янып йолдызга әйләнәчәк, кибеп шәүләгә калачак, әмма туктамаячак. Малкай гына чыдый күрсен, ходаем. Ул җиргә карап йөгерергә карар итте. Алга карасаң, офыкның моңсыз чиксезлеге күңелне төшерә. Малай хисап фәненнән шәп иде. Ул исәпләп тә чыгарды, әгәр һәр метрны ике атлап үтсә, Керешкә кадәр ундүрт мең адым. Ундүрт мең талпыну.

— Бер... Ике... Өч... Кырык дүрт... Кырык биш...

Йөзгә җиткәч тә, малай яңадан бергә әйләнеп кайта торган булды.

Әйе, бердән, икедән, өчтән башлана икән дөньяны танып-белү. Дөнья кешене аермый, дөнья һәркемне кешелек бишегендә тигез ярата, тик әнә шул кешеләр үзләре кемне нинди бишеккә салалар, нинди теләкләр теләп, нинди җырлар җырлап үстерәләр—шунда гына икән аерма. Теләсә нинди бишектә дә әнә шушы иң зарури, иң гади һәм иң шәхсәнә саннарның—бер, ике, өченең такка да, җопкә килү мөмкинлеген үз аяклары белән атлап, үз күзләре белән күреп, үз куллары белән тоеп тәрбияләнүе шарт. Беренчел тормышның иң кадерле, иң мөкатдәс бөҗрасы дүрт шарттан тора. Шушы дүрт шартның берсе җитешмәсә, бөҗра өзелә һәм мәңге ялгана алмый. Нәрсә ул бер? Атасыз яшәп кара. Малай атасыз яшәп карамый—яши. Атасы сугышка киткәндә аңа нибары бишенче генә яшь иде. Бикташ тавына кадәр йөгереп озата бардылар алар аталарын. Каршылый гына алмадылар. Сугышның нәкъ азагында, кайдадыр Татра дигән тауларда һәлак булды ул. Нәрсә ул ике? Инәсез яшәп кара. Нинди бәхет—аның инәсе бар. Менә әле ул инәсез яшәп карый. Төрмәдә утыра әле инәсе. Җиңелме Кәбиргә? Үзе белә. Нәрсә ул өч? Бертуганнарыңнан башка яшәп кара. Өлкән абыйсы Гадел былтыр бәхет эзләп, Урта Азиягә чыгып китте. Уртанчы абзыйсы Рәүфне быел кыш ФЗӨга алып киттеләр. Бирәсе килмәде инәсенең. Абзыйсының да барасы килмәде. Силсәүитләр аны, хөкүмәт куша дип, чанага бәйләп алып киттеләр. Сабыр күперенә кадәр ишетелеп торды унбиш яшьлек абзыйсының йөрәк ертып елаган тавышы... Нәрсә ул дүрт? Бердәнбер дуссыз, дуслыктан башка яшәп кара.

Менә ул әле шул дусыннан, аның дуслык тойгысыннан мәхрүм. Сагынды, их сагынды ул Харис ахирәтен! Җиңелме? Үзе белә.

Мең булыр өчен тугыз йөз туксан тугыз берне, нәкъ әнә шул берләнберне көтеп, исәптән читтә тора. Инде мең булган тугыз йөз туксан тугызга җылыну һәм тамагын туйдыру өчен тагын да шул бер берләнбер шырпы кирәк. Бер учак. Их, бу «бер»ләрдән торган бердәмлек боҗрасы! Миннән дә бәхетле юктыр, дип әйтергә ярамый — башкалар турында борчылу кирәк. Миннән дә бәхетсез юктыр, дип өзгәләнергә ярамый — башкаларның хәленә керү, сагыну, тагын да шул күңел яктылыгы кирәк.

Их, бу яктылык! Яктылык әнә шул намус, бишектән алган әдәп микъдары, күрәсең. Тәүдә мең дәүмәлен өйрәнеп, соңыннан кирегә — бергә таба санарга өйрәнү бердән башлап санарга өйрәнүгә караганда читенрәк. Әмма шушы гади хакыйкатьне исәпкә алмаучылар да очрый икән тормышта. Бу инде күңел күзенең әвәлдән үк мең дәүмәле белән сукыраюыннан киләдер.

Әдәп микъдары — язмыш яктысы. Патша да, кол да кешенең халәтен аңлый алырга тиеш. Бу сыйфаттан мәхрүм булган патша да, кол да рухи һәм матди канәчкечлек чире белән авырый башлый. Хәерчегә дә язмыш яктысы — аң кирәк. Аң исә саннар нисбәтенең гап килү-килмәве белән билгеләнә.

Менә әле бер аягы чабаталы, бер аягы оекчан килеш, тир тозы белән көмешләнгән киндер күлмәктә, кыршылып, изрәп беткән малюскин чалбар-пинжәктә, аркасына авыр капчык асып, кара юлдан җилкән кебек агарып чапкан малай, ни кадәре кискен хәлдә булса да, үзен һич кенә дә бәхетсез санамый иде. Аның бөтен теләге һәм ышанычы — якты күздә Кәрешкә барып егылу, берәр кеше почмагында төн кунып чыгу. Кайдадыр җитез тимер кошлар — корыч самолетлар гөрләп якты һаваларны яра, кайдадыр җитез ак кораблар якты дәрьялар гизә, кайдадыр тепловозлар күкрәкләре белән киңлекләрне коча, аларның барысында да үзен мәңге тере булачак итеп тойган якты күңелле кешеләр, ә кайдадыр әле өстенә үлән дә шытып өлгермәгән каберләр, иртәгә нәрсә белән тамак туйдырырбыз дип кара төнгә каршы күзләрен йомган, хәрабәләр эченнән якты көнгә атлыгып караган тома ятим сабыйлар, кайдадыр китапларда һәм киноларда гына күрә алган якты Кызыл Мәйдан, Кремль, Спас манарасы йолдызы — ә монда Сабыр дигән кечкенә елга үзәненнән капчыгына утыз ике бәрәңге һәм бер бөтен икмәк салып, илен, туган җирен, кешеләрне, ахыр чиктә үзен аңларга тырышкан малай чаба. Җир шары әйләнә. Җир шары белән бергә ат, атка дилбегә белән бәйләнгән малай да әйләнә. Алда да, артта да, уңда да, сулда да — Ватан, Ватан, Ватан...

Гамәлдә малай бик бәхетсез, хәтта ватанлы ватансыз җан иясе иде.

... Зөлхиҗә әбиләренә кичләтеп, көтү кайткан мәлдә килеп җиттеләр. Әбисе лапас астында мал карап йөргән булган, күрәсең. Ачык капкадан трактор чылбыры салган дүңгәләкләрдә дыңгырдап килеп кергән арбаны күргәч, әбисе җәһәт адымнар белән ишек алдына чыкты һәм, ниһаять, ерактан ук танып алып, кулларын җәеп җибәрде:

— И-и ходаем! Күрер көннәрем бар икән!...

Кулындагы савыты төшеп китте, аяк астындагы кош-корт, сабырсызланып, җимгә ябырылды.

Апа белән сеңел, озак очрашмый торуларына карамастан, сабыр гына күрештеләр.

— Көш-көш-шу! — дип куды аяк астында кайнашкан кош-кортны Зөлхиҗә әбисе. — Кеше белән сөйләшергә форсат бирми, бирән тамаклар!..

Арбаны лапас баганасына кадәр илтеп терәтеп, атын тугара башлаган Кәбиргә дә чират җитте:

— Балакаем, килдеңме? — Әбисе аркасыннан сөеп алды.
— Әйдә, күрешик инде... Кара, ничек кенәләр үсеп киткән безнең Кәбир, ә, Сания? Олыларыннан хәбәр-хәтәр бармы соң?
Инәсе җавап бирергә өлгермәде. Урамнан ихатага 50—55 яшьләр чамасына чыккан, мөселман кешесенә генә хас сакал-мыек тәрбияләгән, башына кара түбәтәй кигән карт килеп керде.
— Сезнең бәхетегездән, әнә, жизнәгезнең дә өйдә чагы туры килде! — Зөлхиҗә әбисе шатланып кычкырып җибәрде.
— Муса, кунаклар килде бит...
Муса бабасы инәсе белән куш куллап күреште. Кеткелдәп көлеп тә алды. Кәбир бабасы елмайганда бит алмаларында мөлаем чокырлар хасыйл булуына игътибар да итеп өлгерде. Аннан ул малайны кочагында өерелдерде:
— Урамда кыйнап китсә, танымассың! Безнең ише Бохара ялкавын көтеп тормаган, атны тугара да башлаган, маладис!..
— Әйе, жизни, үсте... Еллары гына тыныч булсын... — Инәсе горурланып алды. — Хәзер олылар белән рәттән Акчуннан симәнә ташый.
— Акчуннан?! Җитмеш чакрымнан?! — Бабасы аптырагандай итте. — Китереп бирсәләр нәрсә булыр иде ул симәнәне...
Шаян кеше икән бабасы. Китереп бирерләр, бирми ни! Тот капчыгыңны. Ул арада хатын-кызлар өйгә кереп китте.
— Әйдә, булмаса, мин дә тугарышыйм, улым...
Кәбиргә җылы йөгерде. Аңа «улым» дип эндәшкән ирләр сирәк. Бабасы атка якынлашты һәм, упкын алдына туктаган кебек, аптырап калды. Төсенә, сөлектәй килеш-килбәтенә, маңгаендагы кашка йолдызына карап торды да, мыек астыннан гына мыгырданды:
— Бурлы бия... Сөбханалла, сөбханалла... Исеме ничек соң?
Әйе, бурлы шул Бамбук. Хәтта янып торган кызгылт бурлы. Кәбирләрнең пычак кайрый торган беләүләре дә шундый төстә.
— Аның исеме — Бамбук!
— Без үскәндә андый исемнәр юк иде, улым...
Аркалыкны ыңгырчактан бушатып, камыт бауларын чишкән арада карт, Кәбир сизмәсен дигәндәй, саклык белән генә атның сылу гәүдәсен ниндидер төсмерләүләр аша тикшерә, чагыштыра, күз карасына керердәй булып, нидер эзли, кемнедер чакыра, йолдыз кашканы көрәктәй куллары белән иркә сыйпап, укына, ниндидер йола башкара иде...
Атны тугарып, абзардагы эчке аранга бәйләгән һәм аңа арбадан яшел печән кертеп салган арада Кәбир йорт-җиргә хуҗаларча караш ташларга да өлгерде. Дүрт ягы саманнан, алгы ягы каен чаукалыгыннан каерып ясалган, тирә-якка данлыклы Күлләр акбуры белән агартылган өйдә, шактый оста, хәстәрлекле кул белән бөтәйтелгән абзар-кура, бакча билендәге мунчада — барысында да тәзеклек һәм чагыштырмача муллык сизелә. Лапас астында кышкылыкка бөгеп куелган чана табаннарын, тәгәрмәч тугымнарын, кайрылары каезланган тәртәлекләрне күреп, малай бабасының тракторчыдан бигрәк балта остасы икәнлегенә үз күзләре белән ышанды.
Әйе, һичкенә дә югалып калмаган шул бабасы. Югыйсә, инәсенең: «Кеше-карага лыкылдыйсы булма!» — дип кенә сөйләгәне хәтердә. Утызынчы еллар башында Муса бабаларын кулаклыкта гаепләп, балалары-нинәре белән кышкы суыкта өйләреннән оекчан куып чыгарып, Акчунга озаталар, имеш. Инәсе ягыннан картинәсе белән картатасын да озаталар соргенгә. Йортларын тартып алалар. Хәзер анда кәнсәләр. Кәбир белә, ат дворының каравыл йорты — картатасыныкы келәте. Мәктәпнең алгы ягы — Муса бабасыныкы. Сугыш беткәч, кайтардылар карт аталарын. Ул акылыннан язган иде. Ә менә Муса бабалары нишләптер кире авылга кайтмады. Сөргеннән котылгач, алар менә шушы совхозга килеп урнашканнар икән. Инәсенең авылда ике бертуган абыйсы да бар. Ләкин алар йөрешмиләр. Берсе урман каравылчысы, икенчесе

дәүләт келәтләре хуҗасы. Байлар. «Алар әтәй-инәйдән баш тарттылар, шуңа күрә генә котылып калдылар»,— дип сөйләгән иде инәсе. Кәбирнең атасы ягыннан туганнары сугышта кырылып бетте. Алардан чыпыртап торган балалар калды, өлкәннәре исә ике туганнары Кәбирне «кулак калдыгы» дип күзен дә ачырмый. Әллә инәләре котырта? Һич кенә дә аңламый Кәбир: кем була ул кулак? Баймы? Бай булса, эшләмичә баеганмы? Нәрсә, Кәбир дә баймы? Атасы ягыннан үз картатасы белән картинәсе дә юк. Алар инәсе килен булып төшкән нигездә бергә яшәделәр. 1943 елның кышында булса кирәк, колхоз атларын караучы картатасы атлар эчергәндә коега төшеп үлде. Аны ыргак белән тартып чыгардылар. Гәүдә зәп-зәңгәр боз пыяласы эчендә иде. Атасының үлем хәбәреннән соң картинәсен өянәк сукты. Бераз урыннан торалмый ятканнан соң, ул да вафат булды...

Инәсенең сөйләвенчә, Муса бабаларының мәсхәрәсенә шул Бөкебаш Галләмнәр гаепле, имеш. Кәбир монысын да аңламый: нигә куарга кирәк булды икән авылдан шундый алла бәндәсен? Балта осталары һәм тракторчылар аларның үз авылына кирәкмәде микәнни?

— Атны сугарып килик мәллә, улым?

— Юк. Усылыны кичкәндә суны мул гына чүмерде.

— Шулай ук мул гына чүмердеме?— Бабасы хәйләкәр елмаеп, тагын сорап куйды:— Бүтән эчмәсме?

— Эчмәс.— Малай хуҗаларча кырт кисте.— Дымлы үлән белән аркасындагы тозын сыдырсак кына...

— Кхе-кхе-кхе...— Бабасы ләззәтләнеп кеткелдәде.— Әйдә, сыдырып төшерик булмаса. Озын юлдан соң тын алып китәр, малкай...

Малай йөгертеп бер чиләк су алып килде. Җиң очларын сызганып, яшел үлән учмасын сулы чиләккә тыгып, икесе ике яктан атның сырт биләмәсен, янбашын юл тузаны, тир һәм тоз утырымнарыннан арындыра башладылар.

— Карап-карап торам да, син ат колагыннан чыккан бәндә күренәсең, улым...

— Ат колагыннан?— Малай шаркылдап көлеп җибәрде.— Кеше ат колагыннан чыга ди мени?

— Күрәсең, чыга... Ат җанлы кешеләрне шулай диләр.— Бабасының авыр уфырганы ишетелде.— Галләм нихәлдә соң? Исән-саумы?

— Бөкебашмы? Исән булмый, нәрсә булсын аңа...

— Хәзер аны шулай атыйсызмыни? Элек аны коммун Галләм диләр иде.— Карт бераз тын торды.— Бурлы бия нәселе бармы соң әле сездә?

Үзенә күрсәтелгән игътибардан һәм гәүдәсен били барган сафлыктан иркәләнгән Бамбук йөгән тимерен утлык читенә бәрә-бәрә сусыл үлән умыра иде.

Нинди бурлы бия турында сүз барганлыгын төшенеп бетмәгән малай җавап бирергә ашыкты:

— Бар! Нишләп булмасын, ди... Стаханов колхозында да, Клим Ворошилов колхозында бар диләр бу биянең нәселен. Инәсен былтыр гына иткә озатканнар, имеш. Безнең колхозда Бамбукның ике баласы бар — алашалар! Әйе!..

— Безнең Бурлы бия нәселе түгел микән, дип әйтүем,— диде карт.— Бигрәк кенәләр охшаган...

— Юктыр ла,— дип кырт кисте малай.— Бамбук фронттан кайткан ат. Әнә, бөтәшкән ярасы да бар!— Ул кул яссуы белән яра өстеннән сыпырып куйды.— Безнең авылда бердәнбер пашпортлы ат ул. Первай режим, савнаркум паегы...

— Алай икән...

Алар абзардан чыкканда урамнан шаулашып бер төркем малайлар узды. Телләре Кәбиргә аңлашылмады.

— Бездә урыслар күбрәк, улым. Иртәгә танышырсың әле. Усылыда

бергәләп су керерсез, ходай кушса... Балык тотарсыз. Бездә балыклар — менә! — Бабасы кулларын җәеп җибәрде.

Шомарып беткән таш баскычлар, җир идәнле өй алды — кәҗәнкә аша алар өйгә үттеләр. Мондагы һава Кәбирнең һушын алырлык тәмле исләр белән тулган иде. Иң беренче итеп күзе төшкән нәрсәләр — куерып килгән караңгыда келт-келт итеп йөреп яткан ике герле сәгать һәм үз-үзенә мыгырданып торган «кара эшләпә» иде. Мондый сәгатькә бер аптыраса, малай кара эшләпәгә ике аптырады: ырадиу дигәннәре шушы икән! Аларның авылында бит сәгать дигәнең бары тик мәктәптә генә бар, анысы да бер генә герле. Кайда ди ул ырадиу!

— Нигә караңгыда утырасыз? — Бабасы ишек катындагы ниндидер кара сәйләнгә басты һәм бөтен өй эче ялт итеп яктырып китте. Мич тирәсендә кайнашкан әбисе дә, шунда сәке читенә кунаклаган әнисе дә нурдан коендылар.

— Електрмы бу, Муса бабай?

— Әйе, електр, улым.

Яшиләр, менәтерәк! Малайда нәселләре өчен горурлану тойгысы туды. Шундый ырадиу-електрлы туганнары бармы аның яшьтәшләренең? Бар ди, пычагым!

— Шул урыс такмазасын баса төш әле бераз, — дип көяләнеп алды бит алмалары алсуланып киткән әбисе. — Әллә нигә бер күрешкән туганым белән иркенләп сөйләшимче, ичмасам...

Муса карт сәке өстенә менеп, кара эшләпәне авызлыклый бирде. Табын уртасында хуш исле йомшак бодай икмәге, кызыл бөрлегән һәм чия салып кайнатылган сары май, җиләк кайнатмасы, ул гына дисезме — бер таба йомырка тәбәсе һәм куырылган балык, сөт өсте салынган куе чәй — болар барысы да Кәбир күрмәгән оҗмах ризыклары иде. Малайның кыстатмаганын күрсә дә, әбисе кыстаган булды. Әбисе кыстагач, Кәбир йомырка тәбәсен бөтенләй үк урынына менгезеп куйды.

Корсагы гөп итеп калган малай, ниһаять, амин тотып, сәке читенә шуышты. Көне буе тулганып арыган малайның колагына олылар сөйләшкән сүзнең һич кенә дә кызыгы юк иде. Аңа кәҗәнкәдәге агач караватка урын җәйделәр.

Йомшак түшәк һәм инде киләсе елга бәйләп куелган каен себеркеләр хуш исе кочагында Кәбир татлы хыялларга чумды. Их, белсәләр иде дуслары аның ни кадәр бәхетле икәнен! Менә ул иртәгә Усылыга атын сугарырга барачак. Таныш түгел рус малайларына атын мендереп караячак...

Күп тә үтми, ләззәтле хыял диңгезендә йөзгән Кәбир тирән йокыга талган иде инде.

... Кинәттән нәрсәдер дөбердәде, чөлперәмә килде. Йокысыннан айный алмаган малай күзләрен тырнап ачты һәм үзенең кайда икәнлеген исенә төшерә алмый азапланды. Тирә-як дөм караңгы. Ишек алдында, абзар тирәсендә кычкырышкан тавышлар ишетелде.

— И, ходаем, харап кыналар булдык!..

Бу әбисенең тавышы иде.

Дөпелдәтеп мылтык аттылар.

— Фонарьны алып чык, дим, фонарьны!

Бабасының тавышын абайлап алгач та, малайның йокысы табан астына качты. Яшен тизлеге белән юрганны атып ташлап, ул төн салкыны алган ташлар аша тышка атылды.

— Балакаем, атыбызны... бугазлады бит!..

Ихата тутырып үксегән инәсе аны үзенә тартып алды дигәндә генә Кәбир таш булып абзарга ыргылды:

— Бамбук!!!

Бөтен мал-туар почмактан-почмакка ду килеп өерелгән абзарда нәрсәдер аңлау мөмкин түгел иде. Кем, нәрсәне бугазлаган? Кинәт аран эченнән ат үзәкне өзеп кешнәп җибәрде.

— Исән? Бамбук!!

— Фонарь, улым, фонарь!

Тынычлыгын тәмам югалткан һәм бер-берсен таптап, караңгыда капкага юл эзләгән маллар арасыннан, яңа гына ләпәшкән сыер пәрәмәчләренә бата-бата, малай тышка ташланды. Өйдә нәрсәдер гөрселдәпауды. Тупсада аңа каршы булган Зөлхиҗә әбисенең кулыннан фонарьны тартып алып, ул үз юлын үзе яктыртып, яңадан абзар караңгылыгына чумды.

Абзар эче соргылт якты белән зәгыйфь кенә җанланды. Кәбирнең күргәне җимерелгән аран, кан эчендә җан биреп яткан сарык һәм бер якка сөер янтаеп басып торган Бамбукның тилергән күзләре иде.

— Тизрәк пычак! Әбиең җылы су да китерсен! — Аран эченнән бабасының карлыккан тавышы ишетелде. — Инәңне тынычландыра күр... Йөрәге тотты бугай.

Шулай икән шул. Әбисе аның күкрәгән уа һәм салкын су белән маңгаен чылата.

— Тынычлан, Сания сеңелем... Без күрәсен кеше күрмәс...

— Башымны тәрмәдә черетәчәкләр... Түтәй!.. Аһ!..

— Инәй, ат исән! — дип кычкырды пычак эзләгән арада Кәбир. — Атка бер нәрсә дә булмаган...

Һәм пычакны кулына кысып, ул чыгып та тайды.

Ул абзарга кергәндә гадәти булмаган мылтык тавышыннан уянып, күрәсең, күршеләре дә җыелып өлгергән иде. Сарыкны ашык-пошык чалган арада Муса карт булган фаҗигане тырыша-тырмаша аңлатты:

— Вулка пришел... Как пришул? Лежал-лежал да инде, абзарда ыштуты ниладны, хадун ходит. И лошад сильны кричал, думал, нүҗәли снова вулка пришел. Зимой гына пришел бит, мәйтәм... Ягненка жрал. Сикереп торам, ружье брал да сарайга, ничауа не видат, ягненка закричал, лошаль закричал, и я ничауа не видал... Капканы открывал, а там вулка навозный укна прыгал, а я ружьедан — шарт!..

Кәбирнең бабасына ачуы килә башлады. Бамбукны караган юк, ә ул һаман «вулка» да «вулка»!

— Повадился, значит? — диде арадан берәү. — Надо что-то предпринять, мужики...

Караңгы почмакта дерелдәгән аттан дерелдәү Кәбиргә дә күчте. Ниһаять, фонарь яктысы Бамбукның башын яктыртты. Әле һаман да ярсуын баса алмаган, бүре киткәч кенә бүре куарга җыенган кешеләргә «Нәрсә беләсез соң сез?» дигән сыман гасабилык белән карап торган байтал аңа күргәзмәгә карагандай караучылардан җирәнгәндәй итеп башын югары чөйде һәм тагын да кешнәп җибәрде. Атның күзләрен күреп тетрәнде Кәбир: алар кан белән укмашкан ике зәңгәрсу йолдыз иде. Малайга бу тирәлекне саран фонарь яктысы түгел, шушы ике күз яктырткандай тоелды.

Ял һәм муен тирәсеннән шуып, нурлар күкрәк атламасындагы ярага килеп кадалды, байтал тиресен җыерды. Бүре тешләренең эзе ярылып яткан төштән кул яссуы кадәр ит умырып алынган иде.

— Бугазны бирмәгән, малкай, — диде күршеләреннән кемдер.

Абзар эче кан һәм чи ит исе белән тулгандай булды. Бүренең тырма сыман тешләре белән өзгәләнеп, эчтән кансырап һәм кызарып торган яра тирәсенә кеше куллары кагылгач, Бамбук тагын тәнен җыерып, пошкырып куйды.

— Почему он так странно стоит? — диде Әндри /рус абзыйның исеме шулай икән/. — Освети-ка низ, Муса агай...

Әйе, иң зур бәла алда торган икән шул. Бамбук алгы уң аягына баса алмый иде. Әле Муса бабасы белән атны җеп сыман энәдән үткәреп тикшергән күршесе Әндри абзый әйтүенчә, бүре белән якалашкан чакта ат аягын утлыкка тыгып сындырган, йә булмаса буын сеңерен өздергән булырга тиеш.

Икенчеләр фараз итүенчә, ат кешедән һәм эттән кала иң акыллы һәм иң сизгер җан иясе: ул абзарда малларны пыран-заран китергән җанварның чынлап та бүре икәнлеген исеннән сизгән һәм үз-үзенә урын таба алмый, аранны җимереп, мал-туарны коткарышырга чыккан, имеш.

Бераз әл-хәл алып, абзарга чыккан инәсе бу сүзләрне ишеткәннән соң, Зөлхиҗә әбисенең иңенә асылынган хәлдә, өзлеккән караңгыны үзе артыннан өстерәп, өйгә кереп китте. Кәбирнең миендә нәрсәдер ялт итеп яктырды, анда гүя яңа кояш кабынды. Бу яктыда бар дөнья ап-ачык күренгәндәй итте. Җир белән күк, тау белән үзән, ут белән су арасында гына түгел, хәтта үзенең йөрәгендә дә нindидер төп, гомерне күтәреп торган авырлык җебе өзелгәндәй итте һәм ул җеп тиз генә ялганмаячак иде.

Әндри абзый бер мәлгә генә югалып торды да, иңенә кыр сумкасы асып яңадан килеп керде. Әйтүләренчә, ул мал духтыры икән. Иң тәүдә күкрәк атламасындагы яраны эшкәртте. Башкалар тынычсызланган Бамбукны тотып тордылар. Аннан Әндри абзый ярага бармакларын тыгып, аны ниндидер зәңгәрсу-көрән эретмә белән юды. Чүпрәккә кара май, аның өстенә он сыман дару сипкәннән соң, өйдән шикәр комы соратып алып, шунысын да өстәде. Тетелеп тешкән тирене урынына җөпләп, дарулы чүпрәк белән каплады һәм дилбегәне бот астыннан, муеннан чалып, яраны бәйләде. Бу мизгелдә Кәбиргә Әндри абзыйдан да кадерле кеше юк иде.

— Как-то надо затащить,— диде Әндри абзый.

Ирләр аран бүрәнәләрен бер почмакка өеп куеп, Бамбукны күтәреп диярлек аранга керттеләр. Әндри абзый ничек кенә тырыштырып караса да, байталны аягына бастыра алмады. Аның аңлатуынча, аяк сынмаган, бәкәл тамыры өзелгән булырга тиеш. Иртәгесен, дөресрәге, көн тугач, тагын да ачыклана төшәр. Ул сумкасыннан икенче бер әшәке исле май алып, бәкәлнең тояктан югары тәңгәленә сөртте һәм Муса бабасы ярдәмендә кысып бәйләде, аннан сөян кабыгы белән көпләп, өстеннән кереш белән дә тарттырды.

— Ногу надо будет прогревать горячим песком, Муса агай...

— Аннан татарчалап өстәде.— Тоз билян да ярай, понял?..

— Храша, Әндри, храша...

Бамбук үлән чемчегәндәй итте.

Күршеләр таралыштылар. Алар артыннан Муса бабасы белән Кәбир дә ишек алдына чыкты. Офыкта күкәй сарысы кебек таң саргаеп килә. Күк йөзе авыр болытлардан арынып, эре һәм якты йолдызлары белән җемелди. Кинәттән генә абзар артындагы өянке яфракларын шыбырдатып, саба җиле исте. Кәбирнең кулбашлары тартышып куйды.

— Бар, улым, кереп ят булмаса...

Малай таш тупсага утырды. Кәҗәнкәдән ниндидер савыт алып чыгып, бабасы яңадан абзар эченә кереп китте. Үз ялгызлыгыннан үзе шомланган Кәбир аның артыннан абзарга кергәндә Муса карт нидер укына-укына почмакларга һәм дивар буйларына нәрсәдер сибә иде.

— Нишлисең, бабай?

— Ә-ә, син мондамыни әле?— Бабасы аңа борылып карамыйча, эшен дәвам итте.— Абзар иясе яраткан малын убырга бирмәс, артыннан эзләп килер, ди... Борынгыдан калган йола буенча абзар иясенең күңелен күреп, тоз һәм орлык сибәм, балам...

Әгәр Бүләктәге абзар иясе малын убырга бирмәгәч, нигә соң ул гына түгел, Усылы абзары иясе дә Бамбукны убырга бирде? Малайның зиһенендә башмактай зур Соры Бүре пәйда булды. Малай тышка чыгып, яңадан таш баскычка утырды. Озакламый урынында оеп барган Кәбирне инәсенең тавышы сискәндерде:

— Кереп ят, улым... Җан биргәнгә җүн бирер әле... Нишләтәсең, Бөкебашлар кулында инде безнең язмыш... Әйдә, кереп ят.

Кәбирнең инәсен кочаклыйсы, әллә нинди иркә сүзләр белән юатасы, атның төзәләчәгенә, ә Бөкебашларның аларга бернинди явызлык та эшли алмаячагына, аннан, үскәч, үзенең көчле дә, акыллы да, эшчән дә булачагына ышандырасы килде — тик тән хәрәкәтсез, тел исә йозаклы иде. Ул инәсенең тагын да күңеле йомшарып, елый башлавыннан курыкты. Инәсенең күз яшеннән дә газаплырак нәрсә юк иде аңа бу тормышта. Инәсенең күз яшен күргә, гүя, аның тәненә чабырткы чабыртып чыга һәм тәнен меңләгән энәләр белән чәнчи башлый. Үзенең дә күзенә яшь бәрә...

Малай ирләрчә түзем саклап, суынган урынына кереп ятты. Күзләрен йомуга алдына тагын да инәсе килде. Үзе белән янәшәдә, әчке якта булуына карамастан, ул аны сагына иде. Атасының үлем хәбәре килүен яхшы хәтерли Кәбир. 1945 елның февраль суыклары иде. Укытучы Маһирә апа атасының яудашы язган русча хатны татарчага тәрҗемә итеп укыды. Иң элек Гадел, аннан Рәүф абыйсы елый башлады. Маһира апаның «... Словакиянең Модри-Камень дигән шәһәрчеге янында, 503 нче биеклектә батырларча һәлак булды», диюенә инәләре яулыгы белән битен каплап, кәҗәнкәгә чыгып китте. Аның артыннан картинәсе юнәлде. Менә шунда гына елый башлады Кәбир. Моңа кадәр нык торган Маһирә апалары да, өйдәге бар нәрсә — буш чөйләр дә, учагы сүнгән казан да, почмактагы кәҗә бәтиләре дә елый иде сыман... Озакламый картинәләре урын өстенә ятты. Юнле-рәтле тәрбия, дәва булган хәлдә, бәлки ул яңадан аякка да баскан булыр иде. Картинәсен җирләгәннән соң өй бушап калды. Ачлыктан шешенеп, кабер якасына җиткән Кәбирне күрше авылда ач балалар өчен оештырылган приютка алып киттеләр... Кырык алтынчы елның җәен шунда үткәреп кенә исән калды малай.

«Атыбыз савыгыр, артык бетеренмә,— дип юатты ул эченнән инәсен.— Ул бит ни дисәң дә ат! Бөкебаш та әллә-ни кыра алмас. Нишләп бәйләнә ул аның инәсенә? Монда нинди әйтелмәгән сер бар? Алар бит атны бүре авызына үзләре илтеп тыкмаган!»

Тормышлар да рәтләнер, дип уйлады ул. Рәтләнми булмас. Әнә, Гадел абзыйсыннан нindирәк хат килеп төште күптән түгел. «Галимулла бабайга рәхмәт әйтегез, чабатасы Сталинабадка кадәр чыдады. Багзалда гына салып ташлап, Күкташка оекчан килеп кердем. Минем өчен кайгырмагыз. Эшкә урнаштым. Багана башларыннан йөреп, кешеләргә електр бирәм. Эристаранда гына ашыйм...»

Багана башыннан йөрим дигәненә инәсе, әлбәттә, бик борчылды. Әле дә борчыла. Багана башыннан йөремичә генә кешеләргә електр биреп булмый микән ни? Егылып төшеп, тән әгъзаларын имгәтә калса? «Эристаран» дигән сүз инәсенең бигрәк тә һушын алды. Әби-сәби, апа-чапа, малай-шалайлардан гына торган күрше-тирәдә аны аңлатырлык кеше табылмады. Фронтлардан исән кайткан Рәхимҗан абзый: «Анда акчалы кешеләр генә йөри»,— дигәч, инәсе бер куанса, шул ук Рәхимҗан абзый «Анда өбәзәтелне аракы!» дип тә өстәвенә ике тапкыр кайгырды. Алар кич утырып, озын хат яздылар. Инәсе әйтеп торды, Кәбир сырлады. Хатка бүрәнә арасындагы мүк кебек яшереп кенә мондый тәгъбирләр дә сипләнгән иде: «Берүк, балакаем, азып-тузып йөрисе булма. Анауы эристаран дигәнең өчен ут йотам — анда ашны аракысыз бирмиләр, имеш...» Абзыйсының хаты озак көттермәде. «Эчкән кешегә монда — вуле. Мин эчмим. Ашаганым бер первый, бер фтаруй...» — дип язган иде ул.

... Агач башларын алтынга манып, тауларга барып төртелгән кичке кояш сыман, Кәбирнең хәле көрчегенә терәлеп бара иде. Алар тагын да бер биш чакрым чамасы үткәннәрдер, мөгаен. Соңгы чиккә җитеп, ашказаны суыра. Ачыгудан да бигрәк, сусады малай. «Бамбукны туктатырга кирәк,— дип уйлап алды ул.— Яланда булса да кунарбыз. Әмма — су, су, су!»

Уеннан кайтып та өлгермәде, туктаусыз ыргудан мунча ташы кебек кызган, инде тәмам коңгырт төскә кергән һәм күбек белән йөгертелгән байтал кинәттән генә шул ук омтылыш белән олы юлдан читкә тартты һәм зирек, шомырт агачлары белән челтәрләнгән ниндидер ташландык урман юлы белән өстерәп алып кереп тә китте.

— Бам-бук, тук-та-а-а!!!

Малай бар көченә кычкырып җибәрде һәм дилбегәсенә асылынды. Әмма күзләрен кан баскан атны туктату мөмкин түгел иде. Күкрәгендә нәрсәдер чәнечте, кычкырырга итә — кычкыра алмый, гүя, эчне кату катырган. Күпмедер ара дилбегәгә өстерәлеп барган Кәбир түмгәләкме, төпсәгәме абынды һәм бөтен гәүдәсе белән лап итеп капланып төшеп, аңын җуйды...

Һушына килгәч, беренче тойгысы сусау да, ачыгу да түгел, гарьлек һәм авыртыну иде. Бөтен тәне әрни. Кайда ул? Нигә йөгерми? Малай яткан җиреннән хәтерләргә тырышты. Юк, хәтерли алмады. Шунысын гына белә — ул бары тик йөгерергә тиеш. Бәлки ул әле дә йөгерәдер, җирдә яткан кебек тоела гынадыр? Ул җир дымына җиреккән тәнен, аякларын кымшатып карады. Юк, йөгерми икән шул. Бамбук кайда? Соры Бүре алып киттеме? Ат караклары урладымы? Әгәр бу могҗизага кеше катнашы юк икән, нинди көчләр борды Бамбукны бу якка? Аның хәтере яңара башлады. Уң кулының бармакларын нәрсәдер түзә алмас дәрәҗәдә буган иде. Бушатырга тырышып карады — булдыра алмады. Икенче кулы белән ярдәмгә килгәч, аңлашылды — беләзек тәңгәләнә уралган дилбегә үзлегеннән чалынып бөйләнгән дә бармакларын кысып, буынсызландырган иде. Дилбегә өзелгән булып чыкты. Аның тәененнән кулын бушатканнан соң, ул көч-хәл белән кулларына таянды һәм торып утырды. Гәүдәсенең бөтен төше сыдырылган икән. Башын капшаса, лепкә тәңгәлендә кан лайласы укмашкан. Анда бармак башы кадәр оры да калкып чыккан. «Баш тишелгән икән». Як-ягына каранды, әмма күз күременде Бамбук шәйләнми иде. Ул шәфәкъ белән саубуллашкан моңлогән тәр бөҗәкнең, чикерткәләрнең чекердәвенә һәм гөжләвенә колак салды — юк, сынган ботак, тояк астында изелгән коры-сары тавышы, гомумән, ат ишарәте сизелми. Малай үзендә чиксез ялгызлык тойды. Ләкин ул мондый ялгызлыкка нишләптер битараф иде. «Буласы булган, буявы сеңгән». Аркасындагы капчыгын салып чиште дә, ипинең бер читеннән сак кына сындырып алып, авызына капты. Ашыйсы килү тойгысы басылган иде. Уң чабатасын чишеп, капчыгына салды. Берәр авылда сыңар иске чабата булса да сорап кияр әле. Шулчак аның карашы сул аягындагы оектан үрмәләп, йөк өстерәп менеп килгән кырмыскага төште. Зур, олы карынлы ана кырмыска иде ул. Оекның йоны аңа нык комачаулый. Менә кырмыска, йөген өстерәп алып бара алмагач, аны әйләнеп чыкты һәм арттан төшеп, мыек кыскычлары белән эләктереп алды да, эһ тә итми, Кәбирнең балагы буйлап менә башлады. «Юл бу,— дип фараз итте малай.— Миңа юл бу». Ул кырмысканы алып, җиргә төшерде. «Бар, кайт, өеңдә балаларың көтәдер». Шулчак баш очында гына саескан шыкырдады.

— Имгәк! Имгәк! Имгәк! — дигән сыман яңгырады бу шыкырдау. Ул йодрыкларын шытырдатып төйнәп, җирне доңгечли башлады:

— Юк! Юк! Юк!..

Аңа көч кергәндәй итте. Ыңгыраша-ыңгыраша урыныннан күтәрелде, капчыгын асты һәм кул беләзегенә эленгән камчысын капшап, урман эченә атлады.

Караңгы төшә башлады. Озакламый ул елгага барып чыкты. Су! Су! Ике яктан да үзәнен күпер сыман итеп таллар билəгән Сабыр дулкыннарын ярга чайпалдырып, берни булмагандай, тыныч кына агып ята. Өстендә зәңгәр су борчалары, суфи чикерткәләре уйнаган елгадан куш учлары белән туйганчы су эчте, битен юды һәм кызган башын чылатты.

Атның елга аша кичүе мөмкин түгел иде. Кире борылып, малай Сабыр канатыннан үргә, авылга таба үрләде.

Әгәр Бамбукны Соры Бүре куып җитеп, бугазлаган булса? Малайга куркыныч булып китте. Ул урман эченнән җан-фәрманга йөгерә башлады. Инде аның бер генә әгъзасы ды сызламый иде. Бер кәүсәдән икенчесенә туп кебек этәрелеп, куе абагалар, ак башлы көпшәләр, ат кымызлыкларына кагыла-сугыла ул алга томырылды.

— Ба-а-ам-бу-у-ук!!!

— Юк!.. Юк!..— дип җавап бирде лабылык.

Сабыр елгасы кинәт сынып, уңга борылды. Хәле беткән малай кычытканлыкка килеп чумды һәм кулларын, муен, күкрәкләрен кычыткан селтесендә пешекли-пешекли, карт өянке төбенә килеп ауды. Авыр иде тын алуы. Күз аллары караңгыланганнан караңгылана. Баш гүли, колаклар зеңли. Аңа өерләре белән черки, сукыр чебен, кигәвеннәр белән бергә хәтта энә караклары да ябырылды. Кичке урманның төнге йокыга талыр алдыннан гына яратыла торган авазлары, аһлары, пышылдаулары да, әчкелтем куе хуш исе дә аның өчен юк иде хәзер. Әнә, черкиләр чалбар һәм өлтерәп беткән пинжәк аша энәләрен бик җиңел үткәзеп, аның сыек канын суыралар. Аның черки куарлык та хәле юк. Әнә, бер черки, безелдәп, аның күз кабагына килеп кунды һәм энәсен кадады. Эчсен, дип уйлады Кәбир. Мал бетмәсә — кан бетмәс. Күктә, нәкъ баш очында гына, самолет гөрелдәгәне ишетелгәндәй итте. «Самолет, самолет, минем әтәйне алып кайт!» — дип кычкырасы килде малайның, сабый чагында болдырдан кычкырган кебек.

Йокларга ярамый! Йокларга ярамый!

Ул кургашын сыман авырайган күз кабакларын ачарга тырышты. Сандугач, урман тургайлары сайраулары тынган арада бала тавышына охшатып, шәүлегән кычкыра һәм күңелгә шом сала. Якындагы елгада сусармы, камамы чайпылдап уйный. Урман күгәрченнәре гөрелдәп куя. Алар тынуга бар җиһан тагын да сандугач моңнары белән кайный башлый. Катык кебек төссезләнеп, оеп барган күзләрен малай күккә юнәлтте. Әнә, Зөһрә йолдыз. Таң алдыннан ул инде Чулпан йолдызга әйләнәчәк. Аны халык шулай атаган. Әнә, Кәбирнең иң яраткан йолдызы — Тимер Казык. Җирнең беренче ире — Адәмнең шул ук җирнең беренче Акбузатын бәйләгән казык икән ул. Боларның барысын да ат кунасында Сәми карт сөйләде. Йолдызлар алар, гомумән, җирдә бәхет тапмый күккә ашкан ир-ат йөрәкләре, имеш. Җирне шулар гына яктырта, имеш. Бамбук белән Кәбир йөрәге дә күктә микән инде хәзер? Халык нигә ир-ат сүзен бергә кушып әйтә? Икесе бер җан мәллә алар? Сәми бабай сөйләвенчә, бер җан икән шул. Борынгы заманнардан алып. Малайның күз кабаклары авыр баз капкачлары булып ябыла һәм ул йокы упкынына оча.

...Әйе, борын-борын заманда җир йөзендә якты көчләр белән кара көчләр арасында җәяүле сугыш барганда Җир-Ана мәһабәт бер ир бала тудыра, аңа кан белән тулган җирдә урын тапмый, күккә чөя һәм шул йолдызга әйләнә, имеш. Кара күк болыннан чапкан канатлы Алтын Бия елаган йолдыз тавышын ишетеп, аны эзләп таба, имезә, имеш. Яңадан ир-балага әверелгән Йолдыз-Адәмне ул канатына утырта. Шул ике канат бишегендә ир булып җитлегә сабый. Канатлы бия сөтен имеп үскәч, үзе дә канатлы була. Ятим баланы карап үстергән өчен рәхмәт йөзеннән Җир-Ана бия карынын алтын белән тутыра, имеш. Моны белеп алган Дию канатлы бияне алтыны-ние белән йотарга карар итә һәм эзәрлекли башлый. Бер җанга әйләнгән канатлы ат белән канатлы ирне күк йөзеннән куып тота алмый ул. Алдатып, Диюне җәһәннәмгә алып төшә ир-ат. Ике җанны аермый торып, алтынга хуҗа була алмаячагына ышанган Дию Мәңгелек Әҗәлчегә әверелә. Төмуг утына җитәрәк кенә Җир-Ана ир-атны яңадан күккә очыра... Шушы куанычтан ул

канатлы ир-атлар туктап ял итсен өчен күккә Тимер Казык кага, имеш. Тимер казыкка бәйләнгән канатлы бия җиде колын китерә, шулардан Җидегән-йолдыз ярала, имеш. Менә ул заманнардан бүгенге көннәргә кадәр Дию үрчегәннән-үрчи барган ир һәм ат дуслыгын җимерү, аларны аеру өчен җир һәм күк буйлап чабулап йөри икән. Мондый аерылу кешегә дә, атка да беркайчан да бәхет китермәгән, ди. Чөнки атның күзе үткер: юлында яткан иген бөртеген ул бер чакырымнан төнлә дә күрә, имеш. Кеше аны ун кат күзлек кисә дә күрә алмый. Атның колагы сизгер: аягында черем иткән чикерткә тавышыннан да уяна. Ә кеше еш кына колак төбендә барабан каксалар да уяна алмый. Атның акылы якты: бер үткән юлын онытмый, хуҗасын таный, аны күзләреннән аңлый. Кеше исә еш кына бер тапкыр түгел, ун тапкыр үткән юлында да адаша, хуҗасын түгел, үзен дә танымый, чөнки ул акыллы, ә бу акыл уй, шөбһә һәм мәкер белән зарарланган. Атның йөрәге тере һәм тугры: ул олыны олы, кечене кече итә, кара төндә җан-фәрман чабып барган юлына биләүле бала салсалар да, таптамый, сикереп үтә, кеше исә олыны кимсетә, кечене мәсхәрәли, кара төндә түгел, якты көндә дә үз карыныннан туган баласын коега сала, ата-анасен урамга куып чыгара... Моны бары тик ат һәм аның рухыннан аерылган кешеләр генә эшли ала, имеш. Менә ни өчен төрле могҗизаларга, машиналарга бай заманда да ир — аттан, аның рухыннан аерылмаска тиеш икән. Аерылса, үзен кеше иткән, әллә нинди җитез очкычларга утырткан атны рәнҗетсә, кыерсытса, ул беркайчан да игелек күрми икән. Бия карынындагы игелекле алтынга беркемнең дә кагылырга хакы юк, ди...

Төн урталары җитеп бара иде. Кошлар да күптән тынды. Бик ерактан күк күкрәгән тавыш ишетелгәндәй булды. Аңына килә алмаган Кәбир, ыңгырашып, авырткан ягын алыштырып, икенче ягына әйләнде. Күзләрен ачып, тирә-ягына колак салды. Шылт та итми. Бары тик йокысыз черкиләр генә безелдәштерә. Тагын да күк күкрәгәндәй итте. Малай урыныннан күтәрелә төшеп, өянкегә аркасын терәп утырды. Кинәттән урман чоңгылы белән бергә йөрәкне телеп, менә монда, якында, уч төбендә генә бар тирә-якны яңгыратып һәм яктыртып, ат кешнәгәне ишетелде:

— И-һа-һа-һай!..

Кәбир ук булып тавыш килгән якка атылды. Ат кайтыр уңайда, елга үзәненнән шактый өстәрәк тәңгәлдә булырга тиеш иде. Һаман да шул тал һәм колмак куерымнарын, кычыткан диңгезен ера-ера, ул урманны урталайга кисә башлады. Йөрәге күкрәк читлегеннән сикереп чыгардай булып типте, шатлык яшьләре бит алмалары буйлап акты.

— Бам-бу-у-ук!..

Әллә чынлап та малайның тавышын ишетеп, әллә аяк астында шатыр-шотыр килеп сынган черек ботак тавышлары сизеп, теге кешнәү тагын да кабатланды:

— И-һа-һа-һай!

Кешнәү чынлап та якында гына иде. Терсәкләрен, битен ботаклардан сыдырта-сыдырта алга томырылган Кәбир ниндидер акланга килеп чыкты. Ай яктысында йөзгән ачыклыкның теге очында атка охшаган карачкы шәйләде. Атмы? Әллә атның башына җитеп, мыекларын сыпырган Соры Бүре шулай ат булып кешниме? Аякка уралган кәрешкә, куе үлән бәйләмнәрен сак кына өзә-өзә ул карачкыга якынлашты һәм аңа берничә генә адым калгач, үз күзләренә үзе ышанмагандай, шып туктады. Карачкы үләнне керт-керт кисә дә башын күтәреп тынлыкны тыңлый...

— Бамбу-ук!

Калган араны ике-өч сикерүдә үтеп, Кәбир атның ялына килеп сарылды. Хуҗасының табылуына куанган байтал, нишләргә белми, аны исни, су исе аңкып торган дымлы иреннәре, җылы кытыршы теле белән битен, муенын, колакларын ялый, танау тишекләрен киңәйтеп фырыл-

дый иде... Менә ул, куанычын кайда куярга белми сөенче алган малай сыман, чәчкә исләре белән куерып суынган һавага тагын бер тапкыр дәррәү аваз салды:

— И-ha-ha-һай!

— Ипләп, Бамбук! Тилердең мәллә?!

Кәбир ике кулы белән атның авызын томалады. Аларның табышуын, ул уйлаганча, һичкем дә белмәскә, һичкем дә күрмәскә тиеш иде. Малай атның муеныннан кочты, балтырган исләре килеп торган иреннәреннән үбеп яратты:

— Йомры тоягым, тырнак колагым минем!.. Карлыгач ботым!.. Күгәрчен төшем!.. Ялбыр ялым, нечкә бөерем!..

Малай сиздерми генә байталның күз яшьләрен сөртеп алды. Ай яктысында зәңгәрсу күл булып яктырткан Бамбук күзләренә озак карап торганнан соң, тагын да беркем дә ишетмәсен дигәндәй, колагына пышылдады:

— Без мондый түгел идек, Бамбук!..

Бу — 1948 елның июнь ае урталары иде.

## Бөкебаш һөҗүмгә күчә

— Хәзер, Бамбук...

Иң мөһиме — кара урмандагы ялгызлык, курку тойгысы качты. Камчысының беләзеген кулыннан шудырып чыгарып, аны якындагы агач ботагына элде. Капчыгын салып, эчендә бутана башлады. Ипине очып китмәсен дигәндәй саклап, кадерләп кенә ай яктысына чыгарды һәм валчыгын да читкә төшерми капчык авызында урталай бүлде. Алдагысын алла белә, бүгенгесе кадерле иде аңа. Илдә чыпчык та үлми. Түтәрәмне тагын да урталай сындырып, Бамбукка сузды. Байтал ак гәрәбә тешләрен ай нурында чарлап, ипине умырып капты. Шул ук түтәрәмнән малай үзенә дә өлеш чыгарды. Әй, тәмле иде ипекәй! Көлдә пешкән, чыннан да чынрак, тыгыздан да тыгызрак, үзледән дә үзлерәк арыш икмәгенең күзәнәгендә иде хәзер тормыш тоткасы, шул күзәнәк эчендә әйләнә иде хәзер җир шары.

Малай якында гына чишмә челтерәвен абайлады. Азыкның калган өлешен күлмәк итәгенә төреп, ул байталдан аерылды һәм челтерәгән тавышка таба атлады. Чишмә ярында торалар ләбаса! Әнә аның үзәне ай нурында көзге ватыклары сыман ялтырап ята.«Мунча ташы кебек кызып, Сабыр елгасын эзләп барган Бамбук көтмәгәндә чишмәгә тап булган икән,— дип уйлап алды Кәбир.— Бәлки ул чишмә исен әллә кайдан тойган һәм Кәбирне дә шул тарафка өстерәгән булгандыр?» Их, сөйләшергә иде байтал белән! Юк, сөйләшә белми шул ул!

Ул Бамбук янына килде. Тагын да ипи каптырды. Күз ачып йомганчы түтәрәм юк та иде инде. Яңадан капчыкка тыгылгач, кулы кәгазьгә төрелгән шырпыга, йомры бәрәңгеләргә кагылып китте — һәм ул чак кына кычкырып җибәрмәде — учак ягабыз, бәрәңге пешерәбез, Бамбук кардәш!

Урман эченнән коры-сыры алып чыгып, учак тергезеп җибәргәч, тормыш тагын да ямьләнеп, учак уты төшкән чәчкәләр — төн миләүшәләре тагын да зәңгәрләнеп киткән кебек тоелды. Ай исә ак салган тана күзе кебек тоныкланып калды. Байтал исә башын әле теге, әле бу якка борып, үз тирәсендәге үлән башларын муены җиткән төшкә кадәр ура да, тагын авыр уфылдап һәм ыңгырашып, яңа кишәрлеккә сикерә. «Өч аяклы килеш ничек төшә һәм менә алган ул чишмә ярыннан? — дип уйлап алды малай. Ул моны һич кенә дә башына сыйдыра алмый иде.— Бәлки ул үзән буйлата күтәрелгәндер?»

Шактый кызып, тармакланып киткән учакның кузланып, хәтта көл дә түшәлеп өлгергән төшенә ул биш бәрәңге күмде. Алтынчысын атка

биреп карады. Дөрес, аңа елкы малының чи бәрәңге ашаганын күрергә туры килгәне юк. «Карыны йотыксамы?—дип сөйләгәне хәтердә Сәми бабасының.—Ат ул, майкаем, арба тартасен дә кимерә. Чи бәрәңгесен дә ашый, сөтен дә, бирсәң, кан да эчә, итле ашын да ашый... Әмма ашлы суны гына өнәми ул, майкаем. Хәзер борынын җыерып, фуфырая башлый. Су дигәнең таза булсын аңа...»

Әмма ат бәрәңгедән баш тартты. Суган кыягыдай ямь-яшел сарут, гергелдәп торган кәрешкә үләне булганда, нишләп синең чи бәрәңгең белән ваклансын ул, дип нәтиҗә ясады Кәбир. Алтынчы бәрәңгесен дә көлгә күмде һәм учак алдына чүгәләде. Баш очында гына тагын да саескан шыкырдады. Лепкәсеннән алып үкчәләренә кадәр шом шыеп үтте малайны. Кайда гына юнәлсә дә, нәрсә генә эшләсә дә, нинди генә уйларга төшсә дә, Соры Бүре аны ычкындырмый, миенең аерым бер почмагын биләп алып, зиһенен һәм җанын туктаусыз борчый, бораулый иде. Капчык төбеннән пәкесен эзләп табып, аны чалбар кесәсенә шудырды.

Бәрәңгеләр изрәп пешкән иде. Ул аларны бераз учактан читкә тәгәрәтеп, кулындагы җәмкәгә охшаган аеры агач ботагы белән учакны ботарлый, көлләрен як-якка тарата башлады. «Бүтән өстәмим, бары көйрәп бетсен». Буы чыгып торган ярмалы бәрәңгене калган ипи сыныгы белән бергә тоя башлады. Өч бәрәңгене ул иртәнгә калдырды. Ярым ач булса да, ул аерым бер канәгатьлек белән корсагына сугып куйды—гөпелдәп тора, билләһи! Яр кырлачындагы эре яфраклы, кылыч кыяклы үләннәр өстеннән шуа-шуа төште һәм куш учлары белән туйганчы салкын су чүмерде. Хәзер аның корсагы чынлап та гөпелдәп тора иде!..

Учак, таркалса да, көйри иде әле. Малай янып бетмәгән төренбашларны, очкын көлтәләре очыра-очыра, бер як читкә ышырды, учак табырын бер генә ут күзе дә калдырмый, җиренә кадәр кырды һәм шул урынга коры-соры, аның өстенә яфрак-йофрак түшәп, үзенә түшәк хәстәрләде. Янар-янмас пыскыган төренбашлар өстенә бер кочак ботак-сатак ыргытты. Ул чытыртый-чытыртый яңадан тернәкләнде, аның соргылт ялкыны Кәбирнең борчек-борчек тир сипкеле баскан йөзен, сүстәй аксыл чәчләрен яктыртты. Черки куарга да, җанварларны куркытырга да ярар, дип уйлады ул.

Инде хәзер бөтен кайгы Бамбукта иде.

Бамбук тирә-ягын табырдай кырып, яңадан алга ыргыды. «Ашасын. Авыр булса да, йөреп ашасын. Иң мөһиме—малның тук булуы. Ничек тә кайтып җитәрбез әле».

Ул атның башын күтәртеп, учак яктысы төшкән күзләренә текәлде.

— Ятыйммы, Бамбук?

— Ят, Кәбир. Ял ит.

Кемдер аңа шулай диде. Әллә чынлап та Бамбук үзе телгә килдеме? Көне буе диярлек беркем белән бер кәлимә сүз дә алышмый кешe сүзен сагынган малай ап-ачык итеп, үз колаклары белән ишетте: «Ят, Кәбир. Ял ит».

— Мин барыбер йокламаячакмын, Бамбук. Мин бары тик ятып ял гына итәчәкмен.

— Йокла, син бит бик арыгансың,—диде аңа байтал.—Мин сине саклаячакмын. Соры Бүре безне тапмас, борчылма...

Малай бу могҗизадан үзе телсез калган иде. Эндәшергә итә—өне юк. Ышану-ышанмау аның өчен хәзер вак мәсьәлә. Әйе, кара урман төпкелендәге ике тере җан иясе нигә телсез булырга тиеш тә, нигә алар сөйләшмәскә тиеш?! Ул Бамбукның башыннан кочып, тагын да күзләреннән үпте. Шулчак йөгәннән өстерәлгән өзек дилбегәне шәйләде. Аны боҗрасыннан ычкындырып, очын очка түгәрәкләп җыйнады һәм капчыгы өстенә ыргытты. Тагын да тирә-якка колак салды. Бар дөнья тын иде. Шулчак ул кинәттән, уйламаганда гына, үзенә нәзер әйт-

те — әгәренки исән-сау кайтып егылсалар, һич кенә дә бишенчегә укырга бармаячак. Укып мулла булмассың, чукып карга булмассың. Укып кем баеган? Әнә, инәсенә никадәр авыр бирүзе дөнья көтүләре. Юк, укымаячак ул. Сәми бабасына алмашка ат караучы булып барачак. Кәбир бер генә нәрсәне дә аттан артык яратмый. Беренче чиратта Бамбукны аякка бастырачак. Аның колыннарын үстерәчәк. Колыннарыннан — кырыкмыш, кырыкмышлардан — тай, тайлардан бар тирә-якка даны таралган айгырлар, чабышкы атлар тәрбияләп, аның нәселен бөтен дөньяга таратачак...

Үзенең гали уйлары белән әсәрләнгән малай, Соры Бүре һәм башка җанварлар һөҗүм итә калса дип, урман эченнән чукмар сыман имән кисентесе алып чыгып, аны учак кырына куйды. Капчыгыннан дилбегә өзеген чыгарып, Бамбук йөгәнендә сөйрәлгән өзеккә төйнәде һәм дилбегәнең икенче очын үз аягына бәйләп, яфраклар аша буланып яткан җылы урынга сузылып ятты. Урын чынлап та җылы иде. Җиде кат бисмилла әйтеп, бала чактан күңелендә сакланган ырымны тәкърарлады: «Ләкәп-ләкәп, ләйли ләкәп, авызың — карыш, телең — тартыш, безне капма, үзеңне кап!»

Тып-тын. Бары тик Бамбук кына керт-керт үлән өзеп бу тынлыкны бозып куя.

Ул күккә карады. Зөһрә йолдызны күргәч, тагын да инәсе исенә төште. Кайтты микән әле Кыргыздан? Әллә пркарул һаман да ябып тотамы? Күз алдына яшел бәпкә үләне, тупса тирәсе, зәңгәр ташлар белән түшәлгән ишек алды, калай түбәле, әмма череп, һәр төшеннән яңгыр үткән карагай йортлары, хуҗасыз калган нигездә каңгырышып йөрегән кәҗә бәтиләре килде. Төнгелеккә абзарга ябарга онытмый микән аларны күрше Хәмдия әбисе? Их, очып кыналар кайтып булса! Малай тагын хыял дәрьясына чума. Менә ул Бамбук белән ихаталарына килеп керә... Килеп керүгә, ни күзләре белән күрсен — Бөкебаш белән Ярар Ярыяхмәтләр инәсе алдына тезләнгәннәр дә, аңардан гафу үтенәләр. Гафу итми инәсе. «Ятимә хатыннарны, ятим сабыйларны башка беркайчан да рәнҗетмәячәкбез, дип ходай тәгалә алдында ант итегез!» — ди. Кәбир исә арттан эре адымнар белән генә килә һәм Бөкебашларны алмашлап камчы белән каезлый башлый... Ялваралар адәм актыклары, юк, гафу итми Кәбир, гафу итми!

Ерак бабасы белән ерак әбисен дә бик сагынды ул. Молотов яклары урманнарында акылын җуйган ерак бабасын халык ихтирам итә, ахры, шуңа күрә аны бервакытта да ямьсез итеп «акылдан язган» дип исемләми, ә йомшак итеп кенә «алмашынган Хисам» дип атый. Үлем түшәгендә ята инде ул. Ашказаны кипкән, диләр ерак бабасының. Ничек була икән ул ашказаны кибү? Совхоз ягына чыгып сызуы хакында ул бит ерак әбисенә дә, хәтта җан дусы Хариска да әйтмәде. Сер итеп саклады. Ә йолдызлар бүген кайда булган? Бер урынга озак карап торгач, ул йолдызларның бихисап икәнлеген ачыклады. Менә кызык, йолдызларны күп итеп күрәсең килсә, күкнең бер урынына текәлеп карарга кирәк икән. Димәк, йолдызлар ялгыз булырга яратмый. Аркасына, аркасыннан бөтен тәненә таралган җир җылысыннан ул үзен оҗмахта итеп тоя иде. Җир шары әйләнә, әйләнә... Менә күп тә үтми, җир шарын бишек иткән малай үзе дә сизмәстән тирән йокыга тала.

...Бүре китергән казадан соң өйдән кунак тойгысы качты. Әбисе белән бабасы аларны ничек кенә тынычландырырга, юатырга тырышсалар да, инәсенең һәм Кәбирнең күңеле юлда иде. «Күргән кебек тә булмады бит ичмасам, тагын берне куныгыз инде», — дип әбисе бик ялваргач, инәсенең тыңламый хәленнән килмәде. Хәер, ул көн һич кенә дә бушка үтмәде: Әндри абзый зур мал духтырын алып килеп, атны яңадан карадылар, аның бәкел сөяге чәрдәкләнгәнлеген, хәлбуки тиз генә төзәлмәячәген, кимендә ике-өч ай вакыт кирәк булачагын кисәттеләр. Яңа дарулар белән бергә, Муса бабасы бик үтенгәч, атның нинди

бәлагә таруы хакында йомышлы кәгазь дә язып бирде зур дух-тыр — кайткач, түрәләргә күрсәтергә кирәк булыр, янәсе.

Атны тәрбияләү бурычын Муса бабасы үз өстенә алды. Бераз тернәкләнгәч, хәбәр итәчәк һәм Кәбирләр аны килеп алачак. Иртәгесен аркаларына үзләре күтәрә алганчы бәрәңге, он һәм коры юл азыгы йөкләп, юлга чыктылар. Инәсе әйтүенчә, хәерле сәгатьтә кузгалган булганнар, күрәсең, Кәрештән соң аларга Дала МТСына ягулык алырга баручы йөкчеләр очрады. Алар арбасында шактый ара үттеләр, рәхмәт төшкере. Калган егерме чакрымы җәяүгә төште. Кәбир сизенде — инә-сенең авылга якты көздә кайтып керәсе килми иде. Кичке шәфәкъне алар Имәнлек урманында көттеләр. Әнә, аста, үзәнлектә, сирәк-саяк утлары белән җемелдәп, Бүләк тә шәйләнде. Авылга якынлашкан саен икесенең дә йөрәкләре урыныннан купты. «Синнән дә сорарлар, бала-каем, икебез бер сүздә булыйк,— диде инәсе.— Урынсыз әйтелгән бер хәбәр башыбызга җитәр, балакаем».

Өйдә җиназа тынычлыгы хөкем сөрә иде. Болай барысы да исән торган.

Төне буе күзен дә йоммады Сания. Иртән Бөкебаш белән очрашуны күз алдына китереп, берсеннән-берсе ачыграк җаваплар эзләргә ты-рышты. Бер төн эчендә кичергән вакыйгаларны ул кырыкмаса кырык тапкыр төйнәп, кырыкмаса кырык тапкыр чиште. Таңнан торып, Сабыр үзәне буйлап, яшертен генә ат абзарына барды. Юк, кешедән куркудан түгел. Аның авылда иң беренче итеп Сәми картны күрәсе, аның белән киңәшәсе килә иде. Әмма ул төнге ат кунасыннан кайтмаган булып чыкты. Абзар эченә кереп, шактый гына көтте. Ниһаять, атларын һау-һаулап, кунадан Сәми дә кайтып төште. Коедан улакка шабыр-датып су салып маташкан арада үз янында ак чәчәк кебек кенә көтмәгәндә калкып чыккан ак күлмәкле Санияне күреп, шаклар катты:

— Пәр-рә-мәч! Син ничек болай тиз әйләндең?

Хәлләрне сөйләп бирде Сания. Мәсьәләнең аешын тиз төшенде карт. Ахырда, тәмәке төтененнән саргаеп беткән мыекларын боргалап:

— Бамбук, кәнишне, бик тә җәлке, майкаем. Бик тә чыдамлы ат иде, майкаем...

Картның үзен артык тыныч тотуы охшап бетмәде Саниягә. Аның уйлавынча, Сәми аны нык кына кыздырырга һәм ниндидер акыллы киңәшләр белән ярдәм итәргә тиеш иде. Шулай да сиздермәде хатын.

— Нигә «иде» дисең, Сәми абзый,— диде ул үзен тыныч тотарга тырышып.— Ат бит исән, кайтыр, ходай кушса...

— Кем сиңа кайтмас дип әйтә? — Картның кашлары җыерылып маңгайга сикерде.— Әмма әлегә бит ат юк! Ничек җавап бирәбез? — Са-ния нәкъ менә шундый сөйләшүне көткән иде.— Нык торың! Бирешмәң, майкаем! Рифкәмиссигә елыш. Сабирҗан һәйбәт кеше. Күр, сөйләш. Җаен тап, майкаем...

— Ничек кенәләр җаен табыйм инде мин аның. Алар барысы да бер чыбыктан куылган инде...

— Туктаң, кызып барма, майкаем. Ат караучы гына булсам да, аларның арасын яхшы беләм мин! Безнең персидәтел Галләметдин әйткән сүзгә мөһер сугучы гына бит ул... Ә Галләметдинне беләсең, збирнең збире... Шуңа күрә, сиңа ике юл бар: тап үзеңдә көч, сыйла Галләметдинне бер тапкыр! Елмаерга тырыш, майкаем! Икенче яктан Сабирҗанны ныгыт. Рифкәмиссидән, ай-һай, шүрли ул!..

— Нәселемнең тамырына балта чапкан кешене алай хөрмәтли алмыйм инде, Сәми абзый, гафу итәрсең...— Сания елар чиккә җитеп, башын читкә борды.— Анысы миннән булмас!

— Аптыраганнан әйтәм инде...— Сәми карт бераз тын торды. Ан-нан, кулларын җәеп, һаваны кисте.— Ә ул синнән күпме ыздыбаться итәчәк... Их, кайда ул сугышка кадәрге ир-егетләребез!.. Юк бит, юк. Сания кәрдәш, барысын да алып китте, каһәрең...

Хатынның күңеленә яңа шомнар салды бу сөйләшү. Котелмәгәнчәрәк килеп чыкты шул. Әмма ул Сәми картны тирәннән аңлый. Ул аңа Галләметдингә сатылырга түгел, үзенә Галләметдинне сатып алырга куша. Мөмкин эшме бу?

Көтү куучы хатыннар әле кичә генә дүрт тәгәрмәчтә еракка сәфәргә киткән ахирәтләренең бүген туп кебек җәяү кайтып төшүенә аптырап калдылар. Яшермәде Сания. Дөресен сөйләде. Нәрсәсен яшерәсең инде аның — ат кадәр атны, энә сыман итеп, чүмәләдәге печәнгә шудырып төшереп булмый. Бөкебаш белән гомер бакыйдан килгән кискен мөнәсәбәтләрнең иң нечкә серләрен, Сания үзе дә белеп бетермәгән төеннәрен белгәнгә күрә, алар бригадирның бу вакыйгадан тулаем һәм уптым илаһым файдаланырга тырышачагын аңлап, сүзсез генә баш кактылар.

Учакка ут алып, казанга бәрәңге салды. Тутасы җибәргән оннан көнбагыш маенда булса да җәймә катырып алды. Аргы очтан бирге очка таба чыбыркы шартлаткан тавышлар чыгарып эшкә өйтеп килгән Галләметдин тавышы авыл өстендә яңгырый башлаган иде инде. Йөрәккә төшү генә түгел, тешне камаштыра торган бу тавышның якынайганнан якыная баруын тәне белән тойган хатын үзен кая куярга урын тапмый, абзар-кура тирәсендә кычыткан урырга тотынды. Кулларын чактырып бетте. Ләкин куллар әрнеми иде нигәдер. Йөрәк әрнегәнгә, күрәсең. Менә ул утынлык түмәрендә кычыткан төя башлады. Балтасын өйтер идең... Килә Бөкебаш, килә... Әнә аның тавышы күпер төбендәге Суфия өянкеләре арасына чумды. Саниялэргә җиткәнче, урамның ике ягыннан санаганда, тугыз йорт калды. Тукта, кемгә дип төя әле ул кычытканны? Тавыксыз калды түгелме кышкы чиләдә? Онытып тора тагын. Алты тавыгы берьюлы мырлады бит быелгы зәмһәрир суыкларында. Тавык малы бер өшесә, һич кенә дә мантый алмый икән.

...Моннан егерме ел элек булып үткән вакыйгалар яңарып алды күңелендә.

Озак йөрде, озак сөйрәлде аның артыннан Галләметдин. Сания аны яратмады, дию генә аздыр. Яз житсә, җирләрен кешегә биреп торып, иген игү урынына әтисе белән бергә атлы килеш хәер сорашып йөргән өчен Галләметдиннән җирәнә иде. Кызның башына һич кенә дә сыймый иде: бөтен әгъзаларың исән булып торып, егет кадәр егет ничек инде, ат җигеп, хәер сорашырга мөмкин? Икенчедән, төсе-кыяфәте белән охшамый иде Галләметдин. Тар маңгай, кушылган сары кашлар. Тирән чокыр төбендәге күзләрне тиз генә эзләп табарлык түгел. Нәкъ мәче башлы ябалак. Көндез кирәгән генә, төнлә кирәкмәгәнен дә күрә. Өченчедән... Әле үсмер чаклары иде. Галләметдиннең атасы Хафиз, ничек кирәк алай, гомерендә беренче тапкырдыр, Саниялэргә уракка ялланды. Үзе теләп шулай эшләдеме, әллә берәрсе котырттымы, Хисам һич кенә дә төшенә алмады. Шулай бер көнне кич белән, бик тә соңлап, Галләметдин килеп керә боларга: «Хисам хаҗи, әгәр буш итмәсәң, дошманнарыңның явыз эшен ачам»,— ди. «Ачма, Галләметдин энем,— ди әтисе шаяртып.— Мин аларны болай да беләм». Аннан егет исәбенә кереп барган үсмерне кызганып, аңа берничә көмеш суза. «Әтәй ике зуратың көлтәләрен кахулларга илтеп сатты. Тагын сатса, тагын килеп әйтермен».

Ышанмады Хисам. Кара төндә басуга китте. Зуратлардан чынлап та җилләр искән иде. Ике-өч тапкыр кабатланды бу хәл. Хафиз урлый, Галләметдине килеп әләкли. Ахырда атасы аларны, хезмәтләрен бәхилләтеп, басуга кертмәде: «Бисмилла әйтеп ашасам, кем, Хафиз кордаш, калганы да җитәр, шулай бит?» Бәйләнмәде атасы. Чөнки ярлылар комитетенә аз да түгел, күп тә түгел, нәкъ рәиснең үзе итеп сайлап куелган әтрәгәләм Хафиз тавыш чыгарганны гына көтә. Шуңа да үзен

иркен тота. Малаеннан үзен-үзе саттыра. Янчыкка вак булса да акча эшләтә. Низаг чыгарырга җай эзли. Галләметдиннең атасын сатарга өзер торуы һәм моның өчен беркемнең аптырамавы, кыз аңлавынча, дөньядагы иң зур вөҗдансызлык иде...

Бәләбәй укытучылар мәктәбен тәмамлап, авылга кайткан Хәлим мөгаллим белән яратышалар алар. Сукмакка аркылы төшкән Галләметдингә күп тапкырлар аңлатырга тырышты бу хәлне Сания. Әмма теге аңламады. Бер караганда, аңарда мәгънәсез көнчелек, тупас ишарәләргә яшерелгән түбәнсетү, котсыз һәм әдәпсез бәйләнүдән башка бер нәрсә дә юк кебек.

Әллә берәрсе котыртамы соң Галләметдинне? Чын ярату хисе булган кеше үзен шулай сәхнәдәге шикелле уенчак тота аламы? Сөйгәненнән яшерде Сания Галләметдиннең тупаслыкларын. Югыйсә, пычакка пычак килеп бетәрләр иде.

1929 елның көзендә җан сөйгән Хәлименә кияүгә чыкты. Галләметдиннең Саниягә генә түгел, инде аларга булган каныгуы көндәлек тәртипкә әйләнде. Чөнки бу арада партиягә, партия аша авыл советында сәркәтиплеккә үрмәләп алган Галләметдин өчен чиксез мөмкинлекләр ачылган иде. Дөрес, Санияләрнекенә караганда күпкә хәлсезрәк иде ул килен булып төшкән гаилә. Йорт-куралары өч тәрәзәле, салам түбәле өйдән, маллары исә бер сыер белән аттан узмаган иде. Әмма матур, килешеп яшәделәр. Хәлим бераз акча юнәткәч, күршедәге украин авылы Хлеборобтан калай түбәле иске йорт сатып алып, Бүләккә күчерделәр.

Бүгенгедәй хәтерендә, бер мәлне аларга, яртылаш күннән тегелгән галифе чалбарларын җилфердәтеп, Галләметдин килеп керде. «Пычкыңны ал, мәчет манарасын кисәргә барабыз»,— диде ул Хәлимгә. Йөрәге жу итеп китте Саниянең. «Чыгып кит, имансыз,— диде аңа тыныч кына инәсе.— Ә син, Хәлим улым, бу бусагадан минем гәүдәм аша гына чыга аласың. Хәзер аркылы ятам».

Чыкмады Хәлим. Екмады инәсенең сүзен. Кичен, ахшам намазы алдыннан, мәчет манарасы гөрселдәп җиргә капланып төште. Намазга килгән картларны Галләметдин куып тараткан, диделәр. Икенче көнне яңа гына оешкан район үзәгеннән тикшерүчеләр килде. Имеш, авыл хезмәтчәннәре өсләреннән язган — алар Хәлим Садрыевны икенче авылга күчерүләрен сорый. Ни өчен дигәндә, Хәлим Садрыев, укытучы һәм коммунист булуына карамастан, кешелек агуы — динне яклый икән. Шикаять расланмаса да, инде кулак атамасы тагылып өлгергән Хисамның киявенә мөртәбә өстәмәде ул. Галләметдин исә эзәрлекләүләрне көчәйтә генә барды.

«Йә бурычыңны кайтарасың, йә нәселеңне корытам»,— диде Саниягә урамда очраган Галләметдин. Нәкъ шулай диде, оятсыз. Нәселгә килгәндә, чынлап та корытты. Утыз беренче елның көзендә атасы белән инәсен, тутасы белән җизнәсен һәм бар тирә-якка билгеле гармунчы энесе Заһидулланы Акчунга, аннан Молотов урманнарына лагерьга озаттылар. Чират Санияләрдә иде. Хәлимнең коммунист булуы гына коткарып калды. Күптән башлы-күзле булып, ярыйсы гына хуҗалык та кораштырып җибәргән Хәбибрахман һәм Галирахман абзыйлары, ата-инәләреннән ваз кичүе аркасында, бу җәзадан акландылар.

Моның өчен берәү дә гафу итмәс аларны. Шуңа күрә бүген дә йөрешмиләр. Мең газап белән туган тарафларга кайтып егыла алган Зөлхиҗә туталары белән генә бәйләнеш тота ул. Ә менә Заһидулла энесеннән ничәмә-ничә ел инде хәбәр-хәтер юк. Кайдадыр Сталинабад якларында, дөресрәге, Куляб дигән кышлакта электр станциясе төзи, имеш. Мал-туарга, йорт-җиргә килгәндә, ун баш ат, унике баш сыерны күмәк хуҗалыкка тартып алдылар. Колхозда савымчы булып эшләгәндә ул сыерларны елый-елый сава иде. Чиләктә сөткә караганда күз яше күбрәк тоела иде Саниягә. Ярый әле атларны, тирә-якка даны киткән

Бурлы Бия нәселе, дип чит-ят хуҗалыкларга тараттылар. Алары, ичмасам, күзгә-башка күренми. Сәми карт әйтүенчә, имеш, Бамбук шул үзебезнең нәселдән икән... Ак өйләреннән бригад кәнсәсе, кара өйләреннән каравыл йорты ясадылар.

Ничек алып китүләрен онытырлыкмы? Атасы үткән кышта гына сигез бәрән тиресеннән камалы тун тектергән иде. Шул тунын киеп чанага утырган җиреннән сөйрәп төшерде аны Галләметдин. Тунны салдырып алды да, әйбер-сәйбер төялгән икенче чанага ыргытты: «Дәүләт шулай куша. Экспрация». «Экспрация»се, кеше суыкта туңып үлсен, дигән сүз булды микән ниде? Алмашка чыпта ыргытты Галләметдин. Заһидулла энесенә итеген кияргә дә бирмәделәр. Оекчан китте. Туган нигезеннән ерак юлга шулай чыптага төренеп чыкты ирексез куылганнар. Авыл очына хәтле артларыннан йөгереп барды Сания. Атлар шәп иде шул. Камчылар да уйнап кына торды. Әллә кемдер типте, әллә үз итәгенә абынып егылды, башкасын хәтерләми. Башы нык бәрелгәнен генә хәтерли.

Галләметдин Акчуннан яңа кама тунда кайтты. Хисам хаҗи тунына алыштырган, дип сөйләде халык.

Юньле-рәтле укый-яза белмәсә дә, Галләметдин сугышка кадәр авыл советында рәис булып та эшләп алды. Эчкечеллек белән шөгыльләнгәне, хатын-кыз белән уйнаш иткәне өчен власть башыннан төшерделәр үзен. Әмма карга карганың күзен чукымый, диләр. Хисапчы итеп куйдылар. Авыл келәтләренә тагын да якынрак булды. Сугыш башлану белән Галләметдин дә китте. Бер елдан урап кайтты ул. Уң кулының баш һәм имән бармагы юк иде. Янвалид, диделәр. Икенчеләр, үзенә-үзе атып кайткан, дип тә сөйләделәр. Сугышның соңгы чорында колхоз рәисе булып та эшләп азапланды. Юк, мантытмады халыкны Галләметдин. Инде килеп, бригадир итеп күчерделәр. Чума да калкып чыга, чума да калкып чыга. Сирәк сәләткә ия булган җитәкче, күрәсең.

Билгеле булуынча, Галләметдиннең яшәү гамәле өч фасылдан тора: айнык, исерек һәм махмырдан башы авырткан чак. Ниндидер үтенеч, эш турында сөйләшү өчен халык аның икенче фасылын кулайрак күрә. Җир астыннан табып булса да эчерергә тырыша, ягъни тагын шунысы кызык: айнык чагында кеше белән эт кебек ничектер ырылдап кына сөйләшкән, холкына туры килмәсә, сынмас җирдә дә шарт сындырган бу адәми зат ылкынганчы эчеп, халык әйтмешли, судагы агач кебек бүртенеп, «йөзе килгәч» кенә күңеле белән йомшара, яхшыра, хәтта ки көлә, җырлый,— һәм иң аптыратканы! — хәтта дә ки елый башлый... Әйе, вакыйган, елый! Мондый чакта урамда очрадыңмы, беттең — туктата, кочаклый, елый... Тимгел-тимгел булып бүртенгән битләреннән гөрләп яшь ага. Айнык хәлдә кеше елатып, инде исерек хәлдә үзе үк елаткан кешесенә елый алу, үзен кызгандыру сәнгатенең нечкәлекләренә төшенеп алыпмы, әллә табигатеннән шулай яратылыпмы, Галләметдиннең бу фасылы беркатлы, эчкерсез, берсе-берсен чакмый, кинә кумый, түгәрәкләп әйткәндә, туганнарча килешеп яшәгән авыл халкын ярыйсы гына оста алдата иде. Түзә мескенкәй халык. Аек чагында кеше өчен — тәмуг, исерек чагында — оҗмах иясе, янәсе. Икесе дә бер үк Галләметдин. Әмма аның иң көйсез сәгатьләре махмырдан изелгән мәлендә. Күзенә чалынасы булма. Хәер, бригадирның әллә ни чалынырлык күзләре дә юк иде. Күз чокырлары тирәсен, дөресрәге, күз карасы булырга тиешле урынын аклы бөҗралар ураткан. Катык тек катык. Ябалак тек ябалак. Һич тә юкка атамаганнар. Дөрес, соңгы елларда Ябалак атамасын сирәгрәк куллана халык. Ябалактан Бөкебашка әйләнде Галләметдин. Аннан килеп, өченче исем дә бик җиңел генә чәпәлде аңа: «Җылак». Юлбашчыларының шушы өч хәлиткеч сурәтен бик төгәл чагылдырган бу ләкабләр көндәлек кулланылышта авылдашларына күп кенә бәлаләрне алдан сиземләргә ярдәм итә. Әйтик, кемдер берәү икенчесеннән: «Бригадирны күрмәдеңме?» — дип

сорый. Тегесе һич тә аптырамый, тыныч кына итеп: «Күрдем Бөкебашны, ник күрмәсен, ди, әле генә келәтләр тирәсенә менеп бара иде»,— дисә, күр дә тор, Галләметдиннең аек чагы. Күзенә чалынасыңмы, юкмы — үзең хәл ит, абзый. Әгәр инде бригадирны Ябалак дип җибәрсә, бел — башкайлары чатнаган, иреннәре ярылган, күз алларының яшелле-зәңгәрле чагы. Аһ, әшәке ул чакта бригадир, аһ, кансыз, мин сиңа әйтим!.. Әгәр Галләметдинне Җылак дип атаса, күңелеңне киң тот: хисе ташкан, синең хәлеңне синең үзеңнән дә ныграк аңлаган, ул гына да түгел, елый-елый ихтирам, чиксез сөю таләп иткән мизгелләре...

Килә Галләметдин, килә...

Атының тояк тавышы инде Хәлимә салып киткән келәт артыннан ишетелә... Сания утын түмәреннән башын күтәрде һәм, эчтән калтыранса да, тыштан сер бирмәскә тырышып, җил капка түренә атлы казак кебек кадакланган затка таба атлады. Сания аның хәләтен ачык кына чамалый да алмады. Сизенүенчә, Ябалак чагы — махмыр чагы иде шикелле. Беразга сүзсез тордылар. Сул кулы белән тезгенен кысып, уң кулында кара камчысын өерелдергән Ябалак: «Менә эләктеңме инде, кошкаем?» — дигәндәй, кәкре танау буеннан гына мыскыллы караш ташлап, хатынның нәрсә әйтерен көтә иде.

— Аяк өсте генә аңлатырлык эш түгел, Галләметдин... Бәлки, өйгә керерсең...

— Мин чәй эчмим! — Бригадир кырт кисте.— Аннан, чинең белән нәрчә турында чөйләшергә мөмкин инде? — Ул авыз чите белән генә елмаю сирпеде. Галләметдин әле былтырдан гына «с» хәрефен әйтә алмый башлады. Ул «ч» сыман чупылдап ишетелә. Кайчак «ш»сы да «ч» булып яңгырый. Берәүләр сөйләвенчә, күрше Галләметдиннең тешен Кәртәле авылыннан иргә чыга алмый җәфаланган депутат Сәҗидәне бүлешкәндә шул ук авылдан салым җыю агенты Канзәфәр сугып сындырган. Икенчеләр әйтүенчә, исерек килеш егылып имгәткән, имеш.

— Син мине тыңларга тиештерсең бит инде,— диде Сания елар чиккә җитеп.— Алла хакы өчен...

— Мин чинең алланны чабанга да, лабагрикка да җигә алмыйм! — Бригадир тирә-якка ишетелсен дип, күрәсең, тагын да ныграк кычкыра башлады.— Чинең аллаң-муллаң төкерә безнең колхоз труттиненә...— Аннан, иелә биреп, оятсыз рәвештә күз кысты.— Ызначит, Трытий Ынтырнационалның икенче атын да чуга чалдым, дичең инде?!

Сания йөрәген тотты. Икенче ат дип Ябалак моннан ике ел элек Акчүн станцасыннан орлык ташыганда йөгенеп, тәртә арасында җан биргән Ләвәнгә ишарә ясый. Ул көрчеккә терәлгән иде, ахрысы. Сания кулыннан үтте ул. Юлдашларыннан артта калган хатын нишләргә белмичә алдына-артына карады. Юк, җилекләргә үтеп сайраган кичке февраль салкыны һәм зәңгәр карлардан башка бер җан әсәре дә күренми иде тирә-якта. Ачлыктан һәм авыр хезмәттән йөрәге ярылып үлгән атның күзләре туңып, сөяккә әйләнеп барганда ул һушына килде — үзе дә туңып үлә түгелме? Ике чакрым чамасы арада җемелдәп шәйләнгән чуваш авылы Суккул утларына карап йөгерде. Авыл советы рәисенә рәхмәт. Атның вафатына тиешле кәгазьне язып, Санияга тоттырды да телефон аша авыл советы урнашкан Кәртәлегә шалтыратты. Өченче Интернационал ат үләксәсен кайтарып азапланмады, чувашларга сабынга калдырды. Чанасында калган бодай орлыгын Сания өлкән улы Гадел белән бәләкәй чанага җигелеп ташыды. Тагын да дөресрәге, Галләметдин ташытты. Хатынның йөрәгенә кадалырга теләгәндә ул һәрвакыт менә шушы Ләвән вакыйгасын искә төшерми калмый.

Сания күз яшьләрен тыя биреп, совхоздагы җизнәсенең абзарына бүре төшүен, атны җәрәхәтләвен, мал духтырының Бамбукны һичшиксез төзәләчәк дип ышандыруын, атын хәзергә ышанычлы кулда — җизнәсе кулында тәрбиягә калдыруын һәм, ниһаять, ат төзәлә биргәч, аны

үзе үк алып кайтачагын, тагын да әллә нәрсәләрне, әллә нәрсәләрне өзгәләнеп аңлатырга тырышты.

— Мине чуган чуы чыгып ычандырырман димә.— Ябалак камчы сабы белән итек кунычына суккалап алды.— Мин чинең күз ячеңне чпрафкы итеп терки алмыйм! Ат кирәк миңа, ат, тере ат, Чания!

Санияның күзләрендә өмет очкыннары тернәкләнеп куйды. Онытып тора икән ләбаса!

— Бар, спрафкысы-ние бар! — Ул калтыранган куллары белән алдан өзерләнеп куелген кәгазьне кесәсеннән чыгарды.— Менәтерәк!.. Мөһере-ние сугылган...

Ябалакның төпкә баткан күзләре тирәсендәге ак бөҗралар кинәттән генә карайды. Ул «мөһере-ние сугылган» нәмәстәкәйне һич кенә дә көтмәгән иде булса кирәк. Корбанына ташланган козгындай алга омтылып, кәгазьне Сания кулыннан йолкып алды һәм дүрткә бөкләнгән язуны эре генә кыяфәттә астын өскә, өстен аска әйләндереп караштырда да, бөтен авылга ишетелсен дигәндәй, кычкырып җибәрде:

— Беләчеңме, нәрчәгә ярый чинең бу филкин грамытың? К...мне чәртергә дә ярамый бит ул! — Ябалак чынлап та үзе әйткән гамәлне башкаргандай итеп, арт ягын ышырып алды һәм йомышлы кәгазьне пәрә-пәрә ертып, җиргә орды.— Менә нинди дүкәмәт күтәреп кайтканчың чин!..— Аннан черек тешләре аша черт итеп төкерде дә тагын ырылдады:

— Эшкә җелпе тартырга барырчың. Планың үтәлмәгән.

Һәм китеп барды.

Таланган каурыйлар сыман һавада тирбәлә-тирбәлә җиргә очып төшкән кәгазь кисәкләрен кыенлык белән учына җыйды да, өенә кергәч, бер кирәкмәсә бер кирәгер әле дип төйнәп, ышанычлы урынга куйды. Галләметдиннең бу кыйланышы аның яшьләрен киптереп алган кебек булды. Ниндидер өмет, ниндидер ышаныч булганда гына елый икән кеше җаны. Ышаныч дигәнең бетсә, яшьләр дә кибә икән.

Зелпе тамыры тартудан да мәгънәсез авыр, файдасыз җәфалы эш юктыр җир йөзендә. Үзенең кара акылы белән зелпе каерысыннан машиналарга эрзин кәпчәк булуына ышанмый иде Сания. Кеше җанын рәнҗетү, түбәнсетү өчен менә шушы Галләметдиннәр эзләп тапкан михнәт итеп карый иде ул аңа. Иң аптыратканы тагын: дошман белән көрәшкәндә түгел, дошманны җиңгәч китереп чыгардылар бу җәфаны. Балтырган шулпасында җан саклаган, ачлыктан шешенә башлаган адәм баласын тәмам йөгендерү өчен эшләнмәде микән ул? Ел саен йорт башына берәр поттан зелпе каерысы салымы салалар; ул кадәресен ишле гаиләләр дә үти алмый; әмма зелпе тамыры катып, суелмый башлаганда кул тиресе мунчалага әйләнә, бармак очларыннан кан тамгандай итә; урман эчендә казынып, сукыр тычканга әверелгән хәлсез кешеләр зелпенең төче һәм ниндидер лайлалы исен сиземләү, шул каерыны күрү белән укшый башлый; монысына гына алар түзгән дә булыр иде, бәлки; алар мең сыкрау белән җир астыннан суырган «елан кабыгы»ның башлап колхоз келәтендә, аннан Акчун келәтләрендә кызышып, череп ятуын күреп, тагын да мең кабат сыкрый...

Кәбирне төмле йокысыннан уятып, тамак туклыгы иткәч, алар капчык һәм көрәкләрен алып урманга юнәлделәр.

Өч көн борчымадылар Санияне. Өч көн буе зелпе тартып, кулларын кабарта-кабарта җиткерелгән салымны үтәргә тырыштылар. Шулай йомылып кына эшләсәләр, бәлки Галләметдин дә ул кадәр каныкмас, намусы килеп, бераз булса да йомшарыр, дип уйлады беркатлы ана. Ревкомиссия рәисе Сабирҗан да шундыйрак киңәш бирде: «Әлегә тавыш-тыннары чыкмый, Сания түтәй. Әгәр эш зурга китәсе булса, мин үз сүземне әйтми калмам. Фронтовик, коммунист укытучы бичәсе, диярмен. Ләкин, беләсең, колхозыбыз рәисе Зәйнетдин абзый бозауның

бозавы бит. Галләметдингә шул гына кирәк. Күзгә чалынып барма, әйткәнеңне үлчәп сөйлә...» Ертып ташланган кисәкләрдән яңадан ябештерелгән йомышлы кәгазьне күрсәткеч, Сабирҗан аны сакларга кушты.

Ат казасын зурга җибәрмәс өчен Сания гомердә ясамаган адымын да ясады. Шулай, тормыш дигәнең дуңгызга да җизни дип әйттерә икән. Сабырбашы дигән чуваш авылына төнлә барып, таңда кайтты ул. Һәр кышта бау-бау җитен һәм киндер сүсе күтәреп килеп, Саниядә утырмада ятып, төннәр буе серләшә-серләшә, бик моңсулаган мәлләрдә чувашча һәм татарча җырлар җырлап җеп эрләгән пелеше — үзе кебек үк ятимә, үзе кебек үк солдатка Плагидан бер чирек чамасы «төнлә туган нәрсә»не — ягъни чөгендер самогоны да алып кайтып яшерде. Кем белә, Ябалак килеп керер, бәлки. Әйдә, лыкынсын, бәдбәхет. Әмма кермәде Ябалак. Капка аша ырылдап кына китә торган булды.

Юк, шома гына басылмады ат казасы. Атның хакын гомере буе түләргә әзер булса да, ул нахак бәлаләрне күтәрергә, аңардан башкаларның файдаланып калу мөмкинлеге белән килешергә һич кенә дә әзер түгел иде Сания.

Дүртенче көнгә чыккач, кояш нәкъ төшлектә торганда, аны кәнсәләргә чакырттылар.

...Инәсенә ияреп, Кәбир дә барды. Аларны кызыл җөйле шәмәхә-зәңгәр фуражка участкауай Сәйфуллин, колхоз рәисе Зәйнетдин абзый һәм Ябалак үзе каршылады. «Без инәңне генә чакырттык»,— дип, Кәбирне тышка чыгарып җибәрделәр. Такта белән генә бүленгән эчке бүлмәнең ишеге ябык булудан файдаланып, Кәбир тышкы ишекне чак кына кысып куйды. Һәр сөйләнгән сүз, һәр уфылдау аңа түгелми-чәчелми килеп җитә иде.

— Гражданка Садрыева Сания Хисамовна?

— Әйе.

— Әти-әниегездән хәбәр-хәтер бармы?

Участковый куылып алып кителгән Хисам хаҗиның акылдан язгач кына акланып, авылга кире кайтарылганын белмәмешкә салыша иде.

— Алар бит кайттылар.

— Шулаймыни?! — Сәйфуллинның ясалма куанычы, ихлас елмаюга әверелә алмыйча, маңгайга сикергән кашларда катып калды. — Шулаймыни... Без белмичә дә торабыз. Ни хәлдә яшиләр? Уллары ярдәм итәме?

— Әйбәт яшиләр. Уллары да ярдәменнән ташламый. — Сания алдашты.

— Карагыз әле, гражданка Садрыева, сез Бамбукны үзегезнең раскулачивать ителгән ат нәселеннән икәнлеген белеп зыянлаттыгызмы? Җизнәгезгә сугымга калдырдыгызмы?

Малайның йөрәге елк итеп куйды: Бамбук чынлап та аларның нәселеннән микәнни?

— Мин Бамбукның безнең ат нәселеннән булуы хакында беренче мәртәбә ишетәм,— диде Сания батырая төшеп. — Мин бит ат нәселен тикшереп утырмыйм. Аннан... Бу вакыйгаларга күпме гомер узган, күпме сулар аккан. Буласы булган, буявы сеңгән...

— Бик сеңеп бетмәгән шул,— диде көлемсерәп Сәйфуллин. — Җизнәгезнең абзарына берничә дә бүре төшмәгән. Совет властенең борынгы дошманы аның аягын махсус сындырган һәм, соң булса да уң булсын, дип киткән малын кире үз кулына кайтарырга уйлаган. Белсәгез килсә, ул инде аны суеп та ашаган!..

— Булмас! — Сания кычкырып җибәргәнен сизми дә калды. — Бамбукның безнең нәселдән икәнлеген раслый алырлык кеше юк хәзер... Юк андый кеше! Минә бу йортның... сез миннән сорау алган йортның безнеке икәнлеген һәркем раслый алыр, ә менә атның... Юк, юк!..

— Тынычланыгыз, гражданка Садрыева. — Участковый күн планшеткасында актарынды да, аннан соргылт кәгазь китереп чыгар-

ды.— Сезнең алдан уйлап эшләгән җинаятегез һәм җизнәгезнең атны суеп, Понамаревка базарына чыгарып сатуы турында безгә уникe кеше кул куйган жалу килде...

— Ялган!.. Ә кемнәр кул куйган ул жалуга?

— Бик күпне белергә теләмисез микән? — Участковый мыскыллы елмайды.— Ә мена монысын белү зарар итмәс... Хәтта мәҗбүри! 1947 елның 4 июнендә кабул ителгән Указга нигезләнәчәк хөкем сезнең башыгызны төрмәдә черетергә җитәчәк. Бер башак — бер ел төрмә! Ике башак — ике ел төрмә!.. Ә монда ат бит, ат!.. Атны сафтан чыгару — колхозны сафтан чыгару дигән сүз, понимаете? Саботаж! — Сәйфуллин кызган табага тамызылган май шикелле чажлый башлады.— Икесенең берсе: йә атның хакын бүген үк түлисез, йә без эшне прокуратурага тапшырабыз.

Тезенә суктыларммыни — Саниянең кинәттән хәле бетте дә куйды.

— Хакын түләргә тагын...— Аның тавышы түмам йотылды.— Ат бит үлмәгән... Исән. Ходай кушса... Рәтләнер, үз аягы белән кайтыр. Менә, спрафкасы да бар.— Ул өстәлгә яңадан ябештерелгән кәгазьне чыгарып салды.

Ябалакның йөзе икегә ярылгандай булды.

— Бу нинди кырык корама тагын? — диде Сәйфуллин.

— Галләметдин ертып ыргыткан иде.

— Шуннан? Ерткан-беткән! Бу кәгазь корамасы ат түгел бит әле.

— Монандый уттай эч өчтендә ат кадәр атны чуга чалып кайтчын да, мин шушы филкин грамотка ышанып утырыйммы? — Ябалак хуҗаларча идән буйлап йөренә башлады.— Аны теләчә нинди авылда теләчә нинди фиршыл язып бирә!

— Барып тикшерегез. Совхоз качкан җирдә түгел ләбаса.

Участковый белән Ябалак бер-берсенә серле караштылар.

— Гражданка Садрыева, сез хөкем органнарына күрсәтмә бирмәгез. Барып тикшерергәме, әллә урындамы — анысын үзебез белербез. Онытмагыз, безнең барып тикшерү чыгымнарын сез үзегез күтәрәчәксез.

Болар белән сүз көрәштерүе ифрат та авыр иде Саниягә. Нәрсә эшләп утыра бу Зәйнетдин? Күзле бүкәнме, әллә колхоз рәисеме? Инәсен якларлык бер генә сүз дә таба алмый микәнни, илаһым, дип уйлап куйды Кәбир.

— Бирегез ат, мин Бамбукны тагып алып кайтам һәм сезнең гаепләнүләрегезнең нигезсез икәнлеген раслыйм,— диде инәсе җавабында.— Эштән азат итсәгез, җитәкләп булса да алып кайтам!

— Өч аяклы ат белән?! — Сәйфуллинның урындыгы шыгырдады.— Аксак атны алып кайтасыз, димәк? Ха-ха-ха!

Малайның зиһенендә көтелмәгән фикер уянды. Куркыныч, адәм ышанмаслык теләк иде ул. Маладис инәсе, каты тора!

— Ха-ха-ха! — Бөкебаш, төнге ябалак тавышлары чыгарып,каһкаһәләп көлде.— Инде чиннән өченче атны да үтертикме? Колхозда һәр әтрәгәләм өчәр атның бачына җитә башлача, юлбашчыбыз иптәш Чталин нәрчә дияр? Иртәгә печәнгә төчәргә торабыз, ә ул ат чорый. Човхозга барып, контр езнәңә ояламакчы итәчеңме.

— М... м...— Зәйнетдин абзый нәрсәдер әйтергә теләп, авызында ботка пешереп алды, әмма сүзе аңлашылмады.— М... м...— Ниһаять, соңгы сүзләре генә килеп җитте Кәбиргә.— Ул кадәрле кирәкмәс иде, Галләметдин... Фронтовик хатыны...

— Мин дә фронтовик! Безне бер дә кызганмыйлар.

— Тырыш хатын, дип әйтүем.

— Тырыч хатын, дип чабатажницаны яклап утырма инде,— Бөкебаш Зәйнетдинне кырт кисте.— Чинең мактаулы колхозницаң ат җигеп чыгып китте, атчыз кайтып керде...

— М... м...

— Сез гражданка Садрыеваның дәүләткә китергән зыянын үз өстегезгә алырга булдыгызмы? — дип ташланды Зәйнетдин абзыйга Сәйфуллин. — Колхоздан күтәртмәкче итәсезме? Власть вәкиле буларак, мин халык мөлкәтен разбазаривать итәргә юл куймаячакмын. Әгәр гражданка Садрыева атның югалткан эш көннәрен түләү турында менә бу йөкләмәгә имза сала икән, без покага эшне хөкемгә тапшырмый торачакбыз.

«Биз шома сөйли участкауай, — дип уйлап алды Кәбир, — кешене кысарга өйрәнеп беткән. Болар инәсен тәмам сындырырга, аяктан егарга итәләр шикелле».

— Кайдан алыйм мин андый акчаны? — дип үксү катыш сөйләп китте инәсе. — Авызымны ачсам, үпкәм күренеп тора... Исән ат өчен иске паласымны сатып, акча түләргә минем башыма тай типмәгән әле!

Барысы да бер мизгелчә тын калдылар. Зәйнетдин абзыйның гына авыр сулап мышнаганы саркыла иде ишекләр аша. Нинди чаралар белән өркетеп алганнар соң аны? Утлар-суларны кичкән ир-узаман нигә өстәлгә йодрыгы белән сугып: «Туктатыгаз әле бу кәмитне!» — дип чик куймый? Бәйләнәсе килмиме? Малай үз манарасыннан торып аңлый алмый иде.

— Димәк, э-э... сез обязательствога кул куюдан баш тартасыз?

— Анысы нәрсә тагын?

— Атның хакын... э-э... атның югалткан эш көннәре өчен түләү турында йөкләмәгез була ул.

— Баш тартам. Колхозчыларның гомум җыелышы хәл итсен.

— Бу явный саботаж, Садрыева! Шунысын онытмагыз: гаделлек безнең якта булачак. Димәк, үзегезгә үпкәләгез.

Урындык таралып китәрдәй булып шыгырдады. Юантык Сәйфуллинның янып пешкән, тир бөрчекләре белән капланган йөзе күз алдына килде Кәбирнең. Аның симез балтырлары итек кунычларын ярып чыгардай булып торалардыр. Әгәр бу күләгәдән кояшлы мәйданга чыгарсаң, Сәйфуллин йомарлам май кебек эреп бетәр иде, дип уйлады малай.

— Якламаячак чине колхоз! — Сүз бетмәгән икән әле. Күрәсең аны Ябалак тәмамлап куярга тиеш иде. — Нәчелең-ниең белән корыткычлар. Ил малын ачаган атаң түчәктә тартынып ята, езнәң Понамаревка базарында үз атым дип Трытий Ынтырнационал малын чата!

— Кагылмагыз минем нәселемә! — инәсе яшелле тавышлар белән бар булмәгә чәтрәңнәде. — Нахакка рәнҗетелгән кешеләрнең күз яшьләре бер килеп буар әле үзегезне... Телегез, гәүдә әгъзаларыгыз череп аксын! Сабыйлар хакы тәнегезгә тамуг чабырткысы булып чабыртсын!...

— Гражданка Садрыева!..

— Мир бетләре! Кандалалар! Имансызлар!..

Их, үзе атылып керер иде дә Кәбир, өчесен өч якка аткарыр, өстәлгә менеп басып, монда сез түгел, мин хуҗа, дип кычкырыр иде. Сез сасы кәнсәләргә әйләндереп, тәмәке төтене белән ысланган менә бу өй — ул минем картатамныкы! Сез утырган урындыклар, сез җиккән атлар да минеке! Сез алай бик эшлекле булгач, кайда соң сезнеке? Кара таңнан кара тир түгеп, балалары белән буразнадан чыкмаган Хисам картның сезнең алда ни гаебе бар?

Әйе, иртә өлгерткән иде сугыш сабыйларны. Көрәш әлифбасын карлы-яңгырлы буразнада Бөкебашлар камчысы астында үзләштергән Кәбир кешеләр даирәсен сыйныфларга бүлми-нитми генә бәһалый иде: аның авылында байлар юк, бары тик ярлылар гына бар, әмма бу ярлылар изгеләр һәм явызларга бүленә. Вакытыннан күпкә алда акылга утырган сабый аксакалларга хас тирән зиһен белән төшенә: алар кебек үк ярлының ярлысы Бөкебашка икенче ярлылар өстеннән власть кирәк, менә шул власть чыбыркыга әйләнеп, башкалар канына сусый, коргаксый башлый...

Инәсе елый иде.

— Гражданка Садрыева...

Әй, туйдырды да соң Сәйфуллин бу «гражданка»сы белән!

— Гражданка Садрыева, безнең рөхсәттән башка авылдан чыгып китәргә тиеш түгелсез. Сез тикшерү астында. Менә монда кул куегыз...

— Мин бер нәрсәгә дә кул куймыйм! — диде инәсе үзендә ихтыяри көч табып. Ул инде ярсуын баскан иде.— Нишләп әле мин туган җирне ташлап, кайдадыр чыгып китәргә тиеш? Куарга итәсезме? Бер кая да китмим мин!..

Кәнсәләр ишеге шәрран-яра ачылды. Малай читкә сикереп өлгерде. Аннан алсуланып һәм яшь белән парланып, инәсе килеп чыкты. Аның күзләре нәфрәт белән кайный, үңәче ут булып көйри иде.

Өйгә кайтып, сәкегә аугач та инәсенең сүзе шул булды:

— Тамагым чатнады, балакаем...

Кәбир йөгереп барып, бер чүмеч җылымса су алып килгәч, ул кулын селтәде:

— Юк. Юлдан яздыра язды, шайтаннар...

Эчмәде суны инәсе. Ул уразада иде.

Өч көн аларны бер кем дә борчымады. Әмма өйдән кеше дә өзелмәде. Бигрәк тә кичләрен. Инәсенең ахирәтләре ничек кенә булса да ярдәм кулы сузарга тырышалар иде. Холыксыз Бөкебашка каршы бергә көрәшкән солдаткалар чарасыздан бичара булып нишләргә дә белмиләр. Җан дусы Садыйка түтәй ярдәм юлын да эзләп тапты шикелле. Саниягә хәер рәвешендә акча җыеп, атның эш көннәрен түләргә кирәк, дигән тәкъдим ясады ул. Инәсе кискен каршы төште: «Тән авыртуы үтәр, җан сыкравы үтмәс. Көне-төне колхоз эшендә бушка изелеп, минем шунлык кына да хакым юкмыни? Бөкебашлар алдында мәмәйләнгәнем өчен Хәлим рухы һичкайчан да гафу итмәс бит».

Дүртенче көн дигәндә, иртән...

Әйе, бодай утарга барырга дип кенә торганда капка төбенә җигүле алмачуар килеп туктады. Арбадан башына карасу-зәңгәр фуражка, өстенә яшькелт китель кигән ир һәм яулыгы иңенә шуып төшкән хатынкай җиргә сикерде.

— Хәерлегә генә була күрсен... Силсәүиттәннәр, улым. Салым җыючы Канзәфәр. Тегесе липутат Саҗидә шикелле...

Кәртәледән, димәк. Бүлектән сигез генә чакрымда ята ул. Быел көз Кәбир бишенчегә шул авыл мәктәбенә барырга тиеш. Кешеләрен белмәсә дә, мәктәбен шактый белә: моннан өч ел элек ачлыктан шешенгән Кәбир берничә ай Кәртәле мәктәбендә оештырылган ачлар йортында тәрбияләнгән иде.

Керделәр көтелмәгән кунаклар. Җылы гына исәнләштеләр. Канзәфәрнең бүлтәеп чыккан галифесенең тез-янбашлары күмердәй кара күн белән көпләнгән. Аның кылычтай үткен һәм очлы озын танавы өйне тутыргандай итте.

Канзәфәр эшне тиз тотарга чамалады. Асылма сумкасын шапылдатып өстәлгә салды, аннан СССР гербы төшерелгән елтыр кәгазьләр тартып чыгарды.

— Бурыч, Сания апа, бурыч. Нишләтәсең инде, дәүләт галәиссәләм безнең дә өстән төшми. Барыгыз, диделәр, авылларга куып чыгардылар. Эткәләгез, тәрткәләгез, салымнар җыю планы үтәлми мөмкин түгел...— Агент дисбе сыман буынтыклы-буынтыклы бармаклары белән кәгазьләр актара башлады.— Садрыева, Садрыева... Тә-әк... Әһә, менә! Сезнең ярты еллык сөт заданиесе белән ничегрәк соң әле? Аһ, сыерыгыз зыянлады? — Аннан ул алтын тапкандай кычкырып җибәрде.— Үтәлгән, ләбаса! Укытучы-коммунист хатынының үтәмәве мөмкин дә түгел!.. Тә-ә-әк, ит заданиесе... Нишләтәсең, монысы да нурмыда икән. Йон? Монда азрак кына недабур бар барлыкка, ничава, көзге җонны тапшырырсыз, шулай бит? Тә-әк, йом-мыр-ка белән хөртерәк

икән. Йом-мыр-ка беләп хөртерәк.— Ул төмләп «йом-мыр-ка» диде.— Тавыкларыгыз вафат булды? Кызганыч. Нишләтәсең, үлгән артыннан үлеп булмый, Сания апа. Тә-ә-әк, йорт-җыр налогы... Самообложение... Заем... Подоходный налог... Нишләтәсең, түләп бетмәгән икән, Сания апа... Ә түләмәскә хакыбыз юк, шулай бит, Сания апа? Илебез хәрабәләрдә ята, империалистлар яңа сугыш белән яный. Украина белән Литвада бандитлар, Сания апа... Сталин бишьеллыклары хакына соңгы тамчыканыбызгача бирәчәкбез, шулай бит, Сания апа?

— Эчеләсе каннар эчелгәндер инде...

— Тс-с, Сания апа!— Канзәфәр кул аясы белән авызын каплап, Саҗидәгә карады.— Без бернәрсә дә ишетмәдек!..— Саҗидә исә чалыш елмайды, сул битендәге чокыры теләр-теләмәс кенә авызына таба шуышты.— Днепрогэс заемына авылда кем башлап язылды? Донбасс шахталарын аякка бастыру заемына кем беренче сукмакны салды? Син, Сания апа! Фронтовик хатыны! Нишләтәсең, бурыч, изге бурыч яшәтә барыбызны!..

Исемендә кан сүзе булса да, йөз җисемендә канның әсәре дә булмаган бу сары йөзле, шома сүзле агент бар тәр салымнарны да «шулай бит»ләр аша «Сания апа»латып чыкканда Кәбир Кралов урманнарында үскән балтырганга һәм анда рөхсәтсез сайраган сандугачларга гына түләү салынмаганлыгын аңлады. Сөт налогын ике түшәкнең берсен, алты мендәрнең икесен, чигүле тастымалларын, бирнә һәм мөһәр бүләкләрен, хәтта атасының күн акча янчыгына кадәр сатып түләде бит инәсе.

Әмма котелмәгән тикшерү эшнең башы гына булган икән. Беразга тынып калган Канзәфәр, гербы кәгазьләр өстендә мыжгып кайнашкан чебеннәрне кугалаштырды да, сүзне кайсы яктан китереп чәпәргә белмичә булса кирәк, аяк очларына күтәрелде, көяз кыяфәт белән күн тез башларын, галифесенең бүлтәеп чыккан корсак канатларын дерелдәтеп алды да, танау астыннан гына мыгырданды:

— Нишләтәсең инде, Сания апа... М-м-м... Түзәргә кирәк. М-м-м... Сезнең безгә... Безнең сезгә... ягъни безгә сезнең мал-туарны, йорт җиһазларны теркәп чыгарга кушылган... М-м-м... Әйдә, Саҗидә, булмаса, син әйтеп тор, мин яза барыйм.

Инәсе ап-ак булып агарынды. Үзендә эндәшерлек тә көч таба алмый, ул салкын мичкә барып, аркасы белән сөялде.

Иңбашлары күперчекле җитен сары күлмәк кигән Саҗидә, шуны гына көткәндәй, йортның хуҗасы сыман түргә атлады, чаршауны сыдырып, эчкә үтте дә, әйберләрне саный башлады:

— Дүрт мендәр! Ястык! Дөя җоненнән юрган, ике чүпрәк, бер асалы палас! Корама юрган! Тышлы тун!..

Малай атасыннан калган бердәнбер тос — тышлы тунны алалар дип куркып, сәкегә сикереп менде һәм, тунны каплап, кычкырып җибәрде:

— Бирмим!.. Монысын бирмим!..

Ул арада Саҗидә мич арасына чумып, ярым караңгылыктан әйтеп тора башлады:

— Бер бидрә сыйдырышлы җиз самавыр! Тимер казан! Савыт-саба, чүлмәк, кашыклар...

— Алары кирәкмәс.

Кәбир бу кәмитнең кәнсәләрдә булган сөйләшүнең өземтәсе, Бөкебаш белән Сәйфуллиннар кузгаткан пычрак эшнең башы икәнлеген аңлаган иде.

— Бу сандыкта нәрсәләр, Сания апа?— Агентның наган сыман тырпайган баш бармагы сандыкка төртеп күрсәтте.

Инәсе мич янынннан сүзсез генә кузгалды,менә-менә түгелеп китәрдәй мөлдерәмә диңгез кебек чайкалып, сандык кырына килде һәм, ябык күз кабакларын ачмыйча, гомер бакый биксез торган капкачны күтәрде.

Сажидә сандык эченә колачын салып, анда казына, актарына башлады. Саниянең үзе белән алып килгән бирнә чүпрәк-чапраклары, Хәлимәнә бүләк итеп чиккән күлмәге, Зөлхиҗә тутасы биргән күлмәклек тукыма, налог кәгазьләре, Хәлименең фронттан язган хатларыннан башка бернәрсә дә чыкмады казнадан. Сажидә сандык төбеннән кеч-кенә төенчек чыгарып, аны калтырана-калтырана чишә башлады. Сәке өстеннән төшкән Кәбир үзе дә шушы төенчек сыман гына булып кечерә-еп калды. Әмма инәсенә барыбер иде шикелле.

Депутат хатын төенчекне, ниһаять, чиште, аннан кәгазь төргәк, кәгазь төргәктән пар көмеш беләзек, пар алка, пар йөзек һәм асылташлы балдак китереп чыгарды. Өйне чебеннәр гөжләве басты. Сажидә төргәк кәгазен өстәлгә салып, кулы белән сыпырып тигезләде, бөкләнгән почмакларын йомшартты һәм кызганыч кеше хәленә керергә тырышкандай, киң елмаеп, инәсенә эндәште:

— Шушындый байлыкны похоронкага төрәләрмени, Сания апакаем! Бу бит мәңгелек документ, югалуы мөмкин... Сандыгыгыз да бикләнми бит ичмасам!

Канзәфәр нәрсәдер язды. Сажидәнең колак йомшакларында ялкылдаган алтын алкаларга игътибар итте Кәбир. Иске паласларны биләп алган чебеннәр өермәсендә мондый байлык табылачагын һич кенә дә көтмәгән хатын әле һаман һушын җыя алмый иде.

— Урынына куй.— Кинәттән генә тыны тыгылып калган Канзәфәр тагын кабатлады.— Урынына куегыз.

— Куймый нишләтим ди мин аны?! — Сажидә дулкынлануын баса алмаган көмешләрне яңадан похоронкага төрә башлады.— Иске авыздан яңа сүз, дигәндәй, менәтерәк! Безнең силсәүит сугышның беренче елында ук алтын-көмеш тапшыру буенча районда беренче урынны алган иде, дип кенә искәртүем, югыйсә... Ә монда барысы да исән-сау! Маладис, Сания апа, саклагансың...— Төргәк инде Сажидәнең учында иде.— Сарыкны сыйрагыннан, бүрене муеныннан асалар, дигәндәй...

— Куй диләр сиңа! — диде Канзәфәр ачуы чыгып. Сажидә төргәген сандыкка ыргытты. Агент аны үз кулы белән япты һәм йомшак кына итеп өстәде:— Әйдәгез, кәжәнкәне карыйк...

Чоланда хәлле заманнардан бушап, серәеп калган ыргак, түшкә элә торган тияклөрдән, иген ларларыннан башка бер нәрсә дә юк иде. Лар өстенә басып, хатын чормага менеп китте. Аннан тузанга йотылган тавышы ишетелде:

— Бу әрҗәдә нәрсәләр?

Бирелгән сорауга җавапны да көтмичә, каурыйлары таланган кошлар сыман битләре биткә аерылып, идәнгә «Коръән»нәр, «Әфтияк»ләр оча башлады.

— Иске китаплар,— диде инәсе хәлсез генә.— Мин бит китап күрмәгән ата баласы түгел. Укыштырам...

— Беләбез, Сания апа.— Канзәфәр чормага кычкырды.— Болары кирәкмәс. Төш.

Түбә кызуында пешенгән һәм бит алмаларына кадәр тузанга баткан Сажидә җиргә төшкәч тә өйгә үтте. Өстәл тапкырында эленеп торган көзгегә килеп, төзәтенә башлады. Әллә бәрәңге буыннан, әллә кичелгән чорларның божра-божра акшарлары белән тапланып, кайсы гына җиреннән карасаң да, йөзне бозык күрсәткән көзгедән ул үзенең мөлаем йөзен таба алмады. Ничек житте шулай төзәтенде дә болдырга чыкты. «Көзгене менә ни өчен исәпкә алмаганнар икән,— дип уйлап өлгерде Кәбир.— Безгә ярап тора ул. Безне бик матур күрсәтә ул.»

— Моны ничек аңларга инде, Канзәфәр туган? — диде инәсе, ниһаять, телгә килеп.— Тентү? Упыс?

— Юк, сез нәрсә, Сания апа? — Агент ак тешләрен җемелдәтеп көлде.— Эшебез шундый бит. Нишләтәсең инде...

Исәнләшеп, капкадан чыкканда агентның галифе чатлары тагын да киңәйгән, тагын да корсаклангандай тоелды Кәбиргә. Бөтен дөнья малы сыярлык дәрәҗәдә зур иде алар.

— Үсеп кенә җитим,— диде Кәбир тешләрен кысып.— Кирәкләрен бирермен әле мин аларның...

...Бамбук дөпелдәп сикереп, урын алыштырганда малай уянгандай итте. Әмма үзен таш сыман бастырган күз кабакларын ача алмады ул. Бит җепселләре тартышып ала, табигатьнең үзеннән килгән ниндидер нечкә сиземләү, ат белән аның арасындагы күренмәс җеп аны борчый, бимазалый, тик уянмый гына.

Таң аткан, кояшның баш түбәсе күренеп, нурлары урманны үтә телгәли башлаган иде. Кәбир ыңгырашты. Ул кычкырырга итте, тик тавышы гына чыкмады. Төш күрә иде ул.

...Алар Бамбук белән тау мәгарәсеннән киләләр, имеш. Кап-караңгы, имеш. Менә кайдандыр Соры Бүре калкып чыга да, аларга ташлана. «Бир миңа бу малайны, аны мин имезеп үстердем».— ди Соры Бүре Бамбукка. «Иһа-һа-һай!— дип кешнәп көлә Бамбук.— Аны син түгел, мин үзем имезеп үстердем!» Шулай ди дә, Бамбук Кәбиргә төшеп калган чабатасын кидерә башлый. Соры Бүге югала. Кайдандыр ике тояклы, тояклары алтын, мөгезле, мөгезе алтын гыйфрит пәйда була. Абзар иясе, имеш. Кулында фонарь. Мәгарә яктыра, баксаң, ул абзар иясе түгел, инәсе икән. Кулында мунчала. Гает бәйрәме алдыннан ташларны да мунчалалап юа, имеш. Аның артыннан кара ташлар агарып бара. Шуннан нәрсәдер шартлый, мәгарә дөм караңгылыкка чума — Соры Бүре аларны куа чыккан, имеш. Кәбир киноларда гына ишеткән телдә кычкырына, имеш: «Хенде шлаттер хохен! Аншлайц цвиннунг виттертайн!» Кәбирне атландырып алган Бамбук чаба, әй, чаба, аларның артыннан кулына фонарь тоткан Соры Бүре менә-менә өсләренә сикерәчәк... Бәй, бу Бөкебаш ләбаса! Сикергән саен башыннан бер бөке чыгып ычкына...

Малай тибенә, кулларын буталап, Бөкебашка сугарга итә... Тукта, аның битен кемдер юеш чүпрәк белән сөртә түгелме? Кәбир уянып китә һәм күзләрен ачса — пәрәмәч, Бамбук үзе аны ялап тора бит! Ул шабыр тирдә иде. Ат исә имгәнгән аягын читкә янтайткан да, карашы белән аңа төбәлгән. Яткан җиреннән генә атның башыннан сыйпап, аерым бер иркәлек белән эндәшеп куйды:

— Кузгалабызмы, Бамбук?

— Кузгалабыз, Кәбирҗан.

Әйе, сөйләшә иде хәзер Бамбугы. Малай сикереп торды һәм үзен уратып алган матурлыкка таң калды: урман эче кояшның меңләгән алтын кылычы белән туракланган, бу нурлар дымлы җирдә, таң алдыннан үләннәрне саран гына сугарган чык энҗеләрендә төрле төсләр белән уйнаклап, күңелгә ниндидер тантана, күтәренкелек, бәхет һәм шатлык тойгысы өсти. Әкрен искән җилдә әле чәчкә генә атып килгән мәтрүшкә, ботнек исе белән аралаш кычыткан, учак, бөреңге ысы аның борынын кытыклады. Чәчкә һәм үләннәрнең ниндиләре генә юк иде биредә! Юк, Бүләк урманнарында бу кадәр төсләр абайлаганы юк иде шикелле аның: зәгъфран, гәүһәр, зәңгәр кыңгырау чәчәкләр дисеңме, соры күке, торнабашы дисеңме, сап-сары сандугач төкереге, ут кебек алсу рәбыйгалар дисеңме... Ә көпшәләр! Инде шартлатып өзәрлек булып җитешкән көпшәләр, кымызлык-кузгалаклар! Дөньясын оныткан Кәбир бер кочак көпшә һәм кымызлык өзеп алып, капчыгына тутырды. Болай булгач, яшиячәк кенә! Афәрин!..

Чамалавынча, кояш офыктан ике-өч иллегә күтәрелгән иде. Малай үзенең озак йоклап ятуына гаҗәпләнеп куйды. Чишмәгә төшеп, салкын су белән битен чылаткач, колаклары ачылып киткәндәй булды. Капчыгыннан ипи чеметеп алып, байталга сузды.

— Рәхмәт, Кәбирҗан. Үзең дә аша.

— Минем монда җитәрлек.

Дилбегәсен җыештырып, капчыкка салды да, тегеннән-моннан үлән кармаштырган байтал янәшәсенә утырып, кичәге бәрәңге һәм калган ипи белән тамак ялгый башлады. Әле генә күргән төшен хәтерләп, аны нәрсәгә юрарга да белмәде. Инәсе кара ташларны агартып юа. Димәк, аны тоткыннан чыгарган булырга тиешләр. Соры Бүренең Бөкебашка әйләнүе бик тә серле иде. Соры Бүре бер яктан, Бөкебаш икенче яктан куа чыкмаганнармы аны? Кәбир өшегәндәй итеп калтыранып куйды. Ул онытылырга тырышты. Кошлар тавышы белән чемердәп кайнаган урманга колак салды.

— Чут-чут-чут! Фью-фью-фьюия!

Бу — сандугачлар.

— Әс-вәс-вәс! Әс-вәс-вәс!

Монысы — урман тургайлары.

— Гөлдер-гөллер! Гөлдер-гөлдер!

Болары — урман күгәрченнәре.

— Бер данә! Бер данә! Бер данә!

Бүдәнәләр.

Малайның бу оҗмахтан кузгаласы килми иде. Алда нәрсә көтә аны? Их, әгәр инәсе булмаса, мәңге кайтмас иде ул авылга! Шул Бөкебашны күрмәс өчен генә кайтмас иде. Харис дусы исенә төшкәч, мондый уе өчен оялып куйды.

Моңсу булып китте. Абзардагы кәҗә бәтиләре искә төште. Карый микән аларны Хәмдия карчык? Малайның битенә үк кагылып, самолет кебек фырылдап, кара кондыз — каеры кондызы үтеп китте. Күтәрелеп караса, аклан авызындагы имәндә мәче башлы ябалак йокымсырап утыра. Күз уемнары акбур белән буялган, кашлары тырпайган бу тәссез, иләмсез кошны Кәбир һич кенә дә өнәми. Гүя, аңа Ябалак Галләметдин үзе карап тора. Куллары белән карманып, тирә-ягында кулай бер нәрсә дә тапмагач, Кәбир учактан калган өемгә үрелде, аннан бер төренбаш алып, ябалакка томырды. Төренбаш, ябалакка җитмичә, ботакларга бәрелеп җиргә төште. Ябалак ыжламады да — ул тәмам йоклаган иде. Аңа эсселе-суыклы булып китте. Сискәнеп, атның яралы аягына карады. Бәйләргә кирәк. Тик... нәрсә белән бәйләргә? Теге чүпрәге бодай басуында чыгып очты бит кичә!

Малайда фикер өлгерде. Пинжәген, күлмәген салып ыргытты да, күлмәгенең сул җиңен пәкесе белән аерды. Андыз яфраклары өзеп алып, капчыгыннан Әндри абзыйсы биргән дару шешәсен чыгарды. Бөкене чыгаруга бар тирә-якны әшәке ис басты. Танавын җыера-җыера, даруны андыз яфрагына сылады, яфракны тасма итеп теленгән җиң чүпрәгенә түшәде, аннан исә атның яралы аягын ирләрчә кыюлык белән эләктереп алып, яра өстеннән кат-кат урады. Байтал тартышып куйды.

Кирәк-яракларын җыештырып салганнан соң, капчыгын аркасына асты, ботакта асылынып торган камчысын кулына киде. «Әйдә, малкай»...

## Чегәннәрдән дә котылдык

Көзге яңгырларда утын-печән ташып, арба тәгәрмәчләре белән тирән чокылган, язын бу ерынтыларга ләм тулып, җәен бака яфрагы, кондырак үлән белән капланган һәм тәмам ташландык хәлгә килгән юлдан яфрак мөгарәсен лаштыр-лоштыр ера-ера алар кояшның нәкъ күзенә килеп чыктылар. Көчле нур ташкыныннан бер мизгелгә сукыраеп калган малай белән байтал карашларын түбән төшерде — үләндә чыкның тузаны да калмаган иде.

Байтал хәзер ыргып түгел, сикерә-атлый бара. Әгәр ул кичә бөтен гәүдәсен, бөтен авырлыгын арт аякларына салып ыргыса, бүген исә өч аягы белән берьюлы сикерә һәм шул ук ыңгырашу әһәңнәре чыгарып, яралы аягын җиргә тидергәндәй генә итеп, бер мизгелгә тукталып калгандай тоела. Атның хәле мөшкел. Бу хак. Үзен юатырга тырышты Кәбир. Күп тә үтмәс, яңа гына сәфәр юлына төшкән малкайның тәне язылыр, тын юллары да ачыла төшәр, дип уйлады ул.

Юраган юш килә, дигәндәй, бу шулай булып чыкты да. Ат гүя йомгакка әйләнеп, җирдән тәгәрәп бара, тизлеген арттыра башлады. Кәбир дә атламнан вак адымнар белән йөгеремсәгә күчте. Озакламый юлдан читтә яткан Көреш тә күренде. Кәбир кәефе килеп, камчысын шартлатты. Юлдан борхылып тузан күтәрелде. Бамбук сискәнде.

— Шартлатма. Кулың кычытмыйдыр бит.

— Ярар, малкаем, ярар.

Юл читендәге ат күмелерлек юан сабаклы һәм эре яфраклы үләннәрне Бамбук барган уңаеннан умырып алырга өлгерә. «Карыны ачыккан»,— дип уйлады Кәбир.— Күп калмады, малкай, түз». Кичә артыннан чак-чак йөгереп өлгерсә, бүген тымызык кына йөгерә-атлаудан узып булмый. Ә бу йөгерүгә караганда читенрәк. Кинәт кемдер сызгыргандай тоелды малайга. Сул яклап. Күп тә үтми сызгыру тагын кабатланды. Хәзер ул уң тарафтан иде. Күз ачып йомганчы әллә нәрсә булды: яңа сикереш ясаган Бамбук кинәттән җиргә сөрлекте, юлның ике ягыннан, куе үлән арасыннан калкып чыккан ике карасакал атны йөгәненнән эләктереп алды; күзләре аларып киткән байтал ни рәвешледер аягына басты, үлем куркынычын тоеп, кешнәп җибәрде; зиһенен җуйган Кәбир, үзе дә аешмастан, мәче сыман алга сикерде һәм атның ялына килеп сарылды:

— Минеке!.. Минеке!..

Сакалбайларның берсе — алар һич кенә дә безнең халыкка, безнең төбәктә яшәгән шивәләргә охшамаган иде — малайның җилкә тамырыннан җиңелчә генә чеметеп алып, читкә очырды:

— Молчи, собачонок! Зарэж-жу!..

Ул итләч балтырыннан сыдырылып төшкән итек кунычына кагылып куйды. Шул ук сакалбай атны җитәкләп алды да, юлдашына ботенләй ишетелмәгән телдә эндәште:

— Гонинэ грес!*

Икенче сакалбай кулына җыеп төйнәкләнгән арканы белән атны тукмый башлады. Чытырман сыман килеп ябеште аңа Кәбир:

— Тимә! Минеке!

Сакалбай аны арыш учмасыдай учмалады, кул беләзегеннән камчысын сыдырып алып, Кәбирне сукмак читенә селтәде. Түмгәк өстенә барып төшкән малайның күз аллары караңгыланып китте. Һушына килгәндә тегеләр атны алдан өстерәп, арттан тукмап, урман эченә алып кереп баралар иде. Көч-хәл белән урыныннан күтәрелеп, Кәбир алар артыннан иярде...

Бамбукны инде үз камчысы белән каезлаган сакалбай артына борылып, кул яссуы белән бугазына ышкып күрсәтте:

— Умырал хочэш?

Нәрсә булса шул булыр, дигән фикергә килгән малай аларның артыннан калмады. Күз яшьләренә буылып, чытырманлык һәм түмгәкләр аша, һаман да шул кычыткannarга кулларын чактыра-чактыра, алга атлады. Якында гына кеше сөйләшкән, атлар пошкырган тавышлар шөйләнгәндәй итте. Күп тә үтми, алар дистәләгән чатырлар, япмалы арбалар, казаннары кайнап утырган учаклар, аллы-гөлле бәбәйтәкләр кигән хатыннар, һаман да шул сакалбайлар белән чуарланган Сабыр буена килеп чыктылар. Кәбирне шундук кояшта кара чутыр булып

---

* Атны ку! (Чегәнчә).

янган, җил-яңгырда тимердәй чыныккан, аяклары түгел, куллары да чебиләп беткән бала-чага сырып алды. Җитмәсә, алар аркадан капчыкны тарткалыйлар. «Чегәннәр табыры»,— дип уйлап алды малай. Авылларыннан үтешли, йорттан-йортка кереп, фал ачкан, акча һәм әйбер-сәйбер җыйган, җае чыкканда чәлдерергә дә күп сорамаган чегәннәрне күргәне бар иде аның. Менә алар авызы киң итеп ачылган ак чатыр алдына килеп туктадылар. Йөрәге лепкәсендә типкән малай хәзер Соры Бүредән түгел, кешеләрдән курка иде. Чатырны күз ачып йомганчы сакалбайлар, хатын-кызлар уратып алды. Аның әченнән өстенә кара ефәк камзул ишарәте, шундый ук кара ефәк шарабар кигән, камзулын чуклы бау белән буган киң җилкәле, тутырым бәдәнле кеше килеп чыгуга, бала-чага чыр-чуыннан шып туктады. Алып килүче сакалбайлар, Кәбиргә тәртеп күрсәтә-күрсәтә, нәрсәдер аңлаттылар. Араларында бердәнбер дип әйтерлек бу сакалсыз кеше чегәннәрнең юлбашчысы иде булса кирәк. Малайны имән бармагы белән үзенә чакырды ул. Кыяр-кыймас адымнар ясап, Кәбир аңа якынлашты. Киң җилкәленең үткер карашы сәләмәләргә төренгән, бер аягы чабаталы, икенче аягы оекчан, башын-күзен тузан баскан кечкенә мосафирны күздән кичерде.

— Куда идешь, мальчик?

— Өйгә кайтам,— диде малай танау астыннан гына мышкылдап, татарча. Үксүдән аны очкылык тота башлады.— Кунакка барган җирдән... атыбызны бүре бугазлады... (Аны тагын очкылык тотты.) Мин аны авылга...

Икесе ике телдә сөйләшеп тә, малайның аны, аның малайны аңлавыннан ниндидер канәгатьлек тапкан юлбашчы, тирә-ягындагы халыкка күз сирпеп алды да, Кәбиргә әйтеп бетерергә дә ирек бирмичә, гөрселдәп көлеп җибәрде:

— Ха-ха-ха-ха-ха!..

Нидән көләләр икән дип, Кәбир тирә-якка карангалап алды. Бәбәйтәкле ярсу кызыл күлмәк кигән хатыннар да, ярымшәрә килеш җир сөргән чегән балалары да көләләр иде үзләре тапкан бу тамашадан.

Малай ике-өч адымда гына башын салындырып торган Бамбукка карады. Күзләрендә тормыш уты сүнгән кебек тоелды.

— Снэми мэшок...

Кәбир аңлап өлгермәде — капчыгын салдырып та алдылар, юлбашчы каршына китереп тә куйдылар. Атыннан тыш инде үзенә дә һәлакәт тойган малай пинжәк кесәсеннән пәкесен кармалап алды, аның үткер ябен чыгарып, юлбашчыга ташланды. Юлбашчы аны күккә чөеп, җиргә төшерде.

— Ты мэнэ нравишься, пацан!..

Кемдер кул беләзеген шартлатып кысты, пәке үзеннән-үзе юк булды.

— Барысын да алыгыз!.. Тик атны гына!..— Кәбир пинжәген, бер җиңсез күлмәген, аннан чалбарын да салып түгәрәккә ыргытты. Анадан тума хәлдә дүрт аякланып, ул юлбашчы каршында җир сөрә, ялвара башлады:— Барысын да алыгыз, атка гына кагылмагыз!

Бу күренеш барысын да айнытып җибәргәндәй булды. Табыр көлүдән туктады.

— Одэвайся, пацан!..

Үз гамәленнән үзе оялган малай сәләмәләрен тиз генә киенде. Аның капчыгын кемдер җиргә бушатып өлгергән иде. Арка җылысында пешенеп парланган кымызлык-кәпшәләр, иске дилбегә, бер тутәрәм икмәк, берничә бәрәңгене күздән кичереп, юлбашчы әйберләрдә казынган сакалбайга эндәште:

— Начи лав! Чув палы!*

* Кагылма! Кире утыр! (Чегәнчә.)

Тегесе байлыкны теләр-теләмәс кенә кире капчыкка тутыра башлады. Юлбашчы тубал кебек кара бөдрә чәчләрен бармак тараклары белән артка тарады да, бер мизгел тын торганнан соң, ике сакалбай белән кызып-кызып сөйләшә башлады. Кәбир аңлавынча, атны бүлешә алмый иде алар. Кулларын селти-селти, юлбашчыга кычкырындылар. Ниһаять, алар Бамбукны бер читкә өстери башлады. Юлбашчы утырган түмәреннән сикереп торды, артларыннан куып җитеп, кендек кебек кыска буйлы сакалбайны бугазыннан алып җилтерәтте:

— Набистр, ми, рома, сиротей нэ обижа!**

Тегесе, ачуын ничек басарга белмичә, лач итеп җиргә төкерде:

— Дык, Зобар!***

Һәм китеп бардылар.

Киң җилкәле яңадан урынына килеп утырды. Инде хәзер нәрсә була, бу тамаша ничек тәмамлана, дип көткән халык тәмам тынып калды. Таза итеп кырынган, киң маңгайлы, бөдрәләре колак алкаларына кадәр салынып төшкән юлбашчыдан да акыллырак, зирәгрәк, гаделрәк кеше юк иде хәзер дөньяда. Менә ул ярым ябылган керфекләре аша сөзеп карап, Кәбиргә эндәште:

— У нас ндравитса? Останэшся?

Төшенде Кәбир. Бездә каласыңмы, ди шикелле.

— Ниту... Диривнә пашул...

Табыр тагын көлешеп алды.

— Петь, плясать умэешь?

Монысын төшенеп бетмәде Кәбир. Ул да түгел, бөдрәбаш такмак әйтә-әйтә, түгәрәктән биеп китте:

— Амма-раппи, тимма-раппи...

Табыр кул чапты. Юлбашчыларының яхшы кәефе һәркемгә күчте шикелле. Җөен кояш ялкыны, кышын чиллә салкынында көйгән бу табигать балаларыннан Кәбиргә көч кергәндәй итте. Аңардан нәрсә таләп иткәннәрен аңлады ул. Алар сораганны үтәгән хәлдә атының да, үзенең дә бу камалыштан исән чыга алачагын исләп алган малай, түгәрәккә төшеп, такмаклап бии башлады:

Биек тауның башларында
Тезелеп үскән әнисләр.
Тезелеп үскән әнис кебек
Яшәсен коммунистлар...

Бер нәрсә аңламаган табыр котырып кул чаба, такмаклый һәм урынында тыпырдый иде. Кәбирнең аптыраганы шул булды: үзләре ботенләй аешмаган чит тел, чит сүзләрдән башка тагын нинди көч куәтләттерә иде аны чегәннәрдән?

— Мин тагын беләм әле,— диде малай инде бераз гына юмакайлана биреп.— Бездә мондый такмазалар буа буарлык ул!..

Әй, түр, түрәтүр.
Шәһәр кызлары матур.
Нигә матур булмасын,
Кондә май ашый бит ул...

— Молодэц!—дип сөйде аның иңеннән, көлеп хәлдән тайган юлбашчы.— Зэря цыганом нэ родэлся...

Кемдер аңа калай савытта ботка алып килде. Бер телем ипи дә куйдылар. Башын аска иеп, тирә-якка битараф карап торган Бамбуктан ояла биреп, малай агач кашыкны алып, капкалый башлады. Шатлыгыннан аның ашыйсы да килми иде. Әмма хуҗаларның кәефен бозарга

** Оныкма, без, чегәннәр, ятимнәрне кысрсытмыйбыз.
*** Кара аны, Зобар!

ярамый, дип уйлады ул. Тамак туклык иткәч, рәхмәт әйтеп, урыныннан торды. Малай аны җибәрмәсләр, дип борчыла башлады. Юлбашчы сул аяктагы чабатасын салырга кушты. Тагын да аптыраган Кәбир, нишләргә дә белмичә, кушканны үтәде. Чатыр эченнән кулына иске, шулай да кара буявы таушалмаган чүәкләр алып чыгып, кияргә кушты юлбашчы.

— Одэвай,— диде ул кырыс кына.— А это... к черту!..

Ул чабатаны бер читкә ыргытты. Әллә шатлыгыннан, әллә гарьлегеннән күзенә яшь бәреп чыккан үсмергә үз тәненең аерылгысыз өлеше — чабата кызганыч булып китте. Йөгереп барып, чабатаны күтәрде һәм капчыгына салды.

— Нилзә! Чабата кирәккәнский!

Кайдан килеп чыкты тагын бу сүзе? Шәп булды түгелме соң? Беркем дә көлмәде. Илһамы килеп киткән юлбашчы чүәкләрне Кәбиргә үзе кидереште. Ул аны йөретеп тә карады. Аның өчен генә тегелгән кебек иде чүәкләр. Юлбашчы үз телендә нәрсәдер әйтте. Табыр аны куәтләп, тел шартлатты.

— Чэловэком будь,— диде бөдрәбаш.— А если воровать будэшь, воруй лишь ворованное... Ну, бывай!..

Ул малайга көрәктәй ялпак кулын сузды. Инде чынлап та шатлыгыннан нәрсә эшләргә белмәгән Кәбир бертуктаусыз кабатлый иде:

— Ыспасибы... Ыспасибы...

Аңа капчыгын кидерештеләр. Кемдер камчысын китереп бирде. Бамбукны этәреп диярлек сукмакка төшерделәр. Беренче атламнар бер ел сыман озын тоелды Кәбиргә. Гүя, алар атлап түгел, шуышып баралар иде. Исенә килеп, пинжәк кесәсен капшады. Пәкесен оныткан. Кире бармаскадыр бит? Шулай да бик кызганыч иде пәкесе. Ул кыяр-кыймас кына артына борылып карады. Корама юрган кебек аллы-гөлле табыр аңа бердәм кул селкеде. Куш кулы белән тәбрикләде һәм алкышлады ул торып калучыларны. Ә пәкегә килгәндә, калсын. Истәлеккә калсын. Нәрсәдер аңардан да калырга тиештер бит!

Хәзер ашыгасы юк иде кебек. Пычак астыннан исән чыккан Бамбук та, шуны аңлагандай, үз җае белән генә титаклый. Әрәмәлек артта калды. Чегәннәр белән очрашу истәлеккә әверелә башлады. Нинди матур итеп сөйлиләр, дип уйлап алды малай. Аңлашылмаса да матур. Һәркемнең үз теле, табигате, фигыле бар. Кем шулай яраткан? Ерак юлга чыкмаган булса, аңа мондый уйлар килгән булыр идеме?

Ят үләннәрдән аңкыган хуш исләрне ул күкрәген тутырып сулады. Байталын күздән кичерде. Бүген иртән бәйләнгән бәйләвече урынында иде. Дөрес, Бамбукны туктатып ашатасы, ял иттерәсе бар барлыкка, шулай да чегәннәр табырыннан мөмкин кадәр ераклашасы килде аның. Кәефе килеп, үзе дә сизмәстән, камчысын шартлатты. Камчы очына эләккән тузганакларның мамыгы җилгә очты. Мбамбо-бимбо! Сама-рана-сама! Бамбук борылып, ачулы караш ташлады.

— Син әллә нәрсә сөйлисең,— диде аңа байтал.

— Чегәннәрдән дә котылдык, Бамбукҗанкисәккәем.

— Күлмәк-ыштаныңа кадәр салып ыргытып, биеп-җырлагач, котылдык инде...— Ат аның колак төбендә генә шаркылдап көлде.— Нишләтсеннәр, коткардылар, биглыйлар... Әйдә, бераз ял итеп алыйк.

— Түз, малкай, түз. Озакламый кичү.

## Мин тагын килдем, Нәстүк!

«Йөгенә генә күрмәсен. Йөгендерә генә күрмим».

Бар курыкканы шул иде.

Әмма аңа икенче бер яңа борчылу да өстәлде. Зур кәнсәләре, телефоннары булган Күлләр авылына якынлашкан саен бу борчылу

үзәккә төшкән шөбһәгә әйләнде. Әгәр аны артыннан, Буләктән куа чыккан булсалар һәм юлда каршы очрасалар? Дөрес, аның бары тик ат артыннан гына авылдан чыгып тайганлыгын беркем дә белми. Сабирҗан абзыйсы белән киңәшләшәсе килгән иде килүен, шулай да шикләнде. Шуңа күрә, күршеләре Хәмдия карчыкка да әллә ни ачылмады. Мал-туарларына күз-колак булып торырга гына кушты. Кыргызга барып, инәйнең хәлен генә белеп киләм, диде. Пркаруллар атның исән-аман икәнлеген ничек кенә булса да ачыкларга, тикшерергә тиешләрдер бит инде? Әгәренки телефон-мазар булмаса, барыбер йомышлы кеше җибәрергә дә тиешле бит алар! Артыннан куа чыксалар, алар һәр авылда сорашачаклар инде: фәлән яшьтәге, фәлән төстәге малай күзегезгә чалынмадымы, янәсе. Әмма Кәбир дә ахмак түгел. Ул авылларда туктамаска, туктаган хәлдә дә, бары тик вак авылларда, анда да авыл читендәге өйләрдә һәм төнгелеккә генә туктарга карар итте.

Менә алар копчәк эзләре белән телгәләнгән Сабыр кичүенә дә килеп җиттеләр. Инде ничәнче мәртәбә елга аша чыгуына карамастан, дәрья һәр кичүендә үзенчә кабатлана иде. Алкым-алкым булып аккан дулкыннар аңа әле канлы төстә булып күренде. Малайның күзләре чөнчеште. Эчкәрәк, чуерташлы төшкәрәк үтеп, Бамбук борын мөшкәләре белән фырылдый-фырылдый суны иснәде, аннан ирennәрен җыерып, шикәрдәй ак тешләре белән сыек дулкыннарны сөзде...

Ат, ниһаять, башын югары чөеп, Кәбирнең өйдәләгәнен дә көтмичә, аргы ярга ыргыды. Хәзер инде Бамбук белән ул түгел, ә аның белән Бамбук үзе боерыклык итә иде. Озак та үтми ул үзенең хуҗасын читтәрәк яткан акланга алып керде. Атның кырт туктавыннан һәм авыр тын алуыннан Кәбир тиз төшенде — аның хәле торган саен мөшкелләнә иде. Ешрак ял иттерергә кирәк, дип сөземтә ясады ул үзенә.

Шулчак юлдан арба теркелдәгәне ишетелде. Бөкебашлар түгелме? Җәядән атылырга торган укны хәтерләткән Кәбир яфрак куерымы аша юлны сөзеп алды: юк, түгел икән. Арбада бөтенләй ят ир белән хатын иде. Теләми иде малай Бөкебашлар тозагына кабарга, аһ, теләми иде!

Малай Бөкебаш белән соңгы очрашуын хәтерләде.

...Йорт җиһазларын исәпкә алып чыкканнан соң бер атна чамасы үтте, әмма әйберләр артыннан беркем дә килмәде. «Нишләптер» абзый белән теге хатынкай дөрес әйткән булып чыктылар, күрәсең. Үз самаварларыннан гөжләтеп чәй эчеп, үз паласларын ябынып йокладылар алар. «Кеше кулы белән шикаять яздырып, мине мәсхәрә итмәкче була бит ул Бөкебаш»,— диде инәсе Кәбиргә ул белмәгән ниндидер серләргә ишарәләп.— Тезләндермәкче, үчен кайтармакчы була, мәлгунь...»

Нинди үч, нинди мәсхәрә? Олылардан бу хакта ничек сорыйсың?

Озакламый бу сер дә ачыла төште шикелле. Шулай бер төнне сәкесендә йоклап яткан Кәбир өйдәге ят авазлардан уянып, күзләрен ачты. Йокысыннан рәтле-чиратлы айнымаган Кәбир тәүдә аңламыйчарак торды — үзен бу өйдә хуҗа сыман тоткан һәм һичбер тартынусыз, авызында азыкны чәйни-чәйни, шактый кычкырып мыгырданган ир кем була бу? Малай яткан сәкене мич каплый, ишек катындагы өстәлдә сөремләгән сукыр ут чит кешенең шәүләсен тагын да зурайтып һәм шөкәтсез килбәткә кертеп, тәрәзә аралыгына китереп кадаклаган. Урындык шыгырдатып, бу шәүлә каядыр омтыла һәм ымсына башлагач, инәсе пышылдап кына эндәште: «Иплән, Галләметдин... Баланы уятырсың...»

Кәбир күзләрен чытырдатып йомды. Ул палас астында шартлар хәлгә җиткән йомгакка әверелде. Кинәт ул үзен утлы табадагыдай итеп тойды, аннан оши башлады.

Алма бакчачына керчәм,
Алма тия җилкәмә, чүп.

Яртысы авыз эчендә, яртысы борын тишекләрендә пешерелгән бу җырдан соң Бөкебаш нәрсәнедер голт-голт чүмерде. Аны каты итеп очкылык тотты. Өйдә чучка абзары, ят, сасы ис таралды. Инәсе нишләп кертергә булган аны? Әллә нинди ят тойгы — көнчелек, ир балага табигатьтән бирелә торган үзеңне һәм сине дөньяга бар иткән кадерле җанны йолып калу тойгысы биләп алды малайны. Шундук сикереп торып, сөреп чыгарырга да күп сорамас иде Кәбир. Әмма аек акыл ашыкмаска куша иде. Бөкебашны күзәтер өчен мөмкинлек эзләп, ул урыныннан как сәкегә шуышты. Менә ул аның ярты гәүдәсен күрә. Шул житкән. Җен арбасы кебек чытырман бармаклы кулларын һавада бутый-бутый, исерек ут яктысына — инәсенә таба сузылды. Инәсе аны җиңел генә этәреп җибәрде:

— Куй, маташма, Галләметдин...

— Их, аңламыйчың хәлемне, Чания! Чиннән бачка ячи алмыйм...— Ул йодырыгы белән өстәлгә сукты.— Бәхетчез мин!... У-у-у...

— Иплән, дим, баланы уятырсың...

— Уянчын! Ул минем улым булырга тиеч иде.

Кара, нәрсә сөйләп утырган була! Моны ничек аңларга тагын?! Инәсе авыр итеп тын алды. Бөкебаш нииндидер савытны аударды, идәнгә шыбырдап нәрсәдер акты. Аңламый Кәбир, һич кенә дә аңламый — нинди гөнаһлары хакына түзә инәсе мондый түбәнлеккә, нинди өметләр белән керткән ул Бөкебашны кара төн уртасында?!

— Мин чине генә яратам бит, Чания җанкичәгем... Их! — Бөкебаш үксеп елап җибәрде.— Чин мине яратмаган ачудан коям бит кечеләрнең күз яшен... Беләм, мине яратмыйлар... Чин мине яратмаганга, мин аларны яратмыйм... Чык миңа, иртәгәдән ук майлаган кебек булачакмын, Чания!..

— Яраткан булсаң, кызганыр идең бераз,— диде инәсе пышылдап кына.

— Телмә бәгыремне, Чания җанкичәгем!...— Бөкебаш инде чынлап та ыңгырашып елый иде.— Беләчең килчә, мине чиннән дә нык кызганган кече юк бу дөньяда... Көндезен мин чинең ячеңне, ә төннәрен үз ячемне коям, аллаһи-билләһи... Мин якламачам, чинең бачың әллә кайчаннан төрмәдә чери иде инде. Ча-ни-я... Закон тәгәрмәченә мин генә аркылы агач чалып торам, Ча-ни-я...— Ул тагын голт-голт итеп эчте, һәм инде тәмам үкереп елый башлады. Кәбир урыныннан күтәрелергә итеп куйды. Кәнсәләрдәге кансыз Бөкебаш белән әлеге Җылак Галләмнең икесен бер кеше итеп күз алдына китерә алмый иде малайның зиһене. Мондый сәхнәви тамаша өчен әле ул яше белән дә, акылы белән дә өлгермәгән иде.

Кемдер утны өреп сүндерде.

Инде мыгырдануга күчкән Бөкебашның сүзләре кисәк-кисәк кенә килеп җитә иде Кәбиргә.

— Яратмыйм мин хатынымны, Чания... Чин киләм, дичәң... Куам да чыгарам, аллаһи-билләһи... Кертчәң, үзем өйдәч булып керәм... Ча-ния...

— Юк,— диде инәсе тыныч кына.— Бу мөмкин түгел эш, Галләметдин. Үтенәм, рәнҗетмә кешеләрне. Кансызлыгыңны минем белән дә бәйләмә... Мин бит өч бала анасы, аларның күзенә ничек карармын? Миһырбанлырак бул...

— Катымын! — Бөкебашның тавышында тимер чаңнары ишетелгәндәй булды. Бу елау белән ырылдау арасындагы бер мәрәкәле халәт иде. Аның күзендәге яшьләрне хәзер көндез чыра яндырып та эзләп табып булмастыр. Инәсенең сүзләреннән соң ул утырган урынында айнып, Ябалак Галләмгә әйләнде, күрәсең.

— Катымын! Каты булачакмын! Мин — влач... Дәүләтнең алтын баганачы! Мин бар — човет влачы бар, мин юк — човет влачы да юк. Үзебезне куркыту, дөньяны куркыту белән генә ячи ул влач!

Урындык ауды, өстәлдәге пыяла савыт-саба төшеп, идәндә челпәрәмә килде. Аннан тагын нәрсәдер гөрселдәде. Иләмсез тавышлар чыгарып, Бөкебаш инәсен талый башлады. Кәбир яшен тизлеге белән сикереп торды, мич арасына үтеп, уклауны кармап алды да, алгы якка чыгып, инәсен егарга маташкан Бөкебашка ыргыды. Аракы, чөгендер суы буында бөкедәй бүртенгән гәүдәгә уклау төшкәндә, көпшәк тән гөпелдәп кала иде. Ниһаять, инәсе Бөкебаш кулыннан ычкына алды:

— Оятсызның да оятсызы икәнсең! Мине шундый көнгә төшәр дип уйладыңмы? Мин Хәлим рухына үлгәндә дә хыянәт итмәячәкмен. Шуны бел, ул син киеп йөргән әтәй тунынннан кыйммәтрәк!— Инәсе идәннән нәрсәдер эләктереп алды — ул көмешкәсе түгелеп бетмәгән графин булып чыкты — Бөкебашның башына койды.— Мә, коен! Мә, тыгыл, бәдбәхет...— Ул ишек катына кадакланган түшкәнең ачык авызына графинны тыкты. Эшләрнең болай китәсенә һич кенә дә ышанып бетмәгән исерек баш чынлап та айный төште шикелле, куллары белән кармана-кармана, чит өйнең ишеген эзли башлады һәм, ниһаять, ишекне этәреп, тупса аша атлаганда Кәбир аның утыра торган йомшак җиренә җан көче белән типте. Шактый уңышлы килеп чыкты бугай: өй катыннан яхшы тизлек алып, өйалды ишеге аша да шул ук тизлек белән үткән Галләметдин болдыр яссылыгында инде үз авырлыгы белән сөрлегеп, ай яктысында күгәреп яткан ташлар өстенә барып мәтәлде. Кәбирдә беренче тапкыр ирлек куәте уянгандай итте — ул идеме соң бу, башка берәү түгел идеме? Аягына басты Бөкебаш. Болдырда аптырашта торган Сания белән Кәбиргә таба борылды һәм бөтенләй ябалак рәвешенә кереп җикерде:

— Нәчелегезне корыт-там мин чезнең!... Чин миңа төрмәдән хатлар язарчың әле, бәгырькәем!..

Һәм җил капка аша урамга лапылдады. Аның аяк тавышлары Сабыр күперенә җиткәнче һавада тугыланып торды.

Ай кара янган иде. Кәбиргә кызык та, кызганыч та булып китте. Кинәттән эчтә, кайдадыр бик тирәндә, нindидер өче төер ярлалды һәм ул тын юллары буйлап югары үрләп, кайнар ыргак сыман яндырып, үңәчкә килеп кадалды. Ул аны һич кенә дә кире йотып җибәрә алмады. Пычранган айның җирсу-коңгырт яктысында өндәү билгесе кебек агарып торган баганага килеп сарылды ул. Ишек алдында кайчандыр ат, мал-туар бәйләнә торган баганаdebt хәлсез куллары белән кочып, ялварырга кереште:

— Әтәй... Әтәй җаным... Кайт, әтәй!.. Бетерәләр безне, әтәй!..

Әле башланып кына килгән гомеренең беренче сәхифәләрендә ул үзе дә сизмәстән сабыйлыгыннан иртә, бик иртә ваз кичеп, олы бер сагыну һәм гарьләнү белән атасының рухын чакырды. Үлемнең аргы ягында, кайтмый торган җирдә иде бу изге рух.

— Бетерә алмаслар,— диде инәсе аны кочаклап.— Әйдә, кереп ят, балам...

...Совхоздан кайтуларына егерме көн дигәндә инәсен Кыргызга чакырттылар. Дөресрәге, участкауай Сәйфуллин алып китте. Прокурорга, имеш. Көнендә кайтам дип киткән кеше икенче дә, өченче көнне дә кайтмады. Авыл озынколаклары сөйләве буенча, имеш, Санияне хөкем алды тикшерүеннән үткәзәләр икән. Барысын да ачыктан-ачык сөйләүдән баш тарткан инәсен су белән ипи катысында гына тоталар, имеш...

Кыргызга инәсен юллап баруның мәгънәсезлек икәнлеген чамалый иде малай. Дүртенче көн дигәндә совхоздан, Зөлхиҗә әбисеннән, хат килеп төште. Гарәп имлясында язылган бу кош теледәй генә кәгазьне Кәбир картинәсеннән генә укытты. «Эзнең атны бик нык тәрбияли,— дип

язган иде әбисе.—Ходай тәгалә насыйп итсә, төзәлер. Күрәеп, түгәрәкләнеп китте. Әмма аяк шәрифләре элеге төзәлде дип булмый. Аягын җиргә тидерә, шулай да басмый. Бер-ике атнадан тагын да хәбәр итәрмез...»

Бу хаттан соң Кәбирдә электән үк уяна биреп куйган фикер тагын да ныгый төште. Кеше ышанмас дәрәҗәдә батыр, дуамаллык белән бер чиктә торган котычкыч фикер иде ул. Ат артыннан малай үзе юлга чыгачак. Авылга үзе үк алып кайтачак. Бу хакта инәсенә тишелгән иде тишелүен. Инәсе чат ябышып каршы төште: «Авызыңнан җил алсын! Атны юлда үтерәсең, угъры-фәләннән урлатасың киләме? Ризалыгым юк!»

Хәзер инәсе КПЗның салкын камерасында үзе өчен дә, ат өчен дә, Кәбир өчен дә ут йотадыр. Әгәр атны исән-аман алып кайтып җитә алса, бу өч төен берьюлы чишеләчәк иде малайның уйлавынча. Ерак юлга чыгуы хакында беркемгә дә әйтмәскә карар итте ул. Картинәсе белән Хәмдия карчыкка инәсен күреп кайтырга, Кыргызга барам, диячәк.

Ике көн үтте ул совхоз белән Бүләк арасын. Атлаган җирдә атлады, йөгергән җирдә йөгерде, бер мәлне хәтта машинага да утырып барды... Ул аны беркайчан да онытмас. Гомерендә беренче мәртәбә якыннан машина күрде һәм күрү генә дисеңме—утырып та барды бит ул аңа! Күлләр авылыннан чыккач булды бу хәл. Аны куып җитеп, узып киткәч, машина борылышта тизлеген киметте. Тузан өермәсенә күмелеп, артыннан чабып барган Кәбир, форсаттан файдаланып,машина әрҗәсенә ыргыды. Әрҗәдә буш тимер мичкәләр даңгор-доңгыр килеп тәгәрәшә. Ул-бу тоймаган малай кабина тапкырына килеп басты, куллары белән чат тотынып, яшен тизлеге белән артта калучы табигать күренешләренә хәйран калып, җилдерә башлады. Их ул чактагы рәхәтлекләр! Тыгыз җәйге җил чәчләрне тарый, маңгайга һәм муенга тәрткелләнгән тир тамчыларын иркә итеп сыдырып ала, яшисе, җырлыйсы, кычкырып көләсе, кош булып әллә кайларга очасы килә икән ул машинага утыргач! Әмма малайның шатлыгы озакка сузылмады. Сыртка күтәрелгәч, машина туктады, кабина эченнән сары чәчле юантык абзый килеп чыкты:

— Ну-ка, слезай, оборванец!..

Шоферга рәхмәт әйтергә торган малай аның мондый явыз кыяфәтен күреп, аптырап калды.

— Слезай, говорю!..

Юантык абзый кабинасыннан кәкре озын тимер тартып чыгарды, бу телне аңламый торган кешегә дә аңлашылган сүзләр белән әшәке сүгенеп, Кәбир янына үрмәли башлады. Инде монда аңлашылмас бернәрсә дә юк иде. Малай тиен елгырлыгы белән җиргә сикерде һәм юл такырлыгыннан кирегә сыптырды. Шофер аны байтак кына куып барды, ләкин җитә алмагач, туктады. Кәбирнең моңа һич кенә дә кәефе кырылмады. Киресенчә, тузанга күмелеп китеп барган машинаны ул кул болгап озатып калды. Нинди матур тойгылар бүләк итте бит ул аңа, ничәдер чакрым җир утыртып, ял иттереп алып килде.

...Малай көпшә һәм кымызлык кабыкларын көнҗәлә итеп алдында өерде дә бер читкә ыргытты. Байларча канәгатьлелек белән кикереп тә куйды. «Әлхәм шөкер, җилкәм чокыр, рахман рәхим, мин кемнән ким?» Кискен, усал омтылыш белән үлән учмалары өзгән Бамбукның күзләрендәге төссез нур аңа сәер, ят булып тоелды. Бәлки Кәбиргә генә шулай төсмерләнгәндер? Ул, калган ярты ипидән тагын бер кыерчык сындырып алып, байталга сузды.

Кузгалдылар.

Байталның кичәге гайрәте күзгә күренеп кимесә дә, малай Тушкыргага кадәр араны юртып үтәргә булды. Әйе, икенче сикереш Тушкырга ясалырга тиеш. Аннан инде Бүләккә дә күп дигәндә 17—18 чакрым гына кала. Хәл барда—алга, алга, алга!

Тыңлармы, аңлармы аны Бамбук? Тәүдә малайның уе хәзер үтеләчәк Күлләр авылында тәнәкләп чыгарга иде. Атын иркенләбрәк ял иттерергә дип тә җыенган иде. Кайда ди ул Күлләрдә андый шартлар? Таныш-белеше дә юк. Аннан килеп, бик зур авыл ул Күлләр. Эте күрә, бете күрә, дигәндәй. Урта мәктәп, авыл советы, телефон, ятим балалар йорты — нәрсәләр генә юк Күлләрдә! Кәбирнең иң шикләнгәне әнә шул телефон иде. Тотарлар да алырлар. 1946 елның кышында аны, ачтан бетләп, күзләрен трахом сүрүе басып беткән малайны чак кына бит тотып алып, шушы Күлләрдәге ятимнәр йортына озатмадылар. Инәсе каршы төште. Рәүф абзыйсы да аны алырга дип килгән йомышлы кешегә әйбәт кенә сеңдерде: «Бирмибез. Үлсәк, бергә үләрбез. Кәфенлек алып килерсез». «Без, җиңүчеләр иле, балаларны ачтан үтерергә хакыбыз юк»,— дип маташты теге. «Җиңүчеләр илендә ачтан үлгән ниндидер баладан гына аның абруе кимемәс»,— дип абзыйсы кырт кисте ул чакта.

Бамбукка яңа тизлек өсти алса, алар күз бәйләнүгә Тушкырга барып керәчәк. Кем белә, Чтапан дәдәсе, бәлки, Бамбукны берәр төрле итеп дәвалар да, чувашлар алар ырым-өшкерү дигән нәрсәгә ифрат та оста бит! Шушы уйларга бирелгән Кәбир тәнгелеккә Тушкырда туктaлуының дөреслегенә тагын да бер тапкыр ышанды.

Авыл аша күз ачып йомганчы үтәргә кирәк. Тизлек дип Бамбукны йөгендереп куйса? Әнә алда калай түбәле пулатлары, каланчалары белән Күлләр күренде. Тукталып тору, туры килгән хәлдә кемгәдер нәрсәдер сөйләп, аңлатып маташу катгый тыела. Һәрхәлдә, ул телсез малай булып кыйланачак. Авылларындагы телсез Минкамал тутасы кебек.

— Әйдә, малкай. Һоп!

Юк, ашыкмады Бамбук. Кәбир байталга якынрак килеп, күзләрен йомды — һәм шактый әрнетерлек итеп берне сыдырып алды.

— Үз акылыңдамы син, дус кеше?

Бамбук, төссез пыялага әйләнгән күзләре белән аңа борылып карады да, үз җаена баруын дәвам итте.

— Мин синнән үтенеп сорыйм, Бамбуккаем.

— Минем хәлем чамалы.

Малай җан ачуы белән берне, аннан тагын берне тамызды. Бамбукның ит ташлаган янбашында очкыннар чәчрәп, йолдызлар кабынды. Ниһаять, байтал арткы аякларына басты, тамагын киң ачып, һава уртлады һәм тагын да ыңгырашу авазлары чыгарып, кичәге алым белән ыргый башлады. Камчысын ат карашында уйнаклата-уйнаклата Кәбир дә йөгерергә кереште. Әмма тизлек кичәге түгел иде шул. Икенче тапкыр баюга кояш нурларыннан сорау билгесенә охшап җиргә төшкән күләгәсе, ике кулын җәеп камчы селтәгәндә өч япьле сәнәкне хәтерләтеп, яссылыктан шуыша иде.

— Син үзеңне дә камчыла...

— Камчылыйм, үземне дә камчылыйм, Бамбук!

Шатлыгыннан күзенә яшь бәргән малай барган уңайга үзен дә каезлый башлады. Синең белән бер җан, бер тән булып яшәгән атны кыйнаганда ирмен дигән ир ничек итеп үзен онытырга мөмкин?! Тәнгә кайнар тасма булып яткан камчы очы шәрә беләкне өттереп алды. Малай артка борылып карады — аны арба куып җитеп килә иде. Малай алга караш ташлады — авыл очыннан эшлиясенең җиз каптырмалары белән кояшта елкылдап, шулай ук арба якынлашып килә. «Элэктерделәр! Мене кайда безне кулга төшерергә ниятләгәннәр!» Ачык яланда, дөресрәге, әле буынга да сикермәгән карабодай басуында, кереп посарлык урын табармын димә. Нәрсә булса да булыр, дип, Кәбир атына да, үзенә дә тагын берне төшереп алды. Якынлаша арбалар. Аларның әйбәт майланган тимер күчәрләрендәге көпчәкләрнең иркә леркелдәве дә колакка чалына. Сөйләшкән тавышлары да ишетелә. Кәбирнең

йөрәге тагын да лепкәдә тибә башлады. Нәкъ уртадан ыргыган Бамбук юл бирү турында башына да китермичә, баруын дәвам итте. Менә өч аяклы ат һәм арбалар берьюлы очраштылар. Ләхәүлә куәтә! Хәзер Бамбук муенына аркан ыргыталар! Юл киңәеп киткәндәй булды: арбадагылар атларын тыеп, читкә каердылар; тузан эчендә калган Бамбук белән Кәбир аларны узып китеп, камалыштан шулай җиңел генә котылганда, малай артына борылып карады — өч аяклап ыргыган атны юлчылар туктап һәм авызларын ачып тамаша кылалар иде.

Авылга керделәр. Җитеп килгән кичнең яланнан көтү, эштән халык кайтып өлгермәгән тыныч, иманлы сәгате иде бу. Дөбер-дөбер китереп, Сабыр күпере аша үттеләр.

Авылдан шулай бер тын белән маҗарасыз-нисез алып чыккан Бамбукны кочасы, ялларыннан кагып иркәлисе килеп китте Кәбирнең. И җаныем! И сабыркаем! Юк, син күргән газапларның азагы булмый булмас, син түккән кара күз яшьләре якты бөртектәй савапка әверелеп, җиргә сибелер һәм алар тук башаклы басулар булып күтәрелер. Төзәлер яраларың, төзәлер, алла боерса. Кайтып кына җитсеннәр, Кәбир аны Сәми бабасы белән өрмәгән җиргә утыртмас, ашамаган ризыгын ашатыр — әмма барыбер аякка бастырыр.

Канатлы бит аның байталы, канатлы! Җитмәсә, Муса бабасы үстергән бит аны. Димәк, үзләренең каны. Нәселләренең хәләл көче. Әгәр бабасы үстереп бирмәсә, кайдан алыр иде мондый байталны «III Интернационал» колхозы?

Бабаларыннан кайткач, бу хакта Сәми карттан сораштырган иде Кәбир. Әмма тегесе өзеп кенә әйтә алмады. «Булуы бик мөмкин, майкаем,— диде Сәми карт.— Мусадан калган бурлы бия нәселе сугышка кадәр бөтен районга таралып өлгергән иде. Бамбукка килгәндә, ул 1944 елның җәендә Пароль исемле кәмиссәвәнни алашага ияреп кайтты. Паспортын ваянкаматка барып алдык. Бирмәскә итәләр. Имеш, сезнең колхозга бер генә ат тиеш. Үзләре табышкан һәм үзе ияреп килгән малны бер-берсеннән ничек аерасың инде? Бәлки алар сугышта да бергә булганнардыр? Парольне 1946 елда иткә озаттык, ә менә Бамбук, ходайга шөкер, исән-сау...» Кайдан килгәннәр соң алар, дип сорагач, Сәми бабасы кырт кисте: «Бәләбәйгә фрунттан бер ишалун кәмиссәвәнни атлар кайтаралар. Районнарга бүләләр. Пароль безгә эләгә. Бик тә имгәнгән, кантужный, бер колакка каты иде, бахыркай. Туры эчәгесе дә эшләмәде. Бар нәҗәсәте — тизәге, сидеге бергә иде. Озакламый ифрат та биреште...»

Кызды байтал. Ана күкшел мамык кисәкләре булып аның бот төпләре күбекләнде. «Яндыра күрмим». Инде ничәнче тапкыр көйдереп ала бу уй Кәбирнең җанын. Алар тау сөзәгеннән дә күтәрелде. Сул кулдан, янәшәдән генә, алтын йомгак булып кояш офыкка тәгәри. Тушкырга бүген үк барып керү хисе малайны тагын да канатландырып җибәрде. Төнгелеккә тукталу өчен Тушкырдан да уңайлы урын юк шул. Куа чыккан кешеләр, әгәр алар чынлап та булган булса, тел белмәгән малай актыгын бөтенләй чит-ят чуваш авылында төнәкләп ятар дип һич кенә дә уйламас. Тукталып та тормаслар, мөгаен. Атны яшерен ашату өчен андагыдан да уңайлырак ат абзарын кайдан табасың? Үзенә килгәндә, ат дворының тавык кетәклегедәй кечеки генә өенә керә дә ава — тап син печән эскертендәге энәне! Иң мөһиме, анда танышлары да бар. Ат караучы Чтапан дәдәй белән кызы Нәстүк шул өйдә яшиләр бит. Теге вакытта, совхозга җәяү сыпыртканда, аларда кунып чыккан иде ул. Кайтканда тукталыр өчен яптәш урыннар караштыргалап барган иде. Дөресрәге, конюшнай сәндерәсендә төн кунармын дип песи сыман почмактан тырмашып менеп барган малайны Чтапан дәдәй тотып алмасынмы: «Кем? Кайда парасын? Тәүдә Кәбир телсез булып азапланды. Барып чыкмады. «Пашны путама,— диде Чтапан дәдәй хәйләкәр елмаеп.— Син акыллы пулган». Сөйләргә туры килде аңа. Һәм сөйләп

дөрес тә эшләгән — бүген менә кемгә барып төшкән, кемгә сыенган булыр иде? Теге чакта кызыл яулыклы Нәстүк аны бик тәмле кычыткан ашы белән сыйлады. Аңардан өч-дүрт яшькә өлкәнрәк бу чыпчык чәчкәсе кебек зәп-зәңгәр күзле кызкайны исенә төшерү белән малайның күңелендә үзе дә аңламаган сыкрану, ниндидер бимаза барлыкка килә — нигә шулай икән?

Кичке шәфәкъ тәңкәләре белән уйнаклап, аларны инде ничәнче тапкыр Сабыр кичүе каршылады. Бамбук агым уртасына керде һәм шып туктады. Шыбыр тиргә баткан малга Кәбир туйганчы эчәргә бирмәде. Үнәче көеп барса да, үзе дә эчмәде: бу тирәдә чишмәләр күп, күрәсең, су тамакны чатнатыр дәрәҗәдә салкын иде.

— Әйдә, малкай.

Бамбук бу юлы, гүя, телсез иде. Тездән су эчендә торган малай аны ничек кенә өйдәләмәсен, ничек кенә көйләмәсен, байтал аның инәлүләренә игътибарсыз калды. Аягүрә үлгән диярсең. Салкын суны куш учлары белән чайпалтып, тоякларына кадәр юыштырып та алды, әллә күңелен киттемме, дип яңадан су эчереп тә карады — Бамбук, күзләрен йомып, йокыга талган иде. Камчыларга кулы күтәрелмәде. Кинәттән малайның тезенә нәрсәдер китереп сукты, күз аллары караңгыланып китте; хәлсезләнеп, урында егылам дигәндә дөнья яңадан яктыргандай итте һәм ул үзенең элеккеге халәтенә кайтты. Бераз арыткан, ахрысы. Ләмгә убыла барган аякларын көчкә сөйрәп, ул ләшпелди-ләшпелди ярга чыкты һәм үләнгә капланды. Күпме вакыт үткәндер, ул башын күтәрә төшеп, карашын Бамбукка сирпеде — ат агымсу уртасындагы тынсыз һәйкәлгә әверелгән иде. Кинәт ул сабырлыгын җуеп, яткан җиреннән йодрыклары белән җирне төйнәкли башлады:

— Барсына ди син гаепле! Синең аркада инәйнең башы төрмәдә! Синең аркада Бөкебаш безгә гөбернатыр! Синең аркада!.. Синең аркада!..

Синең аркада!..

Авазлар ярларга бәрелеп, буш кайтаваз булып кайтты: ар-ка-да-да-да!...

Малай җирдә ауный башлады. Нигәләр генә юк, нигәләр генә исән түгел икән аның атасы?! Аталы балалар да аның хәлендәме хәзер?! Монда бит агачлар да, кошлар да, үләннәр дә ятим түгел — нигә ул гына ятим?! Үксеп, үкереп елыйсы килә, әмма син теләгәндә аның яше дә чыкмый бит!

Ул башын күтәрде. Кем җырлый? Кайдан килә бу тавыш? Пар тавыш? Хатын-кыз тавышы — инәсе түгелме? Тоньк кына ир тавышы — атасы бит, атасы! Кәбир җырның сүзләрен дә аермачык ишетте: «Кайда гыналый бармый, ниләр күрми, ир-егеткәй белән ат башы...» Әллә саташамы, югыйсә? Офыктагы кояш ул юлга чыкканнан алып инде икенче тапкыр упкынга төшеп бара. Күз кырые белән генә Бамбукка сирпелде. Су эчендә торганлыктан, аның дүртенче аягының яралы икәнлеге бөтенләй беленми кебек. Гүя, агымсудан сихәт-дәва тапкан бия чынлап та дүрт аякланган һәм, кояшны арканлап алып, дүрт аягын дүрт ноктага терәгән дә, кояшны упкынга төшереп җибәрмичә, тартып тора...

Кәбир, утка пешкәндәй, сикереп торды. Капчыгын тиз генә иңеннән шудырды, хәлсез куллары белән калтырана-калтырана, аннан соңгы түтәрәм икмәкне, ике чи бәрәңге чыгарды. Чегән бүләк иткән истәлекле чүәкләрнең карарлыгы да калмаган — ләмгә бата-бата ул яңадан Бумбукка таба атлады. Түтәрәмне урталай сындырып, атның иреннәренә терәде... Дымлы мыек төкләре уч төпләрен кытыклаган иреннәр ипи кисәген капшады, ниһаять, теле белән ялмап алып, җай гына чәйни дә башлады... Тагын... Тагын... Күзләре әле һаман табуттагы сыман бикле иде. Аяк астыннан пычак сыман үткен чуерташ кармап, бәрәңгеләрне урталай ярды һәм аларны берәмләп атка бирде. Ул атларның моңа

кадәр чи бәрәңге ашаганын исләгәне юк иде. Ашый икән, нибуч! Шикәр сыман шытырдатып ашый!

Кәбир байталны эчәргә чакырып сызгырынды. Бамбук күзләрен ачты. Алар кичке шәфакъ алсуында шәмәхә-зәңгәр төскә кергән иде. Әмма эчмәде ул.

— Кузгалдык, малкай...

Ат җавап бирмәде. Ул аны арттан этеп тә, төртеп тә, камчы сабы белән чиерттереп тә карады — кузгалмады Бамбук. Тәмам өметсезләнгән малай балтасы суга төшкән агай кебек, яңадан ярга сөйрәлде. Байтал исә, шуны гына көткәндәй, уфырып һәм тирә-якка утлы тамчылар чәчрәтеп, алга ыргыды.

— Җаныкаем!

Алар Тушкырга көтү кайтып, халык мал-туарын җыйнаштырган вакытта килеп керделәр. Урам тузан тутыгында йөзә иде. Өйләрнең берсендә дә ут өсәре күренми. Хәтта этләр дә өрми. Чуваш авылларында эт-мазарның сирәк очравына Кәбирнең элек тә игътибар иткәне бар.

Авыл очындагы ат алачыгына якынлашкач, Кәбир алгарак чыгып, байталны шул юнәлешкә борды. Читән белән уратылган, урыны-урыны белән янтайган һәм арба-фурманнар тезелеп киткән ихатага титаклый-титаклый килеп кергәндә Чтапан дәдәй кое бурасы өстенә атланып алып, атлар эчерә иде. Куерып килгән төннең карасу зәңгәрлегендә мезелдәп янган тәмәкесеннән очкыннар чәчри. Улакка җитәр-җитмәстән ике-өч адымда шикәр кебек агарып яткан таш тозны күргән Бамбук кырт борылды, уфырып һәм ыңгырашып, тагын бер сикереш ясаганнан соң, кисәктән туктады һәм, мәңге күрмәгәндәй, хәле бетеп, тозны ялый башлады. Йөзләгән ат, тай-тулак телләре белән яланып, күзләү-күзләү шомарып беткән таштозның юлыкларын Бамбукның теле кызыл ялкын булып, аерым бер сагыну һәм осталык белән ялмап ала. «Тоз! Ашым тозы! Тормышымның тозы! — ди иде ул гүя. — Саулыгымның тозы-татыры, саумы!» Кәбир маңгае түренә, лепкәсенә бөркелгән эре тир тамчыларын җиң очы белән сөртеп алды.

Кайдандыр ике-өч биләмче кырыкмыш килеп чыгып, байтал тирәсендә өерелеп, зур гауга чыгардылар, тешләшеп тибештеләр. Бамбукка янбашы белән торган кырыкмыш, мин дә буш калмыйм, дип ахрысы, көтмәгәндә генә бот җәяләрен аерып, куш тояк белән Бамбукның күкрәгенә дөпелдәтте. Бия адәми сыкрану белән кешнәп җибәрде. Кәбир үзе дә кычкырып куйды шикелле. Чтапан дәдәй атлар арасында нindидер гадәти булмаган борсалану, ят чалым, шик-шөбһә тоеп, ахрысы, тирә-ягына махра очкыннарын коя-коя Кәбирләргә таба килә башлады:

— Кам унта?*

Уң аягын бераз сөйрәп атлаган Чтапанның якынайганын көтеп, малай эндәшмәде. Тегенең тавышы хәвефлерәк яңгырады:

— Кам унта, ментен ченместен?**

— Мин, — диде юлчы сабыр гына. — Кәбир. Совхоздан кайтып килəм.

— Кәп-пир! — дип кычкырып җибәрде Чтапан дәдәй һәм өерелдереп кочагына алды. — Шәпме! Парып та киләсен, ә? Пына, ичмасам, керой, пына, ичмасам, качча!* Үсен дә курку пелмәс атарви калава икәнсен, ә! — Ул һаман да тоз ялаган Бамбукның ялыннан какты. — Ат никәлдә, ат?

— Хәрт, Чтапан дәдәй. Көрчеккә терәлдек.

* Кем бар анда? (Чувашча).
**Кем бар анда? Нигә эндәшмисең?
* Җегет.

— Алай ук түкелдер лә...— Чтапан дәдәй малайның күңелен күтәрергә тырышып булса кирәк, кеткелдәп куйды.— Тос ялакан — бос ялакан түкел. Тимәк, өмет пар! — Ул беразга гына фикер туплап торды да яңадан эндәште: — Мин кәзер яланга ат кунасына киткән. Йомышыңны әйт!..

Кәбир атка ашарга, үзенә кунып чыгар почмак кирәклеген әйтте һәм, әгәр мөмкин булса, Бамбукның буыннары бераз ял итсен өчен аның алгы санын аркан белән бәллүргә күтәртү зарурияттән искәртте.

— Кәзер! Эчер дә — апзарга!

Борылу Бамбук өчен иң газаплы гамәл иде. Кәбир камчысы белән сыдырып та алды. Кырык адымда кырык җәфа белән алар аны, ниһаять, аранга керттеләр.

— Да-а...— диде Чтапан дәдәй инде үзе дә ышанып.— Кәле чынлап та шәптән булмаган.

Ул аранда фонарь кабызды һәм кызгылт яктылык көлтәсен әле бер, әле икенче тәңгәлгә юнәлтеп, атның барлык әгъзаларын тикшереп чыкты. Аның игътибары байталның бүре тешләре эзе ярылып яткан күкрәгендә тукталып торганнан соң яралы аякка текәлде. Дәдәй бөйләүле чүпрәкне чиште, аннан теткәләнеп беткән андыз яфраклары коелгач һәм аңа таныш дару әчесе таралгач, тагын да бер тапкыр кеткелдәп куйды:

— Антызнын шифалы икәнен син пелгән, ә? Кайдан пелгән?— Дәдәй чүпрәк-чапракларны үреләп биреп, аран тәрәзәчегенең таш нигезенә куйды.— Торып торсын. Иртән карарпыз... Шунысы әйпәт, атнын аяк-калинасы шешпәгән...— дип сөйләнә-сөйләнә, ул фонарьне баганага элде һәм аякларын өстерәп сөндерәгә менеп китте.

Күп тә үтми, аранның кырып тазартылган агач идәненә хуш исле солы күбәләре очып төшә башлады.

— Әйтә, калкуз малы да персидәтель айкыры ашаганны ашасын әле!— Чтапанның тавышы кайдандыр саңгырау караңгылыктан ишетелә иде.— Син, малай, кормушкага ташыган!..

Сабый чактан ук күңелгә якын ат абзары, тизәк исләреннән, алардан да бигрәк, еракта гы чуваш авылында, котмәгәндә өстенә ишелеп төшкән туганлык һәм кешелеклелек игътибарыннан исергән Кәбир, һушына килеп, Бамбук утлыгына яшел солы ташый башлады. Бүген генә чабылган бу уҗымнан кайнатып утыртылган сөт, каймак исләре килә иде. Ат түгел, кеше ашарлык тәмле тәмнәр, бихисап ымлыклар кайный иде бу солыда, билләһи!

Аякларын баскыч аратала рында сак кына алыштырып, Чтапан дәдәй җиргә төште. Фонарь яктысында Кәбир аңа тагын бер мәртәбә күз сирпеп алды. Өстенә саргаеп беткән солдат гимнастеркасы, ямаулы галифе, галифе балакларын оегына кыстырып, бүген генә яңа чабата кигән, кара кучкыл йөзле, күптән кырынган һәм башына түбәтәй дисәң түбәтәйгә, эшләпә дисәң эшләпәгә охшамаган бер чаплашка элэктереп алган бу кеше дөньяга иң бәхетле күзләр белән карый сыман. Дәдәй күрше араннан йөгенгән атларны күтәртеп бәйли торган киң каеш түшлек алып чыкты. Алар тырышып-тырышып солы чөмчегән байтал янына үттеләр.

— Син теге яктан, мин пу яктан.

Эчкәрәк үтеп, караңгыда түшлек бәйләп маташкан малай аран ишек төбеннән яңгыраган моңаем тавыш ишетте...

Бу таныш әһәңдә шөбһә бар иде. Кәбир борыла биреп, артка карады. Әйе, Нәстүк иде ул. Шул ук кызыл киҗедән тегелгән күлмәктән. Саран ут яктысында ул кызның күкрәгенә сибелгән тәңкәләрне һәм вак-вак итеп үрелгән чәч толымнарын да шәйләде. Кайбер сүзләрне белгән малай аңлады: «Әти, әни тагын да килде бит».— диде шикелле Нәстүк.

Әллә ишетмәмешкә салышты, әллә ишетсә дә, җавап бирергә кирәк

тапмады Чтапан дәдәй — кыскасы, эндәшмәде. Ул түшлек астыннан кулын йөгертеп чыкты да, Нәстүккә текәлде. Кыз Кәбирне күрми иде әле. Дәдәйнең йөзе агарынган, күзләрендә исә баягы тормыш уты сүнгәндәй тоелды. Монда нindидер шом бар иде.

— Татах ку дурта уру ан пустар!* — диде ачулы тавыш белән Чтапан дәдәй һәм, безнең беркемнән дә серебез юк, дигәндәй, татарчалап өстәп тә куйды: — Минем ана әйтәсе сүз петкән!

— Йерет вет...**

Чтапан бик яман итеп сүгенеп куйды. Эшен тәмамлаган Кәбир чүгәләгән урыныннан күтәрелеп, ишек катына килде. Көтмәгән җирдә Хозыр Ильяс кебек калкып чыккан малайны күргән һәм таныган кызкай бер мизгелгә чайкалып куйгандай булды. Әтисенең татарча җавабының серен төшенгән йөздә елмаю чагылды. Югалып калган малай нәрсә әйтергә белми, теленә килгәнне әйтергә ашыкты:

— Мин тагын килдем, Нәстүк...

— Килә яптыр! — диде кош кебек канатланган Нәстүк.— Бес кунакка шатпыс! Шулай вет, атте?.. Алар өйгә юнәлделәр. Дөресен әйткәндә, өй түгел, келәт иде бу. Ишекне ачу белән борынга килеп бәрелгән куе махра төтене, парланган чөгендер, нindидер әчкелтем-төчкелтем үлән исләреннән Кәбирнең күңеле уйнап куйгандай итте. Фонарь өйнең эчен яктыртырга өлгермәде, чәчләре тузгыган хатын — Кәбир аны юньле-рәтле күрә дә алмады — Чтапан-дәдәйнең фонарь төбе караңгысында торган аякларына килеп егылды:

— Чтапан чуным! Хаклы чынным!.. Качар мана... Эне унпа сахал пуренне...*

Үкереп, чәчләрен тырнап елаган хатынның тавышыннан өй чиксез зураеп киткәндәй булды. Кәбир бернәрсә дә аңламый иде. Бу Чтапан дәдәйнең хатыны, Нәстүкнең инәсе иде бугай. Ул калтыранган куллары белән тын торган ирнең аякларын кочаклап, солы төсеннән яшелләнгән чабаталарына күз яшьләрен коя... Җәфалы иде бу мизгел. Кайчан туктар бу мәхшәр?! Ир аякларын хатынның кочагыннан арындырды, аның аша атлап, түргә үтте, чөйдән озын саплы каеш чыбыркысын эләктерде һәм шактый ук һиммәтле кизәнү белән чинаган көчек тавышлары чыгартып, гәүдә өстендә берне чыелдатып алды. Инде үрсәләнеп аунаган хатынкай ишеккә аркылы яткан җиреннән буйга сузылып төште. Әгәр Чтапан дәдәй кансызланып, тагын да берне тамызса, Кәбир, һичшиксез, аны үз гәүдәсе белән каплаячак иде. Әмма сукмады Чтапан дәдәй.

— Мин сукышта кан койган, син уйнаш иткән, каналья! Вон! — диде ул тешләрен шыгырдатып.

Нәстүк инәсен бик әрли дә, кызгана да иде шикелле. Ахырдан, инәсе нindидер аңлашылмаган ымлыклар белән мыгырдап маташканда ирennәрен чәйнәп торган кыз кискен генә бер сүз әйтте һәм хатынкай, исерек кеше кебек, кармана-кармана ишекне эзләде, ниһаять, табып, ышанычсыз адымнар белән төн караңгылыгына кереп югалды.

— Анне... Эчә пашлаган, пында килгәндә гел эчеп килгән,— диде Нәстүк эч сере белән уртаклашып.— Атте аннене тегеләй дә яратмаган, пылай пөтенләй яратмаган...

Фонарьне чебеннәр сырып алды. Моңсу булып китте Кәбиргә. Юк, ул беркемне дә гаепләргә ашыкмый: бәләкәй кенә тормыш тәҗрибәсе, үз акылы пышылдавынча, ул аны әле генә туганнарча каршылаган, аны гына түгел, ат кадәр атны бишеккә «салган» һәм, уйлавынча, бары тик

* Бу йортка аяк басасы булмасын!
**Елый бит.
* Чтапан җаным! Кадерлем минем! Мин аның белән озак яшәмәдем... Кичер мине...

сихәт-сәгадәт, килешкәнлек, бары тик кан-кардәшлек шартларында берегеп яшәргә тиешле булган Чтапан дәдәй белән Нәстүк даирәсендә бер генә дә тәмсез сүз ишетәсе, бер генә дә ямьсез төс күрәсе килми иде.

— Ашыйсынмы? — диде ягымлы тавыш.

Кәбир уйларыннан арынды. Нәстүкнең янып торган күзләреннән аз гына нур алып, Бамбук күзләренә күчерәсе килеп китте аның.

— Ашыйм,— диде ул хәлсез генә. Аннан тагын да ныграк ышандырыйм, дигән сыман кабатлады.— Ашыйм, Нәстүк...

— Утыр.

Болай да сәкегә утырып торган Кәбир өйдә утырырлык урындык, өстәл-мазар да күрмәде. Ул аркасыннан капчыгын салып, почмакка ыргытты, камчысын Чтапан дәдәй чыбыркысыннан соң буш калган чөйгә элде. Нәрсәдер җитмәгәндәй, исенә төшеп, ул почмакка килде һәм капчыгының авызын чишеп, берничә бәрәңге чыгарып, Нәстүккә сузды:

— Күчтәнәч... Ипием дә бар иде дә бит — бетте...

— Кирәкми,— диде мич тирәсендә кайнашкан Нәстүк.— Пәрәнге пар песнен!..

— Теләсәң, хәзер үк мичкә тәгәрәтеп ашыйбыз,— диде Кәбир батырая төшеп.

— Иртәгә калган, ярыйпы? Кәзер мин сина аш ашаткан...

Нәстүк кузлары сүрәнләнә төшкән мичтән агач сәнәк белән чүлмәк тартып чыгарды һәм сәке тактасына китереп куйды. Мич белән сәке арасында зеңләгән күкрәкчә тәңкәләре аңа хәзер Сабыр елгасы буендагы кырыкмыш тайлар муенында яңгыраган кыңгырауларны хәтерләтте. Чүлмәк капкачын ачып җибәрү белән өйгә тагын да әчкелтем исләр таралды. Чөгендер яфрагыннан пешерелгән бу апара сыман сыекчаны Нәстүк зур агач кашык белән агач табакка салды һәм Кәбиргә таба шудырды.

Ипи-фәлән куймады кыз. Кайдан, ниткән ипи ди тагын? Малай комсызлык белән яшел сыекчаны җилдерә башлады. Мондый ашны инәсенең дә пешергәне бар, югыйсә. Әмма ул аны яратмый, һич кенә дә ашамый торган иде. Табакның төбе ялтырап калды.

— Тәмле...— диде малай үзе дә сизмәстән.

— Тәмле тисен? — Нәстүк куанычыннан елмаеп җибәрде.

— Тагын салган?

Алар табактан икәүләп алмаш-тилмәш чөгендер ботқасы менгезә башладылар.

«Нинди өйбәт, акыллы һәм сәләтле халык бу чувашлар,— дип уйлап алды малай.— Татар авылында туып-үскән диярсең, ничек кенә сөйләшеп куя Нәстүк татарча, ә? Татарның үзен сатып җибәрер! Урысчага да үтә мачтыр алар. Бишектән төшү белән өч телдә сөйләшә башлыйлар. Кайда бар тагын мондый халык?»

...Сәке өстендә оеп барган малайдан Нәстүк сорап куйды:

— Ятасыңмы?

— Ятам...

Сәке астыннан толып тартып чыгарып, Нәстүк аңа урын җәйде. Кәбир арыган аякларыннан чүәкләрен һәм ләм ләпәшеп каткан оекбашларын салып ыргытты.

Һәм урын өстенә ауды. Ул йоклый иде инде.

*Ахыры киләсе санда*

# ШИГЪРИЯТ

## Нәҗип Мәдияр

### Карыйм тауга, упкыннарга

Башымны өскә күтәреп,
Тауларга карап торам.
Биеклектә — бөеклек, нур!..
Мин шуны аңлап торам.

Башымны түбәнгә бөгеп,
Упкынга карап торам.
Анда караңгы шом күреп,
Коточкыч курку тоям.

Беләм, күпләр чордашларын
Юлдан алып чөйделәр,
Һәм тормыш биеклегенә
Күкрәк кагып менделәр.

Ул биеклек тау күк тартты
Бәндәләрне үзенә.
Ә соңыннан очты күпләр
Упкыннар төпкеленә.

Карыйм тауга, упкыннарга
Һәм мине ялкын урый:
«Таулар» — менүчене көтә,
Ә «упкыннар — җан сорый».

### Үзгәрик!

Элек алай түгел иде кебек,
Нык үзгәрде хәзер дөньялар.
Җиребездә санап бетергесез
Кипкән күлләр, кипкән елгалар.

Бик ешайды көчле җир тетрәүләр.
Таулар ишелеп, күмелә авыллар.

---

Нәҗип МӘДИЯР (1928) — *шагыйрь, «Йөз төрле уй», «Уҗымнар уянганда», «Рәшәл офыкларым» һ. б. зурлар һәм балалар өчен дистәдән артык китап авторы. Чаллыда яши.*

Үлгән үлә, исәннәргә кала
Өем-өем булып кайгы-зар.

Искиткеч хәл, диңгезләр дә корый.
Ниләр булды сиңа, замана?
Күгебез дә теткәләнеп бетте,
Шифалыгын җуйды һава да.

Мондый хәлләр булмас иде кебек,
Җир җелеген суырып якмасак,
Күгебезнең якты зәңгәрлеген
Күз алмасы кебек сакласак.

Әле тагын ни күрербез? Белмим.
Китерүе кыен уйга да
Барысы да, әйдә, чәнчелсен дип,
Тик кул селтәп булмый боларга.

Болганышлар, үзгәрешләр чоры!..
Карыйк микән әллә үзгәреп?
Юкса, күлмәк-ыштансыз бит — безнең
Өлешләргә тигән гүзәллек...

## Еллар үткәч

Яшь чакта без бу чишмәгә
Бергәләп килгән идек.
Мин — синеке, син — минеке
Булырбыз, дигән идек.

Ул хисләрне йөрәкләрдән
Никтер тормыш йолкыды.
Икебезне ике ярга
Какты тормыш дулкыны.

Чәчсәк тә сөю хисләрен,
Уңышын җыялмадык.
Мин — синеке, син — минеке
Нишләптер булалмадык.

Үкенеч юк анысына,
Яшь гомерләр үткән ич.
Синең үз тормышың, минем
Үз тормышым җиткән ич.

Шулай да менә әле мин
Мәшәкатьләрдән бушап,
Шул чишмә янында торам,
Элекке, әллә кайчангы
Елмаюыңа сусап.

## Инеш буендагы уйлар

*Яшьтәшем Зәфәр Шәмсетдиновка*

Карап торам томырылып
Тагын инешкә менә.
Матур диләр, ышанмыйм мин
Имеш-мимешкә генә.

Үз күзем белән күзәтәм
Аның матурлыкларын.
Ташлар арасыннан үтә
Әнә бит җырчы агым.

Тирән түгел, тик мул анда
Гүзәллек тирәнлеге.
Ят та ауна — янында бар
Җәй җәйгән чирәмлеге.

Туп-туры булып та акмый,
Бормалы аның юлы.
Әмма мәңгелек үзенең
Авылга тугрылыгы.

Башы да якында. Барсаң
Бер сәгать вакыт җитә.
Ә көмеш кебек сулары
Бик еракларга китә.

Инешкәем, сине күрми
Шактый гомер узылган.
Карап торам, бу карашым
Мең елларга сузылган.

## Бала тирбәтүче бабай җыры

Күп йокладык без бу дөньялыкта,
...Уяндык, тик соңлап уяндык.
Йокла, улым, килер көннәрендә
Юлдаш булсын өчен уяулык.

Изрәсеннәр әйдә аякларың,
Җиргә ныграк итеп басарга.
Йокла, улым, йоклап йөрмәс өчен,
Йом күзеңне — шәбрәк ачарга.

# Мизхәт Хәбибулла

## Көн сурәтләре

Кадер күргән чишмәләрнең
Сукмаклары тап-такыр.
Иелеп су алган чакта
Төбендә кояш балкыр ла,
Тирбәлеп нуры калкыр.

Тын гына карап тордым мин
Онытылган чишмәләргә.
Сыкранды йөрәк, сыкранды,
Белмәдем нишләргә дә лә,
Белмәдем нишләргә дә.

Чүп-үлән баскан чишмәләр —
Кешенең ялгышлары.
Әй, кешем, бул мәрхәмәтле,
Төшмәсен каргышлары ла,
Төшмәсен каргышлары.
Тибегез, әй чишмәләрем,
Җирнең кан тамырлары!
Ә кеше һаман табыныр,
Өзелеп сезне сагыныр...
Ялгышын таныр әле бер,
Ялгышын таныр әле.

* * *

Мин бер яфрак дөнья атлы зур агачта,
Йотылып эчтем чык суларын, кояш нурын.
Мин тибрәлдем жырлап жилләр кочагында,
Бәхетләрнең көтмәдем дә шуннан зурын.

Ник яшерим: үтә жәйләр, житә көзләр...
Саргаермын, өзелермен мин дә бер көн.
Тик кайгырмыйм. Язлар белән яшь бөреләр
Күзен ачар тирә-юньгә хуш ис бөркеп.

Мәңге шаулар бу серле һәм матур агач,
Тулып торыр төрле сайрар кошлар белән...

Шундый уйлар белән көзгә кереп килөм.

* * *

И, җилдән житез аткаем,
Ут иден, яшен иден.
Сыртыңнан күп чаяларны
Сикертеп күккә чөйден.

И, җилдән житез аткаем,
Керми иден тәртәгә.
Ир-ат өчен сине жигү
Булды бер дан, мәртәбә.

Жиктеләр шул. Дуласаң да,
Керттеләр шул тәртәгә.
Авыр-авыр йөкләрне дә
Тарттың син күп мәртәбә.

Сирәк хәзер сокланучы
Карап күкрәк-түшеңә.
Алдыңа солы салалар,
Карап көнлек эшеңә.

---

Мидхәт ХӘБИБУЛЛИН — *Түбән Кама шәһәрендә яшәүче шагыйрь. Шигырьләре көндәлек матбугатта басылып килә.*

# ПУБЛИЦИСТИКА

Тәлгат Галиуллин

## ЗАМАНА БАЛАЛАРЫ

*Бу әсәрнең бер өлеше үткән ел «Казан утлары»нда (№ 11) укучыга тәкъдим ителгән иде инде. Анда сүз озак еллар дәвамында кулларын Татарстан тезгенендә тоткан, әмма шул ук замана корбаннары — «олылар» турында барган иде. Әлеге язмаларның төбендә, бер караганда, минем баштан узган шәхси шатлык-кайгылар, хәсрәт-сөенечләр ята. Шуңа күрә мин, бу язма безнең бүгенге сәяси көрәшебезгә ярдәм итә алырмы, дигән сөаль тууын да күз алдыма китерәм. Әйе, үткәнне гел искә-ятка төшереп торуның хаҗәте юк, ул берьяклы урам, аның буенча кире кайтып булмый. Узып киттең — бетте, вәссәлам. Әмма әлеге язмаларга нигез-өлге биргән Алабуга педагогия институты бүген милләтара ызгышларны көчәйтү үзәгенә әверелеп бара. Шул уку йорты доцентлары А. Вәлиева, Ә. Насыйбуллин, Н. Вердеревская һ. б. татар халкының бәйсезлегенә, суверенитетка каршы көрәш алып баралар. Шул институтның татар теле, фольклоры буенча хезмәт яклаган кайбер галимнәре, олимп тынычлыгы саклап, читтән күзәтеп торалар. Кыскасы, тормыш кузгаткан сорауларның күбесенә җавапны нәкъ менә үткән белән бүгенгенең бәйләнешендә генә табып була.*

*Чынбарлык хыялдан көчлерәк, диләр. Аннан килеп, партаппарат, парткомиссия турында, чын исем-фамилияләрен атап бәян иткән әсәрләр бездә күп түгел. Тормышны тәрәзәдән карап язылган калын-калын, уйдырма һәм хыялый китаплардан туйган укучы, бәлки, бу уйланулардан үзенә рухи азык табар.*

### И язмыш, язмыш...

Алтмышынчы еллар уртасында Алабуга, Чаллы якларына иске, олы ишкәкләре, көпчәкләре белән суны шап-шап кыйнап, җанга, күңелгә талгын рәхәтлек, илаһи бер тынычлык биргүгә сәләтле иске пароходлар йөри иде. Хәзер метеорлар сәгатендә уза торган юлны, икешәр тәүлеккә сузып, гомер агышын санап, кирәксә-кирәкмәсә, көтүдән калган бозау төсле, туктаусыз тавыш бирен, барыбер сине тиешле урынга китереп җиткерә торган иде ул акрыннар. Аларның һәр пристаньда әле алды, әле арты, әле яны белән үлчәп, ашыкмыйча гына тукталышка керүе, аңа элэгү хыялы белән яр буенда мәш килеп йөргән капчыклы, көянтәле, такта чемоданлы кешеләрнең этешә-төртешә керү-чыгу капкасына сылануы күңелдә бер истәлек булып калган.

Алабуга пристане күренгәнче, сине төрле чокырларга, борылышларга, сукмакларга бай, халыкларның ничәмә гасырлар тарихына шаһит

---

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938) — *тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор. КДУның татар филологиясе, тарих һәм көнчыгыш телләр факультеты деканы. «Илһам чишмәләре», «Дәвамлылык», «Гомер учагы» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

сары балчыклы текә яр, күтәрелештән үк башланып киткән нарат урманы эченә оялаган каен, усак, юкә, миләш, шомырт, чикләвек агачлары каршылый. Кинәт Чулман-Кама буендагы борынгы, ямьле тарихи шәһәрчекләрнең берсе — Алабуга пәйда була. Ул кемгәдер ошарга тырышкан чибәр килен төсле, бөтен матурлыгын, сылулыгын берьюлы ачып сала. Сул якта, иң югарыда, килгән-киткән кешене, болгар бабайлар истәлеге «шайтан шәһәре» манарасы каршы алып, күзәтеп, кинәш биреп тора, бирерәк шәһәр читенә алып менүче сырлы тимер баскыч, янә тау, ун якта олы елганың дәвамы да, башы да булып Тойма инеше җәйрәп ята, күп санлы күлләр, төрле стильләрдә салынган чиркәү гөмбәзләре ялтырый. Шәһәр ике елга буена, җил-давылдан саклый алырлык үзәнлеккә сыланып утырган. Сайлый белгәннәр бит урынны кесәләрендә кандидат, доктор димим, иң гадәти диплом кисәге дә булмаган бабайлар. Әнә бит безнең акыллы башлар кыр уртасына, җил тегермәне утыртасы урынга кала салып куйдылар. Җитмәсә, герой-шагыйрь исемен мыскыл иткәндәй, «Җәлил» дип атадылар үзен. «Яңа Алабуга» да, хәер, шундый ук.

Әлбәттә, хатыным Галияне, өч яшьлек улым Илшатны алып һәм бар мөлкәтемне төяп, Алабуга матурлыгы белән тәэсирләнер өчен сәфәр чыгуым түгел иде. Алабуга педагогия институтының рус һәм көнбатыш әдәбиятлары кафедрасына укытучы булып килүем. Берәү булса, «өлком үзе җибәрде», дип тә өстәп куяр иде. Пароходка утыруның сере бер генә: купец Стахеевлар шәһәренә башка юл белән килеп булмый диярлек. Автобус йөрми, Вятка аша күпер юк, самолет очмый, ә тимер юл Алабугадан 100 чакрым ераклыкта удмурт шәһәре Можгада урнашкан. Ул юлда йөргәнче, пристаньда бер атна пароход көтеп утыруың артыграк.

Безне ике машина белән математика укытучысы Тәвриз Мөбарәков каршы алды. Әллә каян «Победа» юнәткән һәм йөк машинасы да алып төшкән. Пристань тавын көчкә менеп, өйгә житәр-житмәс, бензины бетеп, арттан чатыр-чытыр атып, чаткылар чәчеп кайтса да, бу «Победа» минем өчен иң изге машиналар рәтендә калды. Йөртүчесенең буе дисәң — негр баскетболчыларың бер якта торсын! Керәшен егетенең кушаматы да «бер ярым Иван» икән. Машинада бик сәер утыра, җилкә — түшәмдә, баш рульгә иелгән, югыйсә, түбәне тишеп, башны шунда чыгарып куясы була. Шул «Победа» тормышыбызда беренче үз фатирыбызга төшерде. Ахырзаман житеп, берәр котелмәгән сәбәпләр аркасында, оҗмахка эләксәм дә, ул чактагы шикелле бәхетле була алмас идем, дип уйлыйм. Дүрт ел буенча Казанда кеше почмагында, керогаз янында, хуҗа хатынның күзенә чалынудан куркып яшәү шул чаклы туйдырган иде. Беренче мәлне суы юклыкны, бәдрәфнең урамдалыгын, юешлеген дә сизмәдек. Без бәхетле идек.

Тормыш юлымның башында шактый вакыт «кеше өстендә» яшәвемнең соңрак Алабуга пединституты халкына файдасы тигәндер дип уйлыйм. Хезмәт хакы бәләкәй, социаль яктан бичара, хокук белән якланмаган зыялының үз почмагы гына булырга тиеш ләбаса! Шуңар, ректор булып эшләгәндә, минем ярты вакытым укытучыларга, хезмәткәрләргә квартира өчен тартышып узды. Нефтьчеләр, төзүчеләр, арматура, чүпрәк фабрикасы хуҗалары, соңрак КамАЗ кешеләре белән дустанә яшәргә тырышуымның төбендә институтка күбрәк торак юнәтү нияте ятты.

Алабугада тапкан беренче танышым табак битле, коңгырт мыеклы, шактый тулы гәүдәле Тәвриз Мөбарәков үзенчәлекле һәм әллә ничә катлы шәхес булып чыкты. Әдәбиятны бик ярата, татар җанлы, сәләтле укытучы. Вакыты белән бик кырыс, хәтта шәфкатьсез, миһербансыз да булып китә ала икән. Бик сирәк кешедә менә шундый бер-берсенә капма-каршы сыйфатлар бергә сыеша. Ул сине жанында күбрәк яратуы турында елый-елый сөйләп, биш минуттан хатынына: «Ташла син бу начар кешене»,— дип үгетли башларга мөмкин.

Тәвриз белән танышуымның, хәтта Алабуга якларына юл алуымның

төп сәбәпчесе — фани дөньяны бик иртә ташлап киткән, күп еллар дәвамында Татарстан радиокомитетының дикторы, әдәбият-сәнгать тапшырулары баш редакторы булып эшләгән Рим Кәримов, дисәм, шаять, ялгыш булмастыр. Лирик җанлы, эчкерсез шәхес, талантлы актер, шигърьгә, гомумән, матурлыкка гашыйк. Рим Кәримов, университетны тәмамлагач, Алабуга педагогия институтына татар әдәбияты укытырга җибәрелгән иде. Ярты елдан соң ул олыгаеп, җитлегеп кайтып төште Казанга. Группадашларын, фольклор экспедициясендә бергә йөргән егетләрне җыеп алды да: «Сез олы дөньядан, чын кешеләрдән аерылып, Казанда сөрсеп ятасыз, реаль тормыш һәм Джек Лондон егетләре — Алабугада!» — дип, безне шактый әрләде, мещанлык сазлыгына батуда гаепләде безне Рим Кәримов, кечкенә бүлмәне тутырып ишекле-түрле йөреп. Берәүгә дә каршы әйтү түгел, авыз ачарга да рөхсәт юк, кунак тәмам рольгә кереп җитеп, үзенә якты идеал, таяныч маяк буларак кабул иткән укытучыларының исемнәрен дә әйтеп салды: Тәвриз Мөбарәков һәм Гаяз Сәләхиев. Алар өчәү бер бүлмәдә яшиләр, бик дус торалар икән. Рим беренчесенең ике сыйфатын «күчереп алган». Берсе — кешегә фамилия белән генә эндәшү. Икенчесе — ваклашасың, вакланма, ваклама, вагайма, син надан, син миңа ошамыйсың... кебек сүзләр белән кырт кисү, «наданны» урынына утырту. Икесен бергә ялгагач, ут белән суны кушкандай, теләсә кемне бәреп егарлык гыйбарәләр туа: «Галиуллин, син миңа ошамыйсың», «Юсупов, син ваклашасың», «Кәлимуллин, син надан» һ. б.

Мондый мөрәҗәгатен ул «фәнни» яктан дәлилли бара.

— Исем ул — кушамат. Этнең, мәченең, читлектәге кенәринең кушаматы бар. Кеше алардан фамилиясе белән аерылып тора. Шуңар да, без Алабугада үзара мөнәсәбәттә фамилиягә күчтек.

Рим Кәримов нәфрәтендә дә, мәхәббәтендә дә максималист иде. Аның ялкынлы монологларын тыңлаган һәркемнең шундый яхшы, изге, беркайчан да акча санау, бурычны кире сорау кебек вакlануларны танымаучы кешеләрне күрәсе килү табигый дип уйлыйм. Рим, бер кайтуында, Мөбарәковны шул чаклы дәртләнеп, илһамланып мактады ки, хәтта үзе дә кайдадыр шундый изге зат яшәвенә чын күңелдән ышана башлады бугай.

Менә шул Тәвриз мине каршы алды. Безнең байлык хатын теккән алты ак сәрпинкә капчыкка сыйган иде. Дүртесе — китаплар. Шуларны өйгә ташладык та, киттек кибеткә. Очрашуны, квартираны, уңышлы эш башлауны шактый гына «юдык». Бераз квартираны карыйсы, урнашасы килү дә табигый. Ә безнең мәрхәмәтле каршы алучыбыз китәргә ашыкмый. Машинасы белән Иванны да җибәрми, минем әдәбиятны, сәнгатьне белүемне тикшерә. Горький, Фадеев үлемнәренең сәбәпләрен сорый, режиссер Эйзенштейнның туган елын белешә... «Галиуллин, син миңа ошамыйсың» кебек, Кәримовның һушын-акылын алган җөмләне әйткәч кенә, «Победа»га чыгып утырды. Үпкәләмәдем. Ни әйтсәң дә, «беренче чыганак»ны тыңладым. Ничек кенә булмасын, Мөбарәков Алабугадан бәхет эзләп читкә чыгып киткәнче, миңа дустанә мөнәсәбәттә калды.

Беренче көнне шәһәр мине ямьле табигате, мул суы, нәкъ Балтыйк буйларындагы шикелле, бихисап күлләре, яшеллеге, чал борынгысы белән таң калдырса, иртән анда яшәүче кешеләре һәм җан ияләре белән «бәреп екты». Алабуганың Бродвее — йомыры таш җәелгән, ямь-яшел агач башлары бер-берсенә тиеп торган Карл Маркс урамына аяк баскач, этләрнең күплеге артык сәерсендермәде, мондый кечкенә шәһәрләрдә кеше тере, җанлы дөньяга якынрак була, шулай тиештер дип фараз кылдым, ә менә кешеләре гаҗәпләндерде: очраган икенең берсе сукыр, икенчесе — милиция киеменнән. Бу аптыраш минем хәбәрдарсызлыгым, наданлыгым аркасында гына булган икән. Алабугада сукырларның бик олы хуҗалыгы һәм тирә-якта бердәнбер атаклы милиция мәктәбе урнашкан икән.

Нибары өч факультетлы педагогия институтында татарың өчен янып-көеп йөргән ике кеше табылды. Берсе — дөньяның ачысын-төчесен татыган, күпне күргән Мәһинур апа Фәйзуллина. Ире кара һәм караңгы елларда кулга алынгач, аңа «халык дошманы» хатыны буларак, Казанда калырга рөхсәт бирмичә, Алабугага сөргәннәр. Нечкә хисле, тыйнак, ашка-суга оста Мәһинур ханым кызы белән шунда урнашкан. Ул сугышка чаклы ук Тукай, Җәлил иҗатларына багышланган мәкаләләр бастырган, әдәби процесста шактый катнашкан. Үзенең әйтүенә караганда, ул татар хатын-кызларыннан беренче фәннәр кандидаты икән.

Гомерен татар әдәбиятын укытуга, өйрәнүгә багышлаган, халкының киләчәге өчен борчылып, хафаланып арабыздан китеп барган Мәһинур апаның урыны оҗмах түрендә, яткан туфрагы җиңел булсын. Ифрат татар җанлы, эчкерсез, самими кеше күренгән иде ул миңа. Пенсиягә чыккач та, тырыша-тырмаша мутант оныкларын Казанда фатирлы итеп калдырды. Ничек аңа рәхмәтләр укымыйсың?!

«Вечерняя Казань» газетасы 1991 елның 13 март санында Алабуга педагогия институты укытучысы Ария Хәбиб кызы Вәлиеваның «Мутанты — нелюди» исемле татарга каршы язылган, җанны өшетерлек үчле, әшәке мәкаләсен урнаштырды. Белүемчә, әлеге чыгыш башка милләт, бигрәк тә рус кешеләренә искиткеч тирән тәэсир ясады. Ник дисәң, хат авторы — татар, доцент, укымышлы кеше, ул да русларны кысуга, җәберләүгә түзә алмаган, аларны яклап ярсулы оран салган. «Шәһри Казан», «Социалистик Татарстан» һәм башка газеталарда да мәкалә татар халкын күрә алмаган, шовинизмның ачык бер чагылышы буларак бәяләнде.

Әле генә сүз Мәһинур Фәйзуллина турында барды, кинәт кара рухлы, өтек эчтәлекле бер мәкаләгә сикердек. «Вечерняя Казань» — татарны сүгеп дан алган газета, биредә искитмәле нәрсә юк, диярсез. Бөтен хикмәт шунда: Ария Вәлиева — Мәһинур апа баласы. Кызы да озак еллар дәвамында шул ук уку йортында татар студентларына әдәбият, димәк ки, кешелеклелек, игелек, дуслык дәресләре укыта, мәктәп методикасына өйрәтә. Итагатьле татар балалары Ария ханымның кайбер җитешсезлекләренә күз йомдылар, рәнҗетмәделәр, доцент хезмәте хакы алып, үзе әйткән ике «мутантны» үстерергә матди мөмкинлек тудырдылар.

Кызының сабыр сабы ычкынганы өчен анасы гаепле түгелдер. Бәлки, Мәһинур апа исән булса, инде үзе дә алтмышның өске ягына атлап, акыл теше чыгарга вакыт җиткән кызына тайгак, пычрак юлга төшәргә, үз халкына каршы көрәшкә күтәрелергә киңәш бирмәс иде. Шунда ук, алма агачыннан еракка төшми, дигән икенче бер мәкаль күңелне тырный. Ни әйтергә дә белмим.

Ария ханым белән 20 ел дәвамында бер кафедрада эшләп тә, мин аның мәкаләдә юл уңаенда мактанып алган, дүрт тел белүен дә (шулар арасында үле латин теле дә аталган), бик тирәндә үз халкына агулы нәфрәт саклап йөрүен дә белми-сизми калганмын. Әнисе белән азмы-күпме татарча аңлаша алганын хәтерлим, татар әдәбиятын, матбугатны укып бармаганын исә тәгаен беләм.

Ни өчен Ария Хәбиб кызы үз халкын шулай каһәрли, аңа гаеп ташлый соң? 1937 елда әтисен нахакка кулга алып, татарлар ук аткан өченме? Милләтенең азмы-күпме уянып, рәнҗетелгән тарихын, кимсетелгән язмышын аңларга омтылуы күңелен болгаттымы? Мәкалә уңае белән матбугатта чыгыш ясаган кешеләр аның эчтәлегендә тирән мәгънә эзләп, әллә нинди югары фәлсәфи, әхлакый биеклекләргә күтәрелеп киттеләр. Минем өчен бу бик гади һәм аңлаешлы нәрсә. «Мутанты — нелюди» мәкаләсе авторы халәтенә, бил бөгеп, тез чүгеп яшәвенә риза, башка милләткә хезмәт итеп сындырылган татар халкының мескенлектән килгән авазы гына. Иҗтимагый ноктадан килеп бәяләгәндә, бу күренешнең төбендә башка милләт алдында ялагайлану, яхшы атлы булу, «мәхәббәт дивидентлары» яулап алу ята. Башка берни түгел. Ария ханым ире һәм

урыс милләтенең санын арттырган балаларына шулай ярарга тырыша. Янәсе, ул аларга шул чаклы тугрылыклы, жанын бирергә, халкын сатарга әзер. Ә бит дус-ишләренә, якыннарына ялагайланып, тәлинкә тотып, мәкалә авторы, методист буларак, олы хата ясый, телиме-теләмиме, ул үзе үк ике халык арасындагы дуслыкка чөй кага, урыс милләте кешеләрен, бигрәк тә мутантларны куркыта, өркетә, көрәшкә өнди, баррикадаларга чакыра.

Бу чыгыш Алабуга өчен очраклы күренеш булса бер хәл иде. Редакторы татар кешесе булган «Новая Кама» газетасы жирле халыкның мәдәниятенә, теленә, үзаңы үсүгә каршы көрәшендә «Вечерняя Казань»нан калышмаска тырыша. Анда да педагогия институты укытучылары өлгерләрнең өлгере, булганнарның булганы...

1991 елның 18 февралендә Казан телевидениесеннән барган «Уяну» исемле тарихи-документаль тапшыруга ике меңгә якын кеше уңай бәя биреп, аны яңадан кабатлауны сорап хат яза. Тапшырудан ризасызлык белдергән ике генә хат килә Казанга. Икесе дә Алабуга шәһәреннән. Берсе Ария Вәлиева хаты булса, икенчесенә кул куйган алты кеше арасында жирле институт доценты, элеккеге «марксист» Ә. Насыйбуллин фамилиясе бар. Гомерләре тамак ялына узган сәер буын. Аларны Хрущев «жепшеклеге» дә эретә алмады, яңартып корунның жилләре дә мүкле йөрәкләренә үтеп кермәде.

Аяз көн кебек ачык мәсьәлә тирәсендә сүз куертмастан, Алабуга педагогия институты педагогика кафедрасы укытучысы Тәзкирә ханым Шәрипованың миңа язган хатыннан гына бер гыйбрәтле өзек китереп үтәсем килә. «Татарлар белән русларны берләштерергә жыенганнар, дип сөйләгән, имансыз хатын (Ария Вәлиева — Т. Г.). Чыннан да, «Уяну» фильмы бүгенге көндә бик кирәк. Без болай да бит индә үзебезнең тарихны белми яшәдек, хәзер күзне ача башлаганбыз икән, үзебезнең үк манкортларыбыз тырыша-тырыша русларны безгә каршы котырталар». Фикер ачык, төгәл әйтелгән, минемчә.

Янәдән Алабуга педагогия институтын бизәгән шәхесләргә кайтыйк. Татар өчен тырышып йөргән икенче шәхес — фажигале язмышлы, Кырым татарлары шагыйре, галим, тәнкыйтьче, рус әдәбияты кафедрасы мөдире Керим Решидов иде. Бездә аның шигырьләре Керим Жаманаклы дигән имза белән басылып чыккалады. Алабуга якларына ничек һәм кайчан килеп урнашуы хакында соравы кыен иде. Күрәсең, Сталин Кырымны төп халкыннан көчләп азат иткәндә, бу якларга чыгып киткәндер. Хатыны Рәшидә ханымның Казаннан булуы да, ихтимал, аларның бу якларда төпләнүенә ярдәм иткәндер. Мин ап-ак чәчле, сары йөзле, кысык күзле, шактый олы гәүдәле бу кеше кул астында нибары берничә ай эшләп калдым. Аны рак дигән зәхмәт алтмыш яшендә арабыздан алып китте.

Дөресен әйткәндә, Алабугага күчеп килүемне жиңел кулдан Рим Кәримовка «сыласам» да (ул үзе Алабугада өйләнеп, аспирантурага кереп, бик тиз Казанга әйләнеп кайтты), чынында мәрхүм Хәсән Сәрьян белән 60 еллык юбилеена килгәндә, үзе житәкләгән кафедрага мине Керим ага кодалады. Мин аңа бик тә рәхмәтлемен. Ул Татарстанның мәгариф үсешенә керткән өлеше, туган халкын бабалары жиренә кайтаруга тырышып-тырмашып йөргәне өчен дә игътибарга һәм ихтирамга лаеклы шәхес. Бер мәлне шагыйрь Әхмәт Гадел белән аның шигырьләрен, тәнкыйть мәкаләләрен сайлап алып, тәржемә итеп, бастырып чыгару идеясе белән дә янып йөргән идек.

Кыскасы, Алабуга педагогия институтында татар мәдәнияте турында кайгырту менә шул ике өркетелгән, куркытылган, сындырылган кеше жилкәсендә икән. Ректоратта «милли мәсьәлә» жиңел хәл ителгән, хәзергә КамАЗның югары эшелонындагы шикелле, татар кешесе житәкчелектә юк диярлек. Ректор вазифаларын тарихчы ханым К. П. Петрова башкара, аның беренче урынбасары, хәзер Израильгә чыгып киткән, матема-

тик Г. А. Фрейман, читтән торып укучыларның хуҗасы Каверзин дигән иптәш. Шуңа күрә кайчандыр гөрләп эшләп килгән татар теле һәм әдәбияты бүлегенең ябылуы да, нигезен, таянычын югалткан кафедраның юкка чыгуы да табигый. Караул кычкырырга да, *SOS* бирергә дә кеше юк. Еламаган баланы ашатмау — мәгълүм хакыйкать.

Бер шагыйрь: «Халыкның рухы-иманы барыбер туган телдә»,— дип язуы белән мең хаклы. Рус, инглиз мәктәпләрендә белем алган, үз туган телен нечкәләп белмәгән кеше үз милләтенең кайгы-хәсрәтен тирәнтен аңлаучы, халкы өчен җанын фида кылырга әзер торучы шәхес дәрәҗәсенә күтәрелә алмый, гадәти бер функционер булып кала. Аның рухи таянычы юк. Бер миллионлы эстон халкын үз телләрендәге мәктәпләр һәм бигрәк тә югары уку йорты коткарып, милли аңга ия, мөстәкыйль милләтләр рәтендә саклап калды.

Милли мәктәпләр кичергән фаҗигане башка халыкка, үзәккә сылап калдыру берьяклы булыр. Соңгы 20—30 елда татарның үзе арасыннан ана телен белмәгән, белергә дә теләмәгән, үз милләтенең әхлакый, дини, яшәеш йолаларын тәненә, рухына, канына сеңдермәгән яңа буын күтәрелеп, бик күп мөһим урыннарны биләп алды. Аларның күбесе өчен нинди аллага хезмәт итү, кайсы пәйгамбәргә табыну барыбер, тик тамак тук, өс бөтен, балта сабы кулда булып, кесәдән акча саекмасын. Мәскәү яратсын. Күбесенең хатыны башка милләт кешесе булып, нәселе аның үзендә яшәүдән туктар. Ул кавемне «кыйбласыз татар» дип атау дөрес булыр кебек.

Ә хәзер безгә халык киләчәге өчен җан аткан, гаделлек өчен көрәшә белгән нечкә күңелле, сизгер кешеләр, кыю җаннар кирәк. Хәер, аларга ихтыяҗ беркайчан кимемәде, әмма сталинизм дәверендә андый зыялы шәхесләр кургашка азык булдылар. Шуннан өзеклек барлыкка килде.

Милләтләрнең көннән-көн якыная, кушыла, уртак телгә күчә бару теориясе без төзегән җәмгыятьнең югары казанышы буларак тәкъдим ителгән имансыз елларда татар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләү үзеннән-үзе кысыла, юкка чыгарыла килде. Алтмышынчы еллар уртасында бу сәясәт, шул рәвешле, Алабугада татар кафедрасын ябуга алып килде, шундый ук җинаять элегрәк Тобол пединститутында эшләнде. Педучилищеларда татар бүлекләре кырылды. Татар мәктәпләре күпләп ябылу сәбәпле, әлеге фәнне укытучыларга да ихтыяҗ кимеде.

Хрущев—Брежнев идарә иткән заманнарда вак авыллар перспективасыз дип игълан ителә, аның мәктәбе дә бетерелә, олыракка кушыла. Ә милли мәктәпләрнең күбесе менә шул «вак комплектлы», дөресрәге, комплектсыз булып чыга, район, колхоз, совхоз үзәгендә урнашкан зур мәктәптә укыту рус телендә алып барыла.

Анда инде бабалары мирасын, Тукай телен онытуны мәртәбә, зыялылык санаган, алда әйткән түрә балалары укый. Соңгыларына татар теле факультатив рәвешендә дә кирәк түгел. Кем инде «кухня телен» өйрәнеп баш катырсын да, вакыт әрәм итсен, ди. Соң, кечтеки мәктәпләрдән күчкән укучыларның ата-аналары ни өчен татар телендә сыйныфлар булдыруны, барын саклауны таләп итми, диярсез. Татарны милләт буларак юкка чыгара килгән әлеге кыюсызлык, язмышка буйсынып яшәү, коллык психологиясе җиңеп чыга бу очракта.

Арада әрсез, елгыр, үзфикерле, үзбәяле ата-ана килеп чыкса, татарлар үзләре үк аларның гайрәтен, кикриген менә мондыйрак дәлилләр белән шиңдерәләр: «Син нәрсә, үләргә аягын сузган татар телендә укытып, балаңны надан калдырасың киләме? Почмак теле аттестаты белән ул кая бара ала да, кемгә кирәк? Югары уку йортына, артыннан төртүче булып, керсә дә, укый алмаячак. Балаларың да үзең кебек тракторчы, хатыныңның төсле сыер савучы булып калсын дисеңме?» Аңлашылса кирәк, йөрәк парәсенә бары изгелек теләгән ата-ана әлеге киңәшләр белән килешә, нәтиҗәдә мәктәптә татар сыйныфы ачылмый кала.

Тыйнаклык яхшы сыйфат, әмма ул милли мескенлеккә, карусызлыкка әйләнсә, анысы инде — фаҗига. Зөлфәт «Безнекеләр» шигырендә бу хакта дөрес яза:

Безнекеләр — сабыр... Безләрне шул
Сабырлыктан гына танырлык —
Бик тамырлы булып чыкты безнең
Бар дөньяга мәшһүр сабырлык.

Телне кисеп, артны ямасалар,
Безнеме соң ачу җилкетер? —
Юк, без сабыр! Безнекеләр һәрчак
Рәхмәт укып, сакал селкетер...

Дөрес, поэзиягә җилле, давыллы, романтик шагыйрь буларак бәреп кергән, инде җитлеккән Илдар Юзеев халыкны нәкъ шуның киресенә үгетләү юлына баса:

Һәлакәттән кешелекне,
Җирне тотып калырлык,
Тик бер көч бар, илаһи көч:
Сабырлык...

А. Гыйләҗев, киресенчә: «Нигә шулкадәр юаш без? Нигә шул кадәр рухсыз, көрәшсез яшәгәнбез?!..» — дип ачынып яза («Казан утлары», 1990, № 8). Ярый, менә без, мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр, татар мәктәпләренең шауламыйча, кычкырмыйча, бик сабыр гына үлеп, урыс, башкорт телләренә күчеп баруын ни өчен шулай тыныч кабул иттек соң? Күп еллар буена Татарстан мәгариф министры булып эшләгән кадерле академигыбыз Мирза Мәхмүтов җәмәгатьчелекне матур, ялтыравык чыгышлары белән таң калдырып, мәрткә җибәреп, «сабырлык даруы» белән йоклатып тоттымы? Аны да аңлап була, хәер, туктаусыз чит илләргә йөреп, олы халыкара мәсьәләләр белән шөгыльләнеп, аннан докторлык диссертациясе, соңрак Татарстанда урнашкан оборона заводлары, хәрби мәктәпләр, берише уку йортлары төсле, бөтенләй хаҗәте булмаган фәнни-тикшеренү институтын ачу белән мавыгып (дөрес, агай-эне башка советлардан борып кайтарган докторлык диссертацияләрен «Мәхмүтов институтында» бик җиңел яклый, диләр), берничә сыйныфлы милли мәктәпләрне юкка чыгару, Казандагы бердәнбер 35 нче татар мәктәбен бетерү, шәһәрләрдә мәгариф җитәкчелегендә җирле милләт вәкилләреннән кешеләрнең бөтенләй диярлек калмавы кебек «вак-төяккә» игътибары, вакыты җитмәде. Поезд бер рельсыннан төшсә, аны кабат бастыруы бик кыен нәрсә икән шул. Аның мәгарифтән «котылганына» да шактый вакыт үтте, ике министр алышынды, янә яңасы килде, әмма үзгәреш аз.

Хәзер дә татар телен укытуның күп мәктәпләрдә, бигрәк тә шәһәрләрдә, сүз өчен, күз буяу, үзебезне үк алдау, кыскасы, хыялый дөнья тудыру, өтек өмет хисабыннан гына эшләнгәне сер түгел. Шомартырга, күпертеп, арттырып күрсәтүгә шул чаклы өйрәнгәнбез, алдашуга җиңел барабыз. Ә вакытны югалткан берәүнең дә аны кире таба алганы юк.

...Инде янәдән Алабуга якларына әйләнеп кайтсак, беренче мәлдә институт эшенә, фәнниләбрәк әйткәндә, аның үзенә бер «микроклиматына» өйрәнүе шактый кыен булды. Авылда туып үссәм дә, университетта уку, эшләү һәм ТӘТИдә өч ел кече фәнни хезмәткәр булып йөргәндә галимнәр, язучылар белән аралашу үзенә бер шәһәр һәм мәдәният чирканчыгы биргән, күрәсең. Алабугада, аралашыр мохит булмау, институтны үз эченә бикләнүгә алып килгән. Ялгыз агачны корт басар, диләр. Җәмгыятебез, илебез төсле үк, ябык, «ярым хәрби» оешма булып киткән. Ә үз «эчендә дә» әле югары уку йорты йолалары (ул педагогия институты булып 1953 елда гына оеша), җитди фәнни юнәлешләр юк, табынып карап торган җиде-сигез фәннәр кандидаты да, гыльми эзләнүләрдән күптән читләшкән өлкән буын кешеләре. Кафедралар, каби-

нетлар булуга карамастан, тәнәфес вакытында бер укытучы да аларга керми, мәктәптәгечә, уртак укытучылар бүлмәсенә юл ала, кулын юа да, гомуми сөйләшүгә, гайбәткә кереп китә: берсе кичә кибеттән алган әйберен күрсәтә, базар бәяләрен сораштыралар...

Һәр көнне диярлек җыелыш. Гыйльми совет утырышы коммунистларның тәрбия, әхлак, якты киләчәкне якынлаштыруга багышланган кайнар сөйләшүләре, дип уйлый күрмәгез берүк, барысы да озын-озак профсоюз җыелышлары. Гадәттә, көн тәртибендә әхлак мәсьәләсе: интим-шәхси характердагы хатларны кычкырып уку һәм тикшерү. Берәве чит, матур апага күз салган өчен ире өстеннән язып бирсә, икенчесе, артыннан сөйрәлеп йөреп тә үзенә өйләнмәгән егетне тәртипкә чакыруны сорап профсоюзга мөрәҗәгать итсә, өченчесе үзе аспирантурада чакта, хатыны ирләр белән чуалып, шул чорда сөяркәсенә язган хатларын кулга төшергән «бәхетле» ир булырга мөмкин. Ул да, йола буенча, язмаларны шатлана-шатлана профкомга китереп бирә һәм бик кырыс тикшерү таләп итә.

Хатлар килми торса, профком үзенә шөгыль эзләп, «халыкка чыга», әллә нинди шәхси эшләр уйлап таба.

Натуралист, тормыш-көнкүреш язучысы шул җыелышларда утырса, язарына күпме азык табар иде! Ул чорда профком рәисе педагогика кафедрасы мөдире, илле бишен тутырган Зыя Әхмәров иде. Җыелыш көнне, мәҗбүри рәвештә, үтүкләнгән, җөйләре куылган, ап-ак костюмын кияр, президиум өстәле артына берүзе чыгып басып, көн тәртибен раслатыр да, татар колагына ямьле акцент белән, нәүбәттәге хатны укуга керешер. Зал шыгрым тулы булып, чебен очкан тавыш та ишетелмәс. Җыелышларны вакытны заяга әрәм итүнең әшәке бер алымы дип санаучы акыллы баш скептиклар да, кинога мөкиббән киткәннәр дә шунда утыра. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклабрак сурәтләүләргә барып җиткәч, хәтта өлкән педагогыбыз да каушабрак кала. Оялып кына:

— Бәлки, бу җирләрен укып тормабыз?— ди.

Хатын-кыз тавышы:

— Нәрсә сез? Тулысынча укырга кирәк. Безгә бит кеше язмышын хәл итәсе!..

Ректор ханымны алыштырган, Казаннан җибәрелгән Е. Тихонов бу куркыныч шөгыльне туктатуга ирешге.

Бер ел кафедрада эшләгәннән сон, мине филология факультетының башлангыч сыйныфлар өчен укытучылар әзерләү бүлеге буенча декан ярдәмчесе эшен тәкъдим иттеләр. Бирәдә кадрлар белән кытлык икән, ярдәм итмичә булмас дип, яңа вазифаларны үтәргә керешкәч кенә, мине кинәт «күтәрү»нең серенә төшендем. Бу белгечлекнең читтән торып уку төре генә калган һәм анда да студентлар кабул итү туктатылган булып чыкты. Бүлек исә башка белгечлек алырга теләүчеләр исәбенә, өреп тутырылган һава шары төсле «күбенгән», беренче курска кабул ителгән илле урынына өч йөзләп кеше укып йөри. Югары партия мәктәпләре гомуми югары белем биреп, диплом тоттырып чыгарсалар да, тагаен бер һөнәргә өйрәтмиләр. Күбесе партия, совет, комсомол, профсоюз аппаратында утыра. Шундыйларның күбесе, шул исәптән, Алабуга горкомының беренче секретаре Л. Чернов та, өченче курска студентлыкка «язылган». «Язылганнар», дим, аңлы һәм җаваплы рәвештә әйтәм, чөнки аппарат кешеләренең сиксән проценты сессиягә йөрми, соңрак, машинасы белән килеп, укытучыларны кунак итеп, зачеткасына бәяләр җыеп китә икән. Ярлы укытучы халкына мондый «тыныш билгеләре» шулай ук кирәк. Тик шул ук Тәвриз Мөбарәков турында гына, коньякларын эчә, уылдыгын тәмли, тутырган тавыкларын ботарлый, әмма бәяне куймый: «Син — надан, тагын килерсең!» — дип, иң олы җитәкчеләрне дә буш зачетка белән озаткалаган, дип сөйлиләр.

Тирә-як район, шәһәр җитәкчеләренә ярарга тырышып, ректор да,

декан да чама хисен югалтканнар, тикшерә башлагач, бернәрсә ачыкланды: уку планын ярым-йорты үтәп, ел ярымда институтны тәмамлаучылар да, техникум, училище дипломы белән өченче курска «теркәлгәннәре» дә байтак кына.

Без капчыкта ятмый, бу тәртипсезлекләр өлкә комитетына, Мәскәүгә барып житә, бер-бер артлы комиссияләр килеп төшә, факультет мөстәкыйльлеген югалтып, бүлек хәленә төшеп, филология факультеты составына кертелә. Декан эшеннән куыла, Казаннан яңа ректор килә.

Менә шунда тәртип урнаштыру өчен, бу як кешеләре белән аралашмаган, тузанлы, кара эштән курыкмый торган декан ярдәмчесе кирәк булган икән. Һәр көнне диярлек унар-унбишәр кеше институттан чыгарыла башлады. Кемнеңдер авырткан сөяленә дә басылгандыр, үпкәләп, ачуланып йөрүчеләр дә, куркытып караучылар да булды. Яшь чак, диңгез тубыктан, дигәндәй, бернәрсәгә карамыйча, ректоратка үземнең фикерләрне язма рәвештә житкерә тордым, шул исәптән үзебезнең беренче секретарьны да студент вазифаларыннан «азат» иттек.

Алабугада эшләү дәверендә фирка хуҗаларының төрлесен күрдем. Леонид Георгиевич ифрат татар җанлы кеше булуы өстенә, институт хәлләрен аңларга, кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә омтылып торуы белән күңелдә калган. Институттан чыгарган өчен дә үпкә сакламаган икән үзе, соңрак, берничә тапкыр үзенә чакырып, идеология буенча сәркатип булырга димләде. Минем анык, төгәл, нәтиҗәсе күренеп торган эштән аерыласым килмәде. «Алабуга Сусловы» була алмый калдым.

Бу конкрет шөгыльнең киләчәк өчен файдасы зур, мәктәбе җитди булды. Документлар белән эш итәргә, кешеләр белән аралашырга өйрәнеп калдым. Бу гамәли тәҗрибә алдагы дүрт елда уку-укыту һәм фән эшләре буенча проректор, 1971—1986 елларда ректор булып эшләгәндә дә ифрат та файдалы нигез булды.

Дөньялар имин торса, Алабуга techинституты үткән юлны, аның укытучылар әзерләүгә керткән өлешен киләчәк буын тарихчылары тәфсилләп өйрәнерләр, мөһерләрен сугарлар әле. Аннан соң, институт — үзе бер абстракт төшенчә, аның эчтәлеген кешеләр билгели. Аларның барысы турында сүз алып бару шулай ук мөмкин түгел. Шуңа күрә фикер каймагын 80 еллар уртасында институт тормышында шактый зур урын алган, ахыр чиктә Алабуга югары мәктәбен икегә бүлүгә алып килгән бер вакыйга тирәсендә төерләргә булдым.

## Утлы күмер

Сталин төрмәләре, ГУЛАГ иле фаҗигалары, хокук саклау оешмаларының хокуксыз халыкка каршы кылган явызлыклары әдәбиятта шактый тулы яктыртылды. Татар прозасы да бу гомуми фаш итүгә Ибраһим Сәлаховның «Колыма хикәяләре»н өстәде. Хәзер бу юнәлештә кабатлана да башладык: А. Солженицын, В. Гроссман, В. Шаламов, якташыбыз Е. Гинзбург язганнарга нәрсәдер өстәве дә кыен шикелле.

Әмма шул ук чорда залим Сталинның мәкерле хыялы тудырган гаҗәеп көчле бер оешма эшчәнлеге турында без бик аз беләбез, бөтенләй язмыйбыз. Аның ил, партия тормышында, халык язмышында тоткан урыны турында «Дети Арбата» романында А. Рыбаков кына азмы-күпме мәгълүмат биреп үтә. Башка әсәрне хәтерләмим.

Хикмәт шунда: илдә урта гасыр инквизициясе котырынган чорда ук, «троцкичы», «солтангалиевче», «җидегәнче», «милләтче» тамгасы алган зат, прокуратура тикшерүчесе кулына килеп кергәнче, фирка контроль комиссиясенең тегермәне аша үтәргә тиеш иде. Шунда «иманын» укыткач, дөресрәге, яшәүгә дәртен, ихтыярын сындыргач, ник туганына үкендергәч, фиркалене казыйга, төрмәгә илтеп тапшыралар.

Шул караңгы елларда төп юнәлешләрен алып, вазифаларын ачыклап, көчәеп, ныгып калган комиссияләр КПССның соңгы минутынача, партаппаратның төп җәзалау, үзфикерле, үткен, чая, зыялы коммунистларның муенын «кытыклау» урыны, халыкны тезгендә тотуда төп таянычы булып кала килде.

Парткомиссиянең чәчәк аткан, димәк ки, котырынган чоры имзасыз хатларның, имеш-мимешнең, чыш-пышның, ялган язмаларның житди дәлил, рәсми дәүләт документы буларак бәяләнгән чоры — үкчәсенә янартып кору һәм демократия баса килгән «сугышчан» торгынлыкның соңгы, черек елларына туры килде (Әлбәттә, 30—40 нчы еллар бу үлчәүгә куелмый). Ул аның соңгы сулышы, үлеме алдыннан ачыргалануы булгандыр, күрәсең.

Миңа бу оешма белән очрашырга, күрешергә, аралашырга насыйп булды. Бу хикәяттә сүз өлкә парткомиссиясе уздырган бер «эш» турында гына барачак. Ләкин шул тар гына мәйданда да аның кешедә коллык психологиясен уята, рухны сындыра белү алымнары, юнәлеше, мөмкинлеге ифрат төгәл чагыла.

Адәм баласына һәр чорда үзенең бөтенлеген, әчкә бәйсезлеген, әхлакый дөньясының пакьлеген, кабатланмаслыгын саклап калу жиңел булмаган. Ә безнең тоталитар режим намус, вөждан, шәхескә игътибар кебек төшенчәләрне арзанлы демагогия белән алыштырды, аяк астына салып таптады.

Шул ук шикаять хатларның ерак чал тарихы бар. Ул — кешенең явызлана, усаллана баруының бер билгесе генә түгел, вакыты белән үзен башкача яклый алмаган шәхеснең иҗтимагый тигезсезлеккә каршы көрәш алымы да. Мондый хатларның шул ике ягын да трагедияләрендә һәм сонетларында Шекспир даһиларча ачып биргән. Ялган сүз, гайбәт, пычрак язма Рәсәйдә генә күпме олы шәхесләрнең башына житте?! Әмма белүемчә, бер генә демократик илдә дә имзасыз хатларны житәкче фирканең болай «зурлаганы» юк. Кызык хәл: Үзәк комитет, Совет хөкүмәте бик олыдан кубып, барабаннар кагып, байраклар күтәреп, тантаналы карарлар кабул итә. Журналистлар хәтсез шаулый, тау-тау мәкаләләр, китапчыклар басыла. Әмма әлеге карарда кабул ителгәннәрнең күбесе (хәтта берсе дә) үтәлми, бер оешма да аның гамәлгә керүе белән кызыксынмый, тикшерми.

Шул ук чорда үзәк оешмаларның берсенә папирос кәгазендә, хәреф хаталары белән басылган, автор фамилиясен куярга «оныткан» тәнкыйть хаты килеп төшсә, парткомиссия байтак кешене эшеннән аерып, командировкалар юнәтеп, язма күрсәткән юнәлеш буенча чыгып китә.

Барлык хатларны да шулай тикшергәннәр икән, диген беркатлырак фикер тумасын берүк. Анда да алшартлары бар: житәкче өстеннән артык күп язалар, туйдырды ясә хәтта пычратылган коммунистка партаппараттан кемдер (әлбәттә инде, инструктор түгел, югары дәрәҗәле иптәш) күптәннән теш кайрап йөри. Ә болай шикаятьне олыдан кубып өйрәнү һич тә мәҗбүри түгел, гомуми сүзләрдән торган җавапны кул куеп җибәрү мәсьәләне ябу өчен бик тә житкән.

Бу хәтлесе әле ишетеп, чамалап белгәнем генә иде. Үз башыңа төшкәч кенә чын башмакчы булып житешәсең, диләр. Минем күктә канатсыз очкан бер чор. Профессор таныклыгы кесәдә, китаплар чыгып, мәкаләләр басылып тора, дус-ишкә кытлык юк. Күптәнге таныш Рәис Беляев идеология секретаре булып Казанга күчкәч, ул инде мине белә, аяк терәп, курыкмыйча эшләргә, яшәргә мөмкинлек бирер, диген уй-хыял күңел түрендә аяк бөкләп утыра. Хәер, аның белән мөнәсәбәтемне, күрше авылдан булуымны, абыйсында укуымны, олы дәүләт серен саклагандай яшерә башладым. «Сез бит дуслар икән»,— дип бәйләнсәләр, «юк, начальство белән каберең якын булмасын» кебегрәк шаярту белән котыла идем. Әмма безнең «ачык» җәмгыятьтә берәр нәрсәне йомып калып буламы соң? Тормыш нинди дер өстән иңгән, кемнеңдер

акыллы башында бөреләнгән кануннар буенча гына яшәми икән. Аның үз табигый тәртибе бар, кеше аңа җайлашырга, буйсынырга тиеш. Көтелмәгәндә килеп чыккан бер хәл мине җиргә төшерде, ыргылып барган тулпарны тышауга куярга туры килде.

Партия аппараты мине бөтенләй көтмәгәндә эзли башлаган. Алабуга парткомиссиясе рәисе шалтырата икән.

— Тәлгат Нәбиевич, сезгә сәгать бердә минем бүлмәдә булырга кирәк.

— Нәрсә бар?

— Өлкомнан институтны тикшерергә бригада чыга, иртәнге автобус белән, ректорны чакырып куегыз, диделәр.

— Бер дә хәбәрләре булмады. Нидән шулай зурлыйлар икән? — дип телгә салынам.

— Әйтергә кушмаганнар иде. Дуслардан яшереп булмый. Бер имзасыз хат Үзәк парткомиссиядән әйләнеп кайткан. Өлком, гадәттә, безгә тапшыра торган иде андый язмаларны тикшерүне, бу юлы үз кешеләрен җибәрергә булган.

— Комиссия составын белмисезме?

— Юк, җитәкчесе, өлкә парткомиссиясенең мөдир урынбасарымы, инструкторымы, әйтә алмыйм. Фамилиясе — Липатникова.

Табигый ки, күңелгә шом, вәсвәсә бәреп керде. «Кунаклар»ның максат-ниятләре турында беләсе, тынычланасы килә. Җанга тия, сөяккә төшә торганы — билгесезлек, ачыклык җитмәү. «Тыныч» көннәрдә кәрәш авыррак, яшертен дошман күп мәртәбә хәтәррәк, диләр.

— Сез аның белән танышмы?

— Күргәнем бар. Берәр җитәкчене эшеннән алырга, партиядән чыгарырга кирәк булганда, шул хатынны җибәрәләр.— Артыграк әйтеп ташлаганын аңлап алды шундук егетем:— Сезгә куркырга урын юк, дип уйлыйм, эшегез яхшы бара, Беляев белән якташ... Хушыгыз, соңармагыз.

Комиссияләрне күп күрде инде «авыл» désинституты торгынлык елларында. Тикшерүләрнең төрлесе була: алдан билгелесе, бер-ике кешедән торганы, аерым мәсьәлә белән генә кызыксынганы... Сылтау табып сыйланырга йөрүчеләре дә аз булмады ул елларда. Күзне йомсаң, әле хәзер дә, төсле чемоданнар күтәргән, җилкә аша сумкалар аскан, серкалар тоткан тикшерүче, киңәш бирүче, тәҗрибә белән кызыксынучы затлар, гәрәбә тәсбих төймәләре төсле, үтә күренмәле булып, җемелдәшеп тезелешеп күз алдына килеп басалар. Барысы да диярлек кешечә эшләнә торган иде, бер ай, атна элек институтка шалтыраталар: кунакханә, маршрут мәсьәләләре алдан сөйләшенеп, тиешле белешмәләр язылып, фин кәгазендә бастырып куела торган иде. Бу Комиссия башкаларга охшамаган. Хәер, көтмәгәндә килеп төшеп, бухгалтерияне селкеткәләделәр, складларда яткан, читкә киткән әйберләрне барладылар.

Вакыт узсын, чабата тузсын, дип утырмасаң, эшләгәндә барысы да ал да гөл генә булып тормый. Шикаять хатлары да, партия өлкә комитеты бүлегенә чакырып сөйләшүләр дә, райкомда аңлашулар да чыккалый. Институт — катлаулы, җанлы организм, анда туктаусыз хәрәкәт, үсеш, ярыш, һәр көнне диярлек бөтенләй көтмәгән җирдән бер-бер хәл чыга да куя. Син аны ишектән көтәсең, ә ул, мунча пәрие төсле, тишек түшәмнән төшә.

Үзем дә күктән иңмәгән — шул ук чәчәк аткан, нык үскән социализм җимеше. Кеше арба җиккәндә, чана белән чыкмадым, хәлдән килгәнчә тырышкан булдым.

Иншалла, хәзер кешене төнге бердә, күршеләр, балалар йокыга киткәч алулар юк, мене көндезгә бергә ипле генә чакырдылар. Җидеме-сигезме кешедән торган бик абруйлы комиссия булып чыкты. Сыйфатларына гына игътибар итегез: СССР Педагогия фәннәре академиясенең әгъза корреспонденты А. Кирсанов, Казан désинституты парткомы сәркатибы Ю. Бабанов, янә бер проректор, өлкомның фән бүлеге

инструкторы, республика ОБХСС хезмәткәре, квартиралар бүлү буенча белгеч, профсоюз әһеле һ. б. Кем генә юк иде ул бригадада?! Барысы да мине — Октябрь районының кара урман эчендә адашып калган Кычытканлы авылында туып-үскән, бер аягын Ленинград блокадасында өздереп кайткан чатан Нәбиулла малаен тикшерү максаты белән килеп төшкәннәр! «Бер горурлык хисе» дә дөрләп кабынырга мөмкин бит әле күңелдә.

Житәкче дигәне кырык-кырык биш яшьләрдәге, тулы гәүдәле, болай да артык житди йөзенә үзенә бер дәһшәтле төсмер биреп торучы калын пыялалы күзлек кигән, ясалма чәчле ханым — Липатникова Валентина Георгиевна иде. Озын өстәлнең бер ягына «кунаклар» тезелешеп утырды, каршы якта берүзем калдым.

Ханым алдында яткан блокнотын ачып, минем исем, фамилияне кычкырып укыды да, комиссия әгъзаларын йөгертеп кенә атагач, вакытны заяга әрәм итмичә, эшкә үк ябышты.

Аны сөйләшү дип атау дөрес үк түгел, ул сорау алу шикеллерәк бер нәрсә булды. Синең мәнә бу хәтле ят кешеләр алдында җавап бирәсең киләме, юкмы — мондый әдәп кебек төшенчәләрне бирәү дә искә алмый. Гүя син — бер мәхбүс. Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый, дигәндәй, комиссиянең башка әгъзалары авызларын ачып, суларга да куркып, тыңлап утырдылар. Система шул: сорау — җавап, куркыту — курку, янау — эндәшмәү... Баш ниндидер томан эчендә акрын кыймылдый, реакция бер уч демидрол йоткан кешенеке төсле. Сүз минем Казан янында гына түгел, Юрмалада торгызылган дача, уңга-сулга сатылган дипломнар, блат белән кереп тулган студентлар, өемне ремонтларга алып киткән төзү әйберләре, шоферыма чиратсыз бирелгән квартира, рәнҗетелгән, кыерсытылган, эштән куылган укытучылар, тагын һәм тагын әллә нәрсәләр турында барды. Әйтерсең лә, анадан тума чишендерделәр дә, үзәк урамнан алып баралар. Институт тормышы, уку-укыту шөгыльләре, фәнни эзләнүләр турында кызык өчен генә дә ләм-мим сүз юк.

Комиссия башлыгы, ниһаять:

— Хәзер институтка юл тотыгыз! — дигәч, комиссия әгъзалары, дәррәү күтәрелеп, ишеккә юнәлде. Әмма башлык берсенә ым какты:

— Ә сез калыгыз, бер минутка!

Юлыннан туктатылган кеше текә маңгайлы, сирәк чәчле, урта яшьләргә якынаеп килүче, киң ияагына һәм күзләренә карагандa, татар кешесе иде.

— Менә бу иптәш, республика БХСы майоры институтта инде бер атнадан артык эшли, — диде ханым, миңа ясаячак эффекттан алдан ук канәгать калып.

— Йөгез әле, ниндирәк эшләр майтара алдыгыз?

— Институттагы психологик халәт мине кызыксындырмады, әлбәттә. Күбрәк гараж, склад, спорт базасы, ашханә тирәсендә булдым. Хәзергә бернәрсәне ачыкладым: ягулыкны кычкыртып урлыйлар, машина йөртүчеләр сәгать санын арттырып яза, ректор шоферы уку-укыту мастеры акчасын алып ята. Башка күзәтүләремне язып бирермен.

Майорны шаклар катып тыңлаганда, күзләр маңгайга менде, колакларның кызарганын сизеп тә, каршы яктагы күзгедән күреп тә торам. Явыз мәкер шулай таң калдырды. Иптәшнең вак-төяк ачышлары мине борчымый, бу «үсеш кыенлыклары» ничәмә Мәскәү тикшерүчеләренең актларын бизәмәде инде. Үрмәкүч минем тирәдә күптәннән җәтмәсен кора башлаган, үземваемсыз, гамьсез, саксыз һәм сансыз булып, баскычы алынган салам түбәдә утырам икән, шоферлар урлаган бензинны сибеп, ут төртәсе генә калган.

Соңыннан барысы да ачыкланды. Майор төп «көчләрдән» элегрәк килеп, кунакханәдә урнашып, читтән торып укучылар төркемендә югалып, аралашып, башын юләргә салып, склад, гараж, бинаның аскы катында урнашкан ярдәмче бүлмәләрдә йөреп, күргәнебезчә, әллә ни

майтара алмаса да, шактый имеш-мимешне ишеткән, күргән, теркәгән. Склад мөдире белән шундыйрак «тәҗрибә» уздырып караган. Хатынның исемен алдан белешеп, төче генә сүз башлап җибәргән.

— Сәлам бирдек, Анна Алексеевна!

Аңа гадәттә Нюра апа, Нюра түти дип кенә эндәшәләр. Бу ыспай ир-егетнең шулай сүз катуы шактый усал мөдирне дә эретеп җибәрә.

— Кем буласың, энем?

— Сез кызык кеше, Анна Алексеевна, оныткансыз да, без бит үткән ел ректорның квартирасын яңартканда, батареялар, олифа, пыяла, кадак алган идек. Быел безне дачасын төзеп бетерергә Казанга җибәрергә ниятли. Сездәниләр барын белешеп алырга кушты. Бер-ике литр спирт та яздырырмын, диде.

Анна Алексеевна — күпне күргән кеше, тәти егетнең бик үз булып, озын итеп сөйләшүен ошатмый башлый.

— Кирәк булса, үзе әйтер, проректорын җибәрер.

Майорга уйлану өчен материал бар. Мөдир үткән ел ректор квартирасына төзелеш кирәк-яраклары китүне инкарь итмәде. Ә соңрак хөрмәтле Анна Алексеевна белән документ күрсәтеп сөйләшербез...

Склад мөдире — бик эшчән, исраф итүләрне өнәмәүче, чын хуҗа кеше. Ләкин теленә шайтан гына түгел, газраил үзе төкергән. «Тәти егет»нең милициядән икәнен белгәч, үзенең шулай алданганына бик нык гарьләнә, әлеге очрашуны институт буйлап сөйләп йөреп, соңыннан майорны складына якын да җибәрми. Пенсия яшендәге хатын белән сугышып булмый бит.

Таба алган житешсезлекләрне теркәгән кәгазьләрен тапшырып, житәкчедән уңай бәя алгач, майорның минем белән ачыктан-ачык сөйләшәсе килеп китте. Гаражда тәртип урнаштыру, ремонт эшләрендә нарядларны дөрес ябу һәм башка хуҗалык эшләре буенча «дусларча» киңәшләрен бирде. Рәшит атлы икән. Комиссия терәге, кунак кеше, тыңламыйча булмый. Сизеп торам, күңел түрендә бик тә әйтәсе килгән, миен бораулап, бимазалап торган уе бар. Ул — һәркемгә мәгълүм «фәлсәфи» характердагы фикер булып чыкты.

— Безнең халыкны мин аңламыйм, бер-берсен батырырга, төрмәгә тыгарга әзер... Ә менә Кавказ халкы ничек дус, тату яши, милиция профессорны яклый, профессор, кирәк чакта, үзенең сакчыларын коткара. Ике кулның бармаклары төсле аралашып, яклашып, терәлеп яшиләр.

Мин ир-егетне тыныч кына тыңладым, бүлдермәдем, вөҗданын аз-маз гына корт кимерсә дә, яхшы бит, дип юрадым.

— Соң, сезне икенче шундыйрак эш белән җибәрсәләр, мәсьәләне грузиннар күзлегеннән чыгып бәяләргә тырышып карагыз әле! — дидем.

Комиссиянең беренче рәсми эш көнендә үк институтны танырлык түгел: умарта оясыдай, малай-шалай таяк тыккан кырмыска түмгәгедәй зил-зиләбә килә. Мондый җанлылык беренче сентябрьдә дә һәр ел булмый. Коридор таныш йөзләр белән тулы, максатлары төрле: беришесе мәзәк эзләп килгән, икенчеләре чакыру көтеп йөри, өченчеләре, ректор шымчылары абайламый калганда, шыпырт кына тикшерүче янына чуму хыялы белән килгән. Теләктәшләр, дуслар, дошманнар, гайбәтче озын телләр, элек «идән астында» утырган халык, битарафлар — барысы бергә буталган.

Әлегә партбюро бүлмәсенә берәүне дә кертмиләр, «планерка» бара, һәр әгъза каршына төгәл бурыч куела: «хатта китерелгән һәр өтерне, ноктаны төбенә төшеп тикшерергә, расларга»! Хат тулысы белән берәүгә дә укытылмый. Машинкада күбәйтелгән нөсхәдән житәкче, өлкәләп, бүлекләп, кайчы белән кисеп-кисеп ала да, ак күмәчкә кара уылдык ягып өләшкәндәй, кулларына тантаналы кыяфәт белән тоттырып чыга. Комиссия әгъзаларына бер-берсе белән аралашырга киңәш ителми, дус-ишкә, туган-тумачага чәйгә бару кискен тыела. Шәһәрдән ярдәмгә

чакырылган «өстәмә көчләр» кабинетка берәм-берәм, төрле вакытта кертелә.

Иң әүвәл институт бухгалтериясеннән, төрле бүлекчәдән, деканат-кафедралардан, кыскасы, кәгазь белән алыш-биреше булган һәр бүлмәдән хисаплар, студент эшләре, язгы ташкын төсле, комиссия бүлмәсенә агыла. Аларны ишек астындагы ярыкка кыстырылган, тәрәзә рамасына тыгылган, кунакханәдә калдырылган язмалар тулыландыра. Барысы да җыела, тегелә бара.

Читтән караганда, В. Липатникова күбрәк сиземләүгә генә таяна кебек тоелса да, чынында, аның хәрәкәтләрендә Мюллер белән Штирлиц, Шерлок Холмс белән доктор Ватсон, комиссар Катанилар көнләшерлек, уйланылган эчке бөтенлек ята.

Кәгазьләргә алынырга ашыкмый, иң мөһиме — җанлы кешеләр. Ул, тикшерүне югары җитәкче даирәләрдән башлап, баскычтан түбәнгә таба төшәр, төп игътибарын хат авторларына һәм миннән канәгать булмаганнарга юнәлтер дип уйлаган идем. Әмма минем фаразым бик тә беркатлы булып чыкты.

Иң әүвәл келәмгә миңа иң якын кешеләр чакырылды: машина йөртүче, кабул итү бүлмәсендә утыручы, кадрлар бүлеге һәм ашханә мөдире. Алардан соң, институтта эшләмәсә дә, ректорга мөнәсәбәте булырга мөмкин шәхесләр, әйтик, райпо рәисе, урман хуҗалыгы директоры, якындагы совхоз, колхоз хуҗалары... Сүз дә юк, өлком оста һәм хәйләкәр сунарчысын җибәргән минем баш сөяге артыннан.

Нәрсә әйтергә, ничек сөйләргә кирәклеген өйрәтеп куйганчы, беренче төркемне «җылы» килеш алырга кирәк икән. Шул теләк Липатникованы бер катлы кирпеч бинада урнашкан институт ашханәсенә алып килә.

Бу бозык дөньяда берәр эчкерсез кеше калса, ул уйлап куяр: бит барыбер дөреслек бар, хәзер өлком кешесе шәһәрдә иң яхшы ашханәләрнең берсен торгызу тарихы белән кызыксыныр, аны Алабуга төзүчеләре озак еллар буена планга алмый интектергәч, бик этләнә торгач, ректорның аны Чаллылар титулына кертүгә ирешүен, әмма соңгыларының бу «үги балага» кирәк-яракны бик теләми бирүләрен, бөтен авырлыкның студентлар җилкәсенә төшүен, кышкы суыкларда түшәмне генә өч тапкыр сүтеп җәяргә туры килүен белгәч, күңелендә эш өчен янып-көеп йөрүче кешеләргә карата мәрхәмәт уяныр, аның гел ашәкелек, явызлык күреп, караклар белән эш итеп тутыккан күңеле җепшер...

Чынлыкта вакыйга башкарак юнәлештә үсеп китә. Липатникова бик җилле генә ашханә мөдире бүлмәсенә килеп керә дә, кем икәнен әйтеп тормастан, үзенә кирәкне ачыклый башлый.

— Сез ашханә мөдире буласызмы?

— Әйе, тыңлыйм сезне, — ди Асия ханым бер дә исе-төсе китмичә генә, кара сумкалы хатынны берәр йомыш, үтенеч белән кергән, онытыбрак җибәргән танышына юрап.

— Миңа ректорның төшке аш менюы кирәк иде.

Чибәр мишәр хатыны берни аңламыйча, урыныннан ук сикереп тора. Кан кызу, реакция мәченекеннән ким түгел.

— Нинди ректор, нинди меню? Сез нәрсә сөйлисез, сез кем?

— Хәзер аңлатам. Кызмагыз. Сез институт халкын ашатасыз, күпмедер күләмдә аларга буйсынасыз. Менә бу бинаны да, ишетүемчә, институт салдырган. Димәк, сез аның хуҗасы турында кайгыртырга тиешсез. Ишетүемчә, сез ректор өчен аерым ризык әзерлисез. Дөрес эшлисез, ул зур кеше, профессор, СССР Язучылар Союзы әгъзасы, сез аның сәламәтлеге турында кайгыртырга тиешсез. Менә шул гына!

Сәүдә халкы сүзен нигез-өлге итеп алуы кыен. Ни бәягә алсам, шул ук хакка сатам дигәндәй. Асия ханымга ышансаң, алар арасындагы сөйләшү, аңлашу чакырылмаган кунакны бүлмәдән куып чыгару акты белән тәмамланган. Мөдир: «Мин аның дошманы икәнлеген, безнең каһәр

суккан тикшерүчеләр нәселеннән булуын күрүдә таныдым»,— дип кәпәрәеп йөрде.

Ашханә мөдиреннән соң, икенче кирәкле кеше мине йөртүче Мөнир булып чыкты.

— Хуҗагыз белән мөнәсәбәтегез ничек?

— Төрле чаклар була.

— Сезне еш әрлиме?

— Ул андый кеше түгел. Бер әйтеп куйса, озакка җитә.

— Яшермичә әйтегез әле, гадәттә, ул кемнәр белән аракы эчә? Еш эчәме?

— Машинада эчкәне юк. Ә өендә, башка җирдә ни эшләгәнен мин белмим.

— Әйтик, бүреге яки эшләпәсе сезнең якка төшеп киткәне юкмы?

— Ул машинага утыруга, баш киемен салып, йә тез башына, йә арткы утыргычка куя.

— Нинди чит кешеләрне йөртәсез машинада?

— Соң төрлесе була. Менә кичә спорт лагерена сезнең майорны алып бардым...

Кыскасы, егетнең ныклык кирмәнен какшата алмый ханым.

Мөниргә седуксин төймәсе каптырганда Резеда ханым үзенең шофер артыннан ук калын пыялалы күзлекле хатын каршысына кереп утырасын сизенмәгән икән. Үзе әлеге даруын йотып та өлгерә алмый кала. Ректор бүлмәсе белән партбюро арасы бер-ике метрлык кына.

Липатникова үч ташын чөеп, комнан алтын эзләвен дәвам иттереп, шул ук вакытта үзен генә хаклы, акыллы, ялгышмый торган кешегә санап, әмма һәр шәхеснең үз психикасы, холкы, дөньяга үз мөнәсәбәте барын да исәпкә алып, турыдан-туры шикаять хаттагы хәбәргә күчә:

— Мине гафу итәрсез, Резеда, менә бераү сезне, ректорның сөяркәсе, дип атый. Ышанмыйм, әмма мәсьәләне ябу өчен мин ул сорауны сезгә бирергә тиешмен.

Сөаленнән кәнагать калып, карашын алдында утырган ябык ханымның аклы-кызыллы тимгелләр белән капланган йөзенә, әрнүдән, гарьләнүдән чыланган зәңгәрсу күзләренә юнәлтә. Ректорның череп таркалуын, коммунист буларак әхлакый тотнаксызлыгын фаш итү өчен шәхси сәркатип — иң кулай кеше. Ректорны эшеннән алып атсак, икенче хуҗасының ишек төбен саклар, аңа барыбер түгелмени?!

— Борчылмагыз, сөйләшү безнең арада гына калыр, ачыктан-ачык, дусларча әйтеп бирегез! Без бит монда кемгәдер җәза бирү, кемнедер фаш итү өчен килмәдек. Кешеләр кулларын куеп яисә, Галиуллиннан өркеп, имзасыз хатлар яза икән, без тикшерергә, хакыйкатьне ачыкларга тиешбез. Безнең партия — һәрвакыт дөреслек ягында тора.

Фирка кешесенең озак сөйләве, Резедага уалып киткән зиһенен төйнәргә вакыт, мөмкинлек бирә.

— Валентина Георгиевна, яшем иллегә җитеп килә. Балаларым олы, оныгым бар. Иремнең шул ук бинада эшләгәнен дә беләсез. Сез шул гайбәтләргә ышанып утырасызмы? Икенче тапкыр киләсез, Алабуга халкының шул сыйфатына аз гына да төшенмәдегезме?

Үзе генә «тәрбияләргә» өйрәнгән Липатникова аның сүзен ярты юлда туктата.

— Бәлки, элегрәк сезгә, бик якын кеше булып, башкалар артыннан күзәткәләп йөрүне сорагандыр ректор?

— Шымчы булыргамы? Гафу итегез, мине кем беләндер бутыйсыз.

— Рәнҗемәгез! Мәсьәләгә икенчерәк яктан килеп карыйк. Бәлки, сез аның янында башка хатын-кызны күргәнегез бардыр? Курыкмыйча сөйләп бирегез, рәнҗемәгез. Аннан, сер итеп әйтәм, Галиуллин монда артык эшләмәс, дип уйлыйм...

— Мин сезгә бернәрсә дә әйтә алмыйм. Дөресрәге, берни дә белмим. Миңа чыгарга мөмкинме, «приемный» ачык калды...

Резеда ханым советлар илендә ялгышып кына туган шәхес кебек: эшкә житди мөнәсәбәте, төгәллеге, таләпчәнлеге белән ул буржуа мохитының данлыклы клеркларыннан һич кенә дә кайтыш түгел. Һәр яңа ректорга, ул бер үк тырышлык, бирелгәнлек белән хезмәт итә.

Кадрлар бүлеге хуҗасы кабинетка чакырыла. Липатникова, өстәл артыннан чыгып, Анна Ивановнаның янына килеп утыра, талчыкканлыгына зарлана, озаклап өлкән хатынның бердәнбер шатлыгы, таянычы — кызы, аның гаиләсе турында сораша. Хәтта урынында үрле-кырлы сикеренгән телефон тоткасына да үрелми һәм тирән мәгънәле, озын тукталыш ясап, мәсьәләне кабыргасы белән куя.

— Сез Галиуллинны хөрмәт итәсез дип ишеткән идем.

— Әйе, яхшы кеше бит ул. Бервакытта тупас сүз әйтмәс, тыңлап бетерер, ярдәм итәргә тырышыр.

— Хуш. Аның хәлләре бик мөшкел бит. Эшеннән алынуы хәл ителгән диярлек. Һәм сезгә сер итеп кенә әйтәм, аның төрмә ишеген ачып керү ихтималы бар. Аны коткарып булыр дип уйлыйм. Сездән ярдәм кирәк.

— Минем аңа бик тә ярдәм итәсем килә. Әйтегез, мин нәрсә эшли алам,— ди ул ясаткан бөдрә чәчле, киң битле ханымга ихтирам белән карап.

— Аның дипломнар сатуы инде исбатланган, расланган нәрсә. Менә, мәсәлән, институтның татар теле укытучысы Мамадыш районыннан диплом сатып алган хатынны беләм, дип яза.

— Йә хода!

— Сүз һәр диплом өчен алынган хак турында гына бара. Берәүләр ике-өч меңгә саткан ди, икенчеләре биш-ун меңне атый.

— Йә хода!

— Аннан соң ничә данә диплом сатылган бит әле. Шуннан да тора сезнең хуҗаның язмышы. Кыскасы, менә шул фактлар турында ачыктан-ачык, яшермичә сөйләп биреп, сез аңа ярдәм итә аласыз. Бәлки, бергәләп коткарып та булыр мескенне,— дип сүзне икенче үзәнгә кертеп җибәрә.

— Сез нәрсә сөйлисез? Мин берни дә белмим, бу хакта ишеткәнем дә юк. Каян алып саткан ди соң ректор ул дипломнарны?

— Аңлашыла. Сез дә аны батырырга уйлыйсыз.

Шул сүзләр Калинникованы чынбарлыкка кайтара. Үзен кулга алырга мөмкинлек бирә: «Кешене нахакка батырып яталар ич, дөресен сөйләргә, булганын ярып салырга кирәк».

— Мин нәрсә хакында сүз барганын аңладым. Гаепле кеше мин. Бер хәл булды моннан сигез еллар элек. Мәскәүдән килгән диплом бланклары номерларын журналдагылары белән чагыштырганда, сигезләп сан туры килмәде. Хикмәт шунда, бу хуҗалыкны илленче еллардан бирле берәү дә тикшермәгән, бланклар кайтарылып, сейфка куела, вакыты житкәч, бирелә торган булганнар. Факультетларга тутырылырга өләшенгән бланклар барысы да язылган, урынында, кул куеп алынган.

— Диплом бланклары югалганны ректор беләме?

— Юк, мин бу хәлне ачканда, ул элда иде. Шунда ук проректор Петровның өенә йөгереп бардым, ул институттан ерак тормый, бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Ул мине тынычландырды, каударланмаска, әлегә беркемгә дә хәбәр итмәскә кушты. Иртәгә ректор урынына калган кеше янына бергә кереп, киңәшербез, диде. Икенче көнне өчәү фикер алышкач, техник ялгыш, хата чыккандыр, дигән карарга килдек. Бу хакта мин инде күптәннән онытхан идем. «Ректор дипломнар саткан» дигән гайбәтне институт эшен күз алдына китергән кеше таратмас. Уйлап карагыз: диплом бланклары Мәскәүдән турыдан-туры сейфка килеп керә, шунда саклана. Аны, вакыты житкәч, журналга кул куеп, деканат секретаре ала, тутыра. Дипломга әүвәл әлеге секретарь, аннары дәүләт комиссиясе рәисе имзасын сала, бәяләр куелган өстәмә битен декан

тутыра, иң соңыннан, ректор кул куйгач, бөтенләй башка кеше, канцелярия мөдире, һәркайсына гербლы мөһер сугып, диплом алучының һәркайсыннан кул куйдырып, тантаналы тапшыру өчен деканатка озата...

Калинникова диплом алу юлын озын-озак итеп, дулкынлана-дулкынлана сөйли, әмма тикшерүче кеше аны инде күптәннән тыңламый, үзенең алдагы сорау алулар алымына үзгәртүләр кертеп утыра. Каһәр суккан дөнья син теләгән кануннарга буйсынып кына яшәми шул. Ярты көнен заяга уздырды бу томана халык белән сөйләшеп.

Әйтергә кирәк, бу көннәрдә ректорның кайчандыр югалган бланклардан диплом «ясап» уңга-сулга сатып ятуы турында сүз шактый куертылды. Янәсе, без, дипломны Грузиядә, Әрмәнстанда, Үзбәкстанда гына зур акчага юнәтеп, машинага алыштырып була, дип йөргәнбез. Йорт җиреңне сат та, кил дә алып кит дипломны Алабугадан, теләсәң, чит телләр буенча яздырып ал, унга чаклы саный белсәң, рәхим итеп, математик булып кайтып төш туган авылыңа...

Әлеге вакыйгалар чорында өлкомда бүлек мөдире ярдәмчесе булып эшләгән, хәзер финанс-экономика институтында кафедра мөдире Бикташиров миңа бер хат күрсәтте. Авторы — университетның татар бүлеген миннән бер ел элек тәмамлаган, философия фәннәре кандидаты бер иптәш икән. «Мине, сирәк-мирәк салгалаган, дөресен әйтеп, ректорны фаш итеп үзәк оешмаларга хатлар язган өчен, Кама политехник институтыннан кудылар, әнә бит Алабуга ректоры Галиуллин диплом сатын яткан, аңа берни булмады»,— дип, акка кара белән язып җибәргән...

Алга таба парткомиссия өчен артык ук кыйммәте булмаган «материал», ягъни проректорлар, деканнар, кафедра мөдирләре, укытучылар белән очрашулар китте. Дистәләрчә кешеләр махсус исемлек белән чакыртыла, шул хәтлесе үк ишекне үз ихтыяры белән ача. Үз теләге белән килүчеләр арасында институт, ректор турында уңай фикер әйтергә, дөрес күренеш тудыруга омтылучылар күбрәк булу сәбәпле, «бригадир» аларны кабул итмәү әмәлен эзли һәм, әлбәттә, эзләгән табар, ботакка кадак кагар, дигәндәй, алардан котыла иде.

Кеше партбюро бүлмәсенә ап-ак чырай белән, салмак атлап, гәүдәсен туры тотып керсә, вакыт узгач, кып-кызыл булып, атылып чыга.

Сөйләшү бары ректор турында гына бара. Сорау алу, хәбәр җыю юллары искиткеч бай, мәкерле, әйләнеч, әмма теләсә кемнән бары тик хатта язганнарны раслый торган мәгълүматлар алуга буйсына. Алдан әзерләнгән, оештырылган тикшерүләр өчен абруй, элеккеге казанышлар, кичәге җиңүләр учакка ут дөрләтерлек йомычкага да тормыйлар икән.

Берәр укытучы ректорны мактый башласа, Липатникованың кәефе кырыла, иреннәре салынып төшә, алдында утырган кешене күрми, ишетми башлый һәм күзлеген сөртергә керешә. Ә инде Билданов М. М., Вәлиев Н. М., Овсянников В. В., Хафизов Ш. Г., Шәрәфетдинов З. Т., Синюк А. И. кебек кафедра, бүлек мөдирләре, деканнар кереп, ректорны мактап, «нервысында уйный» башласалар, ул язылачак справкасының эчтәлегеи сөйләргә тотына.

— Менә сез ректорны яклыйсыз, мактыйсыз. Ул эшли башлаганнан бирле әхлакый тотнаклылык арттымы, студентлар арасында тәртип, әдәп көчәйдеме, фән докторлары күбәйдеме? Эчкечеләр азайдымы коллективта? Өгәренки, сез аны чын-чынлап якын күрсәгез, яратсагыз, аның йомшак якларына да искәрмә ясарга тиешсез. Аның төзәлүенә мин ышанмыйм! — дип, кайнарланып түгәлли ул чыгышын.

Егетләр, кул селтәп, бүлмәдән чыгып китәләр. Бәхәс куертудан файда юк. Кыскасы, комиссия рәисе төп «кызыксыну» объектын бер генә мизгелгә дә күз уңыннан ычкындырмый. Ярдәмчеләрне, деканнарны, мөдирләрне бераз кымтырыкласа да, эш өчен зарары булмас иде, дип хыялланып утырам. Мәскәүдән килгән тикшерүчеләр, гадәттә, нииндидер уңай якларны да күрәләр, институтның барлык бүлекләренә төшеп җитә-

ләр, проректорларга да «өлеш» чыгаралар. Кара син аны, мыеклы Джо абыйны, бигрәк кызыклы оешма уйлап тапкан: акыллы эт кебек, бер кешегә ябыштымы, бетте, исемен дә сорамый, каерып алып та булмый.

Исем дигәннән, институтка ике килүендә ничәмә көн бергә «эшләдек», әмма Валентина Георгиевна минем паспортта язылган «кушамат»ны дөрес әйтергә өйрәнмәде: Әфхәт Нәбиевич (өлкомда эшләп алган энекәшкә якын килә, хәер, ул Нәбиуллович йөри), Әсхәт Милеч, Тәлгат Нәбиуллович... Бу ваемсызлыкмы, нечкә юмормы, үзенчә рәнҗетүемме, әллә тәртәгә кергәч, ат була дип уйлавымы? Ни өчен гомере буена татарлар арасында яшәгән номенклатура кешеләренә аз гына да илтифатлылык өйрәтмиләр икән?

Хәер, исемне дөрес әйтергә өйрәнергә теләмәсә дә, ханым минем белән «эшләүгә» җегәрен дә, вакытын да кызганмады. Менә монда инде аны илтифатсызлыкта гаепләргә һич кенә дә хакым юк. Шундыйрак сөйләшүләр, аңлашулар даими булып торды.

— Бөтенләй ришвәт алмыйча яшәмәгәнсездер ич? Юк, мин әле диплом сату, Юрмалада дача салу кебек олы шөгыльләрне күздә тотмыйм. Аларын ачыклау, тикшерү махсус кешеләр эше. Уңышларында шигем юк. Мин чит илдә эшләнгән конфет тартмасын, фин сырын, япон ручкасын, затлы вино кебек күчтәнәчләрне күз алдында тотам. Андый бүләкне кем алмый инде? Бердән, кешене юк өчен рәнҗетеп булмый, икенчедән, андый затлы нәрсәләр кибетендә юк. Дөньясы шундый.

Тавышы ифрат тыныч, ягымлы, дустанә, сораучан, үтенүчән. Янәсе, ярыл, таны, ваклашма, өстенә ал, мин дә тынычлап йокклармын, хет. Буш кул белән кайтуы оят.

Бу алым көткән нәтиҗәгә алып килмәгәч, йөзе икенче, кырыс төс ала. Кеше йөзе — тәрәзә, аннан барысы да күренә. Йөздә язылганны «төзәтү» эшенә иң яхшы редактор да, Хәлиф Курбатов кебек стилист та алынмас дип уйлыйм. Ханым керфекләрен идәнгә чәнчеп, саллы кулын алдында яткан папка өстенә куя.

— Әле генә тагын бер өем хат килде. Бик ышандырырлык дәлилләр җитәрлек. Үзегез танысагыз, яхшырак буласы иде. Карагыз тагын, миңа барыбер, сезнең белән бүрәнәләрем бүлгән.

Әлбәттә, ул мисалларны санап, китереп тормый. Чөнки алар юк, булганы ялган. Мин дәшмәгәч, күзлеген миңа текәп:

— Сез ничек түзәсез! Минем хакта шулай язсалар, күптәннән инде кимендә инфаркт, инсульт белән егылыр идем...

«Чорның акылы, намусы һәм вөҗданы» дип йөртелгән КПСС үз эчке кануннары белән яшәүче аерым бер дөнья иде. Өстән төшкән мәҗбүри кагыйдәләрдән тыш, язылмаган күрсәтмәләре дөнья хәтле. Анда эшләүче зат сакал үстерә, балдак кия алмый, хатыны белән аерылышырга, танышлар булдырырга, яшьлек дустын өлком дачасына алып килергә аның хакы юк. Функционер барына да түзә, зарланмый. Бюрократик бөҗра буларак, аппарат үз эченә бикләнә. Үзенә тугрылыклы кешеләрне, дөресрәге, үз бөҗрасына эләккән бәхетлеләрне, ул адәм нинди генә әшәке, эшлексез, эчкече булып чыкмасын, партия беркайчан да рәнҗетмәде. Алар илдә иртәгәге көне гарантияләнгән бердәнбер иҗтимагый төркем булып килделәр. Кайсы райком секретареның урыныннан киткәч, квартира сорап, эш сорап интеккәне бар? Мин андый очракны хәтерләмим. Аппараттан китеп, үзе теләсә, аңа Казан үзәгеннән профессор, язучы, алдынгы эшченең төшенә дә кермәгән күркәм урыннан, менә дигән яхшы йорттан квартира, бачка, пенсиягә чыкканчы эшли торырлык җайлы хезмәт бирәләр. Әгәр инде башка профессиясе булмаса, вакытлыча кайдадыр селкенеп йөрисе килмәсә, булмаган чирен табып, аны персональ пенсиягә җибәрәләр.

Липатникованың эшкә сәләтлелеге, чыдамлылыгы искитмәле. Егерме сәгать тоташ язып-сызып, документлар өйрәнеп, кешеләр белән сөйләшеп («допрос алып» дияргә телем әйләнми) утыра ала.

Кайсы вакыт филне егарлык җегәрнең чыпчык белән бил алышуга сарыф ителүенә эчем поша. Липатникова ике килүендә дә, спорт лагерендагы мунчага бәйләнде. «Лагерь мунчасыз тора алмый, биредә июнь аенда пионерларны кабул итәбез, аларга да кирәк һәм, гомумән, бер салынган, торсын инде!» — дип карыйм. Юк, махсус кеше җибәреп, сүтерде, ваттырды, мичен чыгарып ташлаттырды. Шунда хәтта калын иреннәре арасында елмаюга охшаган бернәрсә дә күренеп китте.

Күршедә генә күпме хуҗасызлык, әрәм-шәрәм итү. Кама аша күпер салына, ГЭС корыла башлагач, кайсыдыр «акыллы башы», су җиде метрга күтәреләчәк, елга буендагы урманнар су астында калачак, дип хәбәр тарата. Чулман буендагы урманнарны кыра башладылар. Егылган агачлар шунда аунап ятты, теләсә кем аларны сатты, өенә ташыды... Хәзер дә бу урыннар, безнең хуҗасызлыкка ишарә, булып, рәнҗеп ята. Башбаштаклык корбаны урманның элеккеге матурлыгын күрсәгез иде! Яшь гаскәриләр төсле тезелешеп киткән ул наратлардан күпме кораб ясап, ничәмә-ничә өйләр, мунчалар салып булыр иде. Парткомиссия менә шундыйрак олы эшләр белән шөгыльләнсен иде дә, юк шул, аны ректор кабинетындагы Ленин портретының каян килүе, чәй әсбапларының нинди акчага алынуы борчый. Күпернең теге ягындагы заводтан дистәләгән «КамАЗ»ларның югалуына аппаратның исе дә китми...

Ленин фатиха биреп, Сталин төзеп калдырган җәмгыятебез шундыйрак шул. Бөтен бер халыкны пыран-заран туздырып, башка җиргә күчереп куяр өчен бер тәүлек вакыт җитә, монда авыл ректорын ришвәтчелектә гаепләү өчен күпме көч, вакыт куярга туры килә. Бригада әгъзаларының үз эшләре дә, сагынып көткән гаиләләре дә бар бит әле. Көтелгән сенсация чыкмагач, комиссия әгъзаларының пары суынды, кайтып китү ягын каера башладылар. Җитәкче ханым сер бирмәскә тырышты: «Әйе, Галиуллин шикелле бозылып, рәхәт тормышка өйрәнеп, район җитәкчеләрен кулга алып бетергән, череп таркалган шома бюрократларны фаш итү җиңел түгел. Күбесенең балалары, туган-тумачалары институтта укый, шуңар да райком кешеләре ректор белән араны бозмый. Аны өркетү өчен тәҗрибәле, бу шөгыльдә азау теше чыккан кеше кирәк».

Липатникова кебекләр, өстән кушылса, мандат бирелсә, теләсә кемне, якыннарын да, кичә җитәкчесе булган кешене дә харап итәргә риза. Партия кушканда, шәхси мөнәсәбәтләр исәпкә алынырга тиеш түгел. Безнең ил тарихы бу юнәлештә менә дигән мисалларга бай. Кайберәүләр Сталинны, Молотов белән Калининның хатыннарын төрмәгә озаткан өчен, гаепләп маташалар. Бер түшәктә йоклаган кешеләрнең күңелендә «троцкизм» орлыгы, ят, чит уй барын сизенгәннәрдер партия һәм хөкүмәт әһелләре. Хуҗалары теге дөньяга киткәч тә, икесе дә аның идеалларына тугрылыклы калдылар. Сатмадылар, Хрущев төсле, чәпчемәделәр. Молотов, партиядән куылгач та, Сталин турында ник бер начар сүз чыгарсын авызыннан. Вөҗданына тугрылыгы өчен партбилетын өенә үк китереп бирделәр. Коммунист булып үлде, илнең үзәк мәйданына күмелде...

Исемсез һәм имзасыз хатның авторы бик хәйләкәр кеше күренә. Алдан ректорның диплом сатып ятуы, дус-ишенә, туган-тумачасына квартира өләшүе турында хәбәр итеп, ришвәт белән кергән студентларның исемлеген китергәч, сиздермичә генә төп өлешкә күчә. «Галиуллин, җае чыккан саен, өлком сәркатибы Беляев белән бер чорда мәктәптә, университетта укуы, якташ булуы, Кама буйларында яшәгәндә туктаусыз очрашып торулары, кыскасы, бик якын, җан дус булулары турында сөйләргә ярата. Ул анда утырганда, мин беркемнән дә курыкмыйм, телим икән, иртәгә үк зур эшкә Казанга күчеп китә алам, дип туктаусыз кабатлап тора».

Рәис Кыямовичның абруе югары, киләчәккә өметләре зур чак, үзен бик саклый, элеккеге дусларын да, аз гына тайпылсалар, чабуларын җыеп

йөрмәсәләр, кызганып-нитеп тормый, кисә дә төшерә. Сиземләвен, уяулыгын югалткан Галиуллинның да ана кирәге юк, күрәсең. Өстеннән хат язалар икән, димәк, эшендә ялгышлар җибәрә. Тиешле җәзасын алсын!

Парткомиссияләргә бирелгән вәкаләтләрнең иге-чиге юк иде ул чорда. Теләсә нинди оешма аңа буйсына, кушканны йөгерә-атлый үти. Үз оясында «мин кем» дип бүксә киереп йөргән прокурор, милиция бүлеге начальниклары шул ук Липатникова алдында, мәктәптән иkele алып кайткан малайлар төсле, юашланып калалар. Алабуга прокуроры, дөньяны шактый күргән, КамАЗда чыныккан Хәмит Миннеханов институт кешеләре турында үз оешмасына кергән мәгълүматларны әзерләргә йөкләмә алгач, кулларын гына җәя: «Нишлим соң янәсе. Тәлгат туган, русча белмәгәч». Русчаны яхшы белгән, милиция бүлеге хуҗасы, Тамбов егете Виктор Кокорев миңа бер мәсьәләдә ярдәм итәргә теләве аркасында урыныннан колак кага язды. Гыйбрәтле хәл.

Комиссия өчен төп кулланма — фамилияләр куелган хат. Әмма «дуслар» аңа терәү рәвешендә төрле даирәләргә — Үзәк Комитеттан алып, һәммә газета-журналларга, вак тояк оешмаларга — шикаять язмалар җибәрүне дәвам иттерәләр. Өзеклек юк. Хәл киеренкеләнә, сулау кысынлаша бара. Липатникова да беренче килеп төшкән өстәмә хатларга балаларча сөенеп утырса, хәзер берүк нәрсәләр турында укый-укый, туеп килә, очрашкан саен, башын чайкап, папкаларга ымлый, әйтерсең лә, аларны мин оештырып, мин җибәреп ятам. Парткомиссия үзе һәр хатка асылкош тоткандай ябышмаса, күтәреп йөрмәсә, бу чаклы исереп-тилереп, иләс-миләсләнеп язмаслар иде, дип уйлыйм.

«Фирка почтасы» яшерен элемтә юлы белән Липатникова кулына килеп эләгә. Керән телле хатларның совет оешмаларына, төрле редакцияләргә ташланганының бер өлеше, «җавап бирү өчен», институтның үзенә килә, ягъни мәсәләнең андыйларына абзагыз үзе җавап бирергә тиеш була инде. Хатлар соры, минем өчен дә яңалык юк, бер үк сагыз, шул ук черек балык башы.

Шулай күңелсез, өчпошыргыч итеп язмасалар инде дип, чираттагы хатларны караштырып утырганда, бүлмәгә Чаллы бүлекчәсендә эшләүче Равия Абдуллина килеп керде. Сары чәчле, бите яшь кызларныкы төсле җиз сипкел белән бизәлгән бу хатын, холкы бераз сәеррәк булса да, шагыйрә җанлы, татар теленә гаять сизгер, кыю һәм намуслы укытучыларның берсе иде. «Мин сезнең алда гаепле. Бер ай элек машинкамны Урманов алып торган иде, шактый тотты өендә, үзенең ике машинкасы була торып, минекен пычрак эшенә файдаланмадымы икән, дигән шик төште күңелемә. Машинкамда басылган текст та алып килдем»,— диде ул.

Абдуллина чыгып китүгә, милиция бүлеге хуҗасына шалтыратып, машинкада басылган ике текстны (берсе кайсыдыр газетадан урап әйләнеп кайткан имзасыз хат, икенчесе укытучы калдырганы) хәреф охшашлыгы ягыннан тикшереп бирүен үтендем. Экспертиза миңа рәсми җавап китерде: «Ике язма да бер үк машинкада басылган». Димәк, Урманов яңа хатларын Равия ханым машинкасында үрчетеп яткан. Анонимчының ачыклануына Липатникова да шатланыр, дип, кәгазьләрне күтәреп, партбюрога кердем. Документларны игътибар белән карап, үзендә калдырды.

Минем «ачышка» парткомиссия үз мөнәсәбәтен тиз белдерде. Элеккеге эчке эшләр министры урынбасары Җәүдәт Нейметов дигән кеше Виктор Ивановичны ярты сәгать телефоннан тиргәгән: «Син анда үз эшең белән шөгыльләнмичә, әллә нинди шикаятьчеләр эзләп, өлком парткомиссиясе эшенә аяк чаласың икән. Тагын берәр шундый сигнал булса, халык хуҗалыгына эшкә җибәрәм».

Липатникованың: «Имзасыз хатлар язучыны тапсам, кирәген бирер идем»,— дигән сүзләре колакта чыңлап тора. Ә хәзер, хуҗасыннан рөх-

сәт алмыйча, чит машинкада баскан хат авторын тапкан кеше эзәрлекләнә. Шулай шул, аппарат уеннарының кыйбласын аңлавы кыен. Бүген болай, иртәгә тегеләй...

## Өлешеңә тигән көмешең...

Бу фани дөньяда һәркемнең кәгазьгә төшерелмәгән, рәсми беркетелмәгән, әмма дуслар, таныш-белешләре арасында кабул ителгән үз урыны, бәһасе бар. Әлеге бәяне йөзләгән рәсми характеристикалар да үзгәртә алмый. Әйтик, дус-иш фикерен үзгәртергә ниятләп, халык әйтмешли, тыныңны артыңнан алып утырсаң да, синең күп сөйләшергә, кешене бүлдереп, кысылырга яратуыңны белгән мәҗлестәшләрең, «кыланып утырган була тагы», дип кенә мөһер сугып куячаклар. «Саран» дигән тамга тагылган икән, очрашкан саен өр-яңа йөзлекне ташласаң да, әлеге бәя җуелмас, төсе уңмас. Биредә көйле базар экономикасы да берни майтара алмый.

Башка төбәккә күчеп китсәң дә, бәяң контейнерыңнан алдарак килеп җитәр.

Алабуга techинститутына эшкә икенче шәһәрдән профессор Хәй Урмановны чакыргач, аны яхшы белгән агай-эне телсез калды. «Син аның тавышлы, шикаятьче, дәгъвачы икәнен белеп алдыңмы? Казан университеты профессоры Тумашева белән Себер татарлары лөгәтен «бүлешеп» күтәргән җәнҗалларыннан хәбәрдар түгелмени соң? Приказга кул куйганчы, минем белән киңәшәләр аны»,— кебегрәк сүзләр шактый ишетелде. Берәүләре иллегә җитеп килгәндә балаларча беркатлылык күрсәтүем өчен әрләде, икенчеләре кызганды, өченчеләре киләчәктә булачак кызыклы вакыйгаларга күрәзәчелек итте.

Үткән эшкә салават, адәм баласы инде гаиләсе белән күченеп килгән, хәзер нәрсәнедер үзгәртүе кыен. Ул чакта мин әле кешенең төзәлә алуына, изгелеккә яхшылык белән җавап бирүгә омтылуына ышана идем.

Мин, шәхсән, кешедә әле дини хис белән бәйләнмәгән югары башлангыч, илаһи эчке бер көч барлыгына ышанам. Кешегә берәү дә шәфкатьле, мәрхәмәтле булырга кушмаганда, мәҗбүр итмәгәндә, ул затлы батырлык эшләп куярга мөмкин. Кызганычка каршы, менә шунда кеше «эшенә» иҗтимагый фикер, җәмгыять кануннары килеп катнаша.

«Бәлки, профессорның язу-сызуга бәйле сәерлекләре турында арттырыбрак та сөйли торганнардыр. Һәр авызны капларга яулык җиткерә алмассың. Зыялы өчен башка берәүне хурлап, үзен күтәреп куярга омтылудан түбәнрәк, хурлыклырак эш юктыр. Чын татар әдипләре, Колгали, Мәрҗани, Дәрдемәнд, Ф. Кәрими, Ф. Әмирхан, Һ. Максуди, Г. Исхакый оныклары мондый пычрак эшкә бара алырлар идеме икән?» Мин шулайрак уйладым. Әмма...

«Күңелле» вакыйгалар озак көттермәде. Урманов бездә эшли башлап, ике-өч ай узуга, өлкә комитетында имзасыз хат пәйда булды. Иҗтимагый фәннәр укытучылары исеменнән, дип язылган ул хатта, башка тәнкыйть фикерләре белән беррәттән, ректор профессор Урмановны, советтан үткәрмичә, эшкә алды, хөкүмәтебезне алдау юлына басып, аңа иң югары дәрәҗәле «подъемный» түләде, дип язылган иде. Автор хаклы, шундый хәл чыннан да булды. Июль-август айларында киңәшмәне җыеп булмый, һәммәсе ялда. Урманов һәркөнне өйгә шалтыратып, хат язып торды: «Мине, вакытында эшкә чыкмады, дип, азат итәргә җыеналар, советтан узды,— дип, ректор исеменә телеграмма бирүегезне үтенәм, мин монда кала алмыйм, җепләрне кистем».

Кешегә яхшылык эшлим дигәндә, гадәттә, алды-арты турында уйлап тормыйсың. Тазалыгы да, үзе әйтүенчә, әллә кем түгел, яше дә бар,

алырга вәгъдә биргәч, сүздә торырга кирәк, дип, икенче көнне үк «профессор фәлән-фәлән көнне конкурстан узды» дигән телеграмма суктым һәм, күренә ки, үз койрыгын үзе өзгән кәлтә көненә калдым.

Әлбәттә, имзасыз хатны үзенә дә күрсәттем. Мине ул рыясыз тәстә, чын күңелдән тынычландыра: болытлы көннәр мәңгелек була алмый, күк йөзе аязыр, җил болытны таратыр, йолдызлар җемелдәшеп чыгар (ул чакта мин аның әдәби-иҗат эше белән шөгыльләнгәнен белми идем әле). «Хәлләр ничек, артык бәйләнмиләрме, кирәксә, үзем өлкомга барам»,— дип, гел сорашып, хәлне белешеп торды. Күзләрендә ниндидер җәзалану, борчылу, гасабилану сизә идем һәр очрашуда.

Кешеләр бу гөнаһлы дөньяга киләләр дә китәләр, ә җир ана, табигать фасыллары мәңгелек. Менә шул иксез-чиксез галәм әле сине үз кочагында яшәткәндә, мәрхүм кеше турында (Урманов икенче елны, институтта инде Мәскәү комиссиясе эшләү чорында, кинәт вафат булды) телдә: «Үче озынның гомере кыска була» — дигән мәкаль торса да, начар язасы килми. Бөтен сабырлыгымны, зиһенемне җыеп, мин аны аңларга тырышам.

Урманов татар дөньясында үзенә күрә бер феномен булды. Ул безнең ябык, явыз, усал җәмгыятебез тудырган, канат биргән бәхетсез, имансыз кешеләрнең берсе иде. Аның гади бер шикаятьче хәленә төшүен дә аңлатып була.

Фән өлкәсендә җитди ачышлар ясарлык, татар дөньясында эз калдырырлык табигый сәләте юк. Үзен урындыкка бәйләп куеп, ихтыяр көче белән генә эшләнгән докторлык диссертациясе дә искерә, аны сипләү дә әллә ни дан китерми. Бер хезмәттән күпме китап «ясап» була. Элегрәк Казанга күчәргә омтылышлары уңышка алып килми, чөнки үзен куенына сыендырыр кешеләрнең барысы белән дә әчелешле булып беткән.

Җитмәсә әле балалары да, төрле сәбәпләр белән аспирантурадан куылып, бер-бер артлы аталары янына кайтып төштеләр. Профессор аларны институтка эшкә алуны таләп итте. Этне алдау юлы бер — аңа вакытында сөяк ташлау, диләр. Мина да балалары йомшак, ялкау, Мәскәүдән тавыш белән әйләнеп кайтуларына төкереп, кафедра мөдирләренең, деканнарның каршылыгын сындырып, эшкә аласы булган. Шул чаклы мәшәкатьләр чыкмас иде, бәлки.

«Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» дигән исемне бирмәү профессорның кулларын бөтенләй чишә, республика түрәләрен йөреп чыгу да көткән файданы бирмәгәч, язу машинкасына утыра. Шикаять хатлар язу өянәге башлана, аннан соң имза куелганы Үзәк Комитетның парткомиссия рәисе өстәленә ята.

Унбиш-егерме ел эчендә ясалган һәм инде күбесе җыелышларда, утырышларда, комиссияләрдә кат-кат сөйләнелгән нәрсәләр системага китерелгән, аптекадагыча тартмаларга салынган бу хатта: хөкүмәт малын урлау, намуслы кешеләрне эштән куып, туганнарын, ялагайларны җыйнау, әхлакый тотнаксызлык, гараж сату, машина алу, дачалар салу, блат, ришвәт белән укырга алынган студентлар исемлеге. Соңгысы — нәтиҗәләр һәм әлбәттә, яраткан институтта әхлакый-психологик хәлне яхшырту буенча тәкъдимнәр, теләкләр...

Җанга сары май булып керә, кара елан булып чыга торган Урманов кебек кешеләргә яшәве җиңелдер, дип уйламыйм. Хатны язып, үзен торган җирдән ерактагы элемтә бүлегенә илтү — бер хәл, әле борчылып, хафаланып җавап көтәсе, тикшерүчеләрнең эше белән кызыксынасы (юри генә кыланмыйлармы?) да бар бит. Дусларың яныңнан таеп, ямьсез ялгызлыкка дучар булуың да мөмкин. Ә бит әле һәр чорның үз мәнфәгатьләре, үз җиңеллекләре, аңа гына хас кыенлыклары, үз түрәләре була. Әнә бит Горбачев үзе, бигрәк тә хатыны өстеннән язылган хатлардан гарык булгач, тотты да, имзасыз хатларны исәпкә алмаска, дигән карар чыгарып, күпме адәмне рухи таянычтан мәхрүм итте.

Мин хыялымда Урмановның хатлар язу вакытын күз алдына китере-

ргә тырышам. Ул, әлбәттә, машинка янына тыныч күңел белән, явызлыкка каршы көрәшәм, мине яратмыйлар, чөнки мин акыллы, алдан күрүчән, турыга бәреп, дөресен әйтүчән, шуның өчен кысалар, дип утыра. Чит машинкада басылган һәр яңа хат аңа илаһи бер шатлык, сөенеч, рухи җылылык алып килә, әйтерсең лә ул үзенең яшьлек мәхәббәтенә, канатлы хыялларына әйләнеп кайта, кияү булып йөргән мизгелләрен исенә төшерә. Илдә дөреслек урнаштыру, тормышны һәртөрле кәкре куллы бәндәләрдән, караклардан тазарту, Ленин васыять итеп калдырган өметләрне менә шул Алабуга педагогия институтында гына булса да гамәлгә индерү нияте белән, ул янәдән яраткан алымына мөрәҗәгать итә. Бу хат — соңгысы, ди ул үз-үзенә. Әнә күпме шигырь газетага илтеп бирүне көтеп ята, халык җырлары рухында языла башлаган поэмага да кул җитми.

Ул һәр адымын салкын кан белән үлчәп, идеологик һәм башка вак-төяк аңлашылмаучылыкны читкә ташлап, җәтмәдән балык чүпләгән төсле, үзенә файдалы кешеләрне барлап, әйләнеп, сөйләшеп йөри. Партия җыелышында алар хаттагы фикерләрен хуплап, куәтләп чыгарга тиешләр. Аның укытучылар белән эшләү «методикасы» бер төслерәк, хәтта примитив булса да, кешенең хайвани хисләрен уята, котырта белү сәләтенә гаҗәпләнмичә, сокланмыйча мөмкин түгел. Башлыча, иҗтимагый фәннәр укытучылары, мактаулы пенсионерлар кызыксындыра аны.

— Рагиб дус, ни өчен сине ректор шулай читкә тибәрә икән? Алай борын күтәрергә үзе кем соң әле ул чаклы...

— Кирәк түгел,— ди тегесе яман чебенне кугандай, кулын изәп. Урмановның тикмәгә йөрмәвен ул сизенә.

— Юк, чын. Минем әйтәсе килгәнем шул: синең белән чагыштырганда малай-шалай, олыны-олы итеп сөйләшә, киңәшә белсен иде хет. Сезнең кебек Ватан сугышын үз җилкәсендә алып чыгып, исәнлекләрен калдырып кайткан батыр кешеләр аркасында рәхәтләнеп, типтереп яши, көннәр буена йомшак машинасыннан төшми... Кешедә аз гына намус, оят диган нәрсә дә булырга тиештер?!.

Мондый ялкынлы, кешенең рухи дөньясын нечкә сиземләп ясалган нотык күңел кыңгырауларын хәрәкәткә китереп, җавап хисләре уятмыйча кала алмый. Орлыкның сөргән, тырмаланган, дымлы җиргә төшкәнен сизенеп сөенгән, профессор: «Минемчә, аның бәйрәмчә тормышы соңгы көннәренә якынлашып килә», — дип, йөзенә салкын, төссез елмаю чыгарып, сүзен дәвам итә.

— Тиздән яңа тикшерү килергә тиеш. Партиядә дә, эшендә дә калдырырга ярамый аны. Безгә бергә булырга кирәк мондый авыр көннәрдә...

Мин ул сөйләшүләрнең шаһиты булмадым, әлбәттә. Әмма әлеге иптәшләр партия җыелышында сүзне нәкъ менә шул тирәдә куерттылар. Беренче сүзне Урманов үзе алып, хатында теркәлгән фикерләрен кабатлап, ректорны партиядән чыгарырга тәкъдим ясады. Үзенә тугрылыклы калып, икенче булып сүз алган Хәйруллин, экономик укуларның, аудиторияләрдә вакытында утны сүндерүнең әһәмиятенә басым ясап, профессорны хуплады, әмма җәзаны бераз йомшартырга диган тәкъдим кертте.

Менә шундый «булган» кеше дә иде безнең ул чорда бердәнбер профессорыбыз. Тик «хакыйкать» өчен армый-талмый көрәшеп йөреп, үзен кызганмады. Яман кеше өчен яшь әрәм булса да, мин андыйларның тормыш принцибын аңларга тырышам. Бер яктан, алар үзләренең уңышсызлыкларында тирәклекне, җәмгыятьне, аерым кешеләрне гаеплиләр. Таләпләр зур, чынбарлык аларны аңламый, дөрес бәяләми һәм үз түгәрәгеннән туктаусыз кысып чыгара, бер тиенгә тормаган кешеләр җылы-җылы урындык билиләр, рәхәттә яшиләр, ә аны бәяләмиләр. Шуннан кеше үз-үзен раслауның тайгак юлына баса һәм үзенә ошаган барлык алымнарны эшкә җигә. Бер уенга кереп киткәч, ул инде азгын хатын төсле, туктый алмый. Икенчедән, аны бу дөньяда берәү дә яратмый,

көнләшәләр, эзәрлеклиләр, юкка чыгарырга тырышалар. Өченчесе — зыялылык җитмәү. Тоталитар режим кешедә горурлык хисен таптады, шәхес таркалды.

Аңа ачу, үпкә кебек хисләр калмады. Мин вакыт узган саен аны аңларга тырышам. Ул бит үзебез үстергән кеше, социализм дип атала килгән система җимеше иде.

### Җыелыш

Имзасыз мәктүбләрне тикшерү буенча килгән беренче комиссиянең эш нәтиҗәсен эченә алган Липатникова язмасы ябык партия җыелышында каралды.

Читтән кеше булмавы тәэсир иттеме, әллә коммунистлар җитәкчегә шелтә бирүнең тәмен сизеп өлгермәгән иделәрме — хәзер кистереп әйтүе кыен, әмма чыгыш ясаучыларның күбесе хат авторын әрләделәр һәм тәфтиш, тикшерү белән чикләнергә дигән тәкъдим керттеләр. Гомеремдә мин хаталарны күп ясаганмындыр, әмма бу чаклы гади, дөньяны, кеше рухын шул чаклы начар белгән, хәтта (бу сүзне әйтүдән дә курыкмыйм) беркатлы булырмын дип уйламаган идем. Җыелыш ябылыр алдыннан, урыннан күтәрелеп: «Иптәшләр, мин үземнең хаталарны, эшемдәге җитешсезлекләрне барыгыздан да тулырак күз алдыма китерәм, шуңа күрә миңа шелтә бирүегезне сорыйм»— дидем. Гаепне өстемә алуым күпләргә гайре табигый тоелды. Коммунистлар, бераз сәерсенеп, бер-берсенә карашып тордылар да, риза булдылар, янәсе, җитәкче үзе сорап торганда, нигә үтенечен канәгатьләндермәскә?! Кирәк икән, рәхим итсен! Әйтергә кирәк, берничә айдан соң икенче, саллырак җәзаны биргәндә, беренчесе бик тә «ярап» торды. Янәсе, партия буенча шелтәне беренче алуы гына түгел, «гадие» бар, хәзер көчәйтергә кирәк...

Җыелыштагы сәерлегемне үзем болайрак акларга тырыштым. Комиссия эшенең нәтиҗәләре, институт кешеләренең бу хәлләргә мөнәсәбәте турында шәһәр партия комитеты өстәге оешмага мәгълүмат бирергә тиеш. Номенклатура үзенә өстәмә мәшәкать тудырмас өчен, миңа, «винтик»ка, барыбер берәр төрле, әйтик, шул ук Липатникованы канәгатьләндерерлек чара уйлап табарга тиеш иде. Икенчедән, мин шикаятьче дус күңеленең ерак бер читендә йомылып калган намус кыйпылчыгы табылыр, ул минем «егетлекне» аңлар, бәяләр, ә кеше төн йокыларын калдырып, хатлар язып та, нәтиҗәсе булмагач, тынычланмас, янә һәм янә болай да юк кәгазьне әрәм итәр, дип фараз кылдым. Мин, әлбәттә, бик нык ялгышканмын.

«Язучы» форманы югалтырга теләмәде, мәктүбләрен үзәккә җибәрүен дәвам итте. Гайбәт орчыгы үзенә кирәген эрли бирде. «Яралы бөркет» аның тынычлыгын алды. Әмма ниндидер яңа «ачышлар», көчле фаш итүләр булмау сәбәпле, әлеге язмаларга игътибар итүче юк, җавап әзер, бастырылып куелган: «Алабуга педагогия институтындагы хәтта күрсәтелгән җитешсезлекләр өлкә комитеты парткомиссиясе тарафыннан урында тикшерелде. Ректорга шелтә бирелде». Имза. Вакыт.

Бу дөньяда шактый яшәсәм дә, бер хикмәтнең серенә төшенә алмыйм интектем. Каян килә синең төсле үк җиһанның иң югары казанышы, табигатьнең таҗы булган кешегә шундый явызлык, әшәкелек, дошманлык? Шул ук шикаять хатларга маһирлык нәселдән килгән авыру төсле буыннан-буынга күчәме, тәрбиядән (тәрбиясезлектән), мөхиттән киләме? Явызлыкның төбендә яхшыны, матурны күрәлмәу, көнчелек хисе ята. Башка адәмдә кешелеклелек түгел, ә начарлык эзләү, аңа аңлы рәвештә пычрак ягу, явызларга бәхетле мизгелләр бүләк итә. Менә шуңа да инде шикаять хатлары тарала. Язма уңышлы чыгып, кәкре үк турыга китсә, бу

халыкның кәефе ифрат күтәрелә, җилкәләр турая, аркалар уклау йоткан төсле ката, күзләргә зәһәр ут, балкыш куна.

Ниһаять, Үзәк Комитет парткомиссиясеннән имзалы хат әйләнеп кайта, өлкә комитеты шул ук В. Г. Липатникова җитәкчелегендә яңа бригаданы пединститут «өстенә» җибәрә. Хатта ике имза: СССР тюркология комитеты әгъзасы, профессор Х. Урманов, доцент Ф. Быкова. Бу эшне нәкъ шул ике адәмнән көткән төсле, җәмәгатьчелек һич кенә дә гаҗәпләнмәде, аптырамады. Сөйләнүләр бер рухтарак булды: «Урмановны үзе алып кайтты. Кем икәнен белә торып. Үзенә-үзе баз казыды». Ханым турында: «Кара син аны Керим Решидович Җаманаклы кызы нинди кеше булып чыкты. Атасына хөрмәт йөзеннән, Галиуллин күпме яхшылык эшләде үзенә, җайлы аспирантурага җибәрде, якларга булышты. Өч бүлмәле квартира алып бирде, телефон кертергә булышты. Кешенең мәкерлеге, явызлыгы чик белми икән». Соңрак Быкованың, хатка кул куярга өндәп, байтак укытучының өйләренә йөргәне билгеле булды. Нәкъ менә шул сәбәп мине Керим Җаманаклы иҗатын барлаудан, өйрәнүдән, җыентык төзүдән читләшергә мәҗбүр итте. Юк, ихтирам иткән кешемнең баласына үпкәләүдән түгел. Кызының миңа мөнәсәбәте шундый булгач, атасының иҗатына алынырга әхлакый хакым юк, миңа «табу» салынды дип фараз кылам. Чөнки кызы нәкъ шул чорда әтисе иҗаты белән шөгыльләнгәнемне тәгаен белә иде.

Бу юлы мәсьәләне өйрәнү, әзерләү, тиешле «кондициягә» җиткерү киңрәк җирлеккә куела, «яңача» алып барыла. Хәбәр таратыла: комиссия ректорның әле безгә әйтмәгән, халык белмәгән яңа махинацияләрен ачкан, сатып алган кешеләр дипломнарын кире китереп, акчаларын таләп итәләр, ди, аны партиядән чыгару һәм эшеннән алу хәл ителгән мәсьәлә икән. Хөкүмәт тиененә кул сузуы да расланган, ди. Комиссия әгъзасы, өлком инструкторының ректор булып калу мөмкинлеге бар икән. Өлком секретаре Р. Беляев: «Үзең барып, тикшереп, Галиуллинның чын йөзен ач, шул эшне ирләрчә үти алсаң, бәлки, үзеңне үк ректор итеп җибәрербез»— дип әйткән, имеш. Бу гайбәтләрне таратуда комиссиянең гаебе ни дәрәҗәдә булуын әйтүе кыен. Ләкин аның хакыйкать эзләмәве, аңлы рәвештә ялган юлга басуы, фактларның үзенә файдалысын гына сайлап алып, кирәккәнчә аңлатуы, бәяләве бәхәс уятмый.

Әлбәттә, «сарафан радио» сының бу тапшыруларыннан хәбәрдар һәркем үзенең киләчәк язмышы, гаиләсе, басылмаган китабы, алынмаган доцентлык таныклыгы, бәләкәй фатиры турында уйлый да, язмышын дөрләп янып, утлы күмергә әйләнгән Галиуллин белән түгел, ә яңа хуҗа белән бәйләргә карар кыла.

Тарих безне шулай «ясап» калдырган: татар кешесе үз фикерендә нык торырга өйрәнмәгән, кемгәдер тиз ышанып, уен үзгәртә, кыйбласын кире якка бора да куя. Бу яктан аның буыны йомшак, сөяксез, тотрыксыз (Шаһгалиләр кавеменнән килә торган бер сыйфатмы шунда?). Манкортта иман, кешелеклелек була алмый.

Шулай да башны эшләтергә өйрәнгәннәре ашыкмый, ник дисәң, әле Галиуллинның эштән алынуы суга сәнәк белән язылган, аннан килеп, яңа түрә бүген элеккеге ректорны «комиссион бәягә» саткан кеше, ни өчен мине тагын да арзанракка ычкындырмас?..

Бу юлы инде җыелыш горкомның күпчелек бюро әгъзалары, өлкә парткомиссия рәисе һәм коммунистларының йөз процент катнашы белән вакытында башланып китте. Ябык партия җыелышы. Залда яртысы пенсия яшендәге адәмнәр, институт эшен җилкәләрендә алып баручы, мине яклый-аңлый алырдай кешеләр «баррикаданың», ишекнең теге ягында калдылар. Мәсьәләне бөтен коллектив белән тикшерергә дигән тәкъдимне партаппарат кабул итмәде. «Без коммунист Галиуллинның персональ эшен тикшерәбез»,— дигән арзанлы демагогия җиңде.

Җыелыш алдан ук ныклап һәм һәрьяклап әзерләнде. Инде шактый сузылган, туйдыра башлаган бу галәмәтләргә нокта куеп кайтасы дип,

өлкә парткомиссия рәисен ук җибәргәннәр. Ул үзенең максатын, вәкаләтен шәһәр комитетында беренче очрашуда ук ачыктан-ачык әйткән, коммунистлар ничек хәл итсә, өлком шуңа риза, партиядән чыгарып, эшеннән азат итүгә дә каршы түгел, дигән. Бу фикере шунда ук егерменче гасыр әлемтәсе ярдәмендә миңа килеп җитте, җыелышта бу тәкъдимне беренче булып сүз алган хат авторы Урманов кертте.

Липатникова каләменнән төшкән бәяләмәдә институт тормышы, башкарылган эшләр турында чирек уңай сүз дә әйтелмичә, мөмкин булган бөтен җитешсезлекләр, үсеш кыенлыклары, бездән тормаган проблемалар бер кеше өстенә өелгән. Бәядә рус теле арсеналында булган тискәре сыйфатлы эпитетлар мул кулланылган, буяулар тыңлаучыларның хисенә, психикасына яман тәэсир итәрлек, йомшаграк нервлыларны авыруга сабыштырырлык куе төсләрдә бирелгән. Тикшереп, уйланып, шикләнеп вакыт уздырасы түгел, кулга йозак кидереп, алып кына китәсе гаепләне. Эшләп торган кеше турында бармактан суырып чыгарып, юкны бар итеп шундый усал, миһербансыз нәтиҗәләр ясап булуына үз колагым белән ишетмәсәм, хәзер дә күчермәсе алдымда ятмаса, билләһи, ышанмас идем.

Кеше күңеленең иң тирән катламнарында яткан азгын хисләрен уятып, җитәкчегә яисә башка берәр затка каршы һөҗүмгә күтәрү алымнары бездә ифрат яхшы эшләнгән икән. Липатникова бу мәсьәләдә җитлеккән, партаппаратның кеше рухын сындыра алырлык бик күп алымнарын ифрат иҗади үзләштергән булып чыкты. Комиссия эше йомгагы — бәяләмә язманың исеме генә дә теләсә кемнең шиген, икеләнүен, ышануын, өтек өметен чәлпәрәмә китерерлек иде. Андый хокук бирелмәү сәбәпле, татар теле кешене каһәрләүгә артык җайланмаган, үсмәгән, шуңа күрә атаманы язылган телендә китерәм: «О серьезных нарушениях и недостатках, нездоровой обстановке в Елабужском государственном пединституте и неправильных действиях, поведении ректора, члена КПСС т. Галиуллина Т. Н.». Эчтәлектә «шыксыз үрдәк бәпкәсе» турында бер генә уңай фикернең дә урын ала алмавы аңлашылса кирәк. Аннан килеп, һәр нәрсә фирка исеменнән эшләнә, ә аңа тел тидерергә дә, кагылырга да ярамый иде әле.

Аерым кешене төрмәгә озатып була, ә партияне хөкемгә тартып кара?! Ул биргән мөмкинлекләргә, чиксез ирекккә, хакимияткә кызыгып, шактый намуссыз, йөрәгендә изге утсыз кешеләр кереп тулды да замананың аның сафларына.

Рәис «гөнаһлар дәфтәрен» укып бетергәч, мине яратмаган, миннән гарык булган, туйган кешеләр дә сулышлары бетеп, югалып калдылар. Тып-тын. Патша туган тантаналы мизгел диярсең. Авыр тынлыкны таратып, сорау бирергә батырчылык иткән кеше дә табылмады хәтта. Әлбәттә, институтны тикшергән комиссиянең әлеге нәтиҗәдә чагылган миңа карата куралмаучыл мөнәсәбәте әлек мине аклап, яклап килгән, битараф укытучыларны да аптырашта калдырды. Кем инде батып барган көймәгә төшеп утырсын!

Сөйләүчеләр бихисап күп булды, җыелыш сигез сәгатькә сузылды. Чыгышлар, сүзләр, шәхси үч алу, үпкәсен, рәхмәтен, хуплавын әйтеп калырга ашыгу. Зал мунча ташы кебек кызды, су ташласаң, пар күтәрелер сыман хәлгә килде бер мәлне.

Һәр нотыкчының үз сөйләү алымы, холкы, фигыле бар. Берсе нахак бала ягудан, әрләүдән, тәрбияләүдән, акыл сатудан тәм тапса, икенчесе купшы мактау юлына баса, өченчесе килгән-килгән буш кул белән кайтмыйм, сөйләгән сүз, аткан ук булмаса да, ярап торыр шунда, дип, буш җөмләләр, гомуми сүзләр тезеп китә. Соңгылары миңа бераз ял итәргә, тынычланырга мөмкинлек бирәләр.

Вакыт узып, әлеге хәлләргә башкачарак карарга мөмкинлек тугач, минем бу җыелышны нишләптер океанга тиңлисе килде. Аның тозы, җылылыгы төрле җирдә төрлечә була диләр. Ә давыл бөтен пычракны,

күбекне, башка файдасыз нәрсәләрне астан өскә чыгарып, яр буена ыргыта. Бу очракта «күбекнең» мөһим өлешен өлкән буын ир-ат халкы тәшкил итте. Иң явыз, миһербансыз сүзләр алар авызыннан чыкты. Ни өчен безнең халык олыгайган саен шулай шәфкатьсезгә әйләнә икәнен өздереп әйтә алмыйм. Күрәсең, ирлек хасияте кими барган саен, кеше вагая, гиенен саный, үзеннән яшьрәкләрне күрә алмый башлый. Арткан үч, көнчелек якыннарга, бергә эшләгән оешма кешеләренә күчерелә. Пенсия акчасының тормышның очын-очка ялгап баруга җитмәве дә аны гарьләндерә. Машинада узып киткән шома чырайлы һәр түрә аның шәхси дошманына әйләнә. Эшләгәндә җыела килгән үпкә, каргыш, аяу да кайчандыр бер түгелергә, тышка чыгарга тиеш. Кая соң гыйлемле аксакаллар?! Халкыбызның илаһи йолалары шулай югалып, таш-кан астында калдылармыни? Аяныч!

Өлкәннәрнен явызлыгы, кемнедер күрә алмавы (сүз минем хакта гына түгел, аларга барыбер, мине алыштырган ректор белән дә шул ук «операцияне» тизрәк һәм уңышлырак башкардылар), минемчә — шәфкатьсез, мәнсез, кешелексез җәмгыять тәрбиясе, шәхеснең бәясе бетү нәтиҗәсе.

Җыелышта төрле тамгалар ябыштырып, шәхси үпкәсенә иҗтимагый, сәяси яңгыраш сөмсере бирергә тырышып, чәпчеп миңа каршы чыккан кешеләрнең күбесе — пенсионерлар. Урманов, Арсланов, Насыйбуллин, Гайнуллин, Елизов кебек кешеләр иде. Аларның мине «үзләренеке» дип кабул итмәвенә шатланып та куям. Алар рәтенә басмавым яхшы — хәзер яшьләр күзенә күренүе бик тә читен булыр иде.

Гомумиләштерүгә һич кенә дә дәгъва итми торган тагын бер күзәтүем: кыенлык килгәндә, иҗтимагый фәннәр һәм педагогика укытучыларына ышыклануы суга таяну белән бер, алар һичкайчан да кеше өчен башларын бүкәнгә куймас икән.

Эш гөрләп барганда, син аларның мәсьәләләрен хәл итә, китапларын чыгарыша, диссертацияләрен яклауга булыша, чиратсыз машина алып бирә алганда, алар һәрвакыт кул астында, янында тора, «көйгән ис» килә башладымы, бар да яныңнан таяр: туганнарыннан телеграмма суктырыр, конференциягә чакырту оештырыр (хыял дисәң — диңгез), әмма җыелышка килмәс, килсә дә чыраена күпмәгънәле битарафлык чыгарып, мода журналын актарып утырыр!

Ә сиңа каршы чыгыш ясарга җыенганнары шифаханәдә ятса да, качып чыгар, барып сәяхәтен кичектерер, туганын күмәргә кайтмас. Менә шундыйлар алар Маркс оныклары, Макаренко варислары. Бик үк тугры булмаса да, бик үк тугры түгел бәндәләр дә изгеләр кебек чыгыш ясый.

Миңа хәерхак кешеләр бер тирәгәрәк җыелышып утырганнар, берсе өстәлдәге рәсемнәрне өйрәнә, икенчесе тәрәзә рамаларындагы тутыккан тупсаларны барлый, өченчесе күршесе белән гәпләшә. Аларның мине яклап урыннан күтәрелерлекләре юк, ректорга якынлыклары өчен бүгенге очрашуга алып килгән хатта алар тискәре геройлар рәтендә. Һәркайсына берәр тамга салынган. Аннан соң, алар һәр җыелышта нотык тотып, каешланып, керләнеп беткән кешеләр түгел. Кулуарда чыгыш кирәксә, рәхим ит, ә трибунага чыгып... Андыйлар әнә алгы рәтләрдә утыра.

Ректорларын берәү дә якламаган дип уйлый күрмәгез берүк. Андыйлар күбрәк тә иде. Калай әтәч кебек кызып-кызып сөйләүче яшьләр шактый булды. Институтта эшләп, ялга чыккан саф күңелле хатын-кызның мине кызганып, хаксызлыкка гасабиланып, җаннары миңа өзгәләнгәнен, күңелләре ихласлыгын күрсәгез иде! Фәридә Морадыймова, Саимә Латыйпова кебек олы рухлы шәхесләр трибунадан җылый-җылый сөйләделәр, акылдан шашмаска, әхлак кагыйдәләрен онытмаска чакырдылар.

Әмма хискә корылган чыгышларга эзлеклелек, дәлилләр җитешми.

Сүз бирү тәртибе исә нык уйланылган. Чөнки яманлыкка юнәлеш биреп торучы үзәк бар, президиум алар яклы. Тарихны искә төшерегез. Оешканлык, үз көченә ышану 1917 елда аз санлы большевикларга властьны үз кулларына алырга мөмкинлек бирде.

Кырык өченче аудиториядә үзем өчен тагын бер «ачыш» ясадым. Кеше үзенә турыдан-туры кагылмаган хакыйкатьне, әрнүне, сызлануны, гарьләнүне аңларга һәм күрергә өйрәнгәнче, явызлык, кабахәтлек дәвам итәчәк, җәмгыять әхлакый үсешендә дини һәм рухи дәреслекләрдән баш тарткан, аларны анафемага биргән урында таптаначак.

Җавап сүзгә мин үземчә чын-чынлап, озак итеп әзерләндем. Әмма бу җыелышта әллә ни майтарып булмаслыгын аңлавы кыен түгел иде. Парткомиссия бернинди иллюзиягә дә урын калдырмаслык итеп «эшләгән». Миңа алдан, Казанда ук билгеләнгән җәза бирелмичә, халыкка өйгә таралырга рөхсәт булмаячак. Арыган, талчыккан кеше исә теләсә нинди тәкъдимгә риза, тизрәк бу тынчу залдан чыгып китәргә генә кирәк!

Ике чыгыш тыңлыйсы калды: институтның партбюро секретаре Г. Петровның сөйлисе бар һәм шәһәр партия оешмасы хуҗасы нәтиҗә ясарга тиеш.

Беренче оратор белән институтка бер чорда килдек, балаларыбыз бергә тәгәрәшеп үсте, бер табактан ашаган, эчкән ризыкның исәбе-хисабы юк. Партбюро секретаре булып теләп, тәмләп утыра. Сүзгә осталыгын, җөмлә төзи белү, юморны сиземләү сәләтен күрсәтергә мөмкинлек бар. Һәрвакытта тыңлаучы табып була. Фәнни эше барып чыкмады. Алдан Казан университеты, аннан Ленинград педагогия институты аспирантураларында укып, һәртөрле белем күтәрү, иҗат ялы, командировка кебек мөмкинлекләрне ахыргача кулланып та, диссертациясен очлап чыга алмагач, ул бу эшкә кул селтәп, физиканы ташлап, политология белән шөгыльләнә башлады. Тән чирне үзеннән чыгару юлын табарга тиеш барыбер.

Үземә кешеләрчә, хәтта дусларча мөнәсәбәтенә шикләнмәгән егетем бер мәлне кискен үзгәрә, кирәксә-кирәкмәсә дә тәртәгә тибә башлады. Гаеп үземдә дип уйлыйм. Хикмәт шунда: югары уку йортларындагы кайбер укытучыларга кандидатлык, докторлык диссертациясен якламасаң да, фәнни һәм методик әсбаплары булса, доцент, профессор исемнәре бирелергә мөмкин. Әлбәттә, кемдер бу эш артыннан армый-талмый йөрергә, җаваплы кешеләр белән очрашырга, аңлатырга, исбатларга тиеш.

Доцентлык кенәгәсен кесәсенә салуга, фирка секретаренең аркасы уклау йоткандай катты. Аңа эчке, рухи йөзен ачу һәм үзен күрсәтү өчен минә шундый бөр терәк кенә кирәк булган икән. Шуңа күрә хәзерге чыгышының да миңа каршы буласына шикләнмәдем дә диярлек. Шик нигезле булып чыкты. Ул, шикаятьтәге күпчелек фикерләрне яклап: «Мин аңа бу җитешсезлекләре турында әйткәләдем, әмма соңгы вакытта ул беркем белән дә санашмый, кеше сүзенә колак салмый, бюрократлашып җитте һәм ректорга бу бозыклыклары өчен җавап бирергә вакыт»,— дие тәмамлады сүзен пединститут коммунистлары җитәкчесе.

Сүзне Алабуга хуҗасы — татар җире тудырган үзенчәлекле шәхесләрнең берсе — Й. Курмашев алды. Баһадир гәүдәсе, салмак йөреше, өлкәннәр белән сөйләшкәндә, үз фикеренә ябышып ятмыйча, әйткән белән килешә белүе ярдәм иттеме, хәзер тәгаенләве кыен, әмма ул гомерен табынның түрендә, үрнәк-өлге җитәкче буларак уздырды. Сөйләшкәндә, халык теленнән ингән берәр акыллы гыйбарәне, күзәтүне, әйтемне вакытында кыстырып куя белә. Татарчасы чамалы түрәләр аның мәзәкләреннән, сөйләкләреннән, үзләрен урынлы мактап куюыннан мөкиббән китеп, аны гел үзләре белән йөртеләр.

Өлкә комитетының беренче секретаре итеп Усманов расланган. Курмашев аның якын киңәшчесе, сердәше, яраткан аксакалы булып китте.

Алабуга партия оешмасын җитәкләү, түшкә РСФСР Югары Советы депутаты билгесе тагу, соңрак тыныч кына «Кама» агропромы рәисе булып күчү, кыскасы, тормыштан үзенә кирәген алып калуга юл ачу — Усманов мәхәббәтенең җимеше иде. Безнең тоталитар җәмгыятьтә менә шундыйрак кешеләр аеруча рәхәт, тыныч гомер кичерәләр шул.

Бу юлы Йолдыз Вагыйзовичка хәйләкәр осталыгын җыеп, ректорны да рәнҗетмичә («астына су керсә дә, барыбер үзебезнең малай»), коммунистлар һәм өлком кешесе алдында да абруен төшермичә, җыелышны ипле генә төгәлләргә кирәк иде.

— Болай да авыр дөньяны без үзебез катлауландырабыз,— диде ул.— Кулга кул тотынып, бер түгәрәктә йөрисе урынга, бер-беребезгә баз казыйбыз, кешене шунда төртеп төшерергә омтылабыз. Бу дусларча да, заманча да, коммунистларча да түгел. Сез бит барыгыз да иң кимендә югары белемле, акыллы кешеләр. Менә горком күпме вакыт инде бары тик институт белән мәшгуль. Эшкә килеп керсәң, сездән берәресе кәтеп утыра, кемнәрдер канәгать түгел. Ректор турында. Кемдер барыбер эшләргә тиеш бит ректор булып. Иртәгә мин килсәм, белеп торам, минем өстән дә барыбер язачаксыз. Алай ярамый, иптәшләр, бетерергә кирәк бу тәртипсезлекләрне...

Әйе: берәү урлый алаша, берәү карый тамаша.

Партаппаратның төп максаты — үзенә охшамаган, каршы төшкән кешене әхлакый имгәтү, рухи буйсындыру. «Кеше бар — проблема бар, кеше юк — проблема юк». Бу гыйбарәне Сталин үлеп яраткан, диләр. Тиран кешене физик юкка чыгаруны күздә тоткандыр, әлбәттә. Әмма шәхесне әхлакый сындыру, психик имгәтү дә вакыты белән физик югалтуларга торырлык иде.

## Шәрәфетдинов «эше»

«Эше» сүзен укыгач кайберәүләр мавыктыргыч детектив көтәр. Әмма бу язмада сүз гадәти бер вакыйга, аппарат уеннарының гыйбрәтле бер «эше» турында барачак.

Урманов белән Быкова иптәшләрнең ул чорда Соломенцев җитәкләгән оешмадан әйләнеп кайткан хатларында икенче «халык дошманы» (беренчесен, чуваш кардәшләр әйтмешли, «үсепес тип пеләпес»), институтның Чаллыдагы факультеты деканы Зиннур Шәрәфетдинов булып чыкты. Яшь кеше өстенә пычракны кызганмыйча, подаукалап тондырганнар. Санап бетерерлек түгел: факультет суыткычын өенә алып киткән, тыйнаксызлык үрнәге күрсәтеп, биш бүлмәле менә дигән фатирга кереп утырган (өч баласы барын, әнисе аның белән яшәвен әйтергә яхшысынмаганнар), үзен тәкәббер, эре тота, милли хисләренә ирек бирә, туганы, ата хөрәсән Гавазга ике-өч ставка түли, институт машинасы белән туган авылына кайтып килгән һ. б.

Шул гаепнамәләр буенча Липатникова бригадасы тулы тикшерү оештырды, мәсьәләне партия җыелышына чыгарды. Әйтергә кирәк, Шәрәфетдинов балтасын коега төшермәде, үзенең хаклыгына ышанычын югалтмыйча, үзен кыю тотты. Аның егетлеге ике мәсьәләдә ачык күренде.

Парткомиссия эше нәтиҗәсен тикшергән җыенда ул, кешеләргә яла ягу, микроклиматны бозу, туктаусыз хатлар язуы өчен профессор Урмановның «шәхси эшен» көн тәртибенә кертүгә ирешә. Парткомиссия һәм райком вәкилләре мондый борылышны көтмәү сәбәпле, югалып калдылар. Гомер буена алдан күрсәткән, сызылган юлдан йөрергә өйрәнгән кешеләр өчен буразнадан читкә чыгарудан да куркыныч нәрсә юк. Ул гына да түгел, Зиннур Тәлгатович кат-кат чыгыш ясап, дәлилләр китереп, халыкны «көрәшкә» күтәреп, Урмановка каты шелтә бирдерүгә ирешә.

Табигый буларак, КПССның Чаллы Комсомол районы комитеты, Урмановның үзе өстеннән яза башлавыннан өркеп, «первичка»ның карарын расламады.

Бездән соң килгән буын коллык рухыннан җиңелрәк арына. Алар һәр әйткәнгә разый булып тормыйлар, үз фикерләрен ярып сала беләләр. Вакыйганың 1986 ел башында барганлыгын, яңартып коруның әле беренче иртәнге нурлары гына күренә башлаган чор булуны да онытмыйк. «Үз эшенә йөрәген, җанын-тәнен биргән кешеләрне җәберләү, кызганычка каршы, безнең җәмгыять өчен гадәти хәл»,— дип яза «Известия» газетасы (1990, 3 август).

Җөмһүрият парткомиссия рәисенең икенче максаты да бар икән: Шәрәфетдиновны деканлыктан азат итү. Бу хакта сөйләшүгә инде райкомда нигез салынса да, җыелышта күтәрергә нигәдер базмадылар. Яшь декан белән шундыйрак аңлашу булды.

— Безнең илдә кешегә бәяне эшенең нәтиҗәсенә карап бирәләр. Дөрес, Чаллыга факультетлар белән күчеп, биредә шактый эш башкардыгыз. Яңа бинаны коруда да, тулай торакны төзүдә дә сезнең өлеш бар. Шул ук вакытта онытмыйк, бу объектларны шәһәр салып бирде,— диде аппарат кешесе, мактавында чама хисен югалта баруын сизеп.— Тикшерү күрсәтүенчә, сез төп эшегез, үз вазыйфаларыгыз белән аз шөгыльләнгәнсез!

— Мәсәлән? — диде декан, кыска сөйләү үрнәге күрсәтеп.

— Бармакта саныйм. Соңыннан дәгъвасы булмасын. Чаллыда урнашкан факультетларда дус, эшчән коллектив тудыра алмагансыз. Хат язу осталары Урманов белән Быкова кайда эшлиләр? Сездә? Алар ректор өстеннән туктаусыз яза, коллективның астын-өскә китерә, безгә дә тынычлык юк (менә бит ничек борып куеп була мәсьәләне). Димәк, тәрбияви эш сезнең тарафтан начар куелган. Яныгызга шактый туган-тумачагызны, дус-ишегезне җыйгансыз. Дүртенчедән, горком секретаре, ничек әле фамилиясе, кыскасы, баш идеологыгыз сезне Мәскәү самолетыннан төшкәндә, бик арыган, таушалган килеш күргән...

Шәрәфетдинов бу уйдырма гаепләүләрне «бусагадан» кире кага. «Деканлыктан, бәлки, вакытлыча китеп торырга кирәктер сезгә, дөньялар тынычланганчы»,— дигән тәкъдим дә кабул ителми. «Мине, һәрхәлдә, гыйльми совет сайлап куйды, ул хәл итәр»,— дип кенә җавап бирә.

Мин янә яшьләр өчен шатланам: боларда партия сүзеннән урманда бүрегә юлыккан кеше төсле кот чыгу, сүзсез буйсыну, курку рухы малай чакта Сталинны күмүне күргән кешеләрдәге төсле ямьсез, бозык төс алмаган. Миңа: «Эшеңнән китү хакында гариза яз»,— дисәләр, шунда ук каләм белән кәгазьгә ябышып, шундый житешсезлекләрем булуга карамастан, озак еллар буена ышаныч күрсәтеп, ярдәм итеп эшләткән өчен партиягә, министрлыкка рәхмәтләр әйтеп, укытучы эшенә күчерүне сорар идем (соңрак нәкъ шулай килеп тә чыкты).

Ә яшьләр кулга каләм алырга да, тезне җиргә иңдерергә дә ашыкмый. Миңа иң кыен мизгелләрдә, үзләренең репутацияләрен бозу, кемгәдер ошамау кебек нәрсәләр белән санашмыйча, нәкъ менә Шәрәфетдинов кебек яшьрәк буын ярдәмгә килде. Минем белән бергә атлау яшьләрнең фәнни, эш буенча үсүләренә зарар китермәде кебек. Кеше язмышы өчен янып-көеп йөрү аларның үзләрен дә үстерә, зиһеннәрен зирәкләндерә, гражданлык рухларын ныгыта. Хәзер әлеге егетләрнең берсе ректор, икесе проректорлар дәрәҗәсенә күтәрелүләрен искәртеп узу белән генә чикләнәм бу урында.

Липатникованың башкаладан ияртеп килгән, урында табылган күп санлы ярдәмчеләре РСФСР хокук кодексыннан «житәкченең туганнан туганы турыдан-туры ярдәмчесе, урынбасары булып эшли алмый» дигән аңлатма табып бирәләр. Ә Шәрәфетдинов, парткомиссия санап чыгарунча, минем әтинең туган сеңелесенең малае икән. Зиннурга: «Үзегез

гариза язып эштән китсәгез, яхшырак булыр»,— дигән киңәшне бөтенләй бушлай колагына пышылдадылар. Шәрәфетдинов: «Мин берни дә язмаячакмын!» — дип, райком бинасыннан ук чыгып китте.

Безнең күз алдында, сөйләсәң кеше ышанмаслык гаҗәеп бер метаморфоза пәйда булды: Татарстан коммунистларының өлкә парткомиссиясе рәисе безнең шикелле үк кеше рәвешенә кайтып төште. Сүзләре шаяру кебек, әмма тавышында үтенеч, сорау. «Әйтсәм, әйтим инде. Миңа, Шәрәфетдиновны деканлыктан азат итү турындагы приказның күчермәсеннән башка, Казанга кайтырга рөхсәт юк. Зинһар, шуны эшлик инде! Әмер — секретарьдан».

Партаппарат кешеләрен кызганып чәчләр агарды, яшь гомерләр үтте инде. Баш бирмәс Шәрәфетдиновны, гаризасыннан башка, парткомиссия басымы астында, төрле уйдырма сәбәпләр табып, эшеннән азат иттек. Ә икенче көнне декан, кодекстан соңрак дөнья күргән, аңлатмалар китабын күтәреп килде. Мәгълүм параграфта буйсыну турыдан-туры булган очракларда да, сайлап куела торган урыннарны (декан биш елга гыйльми совет тарафыннан, яшерен тавыш бирү юлы белән, сайлап куела) җитәкченең туганнан туганы рәхәтләнеп били ала, дип ачык, төгәл итеп язып куелган. Акка кара белән. Әмма инде соң. Мин — янәдән аппарат уены корбаны. Приказ күчермәсе өлком парткомиссиясе рәисе кесәсендә мәркәзебез Казанга китте. Шәрәфетдинов каршында мин икеләтә гаепле кеше: әүвәл факультетына Хәй Урмановны алып кайтып утырттым (үзең тапкан мал, капчыгың тутырып ал, дип әйтерлек хакы да бар иде аның). Аннан бик үк законлы булмаган приказ «селтәдем». Шулар өчен күңел җәрәхәте әле дә саркып тора.

Шул көннән алып миемне бер уй бораулый. Партиягә рәхмәтләр укыганда, без кемне күз алдында тота идек соң, күзгә күренмәгән, капшап карап булмаган идеалнымы, рәшәнеме, әллә аның башында утырып, халык исәбенә болытсыз күк астында, «махсусларда» ял итеп, сәламәтлеген төзәтеп, олы эшләр белән шөгыльләнәсе урынга, яшь җитәкче Шәрәфетдиновны мәкерле юллар белән булса да эшеннән алуны намус эше санаган аппаратның аерым кешеләрен шулай зурлыйбызмы? Хәер, Шәрәфетдинов нибары берничә ай «бәйсез» доцент булып, түшәмгә төкереп яшәп кала алды. Коллектив аны әүвәл кафедра мөдире итеп сайлап куйды, аннан деканлыкка кайтарды. 1990 елда Чаллыда республикада өченче мөстәкыйль педагогия институты ачылгач, ул аның ректоры итеп билгеләнде.

Кайчандыр Шәрәфетдиновны деканнан азат итүгә «ирешкән» Р. Беляев («әмер» биргән секретарьны мин шунда ук таныдым) үзе дә аппарат уеннары корбаны булып, өлкә комитетыннан китте. Күрше авыл малаена, Чаллыда эшләгәндә, нindидер үпкәсе, әйтелмәгән «васыяте», үче булгандыр. Номенклатура, кемнедер «акылга утырту» җае чыкканда, форсатны кулдан ычкындырмый торган иде.

Язмыш аларны тиңләде. Аксубай киңлекләрендә бер-берсенә сыенып утырган, борын-борыннан уртак базарлар корып, шатлык-кайгыны бүлешеп, киленнәр алышып яшәгән Карасу белән Шәрбән авыллары чишмәләре суын тәмләп, болыннарын таптап, урманнарын гизеп үскән З. Шәрәфетдинов белән Р. Беляев хәзер икесе дә институт ректорлары.

Данлыклы КАИ, КХТИ кебек шәһәр уртасындагы иң яхшы биналарга урнашкан институтларның татар халкына күпме файдасы тия торгандыр, төп милләт вәкилләреннән җитәкчеләр, укытучылар, студентлар күпмедер — әйтә алмыйм, алар күбрәк үзәктәге министрлыкларга хезмәт итәләр, ә Чаллы педагогия һәм Казан мәдәният институтларының милләтебезнең рухи, әхлакый, сәяси үсешен, туган телебезнең, әдәбиятыбызның киләчәген билгеләүдә иң мөһим кылларын кулларында тотып баручы көчләр булуы бәхәс уятмас кебек. Бер тәртәгә җигелеп, тартасы гына калды авыр йөкне күрше авыл егетләренә, бер-берсенә карата миһербанлылык һәм шәфкатьлелек үрнәкләре күрсәтеп. Вак-төяк үпкәләрне онытып!

Җитмешенче-сиксәненче елларда Алабуга горкомында булган кеше хәтерләми калмас: икенче катка күтәрелгән уңайга «районның алдынгы пропагандистлары» дигән мактау тактасы эленеп тора. Җиренә житкереп эшләнгән стенд, күләмле рәсемнәр битараф калдыра алмый. Хуҗалар утырган якка узганда, алар сине тутыккан кадак төсле бер ноктага төбәлгән, тоныклана барган күз карашлары белән озатып, әйтерсең лә, фатиха биреп калалар. Алабуга пединституты укытучылары Сәхибуллин белән Хәйруллинның фотолары икесе янәшәме, чиратлашыпмы, бу күргәзмәдән төшмәделәр.

Ике аерылмас дус! Ирләр татулыгы турында күпме дастаннар, риваятьләр чыгарылган, шигырь-романнар язылган?! Мондый ахириләрне татарың Әсәк белән Көсәк дип йөртә. Фикерләү рәвешләре, тормыш юллары, кылган гамәлләре, иртәнге хыяллары, тирәлеккә мөнәсәбәтләре аларны шул чаклы якынлаштыра, тышкы охшашлыклары да бераз килсә, алар Сиам игезәкләренә көндәшлек тудыра алырлар иде.

Биографияләрендәге уртак гомуми урыннарны саный башласаң, кул бармаклары гына җитмәс. Белем урта мәктәптән, югарысына чаклы, читтән торып алынган. Ул чорда Казанда кадрларны кирпечтәй «сугып» торган югары партия мәктәбе бар иде. Эштән аерылмыйча уку ул чорда кешенең активына языла, күкрәк киереп, мактанып йөрерлек бер нәрсә иде: янәсе, көндез укып, ыштан туздырып йөрми абзагыз, белемен дә куш учлап ала, якты киләчәкне якынлаштыруга да үзеннән гамәли өлеш кертә. Әнә бит Горький каләменнән төшкән бер герой да: «Уку кеше исәбенә яшәү түгелме соң ул?» — дигән сорау куя.

Сәхибуллин белән Хәйруллинның көндез укырга мөмкинлекләре дә булмый. Икесе дә Бөек Ватан сугышында катнашып, шактый батырлыклар күрсәтеп, фронтовиклар дулкыны белән халык хуҗалыгына килеп кушылалар һәм шактый еллар дәвамында партия һәм совет номенклатурасы дигән «хезмәт армиясе» сафын Морты районында бизиләр. Хрущев заманында кыскартылгач, Алабуганы бәхетле итәләр. Әхәт Сәхибуллович сигез-тугыз ай тирәсе яңа горкомның беренче сәркатибы вазифаларын да үтәп ала. Әмма тупаслыгы, дорфалыгы, эш тәртибен белмәве һәм агымдагы хәлләрне ходай кызганмыйча биргән юан тавышы белән, күк алласы Зевс кебек, күк күкрәтеп кенә хәл итү юлына басуы өчен каты себерке белән, ягъни башка эш урыны тәкъдим итөлмичә, куыла.

Әүвәл озак кына шифаханәдә ял итеп ала (партаппарат бу алымны бик тә яратып «эшкә» җигә иде), шунда киләчәк язмышы турында уйлана башлый. Горкомның җайлы бүлмәсендә утырганда ук, шәһәрнең аргы читендә, буш, иркен кырда, дүрт катлы затлы бинада урнашкан оешма күңелен кымтырыклаган аның. «Күр әле син, яшь егетләр, чибәр кызлар, кирәкле эшемне кырган кешеләрдәй, бинага бер керәләр, бер чыгалар, шәһәрдә дә, кәҗә тәкәләредәй сикерешеп, тыз-быз килеп йөргән булалар. Ә әрәм тамак укытучылары! Державага тиешлек файдалары юк, нечкә муенны галстукка тыгып, портфель күтәреп, һавалы гына узып китәләр яныңнан. Бюрога чакыртып, кирәкләрен бирәсе иде дә, өлгерә алмый калдым. Кемнәр генә хөкүмәт акчасын кесәсенә салып ятмый институтта: Гитлер эзәрлекләвеннән качкан Австрия яһүде, сатлык җаннар токымы, башы Себердә черергә тиешле Кырым татары, Саратов өлкәсеннән куылган немецлар дисеңме, һәммәсе балга очып килгән кортлар. Партия йогынтысы җитешми. Миңа калган гомеремне яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләү эшенә багышларга кирәк булыр!»

Институт ректоры горкомның элеккеге беренчесен партия тарихыннан өлкән укытучы итеп алырга шатланып риза була. Татарстанда бу хәл табигый: аппараттан кысып чыгарылган янсә «янган» кешене югары уку

йортларына марксизм укытырга җибәрәләр. Казан институтларындагы иҗтимагый фәннәр укытучыларын күздән кичереп карасагыз, күбесе томшыгын партия, комсомол эшендә чыныктырган булыр! Шул рәвешле, зыялылар урынын ярым-йорты белемле, тыңлаулы, ихтыярга мохтаҗлыгы сизелмәгән кешеләр алып куя. Белемне аннан-моннан чүпләгән өйрәнчекләр, партаппараттан куылган кешеләр әлеге фәннең абруен артык күтәрә алмадылар шул.

Иртәгесе көне өчен тыныч булсын дип, Сәхибуллинны институт советында сайлап куярга килешәләр. Ялкынлы чыгышында ректор ханым булачак укытучысына унай бәя бирә: янәсе, бездә теоретиклар биниһая, буа буарлык, әмма тормышны белгән, сүзе белән эшен кушып алып барырдай шәхесләр юк диярлек. Хәзер ул безнең алда утыра. Тавышыгызны кызганмавыгызны үтенәм. Мин үзем Әхәт Сәхибулловичны рәхәтләнеп сайлаячакмын! Яшерен тавыш бирү башлана. Барысы да, үгетләүне чынга алып, зәхмәтне уздырып та куярлар, дип коты чыккан совет рәисе, үзе кара шар тәгәрәтә. Бер генә уңай тавышка да лаек була алмый кичәге шәһәр һәм район хуҗасы. Һәммәсенә оят, аклану, кызгану, кызару, эчке шатлану... Хатаны хисап комиссиясенә сылтап (дөрес санамаганнар, бутаганнар), ректор Сәхибуллинны бер атнадан янәдән совет утырышына куя. Шул ук «югары» бәя кабатлана. «Эшсезлек бездә, капитализм калдыгы буларак, фәлән елда ук бетерелде, кешенең хәленә керергә кирәк, партия үзе өнәмәгән кешеләрне кире алмый» кебек, ректорның шактый буталчык, эклектик чыгышыннан соң, сайлау кәгазьләре таратыла. Бу юлы укытучы буласы кеше бер уңай тавыш җыя, башкалары каршы, әмма берлекнең калган егерме дүрт әгъзасы да «сызмаганы минеке иде» дип, күкрәк кага, бичараның кулын кыса.

Утны-суны кичкән Әхәт Сәхибуллович югалып калып, кулын салындырып, балавыз сыгып утыра торганнардан түгел. Череп таркалган, мәгънәсез бәндәләрдән торган совет каршы дип кенә институтта эшләү ниятеннән кайтып булмас. Икенче көнне үк республиканың мәркәзенә юл тота һәм өлкә комитетыннан яшь белгечләргә генә бирелә торган путевка белән кайтып төшә.

Дусты Сәхибуллин «батырлыгын» кабатлап, Хәйруллин да политик экономия укытучысы булып институтка килә.

Вакытка җайлаша белү ягыннан әлеге мөһаҗирләр бик күпләргә үрнәк-өлге дәресләре бирәләр. Совет аша сайланып кую вакыты җитәр алдыннан алар, куштан мәче төсле, үзләренең изге теләкләре, яхшы киңәшләре белән һәрвакыт синең янда сырпаланыр... Кесәләренә югары уку йорты укытучысы таныклыгын салып куйгач, алар фәнгә мөнәсәбәтләрен ачыкларга керешәләр. Мөнәсәбәт дигәне шул инде — фән кандидаты дәрәҗәсе кирәк боларга. Бу дәрәҗә, хөрмәт һәм ихтирамнан тыш, икеләтә артыграк хезмәт хакы да тәэмин итә бит! Үтә хәйләкәр, үз эченә бикләнгән Хәйруллин, аспирантурада йөреп карап, үзеннән фән әһеле чыкмасын вакытында аңлап, түләүле һәм мактаулы иҗтимагый эшкә күчә. Марксизм-ленинизмның горком каршындагы кичке университеты ректоры булу аңа тормышын шактый җайлап җибәрергә мөмкинлек бирә. Бөтен Алабугасына ике генә ректор!

Тормыш тәҗрибәсе, сизгерлек Сәхибуллинны исә җайлы гына тема ярларына алып чыга: фәлән-фәлән елларда КПСС аграр политикасының Идел буе авыл хуҗалыгын күтәрүгә керткән өлеше турында.

Эш ифрат җайлы гына барганда, ике уңайсызлык килеп чыкмасынмы! Берсе чит телдән имтихан тапшыру. Ул беркайчан да бернинди тел өйрәнмәгән, әлифне таяк дип тә белми, теләсә кайсы тел аның өчен шүрәлеләр яши торган кара урман-чытырман, ә инде мөстәкыйль үзләштерү турында сүз дә була алмый. Димәк, корабка зарар китерми генә, бу «айсберг»ны әйләнеп үтәргә кирәк. Усал телләр аның шул чордагы идеология хуҗасы Сусловның кабул итү бүлмәсендә айдан артык ятуы

турында сөйләнделәр. Ничек булганын алла гына белә, һәрхәлдә, чит телдән имтихан бирмәве яклау өчен киртә тудырмады.

Икенче кыенлыгы житдирәк иде шул. Сәхибуллин әфәнде диссертациясен якларга өлгерә алмый калды, кешегә ышанучан Хрущевны яраннары бәреп чыгардылар. Йөз алтмыш битлек әлеге диссертациянең исә алтмыш битеннән артыграгын кадерле Никита Сергеевичтан алынган сылтамалар, өзекләр, мәдхияләр тәшкил итә. Шуларны башка чыганакларга алыштырырга туры килде аңа. «Хрущев»ны — Ленинга, «Пленум» сүзен «съезд»га әйләндерә-әйләндерә шактый чиләнә ул. Әмма инде, кандидат һәм доцент кенәгәләрен кесәгә салгач, фәннен «ф» хәрефен дә ишетергә теләмәде Әхәт Сәхибуллович.

Шулай итеп, ике дусның берсе университет ректоры, икенчесе фәннәр кандидаты булып алды. Әлбәттә, аларга да майлы ботка күктән төшеп, өстәлгә килеп утырмый. Адымны алдан уйлап, һәр хәрәкәтне партия карарларына турылап, үзара киңәшеп эшлиләр. Иң элек алар теләсә нинди жыелышның президиумын бизәү жаен табалар. Берсендә Хәйруллин Сәхибуллинны тәкъдим итә, икенче жыелыш башында нәкъ киресе эшләнә. Әйткәнебезчә, Хәйруллин икенче кеше булып сүз ала, гадәттә: «Мин тагын бер кат экономик белемнәрне фәнни пропагандалау файдасына басым ясарга мәжбүрмен. Империалистик милитаризмның һөжүмчән хәрәкәте көчәйгән дәвердә һәр кеше «экономиканың экономияле булырга тиешлеген» аңлап яшәргә тиеш. Бу — буш һәм матур сүз генә түгел.»

Биттә бер мускул да хәрәкәткә килми, ике олы йодрык өстәл өстенә нык итеп куелган.

— Кичә кич икенче каттагы аудитория яныннан узам, сәгать алтылар тирәсе. Утлар балкып яна, лаборантның исе дә, эзе дә суынган. Эзләп киттем, күрше бүлмәдә яулык чигеп утыралар.

Алдан килешеп куелганча, урыннан берсе реплика ташлый:

— Ул бит сезнең политэкономия кабинеты.

— Шул, шул. Мин хәзер халык байлыгын саклауда өлкәннәрнең бурычын яктыртуга күчәм. Үземә дә тәнкыйть булачак...

Рәислек итүче, чыгыш ясаучыларның алдан әзерләнеп куелган исемлеген тәмамлап, жыелышны ябып куярга ниятли. Ләкин барып чыкмый. Өченче рәттән сөйли-сөйли килә Сәхибуллин президиум өстәле янына. Соңгы кеше булып сүз алуының да мәгънәсе бар: жыелышка бәя бирү, мөһер сугу һәм үзенә чаклы чыгыш ясаучылар арасында лаеклы урын алу.

Соңрак, үзе теләмәсә дә, аны трибунага күтәрмичә калдырмый башладылар. Ректорга «оппозиция» алдан ук аның янына үзенең бер вәкилен утырта һәм кирәкле фикер, тәнкыйть сүзләре белән коралландыра иде.

Сәхибуллинның чыгышы гадәттә өч кисәктән тора: алдан жыелышка мөнәсәбәтен ачыклый, аннан бүген макталган кешегә бәйләнә, соныннан, конъюнктурага карап, йә уңай, йә тискәре нәтижә ясый. Олы гәүдәсе фикерләү рәвешенә килешеп тора.

— Мин чыгыш ясау теләге белән килмәдем бүгенге жыелышка. Доклад ошады. Карап торам: мәсьәләне чын-чынлап тикшерү юк. Кеше космоска чыгу, генетиканың серләрен ачу заманында мактанышып утыру килешми. Карагыз, түшәм ага, актлар залының акшары коела, ректор хужалык бүлеген эшләтми, яклый... Кул кулны юа. Хәйруллин үзе дә изге кеше түгел, тик бүген дөресен ярып салды, институтта утлар сүндерелми, кешеләр урында утырмый... Горкомга тапшырыгыз, безгә газеталар өченче көнне генә килеп житә, нәрсәгә безгә ул макулатура. Без, марксизм-ленинизм укытучылары, тормышның алгы сафында барырга тиешбез... Жыелыш әзерләнмәгән, тәкъдимнәр уйланылмаган, болай ярамый, иптәшләр...

Алар катнашмаган, чыгыш ясамаган жыелыш «булдыга» саналмый.

Икенче көнне үк горкомда тавыш чыга: «институтта коммунистларны чакырмыйча, яисә алар өйдә юклыктан, чирләүдән файдаланып, яшерен җыелышлар уздырып яталар. Чик куелырга вакыт мондый башбаштаклыкка».

Сан ягыннан институтта коммунистлар аз, җәмәгать эшенә ашкынып торучылары тагын да санаулы булу сәбәпле, уртак язмыш соңчиккәчә якынлаштырган ике дус, күп еллар дәвамында берсе икенчесен алыштыра-алыштыра, партбюроны җитәклиләр, һич югында алмаштилмәш идеология буенча секретарь ярдәмчесе вазифаларын үтиләр. Башка кеше аяк терәп каршы килгәндә, ахириләр тыйнак кына, «безнең тәҗрибәбез үзебездә генә ятмасын, халыкка әйләнеп кайтсын», дип сөйләнә-сөйләнә, әлбәттә, аз-маз ялындырган булып, үзләре өчен ифрат файдалы шартлар куеп, ризалык бирәләр. Торгынлык заманында партбюро ректорның аяк-кулын бәйләүче зур көч иде.

Табигый ки, Сәхибуллин үзен сайламаган советны, андагы уенны оныта да, гафу итә дә алмый. Ректор-ханым туктаусыз эзәрлекләүгә, партия исеменнән алып барылган тәнкыйтькә, тавышка түзә алмыйча, Татарстаннан ук чыгып китә. Аны алыштырган Е. Тихонов та, дүрт елын да тутыра алмыйча, чирләп, кире Казанга кайта. Соңрак бу хезмәтне башкарган кешеләрнең кәефләрен һәм биографияләрен бозуга «игезәкләр» шактый өлеш керттеләр.

Бу конфликтларның төбендә идеологик, сәяси килешмәү, укыту методлары өчен бәхәсләшү ятса, бер хәл иде. Һәр яңа хуҗа белән бозылышуның сәбәбе артык дөньяви, тупас реалистик нәрсәләр иде. Туксан тугыз тапкыр яхшылык эшләп тә Сәхибуллин белән Хәйруллинның берәр таләбен канәгатьләндерә алмаса, ректор шунда ук, «дошман лагерына» күчерелә. Усал хәтер яхшылыкны тиз онытучан.

Сорау тууы мөмкин. Институт җитәкчеләренең еш алышынуында ике марксистның ролен күпертебрәк күрсәтү юкмы? Алар һәрнәрсәне булдырырдай көчле шәхесләрмени?

Безнең җәмгыятебезгә эш яратмаган, әмма партия исеменнән китап сүзе сөйләп, демагогия белән шөгыльләнеп, үзләренә тыныч һәм рәхәт тормыш тәэмин итә белгән әрсез кешеләр зур зыян китерделәр. М. Булгаков каләме тудырган Шариков-Швондерлар гына түгел алар. Калканнары шул ук ике төр тимердән — наданлыктан һәм «сыйнфый сизгерлектән» ясалган булса да.

Үз-үзләрен тоту рәвешләре, тормыш ләззәтләренә мөнәсәбәттә иҗтимагый фәннәр укытучылары партаппаратка якын торалар. Аларның күбесен хакыйкать әхлакый категория буларак борчымый, ялган һәм алдау белән томаланган намуслары, мукле йөрәкләре туктаусыз ялда.

Бу «горурлык» аларның шәхси сыйфаты түгел, ә безнең тоталитар режим бәйгесендә иҗтимагый фәннәр укытучылары тоткан аерым урыннан килә. Әйтерсең лә алар — партиянең халык арасына чыккан фәрештәләре. Әлеге фән әһелләренә җил-яңгыр тидерү тыела иде. Аларның йөреше, җилкә сикертүе, арканы туры тотуы, күз карашы, кул белән һаваны кисүе үк үзгә, бөтенләй башкача.

Горький 1919 елда, большевикларга оппозициядә торганда: «һавалы наданлык — иң куркыныч нәрсәләрнең берсе»,— дигән һәм властька килгән кешеләр арасында шуның ялгыларын күреп ачынган.

Иҗтимагый фән әһелләре арасында коммунистик якты киләчәк, шәхес иреге, хокукый азатлык, бәхетле балачак, халыклар тигезлеге кебек гыйбарәләргә чын күңелдән ышанып йөргәннәре дә булгандыр, әлбәттә. Шулай да андыйлар азчылык дип уйлыйм. Чөнки марксист дигән затның башкача уйларга, шикләнергә, «үзеннән өлеш» кертергә хакы юк иде. Ул шул хәленә өйрәнә, күнегә, буыннары, фикерләре бер юнәлештә катып кала.

Дөньяның иң кешелексез җәмгыятен аклау, хокуксыз халыкны алдау өчен дөньяда бер яктан да тиңе булмаган идеологик армия тотты

партия. Үз мәнфәгатьләре өчен фиркабыз беркайчан да мал җәлләп, вакланып маташмады.

Хәзер иҗтимагый фәннәр укытучыларына авыр көннәр килде. Марксизм-ленинизм гыйлеме, янартып кору таләпләренә буйсынып, йөзен, исемен үзгәртү белән мәшгуль. Кызганычка каршы, асылы, җисеме әлегә шул ук кала килә.

Сәхибуллин белән Хәйруллин һәр адымда партияне яратырга, Ленин идеалларына тугрылыклы булырга өндәп яшәсәләр дә, үзләре тормыш бирә алган бер генә гамәли сөенечтән дә йөз чөермәделәр. Аларның мәчеләре дә куян тота. Әйтик, «Жигули» машиналары халыкка сатыла башлауга, аның Алабуга исемле матур калада тукталыш ясаган беренче данәләре үк марксизм укытучыларының җылы кулына килеп керде. Бирмичә кара аларга, «йолкынган йонын» Магаданга очып барып житәр! Гуманистик хис, ни әйтсән дә, пропагандистларның умыртка сөягендә шул. Машиналарны сорап йөдәткән кара, сары, шома ир-егетләрне кызганып, сатып та җибәрделәр. Читкә киткән беренче машинаны икенчесе, өченчесе алыштыра, әр-яңа «Волга» гараж бусагасын әкрен генә үтеп, эчкә уза. Квартира мәсьәләсе дә туктаусыз көн тәртибендә торып, әйбәттән яхшыга әйләнә тора. Искеләренә бала-чага, туган-тумача урнаша килә.

Берәү дә алар белән низагъка керен, кәефен бозып торырга теләми. Хикмәт куркуда түгел, сак кеше явыз этне котыртмауны мәгъкульрәк күрә. Алабуга педагогия институтына дәүләт комиссиясе рәисе итеп чакырылган мөхтәрәм галим Әбрар Кәримуллин исә үзен башкачарак тота.

Фронтта булу, яшьләре бер тирәдә булу Казан кешесе белән Сәхибуллинны бер мәлгә якынлаштырып куя. Әбрар ага кордашына дистә еллар буена дөнья күрә алмыйча яткан, татар халкының килеп чыгышына багышланган кульязмасын укыта, соңгы сугыш турында сүз чыккач та бер үпкәсен әйтеп сала: «Геройлыклар күбрәк очучыларга һәм танышбелешкә бирелде, ә бездәй авыл малайларына, окопны борының белән казып, ут астында күпме калсаң да, зур бүләкләр тәтемәде»,— ди.

Кинәт кабынган дуслык, көтмәгәндә дошманлыкка әверелә. Сәхибуллин имтихан барышында студентларга: «Кызым, әтиең кая эшли», «Улым, әниең нинди хезмәт башкара», ә инде техник фәннәр һәм хезмәт факультетының читтән торып укучысы эләксә, «Жигули»га көпчәк юнәтеп, двигательне ремонтка куеп булмасмы, кебек «марксистик-ленинчыл» сорауларны күп бирергә яратучан. Алабуга укытучылары аның бу «сәерлекләренә» күнеккән, игътибар да итми. Туры һәм кырыс, үҗәт рәис исә мондый әрсезлеге өчен имтихан алучыны бер кисәтә, ике әйтә, файдасы тимәгәч, «фронтовик дустын» аудиториядән үк куып чыгара.

Соңгысы кыза, туарыла: ничек инде ул кафедра мөдирен, шундый олы кешене, аның үз фәненә имтиханга кертмәскә мөмкин!? Институт җитәкчелегендә дә яклау тапмагач, Казан галименең әхлакый йөзен фаш итеп, Бөек Ватан сугышына начар мөнәсәбәтен, «үзнәшер» китапларын теләсә кемгә укытып йөрүен бәян кылып, өлкә комитетына хат илтеп тапшыра. Соңгысы диссидентлар рәтендә үк йөрмәсә дә, рәсми идеологлар өнәп бетермәгән үзсүзле шәхесләренең берсе санала. Сөйләшү-аңлашулар кырыс була. Шуннан соң профессор йөрәк авыруы белән шактый вакыт шифаханәдә ятып чыкты. Чынлыкта бу конфликтның нигезе тирәндәрәк. Үзе белемсез кеше зыялы, үзфикерле, кыю шәхесләрне яратмый, җаны-тәне белән күрә алмый.

Хәзер бөтен ил үзгәртеп кору, коллык психологиясен корыту, сталинизм режимын янача, демократик мөнәсәбәтләр белән алыштыру өчен көрәшә. Иҗтимагый фәннәр укытучылары һәрвакыт тормышның алгы сызыгында булды, дибез. Һәрхәлдә, алар үзләре шулай кабатларга яраталар иде. Сәхибуллин белән Хәйруллинның янартып коруга мөнәсәбәтләре ничегрәк булды дигән сорау туу табигый. Алар бертавыштан:

— Без инде күптәннән яңача, үзгәреш рухында яшибез,— дип җавап бирерләр дип уйлыйм. Югалып кала торган түгелләр. Шулай да кеше, өч кат «марксист» булса да, олы дөнья җилләреннән качып котыла алмый.

Хәйруллинның холкы күзгә күренеп бозылды. Бергә эшләүче иптәшләре, коллегалары белән чәбәләнеп, ямьсезләнеп, мөнәсәбәтне горком, прокуратура аша ачыклауга җиткереп, шәһәр һәм институт җитәкчелеге белән арасын бозып бетергәч, пенсиягә чыгып, квартирасына чаклы алыштырып, Түбән Камага күчеп китәргә мәҗбүр була.

«Ә Сәхибуллинның хәлләре ничек? — дип сорарсыз инде, табигый ки. Студентларга ул хәзер яраткан сорауларын азрак бирә, ди. Кешегә беркая да тынычлык юк. Усал телләр аның турында «күптән түгел Сталин редакциясендә чыккан «Кыскача курс»ны шыпырт кына төпләтеп алган» дигән хәбәр таратып йөриләр, ди. Төпләтсә ни, һәркемнең яраткан китабы була.

## Җыелыштан соң яздым

*Сөекле яр ярын сатты,*
*Кадерле дус дусын сатты.*
*Һәм күңелдә йомарланып,*
*«Шөбһә» дигән елан ятты.*
*(Гамил Афзал)*

Гарьләнү, рәнҗүле хәтер күңелне ярсытып, йөрәкне уч төбендәге мәхбүс кошчыктай сикертеп торса да, йөрәк төшенкелеккә бирелмәде, инсаният барыбер биниһая матур, дәү төсләргә бай, күңелле иде. Сырт сынса да, сер бирәсе килми.

Мин үзем белән булган хәлләрне кемнеңдер явыз, усал ихтыярына гына кайтарып калдырырга җыенмыйм. Без, һәммәбез, шул исәптән партаппарат кешеләре дә — рухи наданлыгыбыз, тарлыгыбыз, яхшыны күрмәвебез нәтиҗәсендә төзелгән тоталитар җәмгыять коллары, шуның кибешкән җимешләре.

Җыелыштан соң явызлык, усаллык, үчлек кебек төшенчәләрнең нигезләре турында чигәләрем чатнап, кан тамырларым кызыл чөгендер төсенә кергәнче уйландым. Явызлык белән көрәшү, аны юкка чыгару әмәлләрен тапмасам да (аларны тәгаен берәү дә белмидер), мин аның кайбер «серләренә» төшендем бугай.

Иң әүвәл бер парадокс күзгә ташлана. Явызлык белән кешелеклелек төрле кыйблаларда яткан төшенчәләр кебек күренсәләр дә, алар кайсыдыр нокталарда үзара кисешеп, хәтта якынлашып та китәләр икән. Икесенең дә төбендә әхлакка яисә әхлаксызлыкка корылган күзаллаулар, дөньяны үзенчә кабул итүләр, бәяләмәләр ята. Шулай ук усаллык — кешелеклелеккә, әшәкелек шәфкатьлелеккә караганда көчлерәк. Бигрәк тә безнең хокуксыз җәмгыять шартларында. Аннан соң беренчеләрнең хәрәкәт ысуллары, «эш алымнары» ифрат төрле, гади акыл аларны кабул итеп түгел, тәфсилләп аңлап, бәяләп тә җиткерә алмый.

Явызлык үзенә ышанган кешеләрне тәсбих дисбесе кебек бер җепкә тезә, уйланган эшнең ахырына җитмичә, бокрадан чыгармый. Аңлатуы кыен булган сихри көч, усал ният төрле-төрле кешеләрне уртак максат юлына алып чыга. Аларны якынлаштырган императив дөресме, ялганмы, илнең экономик көче үсүгә, милли аң дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итәме-юкмы — ул яклар исәп-хисапка алынмый. Ихтыяр бердәмлеге аларны алга әйди, каядыр, кем беләндер көрәшкә, тартышка чакыра. Араларны аныклау, көрәш чараларын сайлап торыш юк. Шикаять хат, аноним телефон хәбәре, имеш-мимеш, гайбәт, колактан-колакка сер әйтү кебек алымнарның һәммәсе дошмани объектка черки тешләве тикле генә

булса да, әхлакый борчылу, физик унайсызлык тудыра алса, «орден әгъзалары» тарафыннан хуплана, яхшы, файдалы табыла. Бу вакытлы берлек кайчакта дуслыктан көчлерәк булып чыга. Җиңелгәндә дә, агулы угын кадап, пычрак эшен башкарып өлгерә әлеге көч.

Ахыр чиктә, явызлык җиңелә килә. Кешелек тарихы шуның шаһиты. Тираннар үз вакытлары белән үлеп, гильотинаны ремонтлаган арада гына булса да, халык яшәп, иркен сулап кала.

Әмма явызлык агуын, җан җәрәхәтен дәваларга еллар кирәк. Җәмгыятькә тиенлек файда китермичә, хакыйкать турында чат саен сафсата саткан саламторханнар белән көч алышуга күпме хәләл көч сарыф ителә, күпме изге җаннар юкка чыга.

Торгынлык елларында миңа ифрат караңгы чырайлы мәзәк сөйләделәр. Нахак гаепне, рәнҗетүне күтәрә алмаган берәү, фани дөньяны ташлап киткәннән соң, аклана. Кабере өстенә шундый язулы таш куялар: «Тыныч йокла, фактлар расланмады».

Кемдер йоклый алмаудан зарланса, ышанмый идем. Безнең җәмгыять булдыра алмаган нәрсә юк икән, мин дә ул халәтнең «тәмен» татый башладым. Әмма үчле кешеләр күпме генә тырышып карасалар да, эш «йөрәк тоту»га ук барып җитмәде, «явыз берлек» каядыр хата җибәрде булса кирәк. Әмма аяксыз калып, ярты еллап шифаханәдә аунарга туры килде.

Безнең илдә кеше, алдынгы милләтләр белән чагыштырганда, 15—20 елга азрак яши. Хуш, шуның биш елын ашау-эчү тәртибе булмауга, аракы, тәмәке кебек зәхмәтләргә кайтарып калдырыйк. Ә башка еллар кая югала, кайларда «эри»? Минемчә, бездә психологик халәтнең киеренке булуы, парткомиссия, халык контроле, хокук оешмалары изүе, кирәкмәгән җыелышлар, тикшерүләр, шикаять хатларны күпертү, куркыту-өркетүләр, иртәгесе көненә сукыр бер тиенлек ышаныч булмау, шәфкатьсезлек, миһербансызлык, имансызлык, гомер-гомергә рухи таяныч булып торган диннән бизү адәм гомеренең зур өлешен алып китә. Кешенең нервысы соң чиккәчә тартылган, ул шартлап үзелергә генә тора.

«Тормыш ул — көрәш», дигән әйтем дә башка илдә туа алмас иде. Тормыш шатлык, ләззәт, бәхет, сөенеч булырга тиеш югыйсә. Шул ук вакытта без яши дә белмибез. Иң камил, алдынгы конституциягә, нык үскән социализмга ышанып, гап-гади көрәшкә дә өйрәнмәгәнбез. Кәүсәне аз-маз селкетү белән, көзге өлгергән чикләвек төсле, шыбырдап җиргә коелабыз.

Алабугада «йөзек кашы» булып, озаграк күгәреп яттым тыйнаксызланып. Көнчелек хисе күпләрдә җыела, сумала кебек кайный торган. Әнә бит Америкада президент хәтле президентны дүрт елдан, бик яхшы эшләсә дә, сигез елдан артык тотмыйлар. Чөнки халык берүк йөзне күреп туя, арый, икенче яктан, шул вакыт аралыгында шәхес эчке мөмкинлекләрен ачып сала да, аннан кабатлана башлый. Советлар илен бетмәс-төкәнмәс фаҗигаларга алып килгән сәбәпләрнең берсе — җитәкчеләрнең сайланып куелмавы һәм үлгәнче утыруы.

Унбиш ел ректор булып эшләү артык күп, иртәрәк кузгаласы булган Казан тарафларына да, язмыштан узмыш юк икән. Бу эштә шулай озаклаган кешене Алабуга пединститутының кырыс тарихы хәтерләми. Петрова К. П. дигән ханым гына җиде елга якын утыра алган ректор бүлмәсендә, башкалары бер, ике, өч, дүрт ел... Бу оешма исәбендә тагын шундый начар йола бар. Коллектив бер хуҗасын да яхшы итеп, олылап, рәхмәтләп, саубуллашуларын сагынып сөйләрлек итеп озата алмады. Нигә без шулай бер-беребезне кадерсезлибез, рәнҗетәбез, кеше гомере болай да төш кебек кыска бит, дип уйлап куясың.

Авыр мизгелләрдә кешеләр ахыргача, йозаксыз сандык төсле ачыла да куя икән. Берәүсе килеп хәл белешә, икенчесе, горком кешеләре читтәрәк чакта, шыпырт кына, җыелышта тәрәзәдән күгәрченнәр үбешкәнне карап утырган дуслар шикелле, беләкне кысып үтә, өченчесе күз-

ләрен яшерә... Соңгысы йә мине гаепләгәндер, йә җәмгыятебез өчен оялгандыр. Кеше күңеле — төпсез кое.

Алабугада миңа мөнәсәбәтнең киеренке һәм «үзенчә» икәнлеге һәр адымда сизелеп тора башлады. СССР Язучыларының VIII съездында Татарстан вәкилләре арасында мин дә бар идем. Кызык кына җыен булды ул. Президиумда яңартып коруны башлаган Горбачев утыра, ә язучылар форумының агышында ул нәрсә сизелми, шул ук «әдәби генераллар» бер-берсен мактап, сыйпап, сүз бирешеп әвәрә киләләр, җитәкчелеккә шулар ук сайлана.

Мәскәүдән кайткач, җирле гәзит «Новая Кама»ның абруйлы хәбәрчесе М. Караваева миннән интервью алды. Андый олы җыелышка Алабугадан делегат беркайчан сайланмаган, үзенә күрә бер вакыйга һәм укучылар күңелендә калырлык булсын, дип, үземчә, съездның рухын, торгынлыктан чыгу авырлыкларын, язучы халкына хас низагъларны ачарга тырыштым. Сез инде, әлбәттә, сүз әлеге мәкаләне бераз кыскарту, сипләү турында баргандыр дип уйлыйсыздыр. Юк шул, «Новая Кама» доктор, профессор, СССР Язучылары берлеге әгъзасы дәрәҗәсенә «төшмәде».

Шәхсән, миндә рус совет әдәбияты курсы тыңлаган, шәһәрнең идеология башлыгы Долорес Галләмова: «Мин белештем, материал яхшы, урын җитми, уборка вакыты бит, тиздән чыгачак»,— дип, кат-кат ышандырды. Үзен тыңламадылармы, аппарат уенының бер затсыз алымы булдымы, өздереп әйтә алмыйм. Мәкалә басылмый калды.

Мондый хәлләр ешайды. Кешене ахыргача бөгүнең алымнары бихисап күп. Әйтик, Алабугада, яхшымы-яманмы, ректор берәү генә. Аңа демонстрация уза торган мәйданга керү өчен бирелә торган пропуск җибәрмәү, тантаналы җыелыш президиумына аның урынына берәр мәктәп директорын утырту, институт мәсьәләләрен калкытып куюю өчен трибунага чыгармау, яңа өйне оешмаларга бүлгәләгәндә, институтны «онытып» калдыру, гадәттә аңа бирелә торган ике фатирны, шәһәргә файдасы зуррак, дигән сылтау белән башкаларга бирү, укытучыларга телефон куйдырмау, хәтта партиягә керергә теләүчеләргә урын «тапмау» һәм башка шундый алымнар — барысы да эшкә җигелде. Партаппаратка «ялгышкан» кешеләр кирәк түгел икән.

Кемдер, бәлки, бу тикшерүләрнең, кысуларның институтка, димәк ки, дәүләткә файдасы булды, дип уйлагандыр шул чорда. Нәтиҗә бөтенләй көтелмәгәнчә булды: элеккеге дус, шәфкатьле, игелекле, шатлыгын, кайгысын бергә уртаклашкан, казарма социализмы шартларында мөмкин кадәр бердәм яшәгән коллектив эреде, юкка чыкты. Кешеләр бер-берсенә ышанмый башлады. Әхлакый нигезләр белән санашу бетте. Парткомиссия һәм горком «тырышлыгы» ярдәмендә Алабуга педагогия институты «митинговый» халәткә иртәрәк килеп керде. Олыга — сан, кечегә кадер бетте.

Җыелыш һәм парткомиссия рухыннан тиз генә арынып булмасын мин соңрак, инде берничә ел Казанда, университетта эшләү дәверендә төшендем. Бер гыйбрәтле вакыйганы искә төшереп үтәсем килә.

1990 елның язгы көннәрендә өйдә телефон шалтырады. Авторы Мөхәммәт Мәһдиев булып чыкты. Хатыннар, балалар эшкә, укуга, базарга таралышкач, телефоннан бер сөйләшеп ала, хәл-әхвәл сораштыра, университетта кемнең кайчан дәресе барлыгын ачыклап куя торган гадәтебез бар иде. Мин озын-озак сөйләшүгә әзерләнеп, кечкенә урындыкны телефон янынарак тартып куйдым. Әмма мин көткәнчә булмады.

— Тәлгат, сәлам, сәлам. Безгә тиз күрешеп алырга кирәк. Кызыклы гына хәбәр бар миндә. Сиңа карый торган.

— Нәрсә булды?

— Телефоннан сөйләшә торган сүз түгел. Эшкә барышлый өйгә сугыл әле.

Юк кына вакыйгага да зур әһәмият, яңгыраш, уйламаган төсмер

бирергә, шуның өстенә серлелек томаны җибәрергә яратканын белә идем Мәһдиевнең. Иҗатында да, яшәешендә дә ул бер үк. Бүген тавышында уен, кылану сизелмәде. Интонациядә ниндидер эчке-борчылу, дулкынлану бар иде. Минем «телефоннан гына әйтмисенме» дигән сүзне кешегә дә санамыйча, коры чыбык сындырган төсле генә, кырт кисте:

— Ярамый. Минем телефон тыңлана. Үзең чамаларга тиеш.

Әдәби персонажлары шикелле үк, табигать баласы Мәһдиевнең үпкәне дә, ачуны да, серне дә эчендә озак саклый алмаганын тәгаен беләм. Яңалыкны вакытында әйтмичә, эчендә озак тотса, мишәр әйтмешли, аның микъдары кәми, чирли башлый. Хәбәр бик житди булмаса, ул аның бер очын уйлана торырга миңа тоттырган булыр иде тимер чыбык аша. Димәк, дөньялар тыныч түгел...

Ярты сәгатьтән мин Мәһдиевнең бер кеше генә сыешлы тар коридорлы, лилипутлар өчен дә кечкенә уенчык кухнялы, тыйнак, әмма жанга рәхәт фатирында идем. Ишек йозакларының биген кат-кат тикшереп, форточкалардан ераграк жиргә утырткач (салкын тиюдән курку хикмәте түгел, озын колаклар ишетмәсен), сүзен куллары белән раслый-дәлилли барып, сөйләп китте.

— Миңа бүген сине яраткан бер районнан звонок булды. Үземдә укыган, жаваплы урында утыручы егет. «Галиуллин дигән кешене яхшы беләсезме? Сез бер факультетта эшлисез бугай»,— ди.

— Мәнә дигән, ышанычлы мишәр дип, кыска гына җавап бирдем. Әле эшнең нәрсәдә икәнен белмим.

— Алабугадан Казанга ничегрәк кайтты?

— Минемчә, нормально кайтты. Анда инде озак эшләдең, житте, башкаларга да үзләрен күрсәтергә мөмкинлек бирик дип, Казанга күчердек.

— Без аны безнең районнан депутатлыкка кандидат итеп тәкъдим итәргә уйлыйбыз. Аны белгән, аңарда укыган кешеләр район мәгарифендә күп икән. Иптәшләр белән тагын бер киңәшкәч, мин сезгә хәбәр бирермен,— дип бик җылы саубуллашты.

Яз сулары акты, умырзая гомере узды, талонлы май житте, әлеге сөйләшүнең эзе коры комдагы су төсле югалды. Мәһдиев тә шактый вакыт узып, «микъдары кәми» башлагач кына, серне чишеп салды. Сер юк иде, үз илендә һәркем пәйгамбәр, дигәндәй, нәкъ мин фараз кылганча булып чыкты барысы да.

— Сөйләшү булды укучым белән. Район риза иде, ди. Тик үзәк аппараттан башка кешене китереп кыстырдылар ул урынга, альтернатив кандидатура йә тракторчы (салгалый торган), йә сыер савучы (бик өлкән яшьтәге) булырга тиеш, дигәннәр. Аннан соң, Галиуллинның Алабугада ректор булып эшләгәндә нәрсәдер булган, дип берничә жирдән хәбәр биргәннәр. Дипломнар сату белән бәйләме, ди шунда. Беренче секретарь чагында Усманов та кайсыдыр газеталамы, журналдамы аны тәнкыйтьләп чыккан булган, Рәис Беляевның якын дусты да диләр аны, ди...

Бу вакыйга тагын бер кат жәмгыятебезне, ижтимагый фикер үсешен сынарга мөмкинлек бирде. «Дуслар» йокламый, нәкъ вакытында яңгырын да яудырып, кояшын да чыгарып, кирәкле хәбәрне, тиешле колакка ирештереп торалар икән һаман да, яңартып кору жилләре үтәдән-үтә исеп яткан заманда да. Кешене юлдан алып ташлауның сыналган алымы. Беркем бер нәрсә өчен дә жавап та бирми. Хәер, әллә ни исем китмәде, мондый борылышларны газиз башкаем күп күргән, иншалла, соңгысы да булмас. Шундыйрак хәлгә юлыккан мәктәп директоры хакындагы хикәят искә төште. Жәтмәгә эләккән балык хәлендә калуның классик бер мисалы.

Бер мәзәкне жае чыккан саен, ә ул һәркемнең тормышында булып кына тора, усал көлүсез, елмаеп искә төшереп ала торган идек дуслар белән очрашканда. Мәктәп директоры зур авырлык белән, бер укучысының атасымы, анасымы аша үзенә затлы бүрек юната. Аракыга каршы

указ чыккан мәл, бүрекне «юып» булмый. Шулай да юанычны болай калдырырга да ярамый. Директор, хатынын җитәкләп, татар театрының яңа спектакленә бара. Бүрекне назлап-сыйпап, иркәләп кенә гардеробка тапшыра. Спектакльнең эчтәлеге һич кенә дә башка керми, уйда — гел бүрек! Вешалкага директор беренчеләрдән булып йөгереп килеп, йөзенә матур елмаю чыгарып, саннары язылган тимерләрне өлкән яшьтәге апага суза. Ханым пальтоны китерә, ә икенче кулы буш. Берәр ришвәтле хезмәттә эшләсә, әтисе мирас калдырган булса, ахыр чиктә, бүреген кешегә ялынмыйча гына кибеттән сатып алырлык булса, шаулап тормас иде дә, хәләл акчага алган бүреген кызганып, укытучы тавыш чыгара. Милиция килә, шаһитлар чакырыла, халык җыела, протокол төзелә, куллар куела. Табылырлык булса, урлап та тормыйлар инде аны. Өч айлап арлы-бирле йөртә торгач (милициягә, театрга чакыралар, мәктәпкә иске кәгазе килә һ. б.), үз бүреген кире сораганына чын-чынлап үкенә башлагач, исемен тәмам пычратып бетергәч, дәгъвачыга күпмедер акча түлиләр.

Янә берничә арзанлы бүрек туздыргач, әлеге директорны райком аппаратына күчерү турында сүз куертыла. Яшь, хезмәт ярата, мәктәпне кулда тота, эчми, гаиләсендә тәртип, нәкъ менә коеп куйган идеология бүлеге кешесе. Хуш, мәсьәлә хәл ителеп җитте дигәндә генә, бюро әгъзаларыннан берсе, ике бармак киңлегендәге маңгаен җыерып, сүз сорый:

— Без бу иптәш белән ашыкмыйбызмы икән? Мин үзем бу хәлнең шаһиты булмадым. Илләм бик ышанычлы кешенең, шул ук даирәдән, аның татар театрында коточкыч җәнҗал күтәрүе хакында бәйнә-бәйнә сөйләгәне хәтердә. Кемнеңдер кыйммәтле бүреген урлапмы, алыштырыпмы тотылып, милиция килеп, тавыш чыгып, протоколлар төзүгә чаклы барып җиткән эш...

Шундый хәбәрдән соң, эш аның файдасына хәл ителмәгәнлеге аңлашылса булыр. Тикшереп, кызыксынып торуның берәүгә дә хаҗәте юк. Бернәрсә бәхәссез: әлеге уйдырма аның артыннан гомере буена, озын шлейф төсле, сузылачак. Эз калдырып...

Безнең җәмгыятьтә төрмәдән чыккан кеше, мафия әгъзасы, ата карак акланырга, дәрәҗәле урынга утырырга мөмкин. Ә менә имеш-мимеш, гайбәт, шикаять хатлар белән пычратылган кешегә кыенрак. Ул гомерен суга төшеп җитә алмаган буш кое чиләге төсле шалтырап үткәрергә дә мөмкин. Үзебез төзегән җәмгыять, үпкәләр урыныбыз да юк.

*1990—1991 еллар.*

# ТАБОРДА — УЧАК ЯНЫНДА...

*Якын араларда Татарстан китап нәшрияты «Чегән әкиятләре» дигән яңа китап бастырып чыгарачак. Аны* **Марс ШАБАЕВ** *тәрҗемәләгән. Без сезгә шул китапның кереш сүзен һәм чегән әкиятләреннән ул китапка керми калган ике үрнәк тәкъдим итәбез.*

Чегәннәр...
Ирекле рухлы, горур табигатьле хөр халык...
Бүгенге көнгә кадәр күчмә тормыштан ваз кичеп бетмәгән төрле-төрле ыру-кабиләләр... Җир шарында алар аяк басмаган, алар яшәмәгән ил-төбәк юк. Чегәннәрне белмәгән-күрмәгән, үз гомерендә бер генә тапкыр булса да очратмаган кеше бармы икән? Чегән хатын-кызлары катлы-катлы кәбестә шикелле киенгән, кулына баласын күтәргән, тагын берәрсен ияртkән булыр. Алар йөреп чыкмаган авыл-кала, алар шакымаган ишек табылырмы икән? Чәүкәләр кебек чәнгелдек тавышлы, кара чутырдай чегән балаларына уралып, күпсанлы төенчекләре, чүпрәк-чапраклары арасында оясындагы ана каздай утыручы чегән хатыннары вокзал-аэропорт тирәләрендә еш очрый хәзер. Базар-кибет алларында алыпсатарлык итүчеләрен хәтта милиция дә әйләнеп үтәргә тырыша. Ә менә ни хикмәттер, чегән ир-атлары алай күзгә бәрелеп тормыйлар, сирәгрәк күренәләр. Хатын-кызларның, бала-чагаларның тормышы безнең күз алдында шикелле тоелса, ир-атларның кайда, ни-нәрсә эшләп йөргәннәре бөтенләй диярлек билгесез.

Элегрәк елларда, без үскәндә чегән таборлары Ык, Агыйдел, Чулман буе болыннарында, чатырлар корып, озаклап урнашып җәй үткәрә торган иделәр. Без — үсмер малайлар — кичләрен Ыкның биек уң як ярыннан аргы якта — болында янган чегән учакларына сихерләнеп карап тора идек, болын-сулар аша яңгырап ишетелгән, безгә җиде ят булган чегән җырларын әсәрләнеп тыңлый идек. Хәзер инде ул болыннар өстендә дулкыннар гына йөгерешә... Түбән Кама ГЭСы төзелгәч, безнең яшьлектәге истәлекле ул болыннарыбыз белән бергә, чегәннәрнең учак ялкыннарын да, аларның моңлы җырларын да су ялмап йотты... Әмма күңел түрендә чегән халкы һаман да серле-сихри бер халык булып яши бирә.

Чегәннәр чыгышлары белән ерак Һиндстаннан. Фирдәүсинең атаклы «Шаһнамә» исемле әсәрендә фарсы шаһы Бәһрамгурның үз кияве — һинд раджасы Шанкалдан бүләккә ун мең музыкант «лури» алганлыгы сөйләнә. Бу хәл 420 елда була. Урта Азия һәм Иран халыклары әле хәзерге көндә дә чегәннәрне «люли» дип атап йөртәләр икән. Менә шушы фактларга таянып, галимнәр чегәннәрнең беренче дулкыны Һиндстаннан башка төбәкләргә бишенче гасырда «чайпалып түгелгән» дигән фикерне әйтәләр. Шуннан соң, чама белән мең еллар дәвамында, дулкын арты дулкын булып, чегән ыру-кабиләләре чит илләргә тарала торганнар.

Һиндстанда яшәгән чорларында кемнәр булган соң ул чегән дигән халык? Мәгълүм булганча, Һиндстанның төрле ыру-кабиләләре, үзләренең чыгышлары, тегеләй яки бу һөнәр ияләре булулары аркасында, башка ыру-кабиләләр белән аралашмый торган социаль төркемнәргә, катлауларга бүленеп яшәгәннәр. Ул төркемнәр к а с т а дип аталып йөртелгәннәр. Бу бүленеш Һиндстанда әле бүгенге көннәргә кадәр сакланып килә. Менә шул бер-берләре белән аралашмый яшәүче касталарның иң түбән баскычта торганнары бөтенләй хокуксыз булганнар. Чегәннәр, һөнәрләре буенча биючеләр, җырчылар, музыкантлар булып,

«йорт» кастасы дигән кастага кергәннәр. Алар иң хокуксыз катлаудан саналганнар, күчмә тормышта гомер иткәннәр.

Чегәннәрнең дөнья буйлап таралу юлын галимнәр чагыштырмача җиңел ачыклаганнар: үзләре белән озаграк аралашкан чит халыкларның теле чегәннәрнең теленә «йогып, ябышып» кала барган. Шул рәвешле байтак кына чегән теле сөйләшләре — диалектлар барлыкка килгән. Әйтик, балкан диалекты, влаш диалекты, карпат диалекты, уэльс диалекты, украин диалекты һ. б. һ. б. Шунысын да әйтергә кирәк, ЮНЕСКО мәгълүматларына караганда, бүгенге көндә дөньяда төрле ыру-кабиләләрдән булган унөч миллионнан артык чегән халкы бар дип исәпләнә. Аз сан түгел бу. Башка рәсми булмаган мәгълүматлар исә бу санны хәтта кырык миллионга кадәр (!) үстерә. Исәпләүләрдәге мондый төрлелек аңлашыла, әлбәттә: беренчедән, чегәннәрнең еш кына, дәүләтләр-илләрнең чикләре белән дә хисаплашмастан, җир шары буйлап һәрдаим күченеп йөрүләре, фән теле белән әйтсәк, миграцион процесслар; икенчедән, үзләренең хокуксызлыкларыннан туеп яки башка милләт вәкилләре белән никахлашып, яисә тагын да башка сәбәпләр белән чегән икәнлеген яшергән, бәлки, бөтенләй дә ваз кичкән кешеләр; өченчедән, шәһәрләшеп, укып белем алган, фән-техника өлкәсендә, сәнгатьтә уңыш казанган һәм шул рәвешле үз милләтеннән «аялып», телен-денен «оныткан» бер төркем...— болар барысы да чегәннәрнең төгәл генә санын алуны һәм исәпләп чыгаруны бик кыенлаштыра.

Мәсәлән, 1979 елдагы халык санын исәпкә алу вакытында үзләрен чегәннәр дип яздырган кешеләрнең саны СССРда 209 мең булып чыккан иде. Чегән халкының шактый үрчемле-ишле гаиләләрдән торуын истә тотыптыр инде, 1989 елдагы халык санын исәпкә алу вакытында аларның саны чама белән 250 меңнәр тирәсе булыр дип көтелгән иде. Ә чынлыкта СССРда яшәүче чегәннәрнең саны 262 мең кеше тәшкил итә икән. Ун ел эчендә 53 меңгә үсеш!

Әгәр дә ЮНЕСКО мәгълүматына гына таянып, чегәннәрне унөч миллион кеше дип исәпләсәк тә, алар бер җирдә генә тупланып, аерым бер дәүләт булып яшәсәләр, Польша, Венгрия кебек илләр белән бер чама ил-дәүләт булыр иделәр.

Биредә чегәннәрнең кайсы чорларда кайсы илләргә күпләп таралуын артык тәфсилләп сөйләп тормастан, аларның Россиягә ничек һәм кайчан килеп чыгуларын әйтеп үтү кирәк булыр. Бу мәсьәлә галимнәр тарафыннан әле һаман да тиешенчә өйрәнеп бетерелмәгән санала. Бары тик шунысы ачык: чегәннәр Россиягә ике юл белән һәм төрле чорларда үтеп кергәннәр. Россиянең көньягына алар Дунай буе төбәкләреннән унбишенче гасырда ук килеп чыкканнар, ә соңга табарак, ягъни уналтынчы-унҗиденче гасырларда, чегәннәр Украина җирләрендә шактый нык урнашып өлгерәләр. Россиянең төньягына һәм үзәк өлкәләренә алар исә Германия, Польша җирләре аша үтеп кергәннәр. Болары әкренләп аерым бер этник төркем тәшкил итеп, рус чегәннәре яки төньяк рус чегәннәре дип аталып йөртелә башлаган. Бу төркемнең телендә, көньяк төркемнән үзгә буларак, немец һәм поляк телләреннән кергән сүзләрнең күп булуы ачык чагыла, соңга табарак болар өстенә, әлбәттә инде, рус теле йогынтысы да килеп кушылган. Бүгенге көндә рус чегәннәре дип йөртелә торган әлеге этник төркем Россиянең бик күп төбәкләрендә яши. Аларны Карелиядә, Архангельск, Вологда, Ленинград, Псков, Новгород, Мәскәү һәм Мәскәү тирәсе өлкәләрендә, Идел буе республикаларында, Себердә һәм Ерак Көнчыгышта очратырга була. Шулай ук Казагстан һәм Урта Азия республикаларында да алар байтак.

Чегәннәр гомер-гомердән нигездә күчмә тормыш алып барганнар. Аларның борынгы заманнардан ук формалашкан ырудашлык мөнәсәбәтләре һәр таборда буыннан-буынга саклана килгән һәм ул әле бүгенге көндә дә үзен шактый нык сиздерә. Шул ук вакытта заман сулышы, заман шаукымнары чегәннәр тормышына да үтеп керә бара. Хәер, бу хакта алдарак сөйләнелер әле...

Тулаем диярлек надан булган, укый-яза белмәгән, үз язулары да булмаган чегән халкы, Бөек Октябрь революциясеннән соң, Рәсәйдәге башка халыклар белән бер рәттән, закон нигезендә тигез хокук ала. Чегәннәр өчен мәктәпләр ачыла башлый, рус алфавиты нигезендә үз язулары булдырыла, дәреслекләр-сүзлекләр басыла, язма чегән әдәбияты туа. Төрле вакытларда чегән телендә «Романы зоря» («Чегән таңнары») һәм «Нэво дром» («Яңа юл») дигән журналлар чыгып килә. 1931 елда, дөньяда беренче буларак, Мәскәүдә чегән театры «Ромэн» эшли башлый. Бу театр хәзерге көндә Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнгән — танылган театрларның берсеннән санала.

Чегәннәрне файдалы хезмәткә тарту, утрак тормышка күчерү максатыннан, утызынчы елларда алар өчен шәһәрләрдә төрле артельләр, берләшмәләр оештырыла. Авыл җирләрендә алтмышлап чегән колхозы төзелә. Әмма, кызганычка

каршы, бу эшләр Сталинның шәхес культы шаукымы астында, чегән халкын ирексезләп-көчләп эшләнә һәм шунлыктан көткән нәтиҗәләрне бирми. Бүгенге көндә исә СССРда бер генә чегән мәктәбе дә юк, бер генә матбугат органы да калмаган, чегән телендәге китап дигән төшенчә дә юк...

Бөек Ватан сугышы елларында, башка халыклар кебек үк, чегәннәр дә зур фаҗига кичерәләр. Шуны гына әйтеп үтү дә җитә: Көнбатыш Германия мәгълүматларына караганда, Гитлер Германиясе җирләрендә һәм оккупациягә эләккән илләрдә сугышка кадәр ярты миллион чегән халкы яшәгән булса, сугыштан соң алардан нибары илле мең чамасы кеше генә исән кала. Димәк, фашист концлагерларында һәр ун чегәннең тугызы һәлак булган дигән сүз. Шул ук чорда СССРның көнбатыш төбәкләрендә яшәүче чегәннәрне дә, аларга ышанычсызлык белдереп, Казагстан һәм Азия якларына сөрәләр.

1956 елда СССР Югары Советының махсус Указы чыга. Ул Указ, хөкүмәтебезнең чегәннәрне утрак тормышка күчерергә зур тырышлык күрсәтүенә дә карамастан, бу халыкның күпчелек өлеше әле дә булса ил буйлап күченеп йөри, сукбайлыкта яши, әрәмтамакларча эшләми көн күрә, дигән нәтиҗә ясый һәм бу «тискәре» күренешне... өч ай эчендә (!) тамырыннан корытырга дигән карар чыгара. Җәза чаралары бик катгый була: кем дә кем әлеге Указга буйсынмый — андыйларны хезмәт белән төзәтү өчен биш елга сөргенгә сөрәләр. Сталинның шәхес культын кыю рәвештә фаш итеп, могҗиза белән исән калган дистәләрчә миллионлаган гаепсезләрне, шул исәптән, кырым татарлары, калмыклар, карачайлар, чеченнар, Идел буе немецлары һ. б. кебек, халкы-халкы белән сөрелгәннәрне дә лагерь-сөргеннәрдән азат иткән хөрмәтле Никита Сергеевич Хрущевның Указы иде бу! Менә шундый тарихи парадокс...

Безнең илдәге чегәннәрнең бүгенге тормышы да әллә ни мактарлык түгел. Без инде аларның мәктәпләре булмавын, нигездә надан калуларын әйтеп үткән идек. Шуңа өстәп, Халык мәгарифенең СССР Дәүләт комитетында бу мәсьәлә белән берәүнең дә шөгыльләнмәгәнен дә искәртергә кирәктер. Чегәннәрнең саулык-сәламәтлек мәсьәләсе белән дә кызыксынучы юк икән. СССР Сәламәтлек саклау министрлыгы хезмәткәрләре: «Чегәннәр медицина ярдәме сорап безгә бик сирәк мөрәҗәгать итәләр. Елга бер-ике кеше Илизаровка (сөякләрне ялгап үстерү буенча мәшһүр табиб) яки Федоровка (монысы атаклы күз табибы) җибәрүләрен сорап үтенүләр булгалый. Берәүне дә кире борганыбыз юк. Хәтта паспортлары булмаса да, ышанабыз...» — дип юаталар. Чегән егетләренең Совет Армиясе сафларында хезмәт итүгә мөнәсәбәтләренә килгәндә, бер мисал китереп үтү җитәдер. Молдовадагы Сороки дигән шәһәрнең чегән бистәсеннән 1989 елда армия сафларына бары тик бер чегән егете алынган булган. Әмма тиздән ул да үз частеннән качып киткән. Ул вакытта бу шәһәр бистәсендә армиягә алынырга тиешле илле тугыз чегән егете булган. Шуларның утыз икесенең армиягә алынуны кичектерү хокукы бар: чөнки алар барысы да өйләнгән кешеләр, һәркайсысының икешәр яшь баласы бар икән! Калган егерме алтысы — призывник, диикме, никрутмы — кайдадыр качкынлыкта йөриләр, аларны хәрби комиссариат вәкилләре эзләп тә маташмыйлар. Ә бердәнбер армиягә алынганы турында өстә әйтелде инде.

Көндәлдә һаман бер икеләнүле-тәшвишле сорау тора: чегәннәрнең үзенчәлекле тормышына тыкшынырга кирәкме икән? Алар үзләре моны телиләрме икән?

«Аргументы и факты» атналыгы хәбәрчесенең 1991 елның январенда Мәскәү урамында бер чегән белән сөйләшүен искә төшерәсе килә.

...— Күчмә тормыш итүләре ничегрәк соң? — дип сорый хәбәрче метроның «Рижская» станциясе тирәсендә үзенә «эш урыны» сайлаган бер чегәннән.

— Юк инде, күченеп йөрү заманнары үтте хәзер, — дип җавап бирә чегән. Аннары болай дип сөйләп китә: — Малай чагымда әти-әниләрем белән күченеп йөри идек. Хәзер миңа егерме җиде яшь. Биш ел инде Астрахань тирәсендә үз йортым белән яшим, хатыным һәм дүрт балам бар. Ә болай — безнең гаилә бик зур. Без, әти-әтинең балалары, унике җан идек, барыбыз да исән-саулар. Һәркайсыбызның үз балалары бар хәзер. Төгәл генә санап караганым юк, шулай да безнең «ояда» илледән туган-тумача җыеладыр...

— Мәскәүгә нигә дип килгән идегез?

— Нигә дип... Акча эшләп кайтырга килдек. Кемебездер сәүдә итә, кемебездер бага-юрый, кемебездер хәер дә сораша.

— Хәер сорану оят түгелме соң?

— Юк. Кешеләр үзләре биреп торганда, аның ни ояты бар!

— Гаиләгез бик ярлыдан мени?

— Юк ла! Нишләп ярлы булыйк, ди: минем йортым бар, машинам бар.

Мәскәүгә без гаиләбездән берничә кеше генә килдек, шулай булса да, көнгә бишәр йөз сумны төшерәбез. Бер ягы гына начар: рэкитер килсә, аңа көненә кеше башыннан бишәр сум түләргә кирәк була. Берни эшләр хәл юк. Мин акчаны гадел эшләп алам, урлашмыйм, сигаретлар сатам менә. Күрәсез бит...

— Аны кайдан аласыз?

— Китерәләр... «Ява»ның кабын бер сумнан. Ә мин аны сезгә ике сумнан төртәм...

— Шул гаделлек буламы?

— Булмыйча! Мин бит көне буе басып торам, салкын, димим, кар-яңгыр, димим. Аннары бар тапканымны әти-әнигә кайтарып бирәм — без өлкәннәрне хөрмәт итәбез. Безнең гореф-гадәт шундый...

— Тагын нинди гореф-гадәтләрегез бар?

— Без барыбыз да бер-беребезгә ярдәм итәргә тиешбез, чегән чегәнне бервакытта да ташламый. Без аз санлы халык. Шуңа күрә, үз ыруыбызны, телебезне-денебезне саклар өчен, чегән чегән белән генә никахлаша. Урыслар белән яки башка халыклар белән никахлашу очраклары да була, әлбәттә. Әмма андыйлардан бөтен ыру баш тарта, туганнары да йөз чөерә. Андыйлар, чегәнлекләрен яшереп, качып китәргә мәҗбүр булалар. Тагынниләр сөйлим соң? Ә, әйе, гореф-гадәт, дигәннән, менә, әйтик, чегән хатыннарының итәк-юбкалары... Минем хатын бүген нинди итәк киеп йөрсә, кайчандыр аның әбисе дә, әбисенең әбисе дә шундыйны киеп йөргәннәр.

— Тормышыгыздан канәгать инде алайса?

— Яшәргә була. Тик беркайдан да әйбәт гитара гына табып булмый әле менә!

Бик гыйбрәтле, уйландырырлык әңгәмә бу.

Илдә милли мөнәсәбәтләр шактый чуалган бер заманда, башка милләтләр белән бер рәттән, чегәннәр дә үзләренең язмышларын үзләре-хәл итәргә хаклылар, безнеңчә. Ә башка халыклар, бигрәк тә тәрәккыяте алга киткән зыялы халыклар, һичшиксез, аларга ярдәм кулы сузарга тиештер.

Бу җәһәттән караганда, укучыларга аз билгеле булган тагын бер фактны сөйләп үтү кирәк булыр.

1990 елның апрель аенда Польшаның башкаласы Варшавада чегәннәрнең Дүртенче Бөтендөнья конгрессы булып узды. Биредә, әлбәттә, таборлар да, табор чатырлары тирәсендәге учаклар да, гитара аһәңнәре дә, төрле диалект-сөйләшле, чуар киемле чегәннәрнең ыгы-зыгысы да юк иде. Һәйбәт костюмнар кигән, галстук таккан чегән делегатлары дөньяның егерме иленнән булып, аларны телевидение һәм матбугат вәкилләре сырып алган иде. Фәнни симпозиумда чегән теле проблемалары хакында бик әтрафлы докладлар укылды.

Конгресс делегатларын урамда очраткан варшавалылар: «Боларның кай төше чегән соң? Дөньяда чын чегәннәр бөтенләй беткән микәнни?» — дигәнрәк аптыраулы караш белән үтә иделәр.

Әлбәттә, чын чегәннәр бар. Әлеге дә баягы: дөньяда күпме соң алар? Бу сорауга дәрәҗәле конгресс та тәгаен генә җавап бирә алмады. Әйтик, рәсми мәгълүматлар буенча, Румыниядә 230 мең чегән яши дип исәпләнә. Ә менә Халыкара чегәннәр союзы (шундый оешма да бар икән) аларны Румыниядә генә дә ике миллион чамасы дип саный. Менә шуннан соң нинди төгәл саннар хакында сүз йөртергә мөмкин?

Чегәннәрнең Бөтендөнья конгрессларының беренчесе Лондонда (Англия) 1971 елда үткәрелә. Нәкъ шул конгресста чегәннәр үзләренең төрле илләрдә кимсетелеп яшәүләре турында аерым мисалларны бар дөньяга ишетелерлек итеп сөйлиләр. Беренче конгресс делегатлары барлык илләрнең хөкүмәт житәкчеләренә чегәннәрнең гражданлык хокукларын тануны һәм хөрмәт итүне сорап мөрәҗәгать белән чыгалар.

Икенче конгресс Женевада (Швейцария) 1978 елда булып уза. Шуннан соң Халыкара чегәннәр союзы Берләшкән Милләтләр Оешмасының иҗтимагый-икътисади советы әгъзасы итеп кабул ителә. Шул ук елны БМО чегәннәрнең уртак гимнын да раслый.

Өченче конгресс 1981 елда ЮНЕСКО канаты астында үтә. Анда Халыкара чегәннәр союзының Президенты итеп Сент Балич дигән кеше сайлана. Ул үзе даими рәвештә Сербиядә (Югославия) яши һәм бик эре бер промышленность предприятиесенең директоры икән.

Соңгы Дүртенче конгресста СССРда яшәүче чегәннәрнең дә вәкилләре катнашты. Бу конгресс чегән теленең киләчәге мәсьәләсен төп проблемаларның

берсе итеп куйды. Күп кенә галимнәр төрле илләрдә, төрле төбәкләрдә яшәүче чегәннәрнең телләрендәге аерымлыкларның бик зур булуын билгеләп үттеләр, шунлыктан чегән халкының гомуми бер уртак әдәби телдә аралашып яшәү мөмкинлегенә шик-шөбһә дә белдерделәр. Әмма күпчелек делегатлар асылда чегән теленең уртак бер гомуми нигездәге төп принципларын эшләп булыр дип өметләнәләр.

СССРда исә Совет мәдәнияты фонды каршысында 1989 елдан башлап чегән мәдәнияты секциясе эшли башлады. Аның идарә рәисе — педагогия фәннәре докторы, профессор Г. Деметр. Идарә әгъзаларының берсе Л. Черенков Халыкара чегәннәр союзының мәгариф комиссиясе әгъзасы да булып тора.

Чегән мәдәнияты секциясе күзгә күренерлек эшләр дә башкарып өлгергән инде. 1990 елның көзендә беренче мәртәбә чегәнчә-русча сүзлек басылып чыга. Чегән шагыйре һәм этнографы Лексо Мануш җитәкчелегендә чегән әлифбасы эшләнә. Мәскәүнең дүртенче номерлы педучилищесында 1990 елдан башлап чегән тарихы, теле һәм әдәбияты буенча башлангыч мәктәп өчен укытучылар әзерли торган махсус группа оештырыла.

Күргәнебезчә, чегән халкы да рухи бер яңарыш кичерә, ул күтәрелештә-үсештә хәзер.

Теге яки бу халыкның тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, йолалары аның авыз иҗаты әсәрләрендә, аерым алганда, әкиятләрендә-җырларында ачык чагылыш таба. Татар укучыларына тәкъдим ителә торган «Чегән әкиятләре» дигән бу китап — үзенә күрә «беренче карлыгач». Әлегә кадәр татар телендә, күп булса, очраклы рәвештә генә тәрҗемә ителгән бер-ике чегән әкиятен генә очратырга мөмкин иде.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: рус телендә дә чегән халык авыз иҗаты әсәрләрен үзенә туплаган китаплар шушы көнгә кадәр юк дәрәҗәсендә булган. Бирелә мисалга шундый китаплардан А. Кунн тарафыннан төзелеп, 1922 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Чегән әкиятләре»нең ике китабын, 1967 елда Ленинградта басылып чыккан «Чегән җырлары»н гына (төзүчесе А. Лихатов) күрсәтергә була. Һәм менә, ниһаять, этнограф галимнәр Ефим Друц белән Алексей Гесслер соңгы елларда бу өлкәдә гаять зур эш башкаралар. Алар, берничә дистә еллар дәвамында чегәннәр арасында йөреп, бик күп әкиятләр, җырлар язып алалар. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1985 елда Мәскәүнең «Наука» («Фән») нәшрияты әлеге ике галим тарафыннан төзелгән «Сказки и песни, рожденные в дороге» («Юлда туган әкиятләр һәм җырлар») дигән күләмле китап бастырып чыгарды. Ул китап бик тәфсилле кереш мәкалә белән ачыла, анда әкиятләрдән тыш шактый күп чегән җырларының русча текстлары да (бер ун-унбишләбе ноталары-көйләре белән үк) бирелә. Ул әкият-җырларның кайда, кемнән, кайчан язылып алынулары хакында аңлатма-белешмә дә урнаштырыла. Ә 1987 елда Мәскәүнең «Правда» нәшриятында алдагы китап нигезендә төзелгән «Сказки и песни цыган России» («Россия чегәннәренең әкиятләре һәм җырлары») дигән тагын бер китап басылып чыкты. Ефим Друц үзе чегәннәрнең тормыш-көнкүрешен чагылдырган «Чегән кызы Стелла» дигән роман язды (Мәскәү, «Советский писатель», 1987).

Укучыларга татар телендә тәкъдим ителә торган «Чегән әкиятләре» китабы «Сказки и песни, рожденные в дороге» («Наука», 1985) дигән китап нигезендә тәрҗемәләнеп тупланды. Кайбер әкиятләр төшерелеп калдырылды, чегәннәрнең гореф-гадәтләрен, ырымнарын чагылдырган кайбер сөйләкләр дә бирелде.

Укучыны әкиятләр дөньясына алып кереп киткәнче, бу урында чегәннәрнең тормыш-көнкүреше хакында кыскача гына булса да сөйләп үтү зарури булыр. Чөнки шунсыз аларның рухи дөньясын, әкиятләрендәге үзенчәлекләрен тулы итеп күзаллавы кыен булачак.

Ничек кенә сәер тоелмасын, әмма чегәннәрнең тормыш-көнкүрешендә әле һаман да Һиндстанда хөкем сөргән борынгы кастачылык — үз эчләренә бикләнгәнлек, чикләнгәнлек ачык чагылыш таба. Әле һаман да чегән халкы дөньяны күпсанлы профессиональ музыкантлар, җырчылар, биючеләр белән баетып килә. Аларны утрак тормышка ияләштерү юнәлешендә, күреп үткәнебезчә, байтак тырышлыклар куелуга карамастан, әле бүген дә чегәннәр игенчелек-терлекчелек кебек һөнәрләр белән кызыксынмыйлар диярлек. Хуҗалык эшчәнлегендә ир-атлар күбрәк ат белән бәйле эшләргә (шул исәптән, ат дагалау, тимерчелек) һәвәслек кылсалар, хатын-кызлар багучылык-күрәзәчелек белән шөгыльләнүне өстен күрәләр. Ә соңгы елларда чегәннәр арасында алыпсатарлар — сәүдә белән шөгыльләнүчеләрнең күбәеп китүе нык сизелә.

Тәмәкемнең бүген беткән чагы,
Өмет итмә берне урарга.
Мә кулымны, чибәр чегән кызы,
Риза булсаң бушка юрарга.

— дип язган иде күренекле шагыйребез Сибгат Хәким.

Чегәннәрнең күчмә тормышын, табор-табор булып яшәү рәвешен күзалларга тырышып карыйк әле. Соңгы елларда бу традицияләр бетүгә йөз тотсалар да, аларның аерым төсмерләре утрак тормышка күчкән чегәннәр арасында әле дә булса сакланып килә.

Нәрсә ул чегән таборы? Социаль яктан караганда табор — күп гасырлык гореф-гадәтләргә, язылмаган кануннарга нигезләнгән ыру-кабилә берләшмәсе ул. Табор шактый күп кешеле бер генә гаилә булырга да мөмкин, бер ырудан булган берничә гаиләне берләштерергә дә мөмкин. Берләшүнең максаты — бер-берегә ярдәмләшеп көн күрү. Гадәттә бай таборлар күп санлы, ә ярлыраклары еш кына ике-өч дистә кешелек бер генә гаилә булган. Таборның бар тапканы табор әгъзалары арасында гадел (әмма бу әле тигез дигән сүз түгел!) бүленеп килгәнлектән, таборда яшәүчеләр үзара күпмедер дәрәҗәдә тигез хокуклы саналганнар. Таборның башында башлык — б а р о тора. Кайбер галимнәр бу сүзнең килеп чыгышын немецлардагы һәм башка кайбер халыклардагы «барон» сүзеннән дигән караштa торалар. Әмма бу фикер фәнни дәлилләнмәгән әле. Бароның абруе бик зур, ул хаким дә, хөкемдар да. Зур таборларда баро еш кына сайланып куела торган булса, бер гаиләле таборда ул, кагыйдә буларак, гаилә башы — тәҗрибәле аксакал булган.

Табор әгъзалары арасындагы низаглы-бәхәсле мәсьәләләр ч е г ә н  с у д ы —чегән хөкеме белән хәл ителеп килгән. Сүздә тормау, вәгъдә бозу, әҗәт түләмәү кебек көндәлек мәсьәләләрдән тыш, кайвакытларда җинаять кылу кебек эшләр дә турыдан-туры чегән судында каралган. Чегән судын җәберләнгән як кешеләре оештыра торган булганнар. Моның өчен еш кына еракларда хөрмәтле-абруйлы чегән ыруларының аксакаллары чакырылган. Аларның юл чыгымнары, ашау-эчү мәсьәләләре дә җәберләнгән як тарафыннан күтәрелгән. Суд эшнең асылын бик тәфсилләп, җентекләп өйрәнә һәм ахырдан үз хөкемен чыгара. Хөкем карары белән килешми калу, аны яңадан карату мөмкин түгел. Ул — катгый һәм соңгы сүз. Әгәр җәберләнгән як эшне отса, ул күтәргән бөтен чыгымнар да оттырган як өстенә төшә, аңардан түләтелә. Хөкем итү еш кына гаепләне ант эчертеп, дөресен сөйләтүгә кайтып кала. Чегән анты изге саналган. Әгәр кем дә кем ант эчеп тә, ялган сөйләсә, ул хурлык белән табордан куыла. Аның хакында тирә-юньдәге чегәннәргә дә хәбәр ителә. Ул кеше белән беркем дә аралашмый, сөйләшми — чегәннәр өчен ул инде үлгән санала.

Табор эчендә чегән гаиләсенең аерым әгъзалары арасындагы вазифалар да бик үзенчәлекле. Бу вазифалар шулай ук борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә нигезләнгән булган. Ул бигрәк тә гаиләдә хатын-кызларның тоткан урынын билгеләүдә ачык чагыла. Чегән хатын-кызлары борын-борыннан килгән язылмаган кануннарга буйсынып яшәгәннәр һәм яшиләр. Аларның тормышы дүрт чорга бүленеп каралган. Беренче чор — балалык, яшьлек еллары, кияүгә чыкканчы булган чор. Чегән балалары, шул исәптән кызлар да, таборда бернинди тыюларсыз, иркәле-иркен мохитта үсәләр. Икенче чор — кияүгә чыгу һәм биш-ун ел ир хатыны булып яшәү чоры. Чегән кызы, кияүгә чыгуга, яулыгын аерым бер чегәнчә ысул белән бәйләп йөри башлый, аңа гаиләне карап-тәрбияләп тору бурычы йөкләтелә. Килен кеше бөтен йорт эшләрен үзе башкара, ул барысыннан да алдан йокыдан тора, иң соңгы кеше булып йокларга ята. Шул ук вакытта ул, башка хатын-кызлар белән йөреп, багучылык-күрәзәчелек эшенә һәм хәер сорашырга өйрәнергә тиеш була... Чөнки гаиләне ашату-эчертү — аның төп бурычы. Иргә буйсынмау, аңа каршы сүз әйтү булырга да мөмкин түгел. Андый очракта хатынны ире тарафыннан каты җәза көтә. Ирдәге хатын әле шуның өстенә «җен-пәриле» саналган һәм бик күп төрле чикләүләргә-тыюларга дучар булган. Мәсәлән, ул атның юлын аркылы кисеп чыгарга тиеш түгел, аңа ат абзарына керү дә тыела, мал-туар карау да аның эше түгел. Чегән хатыны хәтта юлында яткан таякны да атлап чыгарга хаклы булмаган. Тәртә аша ялгыш атлап чыккан хатыннарны җәзага тарта торган булганнар.

Хатын-кызның өченче чоры — инде яше житкән, өлгергән хатын чоры. Бу чорда гаиләнең матди хәле, тормыш-көнкүреше тулысынча хатын кулында була. Йорт эшләренең күбесе аңардан китә, яшь киленнәргә күчә, ул үзе хәзер тулы хокуклы хуҗабикә булып ала. Дүртенче чор — картлык. Чегән карчыклары иң

абруйлы, аксакаллар белән бер үк дәрәҗәдә хөрмәтле саналалар. Еш кына хәтта карчыклар ыру башы — табор башлыгы да булалар.

Чегән ир-атлары исә гомер буена өстенлекләр белән файдаланучылар булып килгәннәр. Чегән ире, теләсә, көннәр буена «бот күтәреп, түшәмгә төкереп» ята ала, хатын тапканны гына ашый-эчә, хатыны ашарына табып алып кайта алмаса, аны үтергәнче кыйнап ташлый. Ир-атның яраткан шөгыле — атлар карау, тимерчелек һөнәре. Җае чыкканда, ул ат урлаудан да баш тартмый, анысы аеруча тәвәккәллек сорый торган кәсеп булып санала. Шул ук вакытта, хатын-кызлар багу багып яки соранып йөргәндә, ир-ат еш кына аларның яклаучысы да була.

Тормыш-көнкүреш йолаларыннан әкиятләрдә еш очрый торган берсенә — туй йоласына тукталып узыйк.

Чегәннәрдә өйләнешү алдан ярәшү яки яучылап алу рәвешендә эшләнә. Еш кына булачак кияү белән кәләш бары тик туйда гына күрешә торган булганнар, аларны бер-берсенә ярәшү ата-аналарның, туганнарының вазифасы саналган. Кыз сорау, яучылау бик тантаналы төстә, матур йолалар белән алып барылган. Яучылар кызның йортына (чатырына) ялларына ал тасмалар үрелгән кыңгыралы атларда килеп төшә торган булганнар. Аларның кулларында традицион «дрэвца» булган. Бу сүзнең русча «деревцо» ягъни «агач» сүзеннән алынганлыгы күренеп тора. Яучылар кызның әти-әниләреннән: «Сез кунакларга шатмы?» — дип сорыйлар. Унай җавап алган очракта, алар «дрэвца»ны чатыр яки өй түренә кертеп куялар. «Дрэвца» үзе рус чегәннәрендә төсле тасмалар, кәгазь чәчәкләр белән бизәлгән, муенса төймәләре — сәйләннәр ярдәмендә тегеп беркетелгән эре-эре кәгазь акчалар эленгән каен ботагы була. Акчалар никадәр эре — әйтик, иллелек, йөзлек булса — егет ягы шулкадәр баерак, мөлкәтлерәк санала.

Туй үзе икегә бүленеп үткәрелә. Башта кәләш йортында (чатырында) аның туган-тумачалары, әти-әнисе белән хушлашуы рәвешендә: шунда яшьләргә хәер-фатиха бирелә, ипи-тоз тәкъдим ителә. Туйның төп өлеше кияү йортында (чатырында) уза. Аның иң җаваплы мизгеле кызның гыйффәтле-саф булуын сынау була. Шунысы характерлы, бу четерекле эш туйның башында ук, туй мәҗлесе башланганчы үткәрелә. Әгәр дә кәләшнең гыйффәте бозылган булган дип табылса, туй сүтелә, кәләшнең әти-әниләренә камыт кигезелеп, исемнәре мәсхәрәләнә һәм алар хурлыклы төстә куып җибәреләләр. Әле шуның өстәвенә туй чыгымнары да тулысы белән алардан түләтелә, никах исә булмаган дип исәпләнелә. Менә шундый шәфкатьсез, кыргый йола булган ул.

Чегәннәрдә кыз урлау йоласы да яшәп килгән. Бу хәл ике гашыйкның — егет белән кызның әти-әниләре аларга каршы килгән очракларда булган. Ә бу зур кыюлык-тәвәккәллек сорый торган эш, чөнки качакларны куып тотсалар, егеткә рәхим-шәфкать булмаган — аны үтереп ташларга да күп сорап тормаганнар. Әмма шунысы бар: егет, кызны урлап алып киткәч, тотылмаса, күпмедер качып бергә яшәгәннән соң, алар, гаепле башларын иеп, кызның әти-әнисе алдына кайта торган булганнар, үзләрен гафу итүләрен үтенеп, хәер-фатиха бирүләрен сораганнар. Еш кына аларга хәер-фатиха биргәннәр дә. Бу йолалар да чегән әкиятләрендә байтак телгә алына.

Чегән әкиятләре, гадәттә, үзләре яшәгән төбәкләрдәге халыкларның әкиятләре йогынтысын нык кичергәннәр. Әмма шул ук вакытта алар чегәннәрнең тормыш-көнкүрешләренә яраклаштырып үзгәртелгәннәр-яңартылганнар. Әйтик, сыйнфый каршылыкларны чагылдырган сатирик әкиятләрнең сыйнфыйлыгы җуелган, чөнки чегәннәр сыйнфый катлауларга бүленүне белмәгәннәр. Шунлыктан андый әкиятләр көлкеле-кәмит юнәлеш алганнар. Тылсымлы әкиятләрнең эчтәлеге исә чегәннәрнең дөньяга карашлары, ышанулары-табынулары, әхлагы-ырымнары белән өретелеп, яңа төсмерләр алганнар.

Һәр таборның үз әкиятчеләре — сүз осталары булган. Табор, нинди дә булса төбәктә тукталып, чатырларын корып урнашкач, гадәттә, учак ягып җибәрәләр. Учак тирәсенә җыелышып, ашап-эчеп алганнан соң, «кич утырганнар»: учак янында күңел ачканнар — җырлаганнар-биегәннәр һәм, билгеле инде, шунда ук әкиятләр дә сөйләнгән. Тылсымлы әкиятләрдә аждаһалар, сихерчеләр, убырлы карчыклар, җен-пәриләр урын алса, икенче бер төр әкиятләрдә табигатьне җанландыру-сынландыру — урман иясе, йорт-абзар ияләре, хәзинә ияләре алга чыга.

Әкиятләрнең барлык төр-жанрлары турында да тәфсилләп сөйләп тору кирәкмәстер. Укучы укыганда аларны үзе күрер, үзе бәяләр — шул әкиятләр аша чегән халкының бик тә үзенчәлекле әчке тормышына үтеп керер.

СССРдагы йөзләгән милләт-халыклар арасында, башка милләт халыклары шикелле үк, чегәннәр да үз рухи дөньясын — телен, гореф-гадәтләрен, әдәбиятын-сәнгатен үстерергә тулы хокуклы халык. Бүген милләтара мөнәсәбәтләрнең үсешендә яңа төсмерләр барлыкка килгәндә, татар укучысы чегән әкиятләрен аеруча бер кызыксыну белән кабул итәр дип уйлыйбыз. Ул — үзенә гаҗәеп бер дөнья!

Әйдәгез, үзебезне чегән таборында — учак янында утырабыз дип хис итик...

## Чегән сәүдәгәренең бай сәүдәгәр белән ачуланышканы

Бер чегән булган, үзе буйга кечкенә генә, чәчләре каракүл сарык йоны төсле бөдрә булган аның. Ул күкрәген киереп, бик масаеп, әллә кем булып йөрергә яраткан. Тирә-якка данлыклы сәүдәгәр булганга күрә, шулай масаеп йөргәндер инде. Данлыклы башка сәүдәгәрләр дә юк түгел-түгелен, әмма монысы араларында иң хөрмәтлесе саналган. Аның ат абзарында парлап-парлап җигәр алты аты, эче көзгеләр белән бизәлгән бик һәйбәт көймәле арбасы-каретасы да булган. Бик бай инде, сөйләп тә торасы юк. Кулындагы акчасы гына да унике мең исәпләнгән. Әмма бу чегән сәүдә итеп кенә йөрмәгән. Аның хакында, ялган акчалар суга икән, дигән хәбәрләр, имеш-мимешләр дә йөргән йөрүен, ә менә бар, исбат итеп кара син шуны!

Бу чегән сәүдәгәренең бер улы булган. Чибәр егет! Тирә-як кызлары аның өчен акылдан шашарга җитеп йөргәннәр.

Бу тирәләрдә тагын бер сәүдәгәр яшәгән икән әле. Анысы чегән түгел. Ул да бик данлыклы булган икән. Бер сүз белән әйткәндә — меңче. Ул кибет тоткан, он, икмәк, мануфактура белән сату иткән, чегәннәргә чыбыркы-камчы, камыт-ияр ише кирәк-ярак дирбияләрен алып кайтып торган.

Бу сәүдәгәрнең исә бердәнбер кызы булган. Чибәр кыз булмаган ул алай. Шул сәүдәгәр кызы булуы гына инде. Менә шул кыз чегән сәүдәгәренең теге чибәр егетенә гашыйк булган бит әй! Ул аны шулкадәр нык яраткан, теләсә нәрсә эшләргә дә әзер-риза икән. Ә егет озын-озак уйлап тормаган, аңа:

— Менә нәрсә, сөеклем, барыбер әти синең миңа кияүгә чыгуыңа риза булмаячак, — дигән.— Безгә качып китәргә генә кала. Әти миңа моннан ерак түгел җирдә бер өй бүләк иткән иде, мин сине шунда алып китеп яшерермен. Әтиеңнең җитезрәк берәр атын ал, төнлә китеп барырбыз, безне беркем дә күрмәс.

Кыз ризалашкан. Бай сәүдәгәрнең нәселле бер шәп юртагы булган икән. Алтын бәясенә торырлык мал. Чабышларда бер атка да баш бирмәгән ул. Сәүдәгәрнең менә шул дөнья бәясе атына утыртып, чегән егете сөйгән ярын алып качкан. Үзенең бүләк итеп алган йортына кайтарып куйган.

— Тыңла әле, сөеклем,— дигән егет,— бу атаклы юртакны нишләтәбез соң? Аны ишегалдына бәйләп калдырып булмас бит — шунда ук танып алырлар үзен. Аннары сине дә эзләп табачаклар. Шулай булгач, безгә атны өйдә тотарга туры килә инде.

Шулай иткәннәр дә. Атны өйгә кертеп, бәллүр люстралы кунак залына бәйләп куйганнар, имеш.

Кыска гына итеп әйтсәм, шул сәүдәгәр кызын югалткан бит! Дөнья бетереп эзләргә тотынган, әмма эзләп кенә таба алмый икән. Бәла өстенә бәла: җитмәсә, юртагын урлап киткәннәр бит әле. Тирә-юньдә зур шау-шу купкан. Юртакны да, кызны да эзләргә керешкәннәр. Эзләмәгән җирләре калмаган, әмма таба алмаганнар. Ләкин шунысы бар бит: күпме генә качып ятсаң да, иртәме-соңмы барыбер чыгып күренергә туры килә. Гомер буе бикләнеп утыра алмассың ич!

Бай сәүдәгәрнең җен ачулары чыккан, яшеннәр яшьнәтеп, күкләр күкрәткән ул:

— Чегән малаен судка бирәм! Башын Себер җибәрәм! — дип кычкырынган.

Нәкъ шул чагында аның кибетенә чегән сәүдәгәре килеп кергән. Бай сәүдәгәр аңа очып кунган:

— Син үзеңнең эттән туган малаеңны тый! Кызымны кешеләр алдында рисвай итеп йөрмәсен! — дигән.

Ә чегән сәүдәгәре җавабында:

— Юк инде, үз кызыңны тыйсаң, яхшырак булыр! Минем улымның исемен ул пычратып йөри,— дигән.

— Ничек-ничек дисең?
— Ә менә шулай дим!
Болар тирәсенә җыелган халык аларның әйткәләшкәненнән авыз ачып тыңлап тора икән. Ә чегән сәүдәгәре тезепме-тезә генә:
— Улымның синең кызың белән сөйрәлүе әллә мина бик ошый дип беләсенме? Ярар, себерелә торсыннар әлегә!
— Ах, син — эт җан!
— Эттән ишетәм!
— Синең улың — карак! Ул минем юртагымны урлап киткән.
— Ялганлама! Китте, диерләр! Безгә синең атларыңның поты бер тиен, үзебезнекеләр дә җитәрлек. Кызың үзе тәкате беткәч, юртагыңда җилдереп, минем малай янына барган бит. Аннары, атын кайтарып куярга онытканн.
Шул чагында, гөнаһ шомлыгына каршы, кибеткә Петрий атакай килеп кергән. Бик тәүфикълы-инсафлы поп булган ул. Унике чиркәүгә баш булып торган. Петрий атакай әйтә икән боларга:
— Әрләшмәгез, яхшы түгел. Аллага тел тигезмәгез! — ди.
Бай сәүдәгәрнең ачуы килгән чак, җитмәсә әле побы килеп кысыла тагын арага:
— Петрий атакай, тай әле моннан! — дип кычкырган ул попка.
Попның күзләре маңгаена менеп киткән.
— Синең эшең түгел, тыкшынма! — дип чегән дә күтәреп алган. — Безгә иркенләп сөйләшергә ирек бир.
Шунда поп Петрий бай сәүдәгәргә:
— Чегән белән әйткәләшеп торырсыңмы? — дигән.
— Ах, мин чегәнме? — дип кычкырып җибәргән чегән сәүдәгәре, кештәдән бер чыбыркыны эләктереп алып, попны кыйнарга ук тотынган ул.
Бай сәүдәгәр кычкыра икән чегәнгә:
— Тукта тизрәк! Унике ел төрмә сиңа!
— Ни өчен?
— Поп өчен.
— Мондый эт себергән нәмәрсә өчен пычагым да булмас. Ул барып әйтеп тә йөрмәячәк, минем акчага яши ич ул!
— Синең акчага, имеш! Каян килгән ди ул сиңа акча, чегән? Минеке шикелле кибетең булса — әле бер хәл иде.
— Миндәге кебек акчаларның синең төшеңә дә кергәне юк!
— Минемме? Карап тор алайса! Менә, мең тәңкәмне күз алдыңда яндырам да ташлыйм. Синеке күбрәк булса, син дә як, аермасын үзем түләрмен.
— Ах, шулаймы? — дип кычкырып җибәргән чегән. — Ярар алайса! Син мең тәңкә яндырсаң, мин менә ун меңне яндырам...
Чегән сәүдәгәре кесәсеннән бумажнигын алып, бер төргәк ялган акчалар тартып чыгара да болгый-болгый кычкырыныра тотына:
— Карагыз, җәмәгать, алдаусыз-нисез ун мең! Сүземне сүз итәрмен. Их, янгыз, әйдә, акчаларым!
Ялган акчаларына ут төртеп бетергәч, бай сәүдәгәргә кычкыра ул:
— Сәүдәгәр түгел син! Адәм мәсхәрәсе! Менә мин сәүдәгәр ичмасам! Миңа хезмәтче булырга гына ярыйсың бит син! — Чегән сәүдәгәр бай сәүдәгәрне акча тулы бумажнигы белән уңлы-суллы яңаклап, әйтеп куйган: — Миңа синең кебек коданың бушлай да кирәге юк. Әле өстәп бирсәң дә, синең белән туганлашасым юк! Ә кызыңны килеп алып кит, безгә кирәге юк аның, — дигән.

## Пушкинның чегәннәрдә яшәгәне турында

Пушкинның исеме чегәннәр арасында күптәннән хөрмәт ителеп килә. Ул аларны яклап җылы сүз әйткән, аларны яраткан, алар арасында яшәгән, алар турында китаплар язган кеше бит. Алеко белән Земфира турындагы китапны хәтерлисезме? Алайса менә шул: Пушкин ул китабында үзенең табор белән Рәсәйне гизеп йөргән чагындагы тормышын язган, дигән сүзләр йөри чегәннәр арасында. Бик күп еллардан бирле йөри инде андый сүзләр...
Пушкин патшаның ачуын китергән икән дә, патша аны сөргенгә сөрмәкче булган, имеш, әмма ул барып чыкмаган, имеш. Пушкин качып киткән. Рәсәй буйлап үзенә-үзе хуҗа булып шулай йөргән чагында ничектер бервакыт бер чегән

таборы янына килеп чыккан ул. Чатырлар корып куелган, аланлыкта атлар утлап йөри, учаклар янып тора икән. Чегәннәр үзләре учаклар тирәсендә ашап-эчеп утыралар, янәшәдә генә бер агач төбенә тимер сандал куелган, шунда ук ат дагалыйлар, шунда ук яшьләр гитарага кушылып җырлашалар икән. Пушкин әле башта таборга килеп кермәгән, бераз читтәрәк туктап, күзәтеп торган. Шунда ул бер чегән кызының урманга утын җыярга кереп киткәнен күреп калган. Яшь, чибәр чегән кызы булган теге. Пушкин аның янына барып, сөйләшеп киткәннәр. Шунысын да әйтергә кирәк, ул вакытта инде Пушкинда байлар төсе калмаган булган, ул, дөнья гизеп йөри торгач, сәләмәләнеп-йолкынып беткән булган. Ә болай Пушкин үзе чибәр генә булган икән ул. Чегән кызының күңеленә хуш килгән, күрәсең, кыз аны әтисе янына алып кайткан. Шулай итеп, Пушкин чегән таборында яшәп калган.

Пушкин белән Земфираны, чегән йолаларына туры китереп, никахлаштырганнар. Шуннан алар ирле-хатынлы булып яшәп киткәннәр. Табор башлыгы Пушкинга:

— Ничек теләсәң, шулай яшә, морэ, күңелең теләгәнне эшлә: теләсәң — тимерчелектә эшлә, теләсәң — атлар белән шөгыльлән — үз ихтыярыңда,— дигән.

Әмма ләкин Пушкин тимерче дә, атлар белән алыш-биреш итүче дә булып китмәгән. Ул берәр агач төбенә барып утыра икән дә үзенең китапларын яза икән. Аннары тагын рәсемнәр ясау белән дә шактый мавыккан ул: чегән балаларын, атларны, чегәннәрнең биегән чакларын, байларга җырлар җырлаган чакларын, соранып йөрүләрен, багу багып, күрәзәлек иткәннәрен — кыскасы, ничек яшәсәләр, тормыш ничек булса, барысын да шулай кәгазьгә төшергән ул. Кызганыч, аның рәсемнәре безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгәннәр, таборда янгын вакытында янып харап булганнар.

Күпмедер вакытлар үткәч, Земфираның Пушкиннан бер улы туа. Кирәк бит менә, гөнаһ шомлыгына каршы, дигәндәй, Земфира табордагы бер чегән егетен яратып йөри башлаган бит. Качып-посып кына егет янына күрешергә йөри икән.

Ничектер бервакыт Пушкин белән Земфира чыбылдык астына кереп яткач, Пушкин күзләрен йомып йоклап китүгә, Земфира, торып, чыклы үлән өстеннән генә егете белән очрашуга китеп барган. Шул мәлне сабый бала елап җибәргән. Пушкин уянып, торып караса — хатыны юк. Эзли чыккан ул аны. Чатыры яныннан чыклы үләнне ярып китеп барган эзне шәйләп алган. Шул эз белән барып, гашыйкларның өсләренә үк килеп чыккан Пушкин. Тегеләр яр буенда кочаклашып утыралар икән.

Пушкинның ачуы эченә сыймаган, ул үзен-үзе тыеп тора алмаган, пычагын суырып алган да Земфираның егетен кадап үтергән.

Табор чегән судына җыелган. Ишетелгән хәл мени: кеше кадәр кеше үтерсеннәр әле, житмәсә, үз таборларында! Сораштырырга, хөкем йөртергә керешкәннәр.

— Егет синең көнчелегеннән һәлак булган,— дигән табор башлыгы Пушкинга.— Көнләшүең дә урынлы. Земфира сиңа алла каршында биргән вәгъдәсен бозган, хыянәт кылган, шулай булгач, син аны үтерергә тиеш идең.

— Мин аны һич тә үтерә алмас идем. Земфираны мин элекке кебек үк яратам. Аннары, мин Земфираны үтерсәм, улыбыз нишләр иде соң? — дип җавап биргән Пушкин.

Картлар бик озак киңәшләшкәннәр, шуннан соң гына Пушкинны борынгы йола буенча хөкем итәргә карар кылганнар: аны, таш өстенә утыртып, табордан куарга дигән хөкем чыгарганнар. Кеше үтергән өчен генә бирелә торган иң каты җәза шундый булган ул вакытларда. Гаепләне таш өстенә утырткач, аның йөрәге чегән ыруы өчен таш булып катып кала, имеш. Һәрхәлдә чегәннәр шуңа инанганнар.

Пушкинны таш өстенә утыртып куйгач, табор урыныннан кубып, шагыйрьнең берьялгызын калдырып, далага китеп барган.

# ГАЛИ РУХЛЫ ШӘХЕС



Соңгы елларда иман яңарту хәрәкәте иҗтимагый аңыбызда зур борылыш ясаган вакыйгаларга бай. Мәдәни һәм социаль тарихыбызга карашыбыз кискен төстә үзгәрә, һәр күренешкә яңача бәя бирү зарурияте арта. Милли мәдәниятебезнең данлы мәйданына исемнәре тарих сәхифәләреннән нахакка сызылган шәхесләрнең кайтуы да моның ачык мисалы. Тарихны моңарчы бары тик ике төрле җете төс белән генә тасвирларга ияләнеп җитүебез аркасында без табигатьтә әллә никадәр башка буяулар һәм төсмерләр дә барлыгын бөтенләй онытып җибәрдек. Яшәешнең ясалма кысаларга гына сыймавын истән чыгарып, без гамәлдә милләтебезнең мөлкәтле катламы вәкилләреннән генә түгел, мәгълүм схемадан «бүлтәеп чыккан» бүтән даирә зыялыларыннан да ваз кичтек. Кимендә мең еллык данлы тарихы булган милләтнең биниһая олуг һәм бай мирасын телгәләп, сортларга аерып, ана унай һәм тискәре тамгалар сугып, без бүген тирән тамыр җәйгән манкортлыкка ныклы зәмин-җирлек әзерләдек. Бу афәттән котылу чарасы бер генә. Безгә аңыбызны пакьләргә, күңелебезне сафландырырга, дегет сыланган мирасыбызны чистартырга, милләт намына бар гомерләрен сарыф иткән могтәбәр зыялыларыбызның исемнәрен барларга, тамырларыбызны, тарихыбызны, мирасыбызны ачыкларга, тикшерергә, өйрәнергә кирәк.

Шушындый әтрафлы барлауга, ачыклауга мохтаҗ, гадел бәяләнергә тиеш, һәр яклап өйрәнелергә лаек шәхесләребезнең берсе — Гайса Еникеев. Бу милләт хадименең татар, башкорт, казакъ, кыргыз, бүтән төрки халыклар, киңрәк алганда, мөселманнар өчен кылган игелекле хезмәте моңарчы тиешле бәһасен алганы юк. Хәлбуки, патша самодержавиесе шартларында төрки-татар, мөселман халкының мәдәни мәнфәгатьләре өчен аның кебек җанын фида кылган каһарманнар бармак белән генә санарлык. Гайса Еникеевның милләт вә диндәшләре мәгърифәте юлында арысландай көрәше генә дә аны заманының иң гаярь ирләре рәтенә куя. Ул гына да түгел. Гайсаның Дәүләт думасы мөнбәреннән ясаган ялкынлы нотыклары бүгенге халәтебезгә шулкадәр аһәңдәш ки, әйтерсең, алар гасырыбызның унынчы елларына түгел, ә бүгенгә адресланган.

Борынгы морза нәселеннән булган Гайса Хәмидулла углы Еникеев 1864 елда Уфа губернасы Бәләбәй өязе Яңа Каргалы авылында дөньяга килә. Әлбәттә, без сүз алып барган чорларда бу нәселнең шәүкәте инде нык зәгыйфьләнгән, хокуклары чикләнгән, аның вәкилләренә «чабаталы морза» дигән атама тагылган булган... Сәләтле малайны Оренбургның Татар укытучылар мәктәбенә (ОТУМ) укырга бирәләр. Бу абруйлы уку йортын бик яхшы билгеләр белән генә тәмамлаган Гайсаны шунда ук башлангыч әзерлек мәктәбе мөдире итеп калдыралар. Шул ук вакытта яшь педагог ОТУМ каршында эшләп килгән укытучылар белемен күтәрү җәйге курсларын даими оештыру белән шөгыльләнә, аның мөдире була. ОТУМда эшләү чорында, ягъни 1883 елда ук Рәсәй императорлык география җәмгыятенең Оренбург бүлегенә гамәли әгъза итеп алына, ә 1887 елда шулай ук Оренбург Фәнни архивы комиссиясенә член буларак кабул ителә. 23 яшьлек татар егете өчен бу инде, әлбәттә, зур мәртәбә була. Әлеге җәмгыятьләрдә Гайса бик актив эшчәнлек алып бара. Урыс телен бик мөкәммәл белгән Еникеев параллель рәвештә җирле банкта штаттан тыш тәрҗемәче булып эшли, монда икътисади белемен тирәнәйтә, финансларга кагылышлы мәгълүматын ныгыта.

Киң кырлы талант иясе Гайса ОТУМда һәм дә атап кителгән җәмгыятьләрдә эшләү дәверендә үк милли музыкаль фольклорны өйрәнү һәм туплау шөгылен башлап җибәрә. Үзе дә матур итеп җырлаучы, курайда гаҗәп оста уйнаучы егет ОТУМ дәверендә һәм гомумән чирек гасыр дәвамында Идел-Урал буе губерналарына сәфәр кылып, бай музыкаль фольклор мирасы туплый. Шул эшчәнлек нәтиҗәсендә, профессор И. Овод ярдәмендә зур кульъязма җыентык төзи. Бу мәҗмугага 200 ләп халык җәүһәрләре теркәлә. Алар арасында 93 татар, 42 башкорт, 10 башка төрки халыкларның җырлары һәм күп кенә дини мөнәҗәтләре, көйләр була. Җыентык мәгълүм дәрәҗәдә фәнни калыпта төзелгән. Андагы көй-җырлар жанрлары буенча ун төргә бүленә һәм шул төр принципларыннан чыгып бәяләнә. Гайса Еникеевның бу өлкәдәге мактаулы эшчәнлегенә музыка белгече М. Нигъмәтҗанов «Музыкальный Татарстан» дигән китабында (1970) югары бәя бирә. Белгечләр Еникеев җыентыгыннан 114 җырның гына безнең көнгәчә килеп ирешүен билгеләп үтәләр, калганнары, барлаучының исемен җуеп, таралып-сибелеп беткәннәр икән. Музыкачы Л. Атанова мәгълүматларына карaганда, Г. Еникеев җыентыгына кергән җырларны В. И. Ленин да яраткан. Кокушкино авылында сөргендә чагында ул бу җырларны көтүче малай Баһавига ияреп җырлый торган булган. Шундыйларның берсе — «Сары, сары, сап-сары...» җыры.

Самодержавиенең реакцион милли сәясәте нәтиҗәсендә 1890 елда ОТУМ ябыла, алдынгы карашлы зыялыларны эзәрлекләү көчәя. Шушы заманда Гайса Хәмидулла углы кыска сроклы мөгаллимнәр курсларына җитәкчелек кыла, мәгърифәтчелек буенча эшчәнлеген дәвам итә.

1895 елда 31 яшьлек Гайсаны татарның иң атаклы мәдрәсәләреннән берсе булган «Хөсәения»гә (Оренбург) чакыралар. Ул монда урыс теле һәм әдәбияты укыта. Шул ук вакытта зыялы морзабыз мәдрәсәнең унике кешедән торган назыйрлар шурасы (попечительный совет) әгъзасы итеп сайлана. Алар арасында Фатих Кәрими, Мәхмүт бай Хөсәенов, Хәсәнгата Габәши, Закир Рәмиев (Дәрдемәнд), морза Хәсән Акчурин һ. б. мәшһүр шәхесләр булуы бик күп нәрсә турында сөйли. Күп тә үтми, кабилиятле педагог мәдрәсәнең директоры итеп билгеләнә.

«Хөсәения» дә эшләү дәверендә Гайса Еникеев укытуның яңа, мөкәммәлрәк ысулларын кертүгә, гыйлем бирү процессын заманының алдынгы уку йортлары дәрәҗәсенә күтәрүгә зур көч куя. Мәдрәсәгә нигез салучы Гани бай Хөсәенов таләбенә муафыйк рәвештә ул уку программасында дөньяви һәм табигать фәннәренең гомуми санын арттыру, сыйфатын яхшырту фикерен алга сөрә, боларны тормышка ашыруда хәлиткеч рольләрнең берсен уйный. «Хөсәения» мәдрәсәсенең даны бөтен Россиягә тарала. Бу мәгърифәт учагы татар (өлешчә башка төрки милләт) зыялыларының бөтен бер буынын әзерләп чыгара. Алар исә төрки-татар мәдәниятен яңа баскычка куючы эшлеклеләрнең алгы сафларында атлыйлар.

XX йөз башында Гайса Еникеев Оренбургтан Казанга күчеп килә. Биредә ул татар сәүдә короле Әхмәт бай Хөсәенов (1837 — 1906) фирмасының ышанычлысы булып хезмәт итә башлый. Әхмәт бай вафатыннан соң, калган бөтен вәкыф маллар һәм шуларны идарә итү өчен васый (опекун) итеп тәгаен кылына.

Мәгълүм ки, 1906 елның 31 мартында патша хөкүмәте төрки-татар, гомумән, мөселман халыкларының мәктәпләрен кысу, ана телләрен чикләү, бу милләтләрне урыслаштыру идеясенә таянган реакцион «Кагыйдәләр» кабул итә. Халык телендә алар, кыскартылып, «31 март правилосы» дип йөртеләләр. Теленә, иманына, диянәтенә зур афәт янаганын сизеп алган татар халкы бу «Кагыйдәләр»гә каршы бердәм күтәрелә, патша администрациясенең төрле идарәләренә шикаятьләр, нәфрәтнамәләр ява башлый. Мондый тәвәккәллекне көтмәгән хөкүмәт мәсьәләне яңабаштан карарга мәҗбүр була һәм ахыр чиктә үзенең үтә реакцион омтылышларыннан вакытлыча гына булса да ваз кичә. Халык мәгарифе министрлыгы (ул чорда «халык» дигәненә басым ясалган) ашыгыч рәвештә махсус комиссия төзи. Мөфти хәзрәтләре Мөхәммәдьяр Солтанов тәкъдиме белән әлеге комиссия составына Гайсә Еникеев та кертелә. Бу комиссиядә Гайса әфәнде «31 март правилосы»н кире кагылгысыз дәлилләр белән фаш итә, милли мәгариф эшенең аяныч хәлен тасвирлый, хөкүмәттән мәктәп-мәдрәсә ихтыяҗларына тиешле чыгымнар тотуны, мөселман мәгарифен һәрвакыт күз уңаенда тотуын таләп итә. Еникеевнең ялкынлы чыгышы мөселман халкы күңеленә хуш килә, ул Гайса әфәндедә милләт мәнфәгатьләрен аяк терәп якларга сәләтле баһадир бер шәхес күрә. Моның нәтиҗәсе тиз күренә. 1907 елның көзендә 43 яшьлек Гайса Еникеев, ун мөселман депутатының берсе буларак, Казан губернасыннан Думага вәкил булып үтә.

Дәүләт думасында аерым мөселман фракциясе төзелә. Билгеле инде, Гайса әфәнде дә аның эшчәнлегеннән читтә калмый. Бик әзерлекле һәм активлыгын искә алып, Г. Еникеевны Дума җаваплы сәркәтипләренең берсе итеп сайламакчы булалар. Әмма ул, президиумда гел уннар гына утырганлыктан, мөселман фракциясенең карары буенча, сайланудан баш тарта. Хәлбуки, бу бик гыйбрәтле факт. Социаль чыгышы буенча морза булган Еникеев прогресс тарафдары иде, шуңа күрә хөкүмәт сәясәтенә ләббәйкә дип торган уннар белән янәшә утыруны ул үзе өчен хурлык санады. Бу җәһәттән Гайса әфәнденең IV Дәүләт думасында (1912 елда ул монысына да сайлана) башкорт, кыргыз, казакъ һәм Төркестан җирләренә үзәк губерналардан урыс крестьяннарын күчереп утыртуга каршы ясаган нотыгы аеруча игътибарга лаек. Хөкүмәтнең аз җирле крестьяннарын мөселман җирләренә күчерү сәясәтен кискен гаепләп, ул әче тәнкыйть сүзләрен башкалада типтереп яшәүче бай алпавытларга да юнәлтә. Ни өчен әле, ди Еникеев, җирләре 15 дисәтинәдән артыграк булган крестьяннар үзләре кебек үк ярлы крестьяннарга ярдәм итәргә тиеш тә, Петербургтагы университет, берничә дистә мең дисәтинә җиргә, бихисап кибетләргә, биш-алты катлы йортларга ия булган затлар читтә калырга тиеш? Без җирсез крестьяннарга ярдәм итү кирәклеген яхшы аңлыйбыз, әмма бер хәерче язмышын икенче юксыл хисабына хәл ителүгә каршы киләбез. Урыннан Алексеев ише уң депутатлар чәнечкеле репликалар ташласалар да, Гайса әфәнде «дөнья кендекләре»нә каршы һөҗүмен дәвам итә, аларның кешелексезлеген, комсызлыгын ачып сала...

Әмма Еникеев монда сүзнең җир микъдары турында гына бармавын яхшы аңлый. Патша хөкүмәтенә, беренчедән, үзәк районнарда җир кытлыгыннан җәфа чиккән крестьяннарның алпавыт һәм шулай ук удел, чиркәү һ. б. биләмәләренә кул сузмавы кирәк иде. Икенчедән, мөселманнарның иң уңдырышлы җирләрен урыс крестьяннарына бүлеп биреп, царизм милләтләр арасында ызгыш тудыруны, җирле халыкны җәберләүне, кысуны, ахыр чиктә этник буталыш тудырып, урыслаштыруны, христианлаштыруны максат итеп куйды. Патша түрәләре мөселман җирләрен урыс крестьяннарына бүлеп бирүне аклау өчен: «Православие динендәге халыклар Рус җирен туплаучылар алар», дип игълан иттеләр һәм бар көчләре белән башкорт, кыргыз, казакъ җирләрен талауны куәтләделәр.

«Рус җирен туплаучылар, җыючылар» мәсьәләсенә тукталып, Гайса әфәнде болай дип белдерә: «Моны Мәскәү князьлекләре хөкем сөргән, Московия чоры турында гына әйтергә мөмкин, хәзер исә Россия гаять зур мәйдан били һәм бу мәйдан урыс элементы гына түгел, бәлки сугышлар вакытында каһарманлык кылган, тугрылык белән хезмәт иткән, фигыль һәм бәхет уртак булыр дип өметләнеп килгән инородецлар тарафыннан да тупланган. Мин уйлыйм ки, ватандашларның бурычы, вазифасы — җирне һәм дәүләтне җыю гына түгел, бәлки аларны химая кылу, ягъни саклау да» (Стенографик отчет, «Россия» газетасы кушымтасы, 2733—2734 б.). Фикерен дәвам итеп, Еникеев тагын шуны өсти: «Бу хокукны без православный «җыючыларга» гына түгел, башка диндәге халыкларга да бер дәрәҗәдә бирергә тиешбез, югыйсә без инде хәзер инородецларга бернинди дә ихтыяҗ калмады дигән мәлгә килеп төртеләбез» (Шунда ук, 2734 б.).

Күчереп утырту («переселенцы»), шуның нәтиҗәсе буларак көчле низаглар, милләтара ызгышлар кабыну мәсьәләсе ул чорларда кискен төс ала. Бу турыда татар газеталарында әледән-әле төрле хәбәрләр басылып тора. Мәсәлән, 1907 елның 7 февралендә «Урал» (Оренбург) газетасында «Кыргызлардан Рәсәй халкына ачык хат» басыла. Шул ук елның февралендә «Фикер» (Уральск) газетасы «Кыргызлардан — урысларга» дигән җан өшеткеч ачык хатка урын бирә. Башка басмалар да берничә ел дәвамында бу турыда ачынып язып торалар.

«Хөкүмәт... безнең яхшы җирләребезнең барчасын переселенецлар өчен дия алып бетерде... Безгә исә ялгыз (бары тик) әрем кеби нәрсәләр генә үсә торган... һичбер нәрсә үеми торган тозлы җирләрне генә калдырадыр. Переселенческая партия чиновниклары безнең тары, бодай вә солы чәчкән җирләребезне куркытып яки бай кыргызлар илә сатулашып алып бетерәләр вә үзебезне, «бүтән җирләргә китегез» дия куалар..., безне төрмә, кәтер, казак вә солдатлар илә куркыталар... Кыргызлар, җирләрнең бу илә талануына күчеп килмеш урыслар сәбәп дия, аларга дошманлашалар. Ошбу сәбәпле кыргызлар илә переселенецлар арасында дошманлык, үтерешү башланадыр. Ләкин без, аңлы кыргызлар, монда кыргыз вә урыс каннарының гаепсез акканлыгын беләбез, фәкать моның илә бәрабәр кан агу моннан соң... дәхи дә (тагын да) артачагында шөбһә итмибез. Хөкүмәт, алпавытлар файдасын төшенеп, җирсез крестьяннарны кыргыз җирләренә күчерә. Ләкин моның сәбәпле кыргызларның һәлак булачагын һич төшенми. Хәлбуки,

мәмләкәттәге аерым милләтләрнең бәхетсезлеге хөкүмәтнең бәхетсезлегедер. Моны ялгыз хөкүмәт илә урыслаштыру тарафдарлары гына аңларга теләмиләр» («Фикер», 1907, 18 февраль).

Шулай итеп, Г. Еникеев Думадагы чыгышы белән хөкүмәтнең кучереп утырту, ягъни җир талау сәясәтен хурлык тамгасы белән тамгалады, колониаль изүгә дучар ителгән төрки халыкларның икътисади һәм милли мәнфәгатьләрен яклап чыкты.

Мәгърифәт дөньясында шактый кайнаган һәм эш кылган Еникеев, тоткан кыйбласына тугрылыклы булып, Думада да башлыча шул юнәлештә хәрәкәт итә. Ул Думаның мәгариф эшчәнлеген тикшерә торган махсус комиссиясендә әгъза була һәм аның эшләренә бөтен вакытын бирә. М. Ф. Усал, ягъни Фуад Туктаров үзенең «Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре» дигән китабында (1909) Гайса әфәндедең бу комиссиядә һәм мөселман фракциясе мәҗлесләрендә һәрвакыт чыгыш ясавын, уку эшләренә, мәктәп-мәдрәсәләргә кагылышлы канун, циркуляр, закон проектлары һ. б. шуның ише документларны табып, туплап, аларны тәфсилләп өйрәнү нигезендә гамәл кылуын язып үтә. Думадагы мөселман фракциясе мәктәп-мәдрәсәләр турында закон проектын әзерләгәндә бу эшнең башлап йөрүчесе һәм рухландыручысы шул ук Еникеев була. Ул эшнең барышын тасвирлап, киңәш сорап һәм теләктәшлеккә өмет баглап, гәзитләр аша халыкка мөрәҗәгать итә. Бу шәхеснең милләт өчен үз-үзен аямыйча эшләве турында М. Ф. Усал, мәсәлән, болай дип яза: «Гайса әфәнде өчен Думадагы мөселман депутатлары арасында иң эшләүчән вә үзенең вазифасын бик галибанә (каһарманнарча) ифа итүчеләрдәндер (башкаручылардан). Хәтта кышкы вә пасха каникулларында да Петербургтан китмичә, төрле китапханәләргә йөреп, материал вә законнар тикшереп үткәрде. Хәтта шушы ике-өч ай эчендәге хезмәте аркасында Гайса әфәнде бик картайды да. Казаннан кара сач вә мыек белән киткән Гайса әфәнде биш елдан соң ак сакаллы карт булып кайтачактыр» (109 б.).

Гайса Еникеевның урысчасы бик камил булуы турында әйткән идек инде. Хәер, телне яхшы белү генә әллә ни могҗиза түгел, Гайса әфәнде гадәттән тыш оста нотыкчы да була әле. Алда телгә алынып киткәнчә, ул 1912 елда IV Думага да депутат итеп сайлана. Бу юлы Еникеев Думага Оренбург губернасы вәкиле буларак үтә. Ләкин соңгы 4 чакырылышка мөселманнардан фәкать 7 генә кеше сайлана, әмма аларның да берсе (Самара губернасыннан Миңлегалиев) ни сәбәптәндер Дума утырышларында катнашмый, мөселман фракциясен гамәлдә алты гына кеше тәшкил итә. Алар арасында заманының шактый дәрәҗәле һәм укымышлы кешеләре була. Мәсәлән, Котлымөхәммәт Тәфкилев паж корпусы тәмамлап, подполковник дәрәҗәсе белән отставкага чыккан зат, озак еллар Бәләбәй өязендә дворяннар рәисе булып торган. Думада исә мөселман фракциясе башлыгы Биниәмин Әхтәмов — Петербург университетының хокук бүлеген тәмамлаган адвокат Казанда присяжный поверенный ярдәмчесе. Бакудан сайланган Мөхәммәтйосыф Җәгъфәров шулай ук присяжный поверенный булып эшләгән югары дәрәҗәле юрист. Дагстанлы (лезгин) Мөхәммәт Далгат Германиядә университет тәмамлаган зат, доктор, статский советник була. Әмма бу кешеләрнең берсе дә төрки-татар, мөселман мәнфәгатьләрен яклап, аларның мәгариф һәм мәдәният өлкәсендәге аяныч хәлләтен тасвирлап, Гайса әфәнде кебек фидаи чыгышлар ясамый. Еникеев чиста урыс теле, сәнгать дәрәҗәсенә җиткән нотыклары белән барча депутатларны үзенә җәлеп иткән. Хәтта башкалар сөйләгәндә әледән-әле тотнаксыз, тупас репликалар ташлап утырган карагруһ Пуришкевич та, стенографик язмалардан күренгәнчә, Гайса әфәндене бүлдерергә базмаган. Юкса Еникеевнең чыгышлары усал, үткен, аларда Пуришкевич ишеләрнең «үт куыгына» барып кадала торган ачы гаепләүләр, бик күп төрткә гыйбарәләр, кискен, кырку сүзләр тулып ята. Гайсаның маһирлыгы аның көчле логикасында, кәгазьгә карамыйча ыспай җөмләләр төзү осталыгында гына түгел. Ул залдан әйтелгән һәрбер репликага, гаҗәп йөгерек фикерлелек күрсәтеп, яшен тизлегендә җавап бирә, сүз сөрешенә һичбер кимчелек-ноксан китермичә, оппонентының «авызын томалый белә», гасабиланып, фикер җебен чуалтмый, һәр хәрәкәтеннән, ишарәсеннән үз-үзенә ышанганлык, вәкарьлек бөркелеп тора.

Татар милләте вәкиле Г. Еникеевның аерым татар, аерым башкорт, яисә ялгыз казакъ, ялгыз кыргыз халыклары мәнфәгате өчен генә көрәш алып бармавы җиңел аңлашылса кирәк. Ислам динендәге бу милләтләрнең барысына да хөкүмәтнең урыслаштыру, чукындыру сәясәте бер үк дәрәҗәдә яный. Бу гомуми хәвеф-гарасатка бары тик бергәләп кенә каршы торырга мөмкин була. Шуңа күрә дә гомуми мәнфәгатьләрне күздә тотып, Думада төрле милләт вәкилләрен

берләштергән мөселман фракциясе төзелә һәм ул, этник вә тел аерымлыкларын күпертмичә, алга сөрмичә, ислам динендәге бөтен кардәш халыкларның хокукын бертигез яклый.

Шуның белән бергә, Думадагы фракция бер мөселман халкы өчен генә дә көрәшми. Ул милли-колониаль изүне шулай ук шактый татып килгән башка «инородецлар»га да теләктәшлек белдерә — алар өчен дә хокуклар даулый. Билгеле инде, мөселман фракциясе гади урыс халкына карата да хәерхаһлык принцибыннан чыгып эш итә: гомумкешелек, гомумдемократик позицияләрдә торып, социаль, икътисади һәм хокукый җәһәттән нык җәберләнгән православие мәзһәбендәге урыс h. б. халыкларның да мохтаҗлыкларын онытмый, уртак ватан идеясен даими алга сөрә.

Рәсәйдә гомер сөргән төрек-татар һәм мөселман халкында Гайса әфәнде III Думаның 1908 елның 9 июнь мәҗлесендә ясаган куәтле чыгышыннан соң зур шөһрәт казана, киң катлау милләттәшләренә һәм диндәшләренә мәгълүм була. Бу нотыкны барлык абруйлы татар газитләре дә диярлек тәрҗемә итеп бастыра. Без файдаланган «Идел» гәзите (Әстерхан) аны дүрт санында (27 июнь, 1, 4, 8 июль) урын бирә. «Идел»дә басылган бу материал турыдан-туры стенографик отчеттан тәрҗемә ителгән һәм, безнеңчә, рәсми документ көченә ия. Халык мәгарифе нәзарәтенең сметасын раслауга багышланган бу утырышта Г. Еникеев хөкүмәтнең мәгърифәт өлкәсендәге җинаятьчел сәясәтен бөтен кискенлеге белән фаш итә. Россиядә, ди ул, уку-укыту эшенә, гомумән, бик аз акча сарыф ителә. Әмма бу чыгымнарның да төп өлеше православие динендәге халыклар файдасына тотыла, ә мөселманнар үксез бала сыйфатында кала. Урта һәм Көнбатыш уку-укыту округларына, аерым алганда, Мәскәү округына 941 мең сум тәгаен кылынганда, бөтен Төркестан вилаятенә нибары 203 мең тәнкә акча сарыф ителә. Җитмәсә Синодка һәм башка рәсми ведомстволарга да бу суммалардан зур өлеш чыгарыла, ә мөселман мәктәп-мәдрәсәләре бу субсидияләрдән бөтенләй мәхрүм. Мөселман уку йортларына тартым чиркәү-приход мәктәпләре, духовное училищелар, семинария һәм академияләр хөкүмәттән шактый зур суммалар алганда, шундый ук рухи максатларга хезмәт иткән мәдрәсәләрнең ярдәмнән гаҗиз калуы бик аяныч күренеш. Ә бит, дип дәвам итә Еникеев, Синод үзе генә дә һәр ел рухани, дини һәм мәгариф максатларына утыз миллион сум акча сарыф итә. («Идел», 1908, 27 июнь).

Шуннан соң нотыкчы патша хөкүмәтенең «икенче сорт» милләтләргә, ягъни мөселманнарга карата үткәрелгән сәясәтнең тамырларын тикшерә башлый. Екатерина II заманнарына кадәр тарихи экскурс ясый. Ахыр чиктә хакимиятнең асыл максаты — «мөселман балаларын урыслаштыру» дигән нәтиҗә чыгара. Чыгыш дәвамында Гайса әфәнде Александр II вакытындагы Мәгариф министры Дмитрий Толстой, карагруһ миссионерлар Ильминский, Тимофеев, Малов, Шестаковларның җинаятьчел эшләрен фаш итә, 1870 елда кабул ителгән «Инородецларны укыту чаралары» дигән реакцион «Кагыйдәләрне»ң асылын ачып сала. Мәгариф министрлыгының 1870 елдагы махсус журналыннан ул мондый бер өземтә китерә: «Әлбәттә, Рәсәй дәүләтендә яшәгән инородецларны укытудан төп максат — аларны урыслаштыру һәм урыс халкы белән кушу булып тора» (835 б.). Шуннан соң Еникеев хөкүмәтенең беренчесеннән дә әшәкерәк, әмма тегесенә нигезләнеп эшләнгән 1874 ел «Кагыйдәләренә» анализ ясый, аның иң карагруһ һәм чирканыч җиде пунктын тәфтиш итә. Бу «цивилизацияле» документлар нигезендә ана теле, иман, мәктәп-мәдрәсәләр, гомумән, рухи хәят шундый кысуларга дучар ителә ки, хәтта мөселманнар, бу очракта башлыча татарлар, күпләп Төркиягә һиҗрәт кыла, ягъни асыл ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Төрле мәкерле ысуллар белән (мөселманнар мәнфәгате өчен эшләнә дигән уйдырмалар таратып) үткәрелгән урыслаштыру сәясәтен Гайса әфәнде әхлак, инсаф, кешелеклелек төшенчәләренә бөтенләй ят һәм мөселман халыкларын милләт буларак бетерүгә, юк итүгә алып бара дип белдерә. Бу сәясәт, ди ул, мәмләкәт мәнфәгате күзлегеннән дә бик зарарлы, чөнки ватандашлар арасына дошманлык сала («Идел», 1908, 1 июль).

Еникеев ата миссионер, кара йөз Ильминскийның Синод башлыгы (обер-прокуроры) мәлгунь Победоносцевка язган күп санлы хатларыннан өзекләр китерә, боларның төрки-татар, мөселманнарга халык буларак түгел, бәлки урыслаштыру, христианлаштыру объекты итеп кенә карауларын бәян итә. Ул хатларның эчтәлегенә Гайса әфәнде биргән бәяләрне Думаның сул канаты хуплап каршы ала, гөрләтеп кул чаба. Оратор мөселман мәктәпләренә көчләп урыс теле кертүне, урыс класслары ачуны, мең ел игелекле хезмәт иткән гарәп хәрефләрен кысрыклап, кириллица, урыс дәресләкләре көчләп тагуны, мөселман бала-

ларының зиһенен православие рухында «пакьләргә» тырышуны, исламнан йөз чөертергә маташуны кискен гаепли һәм Дума депутатларына мөрәҗәгать итеп, алардан мөселман мәктәпләрен чын милли нигездә тәрәккъый иттерүдә ярдәм кулы сузуларын сорый. Ильминский ысулындагы урыс-инородец мәктәпләре, дип белдерә чыгыш ясаучы, гыйлемгә һәм прогресска хезмәт итмиләр, мөселманнар аларга ышанмыйлар, бу школалар мәгърифәт тарату юлында уңай роль уйный алмадылар һәм алмаячаклар. Фән раслаганча, ди Еникеев, бер халыкны тәрәккъый кылдыру өчен уку ана телендә булырга тиеш. Школа-мәктәпләрдә һәр предмет балаларның үз ана телләрендә укытылып, урыс теленең исә аерым бер дәрес кенә булуы шарт. Бу сурәттә дә урыс телен уку мәҗбүри булмаска тиеш, бәлки балаларның хөсне ихтыярларына тапшырылмалыдыр». («Идел», 1908, 4 июль).

Нотыгының азагында Г. Еникеев мәгариф өлкәсендәге гаделсезлекләрне, телне, иманны, динне кысуларның кичекмәстән бетерелүен, мөселманнар өчен мәдәният өлкәсендә киң мөмкинлекләр тудырылуын, төрле махсус уку йортлары ачылуын, мөселман мөгаллимнәренең урыс учительләре белән хокуклары тигезләнүен һ. б. таләп итә. Һәм шул таләпләрне эченә алган, ун пункттан торган программа әзерләп бирә. Бары тик шушы элементар таләпләр үтәлгәндә генә, дип белдерә нотыкчы, мөселманнар ватаннарына тугрылыклы гражданнар булырлар, аның мәнфәгатьләре өчен бар көчләрен сарыф итәрләр. Бу сүзләргә суллар бик каты кул чабалар.

Гайса Еникеевның Рәсәйнең мөселман дөньясында киң яңгыраш тапкан икенче зур чыгышы III Дәүләт думасының икенче сессиясендә, 1909 елның 20 апрелендә була. Бу нотыгын депутат үткән елгы чыгышындагы таләпләрнең үтәлү-үтәлмәвеннән башлый. Нәтиҗә бер: мөселманнарның мәгариф эшендә бер генә карыш та алга китеш юк, киресенчә, җинаятьчел сәясәт һаман куәтләнә, милләтләрне кысу колачы арта гына бара. Нотыкчы Дума әгъзалары алдында патша хөкүмәтенең 1870 елгы 26 март, 1874 елгы 20 ноябрь «Кагыйдәләре»ннән башлап, 1906 елгы 31 март һәм 1907 елгы 27 октябрь «Кагыйдәләре»нә кадәр — барысының да мөселман халкын чикләү, кысу, җәберләү, изүгә нигезләнгәнен тәкърарлап күрсәтә, боларның «какшамас» вә «тайпылмас» урыслаштыру идеясен генә алга сөрүләрен исбатлый. Менә аның чыгышыннан бер өзек: «Хөкүмәт үзенең мәктәпләрдәге урыслаштыру сәясәте белән балаларыбызның туган әлифбаларын, туган хәрефләрен тартып алырга, аларны гомуммөселман мәдәниятеннән, гомуммөселман тамырларыннан аерырга тели: ул урыслаштыру ансатрак булсын өчен, гомуми мөселман гаиләсен бүлгәләргә, кисәкләргә таркатырга омтыла. Хөкүмәт безнең балаларыбызның дини хисләрен һәлак итеп, аларга ят төшенчәләр тагарга тырыша һәм шуның белән туган төбәгеннән, газиз халкыннан аерырга маташа» (Стенографик отчет, 97 нче утырыш, 2577 б.).

Г. Еникеев бу нотыгында да (Идел буе, Кырым тарафлары үрнәгендә) мөселманнарны тел һәм дин җәһәтеннән иләмсез кысуларның берсеннән-берсе шыксызрак яңа мисалларын китерә, хөкүмәтнең мөселман халыкларына карата һаман саен көчәя барган һөҗүменә нәфрәтен белдерә. Аерым алганда Бөгелмә өязенең Шәлшәле, Миңлебай, Чапай авылларындагы татар мәктәпләрен тар-мар итү, ябу фактлары аның нотыгының тәэсир көчен тагын да арттыра. Еникеев төрки-татар, мөселман халыкларының милләт буларак сакланып калуында ислам диненең нинди әһәмияткә ия булуын бик яхшы аңлый. Исмәгыйль бәк Гаспралының, тел һәм дин — милләтнең нигезе, алар җуелса яисә бозылса, милләт яшәүдән туктый, дигән гали фикере Гайса әфәнде өчен дә кыйбла була. Шуңа күрә ул динне кысрыклауга, мөселманлыкны әзәрлекләүгә, иманны мәсхәрәләү күренешләренә кыя ташы кебек каршы тора, мәктәп-мәдрәсәләрнең нигезендә дин, дини әхлак ятырга тиеш дигән карашны алга сөрә.

Гайса Еникеев төрки-татар, мөселман халкының инде югалтыр нәрсәсе дә юк дәрәҗәсендә дигән караштан чыгып, курку, шөбһәләнү, икеләнүләрне бөтенләй читкә алып ташлый һәм сәяси карашлары, социаль кыйблалары үтә чуар булган Дума әгъзалары алдына, милләт хакын каһарманнарча даулап, биш пункттан торган, «кичекмәстән үтәлергә тиеш» таләпләр китереп куя. Бу чыгышны да суллар дәррәү кул чабып алкышлыйлар.

Бу урында аз гына чигенеш ясап, шуны искәртү зарур: Г. Еникеевның һәр чыгышында, махсус басым ясап әйтелмәсә дә, мондый фикер ярылып ята: Рәсәйдәге төрки-татар, мөселман халкы, православие мәзһәбендәге бүтән милләтләр кебек үк, дәүләткә кырыкмаса кырык төрле салым, йолым түли, солдат бирә, уртак ватанны дошманнардан саклый, патша хезмәтен үти, авылда игенен игә, фабрикада товар житештерә, шахтада күмер чаба, приискада алтын казый һ. б. Кыскасы, башкарган эшләре, вазифа-бурычлары хәтсез, ә хокуклары мыскыл

итү дәрәҗәсендә чикләнгән. Бүтән милләтләр белән бер дәрәҗәдә үк мәмләкәт мәшәкатьләрен күтәргән халыкны Рәсәйнең тигез хокуклы, хөр гражданнары итеп күрәсе, аның тәрәккъыяте өчен бөтен көчне сарыф итәсе, кылган хезмәтләренә тәшәккер итәсе, рәхмәт укыйсы урынына, идарәче даирәләр мөселманнарны тел, дин, мәгариф, мәдәният җәһәтеннән аяусыз җәберлиләр, наданлыкка дучар кылалар, урыслаштыралар, иманына тукыналар. Хөкүмәтнең мөселманнарга таләпләре зур, дәгъвалары олы, әмма аларның үз дигәнчә, кешечә яшәүләре өчен кыл да кыймылдатмый. Җитмәсә, шушы кешелексез мөгамәләгә ризасызлык белдерсәләр, хөкүмәт мөселманнарны сепаратизмда гаепли башлый, панисламизм, пантөркизм ише карачкылар уйлап чыгара, төрле шыксыз мөһерләр баса, тамгалар суга...

Гайса әфәнденең IV Дәүләт думасында 1912 елда ясаган чыгышы да милләт мәнфәгатьләрен яклау җәһәтеннән бик кыйммәтле. Ул биредә дә патша хөкүмәтенең «инородецларны матди һәм рухи яктан изүнең иске традицион юлына» кыю бәя бирә. Дмитрий Толстой, Победоносцев, фон Плеве кебек карагруһларның тынчу дәверен, аларның реакцион мәсләкләрен фаш итә. Самодержавиенең тоткан юлына ул, бер дә курыкмыйча, «карагруһчыл ассимиляцияләштерү, миссионерларча урыслаштыру шаукымы» дигән үтергеч диагноз куя. (Стенографик отчет, «Россия» газетасының 2318 нче санына кушымта, 2140 б.) Ә бу омтылыш, ди нотыкчы, «инородецларны хокукый яктан чикләү, аларны наданлыкта, караңгылыкта тоту, матди һәм рухи зәгыйфьләндерү, җирсез калдыру, ана телен, туган әдәбиятны, дини, этник үзенчәлекләрне, гореф-гадәтләрне юкка чыгару, һәр халыкның иң мөкатдәс нәрсәсе булган милли мохитен, яшәеш һәм матди иминлек шартларын харап итүдән гыйбарәт». Бу вакыт сулдан кул чабулар, «дөрес» дигән тавышлар яңгырый...

Бу чыгышларның аеруча әһәмиятле ягы тагын шунда: аларның текстлары махсус стенографик хисаплардан тыш, урыс һ. б. телләрдәге гәзитләрдә дә басылып торган. Димәк, нотыкларның эчтәлеге белән Рәсәйнең алдынгы карашлы даирәләре генә түгел, чит ил зыялылары да танышa алган, төрки-татар, мөселманнарның аяныч әхвәле турында камил мәгълүмат хасил иткән.

Гайса Еникеев — тирән мәгълүматлы сәясәтче дә. Аерым алганда, ул шул замандагы социаль шартларны, Рәсәйнең империячел асылын, колониаль сәясәтен, милләтләрнең азатлык өчен көрәш омтылышын бик нигезле итеп тасвирлый. Нәтиҗәдә аның чыгышы әледән-әле сулларның бердәм алкышлауларына күмелә. Нотыкчы бер халыкны икенчесенә каршы куюның, «инородецлар» проблемасын куерту, күпертүнең реакциягә бик файдалы икәнен күрсәтә, урыс халкының да империячел структураларда имин яши алмавын искәртә. Хәтта моны дәлилләп мәгълүм классик фразаны да китерә: «Үзе белән янәшә яшәгән милләтләрнең хөрриятенә даими төстә кул сузучы халык үзе дә азат була алмый» (Шунда ук, 2141 б.). Әлбәттә, суллар «теттереп» кул чаба.

Чыгышларыннан күренгәнчә, Еникеев Россиянең патриоты, ватанпәрвәр шәхес буларак гәүдәләнә. Ул мәмләкәтнең бердәмлеге, куәте, иминлеге, өметле киләчәге өчен тирән борчыла. Нәкъ шуңа күрә дә һәр милләтнең «хөр Россиянең хөр гражданнары» булуын тели, «бүлгәлә һәм идарә ит» принцибын катгый төстә кире кага. Идарәче даирәләр үткәргән җинаятьчел сәясәтнең илне һәлакәткә алып баруына көенеч белдереп, Гайса әфәнде Дума депутатларына кисәтү ясый. Хокук, тел, дин җәһәтеннән, кауми аермалыклар, гореф-гадәтләр, рухи һәм матди яктан рәхимсез изү, кысу, җәбер кылу, Россия гражданнары арасына милләтара ызгышлар салу — болар барысы да, дип белдерә нотыкчы, илнең куәтен бик нык киметте. «Әфәнделәр, — ди ул, — хәзерге сугышлар дәүләтнең мәдәни дәрәҗәсенә, ватанпәрвәрлегенә, бу мәмләкәтнең гражданнары бердәмлегенә имтихан икәнен онытмагыз. Победоносцев, Плеве һәм алар компаниясенең җинаятьчел сәясәте Маньчжурия кырларында, Цусима хурлыгында һәм 1905 ел революциясендә бөтен тулылыгы белән гәүдәләнешен тапты...» (Стенографик отчет, 2144 б.). 1905 ел инкыйлабын бу исәпкә кертеп, Еникеев аны китереп чыгарган сәбәпләргә, ягъни шул ук «мисез» сәясәткә ишарә ясады.

Әүвәлге чыгышларындагы таләпләрне дә берләштереп, милләт мәнфәгатьләрен хәятенең иң алгы планына куйган Еникеев IV Дума әгъзалары алдында унбер матддәдән торган янә бер зур программа күтәреп чыга. Хәзерге чорыбыз өчен дә бик актуаль икәнен истә тотып, без аны тулысынча китерүне тиеш табабыз.

1. Мәктәп өлкәсендә мөселманнарны урыслаштыру системасын бетерергә һәм 1870 ел, 26 март «Кагыйдәләреннән» башлап 1907 ел, 1 январь «Кагыйдәләре»нәчә дәвам итеп килгән кысу чараларын юк итәргә.

2. Дәүләт казнасыннан халык мәгарифенә сарыф ителә торган сумма гадел бүленсен, акчаның мөселманнарга тигән өлеше мөселман халкының санына карап тәгаен кылынсын.

3. Мөселманнарның гомумбелем бирү башлангыч мәктәпләре халыкның яшәеш, этнографик һәм дини үзенчәлекләрен катгый исәпкә алып төзелсен һәм бу мәктәпләрдә укыту ана телендә алып барылсын.

4. Бу мәктәпләргә тиешле мөгаллимнәр хәзерләү өчен педагогик уку йортлары ачылсын.

5. Барлык мөселман мәктәбе мөгаллимнәре хезмәт хокукларыннан файдалансын һәм матди яктан урыс укытучылары белән бертигез тәэмин ителсен.

6. Башлангыч мәктәпләр мөгаллимнәрен әзерләү мәсьәләсе хәл ителгәнгә кадәр Халык мәгарифе нәзариятенә тәкъдим итәргә: дини мөселман мәктәпләре указлы мөдәррисләренең мәдрәсәләрне тәмамлау турында биргән таныклыкларын башлангыч җәдиди мәктәпләрдә мөгаллим булып эшләү өчен житәрлек дип танырга; әгәр мәдрәсә мөдире, ягъни мөдәррисенең күзәтүе һәм җаваплылыгы астында төзелсәләр, мөгаллим булачак кешеләрне дидактика һәм методика кагыйдәләре белән таныштыру өчен ачылган педагогик курслар оештыруны тыймаска.

7. Мөселманнарның дини мәктәбе Халык мәгарифе карамагыннан алынып, үзе дә үзгәртеп корылырга тиеш Мөселман дини идарәсенә тапшырылсын. Аннан тыш бу мәктәпләр Изге Синод карамагындагы рухи-тәгълими уку йортлары белән тигез рәвештә дәүләт казнасы хисабына тәэмин ителсен.

8. Мөселман балалары керел укый торган гомумбелем бирү уку йортларына тиешле предмет буларак казна хисабына ислам дине кертелсен һәм мөселман балаларын бу уку йортлары уставында каралганнан олырак яшьтә дә кабул итү гамәлгә куелсын.

9. Хатын-кызлар уку йортлары да Мөселман дини идарәсе карамагында булсын, алар өчен чыгымнар шушы идарә аркылы бирелсен; мөслимәләр өчен тотыла торган сума аларның санына карап билгеләнсен.

10. Башлангыч гомумбелем бирү мәктәпләрен оештыру һәм аларның программаларын төзү җирле халыкның, урыннардагы җәмәгать бешмаларының ихтыяжларыннан чыгып, закон нигезенә корылган тәртипкә таянып эшләнсен. Бер үк вакытта урыннардагы оешмалар программаларны җирле халыкның дини һәм яшәеш үзенчәлекләрен игътибарга алып, төрле кавемнәрнең дини һәм бүтән башкалыкларын истә тотып сайланган вәкилләрнең турыдан-туры катнашуы белән тормышка ашырылсын.

11. Мөселманнар өчен, җирле дини һәм яшәешкә кагылышлы аерымлыкларны күздә тотып, гомумбелем бирү югары типтагы башлангыч мәктәпләр, авыл хуҗалыгы, сәүдә, техник белем, һөнәрчелек мәктәпләре һ. б. профессиональ уку йортлары ачылсын (Стенографик отчет, 2144 б.).

Империя пайтәхете Петербургта, уң һәм карагруһ депутатлар күпләп «кунаклаган» Таврия сараенда мондый программаны игълан кылу, әлбәттә, мисалы күрелмәгән кыюлык иде. Шулай итеп, Гайса әфәнде, атлаган юлыннан язмыйча, төрки-татар, мөселман халыкларының язмышына кагылышлы иң җитлеккән, иң кичектергесез мәсьәләләрне үтәүне тагын да үтемлерәк таләп итә, нотыгын сул тарафларның алкышлары астында тәмамлый.

Г. Еникеевның киң Россия мәмләкәтенең һәр тарафыннан җыелган гаять чуар карашлы вәкилләр мәҗлесендә ясаган мондый үтә кыю, таләпчән, конструктив, тормышчан чыгышлары милли тарихыбызны бизәүче якты бер сәхифә булып тора. Без мондый каһарман шәхесләребез белән чын мәгънәсендә горурлана алабыз. Күргәнебезчә, хәзерге вакытта халык депутатлары съездларында, сессияләрендә чыгыш ясаучы депутатларыбызга Гайса Еникеевның гасыр башындагы нотыкларыннан гыйбрәт алырдай урыннар шактый күп. Чөнки Гайса әфәнде нотыкларының төп өлеше бүгенге көн өчен дә үтә актуаль яңгырый, милләт язмышына, мәдәниятенә кагылышлы бихисап мәсьәләләр әле дә булса хәл ителмәгән, хисә аларның торышы Еникеев чыгышлары заманына караганда да аянычрак.

III һәм IV Дәүләт думаларындагы тынгысыз эшчәнлегеннән тыш та Гайса Еникеев кул кушырып ятмый. Ул шул заман мөселман мәктәп-мәдрәсәләре торышын тикшерү буенча җыелган корылтайларда актив катнаша, мәгариф мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр яза. Мәсәлән, 1910 елда Петербургта «Законопроект о начальном образовании» һәм «Проект предложенного закона о введении всеобщего начального обучения» дигән ике китап бастырып чыгара. Тиздән бу хезмәтләр татарча да дөнья күрә.

Кызганыч ки, Гайса әфәнденең революциядән соңгы тәржемәи хәле һәм эшчәнлеге аз билгеле. Бу өлкәдә әле безгә житди эзләнүләр алып барасы бар. Биредә бер әһәмиятле якны искәртеп китү дә урынлы булыр. Думада ясаган үткен чыгышлары буенча Г. Еникеевны Ленин яхшы ук белгән булырга кирәк. Кайбер саңгырау, риваяти мәгълүматларга караганда, Октябрь хөрриятеннән соң Совет хөкүмәте башлыгы Гайса Хәмидулла углын, мәгариф өлкәсендәге олуг тәжрибәсен күздә тотып, шул сферадагы хезмәткә тартырга уйлаган. Бу хосуста Еникеевка тиешле кәгазь бирелүе дә риваять ителә. Әгәр бу хәбәр расланса, Гайса Еникеевның үз заманында нинди абруйга ия булуын тагын да калкурак күзалларга мөмкин булыр иде.

1918—1923 елларда бу гаярь шәхес Вятка шәһәрендә халык мәгарифе комиссариатының губерна коллегиясе әгъзасы булып тора һәм мәктәпләр бүлеген житәкли. 1923—1928 елларда Еникеевны без инде Уфада Дәүләт банкы хезмәткәре сыйфатында күрәбез. 1927 елда аның «Авыл хужалыгы буенча статистик мәгълүматлар» дигән татарча хезмәте басылып чыга.

Ни өчен туган халкы мәнфәгатьләре, мәгърифәте хакына бөтен энергиясен сарыф иткән мәшһүр зыялы шәхес соңгы елларында «сәер» юнәлеш алып, авыл хужалыгы өлкәсенә, финанс системасына кереп киткән соң? Моның сәбәбе бик гади. Совет властенең сталинчыл дәверендә затлы нәселдән килгән шәхесләрне, гомумән, чыгышы буенча ярлы крестьян яки эшче булмаган кешеләрне мәгълүм сыйнфый күзлектән чыгып кына бәяләү гамәлдә иде. Күпләргә «бай, буржуй, алпавыт, мулла яисә аның токымы» дигән кара мөһерләр сугылып, аяусыз һөжүм кампаниясе җәелдерелде. Кулга алу, ГУЛАГ төпкеленә озату, һич югында эзәрлекләү гадәти бер күренешкә әверелде. Билгеле инде, морза нәселеннән булган (гәрчә «чабаталы» булса да) Гайса Еникеев тә бу шаукымнан имин калмады, ул да сыйнфый көрәш гөбесенә эләгеп, үзенең «аксөяк» чыгышы өчен төрлечә кысрыкланды, төп эшеннән читләштерелде. Шулай да ул үз үлеме белән дөнья куйган «бәхтияр» шәхесләрнең берсе — 1931 елда 67 яшендә Уфа шәһәрендә вафат булды.

Аның нәселе, варислары турындагы мәгълүматыбыз да, Әмирхан Еникине исәпкә алмаганда, әлегә бик чикле. Аның Ибраһим исемле (Рязань шәһәрендә гомер кичергән) улы һәм бер кызы булганлыгы гына мәгълүм. Бәлки бу мәкаләне укыганнан соң, олуг мәгърифәтчебезнең якын кардәшләре, аны күреп яисә ишетеп белгән өлкән яшьтәге кешеләр безне хәбәрсез калдырмаслар, Гайса әфәндене тормышы һәм эшчәнлеге турындагы истәлекләре белән уртаклашырлар.

Югары мөнбәрләрдән халкыбызның хокукларын яклап оран салган, аны агарту, мәгърифәтле, сәгадәтле итү өчен җанын аямаган бу фидакарь милләт хадименең якты рухы алдында без баш иярга тиешбез. Иң кара, сөремле елларда да милләттәшләре мәнфәгатьләре өчен көрәш мәйданына чыгып алышкан, әмма бил бирмәгән каһарманның эшчәнлеген тәфсилләп тикшерү һәм барлау безнең мокатдәс бурычларыбызның берсе.

**Равил ӘМИРХАН,**
тарих фәннәре кандидаты.

# ЯФРАКЛАР КОЕЛМАСЫН ИДЕ

*Яфраклар коела, яфраклар...*
*Нәкъ шулай ел саен бу нәрсә...*
*Күбәләк шикелле талпынып*
*Очалар, аз гына җил бәрсә.*

М. Әгъләмов.

Көз. Тәрәзәм каршындагы агач яфракларын җил кага. Моңсу. Ямансу. Чү! Бер яфрак өзелеп төште. Тагын берәү... икәү... өчәү...

Сизәм: җәй буе яшел чукларын җемелдәтеп, тирә-якка ямь бөркеп торган агачым тиздән «шәп-шәрә» калачак.

Бу — ел саен шулай. Агач матурлыгы да — вакыты белән генә.

Нигәдер, келт итеп, профессор Ибраһим Нуруллинның «шәрә көүсәләр» турындагы сүзләре искә төште: «Әгәр XIX гасыр язучылары геройларның эш-хәрәкәтләре турында күбрәк сөйләп бирү белән генә чикләнсәләр, яңа гасырның (XX йөзнең — С. П.) беренче елларында дөньяга килгән әсәрләрдә инде тасвир зуррак урын тота башлый. Беренчеләренең әсәрләре көүсәләрендә тереклек суы йөгереп тә, шәрә килеш утыра торган агачны хәтерләтсә, соңгыларын исә яңа гына яфрак ярган, ләкин әле шәрәлеге бетмәгән агач белән чагыштырып булыр иде». (XX йөз башы татар әдәбияты. Казан, 1966, 15—16 б.).

Әйе, агач язын шаулап яфрак яра, җәй буе балкып утыра, көзен шәрәләнеп кала... Бер уйласаң, татар прозасы да шулай икән ләбаса. Заманында шәрә агачны хәтерләткән проза күп тә үтми «яфрак яра» башлый. Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Ш. Камал һ. б. сүз сәнгате осталары әсәр тукымасын тел-бизәк чаралары белән оста нәкышли белделәр.

Моның өчен, билгеле, уңай тарихи шартлар барлыкка килде. Егерменче йөз башында әдәби телнең орфография, фонетика, морфология, синтаксис һ. б. тармаклары билгеле бер калыпка (нормага) салынды. Өч стиль (югары, түбән, урта) бер-берсенә керешеп, бер кан тамырыннан ага башлады. Чал тарих төпкеленнән килгән традицион сүз-образлар, яңа шартларда сәнгатьчә эшкәртелеп, укучы рухына эстетик азык сыйфатында тәкъдим ителделәр. Каләм осталарының яңадан-яңа тасвир чаралары әдәби тел хәзинәсенә зур байлык булып өстәлде. Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Әмирхан кебек талантларның әсәрләрен укысаң, аларның тел-бизәк чараларына гына түгел, һәр аваз-хәреф, грамматик форма, җөмлә төзелеше, телнең эчке серләрен тирән аңлап язуларына хәйран каласың. Октябрь революциясенә чаклы татар прозасы (нигездә, ун-унбиш ел эчендә), янә күчерелмә мәгънәдә әйтсәк, яфрак та ярды, чәчәк тә атты.

Агач, көзен яфрак коеп, моңсуланып калса, язын янә яфракланып «бәйрәм итә». Кабатлап әйтик, җәй буе табигать матурлыгы булып балкый. Бу матурлык кеше йөрәгенә рухи байлык һәм сәламәтлек шифасы булып ята. Ә инде әдәби әсәрләр көүсәсе шәрәләнсә, аңа яңадан яфрак ярдыру өчен еллар, дистә еллар, хәтта гасырлар кирәк. Утызынчы елларда һәм аннан соң, чыннан да, проза «яфраклары» коела башлады. Моның сәбәпләре бик күп. Бу мәкаләнең максаты, бер җепкә гәрәбәләр тезгәндәй, аларны тезеп-санап чыгу түгел. Шулай да, бу хакта азмы-күпме мәгълүмат бирү кирәк кебек тоела.

Безнеңчә, әдәби тел артык калыплашып китте. Читлеккә ябылган кошлар кебек, ул бер кысага салына башлады. Сүзлек хәзинәсе ярлыланды. Фәнни, публицистик стильләр, газета теле, көтелмәгән әрсез кунак шикелле, матур әдәбият стиленең ишеген ачып керү генә түгел, ә бәлки аның түренә үк менеп

кунакладьı. Борынгы һәм яңа сүзләр, гади сөйләм лексикасы, поэтизм, диалектизм һ. б. тел берәмлекләре әсәр тукымасында хаклы урын алудан мәхрүм ителә башладылар. Телнең тәэсир итү көче, эстетик йогынтысы, рухи азык булу сыйфаты, халыкчанлыгы кимеде.

Әлбәттә, ташны тишеп чыгып үскән үлән кебек, әдәби тел алга таба баруында дәвам итте. Моны «Гомәр Бәширов стиле», «Фатих Хөсни стиле», «Әмирхан Еники стиле» дип сөйләшүләр дә раслап тора. Гомәр ага Бәширов — телнең гәүһәрләре, энҗе-мәрҗәннәре белән ихлас эш итүче әдип. Ул һәр сүз төркеме, грамматик чара, җөмлә төрләренең прозада поэтик яңгырашына зур игътибар итә. Тасвир бизәкләре идеяле, эчтәлекле, эмоциональ була. Телнең грамматик төзеклеге ягыннан да ул үрнәк-өлге күрсәтүче.

Фатих ага Хөснинең стиль үзенчәлеген без кайчак «уйнак тел» дип кенә бәялибез. Бу уйнак тел безне әсәр башында ук тылсымлы, сихри дөньяга алып керә дә китә. Халык тарафыннан иҗат ителгән мәкаль-әйтем, гыйбарә, чагыштыру, метафора һ. б. тел чараларын чын осталарча эшкәртә ала ул. Үзе дә яңадан-яңа поэтик бизәкләр иҗат итә.

Сүз сайлауның никадәр авыр икәнлеге мәгълүм инде. «Нинди генә предмет булмасын, аны белдерә торган фәкать бер сүз, җанландыручы-хәрәкәтләндерүче бер фигыль, характерлы билгесен ачыклаучы бер сыйфат була»,— дип яза Мопассан. Стендаль Бальзакка язган бер хатында исем алдыннан яки аннан соң сыйфат кую өчен еш кына унбиш минут уйлануы турында әйтә. Әмирхан ага Еники әйбернең эчке һәм тышкы билгесен ачыклау өчен мәгълүм бер сыйфатны, аның хәрәкәт-хәлен чагылдыручы бер фигыльне күпме, ничә минут эзлидер — монысын инде үзе генә белә. Әмма аның сүзләрдәге эчке мәгънәгә гаять нык игътибар итүе бәхәссез.

Кыскасы, алар өчесе дә — сүз сәнгате осталары. Индивидуаль стиль булу — язучы өчен зур бәхет. Бу, билгеле, халык теле диңгезенең гаять киң һәм тирән булуына, аның төбендәге энҗе-мәрҗәннәрне чүпли белүгә, аларны әсәр тукымасында иҗади файдалана алуга һ. б. объектив һәм субъектив шартларга бәйле. Ничек кенә булмасын, язучының индивидуаль стиле формалашу аның үзен генә данламый, ә бәлки зур милли әдәби процессның үсешен, теге яки бу чордагы торышын, киләчәк перспективасын башка милләтләр хөкеменә куярга да ярдәм итә.

Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ә. Еники әсәрләрен укыганда Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ш. Камал, Ф. Әмирхан стиле үзенчәлекләре дә сизелә. Димәк, бу өлкәдә традиция тамырларына берәү дә балта белән чапмаган. Ул тамырлар башка түтәлгә күчереп утырткач яңача үсеп китү сыйфатында дәвам иткән.

Г. Кутуй, И. Гази, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, А. Расих кебек әдипләрнең дә үзләренә генә хас стиль аерымлыклары бар. Г. Ахунов, Н. Фәттах, М. Хәсәнов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Х. Сәрьян, Ә. Баянов һ. б. язучылар татар прозасы стиле үсешенә төрле дәрәҗәдә өлеш керттеләр. Ләкин бүгенге татар прозасы күпләрне канәгатьләндерми: «Минем аңлавымча, бүгенге татар прозасының 80—90 проценты уртакул әсәрләрдән тора»,— дигән иде Н. Фәттах («Гаделлек нигез булсын». Казан утлары, 1989, № 11, 161 б.).

Бу бик куркыныч бит. Әлеге егерменче йөз башында яшел шәл ябынган проза агачларының ботаклары яңадан шәрәләнәме? Шулайрак килеп чыга шул. Тәнкыйтьчеләр дә сизә моны: «һәр эшнең үз җае, үз кое була. Берәү тегүче, берәү тимерче, берәү күмерче булып тамак туйдыра,— ди Ф. Миңнуллин.— Шигырьче булып, язучы булып тамак туйдыру өчен, тел белү, сүзләр ярдәмендә җанлы сурәт, тормышчан динамик картина тудыру сәләте кирәктер, дисәң — юк икән... Бүгенге роман-повестьларның, бүгенге хикәяләрнең күбесен телсез авторлар язган. Баксаң, җанлы сурәт, динамик картина дигәнебез үзе дә дефицитка әйләнеп бара, безнең әдәбиятны, безнең прозаны эчтәлек сөйләү алымы, информацион стиль басып-күмеп китә икән» («Кичермәсләр безне, кичермәсләр...» Казан утлары, 1989 , № 11, 137 б.).

Әйе, киләчәк буын кичермәс. Нәрсә бу? Торгынлык, икътисади хәерчелек, сәяси йомгак чуалу тәэсиреме әллә? Әдәби тел, әдәби әсәрләр теле, язучылар теле, дип сөйләшәбез. Билгеле бер чорда әдәби тел, сәнгатьле сөйләм, сүз сәнгате торышын шул вакытта иҗат иткән каләм осталары әсәрләреннән тел-стиль хәзинәсенә карап билгеләргә туры килә. Кол Гали (XIII йөз), Мөхәммәдьяр (XVI йөз), Утыз Имәни (XVIII—XIX йөз), Г. Кандалый (XIX йөз) әсәрләренә лингвистик анализ ясап, алар иҗат иткән чорның әдәби телен күз алдына китерәбез. Ә инде XX йөзнең икенче яртысындагы проза теле торышы шул чорда иҗат иткән язучылар әсәрләре теле-стиле байлыгының гомум синтезы нигезендә бәяләнә.

Телнең проза әсәрләренә җан, кан, сулыш бирә алмавында төрле сәбәпләр бар. Шуларның берсе, безнеңчә, стиль мәсьәләләрен аңлап бетмәүдә. Телнең сүзлек составы, грамматик төзелеше барлык стильләр өчен уртак. Ул стильләр әнә шул уртаклыкны үзенчәлекле куллану нәтиҗәсендә аерыла. Публицистика стильдә, мәсәлән, сурәтләү-тасвирлау чаралары азрак кулланыла. Анда төп максат — укучы яки тыңлаучының аңына тәэсир итү, фикерләрнең логик дөреслегенә ирешү. Бу яктан ул фәнни стильгә тартым. Ләкин һәр фәндә үз терминнары «ансамбле» хөкем сөрә. Публицистик стиль аларга колачын ныклап ачарга бик яратмый. Матур әдәбият стиле тел-сурәтләү чараларына мул була. Анда укучының күңеленә, йөрәгенә эстетик тәэсир итү максаты куела, язучының фантазиясенә тулы ирек бирелә, тел материалы әдәби әсәрнең идея-эчтәлегенә, ул чагылдырган чорга, сюжет-композициягә, герой-персонажларның характер үзенчәлекләренә, фигыль-холыкларына карап сайлана.

Билгеле, бу әйткәннәргә карап, стильләр арасына «Кытай стенасы» корып та булмый. Алар бер-берсенә керешә. Әйтик, публицистик стильдә матур әдәбият стиленә хас үзенчәлекләр була. Һәм, киресенчә, матур әдәбият стиле публицистик стиль дулкыныннан азат түгел. «Дулкын» сүзен шуңа кулланам: повесть, романнар публицистик стильгә капканы бигрәк киң ачалар шул. Нәтиҗәдә ул дулкын булып агыла да, матур әдәбият стиленең нәфислеген, эстетик кыйммәтен, тәэсирлелек сыйфатын каплап китә. Бу күбрәк тарихи, революцион көрәшне чагылдырган, производствога багышланган әсәрләрдә шулай була. Вакытында «Язгы җилләр» романы да шуңа тәнкыйть ителә иде. Листовкалар, прокламацияләр, тарихи вакыйгаларны солдатлар урынына тезеп бару — боларның барысы да әсәрнең ямен-тәмен югалта.

Хәзер мондыйлар, яңгырдан соң калыккан гөмбә кебек, һаман үрчи бара. Бу, бәлки, соңгы вакытта күп язучыларның журналистикадан килүенә бәйләнгәндер. Бәгъзе берәү гомумән гел публицистик стильдә яза. Хәер, аны публицистик стиль дип тә булмый әле. Бу стиль бит сүзләргә «саран булуны» аеруча ярата. Ә теге иптәш матур әдәбият стиле эчендә публицистик стильнең иң начар формаларын күрсәтә. Елга урынына суза башлый ул салкын сүзләрне, аннан тегендә-монда боргалап, әллә кайларга алып китеп адаштыра сине. Укыганда инде әлеге яфраклы күркәм агачларны күрмисең, чытыр-чатыр арасында гасабиланып йөрисең.

Шушы урында бер чагыштыру кулланасы килә. Минем Агыйделнең атлап кына чыга торган урыннарын күргәнем бар. Анда, арттырып әйтсәк, башка урыннарда сирәк очрый торган кеше буе чәчәкләр үсә. Таҗларының бүрек зурлыктагылары бар. Аларны аллы-гөлле күбәләкләр кунып назлый. Матурлыкка кошлар мәдхия укып шатлана. Ә көмеш сулы Агыйдел, бу сихри гүзәллек белән иркәләнеп, шул ук вакытта үз горурлыгын саклаган хәлдә, тавышсыз-тынсыз гына ага да ага. Тиздән аңа төрле яктан башка вак елгалар килеп кушыла башлый. Кайберләре ферма тиресләре, кайберләре май заводы пычрагы, кайберләре нефть мазутлары ташый аңа. Ләкин хәзергә Агыйдел бирешми әле. Үз өстенлеген саклаган хәлдә, «ак» дигән данын югары тотып, ага да ага. Ә инде әлеге күп төрле елгалардан килгән «кара» таплар «ак»ны капласа, Агыйделнең сихри, тылсымлы, поэтик матурлыгы бетте дигән сүз. Матур әдәбият стиле дә шулай. Әгәр ул башка стильләр пәрдәсе белән төренсә, үзенең эстетик сыйфатын, эмоциональлеген, сәнгатьлелек дәрәҗәсен саклый алмый.

Сүз сәнгате осталары моны аңлап эш итә. Алар стильнең җаен, эчке серләрен, чамасын белеп язалар. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар» романнары, «Кызыл чәчәкләр» повесте зур тарихи вакыйга, революцион көрәшне чагылдыралар бит. Аларда публицистик элементларның булуы — табигый хәл. Бар да ул. Ләкин аны сүз рәссамы сиздерми. Икенче төрле әйтсәк, публицистик стиль матур әдәбият стиле эчендә йотылып кала. Нәтиҗәдә сәнгатьлелек өстенлек ала. Бу тел-сурәтләү чараларын зур осталык белән куллана белүгә бәйләнгән. Г. Ибраһимовның прозасында 8220 фразеологик әйтелмә, ике меңләп чагыштыру, шул чамада метафора бар. Төрле поэтик фигуралар әсәр тукымасына матур бизәк булып чигелә. Ләкин аларның күплеген укучы сизми дә. Чөнки сүз, фразеологик әйтелмә, сурәтләү чаралары бер-берсе белән эчке яктан бәйләнеп, әсәрнең идея-эчтәлеген ачыклау, аз сүз белән күп мәгънә аңлату, җанлы картина тудыруга ярдәм итәләр. Соңгы чиктә алар язучының эстетик идеалы, дөньяга карашы, фикер киңлеге офыклары белән җайлаша.

Стиль эволюциясе кичермәгән зур язучы сирәктер. Мәсәлән, Г. Ибраһимов иҗатының баштагы чорында матурлыкны «ялтыравыклы» сүзләр белән тасвирларга тырыша. Вакыт-вакыт абстракт чагыштыру, метафоралар белән дә эш

итә. Моның өчен аны бик урынлы тәнкыйть итәләр. Билгеле, сүз сәнгате остасы тел белән шаярырга ярамаганлыкны тиз аңлый, соңрак тел-стиль мәсьәләсендә классик үрнәк күрсәтә.

«Иң башта мин авыл картлары сөйли торган бик гади авыл теле белән язарга тырышып карадым,— дип яза Гомәр ага Бәширов.— Миңа авыл кешеләренең сөйләү теле бик ошый, алар арасыннан картларның тирән мәгънәле, тапкыр һәм үткен телләре аеруча кызыксындыра иде... Әмма бу гадилекнең эчке мәгънәсенә һәм «серенә» соңрак кына төшендем. Гадилекнең дә төрлесе була икән бит! Минем кайбер очерк һәм язмаларымның теле эчтәлекнең тирән мәгънәсен бирергә көче җитә алмаслык беркатлы, шактый ук примитив тел булып чыкты... Шунлыктан, билгеле, андый тел дулкынландырмый, укучыга көчле йогынты ясый алмый иде... Баштарак язган хикәяләремнең дә теле канәгатьләндермәде».

Бу хакта күп фикерләр әйтелгән. Пушкин, мәсәлән, әдәби телне халык теле дәрәҗәсенә төшерү түгел, ә бәлки халык телен әдәби тел югарылыгына күтәрү максатын куя. М. Горький халык телен «чи» тел, әдәби телне мастерлар тарафыннан эшкәртелгән тел, ди. Гомәр ага Бәширов, әйтелгәнчә, тел диңгезендә бер аркылы, бер буй йөзеп, аның төбенә чума-чума, энҗе-мәрҗәннәрне күп җыйды, шулар ярдәмендә югары художестволы әсәрләр иҗат итте. «Намус» романы — шуның бер үрнәге. Әмма анда да вакыт-вакыт югары стильгә күбрәк табыну бар шикелле. Ә инде «Туган ягым — яшел бишек» тә тел чамасын саклау нык сизелә.

Боларның барысы да телнең, матур әдәбият стиленең эчке мөмкинлеген, җаен, рухын аңлап эш итәргә кирәклекне искәртә. «Тел — мая, мая булмаса — зая»,— ди бит халык.

Соңгы вакытта прозаикларның тел чирәмен актарырга җиң сызганулары сизелә. Әмма кайберәүләр тәтигә кызыккан баланы хәтерләтә. Яки болын чәчәкләренә ярсып ташланучыга охшыйлар. Халыкның «Баллы сүз баш әйләндерә»— дигәнен дә искә алырга кирәк. Бер урынсыз сүз яңа күлмәккә ямаулык салуны хәтерләтеп тора бит ул.

Соңгы вакытта тәнкыйтьчеләрнең проза әсәрләренә җитди, тирән, объектив анализ ясаулары сизелә. Ә менә сәнгатьчә осталык, тел, стиль мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләр, кызганыч, аз языла. Ә бит Г. Исхакый, Ш. Камал, Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ә. Еники, А. Расих, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Х. Камалов һ. б. прозаикларның әсәрләре торле яклап лингвистик анализ ясауны көтеп тора. Моның файдасы әдәбият мәйданына килгән бүгенге яшьләргә генә түгел, киләчәк буын өчен дә зур булыр иде.

Язучы әсәрләренең халыкчанлыгын да теленә лингвистик анализ ясамыйча бөтен яклап ачыклап булмый. Башкорт дәүләт университетындагы «Тел чишмәсе» түгәрәге әгъзалары бервакыт бу өлкәдә шактый җитди шөгыльләнде. Алар Г. Ибраһимов әсәрләрендәге тел үзенчәлеген башка сүз сәнгате осталары әсәрләренең тел үзенчәлегенә чагыштырып карадылар. Хәтта ярдәмлекләр (бәйлек, теркәгеч, кисәкчә) куллануда да Г. Ибраһимов әсәрләрендәге халыкчанлык рухының башкаларныкына караганда өстенрәк икәнлеге исбатланды.

Поэзия теленә анализ ясаганда, мисаллар белән эш итү кыен түгел. Ә менә прозада мәсьәлә катлаулырак. Анда мисаллар китерү шактый кыен. Шуңа күрә бу мәкаләдә андый юлны сайлый алмадык.

Билгеле, нинди генә катлаулы, каршылыклы чорда яшәмик, хәзерге таләпчән укучының эстетик зәвыгы һаман үсә бара. Аңа йөрәгенә шифа, күңеленә рухи азык итеп алырлык әсәрләр кирәк. Бу максатка ирешә алмаучылар саны һаман сирәгәя бара икән — бик күңелсез хәл.

Йомгак рәвешендә шуларны әйтәсе килә: безгә җанлылык, халыкчанлык, новаторлык, тел һәм стиль осталыгы, сәнгатьлелек һ. б. сыйфатлар җитешми. Традицион тел-сурәтләү чараларын өзер килеш куллану, үзгәртү генә дә җитми, язучы үзе дә өледән-өле яңаларын иҗат итәргә тиеш. Бер швед филологы Роже Мартен дю Гаранның (1881—1958) «Тибо гаиләсе» исемле бөтен дөньяга билгеле булган күптомлы романының 1817 битенә лингвистик анализ ясый. Һәр биттә бер яңа сүз-образ булуын исбат итә.

Боларның барысы да хәзерге прозаикларны нык уйланырга мәҗбүр итә. Ничек кенә булмасын, янә бер мәртәбә кабатлыйк: әдәби әсәрнең эстетик йогынтысы көчле булырга тиеш. Күчерелмә мәгънәдә әйтсәк, яфраклары коелып, шәрә агач хәлендә калмасын хәзерге татар прозасы.

**Суфиян ПОВАРИСОВ,**
филология фәннәре докторы, язучы.

# РУХИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗНЕ САКЛАУЧЫЛАР

Һәр халыкның тарихын, мәдәниятен һәм тормышын өйрәнгәндә аның фольклоры белән танышу зур урын тота. Себернең төп халкы булган татарларның рухи мәдәниятен өйрәнгәндә дә бу фикер шик уятмый.

Себер татарлары гасырлар дәвамында төрле жанрлардан торган бай эчтәлекле фольклор мирасы иҗат итә һәм аны кадерләп саклап килә. Бу мираска аларның борынгы бабаларыннан калган риваятьләр, дастаннар, мәкальләр, табышмаклар, лирик җырлар, бәетләр, тарихларында тирән эз калдырган шәхесләрнең үз халкы кичергән төрле вакыйгалар турында сөйләкләре һ. б. жанрлар керә.

Себер татарлары фольклорында алар яшәгән мохит, реаль чынбарлык, халыкның тормыш-көнкүрешләре чагыла. Мәсәлән, фантастик әкиятләрендә билгеле булган конкрет шартларда алар кулланган эш кораллары, кием-салым, аш-сулары искә алына. Аларның бу әкиятләре һәм кайбер башка жанр әсәрләрендә мифологиясе һәм дини карашларында исламга кадәр яшәгән ышанулары калдыкларын күзәтергә мөмкин. Бу әсәрләрдә сөйләм телендә күптән кулланылудан чыккан борынгы төрки сүзләрне, сүз тезмәләрен, идиоматик аңлатмаларны очратабыз. Мондый мәгълүматлар себер татарларының тарихын, телен, этнографиясен өйрәнүче галимнәр өчен бик әһәмиятле.

Күренекле тюрколог В. Радлов (1837—1918) «Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» дип аталган фәнни хезмәтенең дүртенче томын себер татарлары фольклоры үрнәкләренә багышлаган иде. Аның кыйммәтле мирасыбызны, себер татарлары сөйләшендә булган фонетик, лексик һәм башка үзенчәлекләрне саклап, академик транскрипция белән китерүе аеруча әһәмияткә ия.

Тубыл-Иртеш татарларының байтак халык иҗаты үрнәкләре көнчыгышны өйрәнүче Н. Катанов (1862—1922) тырышлыгы белән дөнья күрә. Бу үрнәкләр арасында: «Тубыл татарларының Күчем һәм Ермак турындагы риваятьләре», «Тубыл татарларының кыргыз (казакъ — С. И.) халкының килеп чыгышы турындагы риваятьләре», «Тубыл татарларның 1572 елда Искәр шәһәренә ислам дине таратучыларның килүе турындагы риваятьләре», «Тубыл татарларының дәһшәтле патша Тамерлан (Аксак Тимер) турындагы риваяте» бар.

Тубыл татарларының Күчем хан турындагы кайбер риваятьләре, җырлары революциягә кадәр Себердә урыс телендә чыккан вакытлы матбугат («Тобольские губернские ведомости», «Сибирский листок» газетлары) битләрендә дә басылган.

Совет дәверендә Себер татарлары халык авыз иҗатын җыю, аларны бастырып чыгару эшенә Хәмит Ярми, Флора Әхмәтева һәм башка галимнәребез зур өлеш кертте, шуның нәтиҗәсендә унике томлы «Татар халык иҗаты» җыелмасында Себердә барлыкка килгән фольклор җәүһәрләребез дә мәртәбәле урын алды. Мин бу мәкаләдә әнә шундый галимнәргә булышкан, асыл байлыгыбызны саклап яшәгән аз билгеле якташларым турында мәгълүматлар бирергә телим.

Себердәге милләттәшләребез арасыннан революциягә кадәр үк буыннан буынга күчеп килгән зур рухи кыйммәткә ия мирасыбызны саклаучы талантлы шәхесләр үсеп чыга. Шундый шәхесләрнең берсе — Ситдыйк Зәйнетдинов (1854—1927).

Фәнни җәмәгатьчелеккә Ситдыйк Зәйнетдинов төрле төрки халыклар тарихын, аларның шигъри әсәрләрен, риваятьләрен яхшы белгән шәхес буларак билгеле. Төрки халыклар арасында киң таралган «Идегәй» дастанының Себер вариантларыннан берсен 1919 елда татар журналисты Н. Хәкимов С. Зәйнетдинов авызыннан язып ала. Ситдыйк 1854 елны Тара өязе Бохар волостенда урнашкан Аубаткан авылында (хәзерге Омск өлкәсенең Большеречье районы) туган. 1880 еллар башында ул үзенең гаиләсе белән Аубаткан авылыннан ерак булмаган Еланлы авылына күчеп яши башлый. Аның бабасы, әтисе һәм Ситдыйк

үзе жир эшкәртү, терлекчелек белән бергә йөк ташу белән дә шөгыльләнгәннәр. Ситдыйкка сәүдәгәрләр йөге белән Өркет, Томск, Төмән, Казан, Нижний Новгород, Урта Азия шәһәрләрендә һәм казакъ сахраларында булырга туры килә. Атналар, хәтта айлар буена сузылган бу ерак юлларда Ситдыйк төрле төрки халыкларның телләрен, гореф-гадәтләрен, фольклорын өйрәнә. Улы Газим Зәйнетдинов сөйләве буенча, Ситдыйк абзый кызыклы вакыйгалар, тарихи шәхесләр турында ишеткәннәрен үзенең кечкенә кесә дәфтәренә теркәп бара торган булган. 1947 елның август аенда Еланлы авылында, 1953 елның маенда Омск шәһәрендә очрашканда Газим «Идегәй» турындагы җырны әтисе авызыннан 1890 елларда ишетүе турында сөйләде.

Ситдыйкның төрле төрки телләрне өйрәнүгә, үзләштерүгә сәләте көчле була. Аның хакында: «Начар булса да, ана телендә укый һәм яза белгән»— дигән раслау дөрес түгел. Чынбарлыкта ул мәдрәсәдә гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнгән, татар, казакъ, үзбәк, башкорт телләрендә яхшы сөйләшкән, шулай ук урыс телен дә яхшы белгән. Ситдыйкның якын танышлары әйтүенчә, аның искиткеч көчле хәтерендә Себер татарлары тарихына кагылган бик күп вакыйгалар турында мәгълүматлар сакланган. Еланлы авылы олы буын кешеләре Әсма Шәехова, Мөнзир Исхаковлар сөйләвенчә, аның китап киштәсендә Әбелгазыйның «Шәҗәрәи төрек» әсәре һәм татар мәгърифәтче галимнәре Ш. Мәрҗани, К. Насыйри хезмәтләре дә була.

Үткен сүзлелеге, зиһене белән Ситдыйк Тара өязендә генә түгел, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә, шулай ук казакълар арасында да билгеле булган. Ләкин аның татар мәдәнияте тарихында хөрмәткә лаек урын алуы төрки халыклар арасында киң таралган «Идегәй» эпосын яхшы белүе аркасында була. Мәгълүм тюрколог А. Самойлович Ситдыйк хакында: «Идегәй» турындагы риваять варианты тапшыручының ораторлык таланты аның халык авыз иҗаты әсәрләрен нык саклаучы көчле хәтергә ия булуын һәм импровизаторлык сәләтен күрсәтә. Бу нәфис сәнгатькә һәм үз халкы тарихына фидаиларча хезмәт итүче Көнбатыш Себер игенчеләреннән чыккан шәхеснең тормыш юлын һәм эшчәнлеген җентекләп өйрәнүгә Себер ягы белән кызыксынучы татар тикшеренүчеләренең игътибарын җәлеп итүне таләп итә»[1],— дип язган иде.

Ситдыйк Зәйнетдинов 1927 елны үлгән һәм Еланлы авылы зиратында җирләнгән.

Себер татарларының рухи мәдәниятен үстерүгә күп көч сарыф иткән шәхесләр арасында Вәкил Елмәт улы Ярмөхәммәдов та (1881—1967) бар. Ул хәзерге Төмән өлкәсенең Тубыл районы Торбы авылында туган. Бабасы, әтисе һәм үзе дә игенчелек, сунарчылык, балык тотучылык белән шөгыльләнгәннәр. Вәкилнең Ярмөхәммәдовлар сөйләве буенча, XVI гасырда Күчемханның вассалы булган татар морзасы Каранча ыруыннан чыккан. Шул сәбәптән Вәкилнең бабалары Каранчаев (русча Каранаев) фамилиясен йөрткәннәр. Иван IV Себер ханлыгын көч белән үзенә буйсындырганнан соң Каранчаевлар йомышлы татарлар катламына кереп, егерме биш ел буена патша хезмәтен үтәп килгәннәр.

Башлангыч мәктәпне бетергәч, Вәкил Торбы мәдрәсәсендә укый. Җәлид мәдрәсәсенә әйләнгәнлектән, анда дини дәресләр белән бергә гарәп, фарсы, төрки телләр, шулай ук математика, җәгърәфия, тарих һәм кайбер башка фәннәрдән дә сабак бирелә. Торбы мәдрәсәсен уңышлы бетергәннән соң, Вәкил ике ел дәвамында Троицк шәһәрендә урыс гимназиясендә укый. Шәһәр тормышы, урыс сыйныфташлары белән якын элемтәдә булу Вәкилгә урыс телен яхшы үзләштерергә мөмкинлек тудыра. Монда ул Пушкин, Лермонтовларның шигырьләре, Толстой һәм башка урыс язучыларының хикәяләре, повестьлары белән таныша. Кызганыч ки, гаиләсенең матди хәле авыр булу сәбәпле, Вәкилгә гимназиянең тулы курсын укып бетерергә туры килми.

Вәкил Ярмөхәммәдов Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша, әсир төшеп, биш ел буе Германиядә яши. Анда ул немец телен яхшы үзләштерә. Германиядән кайтканнан соң, гомеренең ахырына кадәр туган авылы Торбыда яши. Илдә күмәкләшү башлангач, авылдашлары аны яңа оешкан колхозга рәис итеп сайлыйлар.

Вәкил яшь вакытыннан ук туган халкының авыз иҗаты белән, бигрәк тә Тубыл татарларының фантастик әкиятләре һәм бәетләре белән кызыксына. Аларны даими рәвештә җыйнап җирле сөйләш телендә язып бара. Туплаган материалларын җыентык итеп бастыру турында хыяллана. Ләкин Бөек Ватан

[1]Самойлович А. Н. Вариант сказания о Едигее и Тохтамыше. Тюркологический сборник 1972. М., 1973. 196 бит.

сугышы елларында аның бу материалларының күбесе югала. Шулай да Вәкилнең күп еллар буе җыйган һәм үзе тарафыннан тулыландырылган «Сихерле лампа», «Хәсән батыр», «Саран бай» һәм башка әкиятләре олы һәм урта буын якташлары арасында таралып, тулысынча халык иҗаты әсәрләренә әйләнеп өлгерә.

Миңа 1961 елның җәендә Тубыл шәһәрендә, шулай ук Торбы авылында Вәкил Ярмөхәммәдов белән очрашырга туры килде. Бу очрашулар вакытында аның авызыннан берничә фантастик әкиятне, тел үзенчәлекләрен саклап, язып алган идем. Кызганыч ки, себер татарларының рухи мәдәниятен җанландыруда зур әһәмияткә ия булган бу материалларның әле һаман дөнья күргәннәре юк.

1920—1930 елларда Тубыл татарлары халык иҗатын үстерүгә зур өлеш кертүчеләрдән, һичшиксез, Тубыл районы Коллар авылында яшәгән Сабир Сагачиевны исәпләргә мөмкин. Бу гади авыл кешесенең чын сатира һәм юмор хисләре белән сугарылган кыска дүртьюллыклары бик тиз арада халык арасында таралып, күпләрнең рухи милкенә әйләнә барган. Аның җырлары авылда, колхоз тормышында, җәмгать оешмалары эшендә, көнкүрештә очраган житешсезлекләргә каршы юнәлдерелә, еш кына аерым кешеләрнең кире сыйфатларын тәнкыйтьли. Әйткәннәрне дәлилләү өчен берничә мисал китерик.

Колларда колхозчыларның җыелышы булып, анда элекке колхоз рәисен начар житәкчелек итүе сәбәпле эшеннән чыгаралар. Сабир Сагачиев җыелыштан соң яңа сайланган рәискә мөрәҗәгать итеп болай җырлый:

*Яңа утырган претсетател,*
*Яхшы кылган эшеңне,*
*Яхшы кылмасаң эшеңне*
*Сынтырырлар тешеңне.*

*Яңа утырган претсетател,*
*Яхшы кылган эшләрең.*
*Яхшы кылсаң эшләреңне*
*Алтын пулар тешләрең.*

Китерелгән юллар Колларда булган вакыйгага ишарә була. Элекке рәис колхозчылар белән талашып, тешен сындырткан булган.

Колхоз рәисе колхозчы Пәткуллага ындыр табагын себерү өчен себеркеләр хәзерләргә куша, ләкин тегесе бу эшне начар башкара. Бу хәлгә карата Сагачиев:

*Пәткулла себертке пайлайты,*
*Правлениянең пойрыгы.*
*Пәткулланың себерткесе*
*Кара сыер койрыгы,— дип җырлый.*

Илебездә үзгәртеп кору, хөррият җәелгән заманда себер татарларында да үзаң, үз халкының килеп чыгышы, тарихы, мәдәнияте, теле, иҗаты белән кызыксыну үсте. Соңгы елларда алар арасында ана телендә шигырьләр язучылар да күренгәли башлады. Шундый шәхесләрдән күп еллар укытучы һәм дәвалаучы булып эшләгән Майра ханым Фәхретдинованы күрсәтер идем.

Ул 1918 елны Төмән өлкәсе Яркәү районындагы Карагай авылында туган. Балалык һәм яшьлек еллары искиткеч матур табигатьле Тубыл елгасы буенда урнашкан шул авылда үтә. Күңелендә туган җылы хисләрен Майра түбәндәге юллар белән тасвирлый:

*Карагайның Тал елгасы*
*Цылтырап аккан сулары,*
*Карагайта үскән кысларның*
*Сифа, матур пуйлары.*

*Тал елгасының ярлары,*
*Пиек төсмәрлек түгел.*
*Карагай ауыл исемә төшсә,*
*Янем түсәрлек түгел.*

М. Фәхретдинова язмалары профессиональ күзлектән караганда әле камиллектән ерак булсалар да, туган ягы Себернең мәңге яшел урманнары, киң далалары, зур һәм кечкенә елгалары белән илһамланып, чын күңелдән язылулары аша укучылар дикъкатен үзләренә тартып торалар. Ул Себер шәһәрләре, аларда барган зур төзелешләр белән горурлана, шул ук вакытта кайчандыр

гөрләп яшәгән татар авылларының «перспективасыз» саналып, хәрабә хәленә калуына, аларда гомер кичерүче карт-корыларның авыр язмышларына кайгыра.

Хәзерге Тубыл шәһәре Себернең бер промышленность һәм культура үзәгенә әйләнде, берничә ел элек монда татар педагогия училищесы һәм Тубыл педагогия институты каршында татар урта мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү бүлеге дә бар иде. Үз вакытында Тубылда М. Фәхретдинова укып белем алган. Тубылның үсеше, анда яңа биналар төзелү Майраны горурландыра, аңа Тубыл һәм Себер турында яңа шигырьләр иҗат итү өчен илһам бирә.

Сабир Сагачиев, Майра Фәхретдиновалар халык иҗаты хәзинәсе белән азыкланып, шуннан илһам алып, үзләре дә иҗат эшенә керешә. Шул ук вакытта алар Себер татарлары фольклор үрнәкләрен җыюны дәвам итә һәм якташларының кадерле мирасын гомум милли мәдәниятебез үрнәкләре тупланган Казанга тапшыра бара.

Себер татарлары фольклорын фәнни өйрәнү совет заманында аны җыю, эшкәртү, бастырып чыгару өлкәсендә татар фольклорчылары тарафыннан байтак эш башкарылды. Бөек Ватан сугышы алдыннан Иртеш-Тубыл буйларына Казаннан берничә экспедиция оештырылган иде. Бу эшләр сугыштан соңгы елларда да дәвам итте.

1954 елны Казанда күренекле язучыларыбыз Г. Бәширов, А. Шамов, Х. Ярми тарафыннан бастырылып чыгарылган «Татар халык иҗаты» китабында һәм 1959—1967 елларда Нәкый Исәнбәт тарафыннан җыеп төзелгән 3 томлык татар халык мәкальләрендә кайбер себер татар фольклоры үрнәкләре дә дөнья күрде. Татар фольклорының унике томлыгы басылу мәдәни тормышыбызда аеруча зур вакыйга булды — анда да себерлеләр иҗаты саллы урын били. Ләкин аларда әсәрләр себер татарларының төрле этнографик төркемнәре шивәсендә түгел, әдәби телебездә тәкъдим ителде. Нәтиҗәдә, себер татар фольклор жанрларының фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләре бөтенләй югалды, ә бу хәл инде себер татар фольклор материалларының фәнни әһәмиятен аңлау һәм эчтәлеген тулысынча ачуга комачаулык ясады. Күренекле язучыбыз һәм галимебез Галимҗан Ибраһимов исә халык авыз иҗаты үрнәкләрен ничек җыярга кирәклеге турында 1926 елда: «Җыйган вакытта һич нәрсәне үзгәртмәү, бозмау, халык авызыннан ничек ишетелгән, шул көенчә язып алу — беренче шартдыр. Бу мәгълүмне әйтүем шуның өчен: кайберәүләр моны үзләренчә чибәрләп, шомартып язалар. Моның белән бөтен кыйммәте югала. Кайдан, кемнән, нинди кабиләдән, кайсы районнан алынганын, әлбәттә, әйтеп җыярга-язарга кирәк. Моның белән бер үк нәрсәнең төрле җирдә ничек йөргәнен ачарга мөмкинлек туадыр. Без, үзебезнеке дип, татар әдәби телен кулланган кабиләләрнекен җыярга тиешлебез: Казан татарлары, Касыйм татарлары, мишәрләр, алатырлар, тәмәннәр, типтәрләр... Җыйганда имланы матбугатча түгел, бөтенләй тик ишетелгәнчә язмау аркасында кабиләләрнең сөйләшүләре аерылмый кала»[1],— дигән иде.

Себер татарлары халык иҗаты — бай эчтәлекле. Ләкин ул әле һаман тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Мәсәлән, себер татарларының Бөек Ватан сугышы вакытында немец-фашистларына каршы сугышларда күрсәткән батырлыкларын чагылдырган бәетләр бөтенләй диярлек игътибардан читтә калган. Көнбатыш Себернең аерым төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребезнең, шул исәптән «саз арты» татарларының һәм бараба татарларының фольклорларын өйрәнү канәгатьләнерлек түгел.

Шунлыктан себер татар халык иҗаты материалларын җыю, аларны фәнни эшкәртү һәм махсус җыентыкларга кертеп бастыру эше тик фольклорчыларның гына түгел, тарихыбызны, этнографиябезне телән өйрәнүчеләрнең дә актуаль бурычы булып тора.

**Суфия ИСХАКОВА,**
филология фәннәре кандидаты.

---

[1] Ибраһимов Галимҗан. Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы.— «Безнең юл», № 5—6. 38 бит.

Флера Баязитова

# КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ЙОЛАЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛА ҖЫРЛАРЫ

Керәшеннәр — христиан динендәге милләттәшләребез татар халкының бик үзенчәлекле бер этнографик төркемен тәшкил итә. Алар Татарның төп массасыннан дини яктан берникадәр аерымланып яшәгәннәр һәм телдә, традицион йолаларда борынгылыкны саклаганнар, бигрәк тә туганлык мөнәсәбәтләренә, кием-салымга, бәйрәмнәргә, календарь һәм туй йолаларына караган атамалары үзенчәлекле.

Традиция латинча «тапшыру, сөйләп бирү»не, ягъни гасырлар тирәнлегеннән дәвам итеп, бер буыннан икенчесенә тапшырылып, бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән гадәт-йолаларны, әхлак һәм иҗтимагый-эстетик нормаларны аңлата.

Керәшеннәрдә традицион йолалар нык саклаfamнган, дип әйтсәк тә, аларның күбесе инде бүгенге көндә күзәтелми, әмма өлкән буын кешеләре аларны әле дә әйбәт хәтерли. Шуның өчен без бүген күбрәк халык хәтерендә сакланган мәгълүматларга таянабыз.

Традицион, ягъни халык йолалары фәндә икегә бүлеп йөртелә: гаилә йолалары һәм елның төрле фасылларына бәйле йолалар, бәйрәмнәр.

Керәшен татарларында ел фасылларына караган, табигать күренешләренә бәйле төрле йолалар, гореф-гадәтләр бик кызыклы. Алар борынгыдан килгән ышануларга нигезләнеп, күмәкләп, бөтен авыл халкы катнашында үткәрелә торган булган.

Шыйлык — яз көне карлар бетеп җир кипкәч, чәчү алдыннан кырга чыгып үткәрелә торган йола. Күп кенә авылларда шыйлык үткәрү өчен билгеләнеп куелган урын булган. Ул авыл башындарак тигез, матур җирдә, яки кырдагы берәр чишмә яки күл буенда чирәмлектә үткәрелгән. Шыйлык үткәрелә торган көнне иртә белән бәйрәмчә киенгән ир, гаилә башлыгы жилпучка тары, солы, арыш һ. б. чәчү орлыклары салып, шулай ук йәшел төскә буялган йомырка һәм сөт ашамлыклары: май, эремчек, сөзмә, катык алып, кырга, шыйлык үтәсе урынга юнәлә. Алып килгән сөт ашамлыкларын бер кисмәккә тутырып, шунда йомыркаларны турап салгач, җыелган кешеләргә савытлар белән өләшеп биргәннәр. Ашаганнан соң, ирләр кояшка таба тезелеп басып, «келәү итә», ягъни үзләренең теләкләрен әйтәләр һәм әкренләп өйләренә таралышалар.

Шыйлыкның икенче бүлеген хатын-кызлар дәвам иттерә. Төштән соң һәрбер өйдән карт әбиләр, яшь киленнәр, бәйрәмчә матур итеп киенеп, шул ук урынга җыелышалар. Алар шыйлык урынына зур табаклар белән сөттә пешкән тары яки ясмык боткасы алып бара. Шыйлыкның «башлыклары» — олы яшьтәге картлар килеп, табакларны тотып, тагын «келәү итәләр». Шул вакытта яшь киленнәр башларын иеп, картларны хөрмәтләп басып торалар. Шуннан соң хатын-кызлар җыелып утырып ашыйлар, туйганчы сөйләшеп, күңел ачып кайтып китәләр. Шыйлыкның эчтәлеге менә шуннан гыйбарәт. Шыйлык — төрки сүз, сыйлык дигән сүздән үзгәртелгән, аның шул мәгънәсе Башкортстанның Бакалы районы керәшеннәрендә һәм Идел буендагы башка халыкларда сакланган. Мәсәлән, чувашларда шилек, шильак, мариларда шилык ишек алдында зур итеп әзерләнгән табын яки туй мәҗлесен белдерә.

Чүк, чүк итү — корылык вакытында яңгыр яусын өчен дип, кырда ботка пешереп, су сибешү йоласы. Җәй көне озак вакытлар яңгыр яумый торса һәм

---

Флера БАЯЗИТОВА (1942) — *филология фәннәре кандидаты, «Керәшен татарлары сөйләшләрен чагыштырып өйрәнү» монографиясе һәм башка гыйльми хезмәтләр авторы. Казанда яши.*

игеннәр һәлак булу куркынычы туса, елга буена төшеп, зур казан асып, боламык пешергәннәр. Елга буенда яки «келәүле кое» янында үткәрелә торган бу йоланың ахыры, янгыр яусын дип, су сибешү белән тәмамлана.

Казан арты авылларындагы кайбер керәшен сөйләшләрендә чүк бәйрәме күп кеше катнашында үткәрелә торган бәйрәм, җыен мәгънәсендә дә кулланыла, мәсәлән Әрнәш чүге, Тупылат чүге һ. б. Моңа охшаган йола һәм аны белдерә торган сүз чуваш телендә дә бар: учук, чук, чүкләмә. Мари телендә: цок һ. б. — игеннәр чәчкәнче кырда корбан чалып теләк теләү.

Борынгы ышануларга нигезләнгән мондый йолаларның һәм аны белдерә торган сүзләрнең татарларда гына түгел, ә күршедә яшәгән чуваш, мари, удмуртларда да күзәтелүе шактый кызыклы күренеш. Күрәсең, бик борынгы заманнарда төрки йолалар Идел буе халыкларының күпчелеге өчен уртак, бергәләп башкарыла торган булгандыр, дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Корбан (керәшеннәрдә ул «корман» дип әйтелә) төрле бәла-казалардан саклану өчен кырга чыгып терлек суеп, ботка пешереп теләк теләү. «Корман» кешеләр һәм терлекләр имин, ел килеше әйбәт булсын һ. б. теләкләр белән үтәлә торган булган.

Ак балык корманы — корбанга балык чалып үткәрсәң дә, дөрес дип исәпләгәннәр. Шуннан татар телендәге корбан балык (лещ) сүзе калган булырга тиеш.

Тавык корманы — корбанга тавык суеп теләк теләү.

Үгез корманы, сарык корманы — корбанга үгез яки сарык чалып «келәү» итәләр. Корбанга ак төстәге терлек килешә дип, ак бозау яки бәтиләрне корбан өчен калдыра торган булганнар.

Югарыда искә алынган борынгы йолалар хәзер инде халыкның хәтерендә генә саклана. Ә менә нардуган, җапырак бәйрәме (тройцын), питрау, май чабулар әле соңгы елларда да күпчелек авылларда бәйрәм ителәләр иде.

Нардуган. Ул кыш көне, декабрьнең 24-25 ләрендә башлана һәм унике көнгә сузыла. Нардуган көннәрендә, өлкән буын вәкилләре сөйләвенчә, төрлечә күрәзәлек итүләр, кеше танымаслык итеп киенеп, өйдән-өйгә кереп маскарад ясап йөрүләр һәм башка күңел ачу уеннары булган. Нардуган уенының иң көтеп алынганы, күмәкләп башкарыла торганы — йөзек салу.

Әрле дә бирле борыла-сарыла
Кызлар йөри киләп салырга.
Кызлар йөри киләп салырга,
Егетләр йөри йөзек салырга.

Бер өйгә (ул нардуган өе дип атала) кичен егетләр-кызлар җыелып, семьядагы олы, баш бала белән төпчек баланы бәкедән су алып кайтырга җибәрәләр. Су алганда балта белән суны сызыклап, чиләкне агым уңаена каратып алу шарт итеп куела. Суны алып кайтучылар чиләкнең өстен капкачлап, бер дә сөйләшмичә генә кайтырга тиеш булалар. Шулай алып кайтылган су, янәсе, серле көчкә ия була. Сулы чиләкне сәке яки өстәл өстенә куеп, нардуган өенә килгән һәркем үзенең йөзеген яки балдагын чиләктәге суга сала, җырлар әйтә. Уенны алып баручы үзе яки уенда катнашучылардан кем дә булса берәү җырның беренче яртысын әйткәч, чиләктән бер йөзекне тартып алалар һәм җырның икенче яртысын әйтеп куялар. Кемнең йөзеге туры килсә, җыр да шуңа карата әйтелгән булып чыга.

Нардуган көннәрендә «Нардуган бабае» булып, ягъни кеше танымаслык итеп киенеп, өйдән-өйгә кереп, күңел ачып йөрүләр булган, аны шулай ук «аю чикмәне», «бабачы багыты», «кәшери» дип тә әйткәннәр. Нардуган уеннарын хәзерге вакытта өлкән буын вәкилләре сөйләп кенә искә алалар, аны элек тә христиан дине тыйган, нардуган өен — шайтан өе, нардуган уенын шайтан уены дип атаганнар. Мәсәлән, керәшеннәрнең үз араларыннан чыккан шагыйрь Яков Емельянов шигырьләрендә шундый юллар бар:

Җаман эшне — нардуганны
Ич тә искә алмагыз.
Шайтан туе нардуганга,
Кусалар да, бармагыз.

Нардуганны саласыз
Төне белән җыелып.

Нардуганны кылучыга
Шайтан йөри сыенып.

Нардуганда кылanучы
Бик кызганыч тиядер.
Нардуганда кылануны
Шайтан киеме киядер.

Нардуган вакытларындагы төрлечә сынамышлар, өйдән-өйгә кереп күңел ачып йөрүләр — мишәрләрдә, мордва, мари, чуваш, удмуртларда да төрлечә фонетик вариантта әйтелгән нардуган сүзе белән белдерелә.

Бәрмәнчек — урыслардагы «вербное воскресенье» көненә туры китереп яз көне тал бөреләнгәч (ягъни йомшак йонлач «песи» чыгаргач) үткәрелә. Бәрмәнчек дип шушы бөреле тал ботакларын әйтәләр. Аны кичен яки иртә белән кояш чыкканчы су буендагы таллыктан кисеп алып кайталар һәм кичен бер өйгә җыелып, үзара он, йомырка, май китереп ботка пешерәләр, ул — бәрмәнчек боткасы дип атала. Ашагач, яшьләр күңел ачып, бер-берсенә бәрмәнчек белән суккалап урамда йөриләр, тәрәзәләргә бәрмәнчек белән бәргәләп:

Бәрмәнчекәй-чекәй-чекәй
Олы көндә бер күкәй

яки

Бәрмәнчекәй-чекәй-чекәй
Ничә күкәй Бәчкә дәй,—

дип кычкырып, такмаклап йөргәннәр.

Бәрмәнчекне ташларга ярамый, ул изге әйбер дип исәпләнгән, аны әйбәтләп бәйләп чормага (тупыракчага) менгереп куйганнар, яз көне беренче мәртәбә көтү чыкканда аның белән суккалап малларны көтүгә куганнар яки йомырка өстендә утырган каз кәрзиненә салганнар.

Бәрмәнчек бәйрәме, бәрмәнчек сугу йоласы керәшеннәрдә генә түгел, мишәрләрдә («вирба» дип әйтелә) һәм нократ-глазов татарларында («вирба чыбык» дип әйтелә) да бар. Йоланың эчтәлеге дә шул ук, ягъни яз көне тал чыбыгы белән кешеләргә, хайваннарга суккалаганнар, аны изге санап ел буе саклаганнар. Ни өчен соң тал чыбыгы (бәрмәнчек, вирба) изге дип санала, бу йоланың башлангычы кайдан килә? Билгеле булганча, тал агачы яз көне иң беренчеләрдән булып яшәрә башлый, бик матур итеп бөреләр, йомшак йонлач «песи»ләр чыгара. Шул чыбыклар белән суккалап алу, аның яшәрү көчен кешеләргә һәм хайваннарга да бирәсе килү дип аңлатыла, чөнки күп кенә галимнәр шундый ук йолалар борынгы скифларда һәм фракиялеләрдә, праславяннарда да булган дип күрсәтәләр.

Тройцын,财учын бәйрәме яз көне май ахырында яки июнь аеның беренче атнасында үткәрелә, аны халыкта «җапырак бәйрәме», яки «каен бәйрәме» дип тә йөртәләр, чөнки бу бәйрәм нәкъ агачларның яфрак ярган, матурланган чагына туры килә. Ул борынгыдан калган, җәйне каршылау бәйрәме булган.

Тройцыннан бер атна алдан, симек (семик) көнне яшьләр-кызлар урманга барып бер яшь каен агачын сайлап алалар һәм каенга төрледән-төрле тасмалар, яулыклар, ситсылар бәйләп, каен агачын бизәп куялар. Шуннан соң каен агачы аркылы пешкән йомыркалар чөеп уйныйлар. Бу көнне кичен олы кешеләр түгем мәҗлесе (поминки) үткәрәләр, үлгән кешеләрне искә алалар һәм мәҗлестән соң симек болынына җыелып җырлар җырлыйлар. Ә яфрак бәйрәме, тройцын көнне, бер атна алдан бизәлеп куйган каенны авылга алып кайталар, аны урам буенча күтәреп җырлап йөриләр, һәр йорт турысына туктап, биешеп алалар. Кичке якта каенны елга буена алып барып, ботакларын сындырып суга салганнар, яки иген үскән басуга, арыш, бодай басуына илтеп сала торган булганнар. Каен ботакларын суга салган чакта һәркем үзенең теләген әйткән яки аның тиз генә батып китү-китмәвен карап торып, төрлечә юрый торган булганнар.

Май чабу яки кәтәчә чабу бәйрәме урысларның масленица бәйрәменә туры килә. Май чабу көннәрендә матур итеп бизәлгән яхшы атларга утырып, авыл урамнарында «кәтәчә» (кататься) йөргәннәр, ул яшьләрнең күңел ачу, җыр бәйрәмнәренә әйләнгән. «Яшьләр май чапмаса, җитен кыска булыр»,— дип әйтә торган булганнар картлар. Май чабуның үзенең махсус көе һәм җырлары да бар:

Майларны да чапсаң син каты чап
Чана үрәчәләрен шаңгыртып.
Җырларны җырласаң каты җырла
Авыл урамнарын җаңгыртып.

«Җапрак бәйрәме» көнне кичен яшьләр түгәрәк уенга җыела. Түгәрәк уен җырларында бу көнне каен агачын мактап җырлау яңгырый. Менә ул җырларның кайберләре:

Ак та каеннарны җәмле итә
Җапыраккай белән туз гына.
Өстәл өскәйләрен җәмле итә
Ипекәйләр белән тоз гына.

Ай-һай безләр китиек әй китиек
Ай китиек тә каенлыкка барып житиек.
Ай житиек тә ак каен башларын чишиек.
Ак каен башлары уелган,
Анын жапырагы коелган.
Без жырламый кем жырласын
Бар туганнар бергә жыелган.

Жапырагын жарган жәшләр каен
Жәшкәп утырадыр жылгада.
Берләр аерылгач күрешәлмәбез
Айларында түгел лә жылда да.

Ай-һай уйныйбыз без әйләнеп,
Ак каен башларын бәйлибез.
Ишәле диган асыл илдә
Калдык жәйләрне без жәйлибез.

Татарстанның Лаеш районы Ташкирмән авылында тройцын, ягъни яфрак бәйрәме көнне өлкән яшьтәге хатын-кызлар, әбиләр «кала башы» дигән урынга, тау өстенә жыелышып, үзенчәлекле жырлар жырлаганнар. Саф-саф булып тезелеп, кара-каршы басып жырлана торган бу жырлар изге булып санала, аларның сүзләре үзгәртелмичә, буыннан-буынга күчеп килә. Бу жырларның сүзләре дә, көйләре дә бик үзенчәлекле, алар күп кеше тарафыннан башкарыла торган йола жырларының бер үрнәге, бер истәлеге булып тора. Жырлар төрле исемдә йөртелә: «Без килдек», «Чи камыш», «Мәрием», «Жембәки», «Жимчәчәк» һ. б. «Жимчәчәк» — яз көне суга салып, су иясенә бирелә торган чәчәк булган булырга мөмкин, чөнки «жапрак бәйрәме» көненә кадәр жирдән үлән йолкырга, агач яфрагын һәм ботагын сындырырга, шулай ук су коенырга ярамый, дигәннәр, ягъни бу авылның керәшеннәре «жир иманнегә»н (иминлеге), «су иманнегә»н бик нык саклаганнар. Бары тик «жапырак бәйрәме» көнне, жир һәм су ияләренең күнелен күргәннән соң гына, жирдән үлән яки чәчәк өзгәннәр, ягъни табигать байлыгыннан файдаланганнар.

Питырау бәйрәме (Петров день) июль уртасында үткәрелә (14-15). Питырау көнен керәшеннәр генә түгел, татар мөселманнар да яхшы белә, ул авылның жәйге эшләре, халык сынамышлары белән бәйле рәвештә еш телгә алына. Питырау бәйрәменнән соң «печән өсте», аннан соң «урак өсте» һ. б. эшләр ялганып китә.

Питырау көнне яшьләрнең кичке түгәрәк уеннары тәмамлана, бу көнне иң зур, соңгы түгәрәк уен уйналган, ул жырларда да чагыла:

Чуар күке күклидер,
Сука өстендә туктыйдыр.
Безнең уен уйнаулар
Питырау житкәч туктыйдыр.

Уен өсте. «Жапырак бәйрәме» көненнән башлап питырау көненә кадәрге вакытны керәшеннәр уен өсте дип атыйлар. Татар халкының башка төркемнәрендәге кебек үк, керәшеннәрдә жәйге түгәрәк уеннар бик матур жырлар белән уздырылган. Һәр авылның үзенең яраткан жыры, уен көйләре булган, әле хәзерге вакытта да уен көйләрен һәм жырларын хәтерләгән апалар, әбиләрнең ни кадәрле дәрт, моң белән, бердәм рәвештә жырлауларына таң каласың. Апас районы керәшеннәрендә түгәрәк уеннар «уен әйтү» дип атала. Алда әйтелгәнчә, питырау бәйрәме көннәрендә инде «уенны озату» жырларын жырлап, соңгы түгәрәк уеннар уйналган.

И уза, уза ла,
Кулда көмеш туза ла.
Туза тузсын көмешебез,
Уеныбыз уза ла.

Узса узсын уеныбыз,
Утырырбыз аулакта.
Утыртмаслар аулакта,
Апчыгарлар уракка.

Кием-салым ягыннан керәшен татарлары хәзер бүтән милләттәшләребездән аерылмый. Әмма өлкән буын кешеләре арасында әле үзләре сугып теккән, борынгыдан килә торган үрнәкләр белән бизәлгән киемнәрне очратырга мөмкин. Гомумән, керәшеннәр үзләре суккан тукымалардан теккән киемнәрне әле утызынчы елларга кадәр кигән, фабрика товарларын сирәк кешеләрдә генә күрергә мөмкин булган. Үзләре сугып, үзләре теккән күлмәкләрне кайберәүләр әле хәзер

дә кадерләп сандык төпләрендә саклый һәм бәйрәм, туй вакытларында киеп тә йөри. Күп очракта ул киемнәр тәңкәләр тезеп һәм укалар белән чигеп бизәлгән. Сакланып калган борынгы ядкарьләрдән иң күзгә ташланганы — баш киемнәре. Үзенчәлекләр күбрәк хатын-кыз киемнәрендә чагыла.

Кызларның баш киемнәре яшь киленнәрнекеннән һәм өлкән хатын-кызларныкыннан аерылып тора. Яшь кызлар башларына калфак киеп, аның өстеннән ука-чачак бәйләгәннәр. Бик борынгы заманнарда очына чук таккан ак калфаклар киң кулланылышта булган. Ул керәшеннәргә генә хас түгел, гомумән татар халкының борынгы баш киеме булган. Мәсәлән, Чистай, Минзәлә, Алабуга өязләрендә әле XX гасыр башларында да ак калфаклар киелгән.

Ак калфакның кырыйларына, маңгайны каплап торырлык итеп, ука җепләрдән үреп ишелгән чачак бәйләгәннәр. Ул ука чачак дип йөртелә.

Актый калфак белән сары чачак
Маңгай чәчләреңне капласын.
Бер битең ай, берсе кояш —
Яман җилләр какмасын,
Яман күздән ходай сакласын.

Ташкирмәннең чишмәсе
Ага микән боз булып?
Калфак киеп, чачак бәйләп,
Йөреп калдым кыз булып.

Безгә исә, экспедиция вакытларында, соңрак чордагы, кара яки зәңгәр хәтфәгә чигеп, очына чук тагып эшләнгән калфакларны һәм ука чачакларны күрергә туры килде. Мәсәлән, Балык Бистәсе районының Зур Мәшләк авылыннан Елена Гордеева үзенең иптәш кызы белән борынгы киемнәрне киенеп күрсәттеләр.

Баш артына, чәч толымнары өстенә тәңкәләр белән бизәлгән, очына чулпы тагылган чәчкап яки чәчүрем куйганнар, муенга исә мәрҗәннәр белән чигелеп, тәңкәләр тезеп эшләнгән тамакса кигәннәр.

Алабуга районы Иске Бигәш, Иске Үтәгән авылы керәшеннәрендә безгә яшь кызларның баш киеме булган маңгай ука, маңгай тәңкәләрне киеп күрсәттеләр. Ике як чигә турысына тәңкәләр тезеп эшләнгән чигәчә дип аталган киемне яшь кызлар да, өлкән хатын-кызлар да киеп йөргәннәр. Казан арты керәшеннәрендә ул җилкәлек сүзе белән белдерелә.

Яшь киленнәрнең баш киемнәре икенчерәк төрле булган. Туй вакытында махсус «баш бәйләтү» дигән йола булган. Алда әйтелгәнчә, кыяматлык әни, килен буласы кешенең башына мәләнчек (мәләчлек) башны кысып бәйләп куела торган чепчик), аның өстеннән сүрәкә (укалар белән чигеп, биек итеп эшләнгән баш киеме), ике як чигәгә чигәчә яки җилкәлек киертелә. Казан арты керәшеннәрендә иң өстән «түгәрәк яулык» ябылган. Түгәрәк яулык дип аталса да, бу баш киеме дүрт почмаклы булып, кара ефәк җеп белән чигелгән, кырыйларына чачак тагылган, маңгай турысына тәңкәләр тезеп эшләнгән була.

Түгәрәк яулык чиктем мин,
Түгәрәк күзем түктәреп.
Син икәнен белгән булсам,
Карар идем күзем күтәреп.

Алабуга районы керәшеннәрендә әле бүгенге көннәргә кадәр яшь киленнәр баш киеме булган борынгы үрнәкләрне күрергә мөмкин. Ул ука җепләр белән чигелгән, биек итеп эшләнгән баш киеме. Түгәрәк яулык һәм сүрәкә чигүчеләр авылда кадерле кешеләрдән саналганнар.

Сүрәкәләр чиктем киргесез,
Күреп чиккәннәргә биргесез.
Сайлап ярны мин сөймәдем,
Сайлап сөйгәннәргә биргесез.

Сүрәкәләр чиктем исәпләп,
Дүртти почмаккаен пичәтләп.
Әйтәсе сүземне әйтми калдым,
Алдагы көнемне исәпләп.

Олырак хатын-кызлар исә башларына һәртөрле бизәнү әйберләре: чигәчә, җилкәлек, сүрәкәләрне кигәннән соң, иң өстән ак яулык бәйләгәннәр. Ак яулык дип аталса да, ул ике башы күпертеп чигелгән, сөлге сыман сугылган озын ак тукыма булган, аны иң өстән чалма сыман итеп чорнап куйганнар.

Өстән бөркәлә торган ефәк яулыкны дарай яулык дип йөртәләр. Ул гадәттә

кызыл төстәге ефәктән була. Мәсәлән: «Маржыйның сөйгән җегете дарай җаулык бүләк итеп биргән».

Дарай сүзенең мәгънәсе башка төрки халыкларның сүзлеген алып карасаң да, шулай ук ефәк сүзенә барып тоташа. Мәсәлән, нугай телендә «дарьйе» ефәк шәл, комык телендә «дарай тафта — ефәк «дарай гелек» — тафта күлмәк.

Сүрәкә, чигәчәләр, маңгай ука, маңгай тәңкәнең арткы өлешенә сөлге сыман чәчәкле, укалап бизәлгән тукыма беркетелә.

Ул Казан арты керәшеннәрендә — сүрәкә канаты, Алабуга керәшеннәрендә чукул дип атала.

Сөлге сыман итеп сугылган тукыманы (ул тастар дип атала) баш киеме итеп куллану Апас районы керәшеннәрендә күзәтелә. Килен булып төшкәч, башына тастар сарындыру йоласы булган. Килен кеше тастар сарынгач, инде икенче төрле тормыш башланачагын ачык сиземли.

Баш киемнәре генә түгел, күлмәк яки җилән өстеннән киелә торган бизәнү әйберләре дә тәңкәләр тезеп эшләнгән булган. Мәсәлән, Алабуга районы керәшеннәрендә күзәтелә торган мыйтумар яки буйдымар //бутумар//. Ул тукымага өч-дүрт тәңкә тезеп ясалган, аркылыга, бер кулбашыннан икенче култык астына киелә торган булган.

Шунысы кызыклы бутмар //путмар// путемар вариантларында бу сүзнең мишәр сөйләшләрендә дә кулланылуы аның бик борынгылыгын һәм кайчандыр киң кулланылышта булуын дәлилли. Шулай ук көньяк удмуртлар һәм бисермәннәрдә дә бутымар сүзе бар. Казан арты керәшеннәрендә шул ук мәгънәдә кәсилә (хәситә) сүзе кулланыла.

Кәсилә ди бауларың көмеш булса,
Саласың да килмәс муеныңнан.
Сөйгән ди ярларың гүзәл булса,
Чыгарасың килмәс куйныңнан.

Керәшеннәрдә шулай ук күкрәкнең алгы өлешен тоташтан каплап тора торган, тәңкәләр белән бизәлгән күкрәкчә кию дә күзәтелә. Ул Алабуга керәшеннәрендә сакал дип, ә Казан арты керәшеннәрендә түшлек дип атала.

Базарларга барып тәңкә алдым
Хәсиләгә түгел, түшлеккә.
Кызыгыз өчен борлыкмагыз,
Без тотарбыз аны кешелеккә.

Шундый ук тоташ тәңкәләр белән капланган киемнәрдән башкортларда һакал күзәтелә. Ул, тикшерүчеләр фикеренчә, бик борынгыдан килгән кием, аны борынгы күчмә халыклар тормышыннан ук калгандыр дигән фикерләр бар.

Өскә киелә торган киемнәрдән шулай ук кара постаудан билен бөреп теккән әрмәк кигәннәр, хатын-кызларның җәйге киеме җилән шулай ук киң кулланылышта булган. Ул, якалары һәм изүләре укалар белән чигеп эшләнгәнлектән, «ука җилән» дип тә йөртелгән. Шундый җиләннәрне миңа Алабуга районының Иске Бигәш һәм Иске Үтәгән авылларында күрергә туры килде.

Ак киндердән халат сыман итеп тегелгән кием чуба //чыба// дип атала, аны күбрәк төрле йолаларны үткән вакытта кигәннәр. Мәсәлән, кыр келәвендә, бәрмәнчек, чүк боткалары пешерүчеләр чуба киеп пешерергә тиеш булганнар.

Хатын-кыз күлмәкләре күп бала итәкләр ялгап тегелгән, ул калталы күлмәк дип аала. Калталы күмәкләр, аның өстеннән ука-җилән кияр идек, дип сөйли өлкән әбиләр.

Колакка киелә торган сыргалар (алкалар) хатын-кызларның бизәнү әйберләре арасында шулай ук киң кулланылышта булган. Аларны олы сырга, кечти сырга, дип аерып йөрткәннәр. Сырга сүзе борынгы төрки сүз, башка төрки халыклардан башкорт телендә һырга, алтай телләрендә сырга, ызырга, якут телендә ытырга вариантларында кулланыла. Казан арты керәшеннәрендә сыргага ефәк тасма беркетелеп, ул билгә кадәр төшеп, бер сыргадан икенчесенә тоташкан була, ул сырга бавы дип атала.

Сырга ди бауларың билдәндер,
Киемчеләр печеп лә биргәндер.
Бу каншарың белән бу күзеңне
Бер ходаем сөеп биргәндер.

Кулга, бармакларга тәнкәле йөзек, беләккә тәнкәле яки челтермәкле беләзек кигәннәр.

Челтермәкле пар беләзек
Уйды беләккәемне.
Мин киткәчтен кемнәр сөяр
Минем йөрәккәемне.

Керәшен татарларының аяк киемнәре татар халкының башка төркемнәреннән аерылып тормаган. Шулай да алардан искә алып сөйли торган борынгы кием — чарык яки чәрик башмакны (күннән тегелгән баулы аяк киеме) әле бүгенге көндә дә хәтерлиләр. Чәрик сүзе җырларга да кереп калган.

Ишәле урамын йөри-йөри
Чуклы чәригемне туздырдым.
Чуклы чәригемне туздырмадым,
Яшьлек дәверемне уздырдым.

Чәрик /чарик/ сүзләре аяк киеме мәгънәсендә татар халкының башка төркемнәрендә, мәсәлән, мишәрләрдә, себер татарларында, шулай ук алтай, үзбәк, таҗик халыкларында да кулланыла.

Шулай итеп, җәйнен матур көннәрендә чат башларында, су буйларында, ямьле болыннарда оештырыла торган түгәрәк уеннарына, май чабу, питырау һәм тройсын бәйрәмнәренә керәшен хатын-кызлары озын итеп тегелгән калталы (бәби итәкле) күлмәкләр, башларына тәнкәләр тезеп эшләнгән һәм ука-җепләр белән чигелгән баш киемнәре киеп, алмалап сугылган яки чигелгән алъяпкычлар бәйләп чыкканнар. Хәзерге көннәрдә кайбер кешеләрдә генә күреп була торган бу борынгы киемнәрне, үткән гомерләрнең, әбиләрнең, әниләрнең истәлеге итеп, кадерләп сакларга кирәк. Яшь буынга, ул киемнәрнең исемнәрен әйтеп, киеп күрсәтү үзе генә дә ни тора.

Зәй буйларыннан эз киткән,
Ак калпакай кигән кыз киткән.
Ак калпакае сызмалы
Без Якты Күл кызлары.

Ак калфагың кисәнә,
Чугын артка чөйсәнә.
Эчеңдәге җаның ничек,
Безне шулай күрсәнә.

Бу җырны без Зәй районы Якты Күл авылыннан язып алып кайттык. Күрәсез, керәшен татарларының лирик җырларында да борынгы кием-салымнар искә алына һәм без аларны үткән көннәрнең истәлеге итеп таныйбыз.

♣♣♣♣♣♣♣♣♣♣♣

## Сәлам Алишев

# ТАРИХИ БАГЛАНЫШЛАР

Билгеле булганча, мәдәни элемтәләр халыклар арасында бик борынгы заманнарда ук башланган. Бу мәкаләдә исә — Урал буе татарларының Урта Азия халыклары белән булган культура мөнәсәбәтләре XV—XVI гасырлардан башлап Октябрь революциясенә кадәрге дәвердә күрсәтелә.

Казан ханлыгы вакытында татар халкы Урта Азия белән багланышларын Болгар халкыннан мирас булып калган традицияләр нигезендә дәвам иттергән. Ул элемтәләр икътисади өлкәдә дә, культура өлкәсендә дә булган. Мисалга, Һинд солтаны үзбәк Бабыр ханның 1532 елда Мәскәүгә, Казанга илчеләре килгән. Казаннан 1549 елда Боерган сәет Бохарага барган. «Үзбәкстан ССР тарихы»нда: «Күп нәкышлар һәм шигырьләр язган кеше буларак, Шәйбани хан тарафыннан Голәм Шади Казан ханы Мөхәммәт Әмингә җибәрелгән. Казан шагыйре Мөхәммәдъяр Галишир Нәваи әсәрләрен яхшы белгән», — дип язылган. Көнчыгышның классик шигърияте белән татарлар Урта Азиядә танышканнар. Төркестан сәүдәгәрләре Идел буенда күп һәм еш булганнар. Алар исеме белән Казанның бер елгачыгы таҗик аталып йөргән. Шул ук вакытта Болгар-Казаннан алынган «болгари» сортлы күн Урта Азиядә дә эшкәртелгән. Казан архитектурасында да Урта Азия йогынтысы булган. Чыганакларның азлыгы сәбәпле, ул вакытлардагы культура элемтәләрен бөтен тулылыгы белән ачыклый алмасак та, югарыдагы фактлар мондый мөнәсәбәтләрнең нык булуын күрсәтә.

Идел буе Мәскәү дәүләтенә кушылгач, татар халкының Урта Азия белән бәйләнешләре яңа чор кичерә. Ул да үзенә генә хас сыйфатларга ия була һәм Урта Азиянең Рәсәй тарафыннан яулап алынуына кадәр дәвам итә. Бу 300 ел эчендә татарлар белән Урта Азия халыклары культура багланышларында яңа юнәлешләр, формалар туа һәм үсә. XVI гасырның икенче яртысында Мәскәүгә Ташкент, Бохара, Өргәнечтән байтак илчелекләр килә. Шулай ук Мәскәүдән Бохара, Ташкент һәм башка шәһәрләргә илчеләр, шымчылар бара. Бу илчелекләрдә татар йомышлылары зур роль уйный. Алар тәрҗемәче, хатчы, озата баручы, арадашчы һәм илчеләр сыйфатында байтак эш башкара. Мәскәүдә һәм аннан соң Петербургта чит ил эшләре коллегиясендә аларның тулы бер төркеме булган. Дәүләт грамоталары һәм төрле хатлар, эш кәгазьләре Урта Азиягә һәм башка Көнчыгыш илләренә (мәсәлән, Иранга) татар телендә язылган. Аннан килгәннәре урысчага татарлар тарафыннан тәрҗемә ителгән. Мәскәүдән баручы һәм Урта Азиядән килүче илчеләр, сәүдәгәрләр кебек үк, күп вакыт Казанның татар бистәсенә тукталган, ә кайвакыт айлар буена шунда торганнар. Мондый җанлы мөнәсәбәтләр, әлбәттә, ике якның да мәдәни байлыгын арттырган.

XVI йөздә йомышлы татарлар Урта Азиягә илчеләр сыйфатында да йөри башлаган. Мәсәлән, Байбир Таишев, Исәнчура Байкишевләр иптәшләре белән анда барып, дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга әһәмиятле өлеш керткәннәр. Байбир Таишев 1585 елда Хива һәм Бохара илчеләре Хуҗа Мөхәммәт һәм Мөхәммәт Гали белән Мәскәүгә әйләнеп кайткан, ә 1589 елда янә шул дәүләтләргә илче итеп җибәрелгән. Патша архивында XVI гасырда Бохара ханы Габдулладан, Өргәнеч ханы Әҗәмнән, Ташкент ханы Дәрбиштән Мәскәүгә килгән илчеләрнең язмалары, хатлары булган, ләкин хәзергә кадәр сакланмаган.

XVII гасырда илчеләр алмашу, дипломатик аралашу тагын да көчәйгән. 1616 елдан 1747 еллар арасында бары бер Хивадан гына да Рәсәйгә 27 илчелек

---

Сәлам АЛИШЕВ (1929) — *тарих фәннәре докторы, татар һәм урыс телләрендә басылган биш китап авторы. Казанда яши.*

килгән. 1615 елда Хивага йомышлы татар Дәүләкәй Дәүләтхуҗин илче булып бара һәм Рәсәй белән Хива мәмләкәте арасындагы мөнәсәбәтләрне юлга сала. Ул Өргәнечтә дә булып кайта. Тарихи әдәбиятта күбрәк иранлы Гәлимәрдән Даутов һәм Казан татары Йосыф Касыймовларның илчелеге яктыртылган. Аларның икесендә дә байтак татарлар булган. Ә. Даутов биш мәртәбә Төркиягә, Хива һәм Бохарага барып, урыс дәүләтенә зур хезмәтләр күрсәткән. 63 әсирне, шул исәптән, өч татарны Рәсәйгә алып кайткан.

Йосыф Касыймов үз вакыты өчен укымышлы, алдынгы фикерле кеше булган. Ул 1675—1678 елларда Хива, Бохара һәм Һиндстан илләрендә Рәсәй илчесе булып йөри. Күп мәгълүматлар җыя, географик белешмәләр туплый. Белемлелеген ихтирам итеп, аңа анда калырга тәкъдимнәр ясала. Ләкин ул, 18 урыс әсирен сатып алып, Казан аша Мәскәүгә әйләнеп кайта, хөкүмәт алдында тулы хисап бирә. Көнчыгышны төптән өйрәнгән академик В. Бартольд аның турында: Касыймов урыс дәүләтенә Урта Азия һәм бүтән Көнчыгыш Азия дәүләтләре белән мөнәсәбәтләр урнаштыруда зур хезмәт күрсәткән эшлеклеләренең берсе булды»,— дип язды.

XVIII гасыр дипломатлары арасында Котлымөхәммәт Тәвкилев аерылып тора. Ул 1714—1717 елларда Беренче Петр кушуы буенча Урта Азия илләрендә йөреп кайта. Мәскәүдә аннан килгән илчеләр белән үзе сөйләшүләр алып бара. Императрица Анна Иоановна һәм вице-канцлер Остерман 1740 елда Хива илчесе Артык Батыр Разумбаев белән сөйләшүләр алып барганда да ул арадашчы һәм тәрҗемәче вазыйфаларын үтәгән. К. Тәвкилевнең казакъларны һәм башкортларны Рәсәйгә кушу буенча эшчәнлеге дә күпләргә мәгълүм нәрсә.

XVIII гасырның икенче яртысында Бохарага илче булып Мәндияр Бикчурин, Г. Дәүешевлар бара. Казан татары Борнашев дипломатик максатта 1794 елда Бохарада, ә 1800 елда Поспелов белән Ташкентта булып кайта. Алар дәүләтара дипломатик бурычлар гына үтәп калмыйлар, бераз фәнни эшчәнлек белән дә шөгыльләнә. Аларның җыйган материалларында, сөйләгән, язган хисапларында географик һәм этнографик белешмәләр дә бар.

XIX гасырда барлык дипломатик хезмәткәрләр дә диярлек үз эшчәнлекләрен фәнни тикшеренүләр белән бәйлиләр. Шулардан гасыр башында М. Хөсәенов, Ф. Котлымөхәммәтовны, 1850 елларда А. Юнысовны күрсәтергә мөмкин.

Татарларның Урта Азия халыклары белән булган культура бәйләнешләре милләттәшләребезнең сәяхәтнамәләрендә, кулъязмаларында да чагылыш таба. Сәяхәтнамәләре дөнья күргән һәм әдәбиятыбызда киң урын алган «Исмәгыйль сәяхәте» киң билгеле. Исмәгыйль абзый 1751—1774 елларда Урта Азия, Һиндстан һәм башка илләрдә йөреп кайткан. Аның турында махсус әдәбиятта байтак материал булганлыктан, бу урында озак тукталып тору кирәкмәстер. Ләкин шуны әйтергә кирәк: аңа кадәр дә Урта Азиягә сәяхәт иткән һәм андагы шәһәрләр аркылы Мәккәгә хаҗга барган милләттәшләребез булган. Алар сәяхәтнамәләр язып яки матбугатта бастырып калдырмасалар да, күргәннәрен, ишеткәннәрен, минемчә һичшиксез, ватандашларына, авылдашларына җиткергәннәрдер. Сәяхәтләрен тасвирлаучылардан М. Мәдинәи, М. Хөсәениләрне күрсәтергә мөмкин. XVII гасырда яшәгән Янсара Хафиз, XVIII йөздәге Мортаза Галиев, Гали Габдерәшитов, Г. Туймөхәммәтов һәм кайбер башка сәяхәтчеләр турында без бик аз беләбез. Аларның исемнәре Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов һәм кайбер бүтән галимнәрнең телгә алулары буенча гына безгә килеп җиткән. Күбрәк билгеле булганнарыннан 1774—1804 елларда бөтен Урта Азияне һәм Һиндстанны гизеп чыккан пугачевчы Гобәйдулла Әмировны, Җәгъфәр Галиевне, 1820 еллардагы сәяхәтче Мортаза Фәйзуллинны, Бикчуринны күрсәтергә була. Аларның сәяхәте турында хәбәрләр халык арасында язма рәвештә дә, телдән дә киң таралган булган.

Культура бәйләнешләре бигрәк тә мәгариф өлкәсендә нык үскән һәм тотрыклы булган. Бохара, Сәмәркант һәм башка Урта Азия шәһәрләре мәдрәсәләренә татарлар борынгыдан ук, XVIII гасырда бигрәк тә күп барган. Р. Фәхретдиновның «Асар»ында андый кешеләрнең йөзләрчә исемнәре китерелгән. Укыту системасы гәрчә дини-схоластик эчтәлекле булса да, бу мәдрәсәләрдә шәкертләр телләр өйрәнгән, ә сәләтлерәкләре төрле кулъязмалар, китаплар укып шактый тирән белем ала алганнар. Шундыйлардан Тайсуган авылы мөдәррисе Габдрахман Туймөхәммәтевне, Борындыктан Мансур Габдрахмановны, Яңа Әлмәт авылыннан Җәгъфәр Алишины, Курсадан Габденнасыйр Курсавине күрсәтергә мөмкин...

Г. Курсави Бохарада зур тырышлык белән иске кулъязмаларны, борынгы

китапларны, матур әдәбият һәм дини карашларны тирәнтен өйрәнә, шулар нигезендә динне яңарту юлына баса. Аның иseme белән татар иҗтимагый фикер үсешендә туган яңа юнәлеш башлана. Курсави өйрәтүенә кеше язмышының алдан ук күктә билгеләнгән булуына шикләнү, дәреслекне танып белүгә һәм хезмәткә чакыру, кешенең фикер йөртү сәләтенә, аның хезмәте тиешле нәтиҗәләр бирә алуына ышану, кешене беренче планга кую хас. Искелектә катып калган, дини догмаларга каршы чыккан өчен Бохара әмире аны үлем җәзасына хөкем итә. Дуслары һәм фикердәшләре ярдәмендә ул үз иленә качып кайта ала һәм хәзерге Татарстанның Арча районы Курса авылында зур мәдрәсә ачып, балаларны яңача укыта башлый. Аның фикерләре, өйрәтүе киң тарала. Бохарадагы кебек үк, Татарстан җирлегендә дә алдынгы фикерле кешеләр аны яклап искелеккә каршы чыгалар. Бу көрәш дөньяви һәм фәнни белемнәрнең үсүенә юл ача.

Мәдрәсәләрдә төрле кеше укыган. Алар арасында, әлбәттә, фикерен үстермичә, дини караңгылык дөньясыннан чыга алмаган томана муллалар да аз булмаган. Ләкин безне күбрәк алдынгы фикерле, аң-белем алып кайта алган кешеләр кызыксындыра. Дөньяви, файдалы белемнәр таратуда шул ук мәдрәсәләрне бетереп кайткан шәкертләрнең бер өлеше мактаулы эш башкарган. С. Ибраһимов XVIII йөздә үк: «Җир балык яки үгез өстендә тора, дип әйтү — ул әкият, җир әйләнеп йөрүче бер җисем»,— дип язып чыга. Әбүбәкеров тыйб гыйлеме (медицина) буенча күп фәнни белешмәләр җыя һәм фәннәр өйрәнергә чакыра. Б. Шәрипов тарих өйрәнә һәм тарихи вакыйгаларның хронологик таблицасын төзи. Г. Габдрахманов бик күп телләр өйрәнә һәм шуңа башкаларны чакыра, телләр акылны баета, ди. Г. Габделмәннәнов арифметика китабы төзи. Бу өлкәдә ике төбәк кешеләре берләшеп эшли, тырышлыклар уртак була. Идел буе татарлары Урта Азиядә укыйлар да, укыталар да. Ә Урта Азия кешеләре аларны укыта, кайберләре, мәсәлән, Ишнияз Ширниязов, Идел һәм Урал буйларында үзләре мәдрәсәләр тотып сабак бирә, мондагы кешеләрне Урта Азия халкы һәм мәдәнияте белән таныштыралар.

Күренекле татар мәгърифәтчесе, тарихчы галим Ш. Мәрҗани Бохара, Сәмәркант шәһәрләрендә үзлегеннән уку белән шөгыльләнгән. Курсави кебек, ул да андагы мәдрәсәләрдә схоластик укыту белән канәгать булмаган. Борынгы кульъязмаларны, тарихи чыганакларны тирән өйрәнү, аны дөньякүләм танылган зур галимгә әйләндерә. Аның 1865 елда Казанда бастырып чыгарган «Горфател хавакыйн...» хезмәте аеруча әһәмияткә ия. Бу китапта ул Европа тарихчыларына әле билгеле булмаган Көнчыгыш чыганакларына таянып, Төркестан һәм уйгырлар — X—XII йөзләрдәге Караханидлар — тарихын язган. Шулай итеп, Урта Азия тарихын тикшерүгә үзенең зур өлешен кертә.

Татарлар һәм Урта Азия халыклары арасында культура багланышларын үстерүдә үзара китап алмашу, кульъязмалар җыю зур әһәмияткә ия булган. М. Хөсәенов: «Мин 16 ел буена (XVIII гасырның ахыры — XIX гасырның башы) Урта Азиядә, Әфганстан һәм Һиндстанда гарәп, фарсы, төрки, татар һәм үзбәк кульъязма китаплары җыеп, бай көтепханә ясадым, аларның бер өлеше яңа мәктәпләр өчен дөньяви (фәнни) дәреслекләр төзүгә нигез булып хезмәт итә алалар»,— дип язып калдырган. Р. Максудов, Х. Якупов, Ф. Габделгазизов һәм байтак башка кешеләр XVIII гасырның икенче яртысында һәм XIX гасырда да шундый ук эш белән шөгыльләнгәннәр. Ә Дәүләт Галиев Бохарада китап сату-алу эшен оештырган. Ш. Мәрҗанинең Урта Азиядән бик күп китап һәм кульъязмалар алып кайтуы күп кешегә мәгълүм. Ул вакытларда Казанда инде дини китаплар гына түгел, ә бәлки ике төбәк халыкларының да мохтаҗлыгын канәгатьләндерүче фәнни, әдәби китаплар да басыла башлаган. Татар әлифбасы, «Сәйфел Мөлек» кыйссасы, «Йосыф китабы», Низами, Газәли әсәрләре һәм тарихи язмалар басылып чыккан һәм аларның тиражы берничә йөз меңгә җиткән. Бер үк вакытта китаплар, кульъязмалар өстендә уй-фикер йөртү, әдәби тәнкыйть һәм текстологик эш тә алып барылган. Әле XVIII гасырда ук Кәбелгазый Баһадир ханның «Төркиләр шәҗәрәсе» дигән атаклы китабы өстендә Күк Куян авылы мулласы Нигъмәт Максудов, Әстерхан мөдәррисе Ахун Хуҗа, Мәскәүдә Мортаза Тәвкилевлар эшли: носхәләренең күчермәләрен төзиләр, аларны чагыштырып чыгалар, искәрмәләр язалар. Ә татарның беренче мәгърифәтчеләреннән Ибраһим Хәлфин аны җиренә җиткереп редакцияли һәм 1825 елда Казанда нәшер итә.

Урта Азия һәм Идел буеннан чыккан кульъязма һәм басма китаплар һәр ике як халыкларына хезмәт иттеләр, аларны үзара таныштырдылар һәм якынайттылар.

XIX гасырның уртасында, ягъни Урта Азияне Россия яулап алганчы, анда биш меңнән артык татар яшәгән. Алар да кардәшләре арасында культура багланышларын киңәйтүгә, тирәнәйтүгә зур өлеш керткән. Бу багланышларның югарыда күрсәтеп үтелгән формаларыннан тыш, башка төрләре дә булган, әлбәттә. Без монда экономика һәм сәүдә мөнәсәбәтләренә кагылмыйбыз. Бу үзенә бер зур тема. Ләкин әнә шул татарларның XIX йөз урталарында Ташкенттан ерак түгел җирләрдә беренче мәртәбә бәрәңге үстерә башлауларын әйтеп үтәсе килә.

Шулай итеп, Рәсәй белән Урта Азия арасында мөнәсәбәтләрнең үсүендә татарлар билгеле бер роль уйнаган. Культура элементләренең гомумән үсүендә исә барлык халыклар да — үзбәк, татар, урыс, таҗик, төрекмән һ. б. үз өлешләрен керткән. Урыс халкының өлеше һәм йогынтысы исә XIX гасырның икенче яртысыннан көчәеп китте һәм үсә барып, хәлиткеч роль уйный башлады. Урта Азиянең Рәсәй яулап алуыннан (XIX гасырның 60—70 елларыннан) башлап Октябрь революциясенә кадәр чорны без ике төбәк халыклары арасындагы бәйләнешләр үсүенең өченче баскычы дип саныйбыз. Чөнки бу заманда шул өлкәдәге элеккеге юнәлешләрнең һәм формаларның эчтәлеге үзгәрә, аларның яңа сыйфатлары барлыкка килә, яңа формалар һәм күренешләр килеп чыга. Патша самодержавиесе һәм реакцион эшлеклеләре, Кауфман кебек генерал-губернаторлары халыклар арасында дусларча мөнәсәбәтләрне буарга, җирле халыкларны югары культура җимешләренә якын китермәскә тырышсалар да, алдынгы урыс, татар, үзбәк зыялылары массаларга файдалы булган, алар ихтыяҗын канәгатьләндерә торган матди һәм рухи байлыклар тудыру өчен тырыштылар һәм шуның өчен көрәштеләр. Академик В. Бартольд шул чорның культура мөнәсәбәтләренә бәя биреп болай дип язды: «Урта гасырларда Идел ярларына культура Бохара һәм Хивадан китерелсә, XIX гасырда Идел буе татарлары урыслар аркылы Европа культурасы белән танышып, үзләренең Төркестан кардәшләрен агарта башладылар».

Бу чорда электәге дипломатик мөнәсәбәтләр юнәлеше татар халкы вәкилләренең Урта Азиядә урыс дәүләт учреждениеләрендә хезмәт итүләре белән алмашына. Губерна канцеляриясендә һәм башка урыннарда байтак кына татарлар эшли.

Элеккеге сәяхәтчеләрнең башкарган эш формасы фәнни тикшеренү эшләре эченә кереп бетә. Мисал өчен Заһир Бигиевнең Казанда 1908 елда басылып чыккан «Мавәраэннәһердә сәяхәт» дигән китабын алып карыйк. Бу китапта элеккегечә сәяхәтнең ничек баруы турында гына түгел, ә башлыча фәнни белемнәр, тарихи белешмәләр турында сүз бара. Автор шәһәрләр һ. б. объектларны, халык тормышының кайбер якларын күрсәтеп кенә дә калмый, фәнни-тарихи материалларны, үз фикерләрен пропагандалый. XIX гасырның 60-елларыннан Урта Азияне һәм аның халыкларын фәнни өйрәнү, гомумән, нәтиҗәле рәвештә үсеп китә. 1890 елларга инде анда фәнни оешмалар төзергә мөмкинлек туа. 1897 елда Рәсәй географик җәмгыятенең Төркестан бүлеге, 1895 елда Ташкент археологик түгәрәге эшли башлый. Фирганәдә, Сәмәркандтә һәм Сыр-Дәрьяда статистика комитетлары барлыкка килә. Фәнни өйрәнү өлкәсендә татарлардан Бикчурин, Батыршин, Борнашев кебек кешеләр XIX йөздә активлык күрсәтәләр. XX йөз башында аларның саны арта бара. Мирсалих Бикчурин, мәсәлән, Урта Азия шәһәрләренең торышын, архитектурасын, халыкларын, алар арасында һәм Рәсәй белән булган сәүдә торышын өйрәнә һәм шул хакта мәкаләләр бастыра. Галимхуҗа Юнысов XIX гасырның беренче яртысында ук Идел буеннан күчеп, 1870 елларда Ташкентның «хөрмәтле нәсел гражданины» дигән исем ала. Европа культурасын һәм фәнни белемнәрне массалар арасында таратучы доктор-врач Батыршин Ташкент халкында зур абруй казана.

Урта Азия шәһәрләрендә татар мәктәпләре ачылу, татарча, үзбәкчә газета-журналлар чыгару, китаплар бастыру культура багланышларының тирәнәюен, киңәюен күрсәткән яңа тармаклар булып тора. 1873 елда Ташкентта беренче татар мәктәбе, 1886 елда Казалыда беренче (җәдит) татар мәктәбе ачыла. Менә бу яңа методлы татар мәктәпләренең саны 1910 елда Урта Азиядә 89 га җитә. Ә барлык татар мәктәпләренең саны 137 булган. «Аларның төп әһәмияте шунда булды ки,— дип күрсәтә академик Бартольд,— алар йогынтысында башка җирле яки милли мәктәпләр дә берничә елдан соң яңача укыта башладылар». Татар мәктәпләрендә укучылар үзбәк, казакъ, төрекмән, татар, кыргыз балалары булган. Ләкин халыкларның мондый бердәмлегеннән һәм аң-белем алуларыннан курыккан патша хөкүмәте 1911 елда бу мәктәпләрне яба, бетерә башлый. Шул елның 1 гыйнварында чыккан патша указында: үзбәк

балаларын татар укытмасын, татар балаларын үзбәк укытырга тиеш түгел, дип язылган була. Бу инде «Бүлгәлә һәм хакимлек ит» дигән принципны тормышка ашыру иде. Татарларга каршы чыгарылган, аларның Урта Азия халыклары белән туганнарча элемтәләрен кисү юлында эшләнгән чара һәм указларның бу беренчесе генә дә, соңгысы да түгел иде. 1886 елда ук патша хөкүмәте татарларга анда йорт тотарга, җир алырга, предприятиеләргә һ. б. шундый милеккә хуҗа булырга катгый рәвештә тыйды. Бу бик каты закон иде. Шулай булуга карамастан, халыклар арасында дусларча мөнәсәбәтләр дә, культура бәйләнешлары да өзелмәгән. Уку-укытудан башка юнәлешләрдә дә байтак эшләр эшләнгән. Матбугат өлкәсендә бу бигрәк тә ачык күренә.

1870 елда Урта Азиядә беренче газета — «Төркестан хәбәрләре» урыс телендә чыга башлый. Соңрак аның «Төркестан вилаяте газетасы» дип аталган үзбәкчә кушымтасы чыгарыла. Гарәп шрифтлары Казаннан китерелә. Аның хәреф җыючылары да (М. Каримов), редакторлары да (И. Ибраһимов, Ш. Ибраһимов, М. Чанышев) татарлар булган. Генерал-губернатор тәрҗемәчесе Ш. Ибраһимов 1871 елда «1872 елга календарь» исемле беренче үзбәк китабын бастырып чыгара. 1881 елда Казаннан тагын бик күп шрифтлар белән яңа һәм тәҗрибәле наборщиклар Ш. Биккулов, Г. Яушев, Б. Биктимировлар киләләр. Алар тиздән җирле халык телендә матбугат эшен киң рәвештә юлга салалар. Ш. Биккулов монда соңгы көннәренә кадәр (1920 елда үлә) эшли һәм күп санда үзбәк, казакъ һ. б. наборщикларын үз һөнәренә өйрәтә. Аны «үзбәк китабының Гутенбергы» дип атыйлар. Ш. Биккулов һәм аның кебекләрнең эшчәнлеге халыклар мәгърифәтенә хезмәт итү үрнәге ул. Мондый хезмәт рус, үзбәк, татар, казакъ, кыргыз, төрекмән һ. б. халыклар мәдәниятенең үзара баетышуына китерде. XIX гасыр ахырында — XX гасыр башында Урта Азия шәһәрләрендә байтак типографияләр ачыла, урыс, үзбәк, татар, казакъ телләрендә газета-журналлар, китаплар бастырыла. Аларның күбесе демократик юнәлештә була. Бу өлкәдә Урта Азия халкы вәкилләре белән татарлар кулга-кул тотынып эшләгәннәр. Г. Тукайның 80 еллык юбилеендә үзбәк халык шагыйре Гафур Гolәм болай әйтте: «Беренче үзбәк шрифтларын, беренче хәреф җыючыларны биргән, яңа мәдәниятккә юл ачкан татар халкына, аның фидакарьләренә рәхмәтебезнең чиге юк. Яңа заманның беренче укытучылары безгә Татарстаннан килде, бу заман телендә беренче әлифбалар Казанда басылды.»

Урта Азия халыклары әдәбияты белән татар әдәбиятының бәйләнешлары бик киң һәм күп тармаклы. Сәнгать өлкәсендә дә безнең бәйләнешләр тар түгел. Әдәби, үзешчән сәнгать кичәләре, музыка түгәрәкләре оештыру һәм үткәрү эшләре үзбәк, татар, казакъ арасында бергәләп 1900 еллардан башлана. 1911 елдан башлап Урта Азия шәһәрләрендә Г. Кариев җитәкчелегендә «Сәяр», К. Шамил һәм Гыйззатуллина-Волжская җитәкчелегендә «Нур» труппаларының гастрольләре һаман булып торган. Тиздән татар драматургларының пьесаларын файдаланган үзбәк театрлары эшли башлаган.

Үзбәк, казакъ, кыргыз һ. б. халыкларның борынгыдан килгән бай культуралары бар. Аның җимешләре белән татар халкы электән үк файдаланган, үзенеке кебек итеп якын күргән, шагыйрьләре илһам алган. Татар халкының культура байлыклары да Урта Азия халыклары өчен уртак булган, юмарт тәэсир иткән. Татарлар күптән инде Рәсәй дәүләтендә урыс халкына якын яшәгәнлектән, шартлыча Европа культурасы дип аталган яңа дөньяви мәдәниятне алданрак һәм тизрәк үзләштергәннәр. Шуның белән бергә урыс әдәбияты һәм культурасы XIX гасырның икенче яртысында билгеле сәбәпләр нигезендә бик тиз үсеп китә һәм Европадагы башка илләр культурасын өйдәп баручыга әйләнә. Бу мөһим фактның татарларга, алар аша Урта Азия халыкларына хәлиткеч йогынты ясавы табигый хәл.

## Самат Шакир

# ОЧРАШУЛАР

Хәсән Туфан шигырьләрен мин бала вакыттан укып үскән идем. Ләкин 40 елларда аның шигырьләре басылудан туктады. Хәсән Туфанны «халык дошманы булган икән» дип сөйләделәр.

Шактый еллар узды... Туфан әдәбият мәйданында күренмәде. 1949 елның көзендә Арча станциясендә поезд көтеп утырганда элекке Кызыл юл районы, Шура авылының бер егетен — Сәфәргалиев Мөхәммәтгалине күрдем. Ул минем белән кул биреп күреште һәм үзенең яңа гына төрмәдән кайтуын, анда шагыйрь Хәсән Туфан белән очрашуын сөйләде. Мин бик кызыксынып тыңладым, соңыннан сораулар бирдем:

— Сәламәтлеге ничек?

— Сәламәтлеге уртача. Төрмәдә кысанлыгына карамастан, һаман да шигырьләр яза. Без политик тоткыннар түгел, өйдән посылкалар, хатлар ала идек. Ә алар, политик тоткыннар, өй белән элемтә тота алмыйлар. Шуның өчен үзебезгә килгән посылкалардагы сохари, каклаган каз ите, бавырсак, сумса һәм башка ризыклардан аңа да өлеш чыгара идек. Хәсән абый бик рәхмәтләр укый иде һәм: «Бу яхшылыгыгызны үлгәндә дә онытмам»,— дия иде.

Казанга баргач, Язучылар союзына һәм «Совет әдәбияты» журналы редакциясенә кереп бу турыда әйттем. Тик Союзда да, редакциядә дә моңа исләре китмәде. Хәтта «Совет әдәбияты» редакциясендәге бер язучы әле болай диде:

— Туфанның анда язып утырулары нигә кирәк? Безгә төрмә лирикасы кирәк түгел. Халык дошманының шигырен без, мәсәлән, баса алмыйбыз.

Әйе, ул заманда Сталин исән иде, аның «тимер законнарын»нан куркалар иде. Үтә куркыныч, богаулы-чылбырлы болганчык еллар иде...

Шактый вакытлардан соң Хәсән Туфан, акланып, туган якларга кайтты.

Хәсән абый Туфан белән беренче тапкыр очрашу 1957 елның январь аенда, Казанда булды. Бу вакытта «Татар поэзиясе антологиясе» дигән китапны рус телендә бастырып чыгару өчен әзерлек бара иде. Чөнки 1957 елның маенда Ватаныбыз башкаласы Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы булырга тиеш иде. Менә шул декадага алып бару өчен шактый калын — 89 шагыйрьнең иң яхшы әсәрләрен эченә алган китап-антология басылып чыгачак. Бу китап рус теленә тәрҗемә ителеп, рус укучылары өчен дә әзерләнде. Мин, үземнең шигырьләремнең язмышын белү өчен, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясенә кердем. Бүлмәдә, минем каршыда какча яңаклы, озын чәчле, чандыр гәүдәле, кыш булса да өстенә көзге пальто кигән бер кеше басып тора иде. Мине аның белән таныштырдылар:

— Шагыйрь Хәсән ага Туфан,— диде Әнвәр Давыдов. Мин гаҗәпләнеп Хәсән абыйга карап тордым һәм кулымны сузып күрештем.

— Ерак илләрне гизеп кайттым, әле дә ярый, исән калдым,— дип ул минем кулымны кысты. Бу вакытта күзләремнән яшь бөртекләре чыкты. Кулъяулыгымны алып, күзләремне сөртә-сөртә, Хәсән абыйны кочаклап алдым.

— Сезнең шигырьләрне бик яратып укый идем,— дидем һәм аның кайчан кайтуын сорадым.

— Кайтканына байтак булды инде,— дип, аның өчен җавап бирде Әнвәр Давыдов. Хәсән абыйга мине таныштырды:

— Яшь шагыйрь. Инде өч китабы чыкты. Хәзер мәктәп директоры булып эшли.

Хәсән абый, бераз уйланып торгач, әйтә куйды:

— Мин сөргендә чакта «Совет әдәбияты» журналларын кулга төшереп укыганнары арасында синең шигырьләреңне дә укыдым һәм алар миңа ошадылар. Бу турыда Габдрахман Минскийга да хат аша язган идем. Син шул Самат буласыңмыни инде?

— Әйе,— дидем мин.— Шигырьләрем сезгә ошагач, минем өчен зур шатлык бу, Хәсән абый.

Ул яңадан сүзен дәвам итте:

— Яшьләрнең язганнары белән кайткан көннән таныша башладым. Араларында әйбәт язганнары да бар. Татар поэзиясе бик нык үскән, бик шатландым!— дип Әнвәр Давыдовка карады. Шул вакытта «Антология» өчен шигырьләрне тәрҗемә итәргә килгән рус шагыйрьләре бүлмәгә керделәр. Һәм исәнләшеп-күрешеп чыкканнан соң кайбер шигырьләрнең тәрҗемә итү өчен яраксыз булуларын әйттеләр. Шундыйлар рәтенә Әбүзәр Түрәйне дә керттеләр. Хәсән Туфан Әбүзәр Түрәйне яклады.

— Әбүзәрне яхшы беләм мин, шигырьләре әйбәт иде аның. Бәлки, подстрочниклары начар булгандыр, карарга кирәк. Подстрочникларны кабат эшләтеп тәрҗемә итәргә кирәктер... Антологиягә аны кертү ягында торам мин,— диде.

Бүлмәгә унлап шагыйрь керде. Үзара сөйләшә торгач, кичке аш вакыты җитте, иптәшләрнең берсе ашханәгә барырга кирәклеген әйтте. Барыбыз да шуны гына көткән кебек чыгып киттек. «Казан» кунакханәсенең ашханәсенә кердек. Мин Хәсән абый белән бер өстәлдә идем. Үземнең шигырьләремне аңа укып күрсәттем. Ул тыңлап утырды да кайбер шигырьләрне әйбәт диде, ә кайберләрен төзәтергә кушты. Мин төзәтергә булдым. Менә шул вакытта Әнвәр Давыдов:

— Хәсән ага Туфанның әдәбият мәйданына кайтуы безне бик шатландыра!— диде. Мин, шул тәэсиргә бирелеп, Хәсән абыйны кочаклап алдым һәм аның «Ак каен» шигырен күңелдән сөйли башладым:

*Яфраклары яшел ак каенга*
*Юл буеннан аклар килделәр,*
*Ак каенның ярлы авылдашын*
*Билбавына асып киттеләр.*

Шагыйрьнең күзләре яшьләнде. Ул әле Әнвәр Давыдовка, әле миңа карап алды да күзләрен сөртте. Мин аңа бу җырны мәктәптә җыр дәресләрендә, авыл клубларында концертларда бик яратып җырлавымны әйттем. Хәсән абый бераз уйланып торды да, болай диде:

— Күптән язылган җыр инде ул. Минем үземә дә ошый. Музыкасын Мәсәлим Вәлиев язган иде. Утызынчы елларда бик популяр җыр иде. Мәрхүмә Луиза апагыз да гел шуны җырлый иде. Мин үзем дә гомерем буе шуны җырладым. Хәтта... кайгылы-күңелсез көннәрдә дә...

Ул кичне без шактый сөйләшеп утырдык. Безне шагыйрь Салих Баттал фотога төшерде. Бу фоторәсем әле дә альбомымда саклана.

Аннары да еш кына очраша идек. Кайсы чакларда (ләкин сирәк кенә) үткән хатирәләр кузгала иде. Хәсән абый Сталинның таш зинданнары, камералардагы пычраклык, кандала баскан ятаклар, анда аунап ятучы тоткыннар турында ачынып сөйләде. Аерата безгә тәэсир иткәне бернинди гаепсез, гонаһсыз тоткыннарны — Совет дәүләте өчен кулларына корал тотып дошманнарга каршы көрәшкән кешеләрне, әдәбият хезмәткәрләрен, артистларны, юристларны атып үтерүләре турында ачынып сөйләве булды.

— Сәгать төнге бердә атылырга тиешле тоткыннарны камерадан чакырып алып китәләр иде. Барлы-юклы иске-москы әйберләрен алып чыгарга кушсалар, аларның күзләреннән яшь чыга. Кайберләре безнең белән елап саубуллаша иде. Төрмә ишегеннән чыкканда: «Яшәсен Сталин!» — дип кычкыручылар да була иде. Без, тоткыннар, андый фанатикларны кызгана идек. Менә әле дә уйлап исем китә: без тоткыннар «даһи» Сталинга ышана, аны фанатикларча хөрмәт итәбез, ә ул палач безне аттыра, гаиләләребезне кан-яшь түктерә иде. Башта мин дә атылу статьясы белән утырган идем, соңыннан — Мәскәүдән ун елга төрмәгә утыртырга дигән карар килгәч кенә исән калдым.

Бу сүзләрне әйткәннән соң Хәсән абыйның күзләре яшьләнде. Ул авыр сулап сүзләрен дәвам итте:

— Кеше өчен гомер бик кадерле! Минем атылу статьясы ун елга төрмәгә утыртырга дигән хөкем карары белән алмашынып килгәч, шатлыгымнан еладым. Кеше ун ел утырырга мөмкин, ләкин бу әле үлем түгел. Әнә шул вакытта ук мин, гонаһсыз тоткыннарны бәлки акларлар да әле, дип уйладым. Иа хода, ул елларда нәрсә генә уйламадык без! Ач утырсак та, киләчәктә безне аңларлар, гонаһсызга утыручыларны аклап, бу таш капчыктан азат итәрләр, дип юана

идек. Сугыш башлангач «Үзем теләп алгы сызыкка китәм»,—дип берничә гариза яздым. Гариза хат белән җибәрелгәннән соң «Кайчан фронтка җибәрерләр икән?»—дип уйланулар, алгы сызыктан—хәрәкәттәге армиядән шигырьләр язып җибәргәннән соң Казандагы шагыйрь иптәшләрнең хәйран калып ул шигырьләрне укулары, кулга алынган «халык дошманы» Хәсән Туфан сугыш кырларында йөри икән, ут эченнән—окоплардан шигырьләр язып җибәргән, дип баш селкеп уйлануларын төшләремдә күрә идем. Шуны тоткын дусларыма сөйли идем. Тәрәзәгә карап, кызарып кояш чыгуларын моңланып күзәтә идем һәм үземне хәрби кием кигән, бүрегемә кызыл йолдыз таккан солдат итеп күз алдыма китерә идем. Әйе, тоткынлыкта төрле уйлар килә иде. Фронттан кайтып, кызым Гөлгенәне алдыма утыртып, башыннан сыйпап утыруларым да күз алдына килә иде...

...Шагыйрь Гали Хуҗи Казандагы завод газетасы каршындагы әдәбият түгәрәгенә шефлык итте. 1966 елны ул безне: Хәсән ага Туфанны, Мәҗит Рафиковны һәм мине шул түгәрәктәге яшь язучылар белән очрашуга чакырды. Хәсән абыйны бөтен зал кул чабып, аякка басып каршылады. Ул татар әдәбияты турында кереш сүз әйтте һәм үзенең яңа язган шигырьләрен укыды. Халык аны хөрмәтләп озатты. Кайткан вакытта бергәләп трамвайда кайттык. Яңа әсәрләр язуыбыз турында сөйләшә торгач, үзебезнең тукталышка җиткәнебезне сизми дә калганбыз. Трамвайдан төшеп җәяү генә киттек. Урамның икенче ягында фотография бар иде. Шунда килеп җиткәндә мин сүз башладым:

— Хәсән абый, бер истәлек булып калыр, әйдәгез әле, фоторәсемгә төшик.

— Дөрес әйтәсең, Самат. Дөньяны белеп булмый, иртәгә бәлкем йә мин, йә син булмас. Ә фоторәсем мәңгелек истәлек булып кала,—диде Хәсән Туфан. Мәҗит Рафиков та бу фикерне хуплады һәм без өчәүләп фоторәсемгә төштек. Менә ул рәсем:



*Рәсемдә: (сулдан уңга) Мәҗит Рафиков, Хәсән Туфан һәм Самат Шакир.*

1959 елның май аенда Казанда чуваш әдәбияты һәм сәнгате атналыгы булды. Безгә чуваш язучыларыннан Педер Хузангай, Ильбек Мигулайе, Александр Калган, Алексей Афанасьев, Стихван Шавлы, Николай Евстафьев, Василий Краснов-Аслы һәм башка иптәшләр килде. Язучыларның Тукай исемендәге клубында чуваш, татар һәм рус телләрендә чыгышлар булды. Чуваш артистлары үзләренең популяр җырларын җырладылар. Иртәгесе көнне без кунакларны Аккош күленә алып бардык. Кунаклар Аккош күленә килгәч, андагы гүзәллекне, татар язучыларының дачаларын карап йөрделәр, язу өчен матери-

аллар алдылар. Аннары бергәләп сөйләшә-сөйләшә чәй эчтек. Шунда ук шигырьләр укылды, истәлекләр сөйләнде. Соңыннан Казанга кайттык. Кунакларны «Казан» кунакханәсенә урнаштырып, үзебез җәяү гене Бауман урамы белән киттек. Шул чакта фотография яныннан үтеп бара идек, язучы Габдрахман Минский болай диде:

— Бер истәлек булыр, дуслар, әйдәгез әле фотога төшик.

Аның сүзенә барыбыз да кушылдык һәм фотографиягә кереп карточкага төштек. Бу күңелле һәм шатлыклы вакытлар әле дә онытылмас истәлек булып йөрәк түрендә саклана.



*Бу фотода (сулдан уңга) утырганнар: Абдулла Гомәров, Хәсән Туфан, Габдрахман Минский, Геннадий Паушкин. Икенче рәттә: Нури Арсланов һәм Самат Шакир.*

## Шамун Фидаиның тууына 90 ел

Унҗиденче ел революциясе һәм гражданнар сугышы елларында шигырь мәйданында ялтырап алган, таланты белән һәм шул чорның фаҗигале бер шәһите буларак ил-әдәбият тарихына кереп калган Шамун Фидаи атлы шагыйребез бар. Аның исеме белән без Муса Җәлил шигырендә дә очрашабыз: Әйе, «ил бәхете өчен»...

Шамун Фидаи (чын исеме Касыйм, Хәсән улы Шакирҗанов) 1902 елның 15 июнендә Оренбург шәһәрендә туган. Әтисе — чыгышы буенча Әтнә ягының Олы Бәрәзә авылыннан. Аның үз пекарнясы булып, яшь Шамун чагыштырмача хәлле тормышта үсә. Оренбургның бик дини мәдрәсәсендә укый. Әмма шаян, күпне белергә омтылучан, китап җене кагылган малай була. Шәкертләр хәрәкәтендә катнаша, революция булгач, төрле митингларга йөри, кыскасы, яшьтән үк үзен иҗтимагый актив тормышка әзерли.

1917-18 елларда ул Уфада — атаклы «Галия» мәрдәсәсендә укый. М. Гафури, Ш. Бабич кебек шагыйрьләр белән аралаша, мәдрәсәдәге кульязма журналларда («Парлак», «Бораү») беренче шигырьләре белән катнаша. Аннан «Алга» газетасында (татар-башкорт большевиклары органы) басыла башлый, җөмләдән «Сугыш, тукта!» исемле нәсере шунда дөнья күрә. 1918 елның көзендә Уфада революцион яшьләр, гаскәриләр арасында җәмәгать эшләре алып бара, спектакльләр, әдәби кичәләр оештыра. «Шамун Фидаи» имзасы «Кызыл яу» газетасында да еш күренә. Аклардан качып, шул газета идарәсе белән Бәләбәйгә китә, аннан Оренбургка күчә. Колчак һәм Дутовка каршы көрәштә, урындагы яшьләр хәрәкәтендә актив катнаша.

1920 ел башыннан ул яңадан Уфада. Яшьләр союзының губерна комитетында әгъза була, «Яшь коммунист» газетасын чыгаруда башлап йөри, шунда мәкаләләрен, шигырьләрен бастыра. Ул Комсомолның III Бөтенроссия съездына делегат итеп сайлана, әмма анда катнаша алмый... Июль урталарында бер иптәше белән Уфадан комсомол эше белән авылларга дип юлга чыккач, аларны Айгалыш урманында кулаклар үтерәләр. Кабере — Камышлы авылы янында.

Шулай итеп, яшь шагыйрь революция көрәше корбаннарының берсе була. Аның үлеме дә, иҗаты да, бүгенге көн үзгәрешләре яктылыгыннан караганда, төрле фикерләр, карашлар тудырырга мөмкин. Әмма шунсы бәхәссез: унсигез яшьлек шагыйрь вакытсыз һәлак була. Шәехзадә Бабич, Даут Гобәйдиләр кебек... Шагыйрьнең шәхесе, иҗаты турында замандашларыннан М. Гафури, С. Агиш, Р. Ишморатлар безнең көннәрдә Б. Камалов һ. б. истәлекләр, мәкаләләр яздылар. Күренекле шагыйребез Роберт Әхмәтҗан исә, аңа багышлап, «Фидаи» балладасын иҗат итте. Ниһаять, соңгы елларда прозаик әдип Фәнил Мансуров Ш. Фидаи турында күләмле әсәр язып бастырды.

Димәк, шагыйрь — дәвам итә...

## ЮГАРЫ СОВЕТ ҖЫЕНЫ

Май аенда Татарстан Югары Советының унынчы сессиясе эшләде.

Аның көн тәртибендә Татарстан Республикасы Конституциясе проектын, телләр турында закон проектын тикшерү, хокук саклау органнарын республика юриспруденциясенә күчерү, республика бюджетын раслау һ. б. мәсьәләләр кертелгән иде. Сессиядә шулай ук үткән референдум йомгаклары турында да сүз барды. Татарстаннан хәрби хезмәткә чакырылучы егетләр язмышы да тикшерелде. Тикшерелгән мәсьәләләр буенча кабул ителгән карарлар матбугатта басылды.

Сессия тәнәфес игълан итте.

## ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ СЪЕЗДЫ

23 май көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстан халыкларының съезды булып узды. Аны кереш сүз белән республикабызның вице-президенты В. Лихачев ачты. Съезд делегатларын һәм кунакларны Татарстан Президенты М. Шәймиев котлады. Доклад белән Татарстан Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин чыкты.

Татарстан халыклары съезды Белдерү, Татарстан халыкларына мөрәҗәгать, Татарстан Республикасы Президентына, Югары Советына һәм Премьер-министрга мөрәҗәгать, шулай ук Милли-мәдәни җәмгыятьләр ширкәте төзү турында резолюция кабул итте.

## ТАТАРСТАН БМО ИШЕГЕН ШАКЫРМЫ?

13 май көнне Татарстан Президенты М. Шәймиев Берләшкән Милләтләр Оешмасына кермәгән халыклар һәм милләтләр оешмасы рәисе Л. Мяллны кабул итте. Мялл әфәнде Президентны халыклар мәнфәгатен яклаучы бу оешманың максат һәм бурычлары, шулай ук Эстониядәге сәяси һәм икътисади хәл белән таныштырды.

Президент референдумнан соң Татарстанда бара торган хәлләр, республика халыклары арасында бердәмлекнең көчәя баруы, икътисад һәм бигрәк тә авыл хуҗалыгы өлкәсендә күрелә торган нәтиҗәле чаралар хакында сөйләде. Эстониянең теләген хуплап, М. Шәймиев Татарстанның бу дәүләт белән озак вакытлы һәм ике якка да файдалы икътисади хезмәттәшлеккә әзер торуын белдерде.

Икенче көнне Мялл әфәнде республиканың милли хәрәкәт вәкилләре белән очрашты. Кайбер информация агентлыклары хәбәр итүенә караганда (мәсәлән, «Известия» газетасында Интерфакс агентлыгы хәбәре басылды), Л. Мялл Татарстанның Берләшкән Милләтләр Оешмасына әгъза булып алынуына һәрьяклап булышачагын да белдергән.

## М. САБИРОВНЫҢ Е. ГАЙДАР БЕЛӘН ОЧРАШУЫ

7 һәм 8 май көннәрендә Татарстан Республикасы Премьер-министры М. Сабиров Мәскәүдә булды. Беренче көнне ул Россия Федерациясе хөкүмәте утырышында катнашты. Икенче көнне М. Сабиров белән Россия Федерациясе хөкүмәте вәкиллегенең беренче урынбасары Е. Гайдар арасында озакка сузылган әңгәмә үткәрелде.

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе арасында 1992 елның 22 гыйнварында Мәскәүдә төзелгән икътисади килешүне үтәүнең барышы, шулай ук ике республика арасында үзара мөнәсәбәтләрне тирәнәйтә бару турында өстәмә мәсьәлә тикшерелде.

Шулай ук Алабуга автомобиль заводында яңа ВАЗ-2411 маркалы җиңел машина эшләп чыгаруны тизләтү, Казан авиация җитештерү берләшмәсендә ТУ-204 пассажир лайнерын серияләп ясауны оештыру мәсьәләсе буенча да ике җитәкче арасында җентекле сөйләшү булды. Татарстан нефте һәм тагын башка проблемалар да ике якның игътибарыннан читтә калмады.

## ВӘКИЛЛЕКЛӘР БУЛДЫРЫЛА

Республикабыз тулы хокуклы һәм бәйсез дәүләткә әверелү юнәлешендә бер-бер артлы һәм эзлекле адымнар ясый. Президент М. Шәймиевнең 21 апрельдә кабул иткән Указы да әнә шул фикерне раслый. Бу Указ нигезендә Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә керүче илләрдә һәм шулай ук башка дәүләтләрдә дә Татарстан Республикасының вәкиллекләре оештырылачак. Халыкара элемтәләрне көйчәтү өчен бу, әлбәттә, бик тә мөһим һәм вакытлы чара. Матбугатта басылган хәбәрләр әйтүенчә, шулай ук республиканың Тышкы эшләр министрлыгы да төзеләчәк.

## ГАГАУЗЛАР МӨРӘҖӘГАТЕ

Гагауз республикасы Югары Советының Татарстан Югары Советына мөрәҗәгате матбугатта басылып чыкты. Анда мондый сүзләр бар: «1990 елның 19 августында яңартылган Союз составында Гагауз республикасы игълан ителгән иде. 1991 елның декабрендә республиканың бәйсезлеге һәм Президент сайлау буенча бөтенхалык референдумы уздырылды. Референдумда катнашучыларның 95,3 проценты Гагауз республикасының Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә керүе яклы бул-

ды. Гагауз республикасы президенты өчен 96,6 процент сайлаучы тавыш бирде. Аңа кадәр — 1991 елның ноябрендә Гагауз Республикасының Конституциясе кабул ителде.

Безнең халыкларның тарихи тамырлары бер булуны, бәйсезлекне һәм үз язмышларын үзләре хәл итү теләген искә алып, мөстәкыйль республикалар һәм дәүләтләр бары тик берләшә алсалар гына чын бәйсезлеккә ирешә алганлыкларын аңлаган хәлдә, Гагауз Республикасының Югары Советы сезнең Югары Советыгызның чираттагы сессиясендә Гагауз Республикасының бәйсезлеген тану мәсьәләсен тикшерү, ике республика арасында сәяси һәм икътисади хезмәттәшлек килешүен төзүне сорап мөрәҗәгать итә».

## ТЕАТР ЮБИЛЕЕ

Моннан ике гасыр элек, ягъни 1792 елда Казан губернасының баш шәһәрендә беренче рус театры оеша. Ә быел исә Качалов исемендәге рус зур драма театры үзенең 200 еллык бәйрәмен үткәрде. Төрле иҗат берлекләре, хезмәт оешмалары вәкилләре, җөмһүриятебез һәм шәһәр җитәкчеләре иҗат әһелләрен зур бәйрәмнәре белән кайнар котладылар. Татарстан Республикасының вице-президенты В. Лихачев Президентыбыз М. Шәймиевнең театрны республиканың Мактау грамотасы белән бүләкләү хакындагы Указын игълан итте. Театр коллективын шулай ук Премьер-министр М. Сабиров котлады.

## ЯҢА ДОКТОРЫБЫЗ БУЛДЫ

23 апрельдә Казан дәүләт университетының филология фәннәре буенча махсус советында татар әдәбияты кафедрасы доценты Резеда Ганиева «Көнчыгыш ренессансы һәм аның төрки әдәбиятлардагы традицияләре» дигән темага филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсен алу өчен диссертация яклады.

## ЦИРК — ҮЗЕБЕЗНЕКЕ!

Республика территориясенә урнашкан яңадан-яңа оешмалар һәм предприятиеләр Татарстан юрисдикциясенә күчә бара. Күптән түгел Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Казан дәүләт циркын республика юрисдикциясенә күчерү һәм аны республика Мәдәният министрлыгы карамагына бирү турында карар чыгарды.

## ӘДӘБИ ГАЗЕТАНЫҢ БЕРЕНЧЕ САНЫ

Башка милләтләрнеке сыман, әдәби газета булдыру хакындагы сүзләр язучылар арасында күптән йөри иде инде. Аны оештырырга дигән карар 1989 елны булып узган соңгы съездыбыз резолюциясенә дә кертелгән. Һәм менә, ниһаять, 24 апрельдә әдәби газетаның беренче саны дөнья күрде. Ләкин әлегә бу сынау саны гына. Шуңа күрә тиз арада бүтән саннарын да күрербез дигән ышаныч әлегә юк. Әмма басылып чыккан сан бай эчтәлекле. Анда күп гасырлык татар әдәбиятының үткәне дә, бүгенге көннең кайнар сулышы да әйбәт чагылыш тапкан.

## АФӘРИН, ВАФИРӘ!

Май аеның ямьле кичләренең берсендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында халкыбызның яраткан җырчысы Вафирә Гыйззәтуллинаның бенефисы — иҗат отчеты зур уңыш белән үтте. Татарстанның халык артисты исемен йөрткән атаклы җырчыны язучылар, күренекле җырчылар, биючеләр һәм күп санлы тыңлаучылар кайнар котлады. Аны котларга җырчының якташлары да килгән иде. Бу кичә чын мәгънәсендә җыр һәм шатлык бәйрәменә әверелде.

## ГАЛИМЕБЕЗ — ТӨРЕК ЖУРНАЛЫНДА

Журналыбызның узган елгы 6 санында филология фәннәре докторы, профессор Яхъя Абдуллинның «Чишелмәгән төеннәр» исеме белән мәдәни мирасыбызны һәм татар-башкорт мөнәсәбәтләрен яктыртуга багышланган мәкаләсе басылган иде. Төркиядә чыга торган «Төрек дөньясы араштырмалары» исемле журналның 1992 елда чыккан 76 санында әлеге мәкаләнең төрекчәгә тәрҗемәсе дөнья күрде.


## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Беренче биттә:** «Диңгез буенда». Санкт-Петербург рәссамы Рәшит Дәминов эше.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фоторепродукциясе.

Дүртенче биттә: күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе, М. Җәлил бүләге лауреаты Ренат Харис.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосурәте.



**Мирсәет Солтангалиев**
**(1892—1940)**

Бәясе 1 сум 80 тиен

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог